Әдәбияттан хрестоматия

9

МӘГАРИФ НӘШРИЯТЫ

Әдәбияттан хрестоматия 9

Укуга, белемгә тылмач ул бу тел,
Кешене нурлаган нәрсә тел ул — бел.

Йосыф Баласагунлы.
XI йөз

Әдәбияттан хрестоматия

(БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР,
XIX ЙӨЗ ӘДӘБИЯТЫ)

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
9 нчы сыйныфы өчен

*Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
тарафыннан тәкъдим ителгән*

Өченче басма

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2005

УДК 373.167.1:821.512.145*09
ББК 84(2Рос=Тат)я721
Ә26

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Әдәбияттан хрестоматия: Татар урта гомуми белем
Ә26 бирү мәкт. 9 нчы с-фы өчен / Төз. Х. Й. Миңнегулов, Ш. А. Садретдинов.— 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005.— 495 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1451-9

ISBN 5-7761-1451-9

© «Мәгариф» нәшрияты, 2000, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Хрестоматия татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен әдәбияттан программа нигезендә һәм дәреслеккә (Миңнегулов Х. Й., Садретдинов Ш. А. Әдәбият: Борынгы һәм урта гасыр, XIX йөз әдәбияты. Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 9 нчы сыйныфы өчен дәреслек.— 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2005) туры китереп төзелде. Җыентыкка Борынгы һәм урта гасыр, XIX йөз татар әдәбиятының иң әһәмиятле дип табылган әсәрләре кертелде. Күп кенә әсәрләр, аеруча күләмле текстлар кыскартылды. Кыскартылган урыннарга күп нокта (...) куелды яисә җәяләр эчендә мондый өлешләрнең кыскача эчтәлеге бирелде.

Борынгы һәм урта гасыр, XIX йөз әдәби әсәрләренең теле күпчелек очракта хәзерге заман укучысына авыр аңлашыла. Шуңа күрә хрестоматиядә текстларны бирүдә берничә төрле алым кулланылды:

1) Әдипнең тел-стиль үзенчәлекләре белән таныштыру максатында, текстны нәкъ үзендәгечә саклап, аңлашылмаган сүзләргә аңлатмалар астөшермәдәге сүзлектә бирелде.

2) Мондый сүзләр шактый күп булганда, автор текстыннан соң әсәрнең төзүчеләр эшләгән яки башка әдипләр тарафыннан башкарылган тәрҗемәләре урнаштырылды.

3) Кайбер әсәрләрнең оригиналлары бирелмичә, тәрҗемә текстлары гына алынды. Рифма-ритмга салынган мондый тәрҗемәләр хрестоматияне төзүчеләр тарафыннан да башкарылды (Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Гали Чокрый шигырьләре һ. б.).

4) Кайбер әсәрләрдә, авторның тел-стиль төсмерләрен, үзенчәлекләрен нигездә саклаган хәлдә, авыр аңлаешлы сүзләр һәм

гыйбарәләр, сүзлеккә төшерелмичә, текстның үз эчендә үзгәртелде (Муса Акъегетзадә, Ризаэддин Фәхреддин, Акмулла һ. б.). Аерым текстлар билгеле бер дәрәҗәдә хәзерге телгә һәм орфографиягә якынайтып алынды.

Элек авторлар күп очракта шигырьгә исем куеп тормаганнар. Мондый шигырьләргә һәм зур әсәрдән алынган өзекләргә төзүчеләр куйган исемнәр бирелде, алар квадрат җәяләр ([ ]) эченә алынды.

Әлеге хрестоматия программада каралган барлык әсәрләрне дә тулы килеш чагылдыра алмый, әлбәттә. Әмма күп кенә әдипләрнең безнең заманда басылып чыккан китаплары, җыентыклары бар (Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г. Утыз Имәни, Г. Кандалый, К. Насыйри, З. Бигиев, З. Һади, Ш. Мөхәммәдев һ. б.). Ике томлы «Татар поэзиясе антологиясе» нәшер ителде (1992). Мондый басмалар киләчәктә дә дөнья күрер. Без сезгә, бу хрестоматия белән генә чикләнеп калмыйча, шушы китапларның үзләрен алып укырга киңәш итәбез. Шул чакта безнең үткәндәге әдәбиятыбыз хәзинәләре сезнең алда тагын да тулырак, тагын да мулрак ачылыр, рухи җәүһәрләребез яктырак балкыр, акыл, зиһен һәм күңел офыкларыгыз киңәеп китәр.

БОРЫНГЫ ҺӘМ УРТА ГАСЫР ӘДӘБИЯТЫ

БОРЫНГЫ ТӨРКИ РУН ЯЗМАЛАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

(VI—VII гасырлар)*

* * *

...Йөз йәшәйен! Тәңрем — очук безкә. Идел-йәремә — бәңгү бал!

Тәрҗемәсе:

...Йөз яшә (йөзгә кадәр яшим)! Тәңрем — безгә таяныч (учак, йорт, «очаг», саклаучы). Идел-җиремә — мәңгелек һәйкәл (балбал)!

* * *

Энем йите, урым өч, кызым өч әрти. Әбләдем углымын. Кызымын калыңсыз биртем...

Тәрҗемәсе:

Энем җиде, улларым өч, кызым өч иде. Улларымны өйләндердем. Кызларымны калымсыз бирдем...

* * *

Сеземә, йөз кадашыма, алты будуныма, сеземә адрылтым.

Тәрҗемәсе:

Сездән, йөз дустымнан, алты ыруымнан (халкымнан), сездән аерылдым.

---

* *Малов С. Е.* Енисейская письменность тюрков: Тексты и переводы.— М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1952.— С. 66, 84—85.

КҮЛТӘГИН ЯЗМАСЫ (732—735 еллар)

*(өзекләр)**

...Ерак әрсәр йаблак агы бирүр.
Йагык әрсәр әдгү агы бирүр.

Тәрҗемәсе:

...Ерактагыңа начар бүләк бирер(ләр),
Якындагыңа затлы бүләк бирер(ләр).

* * *

Чыгаң будуныг бай кылтым,
Аз будуныг үкеш кылтым.

Тәрҗемәсе:

Ярлы халыкны бай кылдым,
Аз халыкны күп кылдым.

* * *

...Иллег будун әртем,—
Илем амти каны?..
Каганлыг будун әртем,—
Каганым каны?..

Тәрҗемәсе:

...Дәүләтле (илле) халык идем,—
Илем инде кайда?..
Каганлы халык идем,—
Каганым кайда?

* * *

...Каным каган сүсе бүре әрмеш,
Йагысы коң тәг әрмеш.

Тәрҗемәсе:

...Атам каган гаскәре бүре (кебек) иде,
Дошманнары куй кебек иде.

---

* *Стеблева И. В.* Поэтика древнетюркской литературы...— М.: Наука, 1976.— С. 175—197.

* * *

...Кыркыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы — күп йагы әрмеш.

Тәрҗемәсе:

Кыргыз, курыкан, утыз татар, кыдан, татабы — бары да дошман иде.

* * *

...Каның субча йөгертте,
Сөңүкең тагча йатды,
Бәгелег ари углың кол булты,
Сөлек кыз оглы коң булты...

Тәрҗемәсе:

...Каның суча (су кебек) акты,
Сөягең таудай ятты (өелде),
Бәктәй саф (затлы) ул(лар)ың кол булды,
Сөлектәй кыз балаларың кәнизәк булды...

* * *

...Күрер күзем күрмәз тәг,
Белер белегем белмәз тәг булды.

Тәрҗемәсе:

...Күрер күзем күрмәс,
Белер белегем белмәс булды.

ЮРАУ КИТАБЫ (IX гасыр)

(өзекләр)

Әр бушушлуг, тәңре болытлыг булды. Ара көн тугмыш. Буша(н)нч ара мәңи кәлмештер. Анча белеңләр: әдгү ол!

Тәрҗемәсе:

Кеше кайгылы, күк болытлы иде. Арада (алар арасында) кояш чыкты. Кайгы арасына шатлык килде. Шуны белегез: яхшыга (игелеккә) ул!

* * *

Су тамыры корыйсәр,—
Яшь явышгу корыйыр.
Кеше көче корыйсәр,—
Ят кешегә басытыр.

Тәрҗемәсе:

Су юллары корыса,—
Яшь яфрак та корыйдыр.
Кеше көче корыса,—
Ят кешедән басылыр.

Мәхмүд Кашгарый

(XI йөз)

ДИВАНЕ ЛӨГАТЕТ-ТӨРК (1072—1074)

*Мәкальләр һәм әйтемнәр**

Атасы ачыг алымла йийсә, углының теше камар. [Атасы ачы алма ашаса, улының теше камашыр.]

Ач ни йиймәс, тук ни тимәс. [Ач ни ашамас, тук ни димәс.]

Бер карга берлә кыш килмәс.

Бер төлкү тиресен икилә суймас. [Бер төлке тиресен ике мәртәбә тунамыйлар.]

Боздан сув тамар.

Йыгач озын кис, тимүр кысга кис. [Агачны озын кис, тимерне кыска кис.]

Йыгач очына йил тигер, күрклек кешегә сүз килер. [Агач очына җил тияр, матур кешегә сүз килер.]

Канигъ кан белә йумас. [Канны кан белән юмыйлар.]

Куш кылыч кынга сыгмас. [Куш кылыч кынга сыймас.]

Кыш конукы — ут. [Кыш кунагы — ут.]

Күздән йыраса, күңелдән йемә йырар. [Күздән ерагайса, күңелдән дә ерагаер.]

Көнгә бакса, күз камар. [Көнгә (кояшка) бакса, күз камашыр.]

Тегермәндә тугмыш сычган күк күкрәгеңә курыкмас. [Тегермәндә туган тычкан күк күкрәгәннән курыкмас.]

Олыгны олыгласа, кот (бәхетле.— *Х. М.*) булыр.

---

* *Мәхмутов Х.* Тугыз гасыр кичкән мәкальләр //Мирас.— 1992.— № 5.— 91—99 б.

*Шигырьләр**

[Каты юллар йомшара]

Йалвын анық күзе,
Йалкын анық үзе,
Тулун айын йөзе —
Йарды мәнеқ йөрәк.

Әйдем ақар: «Сәвүк,
Безни таба нәлүк,
Кичтеқ йазы кәрик,
Кырлар әзиз бәзүк?»

Әйде: «Сәнеқ узу —
Әмгәк тәлим ызу,
Йомшар катыйг узу,—
Күқлем сәқа йөгрек».

Тәрҗемәсе:

Сихерле анық күзе,
Ялкынлы анық үзе,
Тулган айдай йөзе —
Телгәләде йөрәгемне.

Әйттем ақар: «Сөеклем,
Безгә таба ничек
Кичтеқ киқ дала(лар)ны,
Кырларны, биек тауларны?»

Әйтте: «Сиқа килү юлы (узу) —
Күп газаплы үзе,
(Әмма) йомшый каты юл да,
(Чөнки) күқлем сиқа ашкына».

* *Стеблева И. В.* Развитие тюркских поэтических форм в XI веке.— М.: Наука, 1971.

* * *

Йәй күркенә инанма,
Сувлар үзә таянма,
Әсизлигиг анунма,
Телдә чыкар әдгү сүз.

Тәрҗемәсе:

Җәй (яз) күркенә ышанма,
Су өстенә таянма,
Явызлыкка алынма,
Телеңнән яхшы сүз (генә) чыгар.

* * *

Бирмеш тавар — сәнең, бел,
Йалыңук табар карынка.
Калмыш тавар — ажунның,
Керсә кара урынга.

Тәрҗемәсе:

Биргән мал — синеке,
Кеше карынга табына.
Калган товар — дөньяныкы
(башкаларныкы),
(Әгәр дә) керсә (кеше) кабергә.

Йосыф Баласагунлы

(XI йөз)

КОТАДГУ БЕЛЕК* (1069)

Тел турында

...Укушка, белегкә бу телмәчи тел,
Йарутгачы ирне йорук телен, бел.
[Укуга, белемгә тылмач ул бу тел,
Кешене нурлаган нәрсә тел ул — бел.]

Кешег тел агырлар, булыр кот кеше,
Кешег тел очызлар, йарыр ир башы.
[Кешене тел хөрмәтле, бәхетле итәр,
Кешене тел очсызлар, башын ярыр.]

Тел арслан торыр, күр, ишекдә йатар,
Әйа эвлүг арсык — башыңны йийәр.
[Тел ишектә (читлектә) яткан арслан кебек ул,
Аның белән бераз гына саксызлык башыңны ашар.]

Телен имгәмеш ир никү тәр, ишит,
Бу сүз эшкә тотгыл, үзеңә иш ит:
[Начар телле ир ни дип әйтә, ишет,
Бу сүзне гамәл кыл, үзеңә иш ит:]

---

* *Юсуф Хос Хожиб*. Кутадгу билиг.— Тошкент: Фан, 1971.— 84—88, 656—659, 666—667, 934—939 б.

«Мәне имгәтер тел иди үк тәлим,
Башым кисмәсене кисәен телем».
[«Мине тел күп бәлаләргә сала,
Башым киселгәнче, (мин) телемне кисәм».]

Сүзеңне күдәзгел, башың бармасын,
Телеңне күдәзгел, тешең сынмасын.
[Сүзеңне күзәт, башың китмәсен,
Телеңне тый, тешең сынмасын.]

Будун теле йаулак — сине сүзләгәй,
Кеше кылкы киртүч — итеңне йиийгәй.
[Халыкның теле яман — сине сүзләгәй (гайбәтеңне),
Кешенең холкы киртле (начар)— итеңне ашар...]

Исәнлек теләсә синең бу үзең,
Телеңдә чыкарма йарагсыз сүзең.
[Син үзеңә исәнлек теләсәң,
Телеңнән яраксыз сүз чыгарма.]

Белеб сүзләсә, сүз белегкә саныр,
Белегсез сүзе үз башыны йиийыр.
[Белеп сүзләсә, сүз акыллыга (белемлегә) саналыр,
Наданның сүзе үз башына җитәр.]

Үкеш сүздә артык асигъ күрмәдем,
Йәнә сүзләмешендә асигъ булмадым.
[Күп сүздә артык файда күрмәдем,
Янә (күп) сөйләшүдән файда алмадым.]

Үкеш сүзләмә сүз, берәр сүзлә аз,
Төмән сүз төгенен бу бер сүздә йаз.
[Күп сөйләмә сүз, бераз (гына) сөйлә,
Ун мең сүз төенен бер сүз белән яз (чиш).]

Кеше сүз белә күпты, булды мәлик,
Үкеш сүз башыг йиргә кылды күлик.
[Кеше сүз белән күтәрелде, хөкемдар булды,
Күп сүз башны җиргә идерде (башны җирнең күләгәсе итте).]

Үкеш сүзләсә, «йаңшады,— тир,— теле»,
Йәнә сүзләмәсә, «агын»,— тир кеше.
[Күп сөйләсә, әйтерләр: «теле йомшарды (бушка әйләнде)»,
Янә сөйләмәсә, «телсез»,— дип әйтерләр.]

Кали мондаг ирсә, йорык утру ор,
Йорык утру орса, кешег йөкөтер.
[Әгәр алай икән, урталыкны тот,
Урталыкны тотса, кеше күтәрелер.]

Телег кәд күдәзгел, күдәзелде баш,
Сүзеңне кысыргыл, оза(й)тылды йәш.
[Телеңне кыска тот, баш(ың) сакланыр,
Сүзеңне аз сөйләсәң, гомереӊ озынаер.]

...Нәчә мондаг ирсә, белеб сүзлә сүз,
Сүзең булсы(н) күрсү карагыка күз.
[Әгәр шулай икән, сүзеңне белеп сөйлә,
Сүзең күзсезгә күз кебек булсын.]

Белегсез карагы торыр, билгелүг,
Йөре, әй белегсез, белег ал өлүг.
[Белемсез сукыр торыр, һичшиксез,
Кил, әй надан, белемнән өлеш ал.]

Тугуглы үлер, күр, калыр билгесез,
Сүзең идгү сүзлә, үзең үлгесез.
[Туган (кеше) үләр, күр, калыр билгесез,
Изге сүз сөйләсәң, үлмәссең үзең.]

Ике нәң белә ир карымаз үзе,
Бер — идгү кылынычы, бер — идгү сүзе.
[Ике нәрсә белән кеше үзе картаймас,
Бере — күркәм холкы, бере — изге сүз.]

Кеше тугды, үлде, сүзе калды, күр,
Үзе барды йаңлук, аты калды, күр.
[Кеше туды, үлде, сүз калды, күр,
Үзе киткәч тә (яхшы) исеме калды, күр.]

Тереглег теләсә үзең үлмәгү,
Кылынчың, сүзең идгү тот, әй бәгү...
[Үзеңә бетми торган тереклек теләсәң,
Холкыңны, сүзеңне изге тот, әй акыл иясе...]

Белем турында

...Белег бирде йаңлук бәдүде бу көн,
Укуш бирде өтрү йазылды төген.
[Белем бирде, (шуның белән кеше) бу көн бөеклеккә иреште,
Уку аркасында күп төеннәр чишелде...]

...Белегне бәдүг бел, укушны олуг,
Бу икке бәдүтер әдүрмеш колуг.
[Белемне бөек, укуны олуг бел,
Бу икегә коллык кылган бөек булыр...]

...Белек мәгънәсе, бел, никү тир белег:
Белек белсә өтрү йырар ирдә иг.
[Белем мәгънәсен бел, ни дип әйтер белем:
Белем белгән кешедән бәла-казалар ераклаша.]

Белексез кеше барча иглиг булыр,
Игиг имләмәсә, кеше тәрк үлер.
[Надан кешеләрнең барчасы авыру була,
Чирен дәваламаса, кеше бик тиз үлә.]

Йөре, әй белексез, игеңне ута,
Белексез онытсән, и билгә кота.
[Кил, әй надан, авыруыңны дәвала,
Белемсез (икәнсең) — түбән син, белемле (икән) — бәхетле.]

Укуш ул борындык, аны йитсә ир,
Теләккә тигәр ул төмән арзу йир.
[Белем ул (гүя) тезген (йөгән; ияр), әгәр дә кеше аны
элэктерсә,
Теләгенә ирешеп, күп максатларын гамәлгә ашырыр.]

Укуш булса иргә, кұр, асгы үкеш,
Белек белсә, өтрү булыр ир көшеш.
[Белем булса кешедә, күр, (ул) күп файдалыдыр,
Белем белсә, кеше кадерле буладыр.]

Укуш берлә эшләр камуг эш көдүг,
Белек берлә бикләр бу булмыш өдүг.
[Белем белән барлык эшләр гамәлгә ашар,
Гыйлем белән бикләр максатларына ирешә.]

Шагыйрьләр белән аралашу турында

...Баса килде шагыйрь — бу сүз тергүче,
Кешег үггүчеләр йәмә йәргүче.
[Янә килде шагыйрь — ул сүз тезүче,
Кешене мактаучы һәм дә сугүче.]

Кылычта йәтигрәк боларның теле,
Йәнә кылда йинчкә бу хатыйр йулы.
[Кылычтан үткенрәк боларның теле,
Янә кылдан нечкәрәк хәтер юллары.]

Татыг, йинчкә сүзләр укайын тисә,
Болардин ишет сүз, укылгай баса.
[Татлы, үткен сүзләр белим дисәң,
Боларны тыңла, аларның сүзләре җиңел төшенелә.]

Тиңизгә керер күрсә күңлен төгәл,
Гүһәр, йенҗү, йакут чыкарыр мәсәл.
[Күрсәң: алар күңел диңгезенә тәмам керерләр,
(Аннан) гәүһәр, энҗе, якутларны чыгарырлар.]

Улар үксәләр, үкде илкә барыр,
Калы сүксәләр, аты артыб калыр.
[Алар мактасалар, мактаулары илгә таралыр,
Әгәр сүксәләр, (кешенең) яманаты калыр.]

Уса, идгү тоттгыл боларны, кадаш,
Боларның телենгә эленмә, адаш.
[Уйла, яхшы тот боларны, кардәш,
Боларның теленә эләкмә, адаш.]

Калы идгү үгде теләсә үзең,
Боларны сәвендер, киселде сүзең.
[Әгәр яхшы мактау сүзләре теләсәң үзең,
Боларны сөендер, бетте-китте сүзем.]

Никү кылса, биргел боларка төгәл,
Боларның телендин үзең сатгын ал.
[Ни сорасалар, бир аларга төгәл,
Боларның теленнән үзеңне коткарып кал.]

Һөнәрчеләр белән мөгамәлә кылу турында

...Тәкый бер котысы бу узлар торыр,
Терелгү теләб үзгә узлук кылыр.
[Янә бер төркеме бу һөнәр ияләре торыр,
Яшәр өчен (алар) осталык кылыр.]

Кирәклек кешеләр йәмә бу сиңа,
Йакын тот боларыг, тосулгай тоңа.
[Болар сиңа шулай ук кирәкле кешеләр,
Аларны якын тот, (алар сиңа) файда китерерләр.]

Тимерче, итекче йәнә кырмачы,
Йә сырчы, бидезче, йә укчы, йачы.
[Тимерче, итекче һәм дә кыручы (столяр),
Йә буяучы, бизәүче, яисә ук-җәя ясау остасы.]

Бу дөнья йитеге болардин торыр,
Ажунда таң эшләр болардин торыр.
[Бу дөнья байлыгы алардан торыр,
Галәмдә таң (калырдай) эшләр болардан булыр.]

Боларның белә ма катыл һәм карыл,
Сэвендер уларыг сэвенечен терел.
[Болар белән катыш һәм аралаш,
Аларны сөендер — (үзең дә) сөенеч белән яшәрсең.]

Эшең кылсалар, тәрк тирен тигрү бир,
Йийдыргыл, эчергел ашың кинрү бир.
[Эшеңне башкарсалар, бик тиз тиешле хакын бир,
Ашат, эчерт, ашларын мул итеп бир.]

Әйеңләмәсенләр сине халык ара,
Атың артмасын моны кәд күрә.
[Сөйләмәсеннәр синең хакта (гайбәт) халык,
Яманатың чыкмасын, моны яхшы бел.]

Йәмә йакшы әймеш белеклек сүзег,
Будунга багырсак, ни күңле төзек:
[Ничек яхшы әйткән белек иясе сүзне,
Халыкны яратучы вә күңеле төзек кеше:]

«Тереклек теләмә, ат әдгү теләә,
Ат әдгү кирәк бу терекле белә.
[«Тереклек түгел, ә изге ат (исем) телә,
Бу тереклеккә изге ат кирәк.]

Үзең үлгү, ахыр бу атың калыр,
Атың әдгү булса, тереглек татыр.
[Үзең үләрсең, ахырда изге исемең калыр,
Атың изге булса, тереклек татлыдыр.]

Кемең аты әсиз булыб артаса,
Аңар йегрәке ул терек тормаса.
[Кемнең аты яман булып калганчы,
Аның өчен тере тормавы яхшырактыр.]

Мүн — ул тереклек, телә әдгү ат,
Эсиз кылма, әдгү кылын мәңү ат».
[Бу тереклек — бозыклык, телә изге ат,
Үзеңне пычратма, изгелек кыл, (шунда сиңа) — яхшы исем!»]

Яшьлекне сагыну һәм картлык турында

Йөрегле болыт тик, йегетлекне идтем,
Төби йил кичәр тик, тереклек төгәттем.
[Аккан болыт кебек, яшьлекне үткәрдем,
Искән җил-давыл кебек, гомерне уздырдым.]

Эсизем йегетлек, эсизем йегетлек,—
Тота белмәдем мин сине, тәрк качыттым.
[Яшьлегем үкенечле, яшьлегем үкенечле,—
Тота белмәдем мин сине,— тиз качырдым.]

Йәнә килгел имди, йегетлек, мәңа син,
Айада тотайын, агы, җөз түшәттем.
[Янә кайт инде, яшьлегем, миңа син,
Кадерләп тотармын, ефәк-парчаларга гына салып.]

Эсиз бу йегетлек каны, канча барды? —
Теләб булмадым мән ничә ма теләттем.
[Бу яшьлек эзсез генә (сиздермичә) кая, кайчан китте? —
Эзләп таба алмадым,— никадәр теләсәм дә.]

Тереклеккә татгы сөчек, җан сәвенче,
Йегетлек тик әдгү йук ирмеш әйеттем.
[Яшәешкә татлы эчемлек, җан сөенече,
Яшьлектән башка нәрсә юк икәнен белдем инде.]

Кечеклек татыгы, йегетлек эрәҗе
Йиттердем мән имди тотарда күрәттем...
[Сабыйлык татысын, яшьлекнең рәхәтен
Мин инде югалттым, тотар мәлдә качырдым...]

...Әсиргәб ачырмән сәңа, әй йегетлек,
Камуг күркеме сән йыраттың, йыраттым.
[Үкенәм, ачынам сиңа, әй яшьлегем,
Һәммә күркемне син үзләштереп качтың, (ә мин) югалттым.]

Тәмам аргуван тик кызыл миңзем ирде,
Бу көн зәгъфәран оргын иңдә тарыттым.

[Тәмам алсу төстә иде минем йөзем,
Бу көн аңа инде сары төсне сиптем.]

Йыпарсыг кара башка кафур эшедем,
Тулун тик талу йөз кайука иләттем?
[Җәфардай кара башыма (ак) кафур бөркедем,
Тулган айдай матур йөземне кайда калдырдым?]

Йарук йаз тик ирдем төмән тү чәчәклек,
Хәзанмы түшәттем,— камугны корыттым.
[Күп чәчәкле нурлы яз кебек идем,
Көз җилеме исте,— барысын корытты.]

Каен тик будым, ук тик көни, төз,
Йә тик игри булды, игелдем, төңеттем.
[Каендай буем ук тик туры төз (иде),
(Хәзер ул) җәя кебек бөкрәйде — иелдем, хәлсезләндем...]

...Кечеклек кичердем, йегетлек йитердем,
Көнем чалпаладым, үземне чөкеттем.
[Балачакны уздырдым, яшьлекне калдырдым,
Көннәремне (бушка) үткәрдем, үземне чүктердем.]

Йимәк, эчмәк ирсә — йийдем, эчтем уд тик,
Теләк сөрмәк ирсә, төмән туг тузыттым.
[Ашарга, эчәргә булса, сыер кебек ашадым, эчтем,
Теләкне үтәү өчен, күп вакыт уздырдым (тузан туздырдым)...]

...Теләк арзу берлә йөгердем ничә мән,
Котырмыш бүре тик ажунны улыттым.
[Теләгемне үтәү өчен, күпме йөгердем мин,
Котырган бүре кебек дөньяны шаулаттым.]

Кешег тоттым, алдым көчен йармакын мән,
Кемег сөрдем ирдем, кеме ма ачыттым...
[Кешеләрне тоткын кылдым, көч белән акчасын алдым,
Берәүләрне сөрдем, икенчеләрен газап кылдым...]

Никү асгы? Ахыр йәнеш йиргә булды,
Тору калды, дөнья ике бәз әләттем.
[Ни файда? Ахырда җиргә кайтасы булгач,
Дөнья торып калды, (мин) ике бәз (кәфенлек) алып
китәчәкмен.]

Йалың килдем ирде, йалың киру йиргә,
Нилүг дөньяка үзне монча исетдем.
[Ялангач килдем инде, җиргә дә (кабат) ялангач керермен,—
Ни өчен дөньяга исем китте!]

Кичәр дөнья кичте түби йил кичәр тик,
Кичәр дөньяка үз осалын басыттым.
[Кичәр дөнья искән җил-давыл кебек китте,
Фани дөньяга үземне бастырдым...]

...Никү иктем ирсә, аны ургу ахыр,
Никү урдым ирсә, аның үз сөчеттем.
[Ни чәчкән булсам, аны (хәзер) урам,
Ни урган булсам, аның (белән) үземне (хәзер) юатам...]

Әхмәд Ясәви

(? —1166)

*Шигырьләр**

[Гарибләр]

Гариблегъдә гариб булган гарибләр,
Гарибләр хәлене белгән гарибләр,
Сәбәб берлә ерак йиргә барибән[1],
Карендәш кадрене белгән гарибләр.

Сусаганда суга мохтаҗ булган,
Терекдә[2] зар улыб улган гарибләр,
Кеше белмәс гарибләр хале нидер,
Мәгәр белгәй гариб булган гарибләр.

Гариблегъ катыйг ищдер, и газизем,
Кем ул би кадер — улар мескин гарибләр[3],
Кил имди Әхмәдә[4], үзеңә бакгыл,
Гариб син, син гариб, мескин гарибләр.

---

* *Хуҗа Әхмәд бине Ибраһим бине Мәхмүд Ясәви.* Диване хикмәт хәзрәте солтан...— Казан: Университет тәбыгханәсе, 1893.— 104, 253—254 б.

[1] *Барибән* — барып, барган.

[2] *Терекдә* — исән чакта.

[3] «Кем кадерсез — алар мескен гарибләр».

[4] *Әхмәд* — шагыйрьнең исеме.

[«...Гафу кылгыл гөнаһымны»]

Күңлем кошы очар даим канат тукыб[1],
Ике күзем нәдамәтдә[2] канлар түкеб,
Тән үлтереб, риазәтдә[3] тезен чүкеб,—
Йа Иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Наданлыкда кылган эшем барча хата,
Тәүбә, тәкъсыйр[4] әйләмәдем йакам тота,
Гәрдәнемгә тоук йаңлигъ салыб фута[5],—
Йа Иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Дөнья сөеб, дин сәүдәсен үткәреб мин[6],
Йазык йөген, әйа дустлар, бөткәреб[7] мин,
Дәргяһына[8] мәгъсыятьләр[9] килтереб мин,—
Йа Иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

Шом[10] дөньяга күңел баглаб кәһел булдым[11],
Гыйшрәт белән, ва(й) дәрига, җаһил булдым[12].
Бу дөньяны(ң) үтәрене имди белдем,—
Йа Иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны...

Кол Хуҗа Әхмәд гөнаһига каил[13] ирер,
Һәркем Алла дисә аңа йари[14] бирер,
Ирәнләрне сөхбәтегә маил ирер[15],—
Йа Иляһи, гафу кылгыл гөнаһымны.

---

[1] *Тукыб*—кагып.
[2] *Нәдамәт* — үкенеч.
[3] *Риазәт* — теләкләрне (нәфесне) тыеп тору.
[4] *Тәкъсыйр* — дин әһелләрен олылау.
[5] «Муеныма (гәүдәмә) сөлге (чүпрәк) урап чылбыр кебек».
[6] «Дөнья сөеп, дин шөгылен (эшен) калдырып мин».
[7] *Бөткәреб* — үстереп, күтәреп.
[8] *Дәргяһына* — бусагасына, катына.
[9] *Мәгъсыять* — гөнаһ, йазык эш.
[10] *Шом* — «шомлы, ышанычсыз» мәгънәсендә.
[11] *Кәһел булдым* — ир уртасы булдым, гомер уздырдым.
[12] «Күңел ачып, ай үкенеч, надан булдым».
[13] *Каил* — әйтүче, җиткерүче.
[14] *Йари* — дуслык; куәт.
[15] «Кешеләрне әңгәмәгә (үзе белән аралашуга) һәвәс итәр».

Сөләйман Бакырганый

(?—1186)

*Шигырьләр**

[«Мән еглармын, һәммә галәм көләдер»]

Мәнем җаным сәнең гыйшкың белә(н)дер,
Тәнем гаҗиз, вәли җаным уладыр[1].

Бу гыйшк гәр булмаса, мән ниткәй ирдем[2],
Камуг[3] аһым мәнем гыйшкым кыладыр.

Зиһи халь[4], зиһи халь, зиһи халь! —
Мән еглармын, һәммә галәм көләдер.

Гашыйкдин сормаңыз[5] дөнья вә гокба[6],—
Гашыйк мәгъшукы өчен һәр дәм уладыр[7].

Гашыйкны көйдерер гыйшык уты,
Гашыйклар гыйшык утига мөбтәлядер[8].

---

* Бакырган китабы.— Казан: Кокобин тәбыгханәсе, 1878.— 10—11, 19, 25 б.

[1] «Тәнем көчсез, әмма җаным бардыр (яшидер)».

[2] *Ниткәй ирдем* — нишләр идем.

[3] *Камуг* — һәммә, барлык.

[4] *Зиһи халь* (зәһи хәл) — гаҗәеп хәл.

[5] *Сормаңыз* — сорамагыз.

[6] *Дөнья вә гокба* — дөньяны һәм теге дөньяны; бу һәм теге дөньяны.

[7] «Гашыйк (кеше) һәр сулышында (мизгелдә) үз сөйгәне өчендер».

[8] «Гашыйклар гыйшык утына дучардыр».

Мәнең сән бакмагыл бу сурәтемгә,
Йөрәгем кан булыб, бәгърем суладыр.

Аерды гыйшык мәне хәйл-хишемдин[1],
Күзем яше акыб, мәңзем[2] суладыр.

Күрең: ни хәлгә төшде Кол Сөләйман[3],
Камуг гыйшкым мәнең рәнҗем беләндер[4].

[«Сиңа кол булганым—солтаннан артык»]

Сәнең дәрдең бәңа дәрмандин артык,
Сәңа кол булгам — солтандин артык.

Сәнең ядыңны әйсәм[5] чүл эчендә,
Булыр ул чүл мәңа бостандин[6] артык.

Сәнең ядың әгәр китсә телемдин,
Вөҗүдем корыйур (корыр.— *Х. М.*) вәйрандин артык[7].

Мәнең хар[8] булмышым үз гафләтемдин[9],
Мәгәр кыйлсаң нәзар — ихсандин артык[10].

Газиз хар кыйлгучы солтан сынуксән,
Сәнең лотфың каму әлвандин артык[11].

Нә хуш бу дөньяда иман вә «Коръән»!
Ни булгай дөньяда имандин артык!

---

[1] *Хәйл-хишемдин* — туган-тумачамнан, дус-ишләрдән.

[2] *Мәңзем* — йөзем.

[3] *Кол Сөләйман* — Сөләйман Бакырганыйның әдәби кушаматы.

[4] «Барлык гыйшкым минем газабымдадыр» (ягъни газапларда күренәдер).

[5] *Сәнең ядыңны әйсәм* — сине исемә төшерсәм.

[6] *Бостан* — бакча, гөлбакча.

[7] «Яшәешем корыр хәрабәләрдән дә артык».

[8] *Хар* — түбән, гөнаһлы.

[9] *Гафләтемдин* — ваемсызлыгымнан, пошмаучанлыгымнан.

[10] «Мәгәр күз ташласаң (карасаң) — ярдәмнән (игелектән) артык».

[11] «Синең мәрхәмәтең барлык (төстәге) чәчәкләрдән (нигъмәтләрдән) артык».

Мәнем дәрдеме һич кемсә белмәс,
Әгәр белсә хәким Локмандин[1] артык.

Бу йаңлигъ гасый иркән[2] Кол Сөләйман,
Гыйнаять уманыр барандин артык[3].

[«Кичә-көндез хәзер торың — килер әҗәл»]

Белең, дуслар, ничә кичде[4], ничә калды, —
Нә булгусын, нә килгүсен белгән бармы[5]?!

Монда кыйлган эшләр анда соралгучы,
Соралмаен котылубән калган бармы[6]?!

Соралмагай, әгәр булса изге гамәл,
Кылмыш гамәл җөмләмезгә хирыс әмәл[7].

Кичә-көндез хазыйр торың, килер әҗәл,
Әҗәл килер тибиян, йараг[8] кылган бармы?!

Коллыксыз бирелмәсдер икән дидар[9],
Имгәксез[10] ир морадыга качан йитәр?!

Гаувас кереб гомманга гәүһәр табар[11],
Рәнҗсез, гәнеҗ эстәйүбән табкан бармы[12]?!

---

[1] *Хәким Локман* — Шәрык дөньясының легендар акыл иясе.

[2] «Мондый гөнаһлы икән».

[3] «Ярдәм кәтәр яңгырдан артык» (ягъни аннан яңгырдан да артык мул шәфкать, мәрхәмәт көтәр).

[4] *Кичде — монда:* үлде, теге дөньяга күчте.

[5] «Ни буласын, ни киләсен белгән (кеше) бармы?!»

[6] «Соралмыйча котылып калганнар бармы?!»

[7] «Кылган гамәл — барчабызның комсызлыктыр».

[8] *Тибиян* (тыйбиян), *йараг* — игелек, ярак (кирәкле азык); хәстәр.

[9] *Дидар* — очрашу, кавышу; йөзен күрү.

[10] *Имгәксез* — мәшәкатьсез, хезмәт кылмыйча.

[11] «Водолаз кереп диңгезгә (Гарәбстан ярымутравындагы Оман култыгы да күздә тотыла) җәүһәр табар».

[12] «Мәшәкатьсез, (кемнең) хәзинә эзләп (теләп) тапканы бар?»

Коткаргу[1] үзене монда коллык берлән,
Кермәгү тәмуг эчрә мәнлек берлән[2].

Коллык кыйлгы Мәүласына ирлек берлән[3],
Коллыксыз үзене утдин йолган (йолып калган.— *Х. М.*)
бармы?!

Йарак кыйлгу хәмд-ү сәна шәһадәтне[4],
Гадәт кыйлгу коллыгда кыяфәтне.

Бер көн менгү (менү.— *Х. М.*) ул җеназа атлыйг атны,
Ушал атка һич менмәйен калган бармы[5]?!

Белер булсаң: гәнеж, торыр йир вәйран торыр[6],
Хозыр берлә Муса кәлим(е) йаран торыр[7].

Кал әһеле[8] сүз эчендә хәйран торыр,
Хальне күреб кал әһеле салган бармы?!

Кол Сөләйман, халь берлә, хикмәт төзәр[9],
Халь берлә тагать нәфсене өзәр[10].

Заһир хәраб, батыйн Мәгъмүр булыб гизәр[11],
Гыйшык базарын бүлеп, рәх(ә)тен алган бармы?!

---

[1] *Коткаргу* — коткар.

[2] «Кермә тәмуг эченә минлек белән (үз-үзеңне югары куеп)».

[3] «Аллага коллык кыл син ирлек белән» мәгънәсендә.

[4] «Ярак (теге дөньяга әзерлек) кылуның дәлиле — Аллага мактау, дан уку».

[5] «Шул атка (ягъни җеназа атына) һич менмичә калган (кеше) бармы?»

[6] «Белсәң: хәзинә, торган җир (һәммәсе) вакытлыдыр».

[7] «Хозыр белән Муса (пәйгамбәрләр) — якын дуслар (фикердәшләр) торыр».

[8] *Кал әһеле* — сүз сөйләүче; буйсынып гыйбадәт кылучы.

[9] *Хикмәт төзәр* — хикмәт (шигырь) язар.

[10] «(Аллага гыйшык) хәле белән буйсыну нәфесне өзәр».

[11] «Тышың харап, эчең төзек булып гизәр».

«КОРЪӘН»НӘН ТӘФСИРЛӘР*

«Җир тетрәү» («Зилзилә»)

(99 нчы сүрә, 8 аять)

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кайчан Җир үзенең тетрәү вакытында тетрәтелмеш булса (2), Җир үзенең авыр йөкләрен чыгара (3), шул вакытта адәм әйтер: «Ни булды бу Җиргә?» — дип (4). Шул көндә ул халыкка үзенең тетрәвен һәм дә йөкләрен чыгарып ташлавын бәян итәр (5). Моны бәян итүгә җирнең Раббесе — Аллаһы Тәгалә аңа вәхи[1] белән белдергән булыр.

Шул вәхи сәбәпле бәян итәдер (6). Ул көндә адәмнәр, таралышып, хисап мәйданына төшәләр, үзләренең гамәлләренең җәзаларын күрсәтмәкләре өчен (7). Инде берәү дөньяда вакытында тузан кадәр изгелек эшләсә, шуны да күрер (8). Һәм тузан кадәр явыз гамәл кылган булса, аны да күрер, ягъни тузан кадәр генә изгелекләре булмаган кешеләр дә шул гамәлләренең җәзаларын күрерләр.

«Кыямәт көне» («Әл-Каригаһ»)

(101 нче сүрә, 11 аять)

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Кыямәт көне (2). Нәрсә ул Кыямәт көне (3)? Һәм син Кыямәт көне нинди булуы турында нәрсә беләсең (4)? Кыямәт көне —

---

* *Әнвәр Хәйри* тәрҗемәсендә // Казан утлары.—1991.— № 11.— 178, 179—180, 185 б.

Җәя эчендәге саннар аятьләрнең тәртибен күрсәтә.

[1] *Вәхи* — иңдерү; җибәрү.

һәр нәрсәне куркытучы һәм һәр нәрсәне урыныннан кубаручы, куркынычлы көн. Ул Кыямәт көнендә адәмнәр — таралган чикерткәләр (5), таулар тетелгән йоннар кебек булырлар (6). Инде ул көнне берәүнең гамәл үлчәүләре авыр булса (7), ул кеше үзенең күңеленә ошаган кәеф-сафада булыр (8). Әмма берәүнең гамәл үлчәве җиңел булса (9), ул кешенең урыны — һавийәһ булыр (10) һәм син һавийәһнең нинди булуы турында нәрсә беләсең (11)? Ул — кызулыкта чиктән чыгып янып торучы ут.

«Байлык белән мактану» («Тәкәсүр»)

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Байлык белән мактану — сезне Аллаһыдан аера (2). Каберләргә барып күмелгәнче сезне байлык белән мактану шөгыльләндерде (3). Каберлеккә күмелүне онытып, байлык белән мактанышу — яраклы эш түгел, андый эшнең яраксызлыгын киләчәктә белерсез, ягъни үлгәннән һәм дә үлеп кубарылганда белерсез дә үкенерсез (4). Әгәр дә сез киләчәк куркынычлы кыямәтне үзегез күреп белгән кебек белсәгез иде (5), маллар белән мактанышуны сөймәс идегез (6). Әмма эш сез уйлаганча түгел, ант итәмен, кыяматтә җәхим, ягъни җәһәннәм тәмугысын алдыгызда күрерсез (7). Шул вакытта Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзегезгә бирелгән нигъмәтләреннән соралырсыз, ягъни «Мактанышкан малыгызны кая куйдыгыз, фәкыйрьләргә бирдегезме?» — дип соралырсыз да җәһәннәм тәмугысына кертелерсез (8)! Шулай булгач, каберлеккә барганчы алдыгызны һәм артыгызны карагыз!

«Заман» («Гасыр»)

(103 нче сүрә, 3 аять)

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Заман белән ант итәмен (2), дөреслектә адәм һаман хәсрәттә (3), мәгәр иман китереп, изге гамәл кылып, хаклык белән һәм дә сабырлык белән васыять итешкән кешеләр генә хәсрәттә түгелләр. Ягъни дөнья-ахирәт(тә) сәгадәтле (бәхетле.— *Х. М.*) булачак кешеләр шундый кешеләрдер: алар Аллаһыга һәм

башка ышануы тиешле булган нәрсәләргә иман китерерләр, өсләренә тиешле булган изге гамәлләрнең кулларыннан килгәннәрен кылырлар. Шуннан соң бер-берсенә хак юлда булып, яманлыктан тыелу белән үгет бирешерләр.

«Кешеләр» («Ән-нас»)

(114 нче (соңгы) сүрә, 6 аять)

Мәрхәмәт итүче рәхимле Аллаһ хакына (1).

Әй Мөхәммәд! Әйт син: «Мин адәмнәрнең Раббесе (2), адәмнәрнең Алласы булган Раббемә сыенам (3). Вәсвәсә кылып, ягъни күңел аздырып, изге гамәлләрне кичектерүче заттан, ягъни шайтаннан (4), җеннәрдән һәм адәмнәрдән дә булып (5), адәмнәрнең күңелләрендә вәсвәсә кылучы заттан сакланам» (6).

Кол Гали

(1183—XIII йөзнең беренче яртысы)

КЫЙССАИ ЙОСЫФ
(1212—1233)

*(өзекләр)**

[Йосыфның төш күрүе]

...Газиз Йосыф тәмам унбер йәшәр ирде,
Йагъкуб сәүчи уйлукында уйур иде,
Уйуркан бер гаҗәб дөш Йосыф күрде,—
Тәэвилене атасындан сорар имди.

«Дугар көн, тулун ай, унбер йолдыз
Дөшем эчрә сәҗдә кылды бәңа дөб-дөз,
Ошбу дөши буйлә күрдем һич гөмансыз,
Йа әбәти, боңа тәэвил айгыл имди».

Анда Йагъкуб Йосыфның дөшен йурди,
Тәэвилене мөбарәк әйтүр ирде:
«Өмиддер кем, Мәүладан мәдәд ирде,—
Сәңа гыйззәт вә рифгать күренер имди.

---

* *Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф / Әзерләүчесе *Фазыл Фәсиев.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Текстлар хәзерге языльшка якынайтып бирелә. Өзекләргә исемнәр безнең *(Х. М.)* тарафтан куелды.

Өмиддер кем, Мәүла сәңа вирә мөлкәт,
Фазлы берлә рузи кыйла үкеш нигъмәт,
Кардәшләрең җөмләсе кыйла хезмәт,—
Унбересе сәңа хезмәт кыйла имди.

Галәм эчрә сәнең адың мәшһүр ула,
Мәшрикъ, Мәгъриб олылары сәне белә,
Кыяматкә дикин адың бакый кала,—
Хәлил-зәбих дәүләте күрнер имди.

Нөбүввәт-рисаләт булдачы сән,
Һәм мәмләкәт иясе улдачы сән,
Рахәтегә бәшарәт булдачы сән, —
Бу дөш эчрә газыйм дәүләт күрнер имди...

Вәлякин әманәтдер, җаным угыл,
Бу дөшеңне һич кемсәгә сән әйтмәгел,
Адәмиләр кинәсендән ки саклангыл,—
Адәмигә шайтан дошман улыр имди.

Кирәкмәз кем ошбу әсрар заһир ула,
Кардәшләрең бу мәгънәдән хәбәр белә,
Бу эш эчрә анлар сәңа хәсәд кыйла,—
Ибтидасы безә михнәт ула имди».

* * *

Вар иде Йагъкубың бер үгәй кызы,
Ул ишетмеш бу икендән ошбу сүзи,
Кучылардан бикләсен Халикъ сези,—
Варыб (ул) кардәшләренә әйтер имди.

«Кардәшеңез Йосыф (дәйүр) бер дөш күрмеш,
Ай, көн, унбер йолдыз аңа сәҗдә кылмыш,
Атаңыз Йагъкуб аны изге йурмыш,—
Бән ишетдем, изге тәэвил кылды имди».

Кардәшләре аны ишдеб кәйед кылды,
Хәсәдләре, кәйедләре галиб улды,

Җөмләсенең хатиренә госса йагды,—
Дирнешүбән батыйл тәдбир кылыр имди.

«Әгәр ул дөш йиренә килер улса,
Йосыф олуг падишаһ, улыр улса,
Җөмләмез аңа хезмәт кылыр улса,—
Ул безләргә каты гарьдер»,— дирләр имди...

Тәрҗемәсе:

...Газиз Йосыф тәмам унбер яшәр иде,
Йагъкуб сәүчи итәгендә йоклар иде,
Йоклаганда гаҗәп бер төш Йосыф күрде,—
Төш мәгънәсен атасыннан сорар имди.

«Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз
Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз,
Бу төшемне шулай күрдем, һичбер шиксез,—
Йә әткәем, шул төшемне юра имди».

Йагъкуб шунда юрап бирде аның төшен:
«Булыр,— диде,— бәхетле һәм котлы эшең.
Хуҗабыздан ярдәм иңәр синең өчен,—
Сиңа хөрмәт һәм бөеклек килер имди.

Өмет бар ки, Тәңре сиңа бирер мөлкәт,
Кодрәт берлә насыйп итәр бик күп нигъмәт,
Җөмлә (барлык.— *Х. М.*) кардәшләрең кылыр сиңа
хөрмәт, —
Унбере дә сиңа хезмәт итәр имди.

Синең исмең галәмара мәшһүр булыр,
Мәшрикъ, Мәгърибъ олуглары сине белер,
Кыяматкә тикле исмең мәңге калыр,—
Хәлил-зәбих[1] дәүләте күренер имди.

---

[1] *Хәлил* — чын (якын) дус. *Зәбих* — корбан чалу. Бередә бу сүзләр Йосыфның бабалары Ибраһим һәм Исхак пәйгамбәрләргә карата кулланылган. Риваятьләр нигезендә Ибраһим үзенең улы Исхакны сабый чагында Аллага корбан итәргә ниятләгән була.

Пәйгамбәрлек-нәбилек син алачаксың,
Һәм мәмләкәт иясе син булачаксың,
Рәхәт, шатлык, сөенечләр табачаксың,—
Бу төшеңдә бөек бәхет күрнер имди...

Ләкин, углым, әманәттер, яхшы тыңла,
Бу төшне син беркемгә дә мәгълүм кылма,
Саклан кеше кинәсеннән, шуны аңла:
Кешеләргә шайтан дошман булыр имди.

Кирәкмәскә бу серләрең мәгълүм булса,
Кардәшләрең бу төшеңнең аслын белсә,
Көнчелектән ачулары әгәр килсә,
Бу эш баштук безгә яман булыр имди».

* * *

Ул Йагъкубның бар иде бер үги кызы,
Ул ишеткән бу икәүдән ошбу сүзне,—
Сакла, Хода, әләкчедән үзең безне,—
Барып, кардәшләренә шул әйткән имди.

«Кардәшегез Йосыф,— дигән,— бер төш күргән,
Көн (кояш.— *Х. М.*), ай, унбер йолдыз аңа сәҗдә кылган,
Атагыз бу төшкә изге юрау биргән,—
Мин ишеттем ул юрауны үзем имди».

Кардәшләре, моны белгәч, бик борчылды,
Көнләүләре бар нәрсәдән өстен булды,
Күңеленә һәммәсенең кайгы тулды,—
Бергәләшеп явыз ният корыр имди.

«Ул күргән төш әгәр растка килә калса,
Әгәр Йосыф зур падишаһ була калса,
Һәммәбез дә әгәр аңа хезмәт кылса,—
Булыр бу эш безгә каты гарьлек имди...»

[Агаларының Йосыфны коега салулары]

...Йосыфның биленә йеб дакдылар,
Кәндүләрен миһренә уд йакдылар,
Койу эчрә салмага касд кылдылар,—
Канкысына йалварырсә, бушар имди.

Анлар Йосыф зарына бакмадылар,
Хәсрәт илә йалвардыгын дотмадылар,
Йәһүдәнең[1] пәнденә һәм бакмадылар,—
Җөмләләре дарыгубән бушар имди.

Йосыф әйтер: «Әй кардәшләр, бәңа кылмаң,
Шайтан сези гөмраһ кылыб, аңа уймаң,
Бәнем тәнем гөрйан кылыб, туным суймаң,—
Ата хакын, кардәш миһрен саклаң имди.

Бу көн үлмәс кани бәңа кәфен кирәк,
Имди бәңа кәфен улсын ошбу күңләк?!»—
Зәһи гөҗеб, суык бәгъре, каты йөрәк,—
Күңләкене иңендән суйарлар имди.

Биленә бер йеб дагыб күндердиләр,
Йосыфы ул дар койуйа иңдерделәр,
Шәфкать кисеб йөзләрен дүндерделәр,—
Бере килеб урагын кисәр имди.

Йосыф әйдер: «Иляһәна, кәрим-хәннан,
Бичаралар өмиде сән, рәхим-мәннан,
Һич өмидем калмады ихванымдан,—
Бәңа мәдәд сән ук кылгыл!» — дәйүр имди...

Тәрҗемәсе:

...Алар Йосыфның биленә бау тактылар,
Үзләренең бәгыренә ут яктылар,
Шул коега төшерергә касд (ният.— *Х. М.*) кылдылар,—
Йосыф ялварса, барсы аны сүгәр имди.

---

[1] *Йәһүдә* — Йосыф агаларының берсе.

Алар Йосыфның зарына бакмадылар,
Ялваруын игътибарга алмадылар,
Йәһүдәнең киңәшен дә тотмадылар,—
Җөмләсенең ачулары артыр имди.

Йосыф әйтте: «Мондый эшне сез кылмагыз,
Шайтанга сез сүзен аңлап буйсынмагыз,
Киемсез һәм шыр ялангач калдырмагыз,
Ата хакын, кардәш миһрен саклаң имди.

Үлсәм,— диде Йосыф,— миңа кәфен кирәк,
Инде миңа кәфен булсын ошбу күлмәк»,—
Булып алар суык күңел, каты йөрәк,
Шул күлмәген салдырырлар ертып имди.

Биленә бер бау тагып китерделәр,
Йосыфны шул тар коега төшерделәр,
Шәфкать итми, йөзне читкә чөерделәр,—
Урак белән берсе бауны кисәр имди[1].

Йосыф әйтте: «Йа Илаһым, бөек хуҗам,
Бичаралар өмете син, рәхимле Аллам,
Һич өметем калмады бу туганнардан,—
Бүген миңа үзең ярдәм күрсәт имди!..»

[Дәгыйр углы Маликнең төш күрүе]

Мисыр эчрә олуг таҗир улыр иде,
Аның ады Малик ибне Дәгыйр иде,
Дәгыйр углы Малик бер дөш күрде,—
Мөгаббирә тәэвилене сорар имди.

Әйдер аңа: «Бу кичә бер дөш күрдем,
Дөшем эчрә Кәнганә варыб идем,

---

[1] «Бере килеб урагын кисәр имди» юлын «Бере килеп ураганны (ягъни ураган бауны) кисәр имди» дип тә тәрҗемә кылырга мөмкин *(Х. М.)*.

Гад койусы тирәсендә йөрер идем,—
Көн, хакыйкать, күкдән йирә иңәр имди.

Дугар көн мөгаййән күктән иңде,
Куенымдан керүбән йакамдан чыкты,
Һәм күкдән дөрр-ү мәрҗән, йенҗү йагды,—
Бән аны итәкемә дирдем имди.

Сәүенүбән мән аны дирүр идем,
Җәмигъ кылыб, сандугыма куйар идем,
Бу дөши һич гөмансыз буйлә күрдем,—
Йа мөгаббир, боңа тәэвил кылгыл имди».

Мөгаббир әйдер: «Мондаг дөш күрдең исә,
Дөшең эчрә ул мәкамә ирдең исә,
Гад койусы тигрәсендә йөрдең исә,—
Бер шәриф кол әлеңә керәр имди.

Ул коли очыз сатун алдачы сән,
Аны сатыб үкеш нигъмәт булдачы сән,
Мөлек вә дәүләт иясе булдачы сән,
Ул сәбәбдин үкеш рахәт күрнер имди.

Ул мәгънәдән олуглыкга дигенәсен,
Халикъның берлегенә инанәсен,
Көфер ширкәт михнәтендән кортыласын,—
Дөнья-ахирәт дәүләте күрнер имди».

Аны ишдеб, Малик Дәгыйр сәфәр кылды,
Кәнган иле эченә килде керде,
Гад койусы тигрәсендә йөк төшерде,—
Дөшендә күрдеген эстәр имди...

...Бәшир, Бөшра[1] икеләси кауга алды
Ул койуның үзәренә хазир килде,

---

[1] *Бәшир, Бөшра* — Маликнең хезмәтчеләре.

Койу эчрә каугаләрен нөзуль кылды,—
Йосыф андаакыб аны күрер имди...

Тәрҗемәсе:

Мисырда бер олуг сәүдәгәр бар иде,
Аны Малик ибне Дәгыйр диләр иде,
Дәгыйр углы Малик бер көн төш күрде,—
Юраучыдан төш мәгънәсен сорар имди.

Әйтер аңа: «Бу төнне мин бер төш күрдем,
Ул төшемдә мин Кәнганга бара идем,
Гад коесы тирәсендә йөри идем,
Кояш күктән җиргә иңеп бара имди.

Кояшның җиргә иңгәнен тордым күреп,
Ул якамнан чыкты, куеныма кереп,
Энҗе-мәрҗән яуды җиргә яңгыр кебек,—
Мин аларны итәгемә җыйдым имди.

Аларны мин бик сөенеп җыеп алдым,
Җыеп алып, сандыгыма салып куйдым,
Һич гөмансыз, менә шундый төш мин күрдем,—
Мәгънәсе ни, миңа шуны юра имди».

Юраучы әйтте: «Мондый төш күргән булсаң,
Бу төшеңдә ул урынга килгән булсаң,
Гад коесы тирәсендә йөргән булсаң,—
Бу асыл зат кол кулыңа керер имди.

Бу колны бик очсыз сатып алачаксың,
Аны сатып, бик күп байлык табачаксың,
Дәүләт һәм мөлкәт иясе булачаксың,—
Сине алда бик күп рәхәт көтә имди.

Шул рәвешчә син олуглык казанасың,
Һәм Халикъның (Алланың.— *Х. М.*) берлегенә иманасың,
Көферлекнең михнәтеннән котыласың, —
Дөнья-ахирәт дәүләте күренер имди».

Бу сүздән соң Малик Дәгыйр сәфәр чыкты,
Сәфәр чыгып, Кәнган иленә барып җитте,
Гад коесы тирәсендә йөк бушатты, —
Төштә күргән җирне анда эзләр имди...

...Бәшир, Бөшра шундук чиләкләр алдылар
Һәм тиз-тиз кое янына юнәлделәр,
Бау бәйләп, чиләкне төпкә төшерделәр,—
Йосыф исә барсын күреп торыр имди...

[Йосыфны агаларының кол итеп сатуы]

...Йосыфың кардәшләре тагда иде,
Бакубән ул мәнзилдә кәрван күрде,
Тәгъҗил берлә катарлашу йөгреб варды,—
Йосыфи койуда булмазлар имди.

Анлар качан бу мәгънәдән хәбәр белде,
Хәлка идеб, ул кәрвани чолгаб алды,
Әйдер: «Безем колымыз качмыш иде,—
Аны байык, сез алмышсыз!» — диләр имди.

Рауил[1] әйдер: «Виреңез миннәт илә,
Йухса бер гәз нәгъръә орам һәйбәт илә,
Җөмлә һәлак уласыз михнәт илә,
Өнем ишедән җаны тәслим кылыр имди!»

Малик кылды ихтиат, гакыйл иде,
Йосыфи бонлара киру вирде,
Анлар дәхи мәслихәт уйлә күрде:
«Моны кол диб монлара сатам имди».

Бу тәдбири бонлар буйлә әйләделәр,
Гыйбричә[2] Йосыфа сөйләделәр:
«Үлдерербез йухса,— ди(е)б куркытдылар, —
Кол диб сатам, сән мотыйг улгыл имди»...

---

[1] *Рауил* — Йосыфның туганы.
[2] *Гыйбричә* — яһүдичә.

Йосыф әйдер: «Сез бәне сатармысыз,
Хәсрәт-горбәт мәйданына атармысыз,
Фигълеңездән бәндән гөман тотармысыз, —
Саклайалым, ант эчәлем»,— дәйүр имди...

...Анлар әйдер: «Без сәне зинһарладык,
Атамызга: «Йосыфи корд йиды»,— дидек,
Исраилә без дишвар сүз сөйләдек,—
Йа Йосыф, сән бу сакыныч куйгыл имди!..»

Малик әйдер: «Бу колмыдыр, бәйан әйләң,
Нә мәгънәдән сатарсыз, аны сөйләң,
Нә сөч кылды, нишә качды — дугры сөйләң,—
Гаклы, күрке сездән дагы артык имди».

«Кечек иркән атамыз сатын алды,
Дора-дора беземи илә һәмраһ улды,
Дора-дора бу угланчык йавыз улды,—
Качыб килеб, бу койуйә кермеш имди».

Малик әйдер: «Әхвәлен әйләң гайан,
Ничә дөрле гайбе вардыр, кылың бәйан,
Һич сүз галәт улмасын бонда гөман,—
Шарты сәхих, дөрест сату кыйлам имди».

Анлар әйдер: «Һич гөмансыз байык колдыр,
Колымызның өч дөрле гайбе вардыр:
Угрыдыр, йаланчыдыр, качкычыдыр,—
Бу өч дөрле гайбе берлә алгыл имди...»

...Малик әйдер: «Ун сәкез йармакым вар,
Хакыйкать, алтыным йук — комашым вар,
Ун сәкез йармакны алың сезләр,—
Каланыны бәңа бәхшиш кылың имди».

Анлар әйдер: «Ун сәкез йармак алдык,
Сәнең берлә бу сатуны тәмам кылдык,
Җөмләмез бу сатуйа разый улдык,—
Каланыны сәңа бәхшиш кылдык имди...»

...Йосыф аны ищдеб, канын аглар,
Хәсрәт уды эчен йагар, бәгърен даглар;
Аглар икән һәм киру дәстүрделәр:
«Дәстүр вирсәң, киру варсам»,— дәйүр имди...

...Андан Малик Йосыфа дәстүр вирде,
Йарлы Йосыф хәсрәт илә кире варды,
Бу ун кардәш җөмләсе үрә дорды,—
Һәр бересен үпә-коча аглар имди...

...Ул дәм йула Йосыфи күндерделәр,
Палас ки(е)реб, бер дәвәйә бендерделәр,—
Әлен баглаб, йаулак каты беркетделәр,—
«Бушанубән качмасын!» — дирләр имди...

Тәрҗемәсе:

...Бу чак Йосыф кардәшләре тауда иде,
Ул тирәдә кәрван барын алар күрде,
Бик ашыгып, кабаланып, йөгереп килде,—
Коеда Йосыф юклыгын күрер имди.

Кайчан алар юк икәнен аның белде,
Ул кәрванны алка булып чолгап алды:
«Бер колыбыз бездән качып киткән иде,
Шиксез, аны сез алгансыз!» — диләр имди.

Рауил әйтте: «Бирмәсәгез миннәт белән,
Каты итеп оран салам куәт белән,
Һәлак булыр һәммәгез дә михнәт белән,—
Тавышымнан кеше җанын бирер имди!»

Карышмады Малик — акыллы ир иде,
Кардәшләренә Йосыфны кире бирде,
Кардәшләре мондый хәлдән файда күрде:
«Кол дип сатыйк боларга без»,— диләр имди.

Бу чараны алар болай уйладылар:
Йосыфка гыйбри телендә сөйләделәр,

«Үтерәбез юкса,— диеп янадылар,—
Кол дип сатыйк, шуңа буйсын»,— диләр имди.

...Йосыф әйтте: «Шулай мине сатасызмы,
Хәсрәт-горбәт мәйданына атасызмы,
Эшегезне ачар дип шик тотасызмы,—
Ант итәм, бу серне ачмам»,— дияр имди...

...Алар әйтте: «Сине инде без кисәттек,
Атабызга бүре ашады диеп әйттек,
Аңа бик күп авыр сүзләр без сөйләдек,—
Йосыф, син бу ниятеңне ташла имди!..»

...Малик әйтте: «Бу нинди кол, аңлатыгыз,
Ни сәбәптән сатарга сез уйладыгыз,
Гайбе ни, нигә качты, тугры әйтегез,—
Гаклы, күрке, юкса сездән артык имди».

«Әткәебез кече чакта сатып алды,
Тора-бара безнең белән юлдаш булды,
Тора-бара ул бөтенләй явызланды,—
Качып килеп, бу коега кергән имди».

Малик әйтте: «Барлык хәлен ачыклагыз,
Ничә төрле гайбе бар, таныклагыз,
Хата сөйләп миндә шөбһә калдырмагыз,—
Сату-алу шарты дөрес булсын имди».

Алар әйтте: «Һичбер шиксез бу чын колдыр,
Колыбызның нәкъ өч төрле гайбе бардыр:
Качучыдыр, урлаучыдыр, ялганчыдыр,
Шул өч төрле гайбе белән син ал имди...»

...Малик әйтте: «Нәкъ унсигез ярмакым бар,
Чынын әйтәм, алтыным юк, комачым бар,
Шул йармакка булсагыз сез риза әгәр,—
Җитмәгәнен багышлагыз миңа имди».

Алар әйтте: «Унсигез йармакны алдык,
Синең белән бу сәүдәне тәмам кылдык,
Һәммәбез дә бу бәһагә риза булдык,—
Җитмәгәнен багышладык сиңа имди...»

...Йосыф, моны ишетеп, кан-яшь белән еглый,
Көя хәсрәт утында һәм бәгъре сызлый,
Еглый-еглый Маликтән ул рөхсәт сорый:
«Барыр идем яннарына»,— дияр имди...

...Аннан Малик Йосыфка рөхсәт бирде,
Мескен Йосыф агалары таба килде,
Ун кардәше үрә торып каршы алды,
Һәрбересен үбә-коча еглар имди...

Йосыфка бер тупас кием кидерделәр,
Дөягә мендереп, юлга күндерделәр,
Бер бау белән кулын бик нык бәйләделәр:
«Ычкынмасын бавы бушап!» — диләр имди...

[Йосыфның Мисырга килүе]

...Малик Дәгыйр ул мәнзилдән рихләт кылды,
Бер мәнзил Мисра анчак йакын килде,
Мисыр эчрә һавадан бер өн килде:
«Бер газиз шәхес Миср эчрә килер имди.

Малик таҗир сараена хазир килең,
Ул угланны күрмәкгә һәвәс кылың;
Адәмигә биңзәмәздер, зaһир белең,—
Мөкаррәб фәрештәйә биңзәр имди...

Ул килмәке сезә йаулак котлы дорыр,
Гаклы тәмам, сүзе йаулак датлы дорыр,
Үзе гарьләү, хуш холыклы кемсә дорыр,—
Күрмәкгә йаулак мөштак улың имди!»

Миср әһле боны ишдеб сәүнешделәр,
Җөмләләре вармага дирнешделәр,
Олы-кече, ир вә гаурәт йыглашдылар,—
Һәрберсе каршы чыкыб бакыр имди...

...Миср әһле аны күрә калды хәйран,
Әйдәделәр: «Бу дәгелдер адәмидән,
Мөкаррәб фәрештәдер иңде күкдән!» —
Җөмләләре аңа сәҗдә кылыр имди...

Аны күрә Миср әһле мәҗмуг улды.
Малик Дәгыйр сараена хазир килде,
Арзуларын Малик(к)ә заһир кылды:
«Колыңызи бер күрәлем!» — дирләр имди.

Малик әйдер: «Ул морада ирмәйәсез,
Һәргиз бәнем сараема кермәйәсез,
Һәм Йосыфың җәмален күрмәйәсез —
Берәр динар вирмәйен сезләр имди».

Разый улыб, берәр динар килтерделәр,
Дәстүр алыб, сараена һәм керделәр,
Йосыф сыйддыйк җәмалыны һәм күрделәр,—
Бакан һәргиз җәмалына дуймаз имди...

Тәрҗемәсе:

...Малик Дәгыйр ул урыннан күчеп китте,
Мисырга бик якын җиргә барып җитте,
Мисыр халкы шулчак күктән өн ишетте:
«Мисырга бер газиз шәхес килер имди.

Малик Дәгыйр сараена юл тотыгыз,
Ул угланны күрмәк өчен ашыгыгыз,
Адәмгә ул охшамаган, тик белегез,—
Изге фәрештәгә охшап торыр имди.

Килүе аның сезнең өчен булыр котлы,
Гаклы бөтен, әйткән сүзе аның татлы,

Үзе гарьле, хуш холыклы һәм дә затлы,—
Күрергә сез ашыгыгыз аны имди!»

Бу сүзләргә мисырлылар сөенделәр,
Һәммәсе дә күрергә аны җыендылар,
Олы-кече, ир һәм хатын җыелдылар,—
Һәрбересе каршыларга чыгар имди...

...Мисыр халкы, күреп аны, калды хәйран:
«Ул,— диделәр,— адәмнәргә охшамаган,
Күктән иңгән фәрештәдер, юк һич гөман!» —
Шулай дип, аңа сәҗдә кылырлар имди...

Моны күреп, мисырлылар җыелдылар,
Малик Дәгыйр сараена агылдылар,
Теләкләрен аңа шунда белдерделәр:
«Колыгызны күрсәтегез!» — диләр имди.

Малик әйтте: «Бу морадка җиталмассыз,
Сараема һичберегез кералмассыз,
Ул Йосыфның гүзәл йөзен күралмассыз,
Бирмәсәгез берәр динар миңа имди».

Риза булып, берәр динар китерделәр,
Рөхсәт алып, сараена һәм керделәр,
Гүзәллеген ул Йосыфның һәм күрделәр,—
Күргән кеше йөзен карап туймас имди...

[Зөләйханың төше]

...Колак дотыб дыңлагыз ошбу сүзи,
Ул Зөләйха мәликзадә[1], Тәймус кызы,
Тулун ай тик балкыр иде аның йөзе,
Оҗмах эчрә хурел-гайнә биңзәр имди.

---

[1] *Мәликзадә — монда:* патша кызы.

Ул Тәймус мәлик ирде, Мәгъриб[1] и(я)се,
Йөз бең ирдән артык иде анын сүсе,
Аны йаулак гани итмеш гареш изесе,—
Дөнья эчрә олы мәлик кылмыш имди...

Зөләйха мәлик Тәймус кызы ирмеш,
Йастукы атасының дезе ирмеш,
Йосыфың сурәтен дөшдә күрмеш,—
Аңламыш һәм хакыйкать белмеш имди.

Нә кем Йагъкуб Йосыфы сәүәр иде,
Йосыф аның уйлукындан китмәз иде,
Һәм Зөләйха атасына шуйлә ирде,—
Бәлки дагы артуграк сәүәр имди.

Зөләйха бер көни йатыб уйур иде,
Йосыфың сурәтен дөшдә күрде,
Күрүбән һаман сәгать гашыйк улды,—
Аглайуб уйанубән килер имди.

Атасы сорар, әйдер: «Нә агларсән,
Күңелеңдә нә кичәр, нә теләйүрсән,
Дөшең эчрә нә күреб арзуларсән? —
Морадыңы бәңа игълям кылгыл имди».

Зөләйха әйдер: «Бән йатыб уйур идем,
Дөшем эчрә бер зиба сурәт күрдем,
Уйандым, ул сурәти булумадым,—
Ул мәгънәдән аглайур улдым имди.

Ул сурәт күземә күренү килде,
Хатеремне, һушымны җөмлә алды,
Гаклым алыб, сабрымы гарәт кылды,—
Пәйвәстә нәфсем аны эстәр имди».

---

[1] *Мәгъриб — монда:* Африканың төньяк-көнбатыш төбәге.

Тәймус әйдер: «Бән аны күрсәм иде,
Бән аның канналыгын белсәм иде,
Малым-мөлкем җөмлә фида кылсам иде,
Аны сәңа к(а)ушырмакчөн»,— дәйүр имди.

Зөләйха уйкудан мәхрүм калды,
Ай кеби күрекле йөзе, биңзе сулды,
Йимәкдән-эчмәкдән мәхрүм калды,—
Төне-көне Йосыфы үгәр имди.

Бу хәл үзрә бер ел дагы тәмам улды,
Зөләйха ул сурәте кәнә күрде,
Үгетләб Зөләйхайә әйтер иде:
«Йа Зөләйха, үгетеме дотгыл имди!

Бәйан белгел: сән — бәнең, бән — сәнеңвән,
Бәндән үзгә һич кемсәне сән булуманң,
Бәнем гыйшкым хатереңдән сән салуманң —
Бәндин үзгә һич кемсәгә бакманң имди!»

Зөләйха бу кәүлейә разый улды,
Уйкусындан уйгану дора килде,
Катында ул сурәти булумады,—
Ул ук сәгать бихуд улыб дөшәр имди.

Атасы бу хәл эчрә калды хәйран,
Гашыйклык кяр кылдыгын белде бәйан,
Бимарстан эчрә кылыр дөрле дәрман,—
Гаклы килмәз, һич дәва кяр кылмаз имди...

Тәрҗемәсе:

...Колак салып тыңлагыз сез бу сүзләрне,
Ул Зөләйха — мәликзадә, Тәймус кызы,
Тулган айдай балкыр иде аның йөзе,
Оҗмахтагы хур кызына охшар имди.

Тәймус Мәгъриб җирләрендә патша иде,
Гаскәрләре йөз мең ирдән аша иде,

Күк иясе аңа бик зур байлык бирде,—
Дөньяда ул олуг мәлик булган имди...

Ул Зөләйха мәлик Тәймус кызы иде,
Ястыгы шул атасының тезе иде,
Беркөн Йосыф сурәтен ул төштә күрде,—
Аны чын дип аңлаган һәм белгән имди.

Йагъкуб ничек Йосыфны яраткан булса,
Йосыф аның итәгендә яткан булса,
Зөләйха да шундый иде атасына,—
Бәлки тагы артыграк та булыр имди.

Зөләйха беркөнне йоклап ятар иде,
Шунда Йосыф сурәтен ул төштә күрде,
Күрү белән шундук аңа гашыйк булды,
Еглый-еглый ул уянып китәр имди.

Тәймус әйтте аңа: «Кызым, ник еглыйсың,
Күңелеңнән ниләр кичте, ни телисең,
Төштә берәр нәрсә күреп борчылмыймсың? —
Теләгеңне белдерсәңче миңа имди».

Әйтте аңа Зөләйха: «Мин йоклый идем,
Төшемдә мин бик зифа бер сурәт күрдем,
Уянсам, юк иде тирә-юньдә беркем,—
Сәбәбе шул еглавымның минем имди.

Күз алдымда сурәт ачык пәйда булды,
Һушым алып, күңелемне әсир кылды,
Акылымны, сабырымны тартып алды,—
Күңелем аны бертуктаусыз эзләр имди».

Тәймус әйтте: «Үзем аны күрсәм иде,
Аның кайда икәнлеген белсәм иде,
Малым-мөлкем аңа фида кылсам иде,
Кавыштырыр өчен сезне бергә имди».

Зөләйха исә йокысыннан мәхрүм калды,
Ай шикелле матур йөзе тәмам сулды,
Җитте шуңа: ашамас һәм эчмәс булды,—
Көне-төне гел Йосыфны уйлар имди.

Шундый хәлдә тагын бер ел вакыт узды,
Йосыф сурәтен Зөләйха йәнә күрде,
Сурәт аңа үгет биреп болай диде:
«Йа Зөләйха, үгетемне син тот имди.

Син бел шуны: син — минеке, мин — синеке,
Була күрмә миннән башка һичкемнеке,
Онытма бу гыйшкым нинди икәнлекне,—
Миннән үзгә һичкемгә күз салма имди!»

Зөләйха бу сүз-үгеткә риза булды,
Уянды да як-ягына күзен салды;
Сурәт аңа бер җирдә дә күренмәде,—
Шул ук сәгать ул һушыннан язар имди.

Ата кеше, моны күреп, калды хәйран,
Гыйшык сәбәп икәнлеген белде аннан,
Шифаханәдә кылдырды төрле дәрман,—
Гаклы кайтмас, дәва файда итмәс имди...

[Зөләйханың Мисырга килүе]

...Өченче ел ул сурәте кәнә күрде,
Йаулак каты ант виреб, бу гәз сорды:
«Әйт бәңа кем, мәкамең канда? — диде.—
Хакыйкать, бәне мәхрүм куйдың имди!»

Йосыф әйдер: «Йа Зөләйха, бәне күргел,
Байык Миср газизе бәнвән — белгел,
Әгәр бәне эстәр ирсәң, Мисра килгел,—
Байык бәни Миср эчрә булгыл имди...»

...Зөләйха моны ишедеб үрә дорды,
Сүзен аңды, гаклы килде, фәһем дирде,
Атасына бу әхвальдән хәбәр вирде:
«Эстәдегем — Мисыр и(йә)се!» — дәйүр имди.

...Атасы бу әхвале тәхкыйк белде,
Бөти йазыб, Мисp таба кеше салды,
Бөти йазыб, төгәл әхваль игълям кылды:
«Бер кызым вар, мөдам сәне теләр имди...»

...Ул вакыт Мисра газиз Кыйтфир иде,
Йалауачлар бөти берлә аңа килде,
Бөти укыб, рәва күрде, риза вирде —
Җаваб бөтеб рәсүл ирсаль кылыр имди.

«Һәркем бәне теләйүрсә — теләйүрмән,
Һәзар чәндан арзу берлә эстәйүрмән,
Малым-мөлкем җөмлә фида әйләйүрвән,—
Җаным берлә кабул кылдым»,— дәйүр имди.

Кыйтфирнең йалауачы килде исә,
Тәймуса җавабнамә йазды ирсә,
Бөти укыб, хәлен мәгълүм кылды ирсә,
Зөләйхани йараг кылыб күндерер имди.

Бең катарә дәвә мал йөкләт(дер)де,
Дагы бең кол-карауаш атландырды,
Зөләйха Мисp эчрә килде-керде,
Сарай эчрә тәхет уруб ултырыр имди.

Хәрир киде, таҗ уранды, тәхтә агды,
Күңле ачлыб, хәтеренә шады йагды,
Һәмана кем, унтүртенче көн — ай тугды,—
Биңзе нуры көнәш кеби балкыр имди...

...Ул ук сәгать бәкләр берлә газиз килде,
Бәкләр китде — газиз анда йалгыз калды,

Аны күреб, Зөләйха фөрйад кылды:
«Бу ни ирдер, нишә калды?» — дәйүр имди.

Карауашлар Зөләйхайә әхваль әйдер:
«Байык, Миср газизе солтан будыр,
Хакыйкать, сәнең зәуҗең Кыйтфир дорыр,—
Әдәпсезлек кылмагыл»,— дирләр имди...

...Тәлим мөддәт чук кичде анда кәзин,
Зөләйха Кыйтфирдән саклар үзен,
Арзулайур, сулдырыр күрекле йөзен,—
Пәйвәстә ул Йосыфы үгәр имди.

Халикъ саклар Кыйтфирдән Зөләйханы,
Йосыф өчен саклар иде Халикъ аны,
Һәм йәнә Кыйтфир дәгый белмәз аны,—
Хаҗәт ирсә, җен кызы килер имди...

Тәрҗемәсе:

...Өченче ел сурәтне ул йәнә күрде,
Бик нык аңлап, аңарга ул сорау бирде;
«Әйтче, кем син, торган җирең кайда? — диде.—
Бар нәрсәдән мине мәхрүм кылдың имди!»

Йосыф әйтте: «Йа Зөләйха, әйтим шуны,
Мин Мисырның хөкемдары, бел син моны,
Мисырга кил, теләр булсаң әгәр мине,—
Табарсың син, шиксез, мине шунда имди...»

...Зөләйха моны ишеткәч үрә торды,
Хәлне аңлап, зиһенен һәм гаклын җыйды,
Атасына бу турыда хәбәр кылды:
«Теләгәнем — Мисыр хөкемдары имди!..»

...Кайчан Тәймус мондый хәлне анык белде,
Язу язып, Мисырга илче күндерде,
Язуында әхвальне аңа белдерде:
«Бер кызым бар, ул сине теләр имди...»

...Ул чак Мисыр хөкемдары Кыйтфир иде,
Тәймус хатын илчеләре аңа бирде,
Кыйтфир, укып ул язуны, риза булды,—
Җавап язып җибәрде ул илче имди:

«Кем теләсә мине, аны мин теләрмен,
Йөз мең теләк белән аны каршыларлармын,
Мал-милкемнең барын аңа багышлармын,
Чын күңелдән кабул кылдым»,— дияр имди.

Ул Кыйтфирнең илчеләре килү белән,
Тәймус аның җавап хатын алу белән,
Җавабының нindilегән белү белән,
Зөләйханы ул Мисырга юллар имди.

Мең дөя һәм качырга мал йөкләттерде,
Мең кол белән мең карауаш атландырды,
Зөләйха Мисырга шулай килеп керде,—
Сарайда ул бер тәхет кордырыр имди.

Таҗын киеп, шул тәхеткә ул утырды,
Күңеле ачылып, шатлык белән тулды,
Гүя айның ундүртенче көне туды,—
Йөзе нурлы кояш кебек балкыр имди...

...Шул сәгатьтә бәкләр белән газиз[1] килде,
Бәкләр чыгып китте, газиз ялгыз калды,
Зөләйха аны күрүгә фөръяд кылды:
«Бу нинди ир, нигә калды?» — дияр имди.

Карауашлар Зөләйхага җавап бирде:
«Бу ир — Мисырның газизе Кыйтфир,— диде.—
Хакыйкатьтә синең ирең шушы инде,—
Әдәпсезлек күрсәтмә син, зинһар имди...»

---

[1] ***Газиз — монда:*** хөкемдар.

...Үтеп китте бик күп вакыт аннан бирле,
Зөләйха үзен Кыйтфирдән саклый иде,
Йөзен өмет сулдырса да тәмам инде,
Берөзлексез ул Йосыфны уйлар имди.

Кыйтфирдән саклады Халикъ Зөләйханы,
Йосыф өчен саклый иде Ходай аны,
Кыйтфир һич тә белми иде ни булганны,—
Хаҗәт булса, пәри кызы килер имди...

[Мисыр патшасының Йосыфны сатып алуы]

...Андан соңра йиде ел дәхи кичде,
Хәлләр дүнде, тәлим айлар килде, күчде,
Гакыйбәт Йосыф дәгый Мисра дөшде,—
Миср эчрә кол улыб сатылыр имди.

Мөнадиләр базар эчрә йөгерешерләр:
«Бу угланны кем сатун алур?» — дирләр;
Күрекле йөздән нәкаби күтәрделәр,
Биңзе нуры көн йахтусын тотар имди.

Һич кемсәнә аны сатун алумады,
Бәһа йитереб кемсә йакын килүмәде,
Миср малы аңа бәһа улумады,—
Галәм малы аңа бәһа улмаз имди!..

...Ул ук сәгать әмер кылды анда Кыйтфир:
«Күшек уңы мәйданыны бизәңез,— дир,—
Хәрир-зиба дүшәкләр дүшәңез»,—дир,—
Чүрәсенә тәлим көрси корарлар имди...

...Ушалдәм Йосыф анда хазир килде,
Биңзе нуры сарай эчен рәүшан кылды,
Зөләйха бакыб филхаль аны күрде,—
Һәмандәм бихуд улыб дөшәр имди...

Газиз әйтер: «Бу угланны бәңа сатгыл,
Йенжү-мәрҗән, гәүһәр-йакут бәндән алгыл,
Нәчә бәһа кирәк ирсә, бәйан кылгыл,—
Кыйммәтен мөгаййән сән кылгыл имди...»

...Ушал дәмдә Йосыфы газиз алды,
Малик Дәгыйр Йосыфа нәзар салды,
Әлендә нөбүввәт нурын күрде,—
Сатлыгына пошиман улыр имди...

...Андан соңра Йосыфа газиз сорды,
Хөрмәтене, кадерене бу гәз белде,
Әлен алыб, Зөләйхайә тәслим кылды:
«Бу мөбарәк угланчыкны сакла имди.

Йа Зөләйха, бу угланны хөрмәт кылгыл,
Гаять олы аңа лаек гыйззәт кылгыл —
Бәнән аңа артугырак тәгъзыйм кылгыл,—
Бәзем бу углымыз улсын имди».

Газиз сүзен Зөләйха рәва күрде,
Йосыфы агырлады, хөрмәт кылды,
Өч йөз алтмыш әлван дөрле тун әйләде,—
Һәр көндә бер дөрлесен кидерер имди...

Тәрҗемәсе:

Аннан соңра нәкъ җиде ел тагын үтте,
Хәлләр кичте, бик күп айлар килеп-китте,
Ахыры Йосыф Мисырга килеп җитте,—
Мисырда ул кол итеп сатылыр имди.

Өндәүчеләр базар буйлап әйләнделәр,
«Бу угланны сатып ала кем?» — диделәр;
Гүзәл йөзеннән пәрдәсен күтәрделәр,—
Йөз нурлары көн яктысын каплар имди.

Бер кеше дә аны сатып алалмады,
Бәһа биреп, аңа якын килалмады,

Мисыр малы аңа бәһа булалмады,—
Җиһан малы аның өчен җитмәс имди!..

...Шул ук сәгать Кыйтфир мондый әмер бирде:
«Сарай алды мәйданын бизәгез,— диде,—
Затлы ефәк түшәкләр түшәгез»,— диде,—
Тирәсенә көрсиләр корырлар имди...

...Кайчан Йосыф шул мәйданга килеп керде,
Нуры белән бөтен сарай эче тулды,
Зөләйха да, карап шуннан, аны күрде,—
Күрү белән һушсыз булып төшәр имди...

...Газиз әйтте: «Миңа аны сатыгыз сез,
Энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут алыгыз сез,
Нинди бәһа тиеш — игълан кылыгыз сез,—
Чын бәһасен белдерегез ачык имди!..»

...Шул ук мәлдә Йосыфны газиз алды,
Малик Дәгыйр үз колына күзен салды,
Кулында аның пәйгамбәрлек нурын күрде,—
«Ник саттым?» — дип пошиманга төшәр имди...

...Соңра газиз ул Йосыфка сорау бирде,
Сораштырып, хөрмәтен һәм кадерен белде,
Зөләйхага алып килеп, болай диде:
«Бу мөбарәк угланчыкны сакла имди.

Йа Зөләйха, хөрмәт кыл син бу угланга,
Һәрвакытта күрсәт лаек кадер аңа,
Тырыш миннән артык аны олыларга,—
Йосыф безнең үз углыбыз булсын имди».

Зөләйха хөкемдар сүзен кабул күрде,
Йосыфны ул олылады, хөрмәт кылды,
Өч йөз алтмыш төрле кием әзерләде,—
Һәр көнне бер төрлесен кидерер имди...

[Зөләйханың мәхәббәт газаплары]

...Мөшкел хәлгә дөшде ул анда кәзин,
Бер сәгатьгә күрмәсә Йосыф йөзен,
Сабры калмаз, аңламас кемсә сүзен,—
Нә сүзләсә, «Йосыф!» дәйү сүзләр имди.

Бәгъдазан тәнендән кан алдырса,
Хәҗҗам аның тамырына ништәр урса,
Галялхаль каны акыб, йирә тамса,
Йир үзрә Йосыф ады йазылыр имди!

Һәр заманда күкләр таба нәзар кылса,
Күк йөзендә улдызлары күрер исә,
Һәмандәм Йосыф анда килер исә,—
Улдызлар (һәм) Йосыф дәйү сүзләр имди!..

Тәрҗемәсе:

...Ул бик мөшкел хәлдә сизде соңра үзен,
Берәр сәгать күрми торса Йосыф йөзен,
Сабры бетте, аңламады һичкем сүзен,—
Ни әйләсә, «Йосыф!» диеп әйтер имди.

Берәр вакыт тамырыннан кан алдырса,
Тамырына пәке белән табиб сызса,
Шул чагында каны агып җиргә тамса,—
Җирдә Йосыф исеме язылыр имди!

Кайчагында күккә аның күзе төшсә,
Күк йөзендә йолдызларны күрер исә,
Хәтеренә әгәр шунда Йосыф килсә,—
Йолдызлар да Йосыф исемен әйтер имди!..

[Зөләйха турында Мисыр хатыннарының гайбәте]

...Миср эчрә бер нәчә урагутлар,
Боны ишдеб бер-беренә сөйләшделәр,
Ул хатынлар Зөләйхадан көлешделәр,—
Һәрберсе бер дөрлү сүз сүзләр имди.

«Зөләйха колына гашыйк улмыш,
Колы мотыйг улмамыш — рисва улмыш,
Газиз дәгый ул әхвали бәллү белмеш,—
Колын куа чыкдыгын күрмеш имди...»

...Зөләйха бу әхвали бәллү белде,
Йаулак олы дөкүн әйләб дәгъвәт кылды,
Җөмлә анда дүрт йөз гаурәт хазир килде,—
Барчасы түрә кичеб ултырыр имди...

...Зөләйха Йосыфка зиннәт вирде,
Кәнде әлен Йосыфың сачен үрде,
Кызыл алтун афетабә әленә вирде,—
Күтәрүбән ул мәҗлесә илтәр имди.

Ул гаурәтләр көрси үзрә ултырдылар,
Берәр төрөнеж, берәр пычак килтерделәр,
Әлә виреб, «кисең!» дәйү боердылар,—
Ул хәл үзрә Йосыф дәгый килер имди.

Йосыф сари күзләре дөшмеш улды,
Йосыфың җәмалына хәйран калды,
Ул гаурәтләр бакубән аны күрде,—
Төрөнеж саныб, бармакларын кисәр имди...

...Зөләйха әйтер: «Сезләр, гайан күрдеңезме,
Бәнем биңзем сулдыгын белдеңезме,
Бер бакымдан әлләреңез кисдеңезме,—
Бихуд улыб дөшдеңезме? — дәйүр имди.—

Бән Йосыфы күрдекем йите елдыр,
Йосыф үзрә гыйшкым мөдам арта дорыр,
Мескен үзем бичара, гаҗиз дорыр,—
Шөйлә икән, сабрым сездән артык имди!..»

Тәрҗемәсе:

...Мисырдагы кайсыбер хатын-кызлар,
Ишетеп бу хәлне, бергә җыелдылар,
Зөләйханың хәлен сөйләп кәлештеләр,—
Һәрбересе бер төрле сүз сөйләр имди.

«Үз колына ул Зөләйха гашыйк булган,
Колы аңа буйсынмаган, рисвай кылган,
Эшнең нидә икәнлеген газиз белгән,—
Кол артыннан йөгергәнен күргән имди...»

...Кайчан бу хәл Зөләйхага ишетелде,
Бик зур мәҗлес җыярга ул карар бирде.
Мәҗлесенә аның дүрт йөз хатын килде,—
Барчасы да кереп түргә узар имди...

...Йосыфны ул бик зиннәтләп киендерде,
Чәчләрен үз кулы белән тарап үрде,
Кулына зур кызыл алтын табак бирде,—
Йосыф аны шул мәҗлескә илтәр имди.

Ул хатыннар көрсиләргә утырдылар,
Берәр пычак һәм әфлисун тоттырдылар:
«Әфлисунны турагыз!» — дип боердылар,—
Нәкъ шулвакыт Йосыф килеп керер имди.

Йосыф таба борылып бер карадылар,
Гүзәллеген күреп аның таң калдылар,
Һәммәсе дә күз алалмый карап аңар,
Әфлисун дип, бармакларын кисәр имди...

...Зөләйха әйтте: «Инде сез күрдегезме,
Йөзем нидән сулганлыгын белдегезме,
Бер күрүдә кулыгызны кистегезме,—
Акылыгыз җуйдыгызмы? — дияр имди.—

Нәкъ җиде ел инде аны мин күргәнгә,
Гыйшкым аңар көчәядер көннән көнгә,
Гаҗиз булдым, чара тапмыйм мондый хәлгә,—
Димәк, сабрым сезнекеннән артык имди!..»

[Йосыфның зинданга керүе]

...Зөләйха әйдер: «Йә әмремә мотыйг ула,
Шөйлә бәнем бу рәнҗемә мәрһәм ула,
Йә ки мәхбүс кыйлам, зиндан эчрә кала —
Төгәл гомре зиндан эчрә калсын имди».

Йосыф һәрдәм йалварыр сөбханына:
«Бәне салгыл бу Кыйтфирнең зинданына,
Куркарым дөшәрмен диб гыйсъянына,—
Батыйль эшдән бәңа зиндан йәгрәк имди!..»

...Халикъ җәббар морадын аңа вирде,
Иблис мәлгунь морадыны батыйль кылды,
Зөләйханың фетнәсендән һәм кортарды,—
Батыйльдан нәфсен манигъ улыр имди...

Тәрҗемәсе:

...Зөләйха әйтер: «Әмремә йә буйсына,
Шулай итеп, бу рәнҗемә дәва кыла,
Йә яптырам, зинданда ул торкын була,—
Бөтен гомре шул зинданда үтә имди».

Йосыф исә Тәңресенә гел ялына:
«Салдыр мине,— ди,— Кыйтфирнең зинданына,
Төшәрмен дип куркам гөнаһ тозагына,—
Гөнаһ эштән зиндан миңа артык имди!..»

...Халикъ Йосыфның теләген кабул кылды,
Иблис-ләгыйньнең морады көчсез калды,
Зөләйханың фетнәсеннән котылдырды,—
Бозык эштән Йосыф нәфсен тыяр имди...

[«...Синең хәсрәтеңне йота Йагъкуб»]

...Йосыф ул зиндан эчрә бакый калды,
Кәнгандән[1] бер әгъраби Мисра килде,
Дәричәдән бакыб аны Йосыф күрде,—
Дәвә сөреб, тәгъҗил берлә кичәр имди.

Ул әгъраби зинданә якын килде,
Йосыф анда ирдекен дәвә белде,
Йосыфа дәвә бузлап зарый кылды,—
«Бән Кәнгандән килермен,— дәйүр имди.

Атаң Йагъкуб(и) Кәнгандә күреб килдем,
Аның хәле гөрбәтен белеб килдем,
Хәсрәт зарый кылдыгын күреб килдем,—
Ул мәхзүннең һәрдәм хөзне артар имди.

Мөдам сәнең хәсрәтең дотар Йагъкуб,
Галәм эчрә кич булумаз сәндән мәхбүб,
Сәне аңыб, йирә дөшәр аглаб, угыныб,—
Бер нәчә хәл бихуд улыб йатыр имди.

Агламакдан ике күзин күрмәз улды,
Зәгыйфьлекдән сүңәкләре дормаз улды,
Һич канча эшә күчә вармаз улды,—
Һәрдәм ул Йосыф дәйү аглар имди.

Һәрдәм ул Йосыф дәйү агладыкдан,
Агламага касд-у һиммәт багладыкдан,
Висаль уңуб, фирак илә чугладыкдан,—
Яшь йиренә күзендән кан акар имди!

Мөдам мәгъмум улубән дөн-көн аглар,
Аның зарый кылдыгыны галәм таңлар,
Рәхим Мәүлам рәхмәтенә билен баглар,—
Висаль умар, һәргиз өмид кисмәз имди...»

---

[1] *Кәнган* — Йагъкуб һәм аның балалары яшәгән төбәк.

...Йосыф нәби, боны ишдеб, зар аглады,
Әгърабинең әлен дотыб асмарлады:
«Әманәт — Йагъкубә варгыл,— диде,—
Ул мәхзүнә бәндән сәлям айгыл имди...»

Тәрҗемәсе:

...Ул заманда Йосыф озак тоткын булды,
Шул арада Кәнганнан бер гарәп килде,
Бу гарәпне Йосыф тәрәзәдән күрде,—
Ул ашыгып дөя куып барыр имди.

Кайчан гарәп бу зинданга якын килде,
Йосыф анда икәнлеген дөя белде,
Дөя аңа еглый-еглый зарый кылды:
«Мән Кәнганнан килдем монда,— дияр имди.—

Анда атаң Йагъкубны мин күреп килдем,
Аның хәле мөшкеллеген белеп килдем,
Кайгырып зар еглаганын үзем күрдем,—
Көннән көнгә хәсрәтләре артыр имди.

Даим синең хәсрәтеңне йота Йагъкуб,
Аңа синнән сөеклерәк беркем дә юк,
Уйладымы сине — һушсыз кала шундук,—
Һушсыз булып озак вакыт ятар имди.

Еглый-еглый ике күзе күрмәс булды,
Көчсезлектән буыннары тотмас булды,
Бернинди дә эшкә көче җитмәс булды,—
Һәрдаим ул Йосыф диеп еглар имди.

Берөзлексез Йосыф диеп еглаганга,
Бар өметен еглау белән баглаганга,
Кавышуны уйлап һаман аһлаганга,—
Яшь урнына күзеннән кан агар имди!

Кайгырып ул һаман шулай көн-төн еглар,
Бөтен кеше гаҗәпләнә, карап аңар,

Мәүлабызның (Тәңребезнең.— *Х. М.)* рәхмәтенә өмет
баглар,—
Кавышудан һич өметен өзмәс имди...»

...Йосыф аны еглый-еглый тыңлап торды,
Кулын тотып, үтенечен әйтеп бирде:
«Әманәт шул — Йагъкубка кер кайткач,— диде,—
Ул мескенгә миннән сәлам тапшыр имди...»

[Йосыфның төшне юравы һәм зинданнан чыгуы]

...Хөкме берлә тәкъдир кылды мәлик дәййан,
Бер дөш күрде Мисыр шаһе мәлик Рәййан[1],
Мөгаббирләр бу дөш эчрә калды хәйран,—
Һичкем ирсә аңа тәэвил белмәз имди.

Рәййан әйдер: «Йите симез сыгыр күрдем,
Җөмләсенең аркасына бенәр ирдем,
Бересендән бересенә кичәр ирдем,—
Бу дөш эчрә гаҗаибә калдым имди.

Йәнә күрдем йите сыгыр — йаулак зәгыйфь,
Йителәсе каты зәгыйфь, улмыш нәхиф,
Ачлыкдан улмышлар йаулак нәхиф,—
Ул симез сыгырларны йийәрләр имди!..

Йите сөнбел дәгый богдай берлә күрдем,
Йәнә йите сөнбел дәгый корыр күрдем,
Йәнә богдайлары күкгә очды, күрдем,—
Өч баш богдай йәнә йирдә калыр имди...»

...Йосыф әйдер: «Йиде ел очсыз ула,
Әлван дөрлү нигъмәт илә галәм дула,
Андан соңра кызлык ула, муңлу ула,—
Йиде ел газим дарлык ула имди.

---

[1] Йосыф төрмәгә кергәч, Кыйтфир үлеп, тәхет аның кардәше Рәййанга күчә.

Андан соңра рәхман рәхим кылдачыдыр,
Мәхлук үзрә шадлык-рахәт килдәчедер,
Дөрлү нигъмәт арзанлыклар улдачыдыр,—
Дөрлү нигъмәт көндин-көнә артар имди...»

...Йосыф сыйддыйк зиндандан хәлас улды,
Зиндан әһле аглашу мәхрүм калды,
Бәс, анлара Йосыф сыйддыйк дога кылды,—
Догасыны Тәңре мәкъбүл идәр имди...

Тәрҗемәсе:

...Хөкме белән әмер итеп мәлик-рәхман,
Бер төш күргән Мисыр шаһы мәлик Рәййан,
Юраучылар мондый төшкә калган хәйран,—
Һичберсе дә аңа юрау тапмас имди.

Рәййан әйткән: «Җиде симез сыер күрдем,
Һәркайсының аркасына менеп йөрдем,
Берсеннән-берсенә шунда күчә тордым,—
Мондый төшкә гаҗәпләнеп калдым имди.

Күрдем йәнә җиде сыер — бар да арык,
Бар да хәлсез, бар да беткән арыкланып,
Ачыгудан булган алар шундый ябык,—
Симезләрен арыклары ашар имди!..

Тагын күрдем тулып җиткән җиде башак,
Йәнә корып-кибеп беткән җиде башак,
Бодайлары очып китте күккә шулчак,
Тик өч бөртек җирдә торып калыр имди...»

...Йосыф әйтте: «Нәкъ җиде ел иген уңа,
Төрле нигъмәт-азык белән дөнья тула,
Аннан соңра корылык һәм кытлык була,
Нәкъ җиде ел зур авырлык булыр имди.

Аннан соңра Тәңре мәрхәмәт кылачак,
Кешеләргә шатлык-рәхәтләр киләчәк,

Төрле нигъмәт, арзанлыклар күп булачак,—
Байлык-муллык көннән көнгә артыр имди...»

...Тугры Йосыф тоткынлыктан азат булды,
Зиндан әһле еглап аннан аерылды,
Алар өчен тугры Йосыф дога кылды,—
Бу догасын Тәңре кабул кылыр имди...

[Йосыфның гадел хөкемдар булуы]

...Рәййан күрде Йосыфның җәмалыны,
Гаҗәбләде халкыны һәм хуш холкыны,
Аңа вирде мөлкене һәм малыны:
«Мөлекемә сәндан бойрык улсын имди!..»

...Таҗ уранды, тәхтә агды Йосыф нәби,
Утыз йәшәр егетләрдән ирде гомре,
Биңзе нуры рәүшан ирде көнәш кеби,—
Бакан һәргиз йөздән дуймаз имди.

Гаклы камил, гыйлем вә хикмәт камил белер,
Мөддәгыйләр дәгъва берлән аңа килер,
Хас(с)-у гамә гадел дөрест хөкем кылыр,—
Һич кемсәгә җәүр-ү җәфа кылмаз имди...

...Мисыр эчрә йиде ел киңлек улды —
Дөрлү әлван нигъмәт илә галәм дулды,
Ул хәл кичде, йиде ел дарлык улды,—
Кайгырубән: «Иген икмәң!» — дәйүр имди...

...Ушалдәм шиддәт китде, рәхәт йитде,
Мисыр эчрә Йосыф олы мәлик улды,
Изеси олы мәләкәт рузи кылды,—
Тәмам эшне ихсан илә эшләр имди...

Тәрҗемәсе:

...Мәлик Рәййан аның нурлы йөзен күрде,
Сыйфатын күреп һәм гаҗәпләнде,

Бөтен малын һәм мөлкәтен аңа бирде:
«Бар да синең бойрыгыңда!» — дияр имди...

...Йосыф нәби таҗ киеп тәхеткә менде,
Бу вакыт ул утыз яшәр егет иде,
Кояш кебек йөзеннән нурлар сибелде,—
Күргән кеше күреп һич тә туймас имди.

Гаклы камил, хикмәт гыйльмен яхшы белер,
Дәгъвачылар дәгъва белән аңа килер,
Бай-ярлыга дөрес, гадел хөкем кылыр,—
Берәүгә дә җәбер-җәфа кылмас имди...

...Мисырда җиде ел буе иген уңды,
Төрле ризык белән бөтен дөнья тулды,
Аннан соңра җиде ел корылык булды,—
Кайгырып: «Иген икмәгез!» — дияр имди...

...Шулай михнәт китеп, рәхәт көннәр килде,
Йосыф Мисыр җирендә зур патша булды,
Иляһ аңа зур мәмләкәт насыйб кылды,—
Бөтен эшен игелек белән эшләр имди...

[Зөләйханы никах кылуы]

...Зөләйха әйдер: «Ишет, йа шаһе җиһан,
Хәлем зәгыйфь, күзем күрмәз, белгел бәйан,
Мисыр и(йә)се газиз җефте Зөләйхамән,—
Бән ул хәлдән бу халә дөшдем имди!..»

...Зөләйха әйдер: «Җәмалым, малым вирдем,
Сәнең өчен җөмләсен фида кылдым,
Бәхетемдән, тәхетемдән кирү дүндем,—
Сәнең гыйшкың бәңа әсәр кылды имди!..»

Йосыф әйдер: «Бәллү сән гашыйк ирсәң,
Гыйшыклыкда гәрчәк улыб, салыйк ирсәң,

Гыйшык зарын, дәгъвасен кылыр ирсәң,—
Бу дәгъвая бер борһан кирәк имди».

Зөләйха әйдер: «Имди сән йакын килгел,
Кәрәм әйләб, камчыңны бәңа виргел,
Гашыйк ирсәм, сән бәне бәллү белгел,
Дәгел ирсәм — бу дәгъвам батыйль имди».

Йосыф аңа камчыны сону вирде,
Бер «аһ» өрде, Йосыфа кире вирде,
Камчыга ут доташыб йанар күрде,—
Йанубән Йосыф әлен көйдерер имди.

Камчыны б(ы)ракды Йосыф сыйддыйк,
Зөләйханың гыйшкыны белде тәхкыйк,
Һич гөманы калмады, дотды тәсдыйк,—
Гаҗәбләйү ат гыйнанын дүндерер имди.

Зөләйха әйдер: «Күрдеңме, аңладыңмы —
Камчыга уд доташдыгын таңладыңмы?
Ушал удың йандыгына дүзмәдеңме? —
Кырык елдыр, ул уд бәне йакар имди...»

...Һәмандәм Җәбраил хазыйр килде,
Хакъ сәламен Йосыфа һәм тикерде:
«Зөләйхайә гакд-у никах кылсын,— диде,—
Сән — падишаһ, ул — хатын улсын имди».

Җәбраилдән Йосыф сыйддыйк боны белде,
Зөләйханың мәкаменә кире варды,
Бу әхвале мөждәләде, бәйан кылды:
«Йа Зөләйха, рәхәт ирде»,— дәйүр имди.

Боны ишдеб, Зөләйха улды мәгълүм:
«Ходавәндә, бәнем хәлем сәңа мәгълүм,
Малымдан, җәмалымдан калдым мәхрүм,—
Үзем кари, ике күзем күрмәз имди!..»

...Ул ук сәгать Җәбраил хазыйр килде,
Канадилә сыйфады, дога кылды,
Зөләйханың күзе күрде, йекет улды,—
Биңзе нуры тулун ай тик балкыр имди.

Зөләйхайә ул дәм гакд-у никах кылды,
Йосыф ул дәм йаулак олы дәгъвәт кылды,
Олы бәкләр өндәлеб, хазыйр килде,—
Йаулак олы бәшарәтләр улыр имди...

...Аннан соңра Хакъдан тәкъдир уйлә килде,
Ул икенең бакый гомре буйлә улды:
Унике угыл Ходა рузи кылды,—
Олысына Мөсалим дирләр имди...

Тәрҗемәсе:

...Зөләйха әйтте: «Шаһе җиһан, менә күр син,
Хәлем зәгыйфь, күзем сукыр; янә бел син:
Мисыр хакиме Кыйтфирнең җефете мин,—
Шундый хәлдән бу хәлләргә төштем имди!..»

...Зөләйха әйтте: «Җәмалым, малым бирдем,
Синең өчен һәммәсен дә фида кылдым,
Бәхетемнән, тәхетемнән аерылдым,—
Синең гыйшкың шулай тәэсир итте имди!»

Йосыф әйтте: «Әгәр чынлап гашыйк булсаң,
Гыйшыклыкта чын тугрылык саклый алсаң,
Гыйшык зарын аңлауга дәгъва кылсаң,
Бу дәгъвага бирәр дәлил кирәк имди».

Зөләйха әйтте: «Инде кил син яныма,
Рәхим итеп, бу камчыңны бир кулыма,
Гашыйк булсам, ул күрсәтер моны сиңа,—
Күрсәтмәсә, дәгъвам ялган булыр имди».

Йосыф, килеп, аңа үз камчысын сонды,
Хатын камчыга өрде дә кире бирде,

Камчыга ут кабынганын Йосыф күрде,—
Камчы яныб, Йосыф кулын пешрер имди.

Тугры Йосыф ул камчыны атып бәрде,
Зөләйханың гашыйклыгын ачык белде,
Һич калмады шиге, тугрылыгын күрде,—
Гаҗәпләнеп, ат тезгенен тартыр имди.

Зөләйха әйтте: «Күрдеңме, аңладыңмы,
Камчыга ут кабуга син таң калдыңмы?
Кулыңны пешергәнгә түзалмадыңмы? —
Ул ут мине кырык ел көйдерә имди!..»

...Шулчак Йосыф янына Җәбраил килде,
Хак сәламен аңарга ул ирештерде:
«Зөләйханы никах кылып ал син,— диде,—
Син — падишаһ, ә ул — хатын булсын имди».

Кайчан Йосыф Җәбраилдан хәбәр алды,
Зөләйха торган урынга кире барды,
Бу турыда сөйләп, аны шатландырды:
«Йа Зөләйха, рәхәт җитә»,— дияр имди.

Моны ишеткәч, Зөләйха хәсрәтләнде:
«Йа Иляһым, хәлем сиңа мәгълүм,— диде,—
Малым бетте, җәмалымның күрке китте,
Күзем сукыр, үзем карчык булдым имди...»

...Шул ук сәгать янына Җәбраил килде,
Канаты белән бер сыйпап дога кылды,
Зөләйханың күзе ачылды, яшь-яшь булды,—
Тулган айдай йөзе нурдан балкыр имди.

Зөләйханы Йосыф никах кылып алды,
Зур мәҗлескә бик күп кунак чакырылды,
Чакырылган олуг бәкләр бар да килде,—
Бик күп шатлык, сөенечләр булды имди...

...Аннан соңра Хак тәкъдире шулай булды,
Алар икәү гомер буе бергә торды,
Ходa аларга унике ул бүләк кылды,—
Олысына Мөсалим диярләр имди...

[Йосыфның сарай салдыруы һәм агаларын гафу итүе]

...Фәрман кылды: «Бәнналар хазыйр килсен,
Гаҗәб йүксәк, мәхкәм сарай бина кылсын,
Ул сарайның буе кырык аршын улсын,
Һәм йүксәке кырык аршын улсын имди.

Бизәсенләр анда Йагъкуб сурәтене.
Һәм йәнә бизәсенләр угланлары,
Угланлары Йосыфа нә кылдыгыны,—
Җөмләсен анда мәктүб кылсын имди.

Алдайубән атасындан алдыкларын,
Дунын суйыб, дар койуйә салдыкларын,
Үлдермәкгә хакыйкать касд кылдыкларын —
Җөмләсене ул диварә йазсын имди!

Һәм койудан чыкардыкда килдекләрен,
Колымыз диб, йалан сату кылдыкларын,
Йәнә сатыб, аз бәһа алдыкларын,
Өч гайбе дидекләрен йазмыш имди!»

Газиз Йосыф анда олы дәгъват кылды,
Сарай эчрә дөрле нигъмәт хазыйр кылды,
Кунаклара тәлим дөрле ашлар куйды,—
Ихванларын кунаклайу өндәр имди.

Кардәшләре ул сарайга килеб керде,
Рауил бакды, ул йазуны анда күрде,
Хөфийә берлә бер-беренә мәгълүм кылды:
«Безем батыйль гамәлемез!» — дирләр имди.

«Атамыздан Йосыфы без алдыгымыз,
Атамыза гасый-җафи улдыгымыз,
Һәр нә эш кем Йосыфа без кылдыгымыз —
Бә маликнең сараена йазмыш имди!»

Бу ун кардәш ул язуны анда күрде,
Кәндүләре батыйль эшен гаҗәбләде,
Нидамәтдән эшләренә тәүбә кылды,—
Йимәк-эчмәк кайгусы китде имди...

...Йосыф әйдер: «Калдырыгыз башыңызи,
Багышладым ушал батыйль эшеңези,
Кайгырмаңыз, мәгаф кылам имди сези,—
Сөчүеңези кичердем бән»,—дәйүр имди.

Башларын калдырубән күрешделәр,
Йаулак каты хәсрәтилә аглашдылар,
Камуларын олы үнин иңрәшделәр,—
Аны күреб, фәрештәләр аглар имди...

Тәрҗемәсе:

Әмер бирде Йосыф: «Төзүчеләр килсен,
Гаҗәп биек, таза сарай бина кылсын,
Ул сарайның буе кырык аршын булсын,
Биеклеге дә шулкадәр булсын имди.

Ясасыннар анда Йагъкубның сурәтен
Һәм йәнә угланнарының кыяфәтен,
Аларның Йосыфка ниләр күрсәткәнен,—
Һәммәсен дә ясасыннар анда имди.

Алдап, аны атасыннан алулары,
Чишендереп, тар коега салулары,
Үтерергә аны ният кылулары —
Һәммәсе дә ул диварда булсын имди!

Ул коедан чыккач, шунда килүләре,
Колыбыз дип, ялган сату кылулары,

Йәнә сатып, бик аз бәһа алулары,
Өч гаебен санау да язылсын имди!»

Газиз Йосыф аннан бик зур мәҗлес җыйды,
Бу мәҗлескә бик күп нигъмәт әзер кылды.
Кунакларга төрле-төрле ашлар куйды,—
Кардәшләрен шул сарайга дәшәр имди.

Кардәшләре ул сарайга килеп керде,
Сарайдагы рәсемнәрне Рауил күрде,
Шыпырт кына һәрберенә мәгълүм кылды:
«Безнең батыйль эшләребез!» — дияр имди.

«Атабыздан Йосыфны алуыбыз да,
Аны кайгы-җәфага салуыбыз да,
Йосыфка нинди эшләр кылуыбыз да —
Һәммәсе дә сурәтләнгән монда имди!»

Бу ун кардәш сурәтләрне күреп инде
Яман гамәлләре өчен бик үкенде,
Мондый гөнаһ эшләреннән тәүбә кылды,—
Ашау-эчү кайгылары китте имди...

...Йосыф әйтте: «Күтәрегез башыгызны,
Багышладым бөтен бозык эшегезне,
Кайгырмагыз, гафу итәм бүген сезне,—
Кичерәмен гайбегезне»,— дияр имди.

Алар башларын күтәреп күрештеләр,
Күзләреннән яшьләр түгеп еглаштылар,
Һәммәсе дә аһлар орып иңрәштеләр,—
Моны күреп, фәрештәләр еглар имди...

[Ата белән угылның очрашуы]

...Андан Йосыф кардәшләргә хәлгать вирде,
Алтын-көмеш, ат-катыр буйла вирде,
Атасына килмәкгә рөхсәт вирде:
«Вәгтуни би-әһликөм!» — дәйүр имди.

Бәс, анлар атасына каушдылар,
Җөмләләре Йагъкуба күрешделәр,
Хаталарын дәйүбән аглашдылар:
«Гөнаһымыз багышлагыл!» — дирләр имди.

«Алдайубән Йосыфи сәндан алдык,
Кол дәйүбән еракга аны сатдык,
Бу көн халән аны олы солтан булдык,—
Җөмлә Миср әһле аның колы имди».

Йагъкуб әйдер: «Хатаңызи багышладым,
Сөчеңези бән сезең гафу кылдым,
Бән дәгый Халикымдан рахәт булдым,—
Сезләрә һәм рахәт улсын!»— дәйүр имди.

Бер дәвәне килтерде һәм Җәбраил
(Ул дәвәне виреб ийде Мәүла-җәлил):
«Йа Исраил, Йосыф сари бәҗәд улгыл
Тиз Йосыфа каушмага!»— дәйүр имди.

Шөкер кылыб, ул дәвәйә Йагъкуб бенде,
Әкърәбасы, әһле-бәйте белә китде,—
Тәмам йитмеш өч кешилә йула керде,—
Йакын килә угланлары йалварыр имди...

...Газиз Йосыф бари ләшкәр дирелүбән,
Атасына каршы чыкыб һәм килүбән,
Быргу-табл, кус-нәгарә орылубән —
Тази атлар күрекле өнен кешнәр имди.

Йагъкуб сәүчи, аны күреб, шөкер кылды,
Йосыф нәби атдан иңде, йәйән улды,
Атасы һәм дәвәдән иңеб килде,—
Ата-угыл күрешүбән аглар имди...

Тәрҗемәсе:

...Аннан Йосыф кардәшләрен киендерде,
Бик күп алтын-көмеш, ат һәм качыр бирде,
Атасына да килергә рөхсәт итте:
«Килсен бөтен нәсле белән!» — дияр имди.

Алар, кайтып, Йагъкуб белән күрештеләр,
Һәммәсе дә аның белән кавыштылар,
Хаталарын сөйли-сөйли еглаштылар:
«Кичер безнең гөнаһларны!» — дияр имди.

«Йосыфны без синнән алдап алган идек,
Кол дип аны ерак җиргә саткан идек,
Бүген аның солтан икәнлеген күрдек,—
Бөтен Мисыр халкы аның колы имди».

Йагъкуб әйтте: «Хатагызны ярлыкадым,
Бөтен гөнаһ эшегезне гафу кылдым,
Бүген тагын Халикымнан рәхәт алдым,—
Сез дә рәхәтләр күрегез!» — дияр имди.

Китерде бер дөя Йагъкубка Җәбраил,
Кушкан иде моны аңа Тәңре-җәлил:
«Тизрәк,— диде,— Мисырга бар, йа Исраил,
Йосыф белән кавышырга!» — дияр имди.

Шөкер кылып, шул дөягә Йагъкуб менде,
Гаиләсе, якыннары бар да килде,
Нәкъ җитмеш өч кеше бергә сәфәр кылды,—
Угланнары ялварышып барыр имди...

...Газиз Йосыф бик күп гаскәр әзер кылды,
Атасын каршы алырга үзе барды,
Быргы-чаңнар һәм нагъраләр яңрап торды,
Чабыш атлар матур итеп кешнәр имди.

Йагъкуб нәби, углын күреп, шөкер кылды,
Йосыф нәби, аттан төшеп, җәяү килде,
Атасы да дөясеннән төшкән иде,—
Ата-угыл еглап күрешерләр имди...

Хатимә[1]

...Йосыф сәүче кыйссасын кыйлдык гайан,
Гарәб, гаҗәм деленчә кыйлдык бәйан,
Укымага, дыңламага улды асан,—
Укыйанлар дога илә үксен имди.

Йосыф сәүче кыйссасын гакыйль укыр,
Дыңладыкда күңле эрер, йаше агар,
Әгъзасындан йазыклары сач(е)лү чыгар,—
Рәхим аңа рәхмәт рузи кыйла имди.

Фазыйль кеше ошбу наз(ы)м сөйләр улса,
Гакыйль кеше колак дотыб дыңлар улса,
Каил, сәмигъ бу мөзнибә дога кыйлса,—
Мөҗиб аны мөстәҗаб кыйлыр имди.

Укыйанлар, дыңлайанлар дога кыйлыр,
Бу зәгыйфь дога умар, Халикъ белер,
Дога берлә тәлим гасый рәхмәт булыр,—
Мәгъфирәтә шайәстә улыр имди.

Гәүһәр даш, вәлә(й)кин (даш) гәүһәр улмаз,
Дикмә кеше гәүһәр кадрен кыяс кылмаз,
Бу назымның кадрене ахмак белмәз,—
Гакыйль кеше дыңлар, аңлар, белер имди.

Әй, дәрига, дикмә кемсә дөземәде,
Фәһме иксүк кемсәләр йазымады,
Бу зәгыйфьнең ошбу назмы азумады,—
Робагый вәзен эчрә дорсын имди.

---

[1] *Хатимә* — йомгак, бетем.

Боны дөзән — зәгыйфь бәндә, ады Гали,
Йегерме түрт рәкым эчрә салды йулы,
Йарлыкагыл, йа рәхим, бән гасый колы,—
Рәхмәтеңдин, бәһрәбәндлек умар имди.

Өмид дотар бу мөзниб сән мәүлийә,
Сән кәрим, сән рәхим, сән вәлийә,
Рәхмәт кыйлгыл, рәхим кыл Кол Галийә,—
Кайгылы нәфсем мөфәррих кыйлгыл имди.

Ходавәндә, хаҗәтем сәңа мәгълүм,
Бән мәхзүннең мөнаҗате сәңа мәгълүм,
Йа рәхим вә йа рәхман, кыйлма мәхрүм,—
Ахыр дәмдә иман гата кыйлгыл имди.

Мәүладан мәдәд, носрәт йитүзендән,
Рәҗәб ай чәлаби (җәләли.— *Х. М.*) утызындан,
Тарих чөн алты йөз тукызындан —
Бу зәгыйфь бу китаби дөзде имди.

Тәүфыйк-носрәт, фәһме куәт хакдан булдым,
Илһам рузи кыйлдыгына шакир булдым,
Бу арада бу китапны тәмам кыйлдым —
«Нәфәгана вә иййакем» кыйла имди.

Тәрҗемәсе:*

Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек,
Гарәб-фарсы телләречә бәян иттек,
Уку өчен, тыңлау өчен ансат иттек,
Укыганнар безгә дога кылсын имди.

Йосыф сәүче кыйссасын тик акыллы укыр,
Тыңлаучының күңле эрер, яше агар,

---

* *Кол Гали*. Кыйссаи Йосыф / Тәрҗ. *Нурмөхәммәт Хисамов*.— Казан: Татар, кит. нәшр., 1989.— 216—218 б. (Строфалар ахырындагы «инде» сүзе оригиналдагыча «имди» рәвешендә калдырылды.)

Әгъзасыннан языклары чәчлеп чыгар,
Рәхим аңа игелеген бирә имди.

Укымышлы бу назымны сөйләр булса,
Һәм гакыллы колак тотып тыңлар булса,
Сөйләүче һәм тыңлаучы бер дога кылса,
Кабулчы зат аны кабул кылыр имди.

Укыганнар, тыңлаганнар дога кылыр,
Бу зәгыйфь кол дога көтә. Тәңре белер,
Дога белән күп гөнаһлы кичерелер,
Ярлыкауга алар лаек булыр имди.

Гәүһәр таш, ләкин һәр таш гәүһәр булмас[1],
Тикмә кеше гәүһәр кадрен белә алмас,
Бу нәзымның кадрен бары ахмак белмәс,
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.

Ай-һай, моны тикмә кеше төземәде,
Зиһене ким кеше моны язалмады,
Бу зәгыйфьнең шушы нәзмы аз булмады,
Робагые үлчәмендә торсын имди.

Аты — Гали моны төзгән зәгыйфь колның,
Егерме дүрт иҗек итеп тезде юлын,
Ярлыка син, йа рәхим, мин — гасый колың,
Рәхмәтеңнән өлеш өмет итәм имди.

Өмет тота бу гөнаһлы син Мәүлага,
Син юмарт, син рәхимле һәм син изгегә,
Мәрхәмәт кыл, йа рәхим, ул Кол Галигә,—
Кайгылы бу күңлемне син шат кыл имди.

Йа Ходам, бу кол хаҗәте сиңа мәгълүм,
Мин зарлының мөнәҗәте сиңа мәгълүм,

[1] Тәрҗемәчедә: Гәүһәрне таш дию белән ул — таш булмас.

Йа рәхмәтлем, йа шәфкатьлем, кылма мәхрүм,
Ахыр тында миңа иман син бир имди.

Бу Мәүладан ярдәм, җиңү килгән көндә,
Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
Һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде имди.

Булышлык һәм зиһен көче Хактан алдым,
Илһам бүләк итүенә шөкер кылдым,
Бу вакытта бу китапны тәмам кылдым,
Сезгә, безгә бу файдалы булсын имди.

Котб

(XIV йөз)

ХӨСРӘҮ ВӘ ШИРИН* (1342)

(поэмадан өзек)

[Ширинне сыйфатлау]

...Садәф эчрә тезелмеш тик тешләре дөр(р),
Тешенең шөгъләсе дөр(р)гә бирер нур.

Гаҗәибрәк ике ләгъл-ү Бәдәхшан[1],
Күрәрмән булмыш ул дөр(р) үзрә галтан.

Каракы җадусы күргәнне үртәр,
Яман күзлек күзен көн берлә үртәр.

Телен тибрәтсә ул ил күңлен аулар,
Сүзе әфсүн миңиз тик телләрне баглар...

...Аның шәмгынга пәрванә булыр җан,
Йаруклугынга юк һич бакгу имкян.

Кашы йә *(җәя.— Х. М.)* тик аның һәм керпеке ук,
Аның тик йә вә ук ажунда бер юк...

...Яңакы көн ярукынга юл ормыш,
Аның күркендин ай һәм уфта тормыш...

---

* *Котб*. Хөсрәү-Ширин хикаяте.— Казан: КДУ нәшр., 1969.— 1 кисәк.— 47—49 б.

[1] *Бәдәхшан (Бадахшан)* — Үзәк Азиядәге төбәк. Ул үзенең кыйммәтле ташлары, энҗе-якутлары белән мәшһүр.

...Әгәр әндазә алса үз күзендин,
Йөз аһу аулайур ул күзләре чин.

Кешегә бакса ул күзләре аһу,
Куян йаңлигъ китәр ул күздин ойку.

Тәмам хирмән чичәк тик кадде, юк хар[1],
Чичәкендин юк имкян алса дәййар.

Аның ул нәркиси мәхмуре әйсәм,
Тикәр рәйхан Ирәм багында[2] һәр дәм.

Кашы чөн бәйрәм аеның һилали,
Үзен корбан кылыр кем күрсә хали.

Хәялыны күреб Мәҗнүн таңлар,
Җәмалы берлә Ләйли[3] кайм уйнар.

Тәмам бармаклары бармак шәкәр тик,
Беләге гаҗ йаңлигъ, тәне кар тик...

...Йөзе ширин, сүзе ширин, үзе һәм
Дәме җанга сәбәб Гайса-йу Мәрьям...

...Ни күрклүк кыз кем ул илләрара бар,
Камуг Ширин тәпугында булырлар.

Төгәл йитмеш асылзадә катында
Булырлар барча даим хезмәтендә.

Нәзыйре юк аларның күрк эчендә,
Алар тик булмагай Чин-у Мачиндә...[4]

...Төшеб багларда хуш мәҗлес корарлар,
Бу йаңлигъ зәүкъ итеб гыйшрәт сөрәрләр...

---

[1] *Юк хар* — чәнечкелесе юк.
[2] *Ирәм багы* — экияти бакча, оҗмах бакчасы.
[3] *Мәҗнүн, Ләйли* — Шәрык әдәбиятларындагы образлар.
[4] *Чин-у Мачин* — Кытай мәмләкәте.

...Күтәрмәзләр никаб ил күрмәсен тиб,
Яман күзлүк бакыб зәхм ормасын тиб.

Бу йаңлигъ күрк эчендә ишләре юк,
Тамашадин азин һич эшләре юк...

...Йагый белгерсә нәгяһ илләренгә,
Котармаз җан, керер тәрк әлләренгә.

Орышда йыртыб арслан пәнҗәсене,
Ягандин һәм чыкарырлар тешене...

...Ахурда бер аты бар илгә бирмәз,
Азакы тупракынга йил иярмәз.

Сабак алмыш һавада кошлар андин,
Сувда эврәкчә куркмаз булса туфан...

...Тимер тик тойнакы таглар казар ул,
Йите дәрьяны бер күлчә йөзәр ул.

Замана йаңлигъ аның йөгреше чын,
Узар йолдызны төн тик, өзсә тезген.

Ирүр Шәбдиз аты, рәнге төн тик,
Сәүәр гаять аны ул йөзе көн тик.

Ни Ширин тик кеше күрде бу күзем!
Ни Шәбдиз йаңлигъ ат ишетте үзем!..

Тәрҗемәсе:*

...Тигез булып тезелгән теш — нәкъ энҗе,
Алар алмаз кебек нурлы, пакь энҗе.

Иреннәре Бәдәхшанның якуты,
Уйный тешләр алар белән качышлы.

* *Котб.* Хөсрәү вә Ширин / *Рифкать Әхмәтҗанов* тәрҗемәсе.— Казан: Мәгариф, 2003.— 54—57 б.

Кыя җанны карашы тылсымында,
Яман күзләр якын да килми монда.

Телен тибрәтсә ул ил күңлен аулар,
Сүзе әфсүн булып телләрне бәйләр...

...Очар җаннар, күбәләктәй, бу шәмгә,
Ояла күз, карап булмый гүзәлгә.

Кашы җәя аның, ә керфеге — ук,
Бу җәя һәм бу ук җирдә бүтән юк.

Яңаклар көн нурындин нурлар алган,
Йөзен күреп, ай уфтанышта калган...

...Аның күзе белән чыкса ярышка,
Гаҗәп түгел болан күзе калышса.

Болан күзләр белән бер бакса җанга,
Китәр качып йокың, охшап куянга.

Язын аткан чәчәктәй саф, нәфис ул,
Аңарга ялгышып та тимәгән кул.

Сурәтләсәң аның күз кабагын да,
Гүя рәйхан гөл ул Ирәм багында.

Кашын күрсә, яңа ай тик шәкелдә,
Җанын фида кылыр хәтта хәким дә!

Аның рәсмен күреп Мәҗнүн калыр таң,
Ходай Ләйләгә тиң итеп яраткан.

Аның бармаклары ап-ак шикәрдәй,
Беләге — фил сөяге, тәне кардай...

Сүзе, тыны бирә дөньяга җан, ямь,
Гүяки яшь кенә Гайсә вә Мәрьям...[1]

---

[1] Биредә Гайсә пәйгамбәр һәм аның әнисе Мәрьямнең үлгәннәрне терелтүләренә ишарә ясала.

...Матурлыкта бу кыз даны җәелгән,
Киләләр баш орып аңа күп илдән.

Төгәл җитмеш асылзат кыз катында,
Торалардыр әзер һәр хезмәтенә.

Тиңе юктыр аларның буйда-сында,
Булыр булса бары Чыйн вә Мачыйнда...

...Җыелып багда мәҗлесләр коралар,
Ширин берлә кәеф-сафа сөрәләр...

...Ил алдында болар күтәрми пәрдә,
Яман күзләр тияр дип кайсы мәлдә.

Матурлыкка боларның тиңнәре юк,
Тамаша кылмаган бер көннәре юк...

...Ләкин әгәр Ватанга керсә дошман,
Бу кызларда уяныр куркусыз җан.

Сугышсалар, арысланны ярырлар,
Яган-филнең тешен суырып алырлар...

...Аранда бер аты бар — алны бирмәс,
Җилеп китсә, аңарга җил иярмәс.

Сабак ала очар кошлар да аннан,
Суда — үрдәк, курыкмый ул туфаннан...

...Тояклары тимер — таш-тау ишәрлек,
Җиде дәрьяңны бер күл тик кичәрлек.

Гомер кебек, яшеннәр тизлегендә
Чабар, ычкындырылса тезгеннән.

Исеме Шәбдиз атның, төсе төн тик,
Бу тулпарны сөя Ширин дә бик, бик!

Ширин кебек чибәрне күргәнем юк,
Вә Шәбдизгә тиң аттан хәбәрем юк!

Бәркә Фәкыйһ

(XIV йөзнең икенче яртысы)

[«Догадин онытма, әй ике күзем»]

(өзекләр)

...Изем тәүфыйк бирде, тәмам кылдым уш,
Йадекәр мәнеңдин сиңа куйдым уш...

...Алтынбога ирде ул сабики атлигъ,
Үзе галим-ү хәлим һәм теле татлигъ.

Ирә килдем һәм аның катынга,
«Колый» тиб әйүрләр аның атынга[1];

Килеб Искәндәргә[2] тәҗрид өчен,
Алаен тиб кяфердән мөэмин үчен[3].

Биләсендә килдем нийәте газа,
Төкәтдем китабны[4] уш анда яза...

...Бетедем китабын хатасын бакыб,
Бу зәхмәт чиккәнем белгәйсән укыб.

---

[1] Күрәсең, Алтынбога, Мисырга килгәч, үзенә «Колый» кушаматын ала.

[2] *Искәндәр* — Мисырдагы шәһәр исеме.

[3] Сүз тәре йөртүчеләргә каршы сугыш хакында бара.

[4] Бәркә Фәкыйһ Котб китабын күчереп язу турында сүз алып бара.

Атагым ма «Бәркә Фәкыйһ»[1] тиб анчак,
Үзем мөэмин-ү мөслим, ма аслым кыбчак[2].

Минем берлә килгән, табыб дөньялык,
Миңа бирде йазмак, укымак, белек.

Моның берлә мәшһүр Мисырда үзем,
«Фәкыйһ» тиб әйүрләр, әй ике күзем...

...Бетедем ма йаздым бу бер кач сүзем,
Догадин онытма, әй ике күзем...

...Шәкәргә нәзар кыл, камышка бакма,
Бу ахмак наданның сүзенә йакма.

Бу ахмак бүре тик, гакыйллар — куй ул,
Бу бүре куйынга куйармы һич йул?!.

...Тарих йите йөз ел сиксән бишендә[3],
Сәфәр аеның егерме бишендә.

Йул үзрә ни булса, бетедем китаб,
Хатымны зәгыйфь тиб кылмагыл гыйтаб...

Тәрҗемәсе:

...Аллам тәүфыйк бирде, тәмам кылдым моны,
Миннән сиңа ядкәр итеп куйдым шуны...

...Алтынбога иде аның элекке исеме,
Үзе галим һәм тәрбияле, теле татлы.

Ияреп килдем мин аның белән бергә,
«Колый» дип әйтерләр аның исемене;

---

[1] *Фәкыйһ* — шәригать кануннары белгече, юрист.

[2] Дәшти-Кыпчакның, ягъни Алтын Урданың төп халкын кыпчаклар тәшкил иткән. Бәркә Фәкыйһ чыгышы белән шушы мәмләкәттән.

[3] Һиҗринең бу елы милади белән (ягъни хәзергечә) 1383 елга туры килә.

Килеп Искәндәргә сугышыр өчен,
Алам дип кяфердән мөэмин үчен.

Бергәлектә килдем изге сугышка,
Тәмамладым бу китапны анда язып...

...Яздым китапны хатасын тикшереп,
Никадәр хезмәт түккәнемне белерсең укып.

Атым Бәркә Фәкыйһ дип булды мәгълүм,
Үзем мөэмин-мөселман, аслым — кыпчак.

Минем белән килгән (ягъни Алтынбога) чара табып,
Миңа язу, уку, белем алу мөмкинлеге бирде.

Моның белән Мисырда мәшһүр үзем,
«Фәкыйһ» дип әйтерләр (үземә), әй ике күзем[1]...

...Яздым мин бу күп сүзләрне,
(Шуның өчен) мине догадан мәхрүм итмә, әй ике күзем.

...Шикәргә күз сал, камышка бакма,
Бу ахмак наданның сүзенә карама.

Ахмак (кеше) бүре кебек, акыллылар — куй ул,
Бүре куйларга (сарыкка) куярмы һич юл?!.

...Тарихның җиде йөз сиксән бишенче елында,
Сәфәр аеның егерме бишендә.

Юлда ни булса да, китапны яздым,
Язганымны зәгыйфь дип, кылмагыл шелтә...

[1] *Ике күзем (иккүзем)* дип дәшү мишәр татарлары телендә хәзер дә очрый.

Харэзми

(XIV йөз)

МӘХӘББӘТНАМӘ* (1353)

(өзекләр)

Газәл

Йөзеңдә күрдем, әй җан, бәйрәм аен,
Моның шөкранәсе корбан булаен[1].

Әгәр көн тугмаса һәм йакты кылгай—
Йөзең нуры бу дөньяның сараен.

Гәр Әфләтүн[2] синең гыйшкың төшсә,
Бирер йилгә камуг тәдбир-ү раен[3].

Шәкәр тик тел белә тотты телеңез,
Ничә күп сайд итәр[4] җанлар һомаен[5].

Сәгадәт берлә бәхт икесе бичте[6]
Буеңызга ләтафәтнең букаен[7].

Иҗазәт[8] бирсәңез таң яктысы тик,
Җиһанга хөснеңез җавын йәйәен[9].

---

* *Огыз-наме.* Мухаббат-наме.— Алматы: Гылым, 1986.— 193—195, 201 б.

[1] «Моңа шөкер итеп корбан булам».

[2] *Әфләтүн* — Платон (Антик Грециянең акыл иясе).

[3] «Бирер җилгә (югалыр) барлык акыл-зирәклеген».

[4] *Сайд итәр* — аулар.

[5] *Һомаен* — бәхет кошын. Мифологик ышанулар буенча һомай кошы (феникс) күләгәсе төшкән кеше бәхетле була.

[6] *Бичте* — кисте-текте.

[7] *Букаен* — киемен.

[8] *Иҗазәт* — рөхсәт.

[9] «Җиһанга гүзәллегегезнең данын (гаскәрен) таратам».

Сезә тиб килде. Харәзмине асраң[1],
Кем асрарлар камуг шаһлар гидаен[2].

Гүзәл яр

...Әйа күрк эчрә[3] галәм падишаһы,
Җиһан тотты синең хөснең сипаһы[4].

Пәри рухсарәләрнең[5] күрккә бае,
Йөзең нәүрүз вә кашың бәйрәм ае.

Күңел ширин[6] сүзеңә булды Фәрһад[7],
Күзең Кәшмир җадусыга остад[8].

Кара миң ал яңакыңда ярашыр,
Башым даим азакыңга ярашыр[9].

Буең сәрви, саноубәр тик[10], билең кыл,
Вафа[11] кылган кешеләргә вафа кыл...

...Сачең бер тарина[12] мең хур[13] йитмәс,
Йөзеңнең нурына мең нур йитмәс...

...Кешенең синсезин[14] ни җаны булсын,
Аның тик гомернең ни саны булсын...

...Бүген юктыр син ай тик күктә әсра,
Колың бичара Харәзмине асра...

---

[1] *Асраң* — асра, тәрбиялә, кара.
[2] «Ничек асрарлар барлык шаһлар фәкыйрьләрне».
[3] *Күрк эчрә* — матурлык эчендә.
[4] *Сипаһы* — гаскәре.
[5] *Пәри рухсарәләрнең* — пәри йөзлеләрнең, әкияти гүзәлләрнең.
[6] *Ширин* — татлы.
[7] *Фәрһад* — Ширингә гашыйк булган каһарман.
[8] «Күзең Кәшмир сихерчесенә (дә) остаз булырлык».
[9] «Башым һәрчак аяк астыңа ярашыр».
[10] *Саноубәр тик* — чыршы (нарат) кебек.
[11] *Вафа* — тугрылык.
[12] *Тарина* — бөртегенә.
[13] *Хур* — хур кызы.
[14] *Синсезин* — синнән башка.

Хисам Кятиб

(XIV йөз)

ҖӨМҖӨМӘ СОЛТАН* (1369)

(поэмадан өзекләр)

...Бу кара йир, кем күрерсән, туп-тулуг
Адәм угланларыдыр кечек-олуг.
Һәр кадәм[1] кем йир йөзенә басарсән,
Һәр кадәмдә[2] адәм йөзенә басарсән...
...Бу кара тупрак эчендә ничәләр
Йатырлар ошбу төн, көндез, кичәләр.
Кеме солтан, кеме кол, кеме әмир,
Кеме хуҗа, кеме бай, кеме фәкыйрь.
Кеме углан, кеме шәйх, кеме фәта[3],
Кемнең тупракын йилләр сүвереб[4],
Кеменең сүңәкләре көнгә[5] корыб,
Олуг, кечек, бай вә йуксыл — билгесез,
Әмир, мескен, кол вә солтан — билгесез...

* * *

...Йа Нәбиулла[6], ишеткел бу сүзем,
Кем ниләр күребдер анда бу күзем.

---

* Җөмҗөмә солтан / Төз. *Хатип Госман.*— Казан: КДУ нәшр., 1970.

[1] *Кадәм* — адым.

[2] *Кадәмдә* — адымда; табан асты белән.

[3] *Фәта* — игелек иясе; егет.

[4] *Сүвереб* — себереп.

[5] *Көнгә* — кояшка.

[6] *Нәбиулла* — Алла илчесе.

Ул җәһәннәм тәмугында, и олуг,
Бер кавем[1] күрдем — бичин йөзлек камуг[2].
Анлар ирмеш дөньяда нәфсе кәрәм[3],
Кем йиймеш ирмешләр[4] анлар күп хәрам.

Йәнә бер кавем анлар катында иде,
Башы түбән, азакы[5] өстен иде.
Анлар ирмеш кем борынын күтәреб,
Йөрер ирмеш һәрбере «Мән! Мән!» тиеб.
Иргә мең һөнәр үгрәнмәк күб дәгел,
Илля булса бер — мән-мәнлек йөб дәгел[6]...
...Йәнә бер таифә[7] күрдем, кем торыр,
Күзләре йук; кайда булса, тик йөрер.
Анлар ирмеш онытыб үз-үзләрен,
Үзгәнең гайбенә салмыш күзләрен.

Йәнә күрдем бер кавем мән: теле йук,
Һәм тәкый[8] бер кавем — азак, әле[9] йук.
Телсез анлар — хакимләр ирмеш борын[10],
Игри[11] хөкем берлә тотмышлар урын.
Илсез-азаксыз[12] тәкый анлар, имеш,
Кем анлардин күңшеләре[13] рәнҗемеш...

---

[1] *Кавем* — төркем.
[2] *Бичин йөзлек камуг* — һәммәсе маймыл йөзле.
[3] *Кәрәм* — юмарт.
[4] *Йиймеш ирмешләр* — ашамызлар, ашаганнар.
[5] *Азакы* — аягы.
[6] *Йөб дәгел — монда:* аз түгел.
[7] *Таифә* — төркем.
[8] *Тәкый* — тагын.
[9] *Әле* — кулы.
[10] «Телсезләр — элек хөкем чыгаручылар (судьялар) булганнар».
[11] *Игри* — ялган.
[12] *Илсез-азаксыз* — кулсыз-аяксыз.
[13] *Күңшеләре* — күршеләре.

КИСЕКБАШ* (XIV—XV йөзләр)

[Гали батырның Дию белән сугышуы]

...Ул Дию уйганды та түрт яру бакар,
Күб сүз сүзләр, агзындин утлар сачар:

«Синме килдең, йа Гали дошманымыз,
Синең илеңдин чыкармы җанымыз?

Синме кистең барча диюләр башыны,
Синме түктең монча диюләр каныны?

Халә мән барам,— тиде,— анда сиңа,
Сине монда кем биреб изде миңа?»

Гали әйтер: «Хак биреб из(е)де мине
Парә-парә кыларым бу дәм сине».

Ул Дию әйтер: «Бу сәгать сине йийам,
Дөньяда бер мөселманны куймайам.

Ни сине куйам, ни худ пәйгамбәри,
Йакайын Мәккә, Мәдинә шәһрени.

Ни дошманны куйам, ни газыйңызны,
Бу җиһанда куймайын береңезне».

Әйлә, тиде, йөреде тәкъдир белә,
Мең батман гөрзисе бар үзе белә.

---

* *Ахметгалеева Я. С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы».— М.: Наука, 1979.— С. 131—133.

Алды гөрзи, хәмлә кылды Галигә,
Гали тәкый калкан алды илингә.

Әйлә орды Дию Галигә гөрзини,
Кем Гали батды йиргә тезе тиңи.

Тетрәмәде Галинең улдәм иле,
Һич тәгаййер булмады ул шаһ вәли.

Сәчрәде менде ул дәм таш өстенә,
Шөкер кылды, сәҗдә итте дустына.

Ул Дию әйтер: «Үлмәдеңме, йа Гали,
Куһи Каф ирсәң парә кылам сине!»

Өч хәмлә кылды Галигә, үлмәде,
Казгырыб нә итмешен һәм белмәде.

Чөнки нәүбәт Галигә тикде әйрә,
Гали орды илине зөлфәкарә.

Гали әйтер: «Йа мәлгунь, бармак күтәр,
Тәңренең берлегенә икърар китәр».

Ул Дию әйтер: «Мең яшәдем тоймадым,
Кичде гомрем, дин казгусын йиймадым.

Үләр ирсәм тәкый һәргиз димәйен,
Зирә үлсәм, дин казгусын йиймаен».

Чөн ишетте бу сүзне Диюдин Гали,
Менде ташның өстенә ул дәм вәли.

Чалды андин зөлфәкарны башына,
Кичте китде ирде аның җанына.

Чөнки үлтерде пәри диюне Гали,
Тәңре арсланыдыр ул шаһ вәли.

Ул сарайның ишекене ачтылар,
Галинең өстенә диюләр төштеләр.

Гали орды үзен ул дәм диюләргә,
Чалдыгынча кырар ирде ул йирә.

Гали диюләр башыны кисәр ирде,
Диюләрнең йөзенә ул басар ирде.

Өч йөз диюне үлтерде ул көн Гали,
Тәңре арсланыдыр ул шаһ вәли.

Чөнки бу эшне Галидин күрделәр,
Тәкый анда тормадылар китделәр.

Чөнки бакты Гали: диюләр күрмәде,
Барча диюләр ул арада тормады.

Килде биш йөз мөселман, чиште илен,
Барчасына өләште диюләр малын...

Тәрҗемәсе*:

...Ул Дию уянып, дүрт якка багар,
Күп сүз сөйләр, аузыннан утлар сачәр:

«Синме килдең, йа Гали, дошманыбыз,
Синең кулыңнан чыгармы җаныбыз?

Синме кистең барча диюләр башын,
Синме түктең монча диюләр канын?

Ярый, мин барам,— диде,—анда сиңа,
Сине монда кем җибәрде соң миңа?»

Гали әйтер: «Хак юнәлтте монда мине,
Парә-парә кылырмын бу дәм (хәзер.— *Х. М.)* сине!»

Ул Дию әйтер: «Бу сәгате сине йийам,
Дөньяда бер мөселманны да куймам.

---

* ***Нәҗип Исмәгыйль*** тәрҗемәсендә // Ватаным Татарстан.— 1992.— 19, 26 июль.

Ни сине куям, ни пәйгамбәрең,
Егармын Мәккә, Мәдинә шәһәрен.

Ни дошманны куям, ни газизне,—
Бу җиһанда куймамын берегезне!»

Шулай диде, йөреде тәкъдир белән,
Мең батман гөрзие бар үзе белән.

Алды гөрзи, һөҗүм кылды Галигә,
Гали тагы калкан алды кулына.

Шундый орды Дию Галигә гөрзиен —
Кем Гали батты җиргә тезе тиңен.

Тетрәми ул дәм (чак.— *Х. М.*) Галинең кулы,
Һич үзгәрмәс, курыкмас ул шаһ вәли[1].

Сикерде, менде ул дәм таш өстенә,
Шөкер кылды, сәҗдә итте дустына.

Ул Дию әйтер: «Үлмәдеңме: йа Гали?
Каф тавы булсаң, парә кылам сине!»

Өч һөҗүм кылды Галигә, үлмәде,
Кайгырып, ни итәсен һәм белмәде.

Аннан нәүбәт Галигә җитте янә,
Гали алды зөлфәкарын (кылычын.— *Х. М.)* кулына.

Гали әйтер: «Йа мәлгунь, бармак күтәр[2],
Тәңренең берлегенә икърар китер?»

Ул Дию әйтер: «Мең яшәдем, тоймадым,
Кичте гомрем, дин кайгысын йиймадым.

Үләр исәм, тагын һич тә димәмен,
Әгәр үлсәм, дин кайгысын йиймамын».

---

[1] *Шаһ вәли (шаһе вәли)* — яклаучы шаһ.
[2] *Бармак күтәр — монда:* Аллага иман китер.

Ишеткәчтен бу сүзне Диюдән Гали,
Менде ташның өстенә ул дәм вәли.

Чалды аннан башына зөлфәкарын,
Чалды, кисте, алды Диюнең җанын.

Шулай үтерде пәри диюне Гали,
Тәңре арысланыдыр ул шаһ вәли.

Ул сарайның ишекләрен ачтылар,
Галинең өстенә диюләр төштеләр.

Гали орды үзен ул дәм диюләргә,
Чалгач тагын карар иде ул җиргә[1].

Гали диюләрнең башын кисәр иде,
Диюләрнең йөзенә ул басар иде.

Өч йөз диюне үтерде ул көн Гали,
Тәңре арысланыдыр ул шаһ вәли.

Шулай бу эшне Галидән күрделәр,
Тагы анда тормадылар, киттеләр.

Аннан бакты Гали: диюләр күрмәде,
Барча диюләр ул арада тормады.

Биш йөз мөселманның чиште кулларын,
Барчасына өләште диюләр малын...

---

[1] Бу юлны болай дип тәрҗемә итәргә дә мөмкин: «Һәрбер чалганын (тураганын) җиргә кырып салыр иде» *(Х. М.)*.

Әхмәд Үргәнчи

(XIV йөз)

[Күңелләрне йәшәтсен игү атың*]

И җаным, бел: кичәр дөнйаи фани,
Йитәр, бәс кыл бәңа имди җәфаны.

Үзең остад булыб бу киң җәһанда,
Бары хубларга үгрәтгел вафаны.

Күңелләрне йәшәтсен игү атың,
Хәзансыз хөсн теләб әйләй доганы.

Гомер багында синсез миңа мөшкел,
Кувәй йулыңда булган һәр бәлане.

Килсәң булгай сийаһ коллиям мөнәүвәр,
Кыйлурсән падишаһ Әхмәд гиданы.

Тәрҗемәсе:

И җаным, бел: кичәр дөнья (ул) фани,
Җитәр, туктат миңа дигән җәфаны.

Үзең остаз булып бу киң җиһанда,
Бары яхшыларга гына өйрәт вафаны (тугрылыкны).

Күңелләрне яшәтсен изге атың,
Көзсез матурлык теләп әйт доганы.

---

* *Миңнегулов Х. Й.* Әхмәд Үргәнчи һәм аның ике чордашы // Казан утлары.—1972.— № 6.— 130—133 б.

Гомер багында синсез миңа кыен,
Куала юлында булган һәр бәлане.

(Син) килсәң, караңгы дөньям булыр нурлы,
Кыйлырсың (син) патша Әхмәд гидайны (фәкыйрьне).

[Аксак Тимергә багышлама]

И залим вә канхур, вә тәмуг ут йакары, бибаш,
Таки акады(р) Җәйхун илә Сәйхун тула күз яшь?!

Үрләде күккә аһ-у фөган, илгә килде каза,
Белгел ки, килмәйен калмас илдин синңа һәм җәза.

Куйлара килгән корт очрар чупан таягына,
Кем күтәрсә агыр таш, төшер үзене(ң) аягына.

Үргәнчә иктерсән арпа, үңеб солым(?) чыкады,
Һәр башакның данидин синңа үлем чыкады.

Зәһәр салган ашымыз(г)а, ахыр үзе эчәде,
Кара туфраг үзә үз(е)гә кара кәфен бечәде,

Әхмәд аһын тыңлаб, Алла сине тәмуг(к)а салыр,
Дөньяда безә дустлык, гадәләт шаһы калыр.

Тәрҗемәсе:

И залим һәм кан эчүче, вә тәмуг утына ягасы (нәрсә), башсыз,
Кайчанга кадәр агар Аму-Дәрья белән Сыр-Дәрья тулы күз яше?!

Үрләде күккә аһ-зар, илгә килде каза,
Белгел ки, килми калмас илдин синңа һәм җәза.

Куйга дип килгән бүре очрар чабан таягына,
Кем күтәрсә авыр таш, төшәр үзенең аягына.

Үргәнечкә иктерсәң арпа, шытып иген чыгар,
Һәр башакның бөртегеннән синңа үлем чыгар[1].

---

[1] Аксак Тимер 1388 елда Алтын Урда составындагы Үргәнеч шәһәрен яулап ала. Каланы җимерә, аның урынына «арпа чәчәргә» боера. Биредә шул фәрман күздә тотыла.

Агу салган (салучы) ашыбызга ахыр үзе эчәр,
Кара туфрак өстендә үзенә кара кәфен кисәр.

Әхмәд аһын тыңлап, Алла сине тәмугка салыр,
Дөньяда безгә дуслык, гаделлек шаһы калыр.

[«...Кайгы утында һушсыз адәм мин»]

Хәйатны севгүче күзсез адәм мин,
Вәли гамь утыда һушсыз адәм мин.

Фәкать гүшемдә йуксыллар фөгане,
Күренмәс золым, вәхшәтнең туганы.

Күренмәс булганыга күңел хушдыр,
Хәйәт(и)мәс, бу хәйәт куркулы төшдер.

Гадаләт тохмын изгән зураванлар
Талар илне, түкеб биһудә канлар.

Качан тынычлык гөле йортга сачелгай,
Шу(л) дәм Әхмәднең дә күзе ачылгай.

Тәрҗемәсе:

Тормышны (тереклекне) сөюче күзсез адәм мин,
Ләкин гамь утында һушсыз адәм мин.

Колагымда фәкать юксыллар аһ-зары,
Күренмәс золым-вәхшәтнең туганы.

Күренмәс булганга күңел хуштыр,
Хәят түгел, бу хәят — куркулы төштер.

Гаделлек орлыгын изгән залимнәр
Талар илне, түгеп гаепсезгә каннар.

Кайчан тынычлык гөле илгә чәчелер.—
Шулчак Әхмәднең дә күзе ачылыр.

Мәүла Казый Мөхсин

(XIV йөз)

[Барлык матурларның солтаны]

(газәл)

Сәүдегем бән — адәмиләр җаныдур,
Каму хублар хубының солтанидур.

Кичте Ләйли, кичте Ширин[1] хублыгы,
Ошбу көн — мәнем шаһым дәвранидур.

Бәндәседер буеның — сәрвү, чинар,
Ай вә көнәш — йөзенең хәйранидур.

Яңагы сайрулара алма сатар,
Дудагы — дәрдиләрнең дәрманидур.

Нә яңак кем, мат итәр тазә гөли,
Нә дудак кем, Мисри шәкәр[2] канидур.

Иңәке зинданына төшкән әсир,
Ул ки бу көн Йосыфи Кәнганидур[3].

Каша, күзә алданурса дагыйлар
Мөхсиннең — тәфәррекҗе, рәхманидур.

---

[1] *Ләйли, Ширин* — Шәрык әдәбиятындагы мәшһүр хатын-кыз образлары.

[2] *Мисри шәкәр* — Мисыр шикәре.

[3] Биредә Кәнган коесына салынган Йосыф күздә тотыла.

Тәрҗемәсе:

Минем сөйгәнем — адәмнәрнең җаныдыр,
Барлык гүзәлләрнең дә солтаныдыр.

Кичте Ләйлә, кичте Ширин гүзәллеге,
Инде бу көн — минем шаһым (сөйгәнем) дәвредер.

(Аның) буеның бәндәсе — кипарис, чинардыр[1],
Ай вә кояш — (аның) йөзенә үзләре хәйрандыр.

Яңагының балкышы (алсу төсе, матурлыгы) — алма сатар,
Иреннәре — авыруларның дәвасыдыр.

Шундый яңак ки — яшь гөлдән дә матурдыр!
Шундый ирен ки — Мисыр шикәреннән дә татлыдыр!

Ияк чокырына төшкән әсир (ягъни аңа күңеле төшкән кеше),
(Гүя ки) ул бүгенгенең Йосыф Кәнганиедер.

Кашы, күзе сихерчеләрне (дә) алдарлык,
Мөхсиннең ул — куанычы, Алласыдыр.

---

[1] *Кипарис, чинар* — зифа буйны белдерүче образлар. Ә биредә алар үзләре гүзәл кызның буена мөкиббән киткәннәр.

Мәхмүд Болгари

(?—1360)

НӘҺҖЕЛ-ФӘРАДИС* (1358)

Шәйх ибне Гыймран һәм казый

Бер шәйх бар иде. Гыймран дип әйтер иделәр (үзенә). Аның табынында фәкыйрьләр, торыр җире булмаганнар һәм мөсафирлар тукланырлар иде. Кайчан кем бер дәрвишнең ихтыяҗы булса, ул килеп шәйхкә мөрәҗәгать итсә, шәйх аны кабул кылыр иде...

Беркөн шәйхнең өенә күп кенә мөсафирлар, дәрвишләр барысы бергә җыелдылар. Әмма йорт хуҗасының өендә табынга куярга бернәрсәдә юк иде. Шәйх хәлле кешеләрдән ярдәм сорыйм дип чыкса күрә: каршысына шәһәр казые килә.

Ибне Гыймран әйтте:

— И мөселманнар казыйсы! Йортыма мөсафирлар килгән иде. Әмма табында бернәрсә юк. Кирәк нәрсә бирсәгез иде. (Моның өчен) сезгә ахирәттә җиңеллек булыр...

Казый бу шәйхнең сүзенә илтифат кылмады: аңа һичнәрсә бирмәде. Шәйхнең күңеле төште. Шунда каршына килүче бер яһүдине күрде. Әйтте:

— И яһүди (еврей.— *Х. М*)! Мөмкинлегең бармы? Өемә мөсафирлар килде...

Ул яһүди әйтте:

— Йә шәйх! Ничә алтын кирәк? Бирәм...

---

* Борынгы татар әдәбияты.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1963.— 226—227, 235 б. Текстлар хәзерге телгә яраклаштырылып алынды.

Шәйх: «Монча алтын бир»,— диде.

Яһүди шунда ук шәйх теләгән кадәр алтынны чыгарып бирде...

Шәйх ул алтыннарга азык-төлек алып кайтты. Өйдәге мөсафирлар, дәрвишләр тукландылар, һәм барысы да яһүдигә дога кылдылар.

Ул кичә казый төш күрә: кыямәт булмыш; барлык халык кубарылган. Берәүләр — оҗмахка, икенчеләре тәмугка барырлар. Казый оҗмах капкасына барды. Анда энҗедән корылган, гаять күрекле, (матурлыгын) адәм сыйфатлап бирә алмаслык бер сарай (күшек) күрде. Казый шул йортка үтәргә теләде, әмма фәрештәләр аны туктаттылар.

Казый: «Мине ни өчен туктаттыгыз, узарга мөмкин булмасмы?» — дип әйткәч, капка төбендәге фәрештәләр аңа болай диделәр:

— Бу күшек синеке иде. Әмма син ибне Гыймранның үтенечен канәгатьләндермәдең. Ә инде бер яһүди аны шатландырды. Шуннан соң Хак Тәгаләдән: «Бу күшекне ул яһүдигә бирегез»,— дигән фәрман килде. Бу күшек хәзер яһүдинеке. (Шуңа күрә) сиңа анда керергә рөхсәт юк.

Әбү Мәсрид һәм шагыйрь

Әбү Мәсрид бик юмарт кеше иде. Хәзинәче, якыннары: «Бу күп малын бүләк итә, (шуңа күрә) байлыгы бетәр»,— дип куркып, аңа каршы киләләр иде...

Беркөн аның янына бер шагыйрь килеп, мактау шигыре укыгач, Әбү Мәсрид болай диде:

— И шагыйрь! Әгәр малым үземдә булса, һич кызганмас идем. Ләкин мин сиңа бернәрсә өйрәтәм: әгәр дә мин әйткәнчә эшләсәң, сиңа бүләк булачак.

Шагыйрь: «Бәян ит!» — диде.

Әбү Мәсрид болай диде:

— Хәзер мине казыйга алып бар. Ун мең ярмак (акча берәмлеге.— *Х. М.)* бурычы бар, дип дәгъва ит. Мин дә казый янында моны расларчакмын. Шунда казый миңа болай боерыр:

(бурычың барын) икърар кылдың, инде ун мең ярмакны дәгъвачыга бир. Мин бу карарны үтәмәгәч, казый мине төрмәгә ябар. Шунда якыннарым мине төрмәдә тотуга каршы килерләр һәм ун мең ярмакны бирерләр.

Шагыйрь нәкъ шулай эшли. Ун мең ярмакны ала. Әбү Мәсридне төрмәдән чыгаралар.

Дәрвиш шатлыгы

Акыл иярәреннән (гарифлардан) берәү урамнан узганда, аның өстенә берәү югарыдан көл сипте. Шунда гариф, Ходай Тәгаләгә рәхмәт укып, күп шөкерләр кылды. Шунда аңа әйттеләр:

— И газиз! Башыңа көл түгелде. Ә син ни өчен моңа шөкер кыласың?

Ул гариф болай диде:

— Миннән бер гөнаһ үтте. Чөнки мин, ут килеп, һәлак итәр дип куркып тора идем. Хак Тәгалә исә утның көлен сибү белән ризалатты. Шуңа шөкер кылдым.

Ялган сөйләүнең нәтиҗәсе

Берәү бервакыт кол алу өчен базарга керә. Анда бер колны сатып алырга ихтыяр кыла. Шунда колның хуҗасы әйтә:

— И газиз! Бу колның бер гаебе бар. Риза булсаң, ул гаебне әйтеп бирәм.

Кол алучы: «Гаебе ни торыр?» — дип сорау кылды исә, кол хуҗасы әйтте:

— Бу кол ялганчы торыр, күп ялган сөйләр...

Кол алучы әйтте:

— Ялган сөйләү ул кадәр яман гаеб булмас. Мин бу гаебкә ризамын...

Колны сатып ала һәм өенә юнәлә. Бу кол берничә көн хезмәт итә. Бервакыт хуҗа (каядыр) чыга. Хатыны ялгыз гына кала. Шунда хатынга кол болай ди:

— И хатын! Мин бу хуҗаның сезгә мәхәббәте юклыгын күрәм. Мин сихер кыла беләм. ...Хуҗагыз (ирегез) каты

йоклаган вакытта кайчы белән аның (берничә) чәчен кисеп, миңа бирегез. Мин сихер кылырмын һәм хуҗагыз сезне каты сөя башлар һәм һич тә сезнең фәрманыгыздан чыкмас...

Хатын бу колның сүзенә ышанды.

Аннан соң кол хуҗага болай диде:

— И хуҗа! Бу хатын сине үтерергә форсат эзләп йөри, зинһар, аннан сак бул!

Хуҗа да бу сүзләргә ышанды.

Икенче көнне өйлә вакытында хуҗа, ял итәм дип, йоклаганга сабышып ятты. Әмма: «Бу хатын нишләр икән?» — дип, уяу тора. Күрә: хатын кулына кайчы ала, аннан акрын гына ире янына килә башлый. Бу ир: «Бу (хатын) мине кайчы белән үтерә»,— дип уйлап, сикереп тора да хатынын үтерә.

Бу хәбәр хатынның кардәшләренә ишетелә, һәм алар, җыелып килеп, ирне үтерәләр. Янә хатынның туган-тумачалары килеп, (ирнең) якыннары белән орышалар. Күп кенә кешеләр үлә. Болар бар да ялган сөйләү аркасында була.

Сэйф Сараи

(1321—1396)

ГӨЛЕСТАН БИТ-ТӨРКИ* (1391)

Кереш

...Гөл теләсә хатыйрең тулы табак,
Бу «Гөлестан»ымдан укы бер вәрәкъ[1].

Гөл җәмалы[2] берничә көндә кичәр,—
Бу «Гөлестан» даимә[3] күңел ачар.

Бу гаҗәиб кем гараиб[4] монда бар,—
«Хөсрәү вә Ширин»[5] эчендә,— канда[6] бар?!

Төркигә кылыб гаҗәмдән[7] бу китаб,
Мәгърифәткә ачты сиккез төрле баб[8]...

Бу «Гөлестан»га тамаша кылган ир.
Дәмбедәм мәгънә йимешен тазә йийр[9]...

**Сәйф Сараи*. Гөлестан. Лирика. Дастан.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

[1] *Вәрәкъ* — кәгазь; бит.

[2] *Җәмал* — матурлык.

[3] *Даимә (даимән)* — һәрвакыт.

[4] *Гаҗәиб... гараиб* — гаҗәеп... күрелмәгән.

[5] Биредә Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342) әсәре күздә тотыла булса кирәк.

[6] *Канда* — кайда.

[7] *Гаҗәм* — фарсы.

[8] *Баб* — бүлек.

[9] «Берөзлексез мәгънә җимешен җыеп торыр».

Игү аты калса ирнең яхшырак,
Соңра калгинча тулы алтун рәвак[1].

Ядкаре калса кемнең игү ат,—
Үлмәс ул ир,— кемдә булса бу сыйфат...

Беренче баб

Патшалар тормышы турында

* * *

Фетнә йөзле раст[2] сүздән бул ерак,
Мәслихәтле ялган андан яхшырак.

Гакыйл[3] ул — сүзне йирендә сүзләгәй
Һәм җавабыны мөнасиб күзләгәй[4].

Кем мөхалиф[5] булса солтан сүзенә,
Килтүрүр ул күб бәлаләр үзенә.

* * *

Сыйгар бер хөҗрәгә уникке миһман,
Бер икълимә сыйгышмас икке солтан[6].

* * *

Бүренең баласы булыр гакыйбәт[7]
Атасы кеби ул хәрами[8] бүре.

Ничә күб йидырсаң[9], сәңа беркөн ул
Орыр зәхм[10], андан саклана йөре.

---

[1] *Рәвак* — сарай.
[2] *Раст* — дөрес.
[3] *Гакыйл* — *монда:* акыллы.
[4] *Мөнасиб күзләгәй* — урынлы бирер.
[5] *Мөхалиф* — каршы.
[6] «Бер бүлмәгә унике кунак сыяр, (Әмма) бер илгә ике солтан сыймас».
[7] *Гакыйбәт* — ахыр чиктә, барыбер.
[8] *Хәрами* — карак, явыз.
[9] *Йидырсаң* — ашатсаң.
[10] *Орыр зәхм* — һөҗүм итәр.

* * *

Тотыб мескен кешенең пәнҗәсене[1]
Аермак көч беләң — гайне[2] хатадыр.

Игеб золм орлыкны хәйр эстәгәнләр
Җәһәннәм утына үзен якадыр.

Котылмага теләсәң хәүф илендән,
Рәгыять[3] халенә яхшы бакадыр[4].

* * *

Нәсыйхәт тотмаган гафил[5] кем ирсә[6]
Төшәр даим мәшәккатьнең кынына.
Белерсән: зәхменә[7] чөн такәтең юк,
Кулыңны сукмагыл гакрәб[8] өненә.

* * *

Әйа, гаклы тиңиз, сүзе гөһәрбар[9],
Утырсаң, күзем өстендә йирең бар.

* * *

Ничә кем фәһме[10] мескен ишәкнең
Күтәрмәк берлә йөкне — кыйммәте бар.

Ишәк ул адәмидән яхшырак, кем
Кылыр даим кешенең күңлен азар[11].

---

[1] *Пәнҗә* — кул чугы, биш бармак.

[2] *Гайн* — күренеп торган, ачык.

[3] *Рәгыять* — бер дәүләтнең халыклары; кул астындагы кешеләр, масса.

[4] *Бакадыр* — бага тор, карый тор.

[5] *Гафил* — зиһенсез; надан.

[6] *Кем ирсә* — кеше.

[7] *Зәхменә (зәхем)* — ору; чагу.

[8] *Гакрәб* — чаян.

[9] *Гөһәрбар* — гәүһәрдәй, кыйммәтле.

[10] *Фәһме* — акылы, зиһене.

[11] *Кылыр азар* — рәнҗетер.

Хикайәт [Залим хаким]

Бер залим хаким бер галим иргә сорды[1] кем: «Гыйбадәтләрдә фазыйлрагы[2] кайсы торыр?» Әйтте: «Зөһер[3] вактын оемак, хәтта ул заман эчендә халыкны азар кылмагайсән[4]».

Күрдем өвлә[5] вакыт бер залим оер.
Әйттем: Ул фетнә оеса яхшырак.
Даим илгә золым кем кылса, аның
Үлмәге яхшы хәятындан бирак[6].

* * *

Дүгелдер дустың — нигъмәтдә һәркем
Мәхәббәт лафыны орса янында.
Хакыйкать[7] дустың — ярыңдыр ул кем,
Кулың тотса аякдан төшкәнеңдә.
Екар булсаң дәгый бер гәз күңелне[8],
Күңел аһы сәне кау[9] тик якар бел.

Кәйхөсрәу[10] тажының өстендә бу икке бәйтне языб торырлар:

Башымыз өстендә бу халкы җиһан,
Сәйр иткәйләр[11] йир үзә[12] күп заман.
Илдән илгә[13] килде безгә мәмләкәт,
Илля һәм киткәй килеб илдән рәван[14].

---

[1] *Сорды* — сорау бирде.
[2] *Фазыйлрагы* — әйбәтрәге, файдалырагы.
[3] *Зөһер* — төш (вакыты).
[4] *Азар кылмау* — рәнҗетмәү.
[5] *Өвлә* — өйлә.
[6] *Хәятындан бирак* — тереклегеннән (яшәвеннән) бигрәк.
[7] *Хакыйкать* — чын.
[8] «Бер генә мәртәбә күңелне рәнҗетсәң дә».
[9] *Кау (каудан)* — коры үлән.
[10] *Кәйхөсрәу* — Иранның борынгы шаһларыннан берсе.
[11] *Сәйр иткәйләр* — йөрерләр; сәяхәт кылып торырлар.
[12] *Йир үзә* — җир өстендә.
[13] *Илдән илгә* — кулдан кулга.
[14] *Рәван* — бик тиз.

Хикайәт [Көрәшче пәһлеван]

Бер көрәшче пәһлеван өч йөз алтмыш төрле көрәш гыйльмен[1] белер иде. Тикмә бер көн[2] бер төрле гыйлем белән көрәшер иде. Шәкердләреннән бер сахибҗәмал[3] углан белән хатыйре мөтәгаллекъ булып[4], өч йөз илле тукыз төрле көрәш гыйльмен аңа үгрәтте. Углан ул гаятькә йитте кем, бу вилаятьдә[5] никадәр көрәшче бар иде, барчасын басты. Беркөн солтан хедмәтенә килеб, йир үбеп әйтте: «Остадымның мәнем үзә тәрбият хаккы бар. Юкса куввәтдә вә санәгатьдә[6] мән андан артыкмән». Бу сүз солтанга хуш килмәде, боерды кем: «Көрәшсенләр!» Мәкам[7] тәртиб кылдылар. Әркане дәүләт вә әгъйане хәзрәт, өмәра вә вөзәра хазыйр булдылар[8]. Углан исрүк фил кеби мәйданга кереб, тәссаувыр итте[9] кем, тимердән таг булса, йирендән купаргаймән. Остады дәгый белде кем, үзендән артык торыр. Ул бер гыйлемне кем мондан гизләп иде[10], аны гамәлгә китерде. Углан дәфегъ итә[11] белмәде. Угланны күтәреб, һавадан йиргә орды. Халыкдан гари кубты[12]. Солтан боерды: остадына хилгать[13] вә нигъмәт бирделәр дәгый угланны мәламәт[14] кылдылар кем: «Сән үз остадың белән дәгъви кылдың, дәгъвиең батыйль[15] булды». Углан әйтте: «Ул мәнем үзә куввәт белән галиб[16] бул-

---

[1] *Көрәш гыйльмен* — көрәш ысулын.

[2] *Тикмә бер көн* — һәр көнне.

[3] *Сахибҗәмал* — гүзәл, матур.

[4] *Мөтәгаллекъ булып* — мавыгып, дуслашып.

[5] *Вилаять* — ил, өлкә.

[6] *Санәгатьдә* — осталыкта.

[7] *Мәкам* — урын, мәйдан.

[8] «Дәүләтнең терәкләре, олуг руханилары, әмирләр вә вәзирләр җыелдылар».

[9] *Тәссаувыр итте* — уйлады, күз алдына китерде.

[10] *Гизләү* — яшерү.

[11] *Дәфегъ итә* — кире кага, каршы тора.

[12] *Гари кубты* — хупланды, алкышланды.

[13] *Хилгать* — бүләк ителгән өс киеме.

[14] *Мәламәт* — шелтә.

[15] *Батыйль* — ялган, нигезсез.

[16] *Галиб* — өстен, җиңүче.

мады, бәлки көрәш тәгълимендән бер дәкыйканы[1] гизләмеш. Аның белән галиб булды». Остады әйтте: «Бәли, ул дәкыйканы бу көн өчен гизләб идем. Гакыйллар мәсәле[2] торыр: «Дустка ул кадәр яри[3] кылгыл кем, дошман булса, сиңа зафәр[4] табмагай».

Шигырь

Йа вафа[5] юк торыр бу галәмдә,
Йә кеше кылмады җиһанда аны.
Мәндән ук гыйльмен үгрәнеб киткән
Гакыйбәт[6] кылды ул нишанә[7] мәне.

* * *

Тимер түккән беләк мең корла[8] яхшы,
Ул илдән кем кукесендә биккә каршы[9].

Икенче баб

Дәрвишләр әхлагы турында

* * *

Алныңда — юаш бикин мөшфик яр[10],
Артыңда бүре кеби тиреңне ертар.

* * *

Бер әбләһ уртада кылды яманлык,
Ничә гакыйлларга тигде зыяны.

---

[1] *Дәкыйка — монда:* өлеш, элемент.
[2] *Мәсәл* — элек «мәкаль» төшенчәсендә дә кулланылган.
[3] *Яри (яр)* — дус.
[4] *Зафәр* — җиңү.
[5] *Вафа* — тугрылык.
[6] *Гакыйбәт* — ахырда, ахыр чиктә.
[7] *Нишанә* — мишень.
[8] *Корла* — мәртәбә, тапкыр.
[9] «Бик каршында кукрәккә куйган кулга караганда».
[10] «Алдында — юаш куй кебек шәфкатьле дус».

* * *

Кичә бер хәстә өчен саг ирнең
Таң аткинча күздән яшь килде.
Таң атты. Хак Тәгалә әмре берлә
Сукәл[1] ир саг булды, саг үлде.

Хикайәт [Әдәпне әдәпсезләрдән өйрәндем]

Локман Хәкимгә сордылар: «Әдәпне кемдән үгрәндең?» Әйтте: «Әдәпсезләрдән. Бактым аларның әфгаленә[2], кайсы хәрәкәт кем миңа хуш килмәде, андан ихтираз кылдым[3]».

Әгәр уйнаб бер кеше бер хәрф[4] әйтсә,
Алыр андан белек әһле нәсыйхәт.
Килер ахмак колакына уенчак[5],
Укыр булсаң йөз илле баб хикмәт.

* * *

Сән игү бул, яман дисен хәлаек[6],
Яман булып сәңа яхшы дигәнче.

Хикайәт [Авыр сүзне күтәрү авыр]

Бер салих[7] ир күрде: мең батман таш күтүргән[8] пәһлеванны. Газаби килеб, агызы күбекләнеб утырыр. Сорды: «Моңа ни булып торыр?» — диб. Бер кеше әйтте: «Боңа фәлән кем ирсә сүкте»[9]. Әйтте: «Бу әбләһ мең батман ташны күтүрүр, дәгый бер сүкенечне[10] күтәрә алмас».

---

[1] *Сукәл* — авыру, хаста.
[2] *Әфгаленә* — эшләренә, гамәлләренә.
[3] *Ихтираз кылдым* — тыелдым.
[4] *Хәрф*— хәреф, сүз.
[5] *Уенчак* — уен, кызык.
[6] *Хәлаек* — халыклар.
[7] *Салих* — изге.
[8] *Күтүргән* — күтәргән.
[9] «Моны фәлән кеше сүкте».
[10] *Сүкенечне* — сүгүне.

Бу ирлекдә үкенеп лаф орырсән,
Ничөн бәс нәфсеңә гаҗиз булур сән.
Дәгел ирлек агызга йомрык[1] ормак,
Ир исәң кой агызга бал вә каймак.

* * *

Күңел бирмә күңел бирмәс кешегә,
Ашыккан ир белән юлдаш булма...

Өченче баб

Аз белән канәгать булуның хәере

Төрш йөзленең илиндән йийкинча бал вә тәр каймак[2],
Көләч йөзленең илиндән алыб хәнзал[3] йийсә хушрак.

* * *

Йөзеңне төрш[4] итеб китмә кешегә,
Аның күңлен дәгый гамьгин[5] кылырсән.
Көләч йөз белә кем хаҗәт теләсә,
Эше багланмас[6] ул ирнең, белерсән.

* * *

Сусамыш ирнең агзында җәваһир[7]
Сәдәф берлән сәвадыр[8], и газиз ир.
Аның кем азукы юктыр, күгәрмеш
Коры итмәк табып сөккәр[9] бикин йийр.

---

1 *Йомрык* — йодрык.
2 «Чытык йөзленең кулыннан бал вә тәмле каймак ашаганчы».
3 *Хәнзал* — ачы (өлгермәгән) кавын.
4 *Төрш* — чытык.
5 *Гамьгин* — кайгылы.
6 *Эше багланмас* — эше туктап калмас.
7 *Җәваһир* — «җәүһәр» сүзенең күплек санда бирелеше.
8 *Сәва* — тиң.
9 *Сөккәр* — шикәр.

* * *

Төшеб беркөн атындан бу мәсәлне
Бәдиһә назым итте[1] Хуҗа Исхак[2]:

Җиһан сәүгән кешенең күзләрене
Канәгать тулдырыр йә, үлсә, тубрак.

* * *

Ка(й)чан җан алгыйчы[3] дошман ирешсә,
Әҗәл баглар йөгергәннең аягын.

* * *

Күзен баглар дәраһим[4] гакыйл[5] ирнең,
Тәмәгъ[6] салыр очар кошны тозакка.

Дүртенче баб

Дәшми торуның файдасы

* * *

Гөлдер бу Сараи Сәйф, ләкин
Дошман күзенә тикән[7] күренер.

* * *

...Икке җаһил[8] качан орыш башлар —
Йөз бозарлар орыб, ярыб башлар.

---

[1] *Бәдиһә назым итте* — озак уйлап тормыйча (экспромт белән) шигырь әйтте.

[2] *Хуҗа Исхак* — XIV йөздә яшәгән Алтын Урда шагыйре.

[3] *Алгыйчы* — алучы.

[4] *Дәраһим* — дирһәм (акча берәмлеге) сүзенең күплек санда берелеше.

[5] *Гакыйл* — акыллы.

[6] *Тәмәгъ* — комсызлык, нәфес.

[7] *Тикән* — тигәнәк; чәнечкеле үлән.

[8] *Икке җаһил* — ике надан.

* * *

Мәҗалисдә[1] утырган ир сүзенең,
Белерсән, әүвәленең ахыры бар.

Качан сүз башласа сөхбәтдә бер ир,
Китермә уртага сүз анда, зинһар.

Сүзен ул йирдә сүзләр һәр белекле,
Ки сакит булгай анда җөмлә гөфтар[2].

Бишенче баб

Мәхәббәт һәм яшьлек турында

* * *

Бар иде хуҗаның уздан[3] колы,
Ул иде мәхбуби йари, шәнгәли[4].
Чөнки сәүде хуҗа җандан колны бик,
Хуҗасы кол булды, колы булды бик.

* * *

Күреп ул ай бикин (кебек.— *Х. М.*) йөзне сәңа булыб мән кол,
Янә оныттым үземне булып сәңа мәшгуль.

* * *

Нине күңлең теләсә, бар аны кыл,
Вафасыз[5] дилрәба[6] сән, и биле кыл.

* * *

Килеб үлтер мәне имди, фида кылдым сәңа җан уш,
Мәңа сәнсез терелгинчә, синең алныңда[7] үлсәм хуш.

---

[1] *Мәҗалисдә* — мәҗлестә, җыелышта.
[2] «Барлык сөйләүче туктап калгач».
[3] *Уздан* — гүзәл.
[4] «Ул иде гүзәл яр, шат күңелле».
[5] *Вафасыз* — тугрылыксыз, ышанычсыз.
[6] *Дилрәба* — йөрәкне теткәләүче; гүзәл яр.
[7] *Алныңда* — алдында.

* * *

Сулды кызыл гөл яңакың, и санәм,
Шивәләрең рәүнакы булды гадәм[1].

Хөкмең ишетер иде солтане Чин[2],
Имди бу көн сүзең ишетмәс чебен.

Җәүр ничә гашыйкыңа кылгасән[3],
Җан вә күңелне ни белән алгасән.

Кичте җәмалың[4] гөленең нәүбәте,
Кылма тәсаувыр дәгый ул дәүләте[5].

Баргыл аңа, кем сиңа җаным дигәй,
Наз аңа кылгыл ки — сәне эздәгәй[6].

* * *

Сиңа бу шивәләр[7] берлән күңел алмак кем үгрәтте!
Җәмалыңны күреп, заһид тотыб гыйшкың юлын кисте[8].
Мәнем каум-у кабиләмнең[9] камусы[10] галим ирделәр,
Синең бу гыйшкың остады миңа шагыйрьлек үгрәтте.

* * *

Күңелне баглама бер йиргә, зинһар,
Янә мөшкелдер андан алмак, и йар.

---

1 «Яңакларыңның балкышы юкка чыкты».

2 *Солтане Чин* — Чин (Кытай) солтаны.

3 *Кылгасән* — кылырсың.

4 *Җәмалың* — гүзәллегең.

5 Ягъни «элеккеге дәүләтең (матурлыгың) белән эреләнмә».

6 *Эздәгәй* — теләгәй.

7 *Шивә — монда:* назлылык, матурлык.

8 «Матурлыгыңны күреп, изге зат синең гыйшкың юлына төште».

9 *Каум-у кабиләм* — нәсел-нәсәбем.

10 *Камусы* — һәммәсе.

* * *

Мин кирәк үлгәй идем, и гөле бәдән[1], сәндән борын[2]
Та күзем сәнсез җәһанны күрмәгәй иде бу көн.

* * *

Йомрык[3] синең илеңдән[4] татлы килер агызга,
Үзгә кеше илендән шәhд-ү шәкәр йийгинча[5].

* * *

Бер эшне кем үфкә белән эшләгәй,
Кылыб хәйф, соңра илен тешләгәй[6].

Хикайәте мәнзумә[7]

Ишеткел бу хикайәтне-хәбәрдер:
Ари[8] юлда йөргән бу егет ир.

Бер ай йөзле белән баглаб мәхәббәт
Кылур йирдә hәмишә[9] пакь сөхбәт.

Торыб бер көн ул икке яр-у мәүзүн[10]
Кимәдә ултырыб киттеләр аркун[11].

Каза нагяh мөхалиф йил китерде[12],
Кимәне мәүҗ орыб суга борды[13].

---

[1] *Гөле бәдән* — гөл тәнле.
[2] *Сәндән борын* — синнән элек.
[3] *Йомрык* — йодрык.
[4] *Илеңдән* — кулыңнан.
[5] «Үзгә кеше кулыннан татлы шикәрне ашауга караганда».
[6] «Соңрак, үкенеп, кулын тешләгән».
[7] *Хикайәте мәнзумә* — шигъри хикәят.
[8] *Ари* — саф, дөрес.
[9] *Һәмишә* — hәрчак.
[10] *Яр-у мәүзүн* — зифа буйлы яр.
[11] *Аркун* — акрын.
[12] «Каза кинәт каршы җил китерде».
[13] «Көймәне дулкын орып суга әйләндерде».

Алар төште тирән су игрәменә[1],
Бер узгучы бакыб ул гамь дәменә[2]

Аларның беренә әйтте: «Илең сон[3],
Янә кылмак теләсәң гыйш[4] һәр көн».

Ул әйтте: «И, каләми җаныма кот,
Мәне куй, барыб ул ярым илен тот».

Хакыйкать гашыйк ирнең мәзһәбе ул,
Теләсәң булмага гашыйк,— алай бул.

Йакарлар ул кешене утка йарын[5],
Куеб михнәт эчендә китсә йарын.

Белер Сәйф Сараи гыйшык рәсмен[6],
Ничек кем белсә һәр остад кыйсмен[7].

Алтынчы баб

Картлык вә зәгыйфьлек турында
[Йөз яшьлек картның үлем алдыннан әйткән сүзләре]

Теләдем бер заман күрсәм җиһанны,—
Дәрига[8]! Булды күзем бәбәге хәс[9].

Бер-ике хуш нәфәс өрмәк[10] теләдем,—
Нәфәс юлы тотылды, булдым әхрәс[11].

---

[1] *Игрәменә* — чоңгылына.
[2] *Гамь дәменә* — кайгылы вакытка.
[3] *Илең сон* — кулың суз.
[4] *Гыйш (гайш)* — кәеф-сафа; тереклек.
[5] *Йарын (йәрен, җәрен)* — тиз вакытта, иртәгә.
[6] *Рәсмен* — гадәтен.
[7] «Һәр остаз үз кыйсмен (фәнен) белгән кебек».
[8] *Дәрига* — кызганыч, үкенеч.
[9] «Күземнең бәбәге хәлсезләнде (йомылды)».
[10] *Нәфәс өрмәк* — сулыш алмак.
[11] *Әхрәс* — тынсыз, телсез.

Җиһан ханының әлван нигъмәтендән[1]
Биш-алты локмә йийдым, әйттеләр: Бәс!..[2]

...Бер кешенең тешен чәкиб җәррах[3]
Чыкарыр булса, бел — нидер хале.

Кил, кыяс ит[4], ни булгай ул сәгать
Татлы җан чыкса, калса тән хали[5].

* * *

Вафа эстәмәгел[6] былбылдан, и йар,
Ки һәрбер гөл үзә[7] төрле сайрар.

Хикайәт [Ананың үпкә сүзләре]

Беркөн Рөстәм[8] анасына каты сүзләде. Аның күңеле агрыб, еглап әйтте: «Мәгәр кечелекне оныттың кем, олуглык итәр сән...»

Анасы инҗенеп[9], Рөстәмгә әйтте:
«Әйа күргән озын гайрәтле арслан,
Әгәр булса иде, йадыңда ул көн.
Кем илемдә идең бер яшь углан.
Бу көн буйлә[10] мина җәүр итмәс идең,
Ки сән — бер пәһлеван, мән карый җан».

---

[1] «Җиһан табынының күп төрле нигъмәтеннән».
[2] *Бәс* — җитте; булды.
[3] *Җәррах* — хирург.
[4] *Кыяс ит* — чагыштыр.
[5] *Хали* — буш.
[6] *Вафа эстәмәгел* — тугрылык теләмә.
[7] *Гөл үзә* — гөлдә, гөл өстендә.
[8] *Рөстәм* — Иран халыкларының легендар каһарманы. Фирдәүсинең «Шаһнамә» әсәрендә үзәк персонаж.
[9] *Инҗенеп* — рәнҗеп, әрнеп.
[10] *Буйлә* — болай.

Җиденче баб

Тәрбиянең тәэсире турында

Кечелекдә әдәб үгрәнмәгән ир
Олы булса, бел, андан хәйр килмәс.

Игелер яшь агач ничек теләсәң,
Коры игри агач утсыз төзәлмәс[1].

* * *

Мөгаллим булмаса һәйбәтле[2], и яр,
Сакалындан тотып угланлар уйнар.

* * *

...Һәр ки нәфсен йиңәр — бәһадур ул,
Пәһлеван булсаң — аның биге бул.

Булмаса кырык яшәрдә гакыл вә әдәб,
Дәгел инсан[3] дисәң аны ни гаҗәб.

Ирлек ул эш дәгел — күңел еккай.
Йә кеше гайбене күреб чаккай.

Ир кирәк күңле кинәдән хали[4],
Үзе әлҗак вә һиммәте гали[5].

[Кабер ташына язылган сүзләр]

Шад булыр күңел ничә күрсә,
Җөмлә[6] сәхра йөзен чичәк[7] тотмыш.
Килсәң, и дуст, күргәсән элек яз,
Тубракым өстенә яшь ут бөтмеш [8].

---

[1] «Коры кәкре агач утсыз төзәлмәс».
[2] *Һәйбәтле* — таләпчән, кырыс.
[3] *Инсан* — кеше.
[4] *Кинәдән хали* — үчтән (мәкердән) азат.
[5] «Үзе тыйнак вә теләк-омтылышы олы».
[6] *Җөмлә* — барлык, бөтен.
[7] *Чичәк* — чәчәк.
[8] *Яшь ут бөтмеш* — яшь үлән үсеп чыгар.

* * *

Сәхиләрнең илендә бер дәрәм юк,
Ганиләрдә дәраһим чук, кәрәм юк[1].

Сигезенче баб

Сохбәт әдәбе турында

Эчереб илгә кашык берлә шурба,
Чүмеч сабы белән күзен чыгарма.

Хикмәт

Ике кеше файдасыз рәнҗ чикте дәгый тохмны шүрә йиргә икте[2]: бер — ул, кем мал йигды, дәгый йиймады[3], икенче — ул, кем гыйлем укыды, дәгый гамәл кылмады.

Сүзең бу дорыр ки: мән фәлан галим мән,
Чөн юк гамәлең янә һаман җаһил[4] сән.
Моның мәсәле ушул ишәккә охшар,—
Белмәс ки, йөге утынмыдыр йә дәфтәр.

Хикмәт

Өч нимә даим калмас: бере — тиҗарәтсез[5] мал, икенчесе — бәхәссез гыйлем, өченчесе — сәясәтсез мөлк[6]. Әмма яманларга рәхим кылмак игүләргә җәүр итмәк булыр. Дәгый залимнәрдән гафу итмәк фәкыйрьләргә золым кылмак булыр.

Яманга игелек кылсаң, сонып[7] кул,
Илеңдән дәүләтнең алмак теләр ул.

---

[1] «Юмартларның кулында бер акча да юк,
Байларда (исә) акча күп, юмартлык юк».
[2] *Тохмны шүрә йиргә икте* — орлыкны тозлы җирдә икте.
[3] «Мал җыйды, әмма ашамады».
[4] *Җаһил* — надан.
[5] *Тиҗарәт* — сәүдә.
[6] *Мөлк* — патшалык.
[7] *Сонып* — сузып.

Хикмәт

Ул кеше, кем дошманлар белән солых кылыр, дуслары андан азар булыр[1]...

Илең йу ул монафикъ[2] дустдан, кем
Йөрер дошманларың берлән булыб яр.

Нәсыйхәт

* * *

Адәми күңлен екар сүз сүзләмә,
Солх иясендән хосумәт[3] күзләмә.

* * *

Кыл хәзәр дошман сүзендән, и рәфикъ[4],
Ни кем ул әйтсә, аның сән гаксен[5] ит.

Күргүзсә саг йаны юл сәңа[6],
Сән аның сүзен ишетмә, сулга кит.

* * *

Холкы яман кем ирсә качса бәла илендән,
Кортылмагай[7] ничә кем, ул холк аның беләдер[8].

Нәсыйхәт

Ул эш кем күңелләр азар кылыр[9], сән аны эшләмәгел, үзгәләр эшләсен.

Әйа килгән җиһанга игелек ит,
Яман эшне яманларга куеп кит.

---

[1] *Азар булыр* — рәнҗер.
[2] *Монафикъ* — икейөзле.
[3] *Хосумәт* — дошманлык, кимчелек.
[4] *Рәфикъ* — иптәш.
[5] *Гаксен* — киресен.
[6] «Күрсәтсә юлны уң яктан сиңа».
[7] *Кортылмагай* — котылмас.
[8] *Аның беләдер* — аның беләндер.
[9] *Азар кылыр* — рәнҗетер.

Хикмәт

Ун кеше бер сөфрәдә[1] йимәк йийр дәгый артыр. Ике эт бер мордар[2] өчен бер-берен ертар.

Хикмәт

Белексез кешегә сөкүтдән[3] яхшырак юк. Әгәр бу мәслихәтне белсә иде, белексез булмагай иде.

Кәмале фазл[4] сәндә чөнки юктыр,
Телеңне сакла агзыңда, утыр тик.
Кылыр ирне теле даим фәзыйхәт[5],
Черек кузны[6] ничек кылса йөңүллек[7].

Хикмәт

Арслан белән пәнҗә тотмак[8], дәгый кылычка йомрык ормак гакыйллар эше дәгел.

Хуш әйтте моны ул әдибе зариф:
Мәликкә булырмы каләндәр хәриф[9]?!

Үз иле белән үз кулын сындырыр,
Кави[10] берлә пәнҗә тотышкан зәгыйфь.

---

[1] *Сөфрә* — табын.
[2] *Мордар* — үләксә.
[3] *Сөкүт* — дәшмәү.
[4] *Кәмале фазл* — камил тәрбия.
[5] *Фәзыйхәт* — оятлы, оят.
[6] *Куз* — чикләвек.
[7] *Йөңүллек* — җиңеллек.
[8] *Пәнҗә тотмак — монда:* көрәшмәк.
[9] «Патшага сукбай иптәш булырмы?!»
[10] *Кави* — көчле.

* * *

Тере ирне иңән асан[1] орып ук берлә үлтермәк,
Вәликен үлене мең кем ирсә тергезә белмәс.
Әйа, ук аткучы, яхшы сагышлаб элек[2], андан ат,
Белүрсән ук качан ядән[3] чыкар булса, янә килмәс.

* * *

Җаһилләр ара галим ултырса, аңа охшар:
Бер шәмгы мөнәүвәрдер күзсезләр арасында[4].

Нәсыйхәт

Газиз гомрең хәрҗ итеб[5], татлы җан бикин дуст хасыйл иттең, дәгый бер сәһл[6] сүз белән аның күңлен агрыттың[7].

И ничә көнләр кирәк кем гүрә булса татлы аш[8]!
И ничә еллар кирәк кем ләгыль[9] булса асыл таш!

Сән аны бер сүз белә сындырмагыл, йаре чөст[10]
Кем пиалә сынса, мөшкелдер янә кылмак дөрест.

* * *

...Теләсәң игү атың мәңгү калгай,
Аякдан төшкән илен тотгучы бул[11]!

---

[1] *Иңән асан* — бик ансат.
[2] *Яхшы сагышлаб элек* — әүвәл яхшылап уйла.
[3] *Ядән* — җәядән.
[4] «Надан арасында утырган галим күзсезләр арасындагы якты шәмгә охшар».
[5] *Хәрҗ итеб* — уздырып.
[6] *Сәһл (сәһел)* — җиңел, юк.
[7] *Агрыттың* — үпкәләттең, рәнҗеттең.
[8] «И ничә көннәр кирәк ачы җимеш татлы аш булсын өчен».
[9] *Ләгыль* — кыйммәтле таш.
[10] *Чөст* — үткен.
[11] «Аяктан төшүченең (бәхетсезнең) кулын тотучы бул!»

* * *

...Бер кешене мең арслан үлтермәс,
Килмәенчә аңа казаи әҗәл.

Хикмәт

Солтан хилгате[1] ничә кем газиз исә, һәрбер кешегә үз туны андан газизрәк торыр.

Никадәр кем бикләр ашы татлы булса, и кунак,
Ярлы-юксылга коры итмәке андан яхшырак.

* * *

Сохбәт итмәймән[2] кеше берлән,
Никадәр пакь исәң, мөнәҗҗәс итәр[3];
Көнәш анча биеклеге берлән
Бер әйача болыт күренмәс итәр [4].

* * *

Хатага нисбәт итмәс кем ишетсә,
Сүзе даим аның кем раст булгай.
Һәр ир ялган белән мәшһүр булса,
Кем аны раст диб икърар кылгай[5]?

* * *

Тоз-итмәкне онытмас кәлб[6] гәр йөз
Куар булсаң, янә кайтармас ул йөз.
Монафикъ[7] сохбәтендә нигъмәтең йийр,
Чыкыб дошманларыңа гайбәтең дийр.

---

[1] *Хилгать* — бүләк итеп бирелгән өс киеме.
[2] *Сохбәт итмәймән* — аралашмыйм, сөйләшмим, дуслашмыйм.
[3] *Мөнәҗҗәс итәр* — пычратыр.
[4] «Кояш никадәр биек булса да,
Бер юк кына болыт (аны) күренмәс итәр».
[5] *Икърар кылгай* — раслар.
[6] *Кәлб* — эт.
[7] *Монафикъ* — икейөзле.

Хикмәт

Имам Газзалига[1] сордылар: «Монча мәнзиләткә[2] ни белән йиттегез?» Әйтте: «Аны кем белмәс идем, сормага гарь кылмас идем».

Гарь күрмә белмәгәнне сормага,
Сормаенча гыйлем үгрәнмәс кеше.
Гыйлем укыб һәркем гамәл кылды исә,
Җәннәт эчендә тәфәрреждер[3] эше.

* * *

И ничәләрне күрептер бу җиһан,
И ничәләрдән дәгый артыб калыр!
Сән алардан алмасаң гыйбрәт бу көн,
Таң белә сәндан болар гыйбрәт алыр.

[«Гөлестан бит-төрки»нең ахыры]

Бер нәсыйхәт шартын уш кылдык бәян,
Кем ишетмәс булса безгә ни зыян.

Ул белекле кем, ишетеб эш итәр,
Ляҗәрем[4] максудына асан йитәр.

Юл өчен азык анык итмәк кирәк,
Чөн бу мәнзилдән[5] күчеб китмәк кирәк.

Монда даим игелек иткән кеше,
Җәннәт эчендә тамашадыр эше.

Мөддәте һиҗрәт йиде йөз туксан өч[6],
Ел иде кем аз иде гыйльмендә[7] көч.

---

1 *Имам Газзали* — XI—XII гасырларда яшәгән мәшһүр философ, дин галиме. Татарлар арасында ул бик танылган булган.

2 *Мәнзиләт (мәнзәләт)* — дәрәҗә, югарылык.

3 *Тәфәрреҗ* — күңелле, уңай.

4 *Ляҗәрем (ляҗәрәм)* — һичшиксез.

5 *Мәнзил* — йорт, тору урыны. Биредә «бу дөнья» мәгънәсендә.

6 «Һиҗри вакыты белән 793». (Безнеңчә 1391 ел.)

7 *Гыйльмендә* — шигырь гыйлеме күздә тотыла булса кирәк.

Әүвәле шәүвәл[1] иде кем, и газиз,
Хәтем улды[2] бу «Гөлестан» намәмез[3].

Камил ир гайб эстәмәс, күзләр һөнәр,
Мөддәгъый[4] күзләб һөнәр гайбен күрәр.

Дәмбедәм[5] бу рәнҗ эчендәдер хәсуд[6],
Күргезер даим мөрәүвәт әһле җуд[7].

Йа Иляһи, сән морадын бир аңа,
Кем бу месккенне дога берлә аңа.

Хәйр үзә тот бу китабәт кятибен[8],
Рәхмәтең берлән гани кыл[9] сахибен...

...Кыл нәзар[10] Сәйф Сарайи ярлыга,
Гафу итеб йазукларын ярлыга[11].

Ул куеб китте җиһанда ядгяр,
Бу «Гөлестан»ны тари чөн нәүбәһар[12].

«СӨҺӘЙЛ ВӘ ГӨЛДЕРСЕН» (1394)

Тәрҗемә*

Бу язма бер хыял җимеше түгелдер,
Ике гашыйк турында, булган эш бер.

---

* *Нури Арсланов* тәрҗемәсе.

1 *Әүвәле шәүвәл* — шәүвәл аеның башы, ягъни 1391 елның август башы.

2 *Хәтем улды* — төгәлләнде.

3 *Намә* — әсәр; язу.

4 *Мөддәгъый* — дәгъвачы, гаепләүче.

5 *Дәмбедәм* — һәрчак, бөрөзлексез.

6 *Хәсуд* — көнче.

7 «Юмарт кеше һәрчак егетлек (кешелеклелек) күрсәтер».

8 *Китабәт кятибен* — китапны язучыны.

9 *Гани кыл* — бай кыл.

10 *Кыл нәзар* — кара, бак.

11 *Йазукларын ярлыга* — гөнаһларын кичер.

12 «Чөнки бу «Гөлестан» — мәңгелек яз».

Дәвернең сөйлим аглап бер җәфасын,
Бер ирнең кыйссасын, газап-хафасын.

Тимерләнг Үргәнечкә яу китергәч,
Колак тонды, ә күзләр булды күрмәс.

Сугыштан купты бар галәмдә туфан,
Агызды, су кебек, җир өстенә кан.

Игенче өйләрен яндырды утта,
Бодай тапталды, туфрак булды ботка.

Үлеп калды[1] сугышта Туктамыш хан,
Туганнан аерылып калды туышкан.

Сөһәйл — гаскәр башы әсир ителде,
Бу хәл һәркемгә зур кайгы китерде.

Сугышчылар кылалмый калды чара,
Бу кайгы булды бар күңелгә яра.

Йосыфтан да егет матур чырайлы,
Йөзендә балкыйдыр алманың алы.

Гаҗәп сыйфатлары бар, сүзе татлы,
Гашыйк итәр Шириндәй пәри-затны.

Ләкин язмыш ташы төшеп башына,
Башын салган егет гаме кашына[2].

Залимнәрдән рәхим-шәфкатьме тапсын,
Моңын кемгә сөйләп, эчен бушатсын!

Моны күргәннәр аһ итә, елаша,
Очар кошлар аның хәлен сораша.

Гөлестан җырчысы — былбыл тыналмый,
Өзеп моңлы итеп сайрый да сайрый.

---

[1] Төгәлсезлек киткән булса кирәк. Чынлыкта Алтын Урда ханы Туктамыш 1406/1407 елда һәлак була *(тәрҗемәче искәрмәсе)*.

[2] *Кашына* — янына; «башына кайгы төшкән» дигән мәгънәдә *(Н.А.)*.

Башын игән тулып алтын башаклар,
Башакларны җыярга житте чаклар.

Игәр илгә дип ашлык гел игенче,
Аның бар иккәне — бәхет һәм энҗе!

Агачларда үсәр татлы җимешләр...
Бу җирне бик дөрес оҗмах димешләр.

Сөһәйл юлдан бара, йөзе ваемлы,
Кара көйгән җаны, күзләре дымлы.

Аның күңеле боек, йөзендә яшьләр,
Күренми күзенә гөлләр, агачлар...

Сөһәйлнең чокырда ятуы

Аяк-кулы аның чылбыр-богауда,
Кадакланган баганасы да янда.

Төшерделәр тирән зинданга аны,—
Колакка кермәде һич аһ вә зары:

Кояш дөнья йөзеннән җиргә батты,
Өзелгән гөл кара туфракка ятты.

Күренмидер чокырда яктылык-нур,
Үлек черер урын бу, җанлыга — гүр.

Ләкин чын ир-егет һич монда үлмәс,
Батыр җаннарга бер дә курку килмәс.

Бу дөнья әйләнеп, вакыт килер бер,
Гаделлек орлыгы чәчәк бирер бер!

Сөһәйлнең төш күрүе

Сөһәйл зинданда. Бик кыйналды җаны,
Хәле китеп, йокысы килде аның.

Йокыда күрдеге дәһшәтле төштән
Югалтты ул исен, еш язды һуштан.

Бусында бер пәри кызы күренде:
Җыя-җыя чәчәкләр багда йөрде.

Сөһәйл әйтте: «Нигә гөлләр җыясың?
Үзең — гөл, кайсы гөл тиңдәш сиңа соң!

Затың кем, әйт, пәриме йә адәм-зат?
Атыңны әйт миңа, мәңге итим яд.

Кылам Аллага мин мең-мең шөкерләр,
Миңа биргән өчен кояш кебек яр».

Җавап көтте, гыйшыктан мас булып
(исереп.— *Х. М.*) ул,
Ә тәкъдир чыкты тиз бирмәс булып кул.

Гүзәл кыз чапты да күздән югалды,
Сөһәйл җанын кабызды — утка салды.

Сөһәйл чапты төшеп сылу эзенә,
Җитәм дип ай кебек пәри кызына.

Җиталмый ай чырайлы мисле хурга
(хур кызы кебеккә.— *Х. М.),*
Йөгергәндә барып төште чокырга.

Уянып белде шунда төш икәнен,
Сагыш уты йөрәгенә тигәнен.

**Шаһ кызы Гөлдерсеннең аны күрүе
һәм гашыйк булуы турында**

Чирәмдә шаһ, гүзәл чатыр эчендә,
Җиңүдән шат, масайган үз көченә.

Бар иде шаһ кызы Гөлдерсен атлы,
Тел әйләнмәс: гаҗәп сылу сыйфатлы.

Табылмас гөл бу Гөлдерсеннән артык,
Йөрәгендә гыйшык диңгездән артык.

Сәер итеп (күңел ачып.— *Х. М.)*
утырганда багында,
Ничә яраннары берлән янында.

Китерделәр чокырга дип батырны,
Күреп, кыз әмерен әйтте: бар да тынды.

Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,
Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли[1].

Сөһәйлне — былбыл, үзен гөл санады,
Сөйде, тагын күрергә булды аны.

Ләкин читлектә бит былбыл, ни чара!
Чәчәк тә ихтыярсыз шул, бичара.

Сөяр былбыл гөлен, гөл былбылын гел,
Күзен яшьле итәрме һич аның гөл?! —

Килә кыз күңеленә кинәт бу сүзләр,
Үтә көннәр — моңа чара ул эзләр...

Һәм эзләп шундый яхшы чара тапты:
Савытка салды икмәк, дару якты;

Аны сакчыга ул бирергә булды,
Сөһәйл ярын шулай күрергә булды.

Гөлдерсеннең чокырга төшеп, Сөһәйл белән сөйләшүе

Кичен сакчы янына кыз йөгерде,
Теләген әйтте аңа, нанны бирде.

Йокыга чумды ашап сакчы ашын,
Карады кыз чокырдагы кояшын.

---

[1] Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен Н. Коперник (1473—1543), Д. Бруно (1548—1600) кебек галимнәр ачкан дигән караш яшәп килә. Ләкин моның XIV йөздә язылган әдәби әсәргә килеп керүе галәм турындагы материалистик карашларның Шәрыкта тагын да иртәрәк таралуына өстәмә бер дәлил булып тора *(Х. М.)*.

Ни күрсен күзләре: туфракта шулчак
Ята аунап Сөһәйл, ал гөлгә охшап.

Елап бу хәленә аның гүзәл кыз,
Янына килде, куйды йөзенә йөз.

Сөһәйл башын күтәрде — күрде аны,
Әсирдән патшага әверелде җаны!

Өнендә төштәген күргәнгә ул шат,
Сынык күңеле сагыштан булды азат.

Алар куешты шунда йөзгә йөзне,
Алалмыйча юнәлтеп күзгә күзне.

Вә Гөлдерсен диде: «Сиңа фидамын!»
Сөһәйл аңа: «Ә мин — синең гидаең.

Әгәр син булмасаң — галәм караңгы
Үлем дә куркыталмас безне мәңге.

Җаным мең булса да — сиңа, сөйгән яр!»
Шушы дуслыктан артык җирдә ни бар?!

Сөһәйл белән Гөлдерсеннең чокырдан чыгып качулары

— Бу кич сиңа да миңа килде бер киз[1],—
Диде Сөһәйлгә Гөлдерсен, торып тиз,—

Чокырдан без чыгып ерак качаек,
Бу җирдә агламый, күңел ачаек.

Сөһәйл киде торып кызлар киемен,
Чокырдан карады — юк иде беркем.

Алар икәү аяк атлады юлга,
Тирәне алтын ай күмгәндә нурга.

Икәүләп китте гашыйклар еракка,
Эләкми юлдагы корган тозакка.

---

[1] *Киз — монда:* җайлы вакыт *(Н. А.).*

Юлыкты сахрага ике адашкан,—
Җәһәннәмдәй иде сахра кояштан.

Юк анда су һәм икмәк алларында,
Мәгәр булса да акча яннарында.

Очып килмәс иде кошлар бу җиргә,
Табылмас бер йотым аһ орган иргә.

Сусап егылды ач Гөлдерсен анда,
Бу чүлдә кем бирер ярдәм аларга?!

Сөһәйл азык, сусын эзләп юл алды:
Яры җан биргәнен күрми дә калды...

Сөһәйл шул буш далада калды ялгыз,
Бу хәлне күрде тик ай һәм дә йолдыз.

— Миңа кирәк,— диде,— яр берлә үлмәк,
Газаплар берлә калмак кемгә кирәк?! —

Шулай дип орды ул хәнҗәр үзенә:
Күренми калды киң галәм күзенә...

Сөһәйл аһ итте,— купты ком бураны,
Каралтып күк йөзен япты тузаны.

Алар өстен күмеп комнар өелде...
Бу хәлне бары тик бер сахра күрде.

Сөһәйл ирләрчә үлде, куркусыз — шәп!
Ни хәл итәр идең гәр калса йомшап?

Булыр микән сөю моннан да көчле,—
Ике корбан хәяттан бергә күчте...

Хатын — дустыр, газиз ир, син сөеп дәш,
Авыр чакларда бергә ул, чын иптәш.

Дусы бул син аның, күңел биреп сөй,
Акыл-киңәшләрен — җәүһәрләрен җый.

Килеп күңелгә Мәҗнүн, Ләйлә яды,
Бу сүзләрем кәгазь өстенә яуды.

Булыр бу сүзләрем тарихка ядкарь,
Аларның ялганы юк, бар да хаклар.

Минем язмамны укыр барлык илләр,
Сөһәйл вакыйгасен шуннан белерләр.

Бу Сәйфи Сараины, Тәңре, кызган,
Фани дөньяңны коткар син золымнан.

Җиде йөз туксан алты (1394 ел.— *Х. М.)* нәүрүз ае,
Төгәлләде моны Сәйфи Сараи.

* * *

Сагышлар диңгезенә кермә, Сәйфи,
Беренчелекне бер дә бирмә, Сәйфи.

* * *

Моны җитмеш беренчедә[1] алыстан[2]
Якын телгә күчерде Н. Арслан*.

Әман, тәкъсир! Каты күңелле булма,
Маһирлекне үзеңчә дәгъва кылма.

Кабул ит, мин — фәкыйрь алдыңда зари,
Ерактагы бабам Сәйфи Сараи.

---

* «Сәйф Сараиның моннан 580 еллар чамасы элек язылган бу поэмасын хәзерге заман татар теленә күчергәндә, мин аның ритмикасын, үз рифмаларын мөмкин кадәр сакларга тырыштым. Сүзен-сүзгә, юлын-юлга күчергән академик тәрҗемәгә караганда, болай күчерү борынгы шагыйрьләребезне җанлырак гәүдәләндерергә ярдәм итәр дип уйладым» *(Н. А.)*.

[1] Ягъни 1971 елда.

[2] *Алыстан* — ерактан, элеккегедән.

[Күзләрең]

(газәл)

Корыб кашы йәсен[1] кара күзләрең,
Атар керпек укын мәңа күзләрең.

Бер ук берлә Рөстәмне атдан йыкар,
Ничә атса, кылмас хата күзләрең.

Каракчы бәла кылса төз йазида[2],
Кылыр даим илдә бәла күзләрең.

Алыр сабыр җандан, күңелдән карар,
Кемә бакса бер киз[3] кыйа[4] күзләрең.

Күңелләрне баглаб кара зөлфенә[5],
Усанмасмы[6], җанлар ала күзләрең.

Ни йулдан бу Сәйф-е Сарайиның уш,
Түкеб канын эчәр кана[7] күзләрең.

Әгәр «Һай!» димәсәң, җәһанны хараб
Кылыр гамзә[8] белән йәнә күзләрең.

---

[1] *Йәсен* — җәясен.
[2] *Йазида* — далада.
[3] *Киз* — мәртәбә, тапкыр.
[4] *Кыйа* — кыеп ала торган; үткен.
[5] *Зөлфенә* — чәченә (чәч бөдрәсенә; чәч толымына).
[6] *Усанмасмы* — оялмасмы.
[7] *Кана* — туймас; комсыз.
[8] *Гамзә* — (күз) кысу; назлау.

ИДЕГӘЙ

(XV йөзнең урталары)

(өзек)

[Идегәйнең сугышта үлгәне*]

Кадыйрбирде[1] яшь солтан
Шундый фәрман чыгарды:
— Дәүран (гомер.— *Х. М.*)
сөргән көнемдә,
Идегәй исән булганда,
Идел-йорт миңа ил булмас,
Күргән көнем көй булмас,
Яки Идегәй, яки мин!
Ятмыйк, әйдә атланыйк!
Шулай диеп яшь солтан,
Оран салып, атланып,
Бар урдасын җыйдырды,
Хан урдасын торгызды,
Гаскәр әйдәп, кузгатып,
Идел аша кичерде.

Кадыйрбирде килгәнне
Идегәй дә сизенде,
Яндашларын янга алып,
Ул да купты урыныннан.
Тарлан бүзгә атланып,
Сугышырга китте ул.
Судай ташып гайрәте,
Чиктән ашып ачуы,
Атына камчы орды да
Яуга килеп җитте ул.
Кайда уклар аттырды,
Кайда мылтык аттырды,
Ул читеннән керде дә,
Бу читеннән чыкты да.
Куйга кергән бүредәй,
Гүя куйлар кырды ул.
Иртә булды, кич булды
Каты сугыш — эш булды.
Кояш тотылды, төн булды,
Ике гаскәр очрашып,
Ике Идел арасы
Икесенә тар булды.
Аттан тояк калмады,
Баштан колак калмады.

---

* Идегәй / Балалар өчен махсус әдәбиләштерүче *Әхмәт Исхак*.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 116—124 б.

[1] *Кадыйрбирде* — Туктамыш ханның улы.

Тапталып яткан үлекнең
Исәбе-саны булмады.
Сансыз татар, сансыз яу
Якалардан алышып,
Бер-берсенә ябышып,
Теш-тырнагын кулланып,
Бугазларын чәйнәшеп,
Ни булганын белмәде.
Кайсы башын коткарды,
Кайсы аттан тапталды,
Кич булганда шул булды —
Һәр ике як аз калды.
Идегәй шундый ир булды:
Үлем, үлем дигәндә,
Үлем килеп, йөзенә
Үле сулыш өргәндә
Чигенмәде Идегәй.
Үлем, үлем дигәндә,
Ун мең кеше яудагы
Үлемгә баш игәндә,—
Баш имәде Идегәй.
Кадыйрбирде солтанга
Әйтте шунда Киң Җанбай:
— Алтмыштагы Идегәй
Хәлсезләнеп калганда,
Ике гаскәр сугышып,
Кан заяга акканда,
Каршы килеп бергә-бер,
Бер тукмашсаң ни булыр?
Туктамыш буыны киселде
Хан булыр хан калмады.
Хан таягын кем алыр?
Хан тәхтенә кем менәр?
Бөтен йортны кем биләр?
Идегәй исән калганда,
Халкын җыеп алганда,
Иясез булып Идел йорт,
Идегәйгә калганда,
Туктамышның биләре
Би булыр көн тумастыр!
И Туктамыш биләре!
Идегәй артыннан кем
җитсә,
Җитеп, башын юк итсә,
Хан тәхтенә шул менәр!
Җәт булыйк без, биләрем!
Эзеннән басып барыйк без,
Ярты җаны чыкканда,
Ярты җаны калганда,
Калганын да алыйк без!

Барын шулай дигәчтән,
Унике түрә, алты би,
Эзе буйлап Идегәйнең
Куып килеп артыннан,
Күлгә җитеп туктады.
Камышлыкка җиткәчтән,
Тояк эзен ул биләр
Бик җентекләп карады;
Чыккан эзен тапса да,
Кергән эзен тапмады.
Унике түрә, алты би:
«Табалмадык үзен»,— дип,
Борылып китмәк булганда,
Барын морза туктатты:
— Һай, алданмыйк,
биләрем —
Юк бит киткән эзе дә.
Атын борып, камышка
Арты белән кергәндер.

Моннан ары бармыйк без.
Идегәй исән ир булса,
Җавап бирми булмастыр,
Җырлап сорап карыйк без.
Камышлыкка якынлап,
Барын болай җырлады:
— Идегәй өлкән ир иде,
Үзеннән бер яшь кечегә:
«Син торып тор, газизем,
Мин атыйммы?» — ди иде.
Үзеннән бер яшь олыга:
«Мин торыймчы, газизем,
Син атсаңчы»,— ди иде.

Барын шулай дигәчтән,
Камышлыктан Идегәй
Болай диеп кычкырды:
— Сездәй карачкылардан
Курка торган Идегәй юк!
Көтеп торыгыз, чыгармын,
Сөңгем канга тыгармын,
Яшен уйнатып кылычым,
Күк күкрәтеп сугармын!
Камышлыктан шулай дип,
Шам кылычын кулга алып
Килеп чыкты Идегәй.
Сул кулыннан кан агып,
Уң кулыннан көч алып,
Сугышып килде Идегәй.
Унике түрә, алты би
Тарафыннан камалды.
Алар атта, ул җәяү —
Унике сөңге, алты ук
Идегәйгә кадалды.

Әйтте шунда Идегәй:
— Куркытмагыз, үлемнән
Курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән,
Кача торган буем юк.
Илем өчен аһ орып,
Җирем өчен кайгырып,
Халкыма яхшылык теләдем.
Күкрәк тулып җилкенеп
Көрәшкәннәремне үз халкым
Аңлый микән, белалмыйм.
Аңламаса халыгым,
Аңлатмыйча үлалмыйм!

Ярып кереп сафларын,
Бар атларын яралап,
Шунда батыр Идегәй
Унике ирне үтерде.
Канлы ярасы ачылып,
Хәле тәмам беткәндә,
Барын морза килде дә
Кылыч белән бер чапты.
Башы тәннән аерылып,
Болай диде тәгәрәп:
— Барын, сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын,
Йортың-кураң калмасын!
Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Сөт урнына кан койдың,
Канымны коеп ни кылдың?
Казан, Кырым, Аждаркан[1]
Канымны даулап купканда
Ни буласын күрерсең!

---

[1] *Аждаркан* — Әстерхан *(Х. М.)*.

Идегәй башы шулай дип,
Кояшка таба борылды,
Болай диде шуннан соң:
— Алдагы олы көннәргә
Без барабыз, ул килмәс!
Шулай диеп, җан бирде.
Башын кисүче Барын
булды,
Башын китерүче Шарын
булды.

* * *

Идел йортка дау килде,
Яу өстенә яу килде.
Идегәй әйткән көн килде,
Чыңгыздан калган хан
тәхете
Кан тәхетенә әйләнде,
Казан, Кырым, Аждаркан
Башлы-башлы ил булды,—
Алтын Урда таралды.

Сайяди

БАБАХАН ДАСТАНЫ* («ТАҺИР-ЗӨҺРӘ»)

(өзекләр)

...Диде Сайяди: «Бер шәһәр бар ирде,
Шәһәренең атыны Татар дирде.

Бар ирде бу шәһәрнең падишаһы,
Тигеп ирде аңа фазлы Иляһы.

Дир ирделәр аның атын Бабахан,
Сыйфат кыйлсам, сыйфат кылгулы чәндан.

Ул ирде падишаһи ба дийанәт,
Аңа баккан иде җиде вилайәт.

Гадәләттә ирде мисле Нәүширван[1],
Мөселман ирде-йү ба нуры иман.

Аның әмредә җиде икълим ирде,
Аның хәсрәтен галәм йиийр ирде...

...Вәли кәмлеге: фәрзәнде йук ирде,
Кичә көндез гамь вә госса йиийр ирде.

Бу шаһ күңледә даим ирде — бу гамь,
Бу гамьдин күңле һәргиз, булмады җәм:

«Мән үлсәм, таҗ-у тәхетем игәсе,
Нә кем булгай аларның мәрхабәсе?..»

---

* Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап.— 172—173 б.

[1] Үзенең гаделлеге, укымышлылыгы белән дан алган Иран шаһы.

Тәрҗемәсе:

...Диде Сайяди: «Бер шәһәр бар иде,
Ул шәһәрнең исеме Татар иде.

Бар иде бу шәһәрнең патшасы,
Тигән иде аңа Алла рәхмәте.

Әйтер иделәр аның исмен Бабахан дип,
Сыйфатласам, аның сыйфаты булыр — күп.

Ул иде бик динле падишаһ,
Аңа буйсынган иде җиде ил.

Гаделлектә ул Нәүширван кебек иде,
Иман нуры ия мөселман иде ул.

Аның кул астында җиде икълим (кыйтга) иде,
Аның кайгысын бөтен галәм уртаклашыр иде.

...Кайгысы шул: баласы юк иде, (шуңа)
Кичә-көндез кайгы-хәсрәт җыяр иде.

Бу шаһ күңлендә бу гамь иде һәрчак,
Бу гамьдән күңле һич тә булмады азат:

«Мин үлсәм, таҗ вә тәхетем иясе,
Кем булыр аларның сәламләүчесе?..»

(Алланың рәхмәте белән патшаның кызы, ә вәзиренең улы туа. Аларга Зөһрә белән Таһир исеме куялар. Бу ике бала бергә уйнап үсәләр һәм бер-берсенә гашыйк булалар. Әмма Бабахан патша аларны аера. Егет белән кыз бер-берсен сөюләрен дәвам итәләр. Ахырда аларнын олуг мәхәббәте фаҗига белән тәгалләнә.— Х. М.)

Хәсән (Әсән) Кайгы

(XV йөз)

*Шигырьләр**

* * *

Гаделлекнең билгесе —
Белә тора бормаса.
Акыллының билгесе —
Үткән эшне кумаса.
Җаманнарның билгесе —
Җауга каршы тормаса.
Залимнәрнең билгесе —
Бай-бәднең малын урласа.
Наданнарның билгесе —
Белгәннең телен алмаса.
Артында калыр атак[1] юк,
Тередә даның булмаса.

* * *

«Атадан алтау тудым!» — дип,
Ашкынып җавап әйтмәгез.
«Алганым — асыл ыру!» — дип,
Көн чыгарып җатмагыз.
«Атамның малы күптер»,— дип,
Атны башка тартмагыз.
Исәнең дә — тереӊ дә
Бер булыгыз барыгыз,—
Ахирәткә барганда,
Хак кашында торганда,
Хозыр[2] булгай җарыгыз.

---

* Татар поэзиясе антологиясе.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 1 китап.— 131—133 б.

[1] *Атак* — ат, исем, дан. *Атаклы* сүзе дә шул сүздән ясалган.

[2] *Хозыр* — Хозыр пәйгамбәр.

Мөхәммәд Әмин

(XV йөзнең икенче яртысы — 1518)

ГЫЙКАБ*

Чыкты һиҗрәтдин йиде йөз илледә[2] —
Төшде галәмгә хәраблык зилзилә.
Үзе — аксак, гаклы — ахмак, фетнәдар
Золымыны изһар кылды һәр йирә.
Күп голамә вә мәшаихләр шәһид
Булдылар дине ислам нурилә.
Дарелислам фетнәсендин, бел гайан
Булды вәйран, акды йәшләр хәүфилә.
Нә җавап бирер Хода кашыда ул,
Сорса Алла шиддәт-ү гыйкаб илә.
Йа Илаһи, әйлә ул бәндәңне сән
Ахирәтдә залим вә җаһил илә.

Тәрҗемәсе:

Чыкты һиҗри белән җиде йөз илледә —
Төште галәмгә җир тетрәү кебек хараблык.
Үзе — аксак, гакылы — ахмак, фетнә иясе
Золымын таратты һәр җиргә.

---

* Татар әдәбияты тарихы... I том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.— 291—292 б.

[1] *Гыйкаб* — җәза, үч.

[2] Һиҗридәге 750 ел хәзерге ел исәбе белән 1350 елга туры килә. Чынлыкта исә Аксак Тимернең Урта Иделгә, шул исәптән Болгарга да һөҗүме 1391 елга карый.

Күп галимнәр һәм шәйхләр шәһид
Булдылар ислам дине юлында.
(Аның) фетнәсеннән ислам йорты, ачык бел,
Туздырылды, хәвефтән күз яшьләре акты.
Ни җавап бирер ул Хода каршында,—
(Әгәр дә) Алла каты җәзага тартса.
Йа Илаһым, ул бәндәңне син теге дөньяда
Ит залимнәр һәм җаһилләр (томаналар) рәтендә.

Колшәриф

(XV йөз азагы — 1552)

[«...Гафил торма...»*]

Башың күтәр гафләтдин[1], гафил торма[2], «Һу» тигел[3],
Күзең ачкыл уйкудин, гафил торма, «Һу» тигел.

Һу-һу тию һу кошы[4], акар күзендин яше,
Көеб эче һәм тышы, гафил торма, «Һу» тигел.

Гашыйклары очарлар, гарше шахига[5] кунарлар,
Һу диеб дидар кыларлар[6], гафил торма, «Һу» тигел.

Йите икълим гизәрләр, андин күккә ашарлар,
Бер кадәмдә[7] йитәрләр, гафил торма, «Һу» тигел.

Һу бәхрегә[8] чумарлар, гауваз[9] булыб батарлар,
Һу дөрләрен тирәрләр[10], гафил йөрмә, «Һу» тигел.

---

* Бакырган китабы.— Казан: Коковин тәбыгханәсе, 1878.— 28, 29 б.

[1] *Гафләт* — ваемсызлык.

[2] *Гафил торма* — сизми калма.

[3] *«Һу» тигел* — «Аллаһу» дип әйт.

[4] *Һу кошы* — оҗмах кошы.

[5] *Гарше шахига* — күк агачына.

[6] *Дидар кыларлар* — очрашу көтәрләр.

[7] *Кадәм* — адым.

[8] *Бәхрегә* — диңгезенә.

[9] *Гауваз* — диңгезгә чумучы; водолаз.

[10] *Дөрләрен тирәрләр* — энҗеләрен җыярлар.

Дәргяһ(е) капуг[1] ачыкдыр, рәхмәтләре анықдыр,
Күзең ачыб бакыб күр, гафил йөрмә, «Һу» тигел.

И Колшәриф, тынмагыл, төнләр ятыб оймагыл[2],
Хак зикрене[3] куймагыл, гафил йөрмә, «Һу» тигел.

---

[1] *Дәргяһ(е) капуг — монда:* оҗмах капкасын.
[2] *Оймагыл* — йоклама.
[3] *Хак зикрене* — Алланы искә алу.

Шәрифи

(XVI йөзнең беренче яртысы)

«ЗАФӘРНАМӘИ ВИЛАЯТИ КАЗАН»* (1550) әсәреннән

[Казанны мактау]

Гаҗәйеб бер җайы гыйшрәтдер[1] җиһанда бу Казан шәһре,
Моның тик булмагай галәмдә, борадәр[2], әл-әман[3] шәһре[4].

Казан тик шәһре мәгъмури (төзек.— *Х. М.)* табылмас
дөньяда һәргиз[5],
Казандин аш эчәдерләр ничаклы бу җиһан шәһре.

Бу бер мөлке ирер[6] калмыш әбаэган җәдде ханлардин[7],
Ирер бу йир һәмишә (һәрчак.— *Х. М.)* дөньяда хан бине
хан[8] шәһре.

---

* «Зафәрнамәи вилаяти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңү язмасы») түбәндәге басмаларда дөнья күрде: Идел.— 1995.— № 1.— 12—16 б.; *Кол Шәриф.* И күңел, бу дөньядыр...— Казан: Тат. кит. нәшр., 1997.—76—93 б.; Гасырлар авазы (Эхо веков.— 1995.— № 1 (май).— С. 83—92 (биредә татарча текстның фотокүчермәсе һәм русчага тәрҗемәсе бар).

[1] *Җайы гыйшрәт* — хозур урын; күңелле (рәхәт) җир.

[2] *Борадәр* — туган, кардәш.

[3] *Әл-әман* — иминлек; игелек.

[4] Бу юлны «Моның тик булмагай галәмдә пердарел-әман шәһре (бай һәм имин шәһәр.— *Х. М.)*» дип тә укырга мөмкин.

[5] *Һәргиз* — һич тә; һичкайчан да.

[6] *Мөлке ирер* — биләмәсе (мирасы) булыр.

[7] *Әбаэган җәдде ханлардин* — ханнар нәселеннән.

[8] *Хан бине хан* — «ханнар нәселе» мәгънәсендә.

Йирен-йортын сатып бирмәс атасының ясакыны[1],
Ничен (ни өчен? —*Х. М.*) килгән ушул (шушы.—*Х. М.*)
мәлгунь,— имәсдер[2] бу Ибан[3] шәһре?!

Шәрифи, китмә бу йирдин газат өмиде гәр булса[4],
Бу көндин соң дигәйләр кем,— будыр сахибе Казан[5]
шәһре.

[1] *Ясакыны* — бурычын; салымын.
[2] *Имәсдер* — түгелдер.
[3] Биредә Явыз Иван (Ибан) күздә тотыла.
[4] *Газат өмиде гәр булса* — изге сугышка ышанычың булса.
[5] *Сахибе Казан* — Казан хуҗасы.

Өмми Кәмал
(XIV йөз азагы — 1475)

[«Акар күзем яше...»*]

Иляһи, пәрдәи күтәр күземдән,
Ки фирак идәм[1] дөнеме[2] көндеземдән...

...Иляһи, мөбтәля калдым[3], әлем дот[4],
Ки бәңа һич мәдәд юк кәнд-үземдән[5].

Ничә кем гаҗиз гайб-йазыгыма,
Бакарәм көлл, бизарәм бән үземдән[6].

Янар эчем фирак, хәсрәт илә,
Акар күзем яше «аһ» сүземдән.

Гомер кичде тәләфдә,— кани хасыйл[7]
Бу кыш, яз, йаемдән, көземдән?..

...Чө(н) тугры юл варымызым күрәрләр[8],
Бу халык оемаз[9] бәңа, качар төземдән.

---

* Китабе Өмми Кәмал.— Казан, 1897.— 73, 78—79 б.
1 *Фирак идәм* — аерам.
2 *Дөнеме* — төнемне.
3 *Мөбтәля калдым* — авыр хәлдә калдым.
4 *Әлем дот* — кулымны тот; ярдәм ит.
5 «Миңа һич ярдәм юк үз-үземнән».
6 «Тәмам карарсыз (ихтыярсыз), йөдәгән мин үземнән».
7 «Гомер юкка узды,— нәрсә таптым?»
8 «...Тугры юлдан барганымны күрерләр».
9 *Оемаз — монда:* исе китмәс, иярмәс.

Яранлар илеген чук күрмешбез,
Вәли һич күрмәде бонлар безeмдән[1].

Әгәр бән дидегеме дота белсәм,
Дәхиләр[2] хат ала иде һәр сүземдән.

Сүзендән аеругы йийга бел иде,
Кәмал Өмми кичә белсә үземдән.

Ходавәндә, бу илдә вә ул илдә,
Аерма бән колый калавызымдан[3].

[«...Кунды, кичде»]

Бу йир үзрә[4] ничә хан кунды, кичде[5],
Ки хан үзрә[6] ничә хан кунды, кичде.

Бу дөнья — бер көһел кар(е)бансарайдыр[7],
Ки ничә дөрле карбан кунды, кичде.

Бу өвдә[8] чөн дәхи без бер кунагыз[9],
Ки монда ничә миһман[10] кунды, кичде.

Дүкәли[11] хуҗа, кол, бай, юхсыл[12],
Гидай[13], шаһ йексан[14] кунды, кичде.

---

[1] «Без (үзебез) дуслар кулын (ярдәмен) күп күрдек,
Әмма алар бездән һич (игелек) күрмәде».
[2] *Дәхиләр* — үзгәләр.
[3] «Аерма мин (бу) колыңны юл күрсәтүчемнән».
[4] *Йир үзрә* — җир өстендә (йөзендә).
[5] *Кичде* — «теге дөньяга китте» мәгънәсендә.
[6] *Хан үзрә* — мәмләкәткә.
[7] «Бу дөнья — бер иске кәрвансарайдыр» (кунак йорты).
[8] *Өвдә* — өйдә.
[9] *Кунагыз* — кунакбыз; кунабыз.
[10] *Миһман* — кунак.
[11] *Дүкәли* — никадәр.
[12] *Юхсыл* — юксыл.
[13] *Гидай* — фәкыйрь, ярлы.
[14] *Йексан*— бердәй; бер төрле рәвештә.

Камусы аглайу[1] килде вә күчде,
Әйт: канкысы хәндан[2] кунды, кичде?!

И ничә натәван илә тәвана[3],
Ничә дана[4] вә надан кунды, кичде.

Бу җөмлә халкы[5] бер-бер нәүбәт илә
Он итде бу дегермән, кунды, кичде.

Бу базар эчрә һәрбере мәтагын[6]
Сатубән[7] корды дөкян[8], кунды, кичде.

Бу зәһрә һич бере булмады тиръяк[9],
Бу шәһрә[10] ничә агъйан[11] кунды, кичде...

...Җиһани хөкменә мәхкүм идәнләр[12],
Әҗәл хөкменә фәрман, кунды, кичде...

...Кани ул Адәм, Хаува, ки әүвәл
Бу мөлкә килде гөръян[13], кунды, кичде.

Кани Нух, Хәлил, Исхак, Йагъкуб,
Йа Йосыф-маһе Кәнган?! — Кунды, кичде...

...Кани Идрис йа Гыйса ибне Мәрьям,
Дәхи Муса ибне Гыймран[14]?! — Кунды, кичде...

---

[1] *Камусы аглайу* — һәммәсе елап.
[2] «Әйт: кайсысы шат булып...»
[3] «И ничә көчсез белән көчле (куәт иясе)».
[4] *Дана* — белемле, белем иясе.
[5] *Җөмлә халкы* — барлык халыкны.
[6] *Мәтагын* — әйберен, малын.
[7] *Сатубән* — сатып; сатар өчен.
[8] *Дөкян* — кибет.
[9] «Бу агуга һич булмады аны бетерә торган дәва» (противоядие).
[10] *Шәһрә* — шәһәргә.
[11] *Агъйан* — бай; затлы.
[12] *Мәхкүм идәнләр* — хөкем ителгәннәр.
[13] «Бу патшалыкка килде ялангач...»
[14] Биредә дини-мифологик затлар санала.

...Кани Искәндәр, Кәсри вә Кайсар[1]?!
Ничә фәгъфур[2], хакан[3] кунды, кичде...

...Бу таҗ-тәхтә һәргиз горрә улмаң[4],—
Ки ничә шаһ, солтан кунды, кичде...

...Бу мәйдан(н)ы тотмады бере һич,
У(л) җөмлә пәһлеванан[5] кунды, кичде...

...Кәмал Өмми җәһанә горрә улма,
Чө(н) сәнең бики чәндан кунды, кичде...[6]

---

[1] «Кайда Александр (Македонский), Хөсрәү вә Цезарь?!»
[2] *Фәгъфур* — Кытай императоры.
[3] *Хакан* — төрки, монгол халыкларының императоры; каган.
[4] «Бу таҗ-тәхеткә һич алданма (кәпрәймә)».
[5] «Ул барлык пәһлеваннардан...»
[6] «Өмми Кәмал җиһанга алданма,
Чөнки (ул) синең кебек ничәләрдән калды...»

Мөхәммәдьяр

(1497—XVI йөзнең урталары)

ТӨХФӘИ МӘРДАН[1] (1540)

*(өзекләр)**

[Күңел белән сөйләшү]

Беркөн утырып үз катымда на хуш[2]
Эчеп гамь бадәсен кылыб нуша-нуш[3].

Күңлем уты янмак илә изтыйраб[4],
Кыйлды мән бичараны әсри[5] хәраб.

«Нәчә үртәрсән,— дидем,— сән, и күңел,
Куй мәне үз халемә, мәндин түңел[6]».

Диде күңлем: «Куймазам та мин сәне,
Сәңа иркен яратыбдыр Хак мәне.

Торыб утадин[7] нәсыйхәт кыйлырам,
Гакыйль ир, тыңла, нәсыйхәт кыйлырам:

**Мөхәммәдьяр.* Нуры содур / Кереш сүз, текстлар, искәрмәләрне һәм сүзлекне әзерләүче *Шакир Абилов.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1997.— 336 б.

[1] *Төхфәи мәрдан* — егетләр бүләге.

[2] *На хуш (нәхуш)* — күңелсез.

[3] «Эчеп кайгы эчемлеген бер-бер артлы».

[4] *Изтыйраб* — борчылу.

[5] *Әсри* — күп.

[6] *Түңел (тун)* — баш тарт; кире кит.

[7] *Утадин* — дәвадин.

Ярмөхәммәд, сәңа бирмеш хак теле,—
Бу — фәләк багстанының былбылы[1].

Зәхмәт тәкый нәчә кыйтга сүзләсәң[2],
Ирм(е) улырсән сән гарзы-хален гизләсәң?[3]

Нәчәләр сүзләб бу җиһандин кәчтеләр,
Сүзләмәкдин парча дөрләр[4] сачтеләр.

Нәчәләр сүзләмәен сүз гөлене кистеләр,
Сүзләгәнне күрә белмәй, тән тишеб, кан эчтеләр.

Гакыйль ирсәң, куй җиһанда берничә сүз сән дигяр[5],
Укыганнар дога кыйлгай кичмешенчә рузгяр[6]».

Дидем: «И күңлем, иҗазәт[7] бир мәңа,
Мән тәкый гарзым итәем (һәм) сәңа[8]:

Мән ирермән бу шәһәрдә бер фәкыйрь,
Ил күзендә гаҗиз-у хур, вә хәкыйрь[9]...

...Бер гаҗиб бу кем шәһәрнең эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг.

Куй мәне, үз халем илә булаен[10],—
Мөддәгыйлар сүзедин кортылаен»[11].

---

[1] «Бу — язмыш бакчасының былбылы».
[2] «Кыен булырмы тагын берничә өзек сөйләсәң?»
[3] «Ир булырсыңмы үтенеч-хәлеңне яшерсәң?»
[4] *Дөрләр* — энҗеләр.
[5] *Дигяр* — янә; тагын да.
[6] *Рузгяр* — (бер) вакыт.
[7] *Иҗазәт* — рөхсәт.
[8] «Мин дә үтенечемне (хәлемне) әйтәм сиңа».
[9] *Хәкыйрь* — кимсетелгән.
[10] *Булаен (булаем)* — буламын.
[11] «Дәгъвачылар (гайбәтчеләр) сүзеннән котылаем».

Диде: «И ахмак, нәсыйхәт кыйл кабул,
Бу табигать хаккына кыйлма фозул[1].

Сүзләгел сан берничә шәкәр сачыб,
Бу табигать милкенең агзын ачыб.

Бу эшидә йөрәкеңне даглагыл,
Мәрданәләр дик[2] билеңне баглагыл...»

[Үз хале турында]

Җан кошыга мескин адәмдер кафәс[3],
Гаклыңа килгел, фәкыйрь, сән бер нәфәс[4].

Ятма, торгыл, үтте, күргел, кафилә[5],
Бирмәгәйләр хисса һәргиз гафилә[6].

Нәфсең атыны сыйлама сән, и йар,
Ул екмасын (сәне) менәрдә, зинһар...

...Зәррәчә[7] олуг күрсәң сән үзең,
Кәззаб[8] ирүрсән,— җөмлә ялгандыр сүзең[9]...

...Басмагыл юлга (кем) рәһбәрсез кадәм[10],
Башсыз юлы, үзе булгай кәл-гадәм[11].

Рәхмәтең дәрьясыдин биргел өлеш,
Тугры юлга биргел (һәм үзең) бир хуш йөреш...

---

1 *Кыйлма фозул* — өстенлек кыйлма; (үз-үзеңне) өстен куйма.
2 *Мәрданәләр дик* — егетләр (ир-атлар) кебек.
3 *Кафәс* — читлек.
4 *Нәфәс* — мизгел; сулыш.
5 *Кафилә* — кәрван.
6 «Бирмәсләр өлеш һич тә гамьсезләргә».
7 *Зәррәчә* — бик вак кисәкләр санынча.
8 *Кәззаб* — бик ялганчы (алдакчы).
9 «...барлык сүзең ялгандыр».
10 «Юлга җитәкчесез аяк басма».
11 «...үзе бөтенләй юкка чыгар».

[Үгет-нәсыйхәт]

Мәнмәнлек кыйлыб, мәнмәнлек сатмаңыз,
Онга — кибәк, серкәгә су катмаңыз...

...Һәр кешегә изге кыйлгыл, дийанәт[1],
Сәңа кыйлмасын ул һәргиз хыянәт.

Яманлык кыйлгучыга кыйлма яман,
Яхшылык кыйл аңа, (ә)гәр булаң, һәр заман.

Кеше сәндин күңел өзсә, сән өзмәгел,
Яхшылыкны салып, яманлык төзмәгел...

...Йийдер үтмәк кешегә, и никү зат[2],
Бакый[3] калыр бу җиһанда яхшы ат.

Бакма күз ул сарига,— бакмак кәрәкмәс,
Булмачы сүзгә колак тотмак кәрәкмәс[4].

Тел вә күңлең игри[5] кыйлма кешегә,
Йөзең бер кыйл кәрәк иркәк, тешигә...[6]

...Гыйззәт илә хурлык[ны] күрмәгәй сән,
Сөфрә[7] башындин кешене сөрмәгәй сән.

Хөрмәт иткел үзеңдин яшь, олугны,
Гыйззәт иткел кечек берлә олугны.

Олугны олугдыр тиб гыйззәт иткел,
Кечеккә рәхим итеб, хөрмәт иткел.

---

[1] *Дийанәт* — динле (кеше).
[2] «Кешегә икмәк ашат, и изге зат».
[3] *Бакый* — мәңге.
[4] «Карарга ярамаган якка күзеңне бакма,
Буш сүзгә колагыңны тотма».
[5] *Игри* — ялган; икейөзле.
[6] «Ир-атка һәм хатын-кызга бер төрле бак».
[7] *Сөфрә* — табын.

Катыглык килсә нагяһ[1], сабыр кыйлгыл,
Сабыр тәгамыдин[2] сән ләззәт алгыл.

Әгәр килсә эвеңә мәрде миһман[3],
Тәңре биргән нигъмәтеңне кыйл арзан.

Тәкәллеф кыйлма[4], (сәңа) миһман килсә,
Эвеңдә булганын килтер, гәр булса.

Яхшылык берлә сән мәрд[5] күңлене ал,
Нәсыйхәт яхшысы будыр — колак сал.

Ходa йарың булгай син(ең) һәр ду галәм[6],
Нәсыйхәт сал колакка, ибне адәм[7].

Нәсыйхәт тыңлаган булыр мәрдивар[8],
Нәсыйхәт (бер)лә эш кылмаган булыр хар[9].

Хак бизәр нәсыйхәт тыңламагандин,
Биреб үгет һәр заман алмагандин.

Бел, нәсыйхәт тыңламаганның эши:
Иксүк[10] улмас кәчә-көндез тәшвиши.

Бел, соңыны бакмаен эш иткәннәр[11],—
Наданлыкдин үз башына йиткәннәр.

---

[1] *Нагяһ* — кинәт; берчак.
[2] *Тәгамыдин* — азыгыннан.
[3] «Әгәр дә өеңә кунак килсә».
[4] *Тәкәллеф кыйлма* — боргаланып торма, кыланып торма.
[5] *Мәрд* — кеше; ир-ат.
[6] *Ду галәм* — ике дөнья.
[7] *Ибне адәм* — адәм угылы.
[8] *Мәрдивар* — гайрәт иясе; чын кеше.
[9] *Булыр хар* — түбән булыр.
[10] *Иксүк* — ким; аз.
[11] «Бел, соңына карамыйча эш иткәннәр».

НУРЫ СОДУР[1] (1542)

(өзекләр)

[«Гадел кыйлмак сүзләре...»]

Гадел бабыны бу дәм бәян итеп,
Шаһи галәм, гадел сүзен йад итеп[2],

Әйтәем гадел фәзылыны рәван[3],
Тыңлаңыз аны, и пир-у җәван[4].

Кем җиһанда барча тәгъәтдин зийад[5]
Гадел ирер, кыйл бу сүзгә игътикад[6].

Иртә-кәчә һәркем ул кыйлса аны,
Әсигъ итәр[7] үзенгә ул кыйлганы.

Үзгәләргә тикмәс[8] андин һич өлеш,
Нәчә кем кыйлса гыйбадәт ул үкеш[9].

Гадел кыйлса падишаһ бер дәм[10], ишет,
Ил-улус гадел берлә табса мәшият[11],

Барчага өлеш тикәр[12] андин тәмам,
Кыйлыр аның илә рәхәт хасс-у гам[13].

---

[1] *Нуры содур* — күңелләр (күкрәкләр) нуры.
[2] «Гаделлек булеген хәзер җиткереп,
Галәм шаһы, гаделлек сүзен искә төшереп».
[3] «Әйтим гаделлекнең өстенлеген биредә (кыскача)».
[4] *Пир-у җәван* — карт һәм яшьләр.
[5] *Тәгъәтдин зийад* — барлык тиешле гамәлләрдән артык.
[6] *Игътикад* — ышану.
[7] *Әсигъ итәр* — файда итәр.
[8] *Үзгәләргә тикмәс* — башкаларга тимәс (җитмәс).
[9] *Үкеш* — күп.
[10] *Бер дәм* — бер мизгел.
[11] «Ил-мәмләкәт гаделлек белән тапса ирек».
[12] *Тикәр (тияр)* — җитәр.
[13] *Хасс-у гам* — барлык халык.

Гадел берлә ил камуг булыр әман[1],
Калмаз илдә фетнә вә золым һаман...

...Бер сәгать гадел кыйлмак яхшырак,
Кем гыйбадәт алтмыш елдин озакрак.

Гадел берлә бу җиһан мәгъмур ирер[2],
Гадел берлә уш җиһан пөр[3] нур ирер...

Гадел берлә ил гыймарәт булыр уш,
Барча эшләр табар аның берлә хуш.

Гадел булыр барча эш башы, белең,
Гадел берлә даимән бәс эш кыйлың[4]...

...Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым берлә екылыр улус йөдәб.

Көфер вә кяфир нәфсенә кыйлыр зийан,
Золым берлә булыр ил хале яман.

[Хәммал[5] хикайәте]

...Кем сәха[6] ирер иргә олуг һөнәр,
Ул һөнәр ирер кешегә таҗи сәр[7]...

...Җиһан эчендәге гаибләр камуг[8]
Бер кешедә булса барча, и олуг,

---

[1] «Гаделлек белән бөтен ил булыр имин».
[2] *Мәгъмур ирер* — төзек булыр.
[3] *Пөр* — тулы.
[4] «Гаделлек белән һәрчак җитәрлек эш кыйл».
[5] *Хәммал* — йөкче, йөк ташучы.
[6] *Сәха* — юмартлык.
[7] *Таҗи сәр* — баштагы таҗ.
[8] *Камуг* — һәммәсе, барысы.

Барча гаибләрне сәхавәт[1] йабар,
Һәркем иксә, даим гыйвазын[2] табар.

Хак зийадә кыйлыр[3] аның малыны,
Ахирәтдә хуш кыйлыр әхвалене.

* * *

Бер хикайәт кыйлаем уш, тыңлаңыз,
Кем сәхи васфыны[4] хуш аңлаңыз.

Ул борынгы рузгярда[5], и йигет,
Бер хәммал бар ирде, хуш ишет.

Бакты ирде үзенең әсрү[6] фәкыйрь
Һич нәмәрсәсе юк ирде, и әмир.

Кыяга барып, килтерер ирде утын,
Аркасы берлә күтәреп тигмә көн[7].

Сатар ирде ике данкигә[8] аны,
Ул тәсәддык кыйлыр ирде берене[9].

Янә бер данкисен үзе алыб,
Хәрҗ итә[10] ирде эвенгә[11] барып.

Беркөн утын сатып, үзе нагяһан[12],
Барыр ирде, юлда күрде бер җәван[13]:

---

[1] *Сәхавәт (сәха)* — юмартлык.
[2] *Гыйваз* — бүләк; уңыш; нәтиҗә.
[3] *Зийадә кыйлыр* — күп итәр.
[4] *Сәхи васфыны* — юмартның (юмарт кешенең) сыйфатларын.
[5] *Рузгярда* — көннәрдә, заманда.
[6] *Әсрү* — бик.
[7] *Тигмә көн* — һәр көн.
[8] *Данки* — данкә, тәңкә.
[9] «Ул хәергә (садакага) бирер иде берен».
[10] *Хәрҗ итә* — тота, чыгымга тота.
[11] *Эвенгә* — өенә.
[12] *Нагяһан* — көтмәгәндә; берчак.
[13] *Җәван* — яшь егет.

Бер кеше аны тотып катыйг орыр,
Ул йигет мескен оялып тик торыр.

Хәммал әйтер аңа: «Кем бу, ни торыр,
Нә сәбәбдин сәне бу кеше орыр?»

Ул йигет әйде: «Кем, әйтәем сәңа,
Ике данки бурычлыг ирермән аңа».

Ишетеп хәммал бу йигет сүзене,
Алды ул бурычлыг кулындин үзене.

Саткан утын бәһасын бирде аңа,
Углы, кызы калды ач барча янә.

Иртәсе хәммал мәгәр тагга барып,
Утын алып килтерер иркән[1] арып.

Бер кешене күрде кем балык сатар,
Һич кеше алмаз балыкын, гаиб итәр.

Мәсхәрә тотып аны тигмә бере,
«Ул изелмеш балыкың килтер бире!» —

Тию аңа, көлешер ирде камуг
Ул базар эчендәге кечек һәм олуг.

Ул балыкчы чакырди ирсә рәван[2],
Килде ул хәммал катынга ул заман.

Әйде: «И утынчы, тыңлагыл сүзем,
Бу балык берлә карарды[3] бу йөзем.

Сатсам аны — һич кеше алгусы[4] юк,
Имди мәндин алгыл аны уш сән ук.

Балык алып, биргел сән мәңа утын,
Өйгә барып ашагыл аны бөтен.

---

[1] *Иркән* — бик.
[2] «Ул балыкчы бара иде үз көенә».
[3] *Карарды* — каралды.
[4] *Алгусы* — алучы.

Сәндин үзгә һич кеше алмаз аны,
Лотф итеб андин хәлас иткел[1] мәне».

Кыйлды хәммал аның сүзене кабул,
Утынын биреп, балыкны алды ул.

Ул балыкчы сәвенеп барыр рәван,
Имди ишеткел хикайәт, и җәван.

Килде хәммал эвенгә әсрү[2] арып,
Әйде кем ошбу балык карнын ярып:

«Кыйлаем угланларым өчен тәгам.
Күргел имди Тәңренең лотфын[3] тәмам».

Ярды ирсә ул балыкның карныни,
Бер данә[4] чыкты, (ул) булды гани[5]...

...Йөз мең алтын ирде аның кыйммәте,
Ятмыш ирде — купты хәммал дәүләте.

Аз нәмәрсә берлә кыйлды ул сәха,
Хак гыйваз бирде аңа үкеш гата[6].

[«Сыйдык[7] сүзләре...»]

И җиһан гашыйкларының садыйкы[8],
И заман садыйкларының гашыйкы!..

Гыйшык берлә сыйдык сүзен тыңлаңыз,
Тәкърир итәем[9] аны — хуш аңлаңыз.

---

[1] *Хәлас иткел* — коткар.
[2] *Әсрү* — бик; нык.
[3] *Лотфын* — яхшылыгын, игелеген.
[4] *Бер данә* — бер кисәк энҗе.
[5] *Гани* — бай.
[6] «Ходай Тәгалә кайтарды аңа күп бүләк».
[7] *Сыйдык* — дөреслек, чынлык.
[8] *Садыйкы* — (тугрылыклы) дусты.
[9] *Тәкърир итәем* — аңлатып бирәмен.

Сыйдык бабын кыйлаем сезгә бәян,
Ул бәян берлә аны күрең гаян[1].

Төрки теленчә сыйдык мәгънәсен белең—
Күнилек[2] берлә һәмишә[3] эш кыйлың.

Сыйддикъ, ягъни күни сүзләмәк булыр,
Күни сүзләгән кеше дәүләт булыр.

Каю кеше теләсә дәүләт тәмам,
Күни булсын сүзләре аның мөдам[4].

Күнилек берлә табар дәүләт камуг[5],
Күни сүз берлә булыр кечек олуг.

Кем олуглык теләсә даим үзе,
Барча берлә хуш, күни булсын сүзе.

Күниләрне барча ил улусы сәвәр[6],
Күни сүзләгән кешене хак үгәр[7].

Адәм углының вөҗүде эчрә[8] бел,
Бер тылсым бер әл-гаҗәб[9] ирер бу тел.

Кем җиһан эчендә, и дин олугы,
Гәнҗ, дәүләт, рәнҗ, михнәт — камугы[10].

Ул тылсым ачкычы берлә әчелер,
Ни ки телдин чыкты — ул башка килер.

Тел күни булса, күнүлүр әл-азак[11],
Күни булыр барчасы — бу күз, колак.

---

[1] *Гаян* — ачык.
[2] *Күнилек* — дөреслек.
[3] *Һәмишә* — һәрчак.
[4] *Мөдам* — һәрчак; дәвамлы рәвештә.
[5] *Камуг* — барча, һәммә.
[6] *Сәвәр* — сөяр.
[7] *Үгәр* — яратыр.
[8] *Вөҗүде эчрә* — яшәешендә.
[9] *Әл-гаҗәб* — гаҗәеп.
[10] «Хәзинә, дәүләт, рәнеҗ, михнәт — һәммәсе».
[11] «Тел дөрес булса, дөрестер кул-аяк».

Игри булса тел — камугы игелер[1],
Ул сәбәбдин абруе[2] түгелер...

...Игри булсаң, сән төзәлмәсдин, и тел,
Барчамыз игри булырмыз,— аны бел.

Бәс, ни килсә башка, бел, телдин килер,
Адәмигә нә ки кыйлса, тел кыйлыр.

Кеше ялган сүз белә табмас нәҗат[3],
Тугры сүз берлә табар даим хәят[4]...

...Һәр ки тотты телне — котылды ул,
Телене тотмаган уш тотылды ул...

[«Гафу кыйлмак сүзләре...»]

Гафу бостанының[5] и тазә[6] гөле,
Каршыңызда сайрар уш тел былбылы.

Гафу бабын[7] имди хуш раушан итәр[8],
Сүзләре күңелләрне гөлшан[9] итәр.

Гафу кыйлмак берлә булыр ир газиз,
Гафу кыйл барчадин, и гакълы тәмиз[10]...

...Гафу кыйлмак Тәңре бойрыкы ирер,
Бойрыкын тотканга ул җәннәт бирер...

---

[1] «Ялган булса тел — һәммәсе ялгышыр».
[2] *Абруе* — йөз суы, дәрәҗәсе.
[3] *Нәҗат* — котылу.
[4] *Хәят* — тереклек, яшәеш.
[5] *Бостан* — бакча.
[6] *Тазә* — яшь.
[7] *Бабын* — бүлеген.
[8] *Раушан итәр* — нурлы итәр.
[9] *Гөлшан* — күңелле, куанычлы; гөл бакчасы (кебек).
[10] *Тәмиз* — пакь; җитеш.

Мәүла Колый

(XVII йөзнең икенче яртысы)

ХИКМӘТЛӘР*

[«Нәчә кусаң, үткән гомер янә булмас»]

...Бу җиһандин олуг китап укың сабак,
Сабак укып гакыйл ирсәң гыйбрәтә бак,
Тереклекдә Хак юлында әйлә яраг[1],—
Терек икән Хак юлыны табкым микән[2]?

Бу тереклек кулдин китәр, кайра[3] килмәс,
Гомрең заигъ[4] кичәр, сәңа әсигъ[5] кыйлмас.
Нәчә кусаң, үткән гомер янә булмас,—
Тереклекдә Хак зикрендә торгым микән?

Кяһиллекдә[6] гафил ятып[7] гомер кичәр,
Җандин җөда булып[8] бу тән гүргә күчәр.
Гүр эчерә терек булып күзен ачар,—
Минем хәлем ул көн ничек булыр микән?..

---

*Мәүла Колый хикмәтләре / Төз. *Камил Дәүләтшин*.— Уфа, 1991.— 41 б.

Аерым хикмәтләр бераз кыскартып бирелә.

[1] *Яраг* — кирәк-ярак. *Монда:* рухи азык.

[2] *Табкым микән* — табармын микән.

[3] *Кайра* — кабат, янә.

[4] *Заигъ* — әрәм, буш.

[5] *Әсигъ* — файда.

[6] *Кяһиллекдә* — ялкаулыкта.

[7] *Гафил ятып* — пошмыйча ятып; сизмичә ятып.

[8] *Җөда булып* — аерылып.

...Бу мескин, Мәүла Колый, төн-көн ятмай,
Хак коллыгын кыйлсаңчы (сән) хикмәт айтмәй,
Кол Сөләйман[1] хикмәтенә әдәп тотмай,—
Хикмәт әйтер нәчә хәлең булыр микән?

[Ата-ана турында]

Ата-ана тугырды безне, мөхиб[2] дустлар,
Хөрмәтләрен яхшы кыйлып йөрмәк кәрәк.
Аh-ваh тәйү күңелләре мөшкел булса,—
Хәлләрене тәгъзим берлә[3] сормак кирәк...

...Һәр угыл-кыз ата-ананы белер булса,
Гыйззәт, хөрмәт берлә хезмәт кыйлыр ирсә,
Күңеленә хушнуд кыйлып[4], дога кыйлса,
Ул угыл-кыз хак дустдыр, белмәк кирәк.

Терек икән, ата-ананы газиз белең,
Хәйатлыкда[5] күңелләрен хушнуд кыйлың.
Үлеп китсә, мең ел остай кайд[6] булгың,—
Тереклекдә идгү дога алмак кәрәк.

Нәгяh[7] әҗәл йитеп килсә башларына,
Мәшгуль улыр җан бирмәкнең эшләренә,
Газраил килеп торса кашларына[8],—
Сәне белмәз фиракъ[9] көне, белмәк кәрәк.

---

[1] *Кол Сөләйман* — XII йөздә яшәгән атаклы шагыйрь Сөләйман Бакырганый.

[2] *Мөхиб* — якын.

[3] *Тәгъзим берлә* — олылап, ихтирам белән.

[4] *Хушнуд кыйлып* — сөендереп, ризалатып.

[5] *Хәйатлыкда* — яшәгәндә; исән чакта.

[6] *Остай кайд* — оста юлбашчы, җитәкләүче.

[7] *Нәгяh* — кинәт.

[8] *Кашларына* — каршыларына.

[9] *Фиракъ* — аерылу, аерылышу.

Угыл-кызга ата-ана хәшми[1] булса,
Алгыш[2] кыйлмай, дога кыйлып каргыш кыйлса,
Угыл-кызга йөз кыерса, хакдин булса,—
Мондый олуг хәтәр нә бар, белмәк кәрәк.

Ата-ана сүзе кабул булмаз тимәң,
Алгышы һәм каргышы килмәз тимәң.
Монлар кыйлган дога сиңа булмаз тимәң,—
Бу хәтәрдин хәсрәт йотып тормак кәрәк.

Ата-ананы угыл-кыз сүксә, белең,
Шәригатьдә кисмәк торыр моның телен.
Кулы берлә сугар булса, янә кулын
Буыныңдин кисмәк торыр, белмәк кәрәк.

Мәүла Колый, атаң-анаң белдең микән?
Хушнуд кыйлып, изгү дога алдың микән?
Юкса хушнуд булмай анлар үтте[3] микән,—
Кани[4] бу көн? Кулдин китде, нитмәк кәрәк?

[Карендәшлек турында]

Карендәш мәхәббәте бал-шәкәрдин
Ләззәтледер, кыйммәтенә белер булсаң.
Карендәш — тереклекдә җанга куәт,
Аригъ[5] йуып, гүргә куяр — үләр булсаң.

Карендәшкә кыйлгыл мәдәд[6], йитсә халең,
Сарыф кыйлгыл аның өчен дөнья малын.
Карендәшләр сәнең берлә булса, белең,
Дошманлар сәндин куркар, күрер булсаң.

[1] *Хәшми* — тупас; ачулы.
[2] *Алгыш* — мактау; фатиха.
[3] *Үтте — монда:* үлде.
[4] *Кани* — кайда.
[5] *Аригъ* — чиста, пакь.
[6] *Кыйлгыл мәдәд* — ярдәм ит; булыш.

Карендәшсез кешеләргә юкдыр сәбәп,
Хак Тәгалә үзе кыйлсын аңа мәдәд.
Рузи кыйлсын[1] ул гарибкә мал вә нигъмәт,—
Карендәшсез кеше — гариб[2], белер булсаң.

Карендәшсез кешеләрнең сердәше юк,
Дошманларга каршы торса, юлдашы юк,
Көнлендәге эшне кыйлса, кулдашы[3] юк,—
Һәркем моңлы — карендәшсез булыр булсаң.

Карендәшләр барча хален күреп белсә,
Дөшвар[4] килмеш эшләреңне асан[5] кыйлса,
Һәрбер эштә сәнең сару[6] кулдаш булса,—
Карендәшең шул кешедер, белер булсаң.

Дошман улдыр: өйүгә керер, ашың йийәр[7],
Андин чыкып хәлайыкга[8] гайебең дийәр,
Мәҗал тапса, тигъ алып, күзең уяр[9],—
Баикъ[10] дошман шул кешедер, күрер булсаң.

Карендәшсез кешеләрнең хәсрәте чук[11].
Галәмара тереклекнең ләззәте юк,
Нәгяһ үлем килер башка бер көн баикъ,
Карендәшсез дөшвар эшдер, үләр булсаң.

---

[1] *Рузи кыйлсын* — өлеш чыгарсын.
[2] *Гариб* — гарип; чит, ят.
[3] *Кулдашы* — булышчысы; иптәше.
[4] *Дөшвар* — кыен, мөшкел.
[5] *Асан* — ансат, җиңел.
[6] *Сәнең сару* — синең яклы; синең белән.
[7] *Йийәр* — ашар.
[8] *Хәлайыкга* — халыкка; кешеләргә.
[9] «Мөмкинлек (чара) тапса, пычак (кылыч, хәнҗәр) алып, күзеңне чыгарыр».
[10] *Баикъ* — чын.
[11] *Чук* — күп.

Мәүла Колый, хакга кол бул, моңлуг башың,
Хак бирсен, чура[1] торыр карендәшең.
Хак төзесен гүр өендә сәнең эшең,—
Әҗәл килеп, үлеп гүргә барыр булсаң.

[«...Яз кебек йәшлек китәр»]

Ратканның рәхмәте чук, белер булсаң,
(Бар) алты айны яз итәдер кодрәт берлә.
Тәңрилеген белсен тийү[2] галәм эчрә[3],
(Бер) алты айны кыш итәдер кодрәт берлә.

Бу галәмне йегет кебек төзендереп,
Төрлүк сәчкә берлә йири бизәндереп,
Төрлүк нәбат[4] уңдырубән[5], узандырып,
Оҗмах кебек нигъмәт бирер кодрәт берлә.

Бу кыш көнне карыйлыкка[6] охшатадыр,
Бу галәмдин нигъмәтләрен бушатадыр.
Мәхлукатны[7] ризык биреп кышлатадыр,
Тәмуг кебек суык кыйлыр кодрәт берлә.

Кыш булса төрлүк мивә[8] түгеләдер,
Күреклек нәбат бөгелеп иңеләдер[9].
Карыйларга манәнд[10] улып бөгеләдер,
Карыйлар тик хәлсез булыр кодрәт берлә.

---

[1] *Чура* — кол; хезмәтче.
[2] *Тийү* — дию.
[3] *Галәм эчрә* — галәмдә.
[4] *Нәбат* — үсемлек; үлән.
[5] *Уңдырубән* — уңдырып.
[6] *Карыйлык* — картлык.
[7] *Мәхлукат* — җан иясе.
[8] *Мивә* — җиләк-җимеш.
[9] *Иңеләдер* — иеләдер.
[10] *Манәнд* — охшаш.

Кыш килде исә, көнләре суык булыр,
Яктысы аз, караңгысы чук-чук булыр.
Карыйлык(ы) адәмигә кыш тик калыр,
Шадлык китәр, золмәт[1] кыйлыр кодрәт берлә.

Яз көнендә болыты аз, чуак ула[2],
Йегет кеше кайгусы юк — даим көлә.
Карый кеше мисле[3] һаман кыш тик була,
Шул сыйфатлы гомре кәчәр кодрәт берлә.

Кыш булдисә, йир йөзендин нигъмәт китәр,
Яз булдисә, ут-нәбәт кайра бөтәр[4],
Руза, намаз йегет кыйлса, куәте бар,
Карый булса хәлсез булыр кодрәт берлә.

Кыш көнендә үләнләр(е) йирдә черер,
Яз булдисә, нәбат нигъмәт үсә торыр.
Барча адәм үлеп барып, гүргә керер,
Кыямәт көн кайра терлер[5] кодрәт берлә.

Йимәк-эчмәк хазер кыйлса[6] яз көнендә,
Ул кеше тук, үзгәләр ач бу көн менә.
Рузә, намаз кыйлган булса йегетендә[7],
Оҗмах эчрә нигъмәт бирер кодрәт берлә.

Мәүла Колый, яз кебек йәшлек китәр,
Кышка охшаш карыйлык сәңа йитәр.
Рузә, намаз кыйла күргел, гомрең үтәр,
Кыямәт көн намаз соралыр, кодрәт берлә.

---

[1] *Золмәт* — караңгылык; төшенкелек.
[2] *Чуак ула* — аяз була.
[3] *Мисле* — кебек, шикелле.
[4] «Яз җиткәч, үлән-үсемлек кабат чыгар (үсәр)».
[5] *Кайра терлер* — кабат терелер.
[6] *Хазер кыйлса* — әзерләсә.
[7] *Йегетендә* — егет (яшь) чакта.

[Гариблек турында]

Хак бирмәсен һичбер кемгә гариблекне,
Гариблеки[1] барча хәлдә михнәт иркән.
Бимәкяни[2] вә бичара горбәт чигеп[3],
Йөрәкендә хәсрәт уты янар иркән.

Гарибләргә барча хәлләр ирер хәтәр,
Йорты-мәкян[4], малы-нигъмәт кулдин китәр.
Аһ итмәкдә гариб уты гарешкә[5] йитәр,
Гарибләрнең хәлен сорсаң мондаг[6] иркән.

Гариблек һичкемгә кыйлмаз вафа[7],
Пәйгамбәргә, әүлийага бирде Хода,
Хан углы, солтанларны тәх(е)тдин йыка,
Кол тик булып ишекләрдә торыр иркән.

Гарибләрне һичбер адәм алмаз санга,
Аш йийәрсә[8], ләззәт бармаз һәргиз[9] җанга.
Мәкянлылар миһманлашыр[10] тиңле тиңгә,
Гарибләри моң-зар булып торыр иркән.

Гарибләргә тормага йорт-мәкян кани[11]?
Баш агырса[12], әҗәл йитәр, куркар җаны.

---

[1] *Гариблеки* — гариблек.

[2] *Бимәкяни* — урынсыз; йорт-җирсез.

[3] *Горбәт чигеп* — күчеп йөреп; каңгырып йөреп; чит-ят җирдә яшәп.

[4] *Йорты-мәкян* — йорт-җире.

[5] *Гареш* — дини тәгълимат нигезендә күкнең иң югары (җиденче) каты.

[6] *Мондаг* — моның кебек.

[7] *Вафа* — тугрылык.

[8] *Аш йийәрсә* — аш ашаса; аш эчсә.

[9] *Һәргиз* — һич, һич тә.

[10] *Миһманлашыр* — кунак булыр.

[11] *Кани* — кайда.

[12] *Агырса* — авыртса.

Ыруг, кардәш кыйла алмаз сәне гани[1],
Гариблекдә үлем килсә, дөшвар[2] иркән.

Башында ултырмага[3] атасы юк,
Өстендә хәсрәт йотар анасы юк.
Уңлы-суллы хәлен сорар иясе юк,
Бер үлмәке мең үлмәкдин яман иркән.

Гарибләргә үлем килсә, моңлуг[4] башы,
Юктыр аның гүргә куяр карендәше.
Аш кыйлмагай гариб өчен тикмә кеше,
Гариблекдә килгән үлем шул тик иркән.

Хак гыйшкында горбәт чигә һәр адәми,
Аһ итмәкдә гарешка чыга аның дәми[5].
Хак Тәгалә хәзрәтендә булмаз кәми[6],
Хөллә[7] кийеп, наны-нигъмәт йийәр иркән.

Гарибләргә гыйшык уты төшәр булса,
Күңел бәхре мәүҗ кайнап ташар булса[8],
Гыйшык утилә йөрәк бәгъре пешәр булса,
Хак кашында гариблеки гайан[9] иркән.

Рәсүл Алла гариблекне чикде үзе,
Гарибләргә даим[10] шәфкать ирде сүзе,
Һәр кайчанә гарибләрне күрсә күзе,
Энҗүләйен[11] күзнә йәше тулар иркән.

---

[1] *Гани* — бай; дәүләтле.
[2] *Дөшвар* — кыен, мөшкел.
[3] *Башында ултырмага — монда*: баш очында утырырга.
[4] *Моңлуг (моңлы)* — кайгылы.
[5] *Дәми (дәме)* — сулышы.
[6] *Кәми* — ким.
[7] *Хөллә* — өс киеме.
[8] «Күңел диңгезе дулкынланып ташыр булса».
[9] *Гайан* — ачык.
[10] *Даим* — һәрчак.
[11] *Энҗүләйен* — энҗеләнеп; энҗедәй булып.

Мәүла Колый, гарибләрнең хәлен сорсаң,
Хәлен сорап, гарибләргә шәфкать кыйлсаң,
Кулда барын биреп күңлен хушнуд[1] кыйлсаң,
Изем[2] рәхман сәндин хушнуд булыр иркән.

[«Галимнәр күк йөзендә көнәш яңлигъ»[3]]

Гыйлемлек Хак рәхмәтедер, бер нур торыр,
Кемне галим кыйлса изем, газиз кыйлыр.
Углан икән, төн-көн гыйлем тәхсыйль кыйлыр[4],
Хак рәхмәте ул колына булыр булгай.

Гыйлемлек Хак рәхмәтедер, бер нур торыр,
Хак кемене[5] газиз кыйлса, аңа бирер,
Гыйлем белеп, Хак әмрилә[6] тугры йөрер,
Дөнья-гокъба[7] морадына йитде булгай.

Гыйлемлек һичкем булмаз шандыр[8] белсәң,
Гыйлем белеп ахирәтлек гамәл кыйлсаң,
Алып калмаз сәндин гүргә барыр булсаң,
Гүр эч(е)рә нуру чираг[9] булыр булгай.

Гыйлемлек күкрәкдин иңде галимнәргә,
Мөрсәл, нәби, әүлийа — тәмамләрә[10].
Газиз кыйлып бирде Алла пакь җанларә,
Гыйлем белгән Хак дидарын[11] күрер булгай.

---

[1] *Хушнуд* — канәгать; риза.
[2] *Изем* — Аллам.
[3] «Галимнәр күк йөзендәге кояш кебек».
[4] *Тәхсыйль кыйлыр* — өйрәнер; укыр.
[5] *Кемене* — кемне.
[6] *Әмрилә (әмере илән)* — әмере белән.
[7] *Дөнья-гокъба (гокъби)* — дөнья-ахирәт; теге һәм бу дөнья.
[8] *Шандыр* — дәрәҗәдер.
[9] *Чираг (чыраг)* — шәм; яктырткыч.
[10] «Пәйгамбәр, әүлияләр — һәммәсе дә».
[11] *Дидар* — йөз.

Гыйлемлек күккә охшар, тәхсыйль кыйлсаң,
Наданлык дөнья кебек, гакыйль ирсәң,
Хак рәхмәте күкдин иңәр, гыйбрәт күрсәң,
Гыйлем әмрен хәлаикга[1] сачар булгай.

Надан белмәз: хәлял, хәрам бердер аңа,
Коңгыз-корт тик дөнья өчен һәб казгана[2],
Үләр булса, казгандыги улыр фәна[3],
Малы-милке бу дөньяда калыр булгай.

Үлсә надан, малы-милке гүргә бармаз,
Галим үлсә, гыйлемлеге үздин калмаз,
Гыйлем белгән рәхмәт хакдин кирү калмаз,
Тәмуглардин изем азад кыйлыр булгай.

Наданлар ахирәт димәз, дөнья тотар,
Коңгыз-кортлар йорт тотам дип, тизәк тишәр.
Суык булса кара йиргә иңеп китәр,
Казгандыгы заигъ булып[4] калыр булгай.

Галимнәр күк йөзендә көнәш яңлигъ,
Шәкердләр тулып торган айга яңлигъ,
Мөэминнәр күк йөзендә йолдыз яңлигъ,
Наданлар коңгыз-кортка охшар булгай.

Мәүла Колый, көнәш яңлигь гыйлем кылсаң,
Яки сән шәкерд булып ай тик тулсаң,
Тагъәт[5]-намаз кыйлып яки мөэмин булсаң,
Рәхмәтендин Хакның өмид булыр булгай.

---

[1] *Хәлаикга* — халыкка.
[2] *Һәб казгана* — казына; тырыша; көчен түгә.
[3] «Үлсә, туплаганы юкка чыгар».
[4] *Заигъ булып* — әрәм булып.
[5] *Тагъәт* — гыйбадәт кылу; (Аллага) буйсыну.

[«Игенчелек гали[1] эшдер...»]

Игенчелек хуш һөнәр Хак колларына,
Гыйззәт-хөрмәт бардыр монда, белер булсаң.
Нәфегъ идеп[2] бирде Алла җанларына,
Хак рәхмәте бар монда, кыйлыр булсаң.

Игенчегә Хак рәхмәте баикъ булыр[3],
Дөньялык һәм ахирәтлек кулга килер.
Игенчене рәхман изем[4] газиз кыйлыр,
Кыямәтдә урны — җәннәт, сорар булсаң.

Игенченең әл-азакы[5] булыр туфрак,
Хак Тәгалә хәзрәтендә[6] йөзләре ак,
Кыямәт көн асан[7] булгай сөаль-сораг[8],
Игенченең эше мондаг, белер булсаң.

Игенчеләр туфрак үзә иген иксә,
Кош-корт, хайван, адәм — һәркем андин йийсә[9],
Игенчегә андаг[10] саваб белер ирсә,
Һәр локъмәгә[11] бер кол азад кыйлыр булсаң.

Игенчелек — галәмара изге аты,
Нигъмәт йийәр мөэмин, кяфир — юкдыр каты[12],
Игенчене көйдермәгәй тәмуг уты,
Игенчелек гали эшдер — кыйлыр булсаң.

---

[1] *Гали* — бөек, олуг.

[2] *Нәфегъ идеп* — игелек итеп; киң күңелле булып; кайгыртып; мал итеп.

[3] *Баикъ булыр* — ачык булыр; ирешер.

[4] *Рәхман изем* — рәхимле Алла.

[5] *Әл-азакы* — кул-аягы.

[6] *Хәзрәтендә — монда*: каршында.

[7] *Асан* — ансат.

[8] *Сораг* — сорау.

[9] *Йийсә* — ашаса.

[10] *Андаг (андай)* — шулкадәр.

[11] *Локъмә* — бер кисәк ризык; бер кабым.

[12] *Юкдыр каты— монда*: аермасы юк.

Бу игенне газиз белеп һәркем игәр —
Тереклекдә галәмара гыйззәте бар;
Үлеп барса — Хак Тәгалә рәхмәте бар,
Иген иккел, рәхмәт өмид итәр булсаң.

Мәүла Колый, иген игеп сәхи[1] булгыл,
Сәхи булып, нәфкалекне[2] хакдин кулгыл,
Йите ниран[3] газабындин азад булгыл,
Бу дөньядин ахирәткә барыр булсаң.

БЕРЕККӘНЛӘР СЫЙФАТЫ*

(поэманың ахыры)

Гакыйл адәм берекеб[4] берлек кыла,
Хак рәхмәте берлек(к)ә йакын була.

Кил, әй мөэмин, берекеб кыл һәр эши,
Хакдин рәхмәт булса кәрәк ул кеши.

Береккәнләр сыйфатын әйдем сезә,
Береккән эш асандыр[5] сезә-безә.

Хак рәхмәте берлекдә хасыйл ула,
Берекеб тагъәт кыйлан[6] рәхмәт була...

Тәүфикъ теләб йыгларым сәндин өмид,
Рәхмәтең фәраван[7] сәнең, кылма нәүмиз[8].

---

* Текстның чыганагы: Казан утлары.— 1996.— № 10.— 169—170 б.

[1] *Сәхи* — юмарт.

[2] *Нәфкалек* — тормыш итәргә җитәрлек мая (байлык, акча).

[3] *Йите ниран* — җиде тәмуг.

[4] *Берекеб* — бер булып; бердәмлектә.

[5] *Асандыр* — җиңелдер; ансаттыр.

[6] *Тагъәт кыйлан* — буйсынган.

[7] *Фәраван* — мул; чиксез.

[8] *Нәүмиз* — өметсез; өлешсез.

Тәүфикъ биреб күргүз Хак йулларыңны,
Рәхмәтлек(к)ә йарлыка колларыңны.

Әй Ходайа, гасыйы җафи[1] Мәүла Колый,
Рәхмәтеңлә[2] сән биргел коллык йулы...

Җөмләләри йарлыкаган сән кәрим[3],
Гайбләрен йабкычы[4] гафу рәхим.

---

[1] *Гасыйы җафи* — гөнаһлы, рәхимсез (тәрбиясез).
[2] *Рәхмәтеңлә* — рәхмәтең белән.
[3] «Барчасын кичергән син юмартлык иясе».
[4] *Йабкычы* — «кичерүче» мәгънәсендә.

Габди

*(1679—1709 елдан соң)**

[Галимнәрне якын күр]

Кичә-көндез, собхы-шам[1] галимнәрне тот белеш.
Галим катындан сөрсәләр, катына отры йылыш.
Йыракдин күрсәң анларны, катына килеп кул алыш,
Күңлен алып, көн дә кил — бервакыт булма чалыш.
Галимнәрнең хәлен соргыл — атнада, һәрбер айда.
Хәлен сорап, хәер иткән — бу заманда мондый кайда?!
Бирә күргел малың булса, булса пул[2] йә баглы тай да.
Аңлап алгыл бу сүземне, хафаны итрерсән шәйда[3].

[Ата-анаңны хөрмәт ит]

Атаң берлән анаңа хезмәт иткел күп-күп,
Иртә торып, һәр көндә аякларын үп-үп.
Һәр нә әйтә, анларның сүзләрен күр йөп-йөп[4],
Сабыр кылгыл, һәр нәчә кыйнасалар дөп-дөп.

---

* Казан утлары.— 1978.— № 11.— 141—147 б.; Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 188—192 б.

[1] *Собхы-шам (собых-шам)* — иртә-кич.

[2] *Пул* — акча.

[3] «Хафаны һичшиксез уздырырсың» мәгънәсендә.

[4] *Йөп-йөп* — җөплә; хак күр.

[Аш-су ашат халыкка]

Аш-су ашат хәлаикка[1], нигъмәтең булса тигез,
Сәвенмәгел угыл-кызың туганыга, тугса игез.
Һәр нә тапсаң, дус-иш берлә бергә(ләшеп) йиеңез[2],
«Кем ожмахлык?» — дип сорсалар:
«Сәхи (кеше)!» — диегез[3].

[1] *Хәлаикка* — халыкка.

[2] *Йиеңез* — ашагыз.

[3] «Кем ожмахка керә?» — дип сорасалар, «Юмарт!» — диеп җавап бирегез.

МӘҖМУГЫЛ ХИКАЯТ*

(XVIII йөз)

Вәзирләрен эткә ашатучы турында

Хикәятләрдә шулай сөйлиләр: үткән заманда бер патша бар иде. Гадәте шул иде: һәр елда бер вәзирен, яманлап, этләргә ашатыр иде.

Патшаның бер дусты бар иде, ул әйтте: «Патша ел саен бер вәзирен этләргә ашата. Белмим, аның бу эшендә ни хикмәт бар икән? Бу елда мин вәзирлек итим әле, патшаның бу эшне ни сәбәптән кылганын белермен. Мөмкин булса, бу эшеннән туктатам».

Яңа ел вакыты җитте. Патша, гаскәрен тезеп, уеннар ясады, бүләкләр өләштерде. Вәзирен этләргә ашатты.

Бу дусты аның янына барды, җир үпте: «Бу елны вәзирлекне миңа бирүеңне үтенәм»,— диде. Патша әйтте: «Син нинди теләк телисең? Беләсең бит: ел узгач, мин сине этләргә ташлармын. Ул вакытта хәтта дуслыгыбыздан да файда булмас». Дусты әйтте: «Ярар, патша — син, үзең белерсең».

Патша да риза булды, вәзирлекне аңа бирде.

Ул шулкадәр вәзирлек итте ки — барча халык аннан шат булдылар. «Шаһ моны этләргә бирер вакытта, шаһны үтереп, вәзирне шаһ итәбез»,— дип сөйләштеләр.

Менә бервакыт ел ахыры җитте. Шаһ якыннарын җыйды, әйтте: «Мин аңа вәзир булма дип әйткән идем, үзе теләп алды, мин аны этләргә бирмичә куймыйм». Вәзир әйтте: «Шаһ бу

---

* Хикәятләр *Нәҗип Исмәгыйль* тарафыннан хәзерге телгә күчерелгән // Казан утлары.— 1988.— № 9.— 129— 130 б.

эшне наданлыгыннан, бозык күңелле булуыннан эшләр, бу һич тә ярый торган эш түгел. Ни эшләсә эшләр, хөкем аныкыдыр».

Беркөнне вәзиргә хәбәр бирделәр: «Өч көннән соң патша сине этләргә бирер»,— диделәр. Вәзир улларын янына чакырды, аларга яхшы нәсыйхәтләр әйтте, күңелләрен басты. «Үз нәфсегезгә булышып, бер-берегезгә яманлык эшләмәгез, минем сүземне тыңлагыз»,— диде.

Һәрберсенә үзенә тиешлесен бүлеп бирде, хезмәтчеләрен азат итте. Аннан улларына әйтте: «Мине этләр ашаганнан соң, сөякләремне җыеп, берәр нәрсәгә төреп, атам кабере янына күмегез».

Аннан соң өйдә үзе генә калды. Хикмәт үлчәвен кулына алып, уйлар тәлинкәсенә хәйлә чарасын куеп, бераз утырды. Берничә алтын, ит һәм икмәк китерде. Юлдашсыз, ялгыз гына, караңгы кичтә этләр караучы янына барды. Капка шакыды. Эт караучы чыкты. Вәзирне күрде, аягына төшеп, сәлам бирде, хөрмәт сүзләрен әйтте. «Ни хаҗәтең бар һәм ни хезмәт кирәк?» — диде. Вәзир әйтте: «Этләрне күрергә телим, капкаларын ач». Эт караучы әйтте: «Чыгып китәрләр дип куркам». Вәзир берничә алтынны эт караучының учына салды.

Икенче төнне дә шул рәвешчә килеп, этләргә ит һәм икмәк ашатты. Өченче төнне дә шулай эшләде. Эт караучыга энҗе-җәүһәр һәм ризыклар бирде.

Яңа ел көне килеп җитте. Патша бөтен якыннары белән мәйданга чыкты, яңа елны игълан итте, бүләкләр өләштерде.

Аннан патша этләргә салу өчен, вәзирнең аяк-кулын бәйләргә боерды. Патша әйтте: «Менә, үз-үзеңә артык нык ышансаң, шулай була ул». Вәзир әйтте: «Үтенечем бар, кабул ит». Патша: «Ни теләсәң дә эшләрмен»,— диде. Вәзир: «Мине ташлар алдыннан этләргә ашарга бирмәсеннәр. Тагын берсе: минем сөякләремне улларым алсын, кабергә күмсеннәр»,— диде. Патша: «Үтенечләрең бик җиңел икән»,— диде. Эт караучыга боерды: «Этләрне ачыктыр, вәзирне сакла!»

Кич булгач, вәзирне ялангач калдырып, этләр алдына ташладылар. Этләр, бу кешенең берничә көн ризык биргәнен исл-

ренә төшереп, янына килделәр, яландылар, юмаландылар. Вәзир уйлады: «Болар мине икмәк китерде дип саныйлар. Ялыналар, бирмәгәнемне белгәч, ачыгырлар, мине ерткаларлар. Тәңрегә дога кылыйм, үлсәм, сәҗдәдә үлим»,— дип, башын сәҗдәгә куеп утырды. Этләр, икмәк һәм ит өмет итеп, бераз тордылар, бераздан соң өметләрен кисеп, һәммәсе вәзир тирәсенә елышып, башларын ал аяклары өстенә салып яттылар, иртәнгә кадәр кузгалмадылар.

Таң аткач, эт караучы килде, вәзирнең сөякләрен җыям дип, капканы ачып керде, ач этләр эт караучыга ябыштылар, бичара эт караучының канлы сөякләре генә калды.

Бу хәлне белделәр, патшага хәбәр бирделәр. «Вәзир сәламәт утыра, әмма эт караучыны ботарлаганнар»,— диделәр. Патша шул ук мизгелдә, яланбаш, яланаяк килеш, атына атланып, ашыгып-чабып, этләр янына килде. Күрде, ишеткәне дөрес булды. Түбәнчелек белән вәзирнең аягына төште, әйтте: «Тәүбә булсын, моннан соң һичкайчан моның кебек эшне эшләмәм. Әмма миңа әйт: нинди хәер һәм яхшылыклар эшләдең. Хак Тәгалә ничек сиңа моның кебек кадер-хөрмәт һәм котылу бирде, бу канечкеч этләрдән ничек котылдың?» — диде. Вәзир әйтте: «Мин әллә ни яхшылыклар эшләмәдем. Әмма шушы вакытка кадәр тугрылык һәм тырышлык белән сиңа хезмәт иттем, бер сәгать эшеңне калдырмадым. Ахырда шул булды: мине этләр авызына бирдең. Өч кич бу ерткыч җанварларга хезмәт иттем, бу өч кичәдә күрсәткән хезмәтемнең кадерен белделәр, миңа зыян тидермәделәр. Син үзең, җиһанның олы патшасы, шул этләр кадәре дә булмадың, ничә заманлык хакымны сакламадың. Синнән ни көтмәк кирәк?!» — диде.

Бу хикәяттән мәгълүм булсын: кешенең игелеген белмәгән кешедән эт яхшырак. Шагыйрьләр әйткәннәр:

Тоз-икмәк белмәк — олы һөнәрдер,
Тоз-икмәк белмәгән — эттән битәрдер.

Габдессәлам

(1700—1766 елдан соң)

ИЛАҺИ БӘЕТ*

...Байның кызы бай кебек, йөзе тулган ай кебек.
Күз өстендә кашлары корып куйган йай кебек[1].

Биле нәзек талдай ирүр, агъзы шикәр-балдай ирүр.
Әйткән сүзгә тормыйдыр, кылыгы (?) (холкы.— *Х. М.*)
йаман алдыйдыр.

Каләм тарткан каш кына, күрсәм күңлем ашкына,
Әйтеп, сүзем тыңламай, ниндәй бәгъре таш кына...

...Кашың берлә күзеңә, йөз мең алтын үзеңә,
Җаным фида кыйлырмын, бер кәлимә сүзеңә...

...Күңлем төште үзеңә, коңгыр(т) кара күзеңә,
Йөрәк кенәем йанадыр, кермәйсең лә сүземә,

Куй күзеңнең багышы(н), күптер аның сагышы.
Күп сагышка төшергән ике күзең багышы.

Нәркәс кара күзләрең, тулган ай тик йөзләрең,
Һич күңлемдин китмәйдер бал-шикәр тик сүзләрең...

---

* Татар поэзиясе антологиясе. 1 китап.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.— 196—197 б.

[1] *Йай кебек* — җәя кебек.

Габдерәхим Утыз Имәни

(1754—1834)

МӘРСИЯИ ГАБДЕННАСЫЙР ВӘЛӘДЕ ГАБДЕРӘХИМ*

Кичәләрне йите бүлгән,
Мәнем өчен уйагъ торган,
Кечелекдә сөтен биргән
Шәфикамдин җөда булдым[1].

Намаз куйма дәйү сүккән,
Сабак куйма дәйү орган,
Уен өчен каһәр кыйлган
Миһербандин җөда булдым.

Нәсыйхәт сүзләрен айган[2],
Бәһа яхшы дога кыйлган,
Нәчә йөз мең хәтем кыйлган[3]
Шәфикамдин җөда булдым.

Тәгамемни пешек кыйлган,
Либасемни[4] төзек кыйлган,
Черек җамәм[5] алып юган
Шәфикамдин[6] җөда булдым.

Күзем нуры — балам, дигән,
Мөлаемлык бәһа кыйлган,
Яман эшдин мәнгъ иткән[7]
Миһербандин җөда булдым.

---

* *Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари.* Шигырьләр. Поэмалар / Төз. *Әнвәр Шәрипов.*— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— 398 б.

Утыз Имәни бу мәрсиясен (матәм шигырен) үзенең улы Габденнасыйр исеменнән язган.

[1] *Җөда булдым* — аерылдым.

[2] *Айган* — әйткән.

[3] *Хәтем кыйлган* — изге сүз сөйләгән; Коръән укыган.

[4] *Либасемни* — киемемне; өс-башымны.

[5] *Җамәм* — күлмәгем, киемем.

[6] *Шәфика* — шәфкатьле.

[7] *Мәнгъ иткән* — тыйган.

Кичә-көндез гамем йийгән,
Күңел эчрә нурым дигән,
Бәгъәл эчрә[1] дөррем[2] дигән
Галәфемдин[3] җөда булдым.

Тәрҗемәсе*:

Кичәләрне җиде бүлгән,
Янымда гел уяу торган,
Сабый чакта сөтен биргән
Шәфикамнән аерылдым.

Намазым калса әрләгән,
Сабагым калса тиргәгән,
Шаянлансам каһәрләгән
Миһерлемнән[4] аерылдым.

Үгет-киңәш биреп торган,
Миңа изге дога кылган,
Өйрәтеп эшкә, боерган
Шәфикамнән аерылдым.

Ашымны пешереп торган,
Киемнәрем әзер кылган,
Каралса, керләрем юган
Шәфикамнән аерылдым.

Күзем нуры — балам, дигән,
Яратып елмаеп-көлгән,
Яман эштән тыеп килгән
Миһерлемнән аерылдым.

Минем өчен янып-көйгән,
Күңелемнең нуры дигән,
Йөрәк энҗем диеп сөйгән
Караучымнан аерылдым.

КИҢӘШ

Тәрҗемә

Тисә киңәш шәменнән нур кешегә,
Тулыр нур күңленең барлык төшенә.

Ерак торса киңәшләр бакчасыннан,
Урын алыр наданлык сәхрасыннан.

Гыйбрәтләр ярдәм итмәс ул чак аңар,
Өмет итсә дә йөз-мең яхшы хәбәр.

Укысаң да аңа Тәүрат һәм Инҗил,
Укып Коръән, шуны итсәң дә дәлил;

---

*Утыз Имәни шигырьләре *Әхмәт Исхак* тәрҗемәсендә бирелде.

[1] *Бәгъәл эчрә* — куендагы; акча янчыгындагы.

[2] *Дөррем* — энҗем.

[3] *Галәфемдин* — саклаучыдан, караучыдан.

[4] *Миһерле* — йомшак күңелле.

Пәйгамбәр сүзләрен торсаң кабатлап,
Арадан иң кирәк сүзләрне сайлап;

Сөйләп сүзләрнең иң кыйммәтлеләрен,
Өйрәтсәң дә гадәтен изгеләрнең,—

Колак салмас синең яхшы сүзеңә,
Сине хурлап, гаеп ташлар үзеңә;

Котырган эт кебек тешләр аягың,
Сугыйм дисәң, аңа җитмәс таягың.

Табылыр һәрчак аны яклаучылар,
Түгелер сүзең, гүя терек сулар.

Кадрең җуйма, кач син андый кешедән,
Үзеннән һәм күзеннән һәм эшеннән.

Киңәш тыңлаучыны тапсаң әгәр син,
Ишекләрен сүзеңнең ачар аңар син.

Берәү тыңламаса киңәшне рәтләп,
Телең тешлә, авызың куй пичәтләп.

ГЫЙЛЕМНЕҢ ӨСТЕНЛЕГЕ ТУРЫНДА ТӨРКИЧӘ[1] БӘЕТЛӘР

Тәрҗемә

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.

Белмәде һөнәрне гыйлемсез кеше,
Булмады аңарда бәхетнең эзе.

Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш иялә һәрвакыт белемлегә.

---

[1] *Төркичә — монда*: татарча (*Х. М.*).

Ал гыйлем, чөнки яшәүнең аслы шул,
Хәл итә барлык кыенлыкны тик ул.

Кем гыйлемле, бел асылташ дип аны,
Һич җиңалмас угры яки дошманы.

(О р и г и н а л д а:
Адәминең гәүһәре даниш улыр,
Аны нә дошман вә нә угъры алыр.)

Гыйлемлек — яшрен хәзинә, кем таба,
Ике дөнья байлыгы булыр аңа.

Шундый байлык ул — гел өстәп тор аны,
Ул, сарыф иткән саен, арта бары;

Дөньяның малы кими тоткан саен,
Өстәлә белем — сарыф иткән саен.

Күп гыйлемле булса адәм — байдыр ул,
Башкалар йолдыз кебектер,— айдыр ул.

Чын кеше димә туны булганга шәп,
Кисә дә атлас, ишәк — һаман ишәк.

Тик гыйлем аша табылды тугры юл,
Булды гөлбакча ничаклы тозлы чүл.

Ит җитәкче ул гыйлемне син үзең,
Шул вакытта дөньяда калыр эзең.

Иң элек булды гыйлем, соңыннан — эш,
Бик түбән булды гыйлемсез кылган эш.

Бәйләсәң эшкә гыйлемне — үлмәссең,
Хак юлыннан читкә барып кермәссең.

Килсә дә үлем, галим үлми һаман,
Үлеме килгәнче үк үлә надан.

(Оригиналда:

Үлмәйә галим кеше, килсә үлем,
Үлде җаһил килмәзедин бу үлем.)

Бел наданнар төркемен үлек диеп,
Үлсә галим, бел аны терек диеп.

Син гыйлем тупла, наданлыктан уян,
Ахирәт көнне надан — эттән яман.

Чын галим үзен надан диеп белер,
Күп белим дип, галим артыннан йөрер.

Бел: гыйлем нур ул, сине нурландырыр,
Ә наданлык — ут, сине ул яндырыр...

(Оригиналда:

Гыйлем — нурдыр, нурлыйдыр күңелләри,
Җәһел — нардыр, яндырыр һәм дилләри...)

НӘЗМЫ ДӘР МӘДХЕ ЧӘЙ-КАЙМАК[1]

Тәрҗемә

Гүяки кәүсәрне[2] татыр
Чәйне бер эчкән кеше,
Нәкъ матур кызлар йөзенә
Охшый ал гөлдәй төсе.

Бирмәде мондый җимеш
Татлы йөземнәр бакчасы,
Эчмәгәннәр калды мәхрүм,
Булса да Рум[3] патшасы.

Син бу кәүсәрнең шәрабен
Бер татып бак: кил, и яр!
Эчми калса кем бу чәйне,
Шөбһәсез бәгъре көяр.

Син кунак булып, бу чәйне
Һич яратмасаң әгәр,
Дус янында кадрең булмас
Ишәк кадере кадәр.

Язды Болгари, аны
Кәүсәр суына охшатып,
Кайчан ул каймаклы чәйне
Баккан иде бер татып.

[1] «Каймаклы чәйне мактау».
[2] *Кәүсәр* — җәннәт чишмәсе; җәннәт суы.
[3] *Рум* — Византия.

ГАВАРИФ-ЭЗ-ЗАМАН[1]

Баштан үткәннәрне сөйләүче бүлек

Тәрҗемә

Лаек җаннар ишетсен моны бар да,
Кичердем күп кыенлык мин җиһанда.

Сарыф иттем егетлек дәверемне,
Алыйм күбрәк, диеп, дини белемне.

Мөселман илләренә илтте юллар,
Төшеп калды кулымнан күпме еллар.

Күп булдым галим затлар арасында,
Ядка алдым сүзләрен аларның да.

Чумып диңгезгә, күп энҗеләр алдым,
Гамәл өчен барсын күңелгә салдым.

Җимеш җыйдым гыйлемлек бакчасыннан,
Зурын сайлап аларның арасыннан.

Мөһимнәрен кешеләргә өләштем,
Зур өстенлеккә бу эштә ирештем.

Гыйлем юлында йөреп артты нурым,
Наданлыкка үземнең бетте урын.

Бозыклыкка ният булмады миндә,
Гомер чиктем олылар хезмәтендә.

Юмартлык диңгезеннән тамчы йоттым,
Комарлык (тырышлык.— *Х. М.*) күрсәтеп,
күп энҗе оттым.

Шушы максат белән күп илдә булдым,
Бу елларда сәяхәт шактый кылдым.

---

[1] «Замана укымышлылары (бүләкләре)».

Юллар мине сусыз чүлләргә илтте,
Кызудан тән уләрлек хәлгә җитте.

Ничә төрле хәтәрләр килде башка,
Качып китеп, сыгындым тауга-ташка.

Җәфа чиктерде, очрап, юлбасарлар,
Кылыч белән яралар салды алар.

Далага аттылар, бәйләп кулымны,
Юлбасарча кылып төрле золымны.

Начар дуслар кулыннан җәфа чиктем,
Күземнән канлы яшьләр күпме түктем.

Җәбер күрдем гүзәл алдакчылардан,
Золым күрдем кораллы сакчылардан.

Кичердем кимсетүләр көнчеләрдән,
Алар кылды хыянәт миңа һәрдәм[1].

Тыйнак кына утенеп авыз ачтым,
Сабыр җамыннан ачы сулар эчтем.

Мәгариф әһле хөрмәт итте бик күп,
Наданнар хурлады, кимсетте бик күп.

Бәхәсләр мәҗлесенә еш юлыктым,
Бәхәсләшеп отылдым яки оттым.

Бу дөнья әһле — солтан һәм дә ханнар
Миңа ул чакта бирде зур урыннар.

Эшен сәнгатьтәге зур осталарның
Күреп һәм дус булып күп ләззәт алдым.

Күпме гауга, газаплар баштан ашты,
Ашарга бетте икмәк, карным ачты.

---

[1] ***Һәрдәм*** — һәрчак.

Сусап кайчак, үләрлек хәлдә калдым,
Зәгыйфьләнеп тәнем, туфракка аудым.

Өемдә булды кайчак мул сый-хөрмәт,
Ничәләр, билне баглап, итте хезмәт.

Шулай аһ-зар белән бу гомрем үтте,
Сәяхәттә йөрү — ахрына җитте.

Кичәрмен бу җиһаннан, йорт италмый,
Кешеләр күк исем-данга җиталмый.

Шуңа мәҗнүн дигән исем күтәрдем,
Гадел хөкмен чыгарсын үзе Тәңрем...

...Сәяхәттә егетлек дәүрем үтте,
Ватанга кире кайту вакты җитте...

МӨҺИММӘТ ЭЗ-ЗАМАН[1]

Тәрҗемәләр

Кәсеп турында

Яшәү өчен хәлялне син кәсеп ит,
Ризыкны тап көчең җиткән кадәр тик.

Ходаның биргәнен азсынма, зинһар,
Аның хөкмендә бит барлык ризыклар.

Тудырды ул анадан яп-ялангач,
Киендерде, карында итмәде ач.

Ана карнында безне тотты ул тук,
Тагын да туйдырыр, мохтаҗлыгы юк...

Егет булу турында

Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә,
Тугры дуслык путасын бәйлә билгә...

---

[1] «Замананың мөһим билгеләре».

Гаделлек кыл, лаек бул изгеләргә,
Тузан чаклы җәфа кылма берәүгә.

Тидермә һичберәүгә син ачы тел,
Әгәр дә ул тидерсә, син бары көл.

Димә: күркәм минем йөз һәммәсеннән...
Китәр күркең бер-ике көндә синнән.

Шулай дисәң әгәр дә — буш адәм син,
Череп гүрдә, булырсың корт өчен җим.

Димә: мин зур, көчем күп, мин булыйм баш...
Хода әмрен үтәүдән тартма һич баш...

...Телең, күзең, кулыңны саклый күр син,
Гөнаһ эшләп, соңыннан булма хур син...

Татулык турында

Тату булып яши күрше белән кем —
Яшәр андый кеше муллыкта һәр көн.

Берәү рәнҗетсә күршесен әгәр дә,
Булыр мәхшәрдә тоткын андый бәндә.

Кыйнама, орма, керсә күрше малы,
Кума, керсә шулай ук балалары.

Табакта булса әгәр татлы нигъмәт,
Чакыр син күршеңне, күрсәт сый-хөрмәт.

Син алсаң күчтәнәч берәр туганнан,
Чыгарып бир өлеш күршеңә аннан.

Сөйләмә күрше хатынын яманлап,
Ире сөйсә аны, син сөйлә мактап.

Юлың бүлмә, әгәр дә очраса ул,
Телең ачма, әдәпле ир кеше бул.

Кеше байдыр, ояты булса аның,
Ләкин байлык түгел — күплеге малның.

Малы калыр, кеше керсә кабергә,
Оят ләкин яшәр бергә гомергә.

Малым бар дип, фәкыйрьне күрмә ким-хур,
Сүзем кадерле дип, һич булма мәгъруր.

Үзем яхшы булыйм дип, итмә әләк,
Ул әләк күпмеләрне итте һәлак.

Берәү килеп сөйләсә бер әләк сүз,
Син андый бәндәдән дуслык җебен өз.

Шулай ук гайбәтен сатма кешенең,
Сиңа һич файдасы юк бу эшеңнең.

Әгәр кылсаң берәүгә изге эш син,
Алырсың шундый ук изге өлеш син.

Әгәр кылсаң яманлык бер балага,
Дучар булмам, димә үзең, бәлагә.

Сиңа атса берәр адәм әгәр таш,
Ачу тотма, үзең ат син аңа аш.

Ару булыйм дисәң, су күк ару бул,
Арулый, былчырак тисә, юып ул.

Сату итү турында

Сату итсәң, хыянәт итмә колга,
Гадел аршын, гадел гер асра кулда;

Кыска кисеп, җиңел үлчәп син сатма,
Җәһәннәм утына үзеңне атма.

Җәберләп тапма малны, синең алда
Хисап көне тора, нишләрсең анда?

Бу аз гомрең әрәм итмә, гадел бул,
Гадел кеше — Ходай сөйгән кеше ул.

Үзеңә Хак җибәргән өлешең бар,
Шуңа тук бул, күңелне сузма, зинһар!..

Сабыр итү турында

Җәфа кылса берәү сиңа әгәр дә,
Сабыр ит син, үтәр беркөнне бар да.

Чын ир өчен сабыр итү күп артык,
Ачуың йот, аңа син атмачы ук.

Юмарт бул син, була күрмә саран бик,
Йөри күрмә, миңа килмәс әҗәл, дип.

Бу миннән ким адәм, дип, бирмә җилкә,
Гомер — өч көнлек ул, очырма җилгә.

Гомер охшый исәр җилгә, ачык бел,
Кышын, җәен күреп аның, фикер кыл.

Язын карсыз, шәрә калыр җир, агач,
Туган кебек без анадан ялангач.

Үсәр җирдә үлән, агачта яфрак,
Ана безне киендергән кебек нәкъ.

Бераз үткәч, үсәр чәчкә, үләннәр,
Егет булган кебек нәни оланнар.

Бераздан чәчкәләр җиргә төшәрләр,
Охшар картлык килүгә мондый хәлләр.

Үлән, яфрак кыраудан булса сары,
Егетләр картаюның бу мисалы.

Үләннәрне салам итәр, басып кар,
Шулай беркөнне туфрак безне каплар.

Әгәр булса гомер шул җилгә охшаш,
Ничек җирдә йөрерсең күтәреп баш?

Берәү гел изге эш эшләсә безгә,
Аның бер ел гомерен тиңлә йөзгә.

Утырсаң син галимнәр белән бергә,
Хисап ит син моны йөз ел гомергә.

Әгәр йөрсә кылып яман эш адәм,
Ни файда җирдә мең ел яшәвеңнән?

Хәләл мал тап, хәләл булсын икмәгең,
Хәләл булсын өстеңә һәм кигәнең.

Гомер итү турында

Бу гомрең күпме калган, уйла инде,
Синең гомреңдә күпме ирләр үлде!

Ничә шаһлар, ничә агалар үлде,
Ничә хәким китеп, яңасы килде.

Берәүнең үлде ата һәм анасы,
Берәүнең үлде күз нуры — баласы.

Берәүнең ире үлеп, калды ул тол,
Берәү бай иде,— бөлде, калды буш кул.

Ничаклы хуҗаларның йорты тузды,
Ничә бәкнең өметен дөнья бозды.

Шул гыйбрәтләр җитәрдер, шаять, безгә,
Килер дип уйласак бу үзебезгә.

Диденме син: бу көн миңа юлыкмас —
Ничек тудың, булып шундый курыкмас?

Хәтәр көннәр турында уйла син уй,
Бозык һәм буш теләккә сонма һич буй.

Сөйләр ахмак: бу дөньяны беләм, дип,
Ул уйламас, кеше миннән көләр, дип.

Акыллы, белсә дә, йөрмәс, беләм, дип,
Аны, белми, диеп сөйләр юләр тик.

Акыллы сөйләр уйлап башын-ахрын,
Сөйли күр син дә белгәнеңне акрын.

Сөйлә сүзеңне син кычкырмый, көлми,
Көлеп сөйләр кем ахмак, берни белми.

Үгет турында

Үгет кермәс кешегә бирмә үгет,
Өйрәтмә син мине, дип, сүгәр ул әт.

Иманлы булса, тыңлар үгетең ул,
Колак салмаса әгәр, тукта, сак бул.

Агармыйдыр юган белән кара таш,
Үгет алмас кешеләр шуңа охшаш...

XIX ЙӨЗ ӘДӘБИЯТЫ

РУС-ФРАНЦУЗ СУГЫШЫ БӘЕТЕ*

Мендем тауның башына, атым[1] яздым ташына;
Бу француз азган икән үзенең газиз башына.

Французлар килеп кергән Мәскәү дигән калага,
Безнең гаскәр килгәчтен, алар качты далага.

Армияне җыйдырып, сайлап-сайлап алдылар,
Без сугышка кергәндә, куанышып калдылар.

Дүрт-биш кердек сугышка, каннар билдин актылар,
Сугышларны бетергәч, безгә медаль тактылар.

Французның атлары бар да ефәк тышаулы,
Французның солдатлары әфисәргә охшаулы.

Тирән суның эчендә озын-озын камышы,
Унике патша эчендә бер француз тавышы.

Наполеонга тәхет кирәк, үз җиренә сыймаган,
Без Мәскәүгә кергәчтен, ул да үзен сынаган.

Французлар монда килгәч, таныдылар үзләрен,
Унда — башкорт, сулда — типтәр, табалмыйдыр эзләрен.

Французның илләре, түгәрәк икән күлләре,
Французларны куганда, үттек без күп илләрне.

---

* Бәет кыскартып алынды.

[1] *Атым* — исемем.

Французның атлары кырын җирдә дулыйдыр,
Башкорт белән типтәрләр французны турыйдыр.

Башкорт, типтәр уклары, туры бәрә күпләре,
Без сугышта күргәннәр әле монда бетмәде.

Мәскәүгә дә кердек без, Наполеонны күрдек без,
Французны җиңгәндә, җир җимереп йөрдек без.

Французны кудык без, үз иленә сөрдек без,
Французларны куганда, күп суларны йөздек без.

Наполеонның эшләпәсе канга тапланган иде,
Без сугыштан кайтканда, илләр шатланган иде.

Бу бәетне язган чакта, каләмнәр камыш иде,
Өйгә керсәң, тышка чыксаң, шатлыклы тавыш иде.

Әбелмәних Каргалый

(1782—1833 елдан соң)

ҮЗЕ ТУРЫНДА*

Шәһре Каргалы[1] — фәкыйрь(н)ең мәүлиди,
Өммәте — Әхмәд, рәгыяте — Мәскәви,
Атасы — Әбелфәез, җәдде — бәнам:
Дәүридә остазы көлл Габдессәлам.
Бәндәи Хакның миянында сарих
Кәмтәранә бәндәсе Әбелмәних.
Кыйсмәтен Хак әйләмешде интишар,
Бу сәбәпдин сәйр идебде чук дияр.

Тәрҗемәсе:

Фәкыйрьнең туган җире — Каргалы бистәсе,
Өммәте — Мөхәммәд, үзе — Мәскәү иле кешесе,
Атам — Әбелфәез, атаклы булган бабам:
Дәверендә тулы остаз диелгән Габдессәлам[2].

---

* Өзекләр «Тәрҗемәи хаҗи Әбелмәних Әл-бистәви Әс-Сәгыйди» («Сәгыйть бистәсенең Әбелмәних хаҗи тәрҗемәләре») китабыннан (1845, 1889) алынды, исемнәр төзүче-тәрҗемәче тарафыннан куелды.

[1] *Шәһре Каргалы* — XVIII гасыр урталарында Оренбургтан ерак түгел төзелгән Сәгыйть бистәсе. Соңга таба аны Каргалы дип атый башлыйлар.

[2] *Габдессәлам Уразмөхәммәд* (Урай) улы Казан өязе Олы Мәңгәр авылыннан. Танылган укымышлы була. Беренче күченүчеләрдән булып, Сәгыйть бистәсенә килеп урнаша, бистәнең беренче имамы һәм мөдәррисе була, ахун дәрәҗәсенә күтәрелә.

Хак коллары арасында бик кечкенә һәм нәни,
Түбәнчелек-кимчелекле бәндәсе Әбелмәних.
Ризыгын чәчкән Ходай күп җирләргә,
Шул сәбәпле йөрде ул күп илләрдә.

ТУГАН ИЛ

Тәрҗемә

Туган илне сагыну һич китми икән,
Кайтам илемә, аңа җитми икән,
Ватан мәхәббәте иманнан ул,
Ир-хатынның үлгәнче саклаган тойгысы шул.

СӘЯХӘТЛӘРДӘН КАЙТКАНДА

Тәрҗемә

Үкенмә үткәнгә, киләчәк өчен хәсрәт чикмә син:
Йөреп җирнең күп илләрен, тамашасын күрдең син!

ӘСИРЛЕККӘ ТӨШКӘН ДУСТЫ — КАЗЫЙ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

Бәндә дөшмәк илә динелмәз хәкыйрь,
Аһәнин кайд(г)а дөшәр, әлбәттә, шир,
Хәр илә хинзирә улмаз игътибар,
Зәнҗерә дөшмәктин улмаз ширә гарь.
Бәр-карар улмаз җиһанның кәрд-эше:
Гяһ бәләнд, гяһ пәст улыр бонда кеше.
Кәтмәян дәүләт ирер гыйльме кәмал,
Гяһ кәлер, гяһа кәдисәр җаһ-у-мал.

Тәрҗемәсе:

Бәндә бәлагә төшкән икән, хурлык саналмас,
Тимер богауга төшкән, әлбәттә, арыслан булыр,
Ишәк белән дуңгызга игътибар булмас,
Чылбырга төшүдән арысланга гарьлек булмас.

Бер көе генә тормас дөньяның эше:
Бер югары, бер түбән булыр кеше.
Бетмәс дәүләт булыр камил гыйлем генә,
Мал-дәрәҗә бер килер дә бер китәр.

МӨНАҖӘТ

Җиһанның җаһ-малы нәфсә гаять тә хәсәндер бу,
Вәли мәгънан җәһәннәм суигә каид рәсәндер бу.
Үзене дөхтәре душизә кеби күстәреп дөнья,
Фәрифтә әйләян чукларны мәккяр пирәзәндер бу.
Гарусы нәү идеп кәнден, нәчә дөрлү вireп тәзиин,
Нәчә данаи даминә грифтар әйләяндер бу.
Буның мәкер илә аленә ирүрмәз фикре фазыйльләр,
Нәчә галимнәр(н)ең гыйльмен һәбая иргезәндер бу.
Буның тәзвиренең бере беренә биңзәмәз һәргиз,
Нәчә заһидләр(н)ең әгъмалене бадә вирәндер бу.
Буның җаһы илә малына гаҗәп алданамы гакыйль?
Сәрасәр робгы мәскүнне дотанлардин кичәндер бу.
Әя мескен Мәних, өммә сафа бу би вафадин сән,
Сөрүрең беренә бең җәфа бәхеш әйләяндер бу.

Тәрҗемәсе:

Дөньяның мал-дәрәҗәсе нәфсегә күркәмдер ул,
Әмма безне җәһәннәмгә сөйри дә кертәдер ул.
Үзен чибәр яшь кыз кебек һаман күрсәтә дөнья,
Әмма күпләрне алдаган мәкерле корткадыр ул.
Яшь килен кебек төзәнеп, ничә төрле бизәнеп,
Ничә галимне алдалап, бушка йөрткәндер ул.
Ирешмәс гаклы күпләрнең моның хәйләләренә,
Ничә галимнең гыйлемен тузан күк кылгандыр ул.
Моның ялганы, алдавы охшамас бер-берсенә,
Ничә изгенең гамәлен җилгә очыргандыр ул.
Дөнья малы, дәрәҗәсе — барсы да ялгандыр ул:
Җир йөзен иңләп биләгән затлардан калгандыр ул.
Әй мескен Мәних, көтмә рәхәт бу игелексездән,
Бер шатлыкка мең җәфа бүләк иткән дөньядыр ул.

* * *

Бөтен дөнья бәнем булса, гамем бетмәс, нәдәндер бу?
Әзәлдә[1] гамь торабыйлә[2] яратылмыш бәдәндер[3] бу.

СӘХРАДА

Ошбу көн вармыш идем сәйран өчен сәхрә тараф,
Күп гүзәл улмыш чәмәннәр[4], лаләзар улмыш шорыф[5].
Бер тарафда күке «кәк-кук» дәюбән налан идәр[6].
Әһле дәрднең һушыны гарәт идәр, талан идәр[7],
Суфый тургайлар дәмадәм[8] күкләрә җәүлан идәр[9].
Бүдәнә йирдә торып, үрдәк суда тайран идәр[10].
Торналар тормаз, очар, казлар карар итмәз, качар,
Былбыл диваналар гөлләр өчен йәшен сачар.
Күл эчендә бакалар «бак-бак» дәю җәүлан идәр,
Бер тарафдан дәхи тартай «тарт» дәю налан идәр.
Үлән эчендә чикерткә төрле авазын чалыр,
Черки илә суйры чебен тызлаеп мазаң алыр.
Һәрбере нәгъмә нәвасене кыйлыб[11] сазын чалыр,
Сәрүкад дилбәрләрең[12] кальбендәге назын алыр.
Шуйлә дилкәш[13], буйлә хөррәм[14] монча гыйззәтле һава,
Бәс моның дәк дилкәшадә чикмәсеннәрме нәва![15]

---

[1] *Әзәлдә* — мәңгелектә.

[2] *Торабыйлә* — туфрагы белән, туфрагыннан.

[3] *Бәдән* — тән, гәүдә.

[4] *Чәмән* — үлән, болын.

[5] *Лаләзар улмыш шорыф* — чәчәкләргә күмелгән чак җиткән.

[6] *Налан идәр* — кычкырыр.

[7] *Гарәт идәр, талан идәр* — талап алып китәр, ирексездән һуштан яздырыр.

[8] *Дәмадәм* — һәрвакыт, бертуктаусыз.

[9] *Җәүлан идәр* — күтәрелер.

[10] *Тайран идәр* — очып йөрер.

[11] *Нәгъмә нәвасене кыйлыб* — матур авазларын чыгарып.

[12] *Сәрүкад дилбәрләрең* — нечкә билле матурларың.

[13] *Шуйлә дилкәш* — күңелне шундый үзенә тартучы.

[14] *Хөррәм* — шатландыргыч.

[15] *Бәс моның дәк дилкәшадә чикмәсеннәрме нәва* — моның кебек хозурлыктан ничек соң аваз бирмәскә, җырламаска!

Һибәтулла Салихов
(1794—1867)

ӘБЕЛМӘНИХНЕҢ «ТӘНДӘ ҖАНЫМ...» ШИГЫРЕНӘ
(өзекләр)

Тәндә җаным ничә көн миһман[1] икәндер, белмәдем,
Үтте гомрем, барысы — хосран[2] икәндер, белмәдем.
Дөньяда төздем гыймарәт[3] бары наданлык белән,
Бу гыймарәт һәммәсе җимрек икәндер, белмәдем.
Хабы гафләттән[4] күземне ачмадым, төнлә торып,
Төнлә торган бәндәләр солтан икәндер, белмәдем...
Хабы хурдан[5], ләззәтеннән гомреми кыйлдым тәләф[6],
Гүрдә юлдаш вә тәгать[7] иман икәндер, белмәдем.
Хөббе дөнья[8] илә кальбем мәел итмеш би гөман[9],
Дөнья сәүмәк — ширбәте шайтан икәндер, белмәдем...

---

[1] *Миһман* — кунак.
[2] *Хосран* — үкенеч.
[3] *Гыймарәт* — төзелеш, корылма.
[4] *Хабы гафләттән* — ваемсызлык йокысыннан.
[5] *Хабы хурдан* — йокы һәм ашау-эчүдән.
[6] *Кыйлдым тәләф* — әрәм иттем.
[7] *Тәгать* — Аллага буйсыну, гайбадәт кылу.
[8] *Хөббе дөнья* — дөньяны сөю.
[9] *Кальбем мәел итмеш би гөман* — күңлем биләп алынган уйламыйча.

Һич кеше дошманына кылмас җәфаны җаныма
Кәнду[1] нәфсем ул кадәр кыйлган икәндер, белмәдем...
Күзләдем туй-тамаша, һәзле-һәзьян мәҗлесе[2],
Бәңа хаҗәт — мәҗлесе гыйрфан[3] икәндер, белмәдем...

«МӘҖМӘГЫЛ-АДАБ» («ӘДӘПЛӘР ТУРЫНДАГЫ ҖЫЕНТЫК») китабыннан

(өзекләр)

Тәрҗемә

Замана хакиме[4] охшар еланга:
Яшертен дошманлык саклар уенда.
Еландай ялтырый тыштан күргәндә,
Һәлаклек кылыр ул, форсат йөргәндә.
Хатаңны белсәләр бер-бер эшеңдә,
Сүзеңдә, гамәлеңдә, йөрешеңдә,
Хатаңны — белеп эшләүгә юрарлар,
Бәхәссез, хәтәр эш бу дип санарлар.
Төпченеп, дикъкать белән тикшерерләр,
Булмаганны бар итеп тик йөрерләр.
Тузан күрсә, аны чебен дип саный.
Чебен күрсә, бу — каракош, дип яный.
Төпченүнең максаты — динар[5] алу,
Исендә юк мазлумнарга яр булу[6].
Кулларына берәр нәмәрсә төшсә,
Дирһәм[7] йә динар кебек акча булса,

[1] *Кәнду* — үз, үземнең.

[2] *Һәзле-һәзьян мәҗлесе* — уен-көлке, күңел ачу мәҗлесе.

[3] *Мәҗлесе гыйрфан* — мәгърифәтле, укымышлы кешеләр мәҗлесе.

[4] *Замана хакиме* — патша түрәләре, хакимият иясе, чиновниклар.

[5] *Динар* — алтын акча.

[6] *Мазлумнарга яр булу* — җәберләнүчеләргә, изелүчеләргә дус, ярдәмчел булу.

[7] *Дирһәм* — көмеш акча.

Шул минутта ук ачуы басыла,
Хөкем туктый, тел бәйләнә, йөз ачыла.
Тау кадәр гайбен күрсә, телгә алмас,
Зур җинаять бернигә хисапланмас.
Гаеп эш берлә бер кемсә тотылса,
Каршысына боларның китерелсә,
Гаепледән акча, әйбер алырлар,
Сүз куертмастан аны коткарырлар...
Әгәр чыкса алар бер-бер сәфәргә,
Йә патшаның бер хезмәтен үтәргә,
Йә бер яшерен эшне тикшерергә,
Йә бер байда кунак булып типтерергә,
Һаман ил өстенә салып җәфалар,
Йөрерләр күп, чигеп кәеф-сафалар.
Фәкыйрьнең күбеседер ялгыз атлы,
Башында төрле михнәт, кайгы каты.
Ат-ияре, кораллары бик начар.
Шаһ хезмәтен көчкә үти, бичара.
Ашау-эчү вә кием — бар да кирәк,
Кайсы егълап итәр Хакка гыйбадәт.
Керешер ул кайчан берәр кәсепкә,
Арендалау йә сәүдә кебек эшкә.
Бу эшләр дә уңышлы тәмамланмый,
Шатлыкка ирешергә мөмкин булмый.
Күрер, белер бу хәлне ул түрәләр,—
Һаман үз максатына җилдерәләр.
Үз маллары кырда йөри караусыз,
Игенчегә зыян сала санаусыз.
Җигәрләр ул фәкыйрьнең ялгыз атын,
Уйламастан һич эше югын-барын.
Чабарлар илдән илгә бик зур булып,
Фәкыйрь калыр сүгелеп вә хур булып...
Каршысында тотар үрә каратып,
Боерыр эшләрен, хөкмен таратып.

Аның хөкемен китерми җиренә,
Мөмкин түгел каршы килү беренә...
Бер эштә син тыңламасаң аларга,
Юлыгырсың һич бетмәс бәлаларга...
Әйе, дибез, аларның хөкме җиңә,
Көчләп алып малың, үзеңне җигә.
Бу бәланең әмма бер чиге булыр,
Килеп җиткәч соңына газиз гомер.

* * *

Олуг димә, кечек димә, би кибар[1],
Нә кем гаҗизне[2] күрсәң, әйләгел яр[3].

* * *

Кирәк син — ибне солтан, хуҗазадә[4],
Үзеңне күрмә һичкемнән зиядә[5].

* * *

Әгәр сөйсә залимне бер мөселман,
Булыр, шиксез, аның динендә ноксан[6].

* * *

Берәр түрә килде исә иленә[7],
Чакыртыр, баглап кылыч биленә.

* * *

Зарури булса сәңа әгәр сүз,
Кирәк микъдары сүзлә, артыгын өз.

---

[1] *Би кибар* — тәкәбберләнмичә.
[2] *Гаҗиз* — җәфа чигүче, көчсез.
[3] *Әйләгел яр* — дус ит, ярдәм күрсәт.
[4] *Ибне солтан, хуҗазадә* — солтан, патша улы.
[5] *Зиядә* — артыграк, өстенрәк
[6] *Ноксан* — кимчелек, җитешсезлек.
[7] *Иленә* — «авылга, яшәү урыныңа» мәгънәсендә.

* * *

Әдәпсезлеклә[1] иман бергә тормас,
Әдәп берлә имансыз һәм бакый калмас.

* * *

Гаса[2] кеби, аяксызга аяк бул,
Олуг юлдыйн адашканга маяк бул.
Гаса кеби, батып балчыкка, карга,
Рәфикың[3] куймагыл юлдыйн чыгарга.

---

[1] *Әдәпсезлекл*ә — әдәпсезлек белән.
[2] *Гаса* — таяк.
[3] *Рәфикъ* — иптәш, юлдаш, дус.

Шәмседдин Зәки

(*1821—1865*)

* * *

Һай, нә оерсән[1]?! — Уян, йөз мең хәтәр җаныңдадыр!
Күңлеңе гыйшык илә дөргез кем, үлем — яныңдадыр.
Һай, сакын[2]! Бу нәфсе әлендән эчмә гафләт[3] ширбәтен,
Тәңре хакы кем, һәлакең — ошбу дошманыңдадыр.
Вирмә күңелең сандыгын шайтан әленә кем, аның
Касды[4] — иманыңда вә җаныңда вә каныңдадыр...

* * *

Бу сүз(н)е кәгазь(г)ә язмак кирәкдер,
Бу дөрре[5] бер йебә тезмәк кирәкдер.
Вафасызлык[6] — бу дөньяның эшедер,
Вафасыз нәснәдән бизмәк кирәкдер.
Бакөлли[7] хакка йөз тотып һәмишә,
Бу батыйльдән[8] күңел өзмәк кирәкдер.
Сафа вә нигъмәтә ирмәклек өчен,
Җәфа вә михнәтә түзмәк кирәкдер...

---

[1] *Нә оерсән?* — Ник йоклыйсың?
[2] *Сакын* — саклан.
[3] *Гафләт* — ваемсызлык.
[4] *Касды* — явыз (начар) нияте, теләге.
[5] *Дөрре (дөррне)* — энҗе бөртекләрен.
[6] *Вафасызлык* — ышанычсызлык, вәгъдәсезлек.
[7] *Бакөлли* — тулысынча, бөтен барлыгың белән.
[8] *Батыйль* — бозык, әшәке.

Исеп җил дик, агып су дик, тәмамәт,
Бу юлда ут кеби кызмак кирәкдер.
Ходага гарзы, хаҗҗәт[1] вә мөнәҗәт
Кылыб, күз яшен агызмак кирәкдер.

* * *

Эстәсәм[2], галәмдә сән дик яр булгай-булмагай,
Булса булгай, сән кеби гамьхар[3] булгай-булмагай.

Бу җиһанның шәһренең базарының сәүдәсе күп,
Кыл бу сәүдәне, янә базары булгай-булмагай.

Ат сәнең астыңдадыр, йөргел, бу йирнең хәдден ал[4],
Нагяһан[5] ул ат сәнең астыңда булгай-булмагай.

Карчыга кулыңдадыр, аула бу күңлең шәһрене[6],
Нагяһан ул карчыга өндәүгә килгәй-килмәгәй!

Җан илә иман, икәүләб, бер өйдә бал эчәр,
Нагяһан ул икесе бер өйдә булгай-булмагай!

Та терек[7] сез, дусларым, бер-береңә гыйззәт кылың[8],
Ваһ, бу үлем! Үзгә дәм[9] нагяһ булгай-булмагай.

Хафиза[10]! Ширин кәлам[11] сүзлә, телеңнең барында,
Нагяһан, килсә әҗәл, тел сүзгә килгәй-килмәгәй!

---

[1] *Гарзы, хаҗҗәт (кылыб)* — үтенечләреңне, йомышларыңны әйтеп.

[2] *Эстәсәм* — эзләсәм, теләсәм.

[3] *Гамьхар* — (минем өчен) борчылучы, кайгыртучы.

[4] *Хәдден ал* — чиген ал, чигенә чык.

[5] *Нагяһан* — кинәт, көтмәгәндә, искәрмәстән.

[6] *Аула бу күңлең шәһрене* — (тыңлаучы карчыга кулыңда чакта, ягъни көч-ихтыярың барында) күңелеңне юк-бар бозык уй-ниятләрдән тазарт, аулап тор.

[7] *Та терек* — тере-исән чакта.

[8] *Гыйззәт кылың* — ярдәм ит, яхшылык эшлә.

[9] *Дәм* — вакыт (очрак, мөмкинлек).

[10] *Хафиза* — китапларны яттан белүче (шулай дип, шагыйрь үз-үзенә дәшә).

[11] *Ширин кәлам* — татлы сүзләр.

Габделҗәббар Кандалый

(1797—1860)

МУЛЛА БЕЛӘН АБЫСТАЙ

Тотынышып кулың кулга,
Үзең кергән сары тунга,
Кая киттең болай, хәзрәт,
Абыстайны салып уңга?

Үзең түргә утыргансың,
Авызыңны тутыргансың,
Төгәл кәефне коргансың,
Абыстай утырып уңга.

Синең өчен тавык чалган,
Суган, балтырганын салган,
Син әйткәч, чакырып алган,
Егермесен сатып унга.

Качырма син бу форсатны,
Чәеңә сал бавырсакны,
Тутыр бик яхшы корсакны,
Икенче калмасын соңга.

Сиңа атап тавык суйгач,
Ашап-эчеп тамак туйгач,
Кесәгә ун тиен куйгач,
Чәй эчеп төн буе кунма.

Ләкин, мулла, онытма син,
Бу ашларга кызыкма син,
Ки алдыңа сызыкла син,
Мужиклар да бизәр соңра.

Савыт-саба ышылдамас,
Бу коймаклар чыжылдамас,
Дәхи хәлвә хышылдамас,
Ки, акча юк, ди-ди, онга.

Абыстай да сөйми башлар,
Катаңны өстеңә ташлар,
Чытык йөзләр, түбән кашлар,
Чакырмыйлар нигә шунда?

Торып иртә битең югач,
Ашык-пошык намаз кылгач,
Берәр ашка баруны син
Үзеңә зур бәхет сандың[1].

Абыстай берлә икәүләп,
Мужикның сыртын игәүләп,
Тавык, күркә, казын ашап,
Ки кайтып йокыга талдың.

Тавык төштә тары күрә,
Синең дә ашларың керә,
Йокыңда сөйлисең нигә:
— Абыйстай, чык, кеше керә!

Чакыручы түгел икән,
Бу бары төш кенә икән,
Күп ашап, саташып шулай
Төшеңдә сөйлисең икән...

* * *

Катаң бозга катып беткән,
Ки чаңгыдай шуып киткән,
Абыстайны да син сөйрәп,
Кай арада барып җиткән?!

* * *

Агайга син сада салдың[2]:
— Өйдәме? — дип хәбәр алдың.
Икәү бергә йөреп ашка,
Гомергә көлкегә калдың.

ОНЫТМАМ СЕЗ НАДАННАРНЫ!

Бу илләрдә[3] торып калсам,
Ярамас кызга күз салсам,
Атамның каргышын алсам...
Качыйм тизрәк бу илләрдән!

Арысландай егет иргә,
Батып бетсә дә кан-тиргә,
Чит илләргә, ерак җиргә
Качу әүла[4] бу илләрдән.

Сөеп бу илгә килсәм дә,
Ки юрга кеби йилсәм дә...
Бөтен вөҗүдем[5], ил, сәндә,
Нигә тиз мине ятсындың?

Туган илем ерак калды,
Җәяү йөреп сыйрак талды,
Тагы бигрәк йөрәк янды...
Әзәлдәген[6] ник азсындың?

---

[1] *Сандың* — санадың.
[2] *Сада салдың* — тавыш бирдең, хәбәр җибәрдең.
[3] *Монда: ил* сүзе «билгеле бер як, урын, авыл» мәгънәсендә.
[4] *Әүла* — яхшырак, өстенрәк.
[5] *Вөҗүдем* — бөтен барлыгым, җаным-тәнем.
[6] *Әзәлдәген* — мәңгелектәгене, чиксезлектәгене.

Бу илнең һич чиге юктыр,
Биниһая[1] адәм чуктыр[2],
Бере ач юк — бары туктыр...
Нигә соң миңа тарсындың?

Тарсынма бер дә, китәрмен:
Җен, Иблистән дә битәрмен,
Үз белгәнемне итәрмен,
Ки әгъля-гаршә[3] ашкындым!

Миңа бердер кая булсам,
Баг алмадай пешеп тулсам,
Ки соңрадин шиңеп сулсам...
Шуныңчөн сәңа гарьсендем.

Кусагыз да, һич уфтанмам,
Язуымнан да тукталмам,
Котылмассыз барыбер сез,
Әле болай гына калмам!

Төреп чалма-чапаннарны,
Йөресәм кыр-япаннарны,
Онытмам сез наданнарны,
Элеп салмыйча һич калмам!

САХИБҖӘМАЛ

(*поэмадан өзекләр*)

I

Сәңа, җаным, дога иттем,
Дога илә сәлам әйтдем,
Сәламнәрнең соңы, җанкәм,
Язып гозре кәлам иттем[4].
Сахибҗәмал, чибәрем лә,
И матурым, сөярем лә,
И белмәдем нидәрем лә,
Сагышыңны мөдам иттем[5].
Сөеп, күңлем дә бизә алмай,
Гыйшкың берлә түзә алмай,
Өмидемне өзә алмай,
Ике-өч ел чыдам иттем.
Болай торганча тик качып,
Күренгел бер күңел ачып,
Агыздин энҗеләр сачып,
Сөйләш дәю бәян иттем.
Гүзәл сән алтын алмадый,
Җәмалең[6] күңлем алдадый,
Түзәр хәлем дә калмадый,
Алай да күп чыдам иттем.

---

[1] *Биниһая* — чиксез, иге-чиге булмаганча.

[2] *Чуктыр* — күптер.

[3] *Әгъля-гаршә (гарешкә)* — күкнең иң югары катлавына, биеклеккә.

[4] *Гозре кәлам иттем* — утенеч сүзе әйттем.

[5] *Мөдам иттем* — озак вакытлар, дәвамлы кичердем.

[6] *Җәмалең* — матурлыгың, гүзәллегең.

II

Гүзәлсән бик — Параудa[1] бер,
Күңелләргә ярауда бер,
Матурсән — күз карауда бер,
Дәхи сөйләргә телләрдә.
Ирәм багындамы[2] үстең?—
Йөрәгем бәгърене кистең,
Сәба йиле[3] кеби истең
Ки сахраларда, чүлләрдә!
Мәхәббәтең лә дәрдеңдин,
Сәнеңчөн, сәнең артыңдин
Парау иленә бардым мин,
Елап-сыктап сәбилләрдә[4]...
Нәсыйхәтдер сүзем, уйла:
Җәмалең кадрене җуйма,
Надан иргә барып, койма
Газиз гомреңне йилләрдә.

III

Килә белмәсәң, и җанкәм,
Бәнем дик мелла гашыйкка,
Барырсың... юмаган
Надан бер кара мажикка.
Намаздан каты бизгәне,
Эшендин белмәс үзгәне,
Иман дәюб дә сүзләми —
Тоташлай бара языкка...
Эш эшләп унике аең,
Гомер буең, кышын-җәен,
Сызып бетеп йөрәк маең,
Каның да калмый кашыкка.
Кыекча башыңа чорнап,
Урырсың лабаса ерлап,
Кулың, битең камыл тырнап,
Юлыгып билчән ашлыкка...

* * *

Мажик ир булса юлдашың,
Күзеңдин китмәгәй яшең,
Гакыл йитмәй, азат башың
Үзең салдың ла коллыкка!
Гүяки бер бояр колы,
Боярның әмре аркылы,
Эш эшләп, кабарып кулы,
Саладыр акча оброкка...
Бу хәл илә гомер буйлай,
Кулыңдин эшләри куймай,
Йөрерсең, тамагың туймай,
Ки бәгъзе чакта ачлыкка.
Борынгылар шулай димеш:
Балыкчының асты юеш,
Тамагы ач булыр, имеш,
Тоташ йөрсә дә балыкка.

* * *

Сука белән сабан сөреп,
Тузан-туфрак үзә йөреп,
Каралубән килер кереп...
Изеп, атына болгатып,

---

[1] *Парау* — Сахибҗамал авылының исеме. Хәзерге Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс районында.

[2] *Ирәм багы* — Көнчыгыш риваятьләрендә сөйләнгән гаять гүзәл бакча, җир өсте җәннәте.

[3] *Сәба йиле* — йомшак җил, таң җиле.

[4] *Сәбилләр* — юллар, олы юллар.

Арыдым, дип, тиз ук ятып,
Оеса, булмас уйгатып,
Башын бер куйса ястыкка.
«Сукаладым, парладым» дир,
«Уалдым» дир, «арыдым» дир,
«Каты йиргә тарыдым» дир,—
«Сарутка» йә «тамырлыкка».
Көне-төне кулың эштә,
Үзең зур, каты тел-тештә,
Рәхәт күрәлми бер төштә
Тыныч йокларга тансыкка...

V

Парау илендә төш күрдем,
Ки бер кош тоттым, ук аттым,—
Парау илендә бер матур
Өчен уйкумны югалттым.
Ничә кемсә, ничәләрдә,
Ашыйлар да, эчәләр дә;
Ки бән шул көн-кичәләрдә
Аш үтмичә, елап яттым.
Сезә булдым барыр кеби,
Сәңа юлда тарыр[1] кеби,
Сөеп-кочып арыр кеби,—
Хыял дәрьясына баттым...

VIII

Әгәр дә меллага барсаң,
Сәнең урның булыр түрдә,
Күреп дөньяда күп файда,—
Кыямәттә ки һәм гүрдә.
Торып яхшы гурничәдә[2],
Тәмам гомрең буенча да
Сөешмәктә, уенчада,
Пошына белмәссең бер дә.
Кичә-көндез бизәнмәктә,
Киенмәктә, төзәнмәктә,
Булып күркәм, чибәрлектә,
Торып мелла-галим ирдә.
Аягыңда читек-башмак,
Башыңдадыр ки ак калпак,
Мамык яки ефәк калпак,
Ки һич тә кунмаган кер дә...
Ничек тә хәтрең екмас,
Уракка һәм алып чыкмас,
Кояш илә һава сукмас,
Пешекмәс һәм тәнең тирдә.
Уен-көлкедә ялыксаң,
Торып бер төштә ябыксаң,
Атын җигәр, әгәр чыксаң,—
Йөртер сәне һәр йирдә...
Галимдән хуб бала туар,
Галимлек сәңа һәм йогар,
Догачы булалар болар,
Үзең ятсаң да һәм гүрдә.
Балаларның балаларый
Укытырлар һәм аларый,
Догачы булалар барый,—
Кирәк кыз да, кирәк ир дә...
Чыгарма, җаный, бу серне,
Безем бу меллалык йирле[3],—
Ки йите бабадин бирле
Килеп өзелмәгән бер дә.

---

[1] *Тарыр* — очрар, туры килер.
[2] *Гурничә* — (горница) зур, якты, «ак» өй.
[3] *Йирле* — җирле, ягъни нык нигезле.

IX

И алтыным, бәян әйлә:
Сүзем кабул итәрмүсән?
Шулай тилмертебүк әллә
Бүтән ярга китәрмүсән?!
Бу үзсүзле мишәр, диеп,
Ки бер сүзне бишәр, диеп,
Уңга таба ишәр, диеп,
Ки сән сулга сүтәрмүсән?..

X

Сәба йиле, исәр булсаң,
Парау атлыйг нәфис җайга[1],
Сәламемне тикергәйсән
Сахибҗәмал абыстайга!
Диеп: «Кандалда бер хәзрәт,
Сәңа гыйшкы төшеп кәсрәт[2],
Кичә-көндез чигеп хәсрәт,
Янып көядер, ай-һай ла...»
Гөлем бул, гөл егачым[3] бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәрдемгә гыйлаҗым[4] бул,
Сахибҗәмал абыстай ла.
Сәнең илә аем-көнем,
Сәнең илә көнем-төнем,
Сәнең илә төшем-өнем
Үтәдер, и абыстай ла!

* * *

Берәү карышты Борнайда[5],
Тик үк кайтты да тормай да,
Елыйдыр, дәхи ерлай да,
Булып мәгъмум, булып
мәхзүн[6]...

XII

Аның кеби була күрмә,
И тумачи, тудык кына:
Ки без аңа явыз каргыш
Догасын укыдык кына.
Эше ирде ки элгәре,
Соңындин булды тискәре,
Күрәнләр китте исләре,—
Гаҗәп шәүкый, чудук кына![7]
Ире бик әйләде каһри,
Елан кеби сачып зәһри,
Ки тәгъзиб әйләде[8], дәһри[9],

---

[1] *Нәфис җайга* — нәфис, матур урынга, авылга.

[2] *Кәсрәт* — артык, бик көчле.

[3] *Егач* — агач.

[4] *Гыйлаҗым* — чарам, даруым.

[5] *Борнай* — авыл исеме. Хәзер — Татарстанның Әлки районындагы Татар Борнае авылы. Сүз шушы авыл кызының кияүгә чыккач күргән җәфалары турында бара.

[6] *Мәгъмум, мәхзүн* — күңелсез, кайгы-хәсрәтле.

[7] *Гаҗәп шәүкый, чудук кына* — мәхәббәт әкәмәте, (чудо) могҗиза үк кына.

[8] *Тәгъзиб әйләде* — газаплады.

[9] *Дәһри* — динсез, имансыз.

Булып агъзы тулук кына.
Көне-төне дә сугышты,
Яла ябып, ләкаб[1] кушты,
Ки пошмам дисә дә пошты,—
Килешмәде шул ук кына!
Кыйныйдыр иде фәрманга,
Түзалмый монча дәрманга,
Качып китәрде[2] урманга,
Йөгерүбән турук кына.
Пүнәтәйләр билә табып,
Кыйнарде китереп, җабып,
Орып, яңагына чабып,
Сүгеп-хурлап ул ук кына.
Тотып, чормап сач үрмәсен,
Ашатты камчы җөрмәсен,
Ки дошманың да күрмәсен,—
Ки ул икән шул ук кына.
Тәнендин яра китмәде,
Күзендин кара бетмәде,
Морад-максудка йитмәде,
Ки һичшиксез, чын ук кына.
Ки һәр кыен[3], сугыш артын,
Барып мәгълүм итәр сартын[4],
Чакрып сутник, авыл картын[5],
Елады ул тудык кына.
Агып күз яшьләре чишмә,
Ике күзе булып шешмә[6],—
Сән аның көненә төшмә,
Ишет, аңла, тудык кына...

* * *

Сөяген тоз кеби уып,
Ки борнын кан илә юып,
Йибәрде ахыры куып,—
Ки Борнайга турук кына.
Ни биргән акчасын алды[7],
Бушатты, үзендин салды[8],
Бер үксез баласы калды
Елап — күңле сынык кына.
Баласы өстенә бакып,
Күзендин яшьләре акып,
Елады йөзтүбән ятып,
Туянча берьюлук кына.
«И бәбкәм, бала сән, дәюб,
Ятим лә каласән, дәюб,
Бәне утка саласән, дәюб,
Гомергә, и сынык кына!»
Бер анфалит[9] кеби кайтып,
Ике битене саргайтып,
Ике күзене акайтып,
Утырадыр толук кына...

---

[1] *Ләкаб* — кушамат.
[2] *Китәрде* — китәр иде.
[3] *Кыен* — кыйнау.
[4] *Сартын* — өчен.
[5] *Сутник, авыл карты* — сотник, староста (ул замандагы авылда тәртип сакларга тиешле кешеләр).
[6] *Шешмә* — шешенеп.
[7] *Ни биргән акчасын алды* — өйләнгәндә кыз өчен түләнгән калым турында сүз бара.
[8] *Үзендин салды* — үзеннән ташлады.
[9] *Анфалит* — инвалид.

XVI

Сәңа гыйшык төшеп, җанкәм,
Тотып шәукате зәукатьләр[1],
Тәмам дүрт ел елап-сыктап,
Ки заигъ итдем әукатьләр[2].
И бу дүрт ел! И бу дүрт ел!
Ки һәр сәгате дә — дүрт ел!
Җаныма йибәрә ут ул,
Китәрә җөмлә тәкатьләр!

* * *

И-и, и генә лә, и генә!
Ни булды мәңа, ни генә?
Эшемдә юк ла көй генә,
Никадәр язамын хатлар!
Ничә кәррә[3] язам пуштым[4],
Сәңа тигермәгә куштым,
Хатым йитмәдеме, дустым,
Йә килешмәде сәгатьләр?!

XX

Һаваланмакың, и Биби[5],
Ки һич тә файдасыз зиби[6],
Ки бән дәхи сәнең кеби
Һаваландым, и җанкәй лә.
Үземә тапмадым тиңне,
Тик эстәп кашкалы-миңле,
Юлыктым аңлы да миңле
Җуләр ярга, и җанкәй лә.
Отыйм дигәндә — отылдым,
Тотыйм дигәндә —
тотылдым,
Соңындин көчкә
котылдым —
Ки биш ел соң, и җанкәй лә!
И-и, и генә лә! И генә!
Эшем дә булды чи генә!
Сәбәп кенәсе ни генә,—
Бәян итсә, и җанкәй лә!
Бу нидән булды чи генә?
Эшем дә йитде чигенә,
Сахибем кире чигенә,—
Исем китәр, и җанкәй лә!

* * *

Утырып саба йиленә,
Очардем[7] Парау иленә,
Куеп кулымны биленә,
Кысып Сахибҗәмалемне.
Билең нечкә — кысыйм
дисәм,
Буең зифа — кочыйм дисәм,
Сәңа таба очыйм дисәм —
Кирәк баде[8] Сөләймани...

---

[1] *Шәукәте зәукатьләр* — зәвыклы сөешүләр.
[2] *Заигъ итдем әукатьләр* — бушка вакытлар уздырдым.
[3] *Кәррә* — тапкыр, мәртәбә.
[4] *Пуштым* — почта белән.
[5] *Биби* — Сахибҗәмалның исеме Бибисахибҗәмал булган, күрәсең.
[6] *Зиби* — бизәк, зиннәт.
[7] *Очардем* — очар идем.
[8] *Баде* — җиле.

XXIII

Төшемдә Парау илендә
Ки тайран итдем[1] — очмакта,
Барып, анда сәнең илән
Ки сәйран итдем оҗмахда...
Йөзеңә йөземи сөрдем,
Сәнең лә күп сафа сөрдем...
Уяндым — үземи күрдем:
Ятамын өйдә почмакда!..

XXIV

Йөзең алсу кызыл гөлтик,
Яңагың кызыл алматик;
Кызыл алма кеби кызны
Нәсыйб итәр микән Алла?
Кашың кара тумышыңдан,
Битең һәм якты гөлбөстан,
Сәнеңтик зифа җан дустан
Аермасын кәрим Алла!..

БУ ХӘСРӘТЛӘР БЕТӘР МИКӘН?

Сәбах эчрә[2] ки йилләрдин
Киләдер илгә илләрдин.
— Хәбәр көтәм
туганнардин,—
Дәюб сорам[3] ки анлардин.

— Әя йил, сән белермүсән?
Туганнарым күрермүсән?
Хәбәрләр килтерәрмүсән? —
Дәюб сорам ки анлардин.

— Әя йил, сән каян истең?
Нәчә сахра үтә кичтең?
Туганымны кайда күрдең? —
Дәюб сорам ки анлардин.

— Әя йил, сән китәр булсаң,
Фәлән йиргә йитәр булсаң,
Туганымны күрәр булсаң,
Дога дигел ки безләрдин.

— Әя йил, исмәгел бик тиз,
Бәнем хәлем итеп йиткез,
Вәләкин һич карар кыйлма,—
Әманатдыр ки безләрдин.

— Әя кош, сән күрермүсән?
Фәлән йирдән кәлермүсән?
Туганымны күрермүсән? —
Дәюб сорам ки анлардин.

— Әя кош, сән бармы балаң?
Атаң берлән дәхи анаң?
Вәсил итеп йөрермүсән[4]?
Фиракмусән[5] ки анлардин?

Туганың сагына дигел,
Сагынып, саргая, дигел;
«Туганым, сән кайда?» —
дигел,—
Дога булсын ки безләрдин.

---

[1] *Тайран итдем* — очтым.
[2] *Сәбах эчрә* — таң вакытларында.
[3] *Сорам* — сорыйм.
[4] *Вәсил итеп йөрермүсән* — очрашу эзләп йөрисеңме.
[5] *Фиракмусән* — аерылгансыңмы.

Нәгаh[1] бән сахрага чыксам,
Нәчә төрле егач күрсәм,
Ул ук катларына[2] барсам,
Хәбәр сорам ки анлардин:

— Әя егач, яшең күпме?
Түгелгән йимешең күкме?
Бәнем дик сагышың
күпме? —
Дәюб сорам ки анлардин.

— Нәчә йимешләрең үсте?
Нәчә яфракларың төште?
Ботакларың кемнәр
кисте?! —
Дәюб сорам ки анлардин.

Яфраклар яшь гомер икән,
Ботаклары бала икән;
Фираклык бер бәла икән,—
Бәгырь өзгән туганнардин.

Егачлардан нә чыкмагай?
Сачаклардин нә булмагай?..
Бу дәрдемә дәва тапмай,—
Дәюб кайттым ки
анлардин.

Языйм микән, йитәр
микән?
Ушал[3] кайгу бетәр микән?
Ушал кайгу, ушал хәсрәт
Күңелләрдин китәр микән?

* * *

Иген икмәк бирер икмәк,
Белеп иксәң, бирер күпләп.

* * *

Якутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмыйдыр якут берлән.

---

[1] *Нәгаh* — кинәт, бердән; *монда*: кайчак.
[2] *Катларына* — яннарына.
[3] *Ушал* — шушы.

Каюм Насыйри

(1825—1902)

ХИКӘЯТЛӘРЕННӘН ҮРНӘКЛӘР*

Ярлы кайгысы

Бер фәкыйрь үлем сырхавы хәлендә ятканда, якыннарыннан янына җыелган адәмнәр: «И фәлән, хәлең начар, иманыңны әйт»,— дигәч, ул бичара: «Һай, шул үлем хәлендә дә имана[1] белән аптыраталар ла»,— димеш.

Мулла кайгысы

Берәү вафат булып, мирасыннан бер яхшы тунын бер муллага җибәрделәр. Ул мулла әйтте: «Вафат булганын ишетеп, бик кайгырган идем, тунын күргәч сөендем тагын»,— диде.

Иске мәдрәсәдә

I

Берәү әйтте: «Бер хәлфәне күрдем, янында бер озын вә бер кыска таяклары бар, бер быргы, дәхи барабаны бар».

— Болар ни эшкә? — дип сорадым. Хәлфә әйтте:

---

* Бу новелла-хикәятләр К. Насыйриның «Кырык бакча» (1880) һәм «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) дигән җыентыкларында урнаштырылган.

[1] *Имана* — җир налогы, салым.

— Бу авылда мин балалар укытып торамын. Балалар шаяралар, сабакларын укымыйлар. Миңа якынрак утырганнарын кыска таяк белән сугамын, ерактагыларын озын таяк белән сугамын. Алар минем сүземне тыңламыйлар, үземнең өстемә ташланалар. Аннан соң барабанны орамын, быргыны кычкыртамын, шуннан соң халык җыелып мине коткаралар,— диде.

II

Янә бер авылда бер өйнең ишеге төбендә бер хәлфәне күрдем, эт кебек өрер. «Бу ни хәл?» — дип туктадым. Күрдем: Өйдән бер бала чыкты. Хәлфә ул баланы тотып алды, колагыны борды.

— Бу ни хәл? — дип сорадым. Хәлфә әйтте:

— Мин балалар укытучы бер хәлфәмен. Бу бала бик усал, каршы. «Сабагыңны укы!» — дисәм качып китә; өенә керәдер дә чыкмый, эт белән уйный. Качан ки мин эт кебек өрсәм, «эт бар икән» дип чыгадыр да, тотып аламын,— диде.

III

Мәдрәсәдә бер шәкерт үзенең энесен куа: «Бар, фәлән, су алып кер, минем эчәсем килә»,— ди. Энесе бармады, кабатлап әйтте — бармады, чөнки энесе яткан иде. Боларның хәлфәләре бар иде, ул әйтте: «Бар син, фәлән, үзең миңа су алып кер, минем эчәсем килә»,— диде. Ул шәкерт торды, су алып керде, хәлфәсенә бирде. Хәлфә әйтте: «Ярар, рәхмәт, үзең эч инде, мин эчмимен»,— диде.

Надан мөәзин белән надан мулла

Бер мөәзинне манарада күрделәр, кулында «Иман шарты» бар, азанны «Иман шарты»ннан карап әйтә. Сорадылар: «Ник карап әйтәсең, азанны күңелеңнән белмисеңме?» — диделәр.

— Мулладан сорагыз,— диде.

Муллага бардылар. Мулла ул вакытта ишегалдында икән. Барып: «Әссәламегаләйкем»,— дип сәлам бирделәр. Мулла, сәлам алмыйча, өенә кереп китте дә бер китап алып чыкты, аны актарды-актарды да: «Вәгаләйкемәссәлам»,— диде.

— Хәер, мулласы да шулай икән,— дип киттеләр.

Суфый

Бәгъзе суфыйга әйттеләр: «Җөббәңне[1] сат, акча булыр»,— диделәр. Суфый әйтте: «Балыкчы кармагын сатса, ни белән балык тотса кирәк»,— диде.

«Һаман фәкыйрь икәнсең...»

Ибраһим Әдһәмгә[2] бер кеше әйтте: «Йә шәех, кабул ит, бу чапанымны сиңа бүләк итим»,— диде. Ибраһим әйтте: «Әгәр син бай кеше булсаң, кабул итәрмен». Ул кешегә әйтте: «Күпме акчаң бар?» Ул кеше әйтте: «Ике мең акчам бар». Янә Ибраһим әйтте: «Әгәр дүрт мең булса, сөенер идеңме?» Ул кеше әйтте: «Әйе, сөенер идем». Ибраһим әйтте: «Юк, алайса, син һаман фәкыйрь икәнсең, чапаныңны кабул итмимен»,— диде.

Хикәят

Бер сабый бала, кояшлы көн бер җирдә йөргәндә, үзенең күләгәсен күреп, күләгәсе артыннан җитмәкче булды. Күләгә артыннан җитәмен дип бара. Ул барган саен, күләгә һаман алга китә. Бу баланың ачуы килеп, күләгәнең өстенә басарга теләп, йөгерә башлады. Ул йөгерсә, күләгә дә йөгерә. Бала тәмам арыды. Әйләнеп, янә киткән урынына кайтып барганда, артына әйләнеп караса, күләгә артыннан ияреп килә: «Һи, мин юкка йөгердем, ул миннән үзе дә калмый икән»,— диде. Дөнья куучылар да шулайдыр, уйлап карасаң.

---

[1] *Җөббә* — мулла, ишан һәм суфыйлар кия торган озын кием.

[2] *Ибраһим Әдһәм* (VIII гасырда яшәгән) — риваятьләргә караганда элек патша булган кеше. Патшалыгын, тәхетен ташлап, дәрвиш, суфый булып киткән, бөтен гомерен Аллага табынуга багышлаган. Суфыйчылык рухындагы әдәбиятта аның турында күп кенә әсәрләр язылган. XIX йөз татар шагыйрьләреннән бу образга Әбелмәних Каргалый һәм Габделҗәббар Кандалый да мөрәҗәгать иткәннәр.

Хәйлә һәм тапкырлык

I

Бер үзен-үзе җыя алмаган аңгыра кызны кияүгә бирделәр. Кияү кыз янына кергәч күрде: кызның кулы камырлы, тырнак төпләре камыр гына.

Кияве пакьлек ярата торган адәм иде. Бер хәйлә табып: «Абау, эчем»,— дип угалана башлады. Кыз, хафаланып: «Соң ничек итик, моннан элгәре эчең авыртканы бар идеме, ни дару итә торган идең?» — диде. Егет әйтте: «Эчем авыртканда, әнкәй кулындагы камырны юып эчертсә, төзәлә торган иде»,— диде. Кыз үзенең кулына карады: «Минә кулымда камыр да бар икән, алай булса, юып бирим»,— дип, бер табакка су салып юды. «Мә, эч»,— дип, киявенә бирде.

Егет күрде, кызның кулында камыр һаман бетмәгән, имеш. «Әни өч катка чаклы юа торган иде»,— диде. Кыз, кулын янә ике кат юып, кул юган суын киявенә бирде. Кияве суны кулына алды да: «Аллага шөкер, инде эчем авыртуы басылды, мә, бу суыңны түгеп ташла»,— диде. Кыз дәхи ул суны чыгарып түкте, хәйлә белән юдырганын аңламады.

II

Янә бер егет кыз катына барды. Егеткә аш пешереп китерделәр. Кыз барды да иң әүвәл ашны кабып карады. Авызы пеште. «Һай, безнең әни һәркайчан ашны суытып китерә»,— диде. Егет дәхи: «Мин дә кабып карыйм»,— дип барды да, салкын аш капкан кебек, алып кисәктән кабып йотты. Авызы, тамагы пеште, күп заманча күңелсез булып йөрде. Кыз ул арада чыгып керде. Егет әйтте: «Тышта һава ничек?» — диде. Кыз әйтте: «Тышта һава авызы пешкән егет кебек»,— диде. Чөнки һава болытлы вә томанлы иде.

III

Бервакыт хәзинәдән бер капчык алтын югалды. Казыйга[1] хәбәр бирделәр. Хәзинә йортында булган кешеләрнең барын да

---

[1] *Казый* — хөкем итүче, судья.

казый үзенә чакырды вә һәрберсенә берәр таяк бирде. Таяклар һәммәсе бер озынлыкта, бер үлчәүдә иде. Казый әйтте: «Кем дә кем угры булса, ул кешенең таягы бер бармак кадәре озын булыр»,— диде. «Бар, кайтыгыз!» — дип кайтарып җибәрде.

Капчык белән алтынны угырлаган кеше курыкты да казый биргән таякны бер бармак кадәр кисте.

Икенче көнне казый ул кешеләрнең һәммәсен үзенә чакырды, таякларын карады. Берсенең таягы бер бармак кадәрле кыска булып чыкты. Мәгълүм булды, алтынны ул кеше угырлаган, имеш. Алтынны хәзинәгә тапшырып, ул угрыга җәза билгеләде.

Тапкыр хәлфә

Бер патша үзенең углын гавам[1] балалары укый торган мәдрәсәгә бирде. Хәлфә аны укытты, кулыннан килгән чаклы тәрбияләде. Ләкин патша баласы күпчелек укучыларга караганда сәләтсезрәк һәм әхлак ягыннан да түбәнрәк булып чыкты.

Хәлфә бу бит патша баласы дип тормады, малайны бүтән укучыларыннан да битәр җәзалады, суктырды. Иркә малай хәлфәнең бу катылыгына түзә алмады, атасына кайтып зарланды, тәнендәге яраларын ачып күрсәтте. Патша, моны күреп, бик каты ачуланды һәм тиз генә хәлфәне үз каршына чакырып китерергә кушты.

Хәлфәне китерделәр, патша каршына керттеләр.

— Син, хәлфә,— диде патша ачулы тавыш белән,—минем баламны хәтта гавам балаларына караганда да катырак җәзага тартасың икән. Әйт, ни сәбәптән болай итәсең?

Хәлфә аңар җавап бирде:

— Гавам балалары алар болай да тормышның ачы һәм төчесен татып үсәләр. Аларга җәфаның ни икәнен белдереп торасы юк. Патша балалары исә, киресенчә, җәфа ни нәрсә дә җәбер ни нәрсә икәнен белми үсәләр. Аннары, патша булгач,

---

[1] *Гавам* — гади халык.

халыкка җәбер-җәфа кылуны нигә дә санамый торган булалар. Мин, шуны истә тотып, сезнең балагызга җәзаны катырак бирәм,— диде.

— Сәбәбе шул гынамы? — диде патша.

— Юк, тагын бер сәбәбе бар.

— Әйт, анысы нидән тора?

— Анысы,— диде хәлфә,—моннан гыйбарәт: гавам балалары күп вакыт патша һәм бай балалары белән чагыштырганда үткенрәк, зирәгрәк һәм сәләтлерәк булалар. Мин сезнең балагызны өйрәтүгә күбрәк көч салам, ул исә һаман да артта калып бара.

— Алайса, мин баламны синнән укыттырмыйм, алып бүтән хәлфәгә бирәм,— диде патша.

— Анысы сезнең ихтыярыгызда, падишаһым, тик шуны онытмагыз: тәрбия бер, сәләт башка,— дип җавап бирде хәлфә.

Патша белән карт

Беркөн бер патша бәгъзе вәзирләре белән сәйранга[1] чыкты, йөри торгач, бер җирдә, кешеләреннән аерылып, ялгыз калды. Үзенә бер карт очрады, һәм ул картка әйтте: «Бабай, син кайдан?» — диде. Карт әйтте: «Мин ошбу шәһәрдәнмен». Патша әйтте: «Бу шәһәрнең хакимнәре ничек?» Карт әйтте: «Хакимнәребез бик залимнар, бик усал кешеләр»,— диде. Патша әйтте: «Патша хакында ни әйтәсең?» — диде. Карт әйтте: «Мәмләкәтебездә моның кебек залим патша булганы юк иде, золымы белән мәмләкәтне корытты»,— диде. Патша әйтте: «Мине танышсыңмы, мин кем?» — диде. Карт әйтте: «Юк, танымыйм». Патша әйтте: «Мин шәһәрнең патшасы булырмын»,— диде. Карт әйтте: «Син мине танышсыңмы?» Патша әйтте: «Юк». Карт әйтте: «Мин гаҗәм кабиләсеннән фәлән углы фәлән мәҗнүн, көн саен ике мәртәбә шулай җүләрләнеп, саташып йөримен»,— диде. Патша көлде дә китте.

---

[1] *Сәйран* — күңел ачып йөрү.

Бай һәм хезмәтче

Берәүнең бер хезмәтчесе бар иде. Аңар акча бирде, боерды: «Бар, базардан йөзем вә инҗир алып кайт!» — диде. Малай базарга китте, бик озак торып кайтты. Йөзем алып кайтты. Янә икенче мәртәбә инҗир алырга китте, төнлә кайтты. Аннан соң бае орышты, кыйнады. «Бер йомышка баргач, ике йомышны бетереп кайтыр кеше»,— диде.

Бервакытны бу бай сырхау булды. Баягы малайны табибка җибәрде. Хезмәтче китте, табибны алып килде. Аның белән янә бер кеше ияртеп килде. Бае әйтте: «Бу кешене нигә алып килдең?» — диде.

Хезмәтче әйтте: «Фәлән вакыт үзең мине кыйнадың, бер йомышка барганда ике йомышны бетереп кил, дидең. Инде менә сиңа табиб, Аллаһ бирсен, шифа тап, әгәр үлсәң, менә сиңа кабер казучы, икенче мәртәбә мине йөртмә!» — диде.

Аңгыралык бәласе

Берәү углын сукага җибәрде, углына әйтте: «Углым, кич кайтканда, сука тимереңне яшереп кайт, угырлап китмәсеннәр»,— диде. Углы барып бөтен көн сукалады, кич кайтканда сука тимерен бер карама төбенә яшереп куйды.

Кайтып килгәндә, атасы берничә адәм белән урамда утырып торыр. Атасына кычкырды: «Әти, сука тимерен фәлән карама төбенә яшереп калдырдым»,— диде. Атасы әйтте: «И ахмак, яшергән нәрсәне шулай кычкырып әйтәләрме»,— диде.

Икенче көнне сукага барса, күрде: карама төбеннән сука тимерен урлап китмешләр. Тиз үк атына атланып, атасы янына чабып кайтты. Атасы печәнлектә йоклаган иде. Атасын эзләп тапты. Атасының колагына акрын гына: «Әти, сука тимерен урлаганнар»,— диде.

Хикәят

Бер заман кыш гаять суык булып, бер бака әрләннән азык сорады: «Ашарыма юк, бераз ризыклык рәхим итсәнә»,— диде.

Әрлән әйтте: «Җәй көне көн буенча авыз күтәреп кычкырып тордың, ни эшләдең, ник кыш көне өчен азык хәзерләмәдең?» — диде.

Язу сәнгате

Арсту[1] әйтте: «Нинди хәерле вә файдалы нәрсә язарсың, гүзәл вә укырлык булсын, матур-пөхтә итеп яз, вә нинди хәерле вә файдалы нәрсәне күңелеңә сеңдерерсең, аны язарлык булсын, ягъни күңелдән ятлаганыңны онытма, күңелдән чыгарып, кәгазьгә төшерерлек булсын. Каләм кәлямның[2] илчеседер. Язу кулның теледер».

Күркәм язу яза белмәк ярты гыйлемдер вә ризыкның артуына сәбәптер.

Каләм өйрән: каләм изгегә тартыр,
Каләм берлән кешенең ризкы артыр,—

димешләрдер, кадимнән (электән) бар сүздер.

Җыр һәм музыка

Хәкимнәр әйтмешләрдер ки, җыр-музыка җаннарның азыгыдыр, нитәкки, ашамлык тук булу азыгыдыр. Уй-фикерне саф кылыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, куркакны баһадирландырыр, саранны юмартландырыр, димешләр.

---

[1] *Арсту* — борынгы грек галиме, акыл иясе Аристотель.

[2] *Кәлям* — сүз, сөйләм.

Муса Акъегетзадә

(1864—1923)

ХИСАМЕТДИН МЕНЛА[1]

Милли роман яки хикәя*

(1886)

I

Русия уртасында Идел елгасыннан ерак түгел бер татар авылы бардыр. Авылның халкы ике йөз кадәр өй булып, атын тулысынча әйтеп тормыйбыз, шуңа күрә, хикәябезне җиңел аңлатмак өчен, атын бары «Н» хәрефе илә генә ишарә итәбез. «Н» авылының йортлары гади йортлар кебек агачтан вә башлары кайберләренең саламнан, кайберләренең тактадан ясалмыштыр. «Н» авылында ике мәчет бар. Бер урамлы авыл булып, урамы озын вә киңдер. Урамы озаеп, кыйбла тарафындагы очында борылып, суга юл чыгадыр.

Халкының башлыча тормыш өчен хезмәте игенчелектер. Ләкин күп кенә кешеләре башка шәһәрләргә, мәсәлән, Әстерхан, Ростов, Казан кебекләргә эш вә сәүдә өчен йөрерләр. Шунда «Н» авылында урта мәчеттән ерак түгел бер кечкенә йорт бар.

---

* Әсәр текстындагы кайбер сүзләр һәм гыйбарәләр хәзерге әдәби телгә күчереп бирелде, бераз кыскартулар ясалды.

[1] *Менла (мәлля)* — укымышлы кеше, галим, мулла.

Бу йорт үзе кечкенә булса да, тактадан башы, анбары вә төзек сарайлары иясенең ижтиһадлы-тырыш вә хезмәт сөючән адәм идегене күрсәтерләр иде. Бу йортта мулла хатыны тол Зөлхәя вә углы Хисаметдин менла атлы адәмнәр торырлар иде. Менла Хисаметдиннең мәрхүм атасы указный менла булмыш исә дә, углы атасының юлыннан китмәде.

Ике-өч ел моннан элек менла Хисаметдин госманлы (Төркия) җиреннән укып ватаны «Н» га кайтты. Хәзердә үзе өенең икенче бүлмә чигендә сабыйларга дәрес бирер иде. «Н»лыларның кайберләре Хисаметдин менлага теләктәшлек итәрләр иде, чөнки ике ел эчендә язу язмак, язу танымак, хисап гыйлеме, дин гыйлеме балаларына өйрәтте. Әмма күп кенә кешеләр бу укытучыны яхшы белмәдекләреннән сөймәсләр иде. Мәсәлән, авылның указный мулласы карт Бикбулат мулла әфәнде Әхмәтша углы, көнчелек итеп, аны сөймәс иде вә мәҗлесенә килгәннәргә әйтер иде: «Ни өчен бу юләр наданга балаларыгызны бирәсез, тәүфыйктан чыгарыр, китерегез минем үз мәдрәсәмә, ул иҗек үгрәтмәс, тугрыдын-тугры сүрә укытыр, аның ысулы тәдрисе җаиз дәгел[1], мәсәлән, а-ба укытыр, әмма әүвәл әлиф сенә бәсендә кирәк». Вә шул рәвешле асылсыз сүзләр берлә Хисаметдин менланы хурлар иде. Күп халык карт мулланың сүзенә шәригать сүзе кебек инаныр иде. Әмма Хисаметдин мәктәбендә укытмыш вә тәҗрибә итмеш кешеләр, карт мулланың буш сүзләренә ышанмыйча, Хисаметдин менлага камил теләктәшлек итәрләр иде. Хисаметдин менла исә морфология һәм синтаксис белеменнән генә түгел, хәтта мөселман хокук белеменнән, хәтта философия фәненнән Истанбулда шәкертлектә тәмам хәбәрдар булган иде. Татар муллаларының кайберләре, үзләре аз белдекләреннән, күп белүче башкаларга көнчелек итеп, сөймәдекләре мәгълүмдер.

Хисаметдин менла хәрәкәт вә кәсеп сөюче кеше иде: ун дисәтинә үзенең җире бар иде. Гәрчә бер хезмәтче тотса да вә

---

[1] *Ысулы тәдрисе җаиз дәгел* — укыту, дәрес бирү ысулы, методы дөрес түгел.

күп чакта яз вакыты иген эшендә башка хезмәтчеләр ялласа да, күп вакыт үзе дә кара иген эшене эшләр иде. Моның аркасында Хисаметдин менла рәхәт вә башкаларга ихтыяҗсыз тормыш итәр иде.

Хикәябез якында гына узган заманнарга карыйдыр, бәйләнешледер.

Кыш якынлашмыш вакытлар. Җомга көн намаздан әүвәл, Хисаметдин менла «Тәфсире бәйзави» китабыны укып утыра иде.

Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә гаҗәпләнерсең. Йөзе гүзәл ачык. Яңарак чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары, вә кыска чәче коңгырт төстә булып, матур йөзенең гүзәллеген тагын да арттырадыр. Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп үтәрләр. Башында бәрхет такыясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар иде.

Тәфсирне куйды. Бүлмәсендә йөрер. Йөзеннән тирән фикергә талдыгы беленер. Йөргәндә биек буены вә ир кыяфәтене күрсәң, гашыйк булырсың. Шул вакытта тәрәзәдән волостной идарәсе хезмәтчесене күреп, капкага тугры барып: «Һай, килдеме?» — дип шатланып кычкырды. Әлеге хезмәтче: «Килде»,— диеп, моңа бер кәгазь бирде. Кәгазьне алып, егет бик тә шатланды. Бу кәгазь Русия исламнарының сәламәтене вә күркәм тормышыны яклаган «Тәрҗеман»[1] газетасы иде. Хисаметдин менла үзенең милләтене, ягъни татарларны бик сөюче адәм иде. ...Хәтта Бикбулат мулла үзене дошман күрсә дә, ул һич дошман күзе белән аңа бакмас иде. Чөнки яхшы белә иде ки, бу дошманлык хәсәдлек-көнчелектән килер. Хәсәдлек кебек зур бәлагә дучар булган адәмне Хисаметдин менла түгел дошман күрмәк, киресенчә аяр иде. Теге газетаны ачып укый башлады...

---

[1] *«Тәрҗеман»* (кемнең дә булса мәнфәгатьләрен чагылдыручы, бәян итүче мәгънәсендә) — Кырымда күренекле мәгърифәтче морза Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский) тарафыннан чыгарылган газета (1883—1918). Милләтне уяту, мәгърифәтле һәм мәдәниятле итү идеяләрен алга сөргән бу газета Идел-Урал буе татарлары арасында да киң таралган.

«Ошбу номер илəр «Тəрҗеман»ның ярты еллыгы[1] тəмам ула. Бу номерга алдыгымыз... Никадəр генə читенлекле вə көч бер эш исə дə, күпнең файдасы өмет ителгəн хезмəттəн...» Ахырына кадəр инде болай укыр... «Мин булсам да, сез булсагыз да, бер фəкыйрь, бер байгуш күрсəк, җанымыз авырып, кайгы хасил булыр. Бер хаста-авыру, хəлсез күрсəк, ярдəм бирергə бер əмəл вə чара үгрəтмəк морад идəрсез. Я үлем түшəгендə яткан бер кеше күрсəк, күземезгə — яшь, күңелемезгə мəрхəмəт килер, дəхи авыруга дучар булган хайван күрсəк, ачынып ахвах идəмез дə, бер түгел, биш түгел, меңнəрчə дин вə күңел кардəшлəремезнең төрле авыру газапка дучар улып, наданлык вə һөнəрсезлек кеби ике олуг вə мəрхəмəтсез дошманның кулына төшеп җан биргəнен күрмəеп, җаныбыз тоймаеп, күңелемез агламаеп, гакылымыз чаралар күрмəеп тордыгымыз күп язык вə хəйран калырлык түгелмедер». Шул җирдə Хисаметдин менла кайгы-хəсрəткə чумып туктады вə күзлəренə яшь килде. Бер-ике фикердəн соңра укуын дəвам итеп: «Əйе, никадəр гаҗəптер ки, бер адəмнең хəленə мəрхəмəт итəрбез дə, бер миллион адəмгə — бер миллəткə мəрхəмəтебез юктыр...» Бу җирдə үз-үзене тота алмаеп, менла еламага башлады вə, укымага тəкате калмаеп, бары тик: «Афəрин, Исмəгыйль кардəшем»,— дигəн сүзлəрне генə əйтə алды.

Болай ачы борчылуын, елавын ишетеп, анасы бүлмəгə керде.

— Нихəл, углым?

Хисаметдин, үзен елаудан тыеп: «Аначыгым, бернəрсə юк, атамны ядыма алдым, кайгыландым»,— дип җавапланды.

Хəлбуки, укучыларыбыз! Ул атасыны һич ядына алмады. Русиядə торучы ун миллион ислам кардəшлəрене ядына алды. Атасы нигə хаҗəт. Ул инде вафат, Алла җəннəт бирсен. Əмма ун миллион мөселман тере калды. Аурупадан башка — госманлылар вə мисырлылар, вə һиндлелəр безнең наданлык вə

---

[1] Газета 1883 елның 10 апрелендə чыга башлый. Димəк, романдагы бу вакыйгалар 1883 елның көз айларында бара. М. Акъегетзадə үзе дə 1887 елда «Тəрҗеман» редакциясендə эшли.

ваемсызлыктан кәләләр, ни аяныч! Әмма мәгълүматлы улмак өчен нәрсә кирәк? Укуны сөю кирәк, дип фикерләнә-фикерләнә, Хисаметдин менла янә бүлмәсендә йөренә башлады. Чыланган «Тәрҗеман»ны исә өстәлгә ташлады.

II

Җомга намазыны укыдыктан соңра, Хисаметдин менла, атыны чанага җигеп, кайбер кирәк нәрсәләр алмак өчен, шәһәргә юлланды.

«Н»дан губернатор утырган шәһәргә бары ике-өч сәгатьлек юлдыр, ләкин бару юлы бик кыен иде: кырда юл утырмыйча, кар бераз яумыш иде. Фәкать ачык туфраклы җирләр дә бар, мондый вакытларда арба илә чыксаң, көпчәк кайчакта карга кереп әйләнмидер, чана илә китсәң, карсыз җирләрдән кичмәк кыен була; вәлхасыйль — кыскасы, мондый вакытта татарча: «Ни арба, ни чана»,— диерләр.

Юлында туры килгән бер тауга менеп барганда, арттан ике ат җигелгән бер арба килеп җитте.

— Бу кем алда? — дип сорады арбада утырып баручы яшь әфәнде ат куучысыннан.

— Бу — тап шул Хисаметдин менла, кайсысыны мин сезгә бик галим диеп сөйләгән идем. Истанбулда укымыш. Безнең муллаларга авыз ачарга да бирми.

Яшь әфәнде күптән бу кеби кеше илә таныш булуны теләр иде. Ничә мәртәбә Хисаметдин менла хакында гаҗәеп сүзләр ишетмеш иде. Шуңа күрә яшь әфәнде, куучыга арбаны чана илә тигезләргә боерып, менлага эндәшеп, сүзен болай башлады:

— Шәһәргә моннан ничә чакрым булыр, әфәндем?

— Унике, унбиш булыр.

— Юл бик начар; кай җирле сез, әфәндем? — сорады яшь әфәнде.

— «Нун» авылыннанмын. Сез яхшы иткәнсез, әфәндем, арба җиккәнсез, мин хата иттем, чанада бик авыр.

— Хөкүмәт эше булмаса иде, мин бу вакыт һич юлга чыкмас идем.

— Нинди хөкүмәт эше, әфәндем? — дип сорады менла.

— Гимназия хөкүмәте. Безнең кагыйдә вә кануннарымыз шундый ки, вакытына килергә кирәк.

— Канунга буйсынган адәм рәхәт булыр. Бу юлны зәхмәттән санасак, һичбер эшкә ярамамыз,— диде Хисаметдин менла.

Бәс шәһәргә җиткәнчегә кадәр яшьләр сөйләшеп килеп юлны кыскарттылар. Бу сөйләшүдән яшь әфәнденең гимназия укучысы икәнлеге аңлашылды. Вә бу ике яшь юлчы, әңгәмәдәш булып бара торгач, бер-берсене бик яратыштылар. Хәтта ки Хисаметдин менла гимназистны шәһәрдә барып күрергә сүз биреп аерылды. Гимназист дигәнебез бу губернадагы бәкләрдән Әбүзәр Дәүләтгилдиев исемле бәк иде. Әмма без Хисаметдин менла артыннан китик әле.

Ул шәһәрдә постоялый дворга, ягъни гавам мөсафирханәсенә[1] төште. Бу мөсафирханә килүчеләр өчен зур бер өйдән вә бер янә артта кечкенә өйдән гыйбарәт булып, хуҗасы Габбас әфәнде Биктимер углы бер сәүдәгәр иде.

Мөсафирханә йорты гаять зур вә мәйдан иде. Бу ханәдә тору өчен хакы бераз артык алынса да, ханәнең, аш вә йимәкнең ару-чисталыгы яхшы вә баерак кешеләрне җәлеп итәр иде. Атны сарай астында җирләштергән заманда менланың күзенә гүзәл бер күренеш туры килде: йорт буенча бакчадан арттагы өйгә бер кыз узып бара!

Кыз урта буйлы, башында яхшы Казан калфагы киелмеш, өстендәге күк йон камзулы нәзек вә зифа буена яхшы ярашып тора. Муенында саф көмеш монетлар киелгән, вак-вак атлап үткән вакытта, йомырык вә таучык шикелле ике күкрәгенә акчалар чылдыр-чылдыр бәрелерләр. Аягында тамбурлы читек-башмак, чәче вә күзләре, вә кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы, кызгылт ак, борыны кечкенә вә гүзәл. Азбарда беркем дә юк дип белеп, шәлене иңенә салып үтеп барганда, менланың күзләре аңсыздан бу матурга төшеп зәвыкландылар. Бу нәзек бил вә гүзәл кыз менланың күзенә тәмамән күренде.

---

[1] *Гавам мөсафирханәсе* — гади халык кунарга керә торган йорт, кунакханә.

Бу кыз мөсафирханә хуҗасы кызы гүзәл вә күркәм Хәнифә исемле иде. Мондый чибәр итеп Алла яратса да ярата икән! Бу нечкә билне тамаша идәрәк, менламыз хәйран калды, тормыш мәшәкатьләрен онытып, үз-үзене онытты. Өйгә якынлашканда кыз, сарай тарафына багып вә бердән менланы күреп, оялдыгыннан көлде вә тиз үк шәл илә капланды, әмма бу көлешендә кып-кызыл иреннәре, вак энҗе тешләре менланың күзеннән качмады. Хәнифә туташ өйгә кердектән соңра, менла, акылыны туплап: «Мин ни иттем, нәфесемә буйсынып кызга бактым, тәүбә-тәүбә»,— дип фикер йөртте. Соңрак менла шәһәргә чыгып, өй-йорт кирәкләрене алып вә башка эшләрне бетереп, янә мөсафирханәгә кайтты. Күрде ки, диваннар вә өстәлләрдә бик күп халык: сәүдәгәр вә гавам кешеләре утырмыш. Кайберәүләре исәп-хисап илә мәшгульдер. Менла үзенә чәй китертеп өстәл янына утырды. Анда утырганнарның кайберләре менла илә сөйләшүгә керештеләр.

Мөсафирлар утырган бу зур һәм киң бүлмә илә янәшә бер кечкенә бүлмә бар иде. Мөсафирлар бүлмәсе илә бу бүлмәнең арасы калын тактадан гыйбарәт иде, бу кечкенә бүлмәгә шулай ук арткы өйдән ишек бар иде. Арткы өй алдагы зур өй белән тоташ иде. Менла мөсафирханәгә кергән вакытта Хәнифә туташ әлеге кечкенә бүлмәдә оек бәйләп утыра иде. Менланың кергәнен белеп вә янә бер күрмәк теләп, Хәнифә туташ, эшене куеп, өстәл эченнән кечкенә пычак чыгарды вә, ике такта арасы табып, пычак илә шпалерны акрын һәм сиздермичә яра башлады. Бер-ике минуттан соң морадына иреште. Үз бүлмәсеннән мөсафирлар бүлмәсенә бер ярык ясады вә шул ярыктан егет менланы бакмак илә хушланыр иде. Шул рәвешчә, татар җырында бик дөрес әйтелгән икән:

Ак эшләпә мамыктан, кызлар карый ярыктан,
Карамас иде ярыктан, бер күрергә зарыккан.

Һай бу йорттагы көтмәгәндә очрашу! Кыз егетләргә бик бакмыйдыр иде. Әмма йорттагы очрашу шпалерлар ярмага кызны мәҗбүр итте. Гаҗәеп икенче туры килү: бу да менламыз тугры ярыкка каршы утырмыш иде. Кыскасы, Хәнифә туташ тулы ләззәт илә ләззәтләнер, әмма теге бүлмәдә утырган җәмгыять, бу эштән хәбәрдар булмыйча, менла илә сөйләшеп утырырлар иде. Менладан шәригать мәсьәләләрен сорарлар иде, чөнки Хисаметдин менла башка муллалар кебек киртек-миртек җавапланмас иде. Тугры вә хакыйкать җавап бирер иде. Мәсәлән, халыктан бересе хатыннар алмак турында сораштыргач, ул диде: «Ислам шәригате икедән дүрткә кадәр хатын алмага рөхсәт бирсә дә, ләкин өйләнмәс борын үз хәлеңә карарга кирәк: ике хатын асрамага синең милкең бармы? Хатыннар хакында гаделлегең вә барчасына тигез дәрәҗәдә мәхәббәтең булырмы? Милкең вә гаделлегең булмыйча, ике хатын алсаң, хокукларыны бирмәсәң, гөнаһлы буласың».

Күзәтү эшендә булган Хәнифә туташ менланың бу сүзләрене ишетеп бик разый-шат булды вә үз җенесе булган хатыннар хакында да мәгълүмат хасил итмәк өчен дикъкатенә арттырып,

колакларыны мөсафирлар бүлмәсенә салды. Хәнифә туташ үзе дә укыган кыз иде. Сөйләшеп утыру исә менла ястү намазыны укырга керешкәнче дәвам итте.

III

«Н» авылына кайтабыз, хөрмәтле укучыларым. «Н» авылының өйләре кечкенә вә саламнан вә кайберләре агач тактасы илә ябылган булуны язган идек. Әмма шулай булса да, авылның аргы очында яхшы бер йорт бар. Ул зур йорт таштан салынган булып, ике катлы вә башы тимер илә ябылмыштыр. Бу өй Гали бай Җаватовныкы иде. Гали бай бу губернада бөек һәм мәшһүр сәүдәгәр иде. Шәһәрдә агач склады вә «Нун»да йон юмак мастерское бар иде. Мәскәү сәүдәгәрләре вә фабрикчылар илә эш йөртүче кеше иде. Һәм авылда Гали байдан сүзе үтемле кеше юк иде: ул ни диде, шул булды. Һичбер кеше аңа каршы торырга батырчылык итмәс иде. Ярты чакрым ераклыктан «нун»лылар Гали байга сәлам бирер иде. Чөнки гавам халкы яхшы белер ки, байны олыласаң, аның кулында булган җирне вакытлы файдаланута (арендага) очсызрак хак илә алмак мөмкин.

Габбас аганың мөсафирханәсендә булуыбыздан өч көн соң кичке аш вакыты. Гали бай гаиләсе илә чәй эчәргә утырган вакытта гына, Бикбулат мулла әфәнде килеп керде.

— Әйдәгез, хуш киләсез, хәзрәт, чәй вакытына туры килдегез, яхшылык теләп киләсез! — диде Гали бай. Хәзрәт утырды.

— Эш илән килдем, егерме бишлек акчамны алыштырырмысыз?

— Яхшы, алыштырырмыз. Берәр чынаяк чәй эчеп алыйк.

Бикбулат мулла Гали байга кияү буладыр, мулланың хатыны Гали байның кардәше иде.

— Әй син, Сибгатулла, сине өйләндермәк кирәк! — диде сүз арасында мулла Гали байның углына.— Гаскәрлектән котылдың, дәүләтегез күп, атаң-анаң карт.

— Тап кыз! — дип җавап бирде Сибгатулла әфәнде.

— Сезгә авыл кызы ярамас, сезгә шәһәрнеке кирәк.

— Шәһәрдә Габбас аганың кызын бик мактыйлар,— дип сүзгә кереште Гали байның сәүдә эшләрендә баш хезмәтчесе.— Укыган, бик күркәм вә уңган дип сөйлиләр.

— Кызны күп кеше мактыйдыр,— диде Гали бай.

— Сезгә тиз бирерләр, яхшылап сорарга да өлгермәссез, мондый дәүләтле кияүгә бирү бөек бәхеттер,— диде Бикбулат мулла әфәнде.

Өйләнү мәсьәләсеннән соң сүз гайбәтләргә күчте. Бикбулат мулланы укымаган дисәк, ялгышкан булырбыз, чөнки «гакает»лар күрмеш; галим дисәк, шулай ук хата булыр, чөнки галим кеше гайбәтләрдән качадыр. Ә Бикбулат мулла хәзердә чәй янында: улсы яман, бусы ялганчы, ул бересе хәерсез, угыры дип сөйләнә-сөйләнә, үзеннән яхшыны тапмаеп, теле Хисаметдин менлага да тиде:

— Белермесез,— диде Бикбулат мулла,— наданыбыз никадәр ярамаслык эш эшләгән шәһәрдә?

— Ни ул ярамаслык? — сорады Гали бай.

— Безнең авылның ятим Мохтар теләнчене мирза Дәүләтгилдиев ярдәме белән полициягә яптырган. Үзе әйтер, исламны сөям, әмма үзе ятимнәрнең ризыкларын кисәр. Бу — кяфер эшеннәндер, мин аны күрим генә, харап итәрмен. Аның бу эше — шәригатькә каршы килә торган эш. Монда дәлил таба алмас, ул сүз түгел, ислам дошманыдыр.

— Ярый, син аны җиңеп атырсың, бездә мәҗлес булыр, кара, бәхәсләреңне яхшы хәзерлә,— диде Гали бай.

Гали бай үзе дә Хисаметдин менланың җиңелеп калуын телидер иде. Чөнки Гали бай тыштан берни күрсәтмәсә дә, эчендә Хисаметдин менлага ачу тотып, сөймәс иде. Чөнки Хисаметдин башка муллалар кебек Гали байны олуглмас иде. Менла Хисаметдин пакь исламиятне сәүдегеннән вә саф исламиятнең таләбен үтәүче буларак, барча исламнар тигез булуына инанып, аның карашында бай вә фәкыйрь тигез иде. Шуңа күрә Хисаметдин менланың бай исламга мәхәббәте фәкыйрь исламга мәхәббәтеннән артык түгел иде. Гали байны шулкадәр сөяр иде, никадәр фәкыйрь исламны сөяр. Гали байга исә бу мөнәсәбәт

бик тә капма-каршы иде, чөнки укымышлыларыннан, муллаларыннан башлап гавамнарынача авылның барлык халкы аны олылап сөяр икән, фәкать бер Хисаметдин менла аны бик олугламас вә туры килгәндә үзен Гали байга тигез кебек тотар.

Һәрхәлдә, икенче көн бай мәҗлесендә Хисаметдин менла да булды, вә бай анасының үлүенә кырык көн үткәнгә Бикбулат мулла Коръән Кәримнән бераз укыгач, табынга чәй китерелде.

Бикбулат мулла түрдә утырган. Аннан соң шәкертләре җирле җиренчә җирләшкәннәр. Хисаметдин менла каршында — самавыр янында Сибгатулла әфәнде кечкенә татар чашкаларына чәй ясау илә мәшгуль. Сибгатулла әфәнде Хисаметдин менла кебек яшь булса да, күркәмлеге юк иде.

Җәмәгать ул-бу турында сөйләшеп утырганда, Бикбулат мулла күбрәк укыган бер шәкертенә күзе илә ишарә итте.

Шуннан соң әлеге шәкерт, Хисаметдин менлага мөрәҗәгать итеп, сүз башлады:

— Шәһәрдә яңа хәбәрләр юкмы?

Бу сорауны ишетеп, мәҗлестәгеләр, аеруча Бикбулат мулла белән Гали бай угылы, бу шәкерт Хисаметдинны харап итәр, дип эчләреннән сөенделәр.

Ләкин Хисаметдин, боларның эчке ниятләрен белмичә, дикъкать итәрлек нәрсә юк, дип кенә җавап бирде. Теге шәкерт, сүзен дәвам итеп, болай диде:

— Авылыбызда сөйлиләр ки, ятим Мохтарны ябып куйганнар.

— Әйе, тугры хәбәр,— җавап бирде Хисаметдин менла.

— Бәлки, тугры, әмма аның ябылуына сезнең сәбәпче булуыгызга без һич ышанмыйбыз.

— Әлбәттә, менла Хисаметдин яптырмас, чөнки ул исламны сөюче кеше; ятим теләнчеләрнең садака-ризыгын кисү исә наданлыктан килер вә кяфер эшедер,— дип бәян итте Бикбулат мулла вә шәкертләренә янә күз кысты. Укымышлы саналган шәкертләр, бу ишарәне күреп, менлага кырмавык кебек ябыштылар:

— Юк, дөрестән дә, сез Мохтарны пулисиягә яптыргансыз. Бу бик зур наданлыктыр, бу кяфер эшедер.

Бу кычкырышуны ишетеп, мәҗлестә булганнарның кайберләре, чәйләрене онытып, Бикбулат мулланың шәкертләреннән хәйран калдылар.

Хисаметдин шәкертләр белән болай никадәрле генә сөйләшәсе килмәсә дә, кяфер эше, дигән сүзләренә чыдый алмыйча, болай җавап бирде:

— Монда ни бар, әфәнделәр? Мин яптырганлыгымны һич тә инкяр итмимен, мин яптырдым.

Бу җавапны ишетер-ишетмәс, Бикбулат мулла үзе һәм шәкертләре кычкырышып: «Бакың, бакың, яман эшне үзе дә инкяр итми. Һай залим! Ә үзе исламны сөям дигән була тагы, бу яман эш исламияткә каршы ич»,— диделәр.

— Исламны сөйгәнлегемнән пулисиягә алдырдым. Китапта боермыш ки, соранмак фәкыйрьлеккә сәбәптер,— җавап бирде Хисаметдин.

— Китап кем, сан кем! — кычкырыштылар шәкертләр.

Хисаметдин менла, боларның хайванлыгыны күреп:

— Мин сезнең белән сөйләшәсем килми, ябышмагыз миңа,— диде.

Шулчак Гали байлар, Бикбулат муллалар, Хисаметдин сөйләшүдән качып җиңелде дип, янә бик шатландылар. Фәкать шәкерт саналганнар тагы да катырак ябыштылар: «А! Сән сөйләшмәктән качасың. Кайсы китапта әйткән, соранмак фәкыйрьлеккә сәбәп дип? Сәнең китабыңдамы?»

— «Шәрхе ширгател-ислам» китабында язылган: хәзрәте рәсүл саллаллаһе галәйһи вә сәллам хәзрәтләре димешләрдер ки, үзе өчен бер кемсә сорамактан бер капу ачса, Алла хәзрәтләре ачар аңа фәкыйрьлектән җитмеш капу. Мин исә ислам кардәшемнең фәкыйрь булуын һич теләмим. Күрәсез, хәзрәте рәсүл үзе дә кешедән соранмакны сөймәгән,— дип куйды Хисаметдин менла.

Ләкин шәкерт саналганнар, бу җавапны ишетмичә, һаман кычкыруда иделәр. Вә соранмак-теләнмәкне гакылларына

рашлы күреп (чөнки тормышлары шул дәрәҗәгә якын иде ки, үзләре дә соранмактан кире тормаслар иде), хәдисне инкяр итәргә калкыштылар.

— Юк, юк, шундый хәдис булмас, син надан, гафил. Әйт хәдисне гарәпчә! — кычкырдылар шәкертләр.

— Мин әйтермен, әгәр бәхәсләшәсез икән, әдәп белән сөйләшегез, яисә дәлилләп сөйләгез, монда әдәпсезлек, бәхәс җире түгел.

Шәкерт саналганнар, барыбер бернәрсә дә аңламыйча: «Әйт, гарәпчәсен әйт»,— диделәр.

Хисаметдин менла хәдисне гарәпчә әйтәсе килмәде. Ләкин кунаклардан берсе: «Әйт инде, менла, үзләренә»,— диюенә күрә әйтте.

— Гарәпчәсе безгә кирәк-зарур түгел, мәгънәсен аңламак өчен төркичәдә җитәдер. Теләсәгез, гарәпчәсе болай,— дип, гарәпчә әйтеп күрсәтте.

Җиңүче булып чыгарга теләгәннәр, бу хәдисне ишетеп вә менла Хисаметдин илә сүз көрәштерергә тәкатьләре җитешмәгәнлекне аңлап, тынып калырга мәҗбүр булдылар. Хисаметдин менла исә бераз кайгылы булды. Кайгыруына сәбәп шул иде ки, Бикбулат ише муллалар мөдәррислек дәгъва итәләр! Моның кеби мөдәррисләрдә гомерне әрәмгә уздырып, шәкертлек итеп, кычкырышмактан гайре бер нәрсәгә дә өйрәнеп булмыйдыр. Көенечле булуына сәбәп: болар кеби шәкертләр бәхәснең нидән гыйбарәт икәнлеген белмиләр. Болар белмәсләр ки, бәхәстән морад кычкырышмак түгел. Бәхәстә дошманлык, мәхәббәт вә һәрбер хосусый мөнәсәбәт мөмкин булмаган бер эштер. Хәтта иң олуг дошманың бәхәстә хакыйкатьне исбат итсә, аның фикеренә кушылырга кирәклекне бу шәкерт саналганнар белмиләр иде. Әмма никадәрле кайгылы булса да, каршы яктагыларның авызларын каплавыннан Хисаметдин күңелендә бер юаныч тапты.

IV

Кышкы вакытларда хикәябездә язылган затларның тормышлары гадәтенчә кичеп, дикъкатькә лаек бернәрсә дә юк иде. Белешләребез Гали бай вә Сибгатулла әфәнде сәүдә эшләре

белән мәшгуль улып, бу көн — Мәскәүдә, иртәгесен — үз шәһәрләрендә вә берсе көнне бер сәүдә үзәгендә вакыт уздыралар иде. Белешебез Бикбулат мулла үз вазифасын үтәү белән мәшгуль улып, муллаларга садака бирергә кирәклекне мәхәлләсенә киңәш итеп вә кисәтеп-искәртеп, аучы куян вә үрдәкне өмет итеп саклаганы кебек, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде.

Белешебез Хәнифә туташ тегү тегеп, китап укып вакыт уздырмакта иде. Белешебез Хисаметдин менла, сабыйларны укытудан башка, арыш вә солыларын суктырып вә сатып кәсеп итеп, эшсез һич ятмас иде. Чөнки бу кеше укымыш улып, белер иде ки, кәсеп вә эш шәригать буенча намаз вә руза тоту кеби фарыз вә гыйбадәттер. Әмма кыш кичеп, яз башлары җитү белән Хисаметдин менланың тормыш рәвеше бераз алмашынды. Кыш вакытына караганда хәзерге заманда шәһәргә күбрәк барырга гадәтләнде. Моның асыл сәбәбе бу ки, язганыбыз Хәнифә белән очрашуы менлага бик көчле тәэсир итте, шәһәргә барган вакыт Габбас агайга төшәр иде вә йортта, капка алдында, яисә урамда Хәнифәне очратырга тырышыр иде. Вә күп тапкыр морадына ирешер иде. Ахрысы, Хәнифә туташка да менла белән очрашкалау хуш иде, чөнки туры килгән вакытларда кыз белән егет бер-берсенә карашып уза башладылар.

Менланың шәһәргә еш килгәләп йөрүе дикъкатьсез калмыйча, беркөн Габбас ага да аңа эндәшеп: «Менла, син шәһәрне ярата башладың; элекке вакытларга караганда хәзер күбрәк киләсең»,— диде.

— Әйе, Габбас ага, һәрвакыт эшләр белән киләмен; аны-моны алырга кирәк була, үзем килмәсәм, минем эшемне кем эшләсен? Мин ялгыз бит,— дип җавап бирде Хисаметдин менла.

Әмма бу килешендә Хисаметдин бик уңышлы вә бәхетле булды. Гүзәл Хәнифәнең чистарынып-таранып, киенеп-ясанып базарга чыгып китүен менлабыз тәрәзәдән күрде. Бераздан, халыкка белдермичә, гүя үз эшенә киткән кебек, мөсафирханәдән чыкты вә бер-ике йортны узгач, Хәнифә туташны куып җитте. Вә узып киткән чагында яшь егет әйләнеп караганда, кыз шәкәр иреннәрен вә энҗе тешләрен күрсәтеп көлеп алды.

Менла да, чын күңелдән шатланып, кызга гыйшыклык көлкесе илә җаваплады. Ике яшь, бер-берсенә багышып, бәхетле булдылар. Халыкның дикъкате тупланмасын дип, менла, бераз калып, кызның артыннан китте. Хөрмәтле укучыларым, хәзер әлбәттә аңладыгыз ки, бу ике яшь бер-беренә гашыйк улмышлар.

Бара торгач, яшь кыз бер кибеткә керде. Шәһәр тротуарларында йөрегән адәмнәр һәрвакыт күп булганлыгы мәгълүмдер; кем кемгә кирәк, һәркем үз эшендәдер. Менлабыз, кибеттән ерак китмичә, йөренеп калды. Гаҗәптер ки, әүвәл вакытларда менлабыз кызны узып киткәндә күрсә дә бик шат була иде, ә инде хәзер бер күрү белән генә канәгатьләнмичә, морады янә артты. Вә хис итте ки, йөрәге кыз белән еш хәбәрләшмәкне, күрешмәк вә күзгә-күз сөйләшмәкне тели. Гыйшыклык шулай ул. Ахыр чиктә, кыз кибеттән чыккан вакыт, Хисаметдин менла тугры аңа каршы барып узганда, әкертен генә бу сүзләрне әйтеп алды: «Хәнифә ханым, иртән таң илә бакчада сарайдан егерме бишенче казык төбендә, таш астында бер гаҗәеп нәрсә табарсыз. Алла өчен алып карагыз, үтенәмен!» — вә сүзләрен бетереп узып китте. Хәнифә туташ исә, бер җавап та бирмичә, туры өенә китте. Хисаметдин менла Әбүзәр бәккә юлланды.

Юлда күргәнебез Әбүзәр Дәүләтгилдиев 18 яшьлек улып, ак йөзле, назлы вә нечкә-гүзәл табигатьле егет иде. Гимназиянең 7 нче сыйныфында укый иде. Бер рус өендә ике бүлмә фатир алып тора иде. Ике дус гадәттәгечә исәнләшеп күрешеп, гади нәрсәләр хакында бик озак сөйләшмәделәр, сүзләре Әбүзәр бәкнең башында озак вакытлар йөргән гомуми мәсьәләләргә күчте:

— Менла, синең ышану-инануың бик яхшыдыр,— дип сүзгә керешге Әбүзәр бәк,— тугры әйтәсең, ислам дине — иң хакыйкать дин, иң олуг дин, мин үзем дә шушы инануда торамын. Ләкин Аурупа әдипләренең кайберләре, ислам диненә тиеп, кимчелекләр табалар. Ни өчен алар исламиятне аңламыйлар икән? Син миңа әйт,— диде.

— Нинди кимчелек табалар? — диде менла.

— Мәсәлән, Аурупа әдипләре диер ки, исламият хатын җенесене хур күреп, кысынлыкта тота, имеш. Ислам хатыннары укый-яза аз белер, имеш.

— Ялганчыдыр синең Аурупаң, ислам шәригате хатыннар хокукын һич тә кысмый; уку хакында исә хәзрәте рәсүл димеш ки, гыйлем үгрәнмәк һәр мөслимгә һәм мөслимәгә фарыздыр. Безнең хатыннарыбыз надан булсалар, монда үзебез гаеплебез, юкса һич исламият түгел,— дип аңлатты менла Хисаметдин.— Аурупаның ислам дине хакында хата сүзе бик күп. Икенче мисал: аурупалыларның уйлавынча, исламият эшлексезлек вә ялкаулыкка ярдәм итә, имеш. Шуңа күрә Аурупа халкындагы, мәсәлән, инглиздәге кебек булмыйча, исламнарның кәсепчелеге вә һөнәрчелеге бик начар вә түбән дәрәҗәдә, имеш. Инглиз кебек кәсепче улмадыгыбызга сәбәп шулай ук үзебез, һич тә шәригатебез түгел. Киресенчә, шәригать юлы белән барсак, безгә инглиздән остарак булу тиеш килә. Шәригатебез урламак вә башка кебек яман кәсептән тыеп, яхшы вә хәлаль кәсепне, киресенчә, саваптан хисап итәр. Чөнки рәсүле әкрәм саллаллаһе галәйһи вә сәллам димештер ки. (...)

— Бу хәдиснең мәгънәсе нәдер? — сорады Әбүзәр бәк.

— Бер кемсә хәлаль кәсеп кылмакыннан арып кич үткәрсә, тиеш булыр аңа җәннәт. Вә кич үткәрер икән, Алла ул кешедән разыйдыр,— җавап биреп, мәгънәсен әйтте Хисаметдин. Һәм болай дип өстәде:

— Ягъни хәдиснең мәгънәсенчә, эшлеклелек һәр җәһәттән файдалы вә саваплыдыр.

— Исламиятнең тырышлык вә гайрәткә өйрәтүен тарихка мөрәҗәгать итеп тә беләбез,— сүзгә кереште Әбүзәр бәк,— мәсәлән, әүвәлдә күчмә-кыргый тормышта вә хайван кебек яшәгән гарәпләр исламиятне кабул итү белән үзгәрделәр. Исламият нәтиҗәсендә тырышлык вә гайрәтләре артып, гарәпләр хәлифәләр заманында шундый бер мәмләкәт төзеделәр ки, ул вакыт гарәп җиреннән олуг җир юк иде: Азиядә булган Һинд елгасыннан Аурупадагы Пиреней тауларына кадәр гарәп җире, ислам дәүләте булып, бу дәүләттә исламият аркасында никадәр

булдыклы хакимнәр, никадәр камил табиблар вә голямалар мәйданга чыкты! Кыскача әйткәндә, исламият нәтиҗәсендә гарәпләр мөстәкыйль бер мәдәният төзеделәр.

— Минем уйлавымча, бәян иткәнең олуг гарәп җиренең харап булуына сәбәп халифәләрнең исламият күрсәткән юлдан чыгуларыдыр. Юкса халифәләр ислам шәригатенчә торсалар иде, ул дәүләт хәзер дә яшәр иде,— диде Хисаметдин менла. Бу сүзләрне дигәч, Хисаметдин, сәгатенә багып: «Сәгать күп икән, миңа мәктүп язмак кирәк»,— диде. Вакыт иреште. Каләм-кәгазь алып, башка бүлмәгә кереп, Хисаметдин мондый бер мәктүп язды:

«Җаным, Хәнифә ханым!

Нурлы йөзеңне әүвәл күрдекем илә бөтен барлыгым тәэсирләнде. Күпме вакытлар хыялымда синең гүзәл сурәтең пәйда була. Күпме кичләрдә йокымда син кадерлемне күрмәктәмен. Әүвәл вакытларда, синең хактагы уйларым — буш уйлар дип, гүзәллегеңне башымнан чыгарып атарга тырышкан идем, ләкин бу тырышлыгым юкка гына булды; зиһенемдә сине йөрәк бәгърем итеп тоеп зәвыкләнмәктән үз-үземне тыярга тәкатем калмады. Гыйшык дәртенә дучар улмышым икән. Мине бәхетле итүче нәрсә синең мәхәббәтеңдер, газизем! Мәхәббәтеңнән аянычлы-үкенечле итмәсәң, бик тә бәхетле булынырмын, әмма, киресенчә, аянычлы итү минем өчен бик зур бәла булыр вә бу бәлагә түзүне бер Ходадан сорарга калыр. Инде сиңа ялварам, йөрәк парәм! Гыйшыкыма каршы мәхәббәтеңне бирермесең? Әгәр ким-хур санамыйча, берәр юл җавап язарга мәрхәмәт кылсаң, шул таш астына иртәгә ун сәгатьтә куюыңны үтенеп калучы, күңел вә җаннан гашыйк Хисаметдин».

Хатны конвертка салып вә Әбүзәр илә саубуллашып, менла мөсафирханәгә кайтты. Ястү намазы җитешкән вакытларда менлабыз, комган алып, гүя тәһарәткә чыкты вә бакчага кереп, сарай читеннән егерме дүрт казык санап, егерме бишенчесенә җитешеп, әлеге хатны куйды вә таш бастырды ки, җил очырмасын. Намазларын укып, эшләрен тәмамлады. Фәкать бу төнне менла бик рәхәтсез кичерде, чөнки җавап булырмы йә булмас-

мы? Шундый уй-фикерләр аның йокысын качырды. Икенче көн иртә Хисаметдин, бакчага чыгып, хатның куйган җирдән алынганлыгын күреп, гаять шат булды. Мәктүпне Хәнифә туташ кабул итеп алган икән, карап карыйк, җавап булырмы? Җавап булачак вакытны, ягъни икенче көн иртә вакытны көтү менлабызга бик кыен булды. Бу бер көн менлага бик озын тоелды. Һәрничек булса да шәһәрдә йөреп, базарга, кибетләргә чыгып, көч-бәла илән бу көнне уздырды. Карынын кайгырткан гади кеше ураза вакытында көннең узуын ничек көтсә, шулай менлабыз да көннең тиз үтүен тели иде. Ниһаять, зарыгып көтелгән икенче көннең иртәсе булды. Вәгъдәләнгән вакыт җитте.

Хисаметдин менла, кемгә дә белдермичә, гүя йөреп кермәк нияте белән бакчага чыкты вә теге казыкның янына килеп, тетри-тетри вә курка-курка ташны күтәреп, мәктүпне алды. Үз мәктүбе алынмыш икән, бу мәктүп аңа охшамаган иде.

Өйгә кереп, мәктүпне ачып, мондый сүзләрне укыды:

«Гыйззәтлү Хисаметдин хәзрәтләре!

Мәктүбегездән аңлашылдыгына күрә, мәхәббәт вә гыйшыкыңызны белдергән булсаңыз да, бу гыйшыкыңызга ышанып карау мөмкин түгелдер дип уйлыйм. Чөнки куәтле вә чын мәхәббәт бер-беребезнең тышкы кыяфәтләребезне күреп кенә хасил булмас, сез тышкы күренешемне яраттыгыз, бәлки мин эчтән яманмын? Бәлки әхлаксызмын. Куәтле гыйшык икебезнең дә әхлак вә табигатебез беленгәч барлыкка килер. Һәр никадәр әңгәмәләрегездән яхшы фикерле, ислам сөюче булуыгызны аңласам да, сез минем әхлагымны вә табигатемне белмисез. Сезнең тугры кеше булуыгыздан ышанам ки, сез гашыйк булгансыз, ләкин гашыйк булгансыз тышкы кыяфәтемә. Мондый гыйшык исә ышанычлы түгел, шуңа күрә бер-беребезнең табигатьләре вә әхлаклары аңлашылмадыкча катгый җавап бирергә батырчылык итә алмыйм. Мәгълүмегез Хәнифә».

Бу хатны укып, менла уй-фикер дәрьясына батты. Әмма хатның эчтәлегеннән сизелгәнчә, мәхәббәткә катгый каршылык күренмәгәнлектән, менла бераз юанды, ләкин мәхәббәт тарафы бераз көчәйде. Чөнки беренче: ихтирам күрсәтеп,

Хәнифә ханым хатка җавап язган; икенче: менланың гашыйк булуына да ышанган; өченче: җавабын шулай итеп язган ки, җавапка җавап язарга юл калдырган.

Әлеге хәбәрләшүдән соң Хисаметдин тиз көндә янә шәһәргә юнәлде, ләкин, шик чыкмасын өчен, бу юлы Габбас агайга төшмәде. Дусты Әбүзәр бәккә төште. Шулай да ничек булса да егерме бишенче казык төбенә менла тагы мәктүп куйды. Бу мәктүбендә Хәнифәгә җавабы өчен рәхмәт әйтеп, соңра гыйшыклык белән тулып сибелгән сүзләре арасында игълан итте ки, Хәнифә ханым көтелмәгән бер вакыйгага хәзерләнсен.

Икенче мәктүп ирешкдектән өч көн соңра, көн урталары кичкәч, Хәнифә туташ кече бүлмәдә тәрәзә төбендә тегү тегеп утыра иде. Кинәт урамнан тәрәзә янына вак-төяк сатучы бер венгр пәйда булды. Венгрның башында зур кара эшләпә, өстенә кара сюртук кигән. Бу венгр Хәнифә туташка эндәшеп, ярты-йорты русча сөйләп, инә-төймә алырга тәкъдим итте вә янә диде: җепләр, оеклар, борын яулыклары кирәкмәсме? Венгрның тавышы Хәнифәгә бер таныш тавыш кебек ишетелде. Күзләре дә, тавышы да Хисаметдин менланыкына охшаган. Шулай да зур кара сакал, озын мыеклар Хисаметдин менланыкы кебек түгел. Хәнифә туташ башын тәрәзәдән чыгарып дикъкать иттектә, әлеге венгр татарча әкертен сөйли башлады: «Җаным, Хәнифә ханым, синең белән күзгә-күз күрешеп сөйләшүне йөрәгем тели».

Инде, хөрмәтле укучыларым, бу ялган венгр Хисаметдин менла иде. Гыйшыклык дәрте шулай эшләргә мәҗбүр итте. Сюртук вә эшләпәләр тапмак менлага көч түгел, мыеклар, сакаллар вә кашлар куймак шәһәрдәге парикмахерның һөнәре иде. Туташыбыз, бердән, бу менланы танып, һаман нишләргә белмичә аптырап вә югалып калды. Гашыйк вә гашыйка арасында аз гына тынлык булып алды. Шуннан соң ялган сатучы сабырсызланып: «Җаным, кил якынрак, сиңа сүзем бар»,— дип әкертен генә дәште. Ике яшь бер-берсенә якынлаштылар. Сатучыбыз киндерен сүтеп үзе инә вә төймәләрен күрсәтер, үзе әкертен генә колактан колакка мәхәббәт сүзләре чәчәр. Төрле сүз арасында Хисаметдин менла: «Газизә Хәнифә, синең ялгыз

тышкы кыяфәтеңә түгел, шулай ук матур күркәм холкыңа гашыйк булдым»,— диде.

— Каян белдең минем яхшы холкымны? — дип, назлы вә нечкә тавыш илә сорады Хәнифә.

— Синең хакта турылыклы кешеләрдән яхшы сүзләр ишеттем. Яшьлектән гыйлем вә укуны сөйгән кешенең әхлак вә фикерләренең яман булуы шөбһәледер. Кил, йөрәк бәгърем, бир җавап, миңа мәхәббәт итәсеңме?

— Итәмен,— сүзе Хәнифәнең авызыннан гүя ирексездән атылып чыкты. Бу сүз венгр сурәтенә кергән Хисаметдинга никадәр ләззәтле, никадәр хуш сүз иде ки, тәэсире колагыннан бөтен тәненә китте. Моннан соң ялган венгр Хәнифә туташка бер ядкяр чыгарып:

— Моны сиңа ядкяр-истәлек итәмен,— дип, алтын йөзек Хәнифәгә бирде.

— Нинди йөзегең нурлы,— диде Хәнифә.

— Синең йөзең кебек. Ки, багаек.

Хәнифә туташ көлә-көлә кияр:

— Бак, нинди чак килде, әйтерсең бармагыма үлчәнгән.

— Килешсә, бик хуп,— диде ялган венгр.

— Бик килешә, мин моны ерак яшерермен вә аулакта йөзегеңне чыгарып киеп вә карап сине исемә алып шатланырмын. Шулвакыт Хәнифәнең анасы ишектән кереп:

— И кыз гына! Ни монда тубалчылар белән маташасың? Тиз бире кил, эш бар,— дип, Хәнифә туташны чакырып алды.

Ялган венгр исә үз юлына китте.

V

Шул көн кич Әбүзәр бәкнең арендага алган фатирында бер җәмгыять булды. Бу җәмгыять өч кешедән гыйбарәт булып: бере Әбүзәр бәк, бере Хисаметдин менла вә бере теләнче ятим Мохтар иде. Җәмгыятьнең тышкы яктан торышына карасаң, хәйран калырсың. Әбүзәр бәк бәһалы кара сукно сюртук, чалбар кигән. Алтын ука илә чигелгән такыясы вә алтын сәгатьләре мал иясе вә зур бәкләрдән идекенә бер дәлил кеби

күренерләр иде. Теләнче Мохтарның өстендә кырык ямаулы сары чикмән, пычрак чабаталары паркетлы идәнне пычратмышлар вә чуарламышлар. Хисаметдин менланың өстендә яхшы сукно бишмәт, аягындагы читекләре яхшы килешерләр иде. Сорамак мөмкин ки, бу өч, бер-берсеннән аерылып торган кешеләр нидән берләшкәннәр соң? Бере бәк, гимназист, бере укымышлы менла, берсе гади теләнче. Нидән алар бер-беренә ярашканнар? Нидән дуслашканнар? Сәбәбе будыр ки, бәк илә Хисаметдин менланы милләт мәнфәгатен кайгыртуда булган уртак сыйфат якынайткан иде. Алар, татарны наданлык дәрьясыннан коткарып, гыйлемнәр илә нурландыру кирәк икәненә һәр икесе бер үк дәрәҗәдә ышаналар иде.

Ышану һәм фикер уртаклыгы булган кешеләр арасында якын дуслык барлыкка килүе билгеледер. Сәүдәгәр сәүдә уенда булган башка сәүдәгәр белән белешер, игенче игенче илә катнашыр һәм башкалар. Мохтарга килгәндә, бу зат үзе галим булмаса да, боларның милләт өчен тырышып йөрүләрен аңлады. Үзе белде ки, Мохтарны теләнеп йөрүдән яптырып тыюлары боларның милләтпәрвәрлегеннән иде. Чөнки дин кардәше соранмак илә фәкыйрьлек бәласенә дучар булмасын дип яптырганлыкларын Мохтар яхшы аңлады. Сүз ачылгач, ябылу хакында да берәр сүз әйтик. Хисаметдин менла, шәһәргә килеп, авылдашы Мохтарның теләнеп йөрүен күреп:

— Бу эштән яхшырак эш тапмадыңмы? Кил, кайт бу хәрәкәттән,— диде.

Мохтарның исә, бу сүзләргә илтифат итмичә, һаман теләнүдә дәвам итүен күреп, Хисаметдин Әбүзәр бәк белән киңәш итте. Соңра бу ике дус, «урлап йөри» дип, Мохтар өстеннән полициягә жалоба бирделәр вә, ялган шаһитлык итеп, аны полиция участогына яптырдылар. Мохтар, болай эшләүнең дин кардәшлеге өчен булганлыгын аңлап, аларга мәхәббәт белән карый башлады вә, алардан үрнәк алып, үзе дә милләт файдасына гайрәт вә тырышлык итәргә карар бирде. Кыскасы, бу өч кешене үз халкын ярату — милләтпәрвәрлек берләштерде. Милли патриотизм исә, гаҗәеп эшләргә сәбәпче булып, һәр

олуг эшләрнең чыганагыдыр. Мәсәлән, тарихка мөрәҗәгать итсәк, рус падишаһы Олуг Петр сирәк очрый торган милләтпәрвәр адәм булганлыгын күрәбез. Бу падишаһыбыз Петрның милләтпәрвәрлеге сәясендә — милли патриотизмы аркасында Русиядә яңа законнар һәм реформалар юлында алмашынулар мәйданга чыкты. Хәзер дә бар булган университетлар ачылды. Руслар диңгез фәннәрен өйрәнә башлап, пароход вә сугыш көймәләре мәйданга чыкты. Руслар механика гыйлемен, техника гыйлемен өйрәнә башладылар. Олуг Петр милләтеннән кыйммәтле бернәрсә белмәс иде. Башында-уенда һәрвакыт рус вә рус, вә рус иде. Диде ки, миллионнарча русларым миңа бер углымнан бәһалыдыр...

Наполеон, француз патшасы, 1812 елда Москва шәһәрен алып, барлык руслар җиңелде дип уйлады.

Юк! Русларның пайтәхете (башкаласы) алынса да, милләтпәрвәрлекләре — милли патриотизмнары алынмады. Наполеонны хур итеп, Русиядән сөрделәр. Бу ике тарихи мисалдан милләтпәрвәрлекнең куәтен күрдегез, хөрмәтле укучыларым! Бәс, һич хәйранга калмагыз ки, милләтпәрвәрлек чабаталы илә бәһалы киемнәрне дус әйләде.

Әмма, гафу итегез, мин хикәямнең асылыннан бераз аерылып киттем. Бәс, бу өч дус кызышып-кызышып сөйләшмәктә иделәр. Ятим Мохтар үзе турында болай диде:

— Мине теләнчелектән тыйдыгыз, бик рәхмәт сезгә. Моннан соңра бер кәсепкә тотынырмын, дусларым! Сездән бик гыйбрәтле сүзләр ишеттем, һай, ничек мин укымый калдым! Наданлык бөек бәладер.

— Наданлыкка карама, яхшы күңелле кеше булсаң, син дә файдалы булырсың,— диде Хисаметдин менла.

— Нинди файда? Гыйлемем дә юк, милкем дә юк. Һич булмаса милкем булса иде, исламиятебез мәнфәгатенә һәрвакыт сарыф итәргә хәзер булыр идем.

— Тугры сүз,— диде Әбүзәр бәк,— тормышта иң зур куәт акчадыр. Бу куәт илә милли мәгарифебез юлында күп эш кылырга мөмкин булыр иде.

— Әлбәттә, акча илә мәңгелек шөһрәт казанырга мөмкин. Ләкин корсак тутырудан башка бернәрсәне белмәгән акча иясеннән ни файда килсен? Мондыйлар кешеләргә файда итүне уйларына да китермиләр. Шуның өчен алар күмелгәч үк онытылалар,— бәян итте менла.

— Юк, дуслар, минем акчам күп булса иде, атымны онытмаслар иде,— диде Мохтар.— Шулай да бер морадым бар, бай булырга телим.

— Кәсеп ит, бай булырсың,— диде Әбүзәр бәк.

— Һәрбер кеше кәсеп итеп бай булуны теләр иде, ләкин бай була алмый,— дип җавап бирде Мохтар.

— Теләкнең теләге бар, чын күңел илә теләп, тырышлык илә кәсеп итсәң, бай була алырсың. Чөнки кеше гакылы бик куәтле нәрсәдер,— диде Әбүзәр бәк.

— Сүзең тугры, тырышып кара,— дип сүзгә кереште Хисаметдин.— Хәзрәте рәсүл димеш ки (...) ягъни кем иҗтиһат итәр, ул табар.

— Син ни өчен соң иҗтиһат итеп тапмадың? — сорады ятим Мохтар.

— Мин байлык эзләмәдем, гыйлем эзләдем. Бераз таптым, әлхәмделилла.

— Сиңа бай булу мөмкиндер,— бәянга кереште Әбүзәр бәк,— хәзер сиңа 18 яшь. Бу яшьтән кискенлек вә әрсезлек илә байлык эзләсәң, бәлки табарсың, кеше гакылы ниләр кылмас!

— Мин сатуга керешер идем, ләкин бер монет кадәр дә акчам юк.

— Егерме-утыз монет (сум) акча эш башламак өчен мин дә бирер идем,— диде Әбүзәр бәк.

— Юк, юк, Әбүзәр бәктән акча алма, кеше акчасы илә эш йөртү егетлек түгел, һәм дә эш файдасыз булып китәр, чөнки акчаның кадерен белмәссең,— диде Хисаметдин.

Бу сүзләр Мохтарга никадәр ачы килсә дә, менланы тыңлап, Әбүзәр бәктән акчаны кабул итмәде.

Бу өч дус сөйләшә-сөйләшә күп вакыт утырдылар. Төн урталары җиткәч, Мохтар мөсафирханәгә кунарга китте. Юлда

баемак хакында уйланыр иде, вә шулвакыт башында мондый фикер барлыкка килде: «Үз гайрәтем илә бәлки баермын, моның өчен миңа йөз монет кирәк. Аннан соңра эшләр уңайланыр. Әмма моны ничек казанырмын икән? Сабыр! Әбүзәр бәкнең бер белеш извозчигы бар, бәкнең тәкъдиме белән бу извозчикка хезмәткә керермен, әрсезлек вә кискенлек илә һәр көн берәр кәпик (тиен) тапсаң да, заман узу белән баемый калырга мөмкин түгелдер. Шундый әрсезлек кирәк ки, бер кәпик тапмай көнең узмасын. Әмма мин көн дә кәпик түгел, егерме кәпик табармын, айда — алты монет, бәс, елда 72 монет була. 72 дән йөзгә кадәр күп түгел. Аннан соңра эшләр куәтләнер. Кыскасы, баемак бик мөмкин,— дип, кискен карар бирде Мохтар.

VI

Яз башының яхшы бер көнендә Бикбулат мулла хатыны белән Габбас агайга килеп төште. Шул уңай белән Габбас аганың өендә зур бер хәрәкәт-гөрелте купты. Габбас аганың хатыны Шәмси абыстай (асылда аты Шәмсекамәр иде, ләкин атын бозып Шәмси диләр иде) күптән бу мулланың килүен өмет итә иде. Чөнки халык арасында сүз бар иде ки, Гали бай угылына Хәнифәне сорарга Бикбулат мулланы башкода итеп җибәрә, имеш. Шунлыктан Шәмси абыстай, боларның килүен күргәч, гаять шат булды. Ни өчен шатланмасын, кызын шундый байга сорарга килгәннәр. Гали бай Җаватов кебек кешеләр бөтен губернага бер-ике генә булалар бит.

Шул уйлар белән иләсләнеп, Шәмси абыстай өйдәгеләргә кычкырына башлады:

— Тиз-тиз, кызым, яхшы гына киен, ризыклы булырсың, мөдәррис әфәнде хәзрәтләре үзе һәм дә абыстай килгән ич.— Шунда ук хезмәтчеләренә эндәшеп:

— Әй сез, яшен кебек әйләнегез, кунакларга яхшы дикъкать итегез,— диде.

Габбас ага мөдәррис хәзрәтләрен хөрмәтләп-олылап каршылады. Шәмси абыстай аның хатынын каршылап үз бүлмәсенә кертте. Моннан соң кунакларга сыйлар, хөрмәтләр башланды.

Башта гадәтчә самавыр мәйданга чыкты. Ашханәдә гайрәт вә хәрәкәт купты: коймаклар, пәрәмәчләр бер-бер артлы пешә башладылар, камырлар басылып, катламалар, кош телләре хәзерләнде. Хезмәтчеләр, ашчылар зур бер хәрәкәттә. (...)

Ниһаять, чәйдән соң Бикбулат мулла Гали байдан күндерелгәнлеген игълан итеп, Хәнифәне Сибгатулла әфәндегә хатынлыкка бирмәк хәерле булмасмы, дип әмер иткәндәй ныгытып әйтте. Аңа җавапта Габбас ага:

— Яхшы, хәзрәт, киңәшербез. Киңәшләшкәч, катгый җавап бирербез,— диде.

Тиз заман ашханәдә янә хәрәкәт купты: шурпалар, пылаулар кунаклар өчен кайнап-кайный, хәтта ки мөдәррис хәзрәтләре йортка йөрергә чыкканда, майлы ашларның исе ашханәдән борынына җитешеп, ләззәт хисләре кичереп, теле тирәсеннән төкерек чыкты. Өйдә барчасы шат, фәкать Хәнифә туташ кына, үз бүлмәсендә ябылып, кайгылы торыр. Хәтта мулла хатыны моңа игътибар итеп:

— Ни өчен соң кызыгыз яныбызга чыкмый? — дип сорады. Шәмси абыстай моңа җавабында:

— Кыз кеше бераз ятсынадыр, гаеп түгел, абыстай,— диде. (...)

Икенче көн Габбас ага, башкодаларның тәкъдимен кире какмыйча:

— Икенче килүегезгә сүзне тәмамларбыз,— диде.

Вә шул хәлдә башкодаларны озатты. Габбас ага вә Шәмси абыстай бөек вә бай адәмнәр арасына кереп, кардәшлек вә руглыкка ирешәчәкләренә шат иделәр. Фәкать Хәнифә туташ, үзен Сибгатулла әфәндегә бирү морадларын аңлап, янә бик тирән борчуга төште. Үз-үзен Хисаметдинга яр итеп күз алдына китермәктә иде. Чөнки Хисаметдин бу көннәрдә егерме бишенче казык төбенә куйган хатында белдерде ки, Хәнифәгә өйләнү морады бар, әш бары Хәнифәнең теләгеннән генә торадыр.

Әмма шулвакыт ике яшьнең теләкләренә каршы Гали бай Җаватовтан башкодалар килде. Бу башкодалар Хәнифә туташ-

ка үткен пычак кебек күренделәр. Кискен пычактан да ачы нәрсә шул иде ки, атасы-анасы аны байга бирергә тырышалар. (...)

Кичке ашлар ашалды, өйдә барчасы ятып, каты йокыга талдылар. Бары Хәнифә туташ кына уяу хәлдә иде. Стенага тагылган сәгатьләр инде берне уздылар, яшь кыз, йомшак түшәгеннән торып, төрле якларга карап, һәммәсе йокыда икәнлекләрен белгәч, лампасын яндырып, каләм, кәгазь табып, мондый хат язды:

«Хисаметдин менла әфәнде!

Миңа өйләнү морадыгызны хатыгыздан күреп сөендем, сезгә хәлаль улмак миңа бик хуштыр, ләкин морадыбызга ирешүебез бик шикле булып китте. Чөнки Бикбулат мулла мине Сибгатулла әфәндегә сорарга бу көннәрдә килгән иде. Һәм дә атам, анам шат улып, мине аңа бирәләр. Мин никадәр каршылык күрсәтсәм дә: «Бармасаң, ирексезләп бирербез»,— диләр. Шуңа күрә мин кайгыдан нишләргә дә белмим. Шулай да бу юлларны сезгә язмак илә күңелем бераз юаныч тапты. Җаннан сезгә гашыйка булып калучы Хәнифә».

Бу мәктүпне язып, туташымыз, әкертен атлап, бакчага теге казык янына чыкты. Чөнки менланың мәктүбендә җавапны тап шул кичтә куярга кирәклеге әйтелгән иде. Казык янына җиткән вакыт Хәнифә туташ бердән туктады, төн бик тын иде, һичбер хәрәкәт ишетелми. Бары тик якындагы бер кечкенә чишмә челтерәп агадыр. Хәнифә туташның колагына бер хәрәкәт ишетелде. Төн бик караңгы түгел иде. Яшь кыз еракта бер кара нәрсә хәрәкәт иткәнен күреп, күңеленә курку төште. Яхшырак дикъкать итеп караса, белде ки, бу шәүлә адәмдер. Бу кеше, туташны күргәч, тизрәк атлый башлады. Хәнифә туташ кача башлаган иде, әлеге адәм:

— Курыкма, җаным, үзем киләмен! — дип дәшкәч, туташ бу кешене танып туктады. Бу кеше сөйгәне Хисаметдин икән. (...)

Менламыз, Хәнифәнең янына тугры килеп, диде:

— Ни өчен озак чыкмадың, саумысың, җаным?

— Әлхәмделилла! Әмма күп тору мөмкин түгел, күрешүебез миңа да хуш исә дә, куркамын ки, белмәсеннәр! — назлы, йомшак тавыш илә диде Хәнифә туташ.

— Курык-курыкма, мин сине тиз җибәрмимен, җаным! — диде менла вә, бер казыкны җирдән суырып чыгарып, бакчага керде. Хәнифә туташның уң кулыннан алып һәм бик тә зәвык белән кысып, яшь кызны бакчадагы кечкенә бер бинага таба алып китте. Бу кечкенә бина Габбас аганың мунчасы иде. Мунчаның эче пакь вә чиста иде.

Мунча сәкесенә кыз вә егет янәшә утырдылар.

— Безгә күптән шулай күрешү кирәк иде,— диде Хисаметдин, уң кулы белән Хәнифәне муеныннан кочаклап. Хәнифә туташ сул кулы белән менлага сарылды. Егет вә кыз бик бәхетле булып, икесенең күңелендә гыйшык уты яна иде. Гыйшык ләззәте белән ләззәтләнеп, егет вә кыз үбешеп, кочышып берберсенә якын сарылдылар.

— Син хәзер җавап куярга килә идең, мин сагалап көттем,— диде Хисаметдин.

— Бу хатымда мин сиңа бер яңа вакыйга турында белдермәкче булган идем, мине Сибгатулла Җаватовка бирәләр.

— Ничек ул булыр, кеше бит агач түгел, алып биреп булмый.

— Ничек булсын, мин хатымда да яздым, беләсеңме, Бикбулат мулла хатыны белән Гали байдан баш кодалый килгәннәр иде, бүген-иртәгә эшне тәмам итәчәкләр.

— Җаным, безне кем аерыр? Мәхәббәтебез шулкадәр көчле ки, безне ни Гали бай, ни атаң-анаң аера алмаячак.

— Аны син сөйлә, атай-анай әйтәләр ки, бармасаң, көчләп бирербез. Сөймәгән кешегә яр булу миңа агудыр.

— Җаным, син миңа яр булырсың. Минем мәхәббәтемне һичкем җиңә алмас.

Шулвакыт менла, түзә алмыйча, Хәнифәнең иреннәреннән суырып үпте. (...) Яшь кыз тәмам егетнең ихтыярына бирелде.

— Мин сине элек әдәп өчен яхшылык белән сорармын. Әмма бирмәсәләр, миңа Алла биргән ихтыяр куәтемә һичнәрсә каршы

килә алмас.— Бу сүзләрне әйткәндә егетнең күзләре ялтырады, тавышы бераз тетрәде, хәтта туташ бу каһәрле тавыштан бераз куркынды. Моны аңлап, менла, Хәнифәгә сөеп карап, болай диде:

— Курыкма, син мине янә элеккечә сөячәксең, ачуым килгәндә мин каһәрлемен, ләкин ачуым атаң-анаңа килде.

— Шәригатьчә дә көчләп бирү мөмкин түгел? Дөресме? — дип сорады Хәнифә туташ.

— Кияүгә чыгу эшендә кызларга тулы ихтыяр биреләдер. Алар, шәригатькә каршы килеп, яман булсалар, без дә яман булырбыз. Безнең ихтыяр вә хөрриятебезне-ирегебезне ала алмаслар. Җаным! Кеше тормышында бер бәһале вә яхшы нәрсә хөрриятгер. Без үз хөрриятебезне саклый белербез.

— Хөрриятсез яшәү көч вә газап-кысынкылык икәнен мин дә беләм,— диде Хәнифә туташ.

Бу сүзләр менланың күңеленә хуш килеп, диде:

— Дөрес әйттең, җаным! Фикерләрең минеке белән уртак икән.

— Болай булгач, бер-беребездән аерылмабыз! — диде Хәнифә туташ.

Зәвык вә сафа чигеп, ике гашыйк таң яралганны белми калдылар.

— Ничек урыныма кереп җитәрмен икән? Әни-фәлән намазга тормасын, җибәр, җаным, сәламәт бул! — диде Хәнифә туташ.

— Сәламәт бул! — диде Хисаметдин.

Яшьләр саубуллашып аерылыштылар. Менлабыз бакчадан чыгып юк булды. Хәнифә туташ, аяк бармакларына басып, үз бүлмәсенә узды.

VII

Берничә көн үтте. Хәзерге вакытта Хисаметдин шәһәрнең тимер юл вокзалында. Көн кичкә авышкан. Шәһәрнең һәммә халкы вокзалга җыелган. Чөнки бу поезд белән мөфти хәзрәтләре Петербургтан Уфага узачак, имеш. (...)

Вокзалның эчендә вә тышында анда-монда мөселманнар сөйләшеп йөриләр. Гали бай Җаватов бу шәһәрнең ахуны вә башка байлар белән бергә сөйләшеп тора. Бикбулат мулла да шунда күренә. Ләкин авызыннан «әйе, шулай»дан башка бер сүз дә чыкмыйдыр. Әбүзәр бәк Дәүләтгилдиев, ялтыравык төймәле формасын киеп, Хисаметдин белән йөри.

Барчасыннан ерак, вокзалның бер диванында яшь бер әфәнде утыра. Бу кеше, крымка бүрекне[1] бераз кырын киеп, һичкемгә кушылмаеп, утыргычның артына аркасы илә таянып, камыш таягы белән ачык калушларының йөзенә уйнап орыр иде. Күзләре дикъкатькә иң лаеклылар. Арыслан гайрәте белән карыйлар. Күзләре белән татарлардан һәрберсен йотып багар, һәр багышында кешенең эченә кереп чыгар. Бу вакыт әлеге арыслан күз, Хисаметдин менла белән Әбүзәр мирзага багып, сүзләрен тыңлый иде. (...)

Кинәт колокол каккан тавыш поездның килүен белдерде. Күп халык платформага чыгып, мөфтине күрергә өмет итте. Мөфти хәзрәтләре үзенә махсус бер вагон алган иде. Шәһәр байларының чакыруын кабул итте. Вагоннан чыкты. Исламнар бер-бер артлы мөфти хәзрәтләренә сәлам бирерләр иде. Күбесе кулын үбеп, түбәнчелек белән каршыладылар. Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев хәзрәтләре хәзерләнгән табын янына утырды. (...)

Хисаметдин вокзалда арыслан күзне эзли башлады. Ләкин теге арыслан күз инде вокзалдан чыгып киткән икән, аны тапмыйча, Әбүзәр белән вокзалдан чыгып: «Мохтар!» — дип, каты тавыш белән кычкырды. Шунда ук, җир астыннан чыккан кебек, артында извозчик Мохтар пәйда булды. Ике яшь егет Мохтарның арбасына утырып киттеләр. Юлда барганда Әбүзәр бәк Мохтардан сорады:

— Эшләр ничек, баеп буламы?

— Мең рәхмәт, сез урнаштырдыгыз! — диде Мохтар.

---

[1] *Крымка бүрек* — Кырым татарлары кия торган түгәрәк бүрек.

— Миңа рәхмәт кирәкмәс. Яхшы гына баерсың. Шул булыр җаныма хуш рәхмәт. Сөйлә, айда күпме табасың? — дип сорады Әбүзәр бәк.

— Егермедән егерме өч монетка кадәр табамын,— җавап бирде Мохтар.

— Соң ничек алай була? Егерме өч сум табасың, ә айлык хакың фәкать алты сум? — диде менла.

— И дустым менла! Айлык хакны инде сөйләмә. Извозчиклыкта башка юллар белән табалар. Әгәр йокламасаң, һәр көн казанырсың өч-дүрт сум. Ә хуҗага бары ике сум бирсәң дә, бик шат буладыр. Шулай һәр көн бер-ике сум яшереп каласың да, акча да җыела.

— Болай мал хасил итмәк тугры юл түгел,— диде менла.

— Бик тугры, чөнки ул акча өчен бәлки ничә төн йокланылмый. Моны ат хуҗасы үзе дә аңлый, һич сүз әйтми, зарар юк,— җавапланды Мохтар.

— Әлбәттә, хуҗа аңласа бу эшне һәм дә рәнҗемәсә, зарар юк,— диде менла.

— Кара, эшне бел! — диде Әбүзәр бәк.

— Аллага шөкер, хәзердә илле монет акча тупладым,— диде Мохтар.

— Эшлә, эшлә, әүвәл җәфа, соңра сафа,— сүз кушты Хисаметдин.

Сөйләшә-сөйләшә яшьләр бер йорт янына җитеп, арбадан төштеләр. Бу йортка төшереп, Мохтар күздән югалды. Бу өй зур агач өй булып, ишегалды мәйданы киң иде. Яшьләр зур өйгә кермичә, бакчага үтеп, анда булган бакыр мастерскоена керделәр. Бакырханә эче тузан вә бакырчы хезмәткәрләр белән тулы. Анда самавыр төзәтәләр, монда лампа төзәтәләр. Бер тарафта молоток-чүкеч илә бакырны чик-чик сугып, башны авырттыралар. Бу бакырханәнең хуҗасы теге, вокзалда күргәнебез, арыслан күз Зурколаков иде. Әбүзәр бәк белән Зурколаков шулкадәр якын дус иделәр ки, гүя боларның ике гәүдәсенә бер җандыр. Мондый дуслыкның сәбәбе бу ике зат уй-фикерләренең уртак булуыдыр.

Әбүзәр бәк татар тормышы хакында фикерләрен күп җирдә сөйләсә дә, һичкем аңламады. Кайбер татарлар: «Фән вә фән, мәгърифәт, гыйлем вә һөнәр кирәк дип сөйлиләр, бу ни сүз? Гыйлем вә мәгърифәтсез дә гомер итә беләбез»,— дип, Әбүзәр бәктән көлделәр. Кайбер исламнар болай диделәр: «Һөнәрле, мәгълүматлы кавем булу, әлбәттә, яхшыдыр, ләкин татар милләте һөнәрле була алмас. Бик күп еллар узды, татар милләте зыяланмады да, инде Әбүзәр кебекләр татарны башка милләтләр шикелле һөнәрле вә мәгълүматлы итәргә телиләр, бу — мөмкин түгел»,— дип, Әбүзәр бәктән көләләр иде. Әбүзәр бәк, мондый татарларга ачуланып, дияр иде ки: «Әфәнделәр, мең еллар узды, татар зыяланмады, дисез. Зыяланмадык шуның өчен кем, эчебездә мәгълүмат алырга омтылыш, теләк юк иде. Мең елларга бакмагыз, бу вакыттан зыялыланырга омтылыштеләгебез уянса, заман узу белән без дә мәгълүматлы булырбыз. Ләкин мең еллар шулай узды дип, йоклауда дәвам итсәк, мең түгел, янә миллион еллар үтәчәк вә без искечә наданлык дәрьясында калырбыз вә үзебез һөнәрләр белмичә, башка милләтләргә хезмәтче вә кол булырбыз. Бәс, телик мәгърифәтне вә һөнәрне, чөнки татар да ярты гакыл түгел, зиһене бик камилдер. Зыялы булырга сәләтле бер халыктыр. Уяныгыз, кардәшләр! Уйланыгыз, моның кеби гакылсыз дәлилләрегез илә үзегездән көлдермәгез! Карагыз башка милләтләргә, бигрәк тә французларга, немецларга: болар суда көймәдә балык кебек йөзү түгел, һавада кош кебек очу машинасы төзи беләләр. Әмма безнең сукалау белән вак сәүдәдән башка һөнәребез юк кебидер... вә фәлән... фәлән». Бу юлда Әбүзәр бәк һәр никадәр сөйләсә дә, фикерләрен һич кемсә аңламас иде. Кыскасы, бу фикерләр стенага борчак сипкән кеби иде. Татарны зыяландырудан өметен кисәргә дә аз калган иде. Ахыр чиктә Әбүзәр өметсезлектән котылды. Зурколаков та мондый идеяләргә күңел беркеткән кеше иде һәм Әбүзәр бәккә фикердәш булды. Икенче дусты Хисаметдин шулай ук аның фикерләрен хуплар иде.

Әмма максудыбызга килик. Гайса Зурколаков, егерме алты яшьлек бер егет булып, һөнәре бакырчылык иде. Бакырханәсе

атасыннан калган иде. Хәзердә атасы вафат булган, Гайниҗамал исемле карт анасы бар иде. Атасы исән вакытта Гайсаны мөселманча вә бераз русча укыткан иде. Яшь вакытларыннан бирле Гайса Зурколаков ислам вә рус, гыйлем вә һөнәр китапларын укырга һәвәс егет булды. (...)

Гайниҗамал абыстай алтмыш яшьләренә җитмеш бер хатын иде. Гаять диндар, яхшы вә хакыйкатьле хатын. Шәһәрнең барча халкы Гайниҗамал абыстайны хөрмәт итәләр иде. Гайниҗамал абыстай менланы күреп болай диде:

— Менла, син улымның хәлен белергә күптән килмисең?

— Хәзердә хәл белергә килдем, абыстай. Сиңа бер үтенечем дә бар.

— Нинди үтенечең, менла, сөйлә, ишетәек.

— Безгә мәрхәмәт итеп, башкода булсагыз иде, абыстай. Өйләнергә телим, Габбас аганың кызын сорасагыз, бик зур мәрхәмәтегездән булыр иде! — диде Хисаметдин менла. (...)

Бер өч-дүрт көннән соңра Гайниҗамал абыстай Габбас агайга башкода булып барды исә дә, Хәнифәне бирергә якын да килмәделәр. Хәнифә туташ Сибгатуллага бармаячагын вә менла Хисаметдинга бару теләген һәр никадәр анасына сөйләсә дә, Шәмсекамәр абыстай кызына:

— Үз файдаңны үзең белмисең, ризыклы вә бай хатын булырсың. Сабыр ит, Сибгатуллага бирербез. Сүземне тыңла: син бала, мин ана! Баштан колак зур булмый,— дип, Хәнифәне үгетләде. Үзенчә төрле чаралар кылды.

Шәһәрдән илле чакрым ераклыкта бер авылда торучы ишан вә багучыны китертеп, бу ишан Хәнифә туташны Хисаметдин менладан суытмага вә Сибгатулла әфәндегә җылытмага, ягъни мәхәббәт иттермәгә кереште. Вә бу хәйлә илә Хәнифә туташка догалар эчереп вә аягына туфраклар ташлап вә шуның кеби башка нәрсәләр эшләп, ишан хәзрәтләре Габбас агада бер атна кунак булып ятты. Киткәндә: «Инде курыкмагыз, эшемне тәмамладым»,— дип, Габбас агадан акча һәм әйберләрдән гыйбарәт күп бүләк алды. Ләкин хәзерге заманда суытмак вә җылытмак, сөйдермәк вә биздермәк һөнәрләрнең юк

нәрсә икәнен вә мондый һөнәрләр — булмый торган эш, чын ялганчылык вә шарлатанлык икәнен һәрбер зиһенле кеше яхшы белер.

VIII

(...) Август аеның якты бер көне иде. (...) Авыл өстендә зур шау-шу вә гөрелтеләр купты. Түбән очтан өчәр ат җигелгән ун арба җил кебек киләләр.

— Бай туе, бай туе башланды! — дип, халык, умартадан чыккан корт кеби, өйләреннән тамашага чыга башладылар. Туй җәмгыяте урам буенча әйләнә, мылтык атудан, кыңгырау тавышыннан колаклар тона. Урамны төтен алды, бер сугыш купты дип уйларсың. Алдагы колясканың мылтыклары артыграк гөрселдиләр, бу коляскада кияү булачак Сибгатулла әфәнде һәм кияү егетләре утырган, атлары яшен кебек йөгерә. Хәтта ки юл аша узып баручы бер эт, өлгермичә, коляска көпчәкләре астында калып, уртага ярылып, эчәкләре һаваны бераз исләттеләр. Туй Хисаметдин менланың йорты каршысына җиткәндә, Сибгатулла әфәнденең кушуына күрә, мылтыклар тагын да көчлерәк гөрселди башладылар. Сибгатулла әфәнде шул мылтык шартлаулары белән үзенең җиңүче булуын Хисаметдин менлага күрсәтергә уйлаган иде. Ләкин Хисаметдин, өйдә булмаганга, үзенең җиңелүен күрә вә ишетә алмады.

Сибгатулла әфәнде бик шат булып, туй мәҗлесен зур һәм тантаналы итеп ясады. Ни өчен шатланмасын, теләгенә ирешә, бу көн Хәнифәне аладыр! Кияү егетләре һәммәсе бал бузасы әсәреннән кып-кызыл кызарганнар. Сибгатулла әфәнде бигрәк тә кызарган иде. Ул, кияү егетләренә карап: «Суттерт, йөздерт!» — сүзләрен бик шатлык илә әйтә. Кыскасы, туй процессы ишетелмәгән вә күрелмәгән бер сурәттә башланды. (...)

Көндезге сәгать дүртләр иде. Кояш үзенең нурларын вә эсселеген чуар булып җәйрәп яткан кырларга чәчә. Сабан басуы дип аталган кырларның күренеше бик гүзәл иде: солы, карабодай вә тары үсеп утырган кырлар күзләргә кызгылт, аксыл, саргылт төсләрдә күренәләр иде. Кырларның гүзәллеге шат туйчыларны тагы да шат итә иде.

Туй җәмгыяте «Н» авылыннан биш чакрымнар киткән бер вакытта, көтмәгәндә каршы яктан атлы бер егет килеп җитте. Бу егет туй җәмгыятенең барудан тукталуына сәбәп булып, иң элек алда баручы Гали байның коляскасы янына килеп сөйләште. Сүз-сүздән соң байның ачуланганлыгы күренеп тора иде. Бәлки бу егет яман хәбәр китергәндер, дип уйладылар. Атлы хәбәрче белән биш-алты минут сөйләшеп, Гали бай углы Сибгатулланы янына чакырды. Туй җәмгыяте: «Ни өчен туктадык?» — дип кычкырыша башлады. Сибгатулла әфәнде исә, атасы илә хәбәрләшкәч, үлек кеби агарып, кайгы вә фикерләр дәрьясына батты. Башкода Бикбулат мулла телсез калып, нишләргә, ни диярргә белмичә аптырып калды. Шунда Гали бай: «Кайтырга кирәк»,— дип, туйчыларга игълан итте.

— Бу ни хәл? Ни гаҗәеп, ни өчен кайтабыз? — дип, туйчылар хәйранга калдылар. Ничек булса да булды, туйчыларның барчасы, башларын җиргә иеп, кире авылга кайтырга мәҗбүр булдылар. Тик Гали бай белән Бикбулат мулла гына, кайтмыйча, хәбәрче атлы егет артыннан шәһәргә юлландылар.

Юлда күп уйланулардан соң, Гали бай Бикбулат муллага болай диде:

— Гаҗәеп, мин хәстәрлек күрдем, туй чыгымнарын күтәрдем вә кәефләрен тәмам кылдым, ә алар кызларын югалтканнар. Бу ни галәмәт! — Бу сүзләргә каршы Бикбулат мулла бер сүз дә әйтә алмады, тик башын тагын да түбәнрәк иде.

IX

Туйдан алда берничә көннәр Хәнифә туташ казык төбенә хатлар куйса да, алар сөйгәненә җитешмәде: Хисаметдин шәһәрдә дә юк, хәбәре дә юк. Хәнифә туташка мәгълүм түгел ки, ни сәбәптән менланың туйдан хәбәре озак юк икән? Бәс, Хәнифә туташ өмет итте ки, Гали бай туе кебек олуг вакыйгадан Хисаметдин хәбәрдар булып шәһәргә киләчәк вә үзен коткарачак. Чөнки «Безне кем дә аера алмас» дигән сүзләре туташның хәтерендә иде. Әмма туташның өмете акланмады. Инде шимбә көн җитте, якшәмбе — туй. Әмма Хисаметдиннан

һичбер хәбәр юк. Кайгыга баткан Хәнифә үз бүлмәсендә өзгәләнә: «Ничә көннәр көтәмен, ни өчен килми икән? Бер-беребездән аерылмаска вәгъдә бирештек. Аның мәхәббәтендә мин шикләнмим. Мәхәббәтенә күрә мине ташламас, аерылышуны һич тә уйлый алмыйм. Ни өчен мине болай зарыктыра икән? Гаҗәеп! Юк, туй турында ул белмидер, белсә, бакчага, әлбәттә, килеп җитәр иде. Һай кош булса идем, очып янына җитешеп, хәлемне белдерер идем. Бүген инде шимбә көн булды. Килеп җитмәсә, мин һәлак булдым. Сөймәгән кеше белән бергә яшәмәк һәлакәт булмыйча нидер? Йә Алла, нинди гөнаһларыма күрә мине газаплыйсың? Юкса ул хыянәт иттеме? Хәер, ул андый кеше түгел. Кичен бакчага килер. Ул җаным мине ташламас. Икейөзле кеше түгел».

Ничә мәртәбә туташ теге казык янына чыгып керде, әмма менла юк, хаты алынмаган.

«Килмәде, килмәде, һәлак булам, ахры? Юк, монда ни булса да бар, эшнең аслын белергә кирәк. Менла хыянәт итсә дә, Сибгатуллага никахланмамын». Шул рәвешле, күп уйлардан соң Хәнифә туташ ныклы бер карарга килде. Вә үз-үзенә диде: «Туктагыз, мин эш кылырмын, миңа хәзер барсы да бер, мин һәрбер казага әзермен». Шулай дип, яшь кыз үз-үзен юатты вә күңеле бераз хуш булды. Анасы исә олуг гайрәттә туй хәзерлекләре белән мәшгуль иде. Ахыр чиктә ярты төннәр булды. Хәнифә туташ бакчага хаты янына чыгып, бу юлы да менланың юклыгын белеп, хатын кире кесәсенә куйды вә бүлмәсенә кайтты. Өйдә барсы да яттылар. Хәнифә туташ кулына беренче туры килгән киемен киеп, тәрәзәдән әкертен генә туры урамга сикерде. Бу яшь кызның өйдән качуы иде. Төн бик караңгы. Шәһәр тирән йокыга талган. Каравылчы сызгыруыннан башка, яшь кызның колагына бер хәрәкәт тә ишетелмәде. Урамда янган фонарьлар гына кызның күңеленә бераз тынычлык бирделәр. Ул, бераз батыраеп, тротуар буйлап бара бирде. Күргәнебезчә, бу яшь кыз караңгы бер төндә иртәгәге никахтан качып бара. Әмма кемгә, кая барырга? Кем сыендырыр?

«Ни булса булыр, Гайниҗамал абыстайга барып хәлемне

белдерим, ул яхшы хатын, мине һәрвакыт ярата иде»,— дип, ул туп-туры Зурколаков өенә юнәлде. (...)

— Абыстай, үтенеп сорыйм, Хисаметдин менла шәһәргә килеп җиткәнче мине яшереп тор, кил Алла ризалыгы өчен!

— Ай кызым, әстәгъфирулла! Ата-анаңа итагать кирәк. Юк, юк, өйгә кайт! — диде Гайниҗамал абыстай.— Бу ни хәл, ярабби! Ничек яшьләр бозылдылар! — Бу сүзләр Хәнифә туташның елавын, яшьләрен тагын да арттырып, ул, янә каты ялварып:

— Әгәр син, абыстай, шәфкать итеп яшермәсәң, мин үз-үземне үтерүгә кадәр барырмын. Кил, шәфкать ит, җанымны коткар! — диде. Шуннан соң гына Гайниҗамал абыстай кызны берничә көнгә калдырырга риза булды вә әйтте:

— Бак, кызым, өч көннән кая теләсәң, шунда кит. Бу эшләр ярамас.

Хәнифә туташ, рәхмәтләр әйтеп, Гайниҗамал абыстай өендә урнашты.

X

Гали бай илә Бикбулат мулла, шәһәргә җитеп, Габбас агайга керделәр.

Туй мәсьәләсендә «Н» авылында бер гауга купкан кебек, бу вакыт Габбас аганың өендә госманлы-төрек сугышына охшаш хурлашмак вә дәгъва башланды. Гали бай кодасының өенә килеп керү белән иң әүвәл сүзләре мондый булды:

— Инде, Габбас ага, яхшы кешеләр болай эшләмиләр. Туемны ничек кайтардыгыз? Мин туй белән киләм, сез кызыгызны күздән юк иткәнсез. Моны туйдан элек хәбәр итәргә кирәк иде, бу рисвайлык миңа!

— Сабыр ит, мин җан-тән белән. Үзебез синнән дә рисвай булдык...

Гали бай белән Габбас ага арасында хурлашмак шул дәрәҗәгә җитте ки, бер-берсенә күп әдәпсез сүзләр дә әйтештеләр. Шәмсекамәр абыстай үзе чыкканнан соң гына, дәгъвалар азая төште. Чөнки Шәмсекамәр абыстай чыгып, шулай ук күп сөйләп, татлы ашатты да ачы костырды:

— Алла, Алла, байлыгыгызга ианып, кызымны көчләдем, харап булдым, йөрәк бәгърем баламнан аердың. Кайдадыр, белмибез,— дип, Шәмсекамәр абыстай күп сөйләде. Кыскасы, Хәнифә туташның югалуы күп сүзләргә, каты дәгъваларга сәбәп булды.

Ләкин без, бу белешләребезне калдырып, менла Хисаметдинның хәлләренә күз салыйк.

Туйдан ике атна кадәр элек шәһәрнең чиста бер чәйханәсендә башка кешеләрдән ерак вә аерым бүлмәдә чәй эчеп, Хисаметдин, Әбүзәр бәк вә Зурколаков әфәнделәр утыралар. Зурколаков әфәнде кызып болай сөйли башлады:

— Дуслар, милләт файдасы, милләт файдасы дип сөйләнәсез, сүз белән файда барлыкка килмәс, эш кирәк, җил куганнар.

— Мин бөтенләй файдасыз да тормыймын, сабыйларны укыту белән милләткә хезмәт итәм,— диде көлебрәк Хисаметдин менла.

— Бу эшләрне сөйләмә, ихласлы милләтпәрвәр кеше бары тик балалар укыту белән генә канәгатьләнмәс. Булса булсын зуррак файда,— кисеп әйтте Зурколаков.

— Синең телең — кискен пычак. Синең белән кем дә сөйли алмас,— җавапланды Хисаметдин.

— Сабыр итегез, дуслар! Иң кирәк булган нәрсә,— сүзгә керешге Әбүзәр бәк,— кирәк булган нәрсә татарны фән китапларыннан хәбәрдар итеп уятудыр. Җәмгыятебезнең күпчелеге фәннәрдән хәбәрләре юктыр. Фәнни китапларны туплап, шәкертләребезгә таратырга кирәк!

— Бу — икенче эш, бу мәгъкуль! — диде Зурколаков.

Бу уртак эш хакында күп киңәшкәннән соң, өч дус мондый карар бирделәр: шәһәрнең ислам халкыннан акча туплап, Кырымда нәшер ителгән җәгъррәфия, тарих вә табигатькә караган фән китапларын сатып алып, шәкертләргә вә укый-яза белгән фәкыйрь кешеләргә өләшергә. Әбүзәр бәк вә Зурколаков кеби кешеләрнең, әлбәттә, үз акчаларына да китаплар алдырырга хәлләреннән килә иде. Ләкин, бу вакыт мөселман җәмгыяте гомуми эшкә никадәр ихласлы, һәвәсле булуын тәҗрибә

өчен, иганә акча җыярга карар бирделәр. Дуслар, иганә дәфтәре ачып, акча тупладылар. Мәгарифне сөюче исламнарның күбесе бу эшкә шактый булышлык вә ихлас күрсәттеләр. Әмма кайбер мөселманнар: «Буш эш белән йөрисез, безгә фән нигә кирәк?» — дип, иганәгә акча бирмәделәр. Мондый мөселманнарга каршы Зурколаков бик ачы вә яман сүзләр әйтте. Хәтта ки иганә акчасы җыелгач, дуслар Әбүзәр бәктә булганда Хисаметдин менла Зурколаковны шелтәләде:

— Гайса, синең телеңне бераз кыскартмак кирәк, бик хәрап синең телең, иганә акча сораганда, ничә кайбер исламнарны хурладың. Бераз әдәп кирәк иде.

— Нинди әдәп? Исламлык дәгъвасын кылалар да, уртак исламия файдасы өчен монет кадәр акчаларын чыгармак өчен алар белән сәгать буе сөйләшергә кирәк. Миңа фән китапларының файдасын инкяр итсеннәр дә, мин мондый кешеләрнең сүзләрен әдәп белән тыңлап торыйм. Исламия файдасы өчен тырышып йөрүне тиле вә буш эштән санасыннар да, мин аларга әдәпле булыйм. Андый гакыллы ишәкләр фән белүне зарарга санасыннар да, мин аларны хурламыйммы? Андый мөселманнарны хурлау гына аздыр. Битләренә төкереп, алардан йөз чөерергә кирәк. Андый гакыллы ишәкләрне...

— Булды, булды! Җитәр, җитәр, Алла өчен җитәр инде, Гайса, синең белән сөйләшү мөмкин түгел! — дип, Гайса әфәндедең сүзен кисте Хисаметдин.

— Әлбәттә, минем белән буш сүзләрне сөйләшеп булмас! — кисеп әйтте Зурколаков.

— Туктагыз! — диде Әбүзәр бәк.— Китаплар җибәрү хакында хат языйк.

Дуслар хат яздылар. Хат белән бергә иганә акчасына үзләреннән дә шактый акча өстәделәр.

Ун көннәр узгач, фән китаплары почта белән килеп тә җитте. Мәгарифпәрвәр егетләр китап өләшүне Хисаметдин менлага тапшырдылар. Бәс, Хисаметдин, китаплар өләшер өчен, тирәякта булган татар авылларына чыгып китте. Нәкъ шулвакыт,

ягъни Хисаметдин китаплар өләшергә авылларга чыккан вакытта, туй эшләре башланды.

Туй турында ишетү Хисаметдинга һич мөмкин түгел иде. Чөнки менла авылларда зур тырышлык вә эштә булып, дин кардәшләренә китаплар биреп, фән мәнфәгатьләрен кайгыртып-аңлатып сәфәрдә йөрде. Ахыр чиктә, туй маҗараларыннан соң бер көн соңра, «Нун»га кайтты. (...) Хәнифә турында ишетеп, анасыннан никадәр сорашса да, эшнең аслына төшенә алмады. Анасы диде ки, кайберәүләр авылда сөйлиләр, Габбас кызы качкан, имеш. Кайберәүләр, суга баткан, дип сөйлиләр. Кайберәүләр, Габбас ага кызын үзе яшергән, дип сөйли. Авылдагы төрле-төрле хәбәрләрдән менланың гашыйк җаны бик борчылып, өендә бер төн дә кунып тормыйча, шәһәргә мәгъшукасын эзләргә юлланды. Шәһәрдә көнне анда-монда сугылып, төрле кешеләр белән сөйләшеп, борчылып уздырды. Ләкин мәгъшукасы хакында һичбер дөрес хәбәр ишетмәгәч, кичен Гайниҗамал абыстайга барырга карар бирде. (...)

Гайса Зурколаков менланы каршылап, китаплар өләшү турында сорашты.

— Ни өчен бик озак йөрдең? — диде Зурколаков.

— Нинди озак? Минемчә, тиз кайттым әле мин. Китаплар биргәндә, укый-аңлый торганрак шәкертләргә бирергә кирәк, андыйларны табу бик тиз эш түгел.

— Ахры, менлаларга вакыт бәһале нәрсә түгел. Син бел ки, вакыт бик кыйммәтле нәрсә. Вакытны бушка сарыф итмәк ярамас. Үзең беләсең ки, бер минут юкка үткәрсәң, ул бер минутны кире кайтармак мөмкин түгел. Шуның өчен инглиз мәкале бар ки, «вакыт сәрмаядер[1], сәрмаяне бушка сарыф хәрамдыр». Бәс, вакытны да бушка сарыф итсәң, гөнаһлы булырсың!

— Булды инде, Гайса! Әйттем ич инде, тиз кайттым. Буш вә кирәксезгә йөрмәдем! — җаваплады менла.

— Ләкин мин синнән дә тиз кайтыр идем! — диде Зурколаков.

---

[1] *Сәрмая* — байлык, акча, капитал.

— Син бүген шат күренәсең, Гайса! Күп сөйләү шатлык галәмәтедер. Әмма белмим, нигә шатланасыңдыр.

— Мин шат булсам, син бүген кайгылысың. Борыныңны җиргә салуың кайгы галәмәтедер. Әмма кайгыланып ни файда булсын. Һәрвакыт шат булу күңелгә дә хуш, эшләр яхшырак барадыр. Кайгы исә һәм эшкә, һәм тәнгә зарар. Чөнки татар шагыйре болай ди:

Каенсар төбендә кар булмас,
Кайгылы йөрәктә май булмас.

— Күп сөйлисең, ахры, синең йөрәктә май күп.

— Үлчә йөрәгемне, ничә мыскал икән? — диде көлеп Зурколаков.

— Кайдан сиңа килде көлке? — сорады менла.

— Ай менла, син аңла, безнең өебездә күп эшләр бар. Ничек килмәсен көлке, анаем булды төлке. Миңа карата төлкелек итә башлады.

— Нинди төлкелек? — сорады менла.

— Олуг төлкелек. Узган төндә анаема бер мөсафир килмеш. Мин сорадым: «Анай, кем сиңа килде?» Ул миңа әйтми: «Кем килмәс, хатыннар эшенә катнашырга синең эшең түгел»,— ди. Мине дә мөсафирне күрер өчен үз бүлмәләренә һич җибәрмидер. Бу төлкелек түгелме? Углыннан мөсафирне яшерә.

— Гаҗәп, нинди ул мөсафир?

— Мин белмим. Хезмәтче хатын миңа диде ки: «Килгән мөсафир яшь хатындыр»,— диде Зурколаков.

Шуннан соң Хисаметдин белән Зурколаков Гайниҗамал абыстайга керделәр. Менлабыз Гайниҗамал абыстай белән сөйләшкән арада үзе дә сизмәстән сүзне туйлар, Габбас агалар тарафына юнәлдерде. Ләкин Гайниҗамал абыстай әлеге сүзне озайтмыйча, аз-аз сөйләп, кыска җавапланып тынып калды. Менла борчылып теге кунак хатын хакында сөйләп карады. Ләкин абыстай моңа җавапта болай диде: «Килгән кунак — бер авылдан килгән хатын».

Инде Хисаметдин менла, мәгъшукасы хакында бер мәгълүмат та тапмыйча, төн җиткән вакытта Зурколаковлардан

чыкты. Хәнифә туташны уйлый-уйлый кайгылы хәлдә бара иде. Күктәге болытлар вә яңгыр менланың кайгысын тагын да арттыралар иде. Караңгы кич, аяк астындагы юешлек вә көчәйгән яңгыр — һәммәсе менланың өметсезлеген арттырып, күңеленә бер кәефсезлек китерәләр иде. Шул хәлдә Хисаметдин, зонтын ачып, хәсрәткә батып, кунак өенә, ягъни Әбүзәр бәккә кайтып бара иде, кинәт артыннан бер кеше куып җиткәнне ишетеп, әйләнеп караса, хәйран калды. Бу шатлыктан хәйран калу иде. Артыннан җиткән кеше — мәгъшукасы Хәнифә туташ икән! Ике гашыйк шунда ук бер-берсенә якынлашып сарылдылар. Элекке кайгы шатлыкка әйләнде. Инде яңгыр да гүя күңелле итеп ява.

— Синме, җаным? Күзләрем алдамыймы? — дип сорады Хисаметдин.

— Тиз, кая китсәң дә алып кит; артыбыздан төшмәсеннәр. Гайниҗамал абыстайда сине күреп, чыгып киткәнеңне көтеп, аннан качтым,— диде туташ. (...)

Ярты сәгать үтәр-үтмәс, Хисаметдин менла сөйгәне белән бергә үзенең йөгрек атында «Нун»га юнәлде...

XII

Бер атнадан соң «Нун»да Хисаметдин менла өендә туй мәҗлесе булды. Габбас ага, Шәмсекамәр абыстай, күп фикерләрдән соң, игътибар белән яхшы гына уйлап, каргыш вә ачуларын ташлап, дәгъвалашудан файда чыкмаячагына төшенеп, ахырда Хисаметдин менланы кияүлеккә кабул иттеләр.

Асылда Габбас аганы солыхка Гайниҗамал абыстай илә Зурколаков кайтардылар. Чөнки Хәнифәне авылына алып кайтканның соңында Хисаметдин тизлек белән Зурколаковларны башкодалыкка вә килешү эзләргә Габбас агайга җибәргән иде. Инде шуннан соң хәзер мондый шатлыклы туй мәҗлесен күрәбез. Бу туйда Габбас ага вә Шәмсекамәр абыстайның якыннары белән бергә, Хисаметдин менланың дус-ишләреннән Гайниҗамал абыстай, Гайса әфәнде һәм Әбүзәр бәк тә булдылар. Белешебез Бикбулат мулла никах укырга мәҗбүр булды. (...)

Гашыйклар берәр ел «Нун» авылында зәвык белән, күңелле итеп тордылар. Әмма ике ел үтмәстән, Хисаметдин, мөлкәтен сатып, Кавказга Тифлис шәһәренә күчте һәм гаиләсен дә шунда күчерде.

Югарыда яздыгымыз ятим Мохтар, хәзерге вакытларда Тифлистә манфактура малы илә сәүдә итеп вә мал-мөлкәт иясе булып, үзенә Тифлистә абруй-авторитет казанып, иске дусты Хисаметдин менланы анда имамлыкка чакырды.

Элекке теләнче Мохтар хәзер инде Мохтар әфәнде Хәмитов булып, имам булган Хисаметдинга үз акчасына мәдрәсә салдырды вә мәдрәсә шәкертләренә кесәсеннән тереклек итәр өчен акча билгеләде.

Башка белешләребез һәркайсы үз эшендә калдылар.

Заһир Бигиев
(1870—1902)

МЕҢНӘР*, ЯКИ ГҮЗӘЛ КЫЗ ХӘДИЧӘ**

Роман

(1887)

I

Хикәябез гаҗәеп гүзәл бер хикәядер. Аңа керешер алдыннан иң әүвәл вакыйгасының кайда һәм кайчан булуын әйтеп үтик. Хикәябездән укып аңлашылачак вакыйга моннан берничә ел элек Казан шәһәрендә булды.

Иртәнге сәгать уннар тирәсендә Казан мөсафирханәләреннән бер олуг һәм могтәбәр мөсафирханә янына бик күп кешеләр җыелган иде. Араларында шундый сүзләр ишетелеп куя иде:

— Ни бар, нәрсә карыйсыз? Ни булган?

— Нәрсә булсын, бүген шушы мөсафирханәдә бер мөсафирә хатынны үтергәннәр.

— Гаҗәп! Кем үтергән икән, үтерүчене тотмаганнармы?

---

* «Меңнәр» сүзен автор гарәпчә өлүф дип алган.

** Язучының романнары кыскартып алынды. Текстлар хәзерге әдәби телгә *Р. Даутов* тәрҗемәсендә бирелә: З. Бигиев. Зур гөнаһлар. Романнар, сәяхәтнамә.—Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.

ОЛЮФЪ

ИЛИ

КРАСАВИЦА ХАДИЧА.

РОМАНЪ

соч. Загиръ Ибни Ярулла Бигѣева.

الوف

یاکه

کوزل قز خدیجه

رومان

اثر محمد ظاهر ابن آخوند ملّا جارالله بیکیوف

(باصمه سنه رخصت بیرلدی پیتربورغده ٦ نچی ایبولده ١٨٨٧ نچی یلده)

باصمه اولنمشدور قزانده ویچیسلاف ننك طبع خانه سنده ١٨٨٧ نچی یلده

«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романының 1887 елда Казанда басылып чыккан беренче басмасының титул бите.

— Ул кадәресе әлегә мәгълүм түгел, хәзер полиция белән суд тикшерүчеләре килгәнне көтәләр. Тикшергәч, бәлкем, үтерүчесе дә ачыкланыр.

Җыелган халык әнә шул рәвештә төрле сүзләр сөйләвендә дәвам итте.

Бер биш-ун минуттан халык:

— Киләләр! Киләләр! — дип янә шаулашырга тотынды.

Килүчеләр үтерелгән хатын эше буенча мөсафирханәгә чакырылган полицейскийлар белән суд тикшерүчеләре иде. Алар, килеп җитеп, җигүле атларыннан төштеләр дә туп-туры мөсафирханәгә кереп киттеләр. Җыелган халык алар артыннан эчкә керергә бик теләсә дә, рөхсәт булмады. Шулай да кешеләр мөсафирханә яныннан таралышмады, нинди хәбәр булыр икән дип, үтә бер кызыксыну, түземсезләнү белән тикшерүчеләр чыкканны көтә башлады.

Инде тикшерүчеләр хәл-әхвәлен языйк.

Алар, мөсафирханә ишеген атлап керүгә үк:

— Үтерелгән хатын кайсы номерда? — дип, мөсафирханә хуҗасыннан сорадылар.

Мөсафирханә хуҗасы Габдуллин дигән кеше:

— Унберенче номерда,— дип җавап бирде.

Шуннан соң тикшерүчеләр, Габдуллин белән бергә таш-пулатның икенче катына күтәрелеп, әлеге унберенче номерның ишеген ачып, эчкә керделәр. Ике бүлмәле номер иде бу. Урам тарафына караган өч тәрәзәсе бар. Кыш көнендәге кебек, тәрәзәләр икешәр катлы. Номер эчендә ике өстәл, дүрт урындык, ике кәнәфи, бер диван, бер карават тора иде.

Идән уртасында — үтерелгән хатын мәете. Аның канга буялган башында пуля җәрәхәтенә охшаш яра бар иде. Хатынның яше егерме ике-егерме өчтән дә артык булмаска кирәк, үзе гаять тә чибәр-гүзәл кыяфәтле иде.

Суд тикшерүчесе, мөсафирханә хуҗасына карап:

— Бу хатын сезнең мөсафирханәгездә кайчаннан бирле тора иде? — дип сорады.

— Җомгадан бирле,— дип җавап бирде Габдуллин.

— Исеме ничек?

— Зөләйха,— диде хуҗа әфәнде.

— Хатынның үтерелүен иң әүвәл кем белде? — диде тикшерүче.

— Хезмәтче хатын-хадимә,— дип җавап бирде хуҗа әфәнде.

— Хадимәне монда чакырып китерегез.

Берникадәр вакыттан хадимә килеп җитте. Суд тикшерүчесе аңардан:

— Бу хатынның үтерелгән булуын сез кайчан һәм ничек белдегез? — дип сорагач, хадимә бу рәвешле сөйләп бирде:

— Мин иртән үз хезмәтем белән йөри идем. Бу номер яныннан узып барган чагымда карыйм, ишек яртылаш ачык тора. Кунак хатынның берәр йомышы юкмы икән дип номерга керсәм, аны шушындый хәлдә күреп, бөтенләй котым очты. Хәтта номердан ничек чыкканымны да белмим.

Хадимәнең җавабы тәмам булгач, тикшерүчеләр бүлмәне карарга керештеләр. Ишек янына килеп карасалар, ишек йозагында ачкыч күреп, гаҗәпләнеп калдылар.

— Бу үтерүче дигәне сәер кеше икән, үзе киткәндә ишекне йозагына бикләргә дә оныткан, хәтта аны яртылаш ачык калдырган. Әгәр дә ишекне йозагына бикләп киткән булса, хатынның мәете табылуы кичегер, үтерүчегә дә качар өчен форсат артыр иде. Әллә юкса бу хатын үз-үзен үтерде микән? — диде тикшерүчеләрнең берсе.

Икенчесе:

— Юк, үз-үзен үтермәгән. Әгәр дә үз-үзен үтергән булса, янында револьвер һәм үз-үземне үтерәм дигән язуы булыр иде,— дип каршы төште.

Башка тикшерүчеләр дә:

— Әйе, шулай булыр иде,— дип килештеләр.

Шуннан соң швейцарны чакырттылар. Суд тикшерүчесе аңардан:

— Үткән кичтә бу үтерелгән хатын янына кем дә булса килмәдеме? — дип сорады.

— Әйе, мәрхүмә белән бергә бер ир адәм килгән иде,— диде швейцар.

— Ул кеше кайчан килеп, кайчан китте?

— Кич сәгать сигездә килеп, төнге унике сәгатьтә китте,— дип җавап бирде швейцар.

— Төгәл уникедә китүен каян беләсең? — диде тикшерүче.

— Чөнки мәрхүмә белән килгән ул адәм мөсафирханәдән киткәндә миннән: «Сәгать ничә?» — дип сорады. Мин, сәгатькә карап: «Сәгать унике»,— дип җавап бирдем. Шуннан соң ул миңа өч тәңкә чәйлек биреп чыгып китте.

Тикшерүчеләр, швейцардан бу сүзләрне ишеткәч, мөсафирә хатынның үлеме кичке сәгать сигез белән төнге унике арасында булганлыгын аңладылар. Алар шулай ук швейцардан мөсафирә белән бергә килгән ирнең төсе-кыяфәте турында да сораштылар. Бу сорауга швейцар:

— Нечкә адәм, озын буйлы, ак йөзле, кечек сары сакаллы, дип җавап бирде.

Швейцарның мәгълүматларын тыңлаганның соңында, тикшерүчеләр номер эчендәге әйберләрне барларга тотындылар. Номер эченнән тикшереп табылган нәрсәләр шулардыр: иң элек, бер сыңар ирләр перчаткасы, сул кулныкы; уң кулныкы юк иде. Әлбәттә, бу табылган сул кул перчаткасы үтерүченең перчаткасы булырга кирәк,— күрәсең, төшереп калдырган. Икенчедән, ике тәрәзә арасыннан ерткалап ташланган бер сурәт — ир кеше портреты табылды. Гәрчә ерткаланган булса да, вак кисәкләрен үз җаена тәртип белән берләштереп каралса, бу сурәтнең нинди кеше икәнлеген танырга мөмкин иде. Швейцарның аңлатуы һәм сөйләвенә таянып, бу табылган сурәтне дә үтерелгән Зөләйха белән үткән кичтә бергә килгән ирнең сурәтедер дип уйларга була иде.

Өченчедән — номер эченнән табылган бер хат. Мөсафирханә хуҗасы үтерелгән Зөләйханың кул язмасын белә икән, аның әйтүенә караганда, бу табылган хат Зөләйха кулы белән язылганга охшый иде. (...)

«Егетләрнең күрке булган Муса әфәнделәренә җан һәм күңел төбеннән чыккан сәламнәребезне күндерәбез. Киң күңеллелек күрсәтеп, бүген кич сәгать сигездә Габдуллин

мөсафирханәсенең унберенче номерына килсәгез иде. 2 нче март».

Тикшерүчеләр, бу хатны укыгач, ул һичшиксез үтерелгән хатын белән үткән кичтә бергә килгән кешегә атап язылгандыр дип гөман кылдылар. Хатның Зөләйха үтерелгән көндә язылганлыгын хаттагы число күрсәтеп тора иде. Үтерелү көне дә, хат язылу көне дә бер үк. Тикшерүчеләргә шулай ук мәрхүмә белән бергә килгән кешенең исеме Муса икәнлеге дә хаттан аңлашылды. (...)

Икенче көнне мәрхүмә Зөләйханың мәетен дәфен[1] кылдылар.

II

Муса исемле билгесез кешене эзләп табу иң зарур бурыч булганлыктан, тикшерүчеләр бу эшне кәсептәшләре арасында мәшһүр һәм могтәбәр саналган Шубин атлы бер сыщик-шымчыга тапшырдылар. Господин Шубин исә, үткен-зирәк шымчы буларак, өч көн эчендә мәрхүмә Зөләйха белән бергә номерга килгән Мусаның нинди кеше икәнлеген һәм кайда торуын ачыклап та өлгерде.

Сезләргә дә, хөрмәтле укучыларым, Мусаның нинди кеше икәнлеген аңлатып үтим.

Муса әфәнде Казан байларыннан мәрхүм Габдулла байның улы Салихов иде. Петербургта университет тәмамлаган булса да, әткәсе вафатыннан соң ул сәүдә эше белән шөгыльләнергә керешкән иде. Яше егерме биш-егерме алтыдан артык түгел, үзе өйләнмәгән. Инде менә, Казан байлары арасында һәркемгә билгеле мәшһүр бай Әхмәди Хәмитов үзенең Хәдичә исемле кызын йөз мең сум көмеш акча белән кияүгә биргәнлектән, Муса Салихов шул туташны кәләшлеккә ярәшеп йөри һәм тагы бер айдан аларның никах мәҗлесләре булырга тиеш иде. Муса әфәнденең әткәсе белән бертуган абзасы — Нигъмәтулла исемле кардәше бар иде. Муса әфәнде Нигъмәтулла абзасы белән бергә сәүдә кылып, бер үк өйдә тора иде.

---

[1] *Дәфен* — җирләү, мәет күмү.

Муса Салихов фабрикасындагы хезмәтләрен карап кайтты да кичке сәгать сигездә үз өендә ялгызы чәй эчәргә утырды. Нигъмәтулла әфәнде әле кайтып җитмәгән иде. Гәрчә ялгыз ашау-эчү Муса әфәндене гадәтендә булмаса да, бу юлы ул бик сусаган иде. Кулында — газета. Газетадан мәрхүмә Зөләйханың Габдуллин номерларында үтерелү хәбәрен укый. Үзе елар дәрәҗәгә җиткән, күзеннән тамчы-тамчы яшь тама. Газета укыганда ул ара-тирә үзалдына сөйләнеп куя. Аның бу үзалдына сөйләшүеннән Муса әфәндене Зөләйханың җеназа намазында булуы да аңлашыла иде. (...)

Муса әфәнде, бер сүз дә әйтмичә, хәйран калган бер кыяфәттә уйга батып утыра бирде. Шул рәвештә чәйләп утырган вакытта бая самавыр китергән хадим кереп, Муса әфәндегә карап:

— Әфәндем, сезне бер адәм күрергә тели, кертергә рөхсәт булырмы? — дип белдерде.

Муса әфәнде, утырган җиреннән торып, хәвефкә калган кеше сыман, калтыравык тавыш белән:

— Нинди адәм? — дип сорады.

— Белмим, әфәндем, исемен сораган идем, әйтмәде. Бик зур йомышым бар, ди.

— Бар, исемен белеп кер,— диде Муса әфәнде. Хадим чыгып китте. Бераздан яңадан кереп:

— Әфәндем! Сезне күрергә теләгән адәмнең исеме — Иван Иванович Шубин,— диде.

— Шубин?! — дип кабатлап сорады Муса әфәнде, гаҗәпләнеп. Чөнки ул Шубинны күреп белмәсә дә, аның исемен һәм сыщик-шымчы икәнлеген ишетеп белә иде. «Нинди йомышы бар икән?» — дип эченнән уйлап куйды Муса әфәнде һәм хадимгә господин Шубинны кертергә рөхсәт бирде.

Бер-ике минуттан ишекләр ачылып, бүлмәгә урта буйлы, кара сакаллы, озын кара чәчле бер рус килеп керде. Бу рус — мәгълүмегез господин Шубин — Муса әфәндене эзләп табарга боерылган шымчы иде.

Муса әфәнде, господин Шубин белән күрешеп:

— Рәхим итегез,— дип, аңа утырыр өчен урындык күрсәтте. Господин Шубин, күрсәтелгән урынга утырып, сәламәтлек сорашкач, Муса әфәнде кунакны хөрмәтләү өчен хадимгә чәй китерергә кушты. Аннары, господин Шубинга таба борылып:

— Безгә нинди йомышыгыз төште? — дип сорады.

— Юк, юк! Сездә әллә ни зур йомышым юк. Габдуллин мөсафирханәсендә, унберенче номерда, бер мөсафирә хатынны үтергәннәр, бәлкем, ишеткәнсез дә, шул хакта килдем.

— Әйе, ишеткән идем, менә бүген газетадан да укыдым,— диде Муса әфәнде.

Господин Шубин, хуҗаның күзләренә туры карап:

— Хөрмәтле Муса әфәнде, сез үтерелгән Зөләйханы исән чагында күреп белә идегезме? — дип сорады.

— Юк! Юк! Белми идем,— дип җавап бирде Муса әфәнде.

Господин Шубин, бераз уйланып торгач, мәрхүмә Зөләйханың номерыннан тикшерү вакытында табылган хатны кесәсеннән чыгарды да, Муса әфәндегә таба сузып:

— Менә бу хатны Зөләйха тере чагында сезгә язган булган. Бу хат сезнең мәрхүмә Зөләйха белән белеш-таныш булуыгызга дәлил,— диде.

Муса әфәнде хатны кулына алып укыды да:

— Дөньяда Муса әфәнде фәкать бер без генә түгелдер, хатның Муса исемле кешегә язылуыннан гына андый нәтиҗә чыгарып булмый,— дип, хатны кире Шубинга кайтарып бирде.

Господин Шубинның күзе шулчак янындагы өстәл өстендә яткан сыңар перчаткага төште. Перчатка ирләр перчаткасы һәм уң кулныкы булып, ул үтерелгән Зөләйха номерыннан тикшерү вакытында табылган сыңар перчатканы хәтерләтә иде. Номерда табылганы сул кулныкы булса, монысы — уң кулныкы. Төсе һәм үлчәме дә бертөрле.

Господин Шубин, перчатканы өстәл өстеннән кулына алып, Муса әфәндедән:

— Әфәндем, бу перчатка сезнекеме? — дип сорады.

— Әйе, минем перчаткам.

— Икенчесе кайда? — диде Шубин.

Муса әфәнде, ачу сизелеп торган тавыш белән:

— Мин мондый сорауларга җавап бирмимен,— дип кырт кисте.

— Әфәндем, хафаланмагыз, сезгә бу эштә бернинди дә зарар булмас, сез бу эштә фәкать шаһит кенә булырсыз.

Господин Шубин телдән шулай дисә дә, күңеленнән бүтәнчә уйлый, ягъни Муса әфәндене Зөләйханы үтерүче дип саный иде. (...)

«Париж» — Казандагы олуг һәм могтәбәр бер чәйханә иде. Бу чәйханәдә господин Шубинны, нинди хәбәр белән килер икән дип, үзе кебек үк сыщик-шымчылар көтәләр иде. Биш-ун минут эчендә атлар господин Шубинны «Париж» чәйханәсенә китереп тә җиткерделәр. Шубин аттан төште дә кучерына:

— Бераз сабыр ит, мин хәзер чыгармын,— дип, чәйханә ишегеннән кереп, югары этажга менеп китте, Шубинны көтүчеләр аны: «Озак, бик озак!» «Нинди хәбәр? Нинди хәбәр?» — кебек сораулар белән каршы алдылар. Господин Шубин хәләхвәлне булганынча түкми-чәчми сөйләп бирде. Аның сүзләреннән һәркайсының аңында «Зөләйханы үтерүче — Муса, Муса!» дигән ныклы фикер калды. Шуннан соң господин Шубин, чәйханәдән чыгып, өенә кайтып китте.

III

Гыйззәтле укучы, господин Шубинның Муса әфәнде янына югарыда без язып үткән йомыш белән килүе хуҗаларны шулкадәр кайгы-хәсрәткә төшерде ки, алар, төн йокысын йоклый алмыйча, иртәнгә чаклы аһ-ваһ килеп, ни булыр икән дип, хафа эчендә уздырдылар. Иртәнге намаз вакыты җитеп, Нигъмәтулла әфәнде Муса әфәндегә:

— Намаз вакыты җитте, тәһарәтләнергә кирәк,— дисә дә, Муса әфәнде җавап кайтармады. Ул елый иде. Аның елаганын күреп, Нигъмәтулла әфәнденең дә, тәкате бетеп, күзеннән яшьләр чыкты. Мондый хәлдә кеше еламыймы соң? Әлбәттә елый.

Биш-алты минут чамасы вакыт үткәч, Муса әфәнде, урыныннан торып, тәһарәт алырга чыкты. Аңа ияреп, Нигъмәтулла

әфәнде дә тәһарәтләнеп керде. Аннары иртәнге намазга утырдылар. Намазны укып багышлагач, хадим самавыр — чәй китерде. Нигъмәтулла әфәнде:

— Иншалла, бернәрсә дә булмас,— дип, чәй эчү максаты белән табын янына килеп утырды. Муса әфәнде дә:

— Әстәгъфирулла! Әстәгъфирулла! — дип, тәкрарлый-тәкрарлый, аның яныннан урын алды.

Нигъмәтулла әфәнде, чәйне касәләргә салып, эчә генә башлаганнар иде, хадим кереп:

— Габденнәсыр әфәнде, рөхсәт бармы? — дип белдерде.

— Рөхсәт, рөхсәт! Керсен,— диде Нигъмәтулла әфәнде, аннары хадим чыгып киткәч, Муса әфәндегә таба борылып: — Мин Габденнәсыр әфәндене кичә иртәнге чәйгә чакырган идем,— дип өстәде.

— Бик яхшы,— дип җавап бирде Муса әфәнде. (...)

Габденнәсыр әфәнде Казан байларыннан Исмәгыйль байның угылы Хәбибуллин иде. Әткәсе Исмәгыйль бай вафат, башка кардәшләре юк иде. Казанда өч-дүрт җирдә ташпулат өйләре бар иде. Габденнәсыр әфәнде гимназиядә курс тәмам иткән, яше егерме өч-егерме дүрттән артык түгел, үзе әле өйләнмәгән иде. Берникадәр вакыт элегрәк Габденнәсыр әфәнде Әхмәди Хәмитовның кызы Хәдичә туташны йөз мең сум көмеш акчасы белән бергә кәләшлеккә алырга ният кылып йөрсә дә, Хәдичә туташны Муса әфәнде кәләшлеккә ярәшүе сәбәбеннән, ул хәзер читкә тибәрелгән иде. Әнә шул Хәдичә аркасында, яки, дөресрәге, аның йөз мең сум көмеш акчасы аркасында, ул Муса әфәндене, тыштан аңа дус булып кыланса да, эченнән бик тә дошман күрә иде. Хәзер Габденнәсыр әфәнде, ялгызлыгы сәбәбеннән үз өендә тормыйча, Габдуллин мөсафирханәсенең тугызынчы номерында яшәп ята иде.

Хадим чыгып: «Рөхсәт, рәхим итегез»,— дигәч, Габденнәсыр әфәнде хуҗалар чәйләп утырган бүлмәгә керде дә:

— Әссәламегаләйкем! — дип сәламен бирде.

Нигъмәтулла әфәнде белән Муса әфәнде, зәгыйфь-көчсез тавыш белән:

— Вәгаләйкемәссәлам,— дип, кунакның сәламен алдылар. Нигъмәтулла әфәнде:

— Әйдәгез, рәхим итегез,— дип, Габденнәсыр әфәндегә өстәл яныннан урын күрсәтте.

— Бик яхшы, рәхмәт,— дип, Габденнәсыр әфәнде күрсәтелгән урынга утырды.— Сәламәтләрме торасыз?

— Әлхәмделиллаһи раббелгаләмин[1], әлегә сәламәтләрбез, тик менә эшләребез генә бераз начарайды,— дип җавап бирде Нигъмәтулла әфәнде.

Габденнәсыр әфәнде, шактый гаҗәпләнеп:

— Ник алай? Нәрсә булды? — дип сорады.

Нигъмәтулла әфәнде кичә кичен господин Шубинның өйгә килүен тәфсилләп сөйләп бирде һәм сүзен:

— Алла боерса, бернәрсә дә булмас,— дип тәмамлады.

— Әйе, бернәрсә дә булмас,— дип килеште Габденнәсыр әфәнде дә. Шулай дисә дә, эченнән ул сөенеп куйды. Чөнки, аның уенча, Муса әфәнде чынлап үтерүче итеп табылса, аны, һичшиксез, төрмәгә ябачаклар. Әгәр ул тоткын ителә икән, димәк, Хәдичә туташ һәм йөз мең сум көмеш акча Габденнәсыр әфәнденеке булачак.

Ике-өч минут тынлыктан соң Нигъмәтулла әфәнде:

— Чәйгә рәхим итегез,— дип, Габденнәсыр әфәнденең алдына бер касә чәй куйды.

Габденнәсыр әфәнде:

— Бик яхшы, рәхмәт,— дип, чәйне эчә башлады.

Өчесе дә шулай сөйләшмичә генә чәй эчәргә тотындылар. Сөйләшмәсәләр дә, ара-тирә Муса әфәнденең авызыннан кайгылы вакытта әйтелә торган ах-ух авазлары ишетелеп куя иде. Габденнәсыр әфәнде исә, кечек кара мыегын бармаклары белән бөтергәләп, уйга баткан сыман алдына төбәлеп утыра бирде.

Берникадәр вакыттан соң Нигъмәтулла әфәнде, тынлыкны бозып:

---

[1] *Әлхәмделиллаһи раббелгаләмин* — бер Аллага дан булсын, Аллага шөкер.

— Ашны да ашагыз, иншалла, бер нәрсә дә булмас, бисмилләһи,— дип, кулын ашлы тәлинкәгә таба сузды.

Габденнәсыр әфәнде, Муса әфәндегә карап:

— Газизем, бу үткән кичтә господин Шубинның сезгә шундый йомыш белән килүен каенатагыз Әхмәди абзый беләме? — дип сорады.

— Үзебез хәбәр иткәнебез юк, белми торгандыр,— диде Муса әфәнде.

— Каен әткәгезгә хәбәр итәргә кирәк. Бер-ике юл язу язып җибәр,— дип киңәш итте Нигъмәтулла әфәнде.

Муса әфәнде:

— Ярар, яхшы,— дип, урыныннан торды да, каләм-кәгазь алу максаты белән, икенче бүлмәгә таба атлады, ләкин шулчак тәрәзәдән каенатасын күреп: — Әнә үзе дә килә, — дип, ишеккә таба борылды.

Габденнәсыр белән Нигъмәтулла әфәнделәр дә, урыннарыннан кузгалып, тәрәзәдән карап, Әхмәди Хәмитовны каршы алырга чыктылар.

Әхмәди байның Муса әфәнделәргә үткән кичтә булган гадәттән тыш вакыйганы ишетеп килүе иде. Хәер, кичәге ул вакыйганы бер Әхмәди бай гына түгел, шәһәр халкының яртысыннан күбрәге ишетеп белә иде инде.

Бераздан Әхмәди бай, үзен каршы алырга чыккан хуҗалар һәм Габденнәсыр әфәнде белән бергә өй эченә кереп, догасын кылып:

— Саулармысез? Сәламәтләрме? — дип сәлам бирде.

— Әлхәмделилла, Аллага шөкер,— дип җавап бирделәр аңа. Әхмәди бай алтмыш яшьләренә җиткән ак сакаллы, калынюан гәүдәле бер кеше иде. Хәл-әхвәл белешкәч, ул, Нигъмәтулла әфәндегә карап:

— Шундый зур эш була торып, ни өчен безгә хәбәр итмәдегез? — дип сорады.

— Хәзер генә сезгә хат язмакчы идек, менә үзегез килеп кердегез,— диде Нигъмәтулла әфәнде.

Бермәлгә тынлык урнашты. Аннары Габденнәсыр әфәнде, Әхмәди байга таба борылып:

— Әхмәди абзый, бу эштә Муса әфәндегә бернәрсә дә булмас, чөнки Муса әфәнде бу эштә шаһит кенә булачак,— диде.

Әхмәди бай, Габденнәсыр әфәнденең сүзләренә җавап кайтармыйча, берникадәр вакыт дәшми торды, аннары, үзалдына карап:

— Хәзер генә безнең өебезгә бер түрә-бояр килгән иде,— диде.— Ул безгә Муса әфәнденең эшендә зур курку бар дип сөйләде. Аңар бу эш бик мәгълүм икән. Бүген Муса әфәнденең эшләре хөкем йортына биреләчәк дип сөйләде. Адвокат — дәгъва вәкиле ялларга мәслихәт кылды. Ялларга кирәк, кирәк!..

Тагын тынып калдылар. Әхмәди байның сүзләренә каршы аһ-ваһтан башка җавап ишетелмәде. Шулай шактый вакыт тын торганнан соң гына, Нигъмәтулла әфәнде, Муса әфәндегә таба борылып:

— Адвокатсыз ярамый. Ат җигәргә кушарга кирәк. Господин Андреевка барып кара,— диде.

— Ул хәзердә Казанда юк, Сембергә китте,— дип җавап бирде Муса әфәнде.

— Кайчан кайтыр икән?

— Иртәгә өйлә намазыннан соң сәгать икеләрдә кайтырга тиеш. Сәламәт булсак, иртәгә барып карарбыз.

Хөрмәтле укучы! Андреев Казанда олуг вә мәшһүр адвокат иде. Муса әфәндегә дус һәм әшнә кеше булып, Петербург университетында алар бервакытта белем алып чыкканнар иде. (...)

IV

Икенче көн җитте. Муса әфәнде белән Нигъмәтулла әфәнде сәгать уннарда иртәнге чәйне эчеп утыралар иде. Муса әфәнденең бүген кәефе әйбәтрәк — төнлә яхшы төш күргән, хәзер шул төшне абзасына сөйли иде:

— Төшемдә үз-үземне бер караңгы җирдә күрдем, дөм караңгы җирдә. Шушы караңгы җирдән чыгарга бик телим икән, имеш тә, тик юл таба алмыйм, имеш. Ахырда шушы караң-

гылык эчендә ике кеше күренде. Алар миңа: «Әйдә, без сине моннан чыгарабыз»,— дип, икесе ике кулымнан тотып, тагы да караңгырак җиргә илтеп куйдылар, үзләре исә күздән югалдылар. Соңыннан бер кеше килеп: «Әйдә бире, әйдә бире!» — дип, мине якты җиргә чыгарды...

Муса әфәнде төшен сөйләп бетергәч, Нигъмәтулла әфәнде елмаеп:

— Төшең яхшы, иншалла, бу кайгыдан котылып, Хәдичә туташны кәләшлеккә алырсың. Төшең бик яхшы, иншалла, бернәрсә дә булмас, котылырсың. Ләкин бүген господин Андреевка барып эшеңне сөйлә, эшегезне бүген хөкемгә тапшыралар. Господин Андреев округ судында адвокатың булыр, иншалла, котылырсың,— диде. (...)

Янә ярым сәгать чамасы үткәннән соң, Муса әфәнде өйдән чыгып җигүле атына утырды да кучерына Воскресенский урамына[1] Андреевларга барырга кушты. Биш-ун минуттан кучер атларны Воскресенский урамында яхшы гына бер ташпулат янына китереп туктатты. Бу ташпулат господин Андреевның өе иде.

Муса әфәнде аттан төште дә, ишектән кереп, швейцардан:

— Барин өйдәме? — дип сорады.

— Өйдә, бүген генә Сембердән кайтты. Хәзер менеп рөхсәт сорап төшәм.

Шулай дип, швейцар-хадим баскыч буйлап ташпулатның югаргы икенче катына менеп китте. Бераздан яңадан төшеп:

— Рөхсәт, рәхим итегез,— дип белдерде.

Муса әфәнде икенче катка менеп җитер-җитмәс аның каршысына господин Андреев үзе чыкты:

— Әйдәгез, рәхим итегез, әйдәгез, рәхим итегез! Ничек әле болай безне хәтерегезгә төшердегез? Исән-саулармы? Сәламәтлекләр ничек?

---

[1] *Воскресенский урамы* — Казанның Кремльдән университетка таба сузылган үзәк урамнарыннан берсе. Октябрь революциясеннән соң Чернышевский, 1960 елда Ленин исеменә үзгәртелде, хәзер Кремль урамы дип йөртелә.

— Әлхәмделилла, Аллага шөкер,— диде Муса әфәнде һәм, Андреев белән кул биреп күрешеп, хуҗа артыннан бүлмә эченә узды.

Господин Андреев калку гәүдәле, озын кара чәчле, карап торышка егерме алты-егерме җиде яшьләр тирәсендәге бер кеше иде. Бусаганы атлап кергәч тә ул, өй хезмәтчесен чакырып, берәр касә кофе китерергә кушты.

Хезмәтче-хадим чыгып киткәч, Муса әфәнде, господин Андреевка карап:

— Мин сезгә бер олуг хезмәт белән килдем... Минем белән сөйләшеп утырырга вакытыгыз бармы? — дип сорады.

— Бар! Бар! Нинди хезмәт белән килдегез? Сөйләгез, сөйләгез,— диде господин Андреев.

Муса әфәнде болай дип сөйли башлады:

— Ишеткәнсездер, Габдуллин мөсафирханәсендә Зөләйха исемле бер мөсафирә хатынны үтергәннәр. Шушы эштә миңа шаһит булырга куштылар. Мин инде нишләргә тиеш? Нинди мәслихәт кыласыз?

— Мин нинди мәслихәт кылыйм? — диде Андреев.— Шаһит булсагыз, белгән нәрсәгезне сөйләрсез.

— Юк! Юк! Алай түгел. Минем хәл ике ут арасындагы кебек. Төне буе йокламыйча уйланып яттым, берниндн фикергә дә килә алмадым. Инде миңа синнән ярдәм кирәк. Юкса минем эшем харап.

— Мин һаман бернәрсә дә аңлый алмыйм әле. Ник эшегез харап? Миннән сезгә нинди эштә ярдәм кирәк?

— Менә ни өчен харап,— дип, Муса әфәнде господин Шубинның, өйгә килеп, тикшереп, сорау алып китүен, аның Зөләйха яшәгән номерда тентү ясаган булуын, тентү вакытында анда ниндидер хат белән сыңар перчатка һәм ике тәрәзә арасыннан бер сурәт табуын, шулай ук мәрхүмә Зөләйха белән янәшә номерларга кереп тикшереп йөрүен — һәммәсен вагы-төягенәчә сөйләп бирде.

Муса әфәнде сөйләп бетергәч, господин Андреев, куркуга төшкән кеше кебек, утырган җиреннән торды.

— Инде аңладым, әфәндем. Эшегез бик әйбәт түгел икән, хәлегез чыннан да ике ут арасында калган кешенеке сыман икән. Бу эштә сез шаһит түгел, тикшерү вакытында табылган нәрсәләр сезне Зөләйханы үтерүче кеше итеп күрсәтә. Әйе, эшегез начар, начар! Бик тә начар! Алла ярдәм бирсен!

Хадим, кофе алып кереп, өстәлгә табын хәзерләде.

— Әйдәгез, рәхим итегез,— диде Андреев, һәм алар кофе өстәле янына килеп утырдылар. Господин Андреев өзелгән сүзен дәвам иттерде: — Әйе, начар! Начар! Начар булса да, кадәри хәл тырышып карарбыз. Бәлки, бернәрсә дә булмас. Инде кофены эчик.

Алар сөйләшмичә генә кофе эчә башладылар. Ике-өч минут шулай тын гына утырганнан соң, господин Андреев Муса әфәндедән:

— Ә сез үтерелгән ул хатынны тере вакытында белә идегезме? — дип сорады.

— Белә идем,— диде Муса әфәнде һәм: — Сез инде, иншалла, беркемгә дә сөйләмәссез,— дип, сүзен бу рәвешле дәвам итте: — Моннан бер ел элек Петербургка барган вакытымда мин «Татарский ресторан» исемле мәшһүр һәм могтәбәр чәйханә-мөсафирханәнең сигезенче номерына төшкән идем. Күрше җиденче номердан мөселманча сөйләшү ишетеп, мин номер хадимен чакырып, аңардан: «Бу җиденче номерда нинди кешеләр торалар?» — дип сорадым. Хадим: «Бу җиденче номерда мөселманнар торалар»,— дип җавап бирде. «Ничә кеше?» — дидем мин. «Ирле-хатынлы икәү, бер кызлары да бар — барчасы өчәү»,— дип җавап бирде хадим. «Күптәннәнме? Ни вакыттан бирле сезнең номерларыгызда торалар?» — дигәч, ул: «Бер ай булды килүләренә»,— диде. «Нинди йомыш белән килгәннәр?» — дидем. «Кызның әткәсе сырхау, күзләре авырый икән. Петербургка шул сәбәптән килгәннәр»,— дип җавап бирде хадим. Озын сүзнең кыскасы, миңа күрше җиденче номерда торучы әлеге кызны күреп, аның белән танышырга насыйп булды. Гимназиядә курс тәмам иткән, гаять тә гүзәл, Зөләйха исемле кыз иде ул. Кызның әткәсе морза булса да, артык бай кеше

түгел иде. Кызны һәр очраткан саен, ул миңа елмаеп карый иде. Кызны шулай бер тапкыр, ике тапкыр, өч тапкыр күреп, мин аңа үлеп гашыйк булдым. Гашыйк булуымны кызга хат аша белдердем. Кыздан да бик яхшы, минем максатыма туры килгән уңай җавап алдым. Хәтта миңа кәләш булырга да разый булуын да язган иде. Мин исә әле ул вакытта Әхмәди Хәмитовның кызына өйләнү турында уйламый идем. Кызны ярәшмәгән идем. Сүзнең кыскасы, мин Зөләйханы аның әткәсеннән үземә хатынлыкка сорадым. Кызның әткәсе, мине яхшы белмәгәнлектән, Зөләйха туташны миңа бирергә разый булмады. Бер җомга үткәннән соң, бу минем күршеләрем Кырымга кайтып киттеләр. Киткән вакытларында кыз миннән кайсы җирдән икәнемне, исемемне, фамилиямне сорап язып алды. Инде менә моннан бер җомга элек кенә шәһәр почтасы аша бер хат килеп төште. Хатны ачып укып карасам, шундый сүзләр күрдем: «Бүген кич сәгать сигездә Габдуллин мөсафирханәсенең унберенче номерына кил!» «Мине шулай кем чакыра икән, кем икән?» — дип эчтән гаҗәпләнеп уйлый-уйлый, Габдуллин мөсафирханәсенә барган чагымда артымнан бер хатын куып җитеп: «Исәнме? Сәламәтмесез?» — дип эндәште. Әйләнеп карасам — Зөләйха, әлеге, бер ел элек Петербургта «Татарский ресторан»да күреп танышкан Кырым кызы. Мин бик тә гаҗәпләнеп: «Сез монда ничек килеп чыктыгыз?» — дип сорадым. Ул: «Әйдә, мөсафирханәгә барыйк, анда сөйләшербез. Мин сезгә хат язган идем, шаять алгансыздыр?» — диде. Шунда гына почта аша килгән хатны Зөләйха язганлыгын аңладым. Мин: «Әйе, алдым»,— дидем. Мөсафирханәгә җиттек, аннары Зөләйханың номерына кердек. Анда кереп утыргач, мин Зөләйха туташтан: «Монда кем белән һәм нинди йомыш белән килдегез?» — дип сорадым. Ул: «Ялгыз килдем»,— дип җавап бирде. «Әткә-әнкәгез сау-сәламәтләрме?» — дип сорагач: «Әткәем моннан өч ай элек дөнья куйды. Әнкәем сау-сәламәт, Кырымда калды»,— диде. «Монда нинди йомыш белән килдегез?»— дип кабат сорадым мин. Зөләйха туташ берникадәр вакыт дәшми торды, аннары елмаеп, йөземә туры карап: «Сезгә килдем. Шаять,

Петербургта биргән вәгъдәгезне онытмагансыздыр бит?» — диде. Минем вәгъдәм исә, әйткәнемчә, Петербургта вакытта Зөләйха туташка үлеп гашыйк булуым сәбәпле, аны кәләшлеккә алу иде. Петербургта вакытта мин аңа хат язган идем. Хатымда: миңа кәләш булырга ризалык бирсәгез, мин сезне хатынлыкка алыр идем, дигән идем. Инде нинди җавап бирим икән дип бераз уйга калып торгач, мин, сүзне озынга сузмыйча, аңа хәл-әхвәлемне сөйләп бирдем: Әхмәди Хәмитовның кызын йөз мең сум көмеш акчасы белән кәләшлеккә алу максатым булганлыктан, Зөләйха туташка өйләнә алмавымны белдердем. Мәрхүмә мине бик тә ярата иде булса кирәк, бу сүземне ишеткәч, кавышу мөмкинлеге юклыгын аңлап, тыела алмыйча еларга керепте. Ләкин никадәр еласа да, мине хатынлыкка ал дип ялынмады, көчләмәде. Киресенчә: «Бик яхшы, Әхмәди байның кызын йөз мең сум көмеш акчасы белән кәләш итеп ал, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә гомерләрегезне озын кылып, мәхәббәтләр бирсен»,— дип хәер-дога укыды. Мин аңа: «Бүген-иртәгә мең сум акча китерермен, өегезгә кайтырсыз»,— дигәч, ул: «Үзең булмагач, акчагыздан миңа файда юк»,— дип, һаман елавында дәвам итте. Күп төрле сүзләр сөйләштек. Икенче көнне килермен дип, Зөләйха туташ номерыннан кичке сәгать уникедә чыгып киттем. Киткән вакытта швейцарга өч сум чәйлек биреп калдырдым. Икенче көнне исә Габдуллин номерларында Зөләйха исемле бер мөсафирә хатынны үтергәннәр икән дигән хәбәр ишеттем. Менә шул рәвештә иде минем мәрхүмә Зөләйха белән танышлыгым,— дип, Муса әфәнде сүзен тәмамлады.

Господин Андреев әүвәлгечә:

— Да, да, эшегез яхшы түгел, начар! — дип кабатлады, аннары, бераз вакыт дәшми уйланып торганнан соң: — Иншалла, котылырсыз, кадәри хәл тырышырбыз, Алла ярдәмсез калдырмас. Инде кофены эчик,— диде дә, икесе дә, кулларына касәләрен алып, тагы кофе эчәргә керештеләр.

Кофе тәмам булгач, Муса әфәнде китәргә җыенды. Господин Андреев аңа:

— Мин бүген-иртәгә эшләрне белешеп, сезгә барып чыгармын. Шунда эшне ничегрәк тотарга кирәклеге турында да киңәш итешербез,— диде.

— Бик яхшы, килегез, килегез,— диде Муса әфәнде һәм, саубуллашып, господин Андреевның өеннән чыгып китте.

Урамда аны атлары көтә иде. Коляскага утыргач, ул кучерга:

— Әхмәди байның өенә илт,— дип боерды.

— Яхшы,— диде кучер һәм, кузгалып китеп, бер биш-ун минуттан Проломный урамдагы өч катлы бер ташпулат каршысында атларны туктатты. Бу ташпулат Әхмәди Хәмитовның йорты иде.

Муса әфәнде, атыннан төшеп, йортка керде. Әхмәди бай, аны үзе каршы алып:

— Әйдә, рәхим итегез, әйдә, рәхим итегез,— дип кабатлый-кабатлый, бер бүлмәгә алып керде.

Бу бүлмә гаять биек зур бүлмә иде. Бүлмәнең идәненә кыйммәтле келәм җәелгән: тәрәзәсендәге хуш исле гөлләр һәм башкача өй җиһазларының яхшылыгы Әхмәди Хәмитовның бай адәм икәнлеген дәлилләп торалар иде. (...)

V

Өченче көн җитте. Муса әфәнде белән Нигъмәтулла әфәнде иртән сәгать тугызда чәй эчеп утыралар иде. Нигъмәтулла әфәнде Муса әфәндедән:

— Бүген нинди дә булса төш күрдегезме? — дип сорап куйды.

— Бернәрсә дә күрмәдем,— диде Муса әфәнде.— Сез үзегез күрмәдегезме соң?

— Мин дә бернәрсә дә күрмәдем,— дип җавап бирде Нигъмәтулла әфәнде, аннары сүзне икенчегә борды: — Господин Андреев ни вакытта килер икән?

— Вакытын тәгаен әйтмәде, кем белсен ни вакытта киләсен...

Шулай аны-моны сөйләшеп утырганда хадим кереп, Муса әфәндегә бер хат бирде. Хат господин Андреевтан иде. Ул рус телендә язылган иде. Тәрҗемәсе болайдыр:

«Гыйззәтле Муса әфәнде!

Бүген сәгать унбердә сезгә киләм. Үзегез өйдә булып, Габденнәсыр әфәндене дә чакырыгыз. Андреев».

Эченнән: «Габденнәсыр нигә кирәк булды икән?» — дип, Муса әфәнде Габденнәсыр әфәндегә язу язды. (...)

Муса әфәнде, ялгызы калгач, тәһарәтләнеп, кәляме шәрифтән[1] Ясин сүрәсен укый башлады. Укып тәмам иткәч, тизме килерләр икән дип, сәгатькә карады. Сәгатьтә янә ун минуттан соң төгәл унбер булачак иде.

Янә биш минуттан соң хадим кереп:

— Габденнәсыр әфәнде килде, керергә рөхсәтме? — дип белдерде.

Муса әфәнде:

— Рөхсәт! Рөхсәт! Керсен! — дип, урыныннан торып, Габденнәсыр әфәндене каршыларга чыкты.— Әйдә, рәхим итегез, әйдә, рәхим итегез!

Бераздан алар икәве бергә бүлмәгә керделәр, Муса әфәнде кунакка утырыр өчен урын күрсәтте. Габденнәсыр әфәнде күрсәтелгән урынга утыргач, саулык-сәламәтлек сорашып, Хадимне чакырып:

— Безгә берәр касә кофе китерегез,— дип боерды.

— Яхшы, хәзер,— диде хадим.

Хадим чыгып киткәч, Габденнәсыр әфәнде Муса әфәндедән хәл-әхвәл сораштыра башлады. Муса әфәнде аңа үткән көнне үзенең Андреев янына баруын һәм господин Андреевның бүген сәгать унбергә монда киләчәген сөйләде.

Хадим ике касә күтәреп кереп өстәл өстенә куйды.

Муса әфәнде Габденнәсыр әфәндене:

— Кәрәм боерасыз[2],— дип, кофе эчәргә чакырды.

Алар, өстәл янына килеп утырып, кофены эчә башладылар.

— Нигъмәтулла әфәнде кайда соң? — дип сорады Габденнәсыр әфәнде.

---

[1] *Кәляме шәриф* — Коръән (сүзгә-сүз тәрҗемәсе: изге, кадерле сүз).

[2] *Кәрәм боерасыз* — юмартлык, нәзакәтлек белән әйтелә торган өндәү сүзләре.

— Магазинга киткән иде, бераз эшләре бар икән, хәзер кайтыр,— дип җавап бирде Муса әфәнде.

Шулай тегене-моны сөйләшеп кофе эчкән арада Нигъмәтулла әфәнде кайтып та җитте. Ул, өйгә кереп, Габденнәсыр әфәндедән саулык-сәламәтлек сорашкач, Муса әфәндегә карап:

— Хәзер господин Андреев белән Әхмәди бай да киләләр,— диде һәм тәрәзәгә күзе төшеп: — Әнә килеп тә җиттеләр... Чыгып каршы алырга кирәк,— дип өстәде.

Нигъмәтулла әфәнде белән Муса әфәнде яңа килгән кунакларны каршы алырга чыктылар. Бераздан Әхмәди бай белән господин Андреев, бүлмәгә кереп, саулык-сәламәтлек сорашып, өстәл янына утырыштылар. Нигъмәтулла әфәнде, хадимне чакырып алып, тагы берәр касә кофе китерергә кушты. Ике-өч минуттан кофе килеп, аны эчә башлагач, господин Андреев, Габденнәсыр әфәндегә карап:

— Сез, газизем, Габдуллин номерларында торасыз шикелле? — дип сорау бирде.

— Әйе, Габдуллин номерларында торам,— диде Габденнәсыр әфәнде. (...)

Янә бер-ике минут үткәннән соң, господин Андреев, Габденнәсыр әфәндегә карап, болай дип сүз башлады:

— Муса әфәнденең эшен, ягъни мәрхүмә Зөләйханың үтерелүен тикшерүне округ судына тапшырдылар. Зөләйханың үтерелүеннән соң тикшерүдә табылган нәрсәләр Муса әфәндене үтерүче итеп күрсәтәләр. Асылда, Муса әфәнде үтерүче булмаса да. Сез, мөхтәрәм Габденнәсыр әфәнде, округ судында Муса тарафыннан шаһит булып, болай дип әйтерсез: Зөләйха үтерелгән көнне Муса әфәнде кич сәгать сигездә минем номерыма килеп, төнге сәгать уникедә кайтып китте дип. Сез хөкем йортында шулай сөйләсәгез, дустыгыз Муса әфәндегә бернинди дә зарар килмәс, ул котылып калыр. Озын сүзнең кыскасы, мәрхүмә Зөләйха үтерелгән кичтә Муса әфәнде минем номерымда иде, диярсез. Шул рәвештә сөйләсәгез, Муса әфәндегә хөкем йортында бернәрсә дә булмас...

Господин Андреев сүзен тәмам иткәч, Габденнәсыр әфәнде, гәрчә Муса әфәнде ул кичтә аның номерына килмәгән булса да:

— Бик яхшы,— дип, господин Андреев өйрәткән сүзләрне хөкем йортында сөйләргә вәгъдә кылды. (...)

Әхмәди бай да, өенә кайткач, господин Андреев биргән бу гүзәл киңәш турында хатыны белән кызына сер итеп сөйләде. Хәдичә туташ, мондый сөенечле хәбәр ишетеп, кәгазьгә язып бетерә алмаслык дәрәҗәдә шатлык хисе кичерде.

VI

Господин Шубинның үткен-зирәк шымчы булуын Муса Салиховны тиз арада эзләп табуыннан шәт аңлагансыздыр. Господин Андреевның бишенче бүлектә без язып үткән киңәшмәслихәтеннән соң өч-дүрт көн үткәч, иртәнге сәгать унберләр тирәсендә, Зөләйха үтерелгән номерга тентү ясаган суд тикшерүчесе үзенең өендә, чәй өстәле янында, господин Шубин белән икәүләп, әлеге вакыйга турында сөйләшеп утыралар иде.

— Бу үтерелгән Зөләйханың нинди хатын икәнлеге дә, кайсы шәһәрдән яисә авылдан килгән булуы да безгә мәгълүм түгел бит әле,— диде суд тикшерүчесе.

— Үтерелгән хатынның кайсы шәһәрдән яисә авылдан килгән булуы безнең өчен ул кадәр үк әһәмиятле түгел,— диде господин Шубин.— Безнең өчен иң әһәмиятлесе — Муса Салиховны кулга алу, чөнки Зөләйханы үтерүче ул икәнлегендә бернинди шик-шөбһә юк.

Бераз дәшмичә уйланып торганнан соң, суд тикшерүчесе:

— Минемчә, Муса Салихов үтерүче түгел, хатынны бөтенләй башка кеше үтергән булырга кирәк,— диде.

Шубин, кулындагы кофе касәсен өстәл өстенә куеп, гаҗәпләнгән тавыш белән:

— Юк! Юк! Үтерүче Салихов икәнлегендә бернинди шик-шөбһә булырга мөмкин түгел,— дип каршы төште. (...)

Бераз туктап торганнан соң, Шубин сүзен дәвам иттерде:

— Үткән кичне бер чәйханәдә ике татар үзара сөйләшәсөйләшә чәй эчеп утыралар. Берсе әйтә: «Хикмәти Хода, ни

өчен Муса Салихов ул мөсафирә хатынны үтерде икән?» — ди. Икенчесе моңа болай дип җавап бирә: «Бәлкем, ул хатынны бөтенләй Муса Салихов үтермәгәндер? Әгәр Муса Салиховның үтерүче икәнлеген исбатлый торган ачык дәлилләр булса, аны бу көнгә кадәр кулга алмыйча тотмаслар иде, һичшиксез кулга алган булырлар иде»,— ди. Тегесе тагы: «Юк, Салиховның үтерүче булуында бернинди шик-шөбһә юк, чөнки бөтен Казан халкы авызында бер сүз: Муса Салихов госманлы Төркиясенә качып китә, имеш, ди. Үтерүче булмаса, ул госманлы мәмләкәтенә качарга уйлар идемени? Шул, аның үтерүче булуында һичнинди шик-шөбһә юк». Менә шулай озак кына сөйләшеп утырдылар да, чәйләрен тәмам итеп, чәйханәдән чыгып киттеләр. (...)

Суд тикшерүчесенең өендә господин Шубин үткән кичне чәйханәдә булган әлеге вакыйганы сөйләп бетергәч, суд тикшерүчесе:

— Хәер, ул хакта миңа да үткән көнне шәһәр почтасы аша бер хат килеп төште,— дип, утырган урыныннан торып, язу өстәле янына барды да, тартмадан бер кәгазь чыгарып, аны Шубинга китереп бирде:—Менә ул хат!

Хат рус телендә язылган иде. Без аны татарчага тәрҗемә итеп бирәбез. Хатның эчтәлеге түбәндәгечә:

«Господин суд тикшерүчесе! Гәрчә тикшерү вакытында сез эзләп тапкан нәрсәләр мәрхүмә Зөләйханы үтерүче Муса Салихов икәнен ачык дәлилләсә дә, ни сәбәбтәндер, сез аны кулга алмыйча торасыз. Күп кешеләрнең сөйләүләренә карaганда, Муса Салихов чит илгә качарга җыенып йөри, имеш. Хаклык тарафдары».

Хатны язучы, үзенең чын исемен белгертмичә, әнә шулай «Хаклык тарафдары» дигән яшерен имзасын гына куйган иде. Хатны укып чыккач, господин Шубин:

— Әйе, дөрес яза, Салиховны бүгеннән калдырмый кулга алырга кирәк. Юкса чыннан да качып китүе бар,— дип нәтиҗә ясады.

Алар, икесе дә тын калып, берничә минут кофе эчү белән мәшгуль булдылар. Аннары суд тикшерүчесе, господин Шубинга карап:

— Алайса бүген, полиция белән барып, Салиховны кулга алырга кирәк булыр,— диде. (...)

* * *

Әхмәди байның чакыруы буенча, Муса Салихов, Нигъмәтулла һәм Габденнәсыр әфәнделәр төгәл сәгать бергә Әхмәди байга миһман-кунак булып килделәр. Зал-гүрничә дип аталган зур бүлмәдә табын әзерләнгән иде. Табын янында безнең хикәябезгә кагылышлы сүзләр бик аз булды. Шуңа күрәме Муса әфәнде, әңгәмәгә катышмыйча, күңелсезләнеп утырды. Аның эче поша, ниндидер билгесез, хәвефле нәрсәдән җаны тырнала иде.

Бу вакыт Хәдичә туташ үз ягында — зал белән янәшә, аңардан такта дивар белән генә аерылган бүлмәдә утыра һәм, Муса әфәндене бик тә күрәсе килгәнгә, берәр ярык-мазар юкмы дип эзләнә иде. Эзләнә торгач тапты һәм, шул ярык аша Муса әфәндене күзләп, теләгенә иреште. Муса әфәнде нәкъ әлеге ярык каршына утырган иде. Кыскасы, Хәдичә туташ, ярык аша Муса әфәнденең моңсу катыш гайрәтле һәм күркәм йөзен күзәтеп, ашкынулы бер ләззәт хисе кичерде. Муса әфәнде үзе дә, башка кунаклар да Хәдичә туташның болай ярыктан карап торуын бөтенләй сизмәделәр.

Әйткәнебезчә, бу мәҗлестә хикәябез өчен зарур сүзләр сөйләнмәде. Мәҗлес сәгать дүртләрдә тәмам булды, шуннан соң һәрбере үз өйләренә кайтып киттеләр. Өйгә кайткач, Муса әфәнде белән Нигъмәтулла әфәнде, тәһарәт алып, икенде намазын укыдылар. Ә кич сәгать җиделәрдә полиция килеп, Муса әфәндене чәй эчеп утырган җиреннән кулга алып, төрмәгә алып китте. (...)

VII

Муса әфәнде төрмәгә ябылганның икенче көнендә, вакытның бик иртә булуына да карамастан,— иртәнге намаз вакытында ук,— Әхмәди бай, Нигъмәтулла әфәнде, Габденнәсыр

әфәнде һәм господин Андреев, тоткын Мусаның хәлен белер өчен төрмәгә килеп, төрмә башлыгының рөхсәте белән, Муса әфәнде ябылган камерага керделәр. Муса әфәнде ялгызы утырган бу камера, гадәттә ат караклары ябыла торган кысан, караңгы, пычрак һәм суык камералардан аермалы буларак, шактый зур, якты һәм җиһазлы бүлмә иде. Өстәл, урындык, карават — һәммәсе бар. Кыскасы, Муса әфәнде асылзатлар камерасына урнаштырылган иде.

Әхмәди бай белән Нигъмәтулла әфәнде Мусага дип алып килгән азык-төлек, аш-суларны өстәл өстенә бушаттылар. Господин Андреев та, башкаларга сиздермичә генә, Әхмәди байның кызы Хәдичә биреп җибәргән хатны Муса әфәнденең кулына сонды.

Муса әфәнде, уйлаганның киресенчә, хәсрәткә баткан кеше булып күренми иде. Күрәсең, ул бу бәладән котылырмын, төрмәдән тиз чыгармын дип уйлый иде. Күрешергә килүчеләр дә әңгәмә барышында аның бу өметен куәтләргә тырыштылар, ә господин Андреев:

— Бер дә хәсрәтләнмәгез, бернәрсә дә булмас, тиз чыгарсыз! — дип әйтеп үк куйды.

Сизгер укучым! Мин дә Муса әфәндегә бернәрсә дә булмас, ул төрмәдән тиз котылып чыгар дип өмет итәм. Сезнең угыз да шулай булса иде! (...)

Муса әфәнде исә, хәл белүчеләр китүгә, Хәдичә туташның хатын ачып укырга тотынды. Хатта түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Гыйззәтле Муса әфәнделәре! Сезнең көч-гайрәт балкыган нурлы йөзегезне әүвәл мәртәбә күргәнемнән бирле минем бөтен җаным-тәнем шулкадәр әсәрләнде ки, инде миңа ничә көннәр хыялымда шул күрекле йөзегез гәүдәләнә, колагыма сезнең матур-татлы сүзләрегез ишетелә, төннәрендә сез газизләрне төштә күреп күңелем хушлана. Көндезләрендә дә, газизем Муса әфәнде, сез йөрәк бәгъремне күз алдына китереп, юану-зәвекъләнүдән үз-үземне тыярга тәкатем калмады, тәмам гыйшык дәртенә баттым. Шул сәбәпле миңа сез газизләргә бер-ике юл хат язарга җөрьәт иттем. Мине бәхетле

иткән нәрсә — ул сезнең котылып чыгуыгыз һәм миңа булган мәхәббәтегез! Иншалла, котылырсыз, хәсрәткә бирелмәгез, хәзрәти Йосыф галәйһиссәлам кыйссасын хәтергә төшерегез. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сезләргә һәм безләргә сәламәтлек биреп, көннән-көн мәхәббәтләребезне арттырсын, амин! Җан вә йөрәктән гашыйкаңыз — Хәдичә».

Муса әфәнде бу хатны укыгач бик сөенде. Чөнки Муса әфәнденең төрмәгә ябылуы Хәдичә туташның аңа булган мәхәббәтен киметмәгән иде — хатны укып, ул шул нәрсәне аңлады. Хәдичә туташ исә, Муса әфәнденең төрмәгә ябылуын ишеткәч, бик тә кайгырган иде. Хәзер исә, господин Андреев килеп, Муса әфәндегә бернәрсә дә булмас дип дәлилләп сөйләгәч, аның хәсрәте бермә-бер кимеде, күңеле тынычланып калды. (...)

VIII

Сабырсызланып көткән унбишенче апрель җитте.

Бүген хөкем йортында Зөләйханы үтерү эше карала, күрик, ни булыр?!

Вакытның бик иртә булуына да карамастан, таң белән үк, хөкем йорты янында төрле җенес, төрле милләттән бик күп халык җыелган иде. Татарлар һәм руслар, ирләр һәм хатын-кызлар... Татарлар гел сәүдәгәр халкыннан гына булмыйча, араларында нәфис яки зәгыйфь чырайлы, сары яки нурлы йөзле япь-яшь адәмнәр дә бар иде. Болары укучылар, мәдрәсә шәкертләре иде. Шулай ук руслар арасында да төрле-төрле халык: офицерлар, студентлар, адвокатлар һәм төрле катлау сәүдәгәрләр күзгә ташлана иде. (...)

Ниһаять, кешеләр җыела башлаудан берничә сәгатьләр вакыт үткәч, ишекләр ачылып, зарыккан халык, бер-берсен басакыса, этешә-төртешә, хөкем йорты эченә су кебек агылып керә башлады. Алдан кергәннәр биек мәхкәмә[1] залындагы агач эскәмияләрнең алгы сафларыннан урын алу бәхетенә ирештеләр. Соңрак кергәннәр — арттагы эскәмияләргә утырыштылар. Бераздан барлык эскәмияләр тыгызланып утырган кешеләр

[1] *Мәхкәмә* — хөкем йорты.

белән тулды. Эскәмияләрдән урын ала алмый калганнар, дүртәр-бишәр кешеле төркемнәргә бүленеп, саф араларындагы буш урыннарга бастылар. Залга җыелган халык арасында, әлбәттә, Әхмәди бай белән Нигъмәтулла әфәнде дә бар иде.

Менә бер-бер артлы присяжный заседательләр — антлы утырышчылар килә башлады. Хөкем эшләре приставы, секретарь-сәркәтип ярдәмчесе дә күренде. Соңгысы хөкем барышында кирәк булачак кәгазьләрне тәртип белән өстәл өстенә тезеп куйды.

Җыелган халык сабырсыз бер халәттә утырыш башланганны көтә иде. Кайберәүләр, эш юктан эш булсын дигәндәй, үз белгәненчә Муса әфәндене хөкем итә. Гомум тавыш эчендә һәр кешенең дә ни әйткәнен ачык ишетеп булмый. Әнә алдагы эскәмияләрнең берсендә бер бай белән бер шәкерт янәшә утырганнар да үзара әңгәмә корып җибәргәннәр.

Шәкерт байга:

— Галиәхмәт абзый, инде хөкем тиз башланыр, әнә ахун хәзрәтләре дә килде,— диде. (...)

— Кайда, кайда ахун хәзрәтләре?

— Әнә! — дип, шәкерт икенче бүлмәнең ачык ишегенә таба кулы белән ишарә ясады.

Галиәхмәт бай, ачык ишек аша икенче бүлмәдәге ахун хәзрәтләрен күреп:

— Әйе, ул! Болай булгач, тиз башланыр,— диде.

Бераздан ахун хәзрәт, залга чыгып, махсус үзе өчен хәзерләнгән кәнәфигә барып утырды. Ахун хәзрәтләрен залдагы бөтен мөселман җәмәгате аягүрә басып, олылап каршылады һәм ул үз урынына барып утырганга кадәр шулай аяк өсте торды. Ахун хәзрәт кергәнче урын таба алмыйча, урынлы кешеләргә көнләшүле күз карашы ташлап, аптырап басып торган берничә мөселман, ахун хәзрәтне олылап каршылагандагы гомум хәрәкәттән файдаланып, кысыла-тыгызлана, эскәмиядән үзләренә урын алып өлгерделәр.

Ахун хәзрәтләренең өстендә яшел чапан, башында биек ак чалма, үзе озын буйлы, какча гәүдәле, зур ак сакаллы, яше

житмешләргә житкән мәһабәт һәм кыю карашлы бер карт иде. Залга җыелган бар халык — мөселманнары да, руслары да — ахун хәзрәтнең нурлы йөзеннән күзләрен алмый карап тордылар. (...)

Янә ярты сәгатьләп вакыт үтте. Антлы утырышчылар, һәммәсе җыелып бетеп, урыннарына утырдылар. Халыкның зарыгыптилмереп көткән минутлары җитте. Хөкем эшләре приставы:

— Җәмәгать, торып басыгыз! Суд килә! — дип боерды.

Халык, бердәм кубып, аягүрә басты. Көмеш якалы хакимнәр-судьялар керде. Алар озын өстәл янына барып утырышкач, залдагы кешеләр дә үз урыннарына иңделәр.

Шуннан соң антлы утырышчыларны сайлау башланды. Бу сайлау беткәч, араларыннан берсен старшина иттеләр. Мөселман шаһитләр белән антлы утырышчыларны ахун хәзрәт ант кылдырды. Рус булганнарын батюшка-поп ант иттерде.

Ниһаять, баш хаким-рәис, хөкем эшләре приставына карап:

— Үтерүдә гаепләнүчене алып керегез! — дип боерды.

Пристав шундук залдан чыгып китте. Бер-ике минуттан ишек яңадан ачылды, һәм хөкем залына әүвәл — пристав, аның артыннан мылтыклы ике солдат арасында Муса Салихов килеп керде. Муса әфәнде гаепләнүчеләр эскәмиясенә барып утырды, аның як-ягына, мылтыкларын тотып, әлеге ике солдат сакка басты.

Хөкем башланды. Хаким-рәис, Муса Салиховка мөрәҗәгать итеп:

— Зөләйха исемле хатынны үтерүдә үзегезне гаепле саныйсызмы? — дип сорады.

Муса әфәнде, урыныннан торып, көр тавыш белән:

— Юк, мин үтерүче түгел! — дип җавап бирде.

Шуннан соң суд-хөкем сәркәтибе торып басты һәм борыны өстендәге күзлеген җайлабрак куйды да Зөләйханы үтерүдә гаепләнгән Муса Салиховның җинаять эше-гамәле язылган кәгазьне укырга керепте. (...)

Шаһитләрдән сорау алу башланды. Беренче булып швейцар җавап бирде. Ул Муса әфәндедәнең кич сәгать сигездә мәрхүмә

Зөләйха белән бергә мөсафирханәгә килүен һәм төнге сәгать уникедә кире кайтып китүен сөйләде. Киткән чакта үзенә өч сум чәйлек бирүен дә әйтте.

Зөләйханың үле гәүдәсен беренче булып күргән хадимә-хезмәтче хатын да үзенең белгәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирде.

Судка мөсафирханә хуҗасы Габдуллин да шаһит буларак чакырылган иде.

Нәүбәт Габденнәсыйр әфәндегә җитте.

— Сез бу эштә ниләр беләсез? — дип сорады аңардан хөкем рәисе.

Габденнәсыйр әфәнде аз гына уйланып торганнан соң:

— Зөләйха үтерелгән көнне Муса әфәнде кич сәгать сигездә минем номерга килеп, төнге уникедә өенә кайтып китте. Мин шуннан башканы белмим,— диде.

Господин прокурор, утырган җиреннән торып һәм хөкем рәисенә таба йөзе белән борылып:

— Мин шаһиттән сорар идем: ул Муса Салиховның нәкъ кич сигез сәгатьтә килеп, уникедә кайтып китүен ничек шулай төгәл истә калдырды икән? Бәлки, Муса Салихов кич җиделәрдә килеп, сәгать унберләрдә үк кайтып киткәндер? — дип үзенең шиген белдерде.

Прокурорның соравына каршы Габденнәсыйр әфәнде:

— Господин прокурор! Мондый сорау сезнең тарафтан урынлы түгел. Онытмаган булсагыз, мин ярты сәгать элек кенә бу эш хакында дөресен сөйләргә ант иттем. Мин ялганчы түгел! — диде һәм бу җавабы белән адвокат господин Андреевны тәмам куандырып җибәрде.

Шуннан соң хөкемгә рәислек итүче мәрхүмә Зөләйха яшәгән номерның ике катлы тәрәзәсе арасыннан табылган сурәт мәсьәләсенә күчте. Бу ерткаланган сурәт-рәсемнең Муса әфәнде сурәте икәнлеген язган идек инде. Господин Андреев, хөкем рәисеннән рөхсәт алып, Габденнәсыйр әфәндегә мондый сорау бирде:

— Сез Зөләйха үтерелгән номерда торган идегезме?

— Әйе, торган идем,— диде Габденнәсыр.

— Кайчан, күптәнме?

— Мин анда мәрхүмә Зөләйха килгәнгә кадәр бер-ике атна элегрәк тордым.

— Әйтегез әле, сез ул номерда торган вакытта гаепләнүче Салиховның нинди дә булса сурәтен ерткалап, номер тәрәзәсенең кече капусы — форточкасы аша урамга ташларга теләмәдегезме? Уйлагыз әле, хәтерегезгә төшмәсме?

Габденнәсыр әфәнде хөкем рәисенә таба йөзен борды:

— Господин председатель! Господин адвокат миннән сорый: мин Муса Салиховның сурәтен ерткалап, номер тәрәзәсе капусыннан — форточкасыннан урамга ташларга теләмәдемме дип. Белдерәмен: мин андый вак нәрсәләрне бу кадәр вакыт хәтеремдә саклый алмыйм. (...)

Шаһит Габденнәсырдан сорау алу тәмам булгач, судьялар, тәнәфес ясап, ашарга-эчәргә чыгып киттеләр.

Бер ярты сәгатьләп вакыт үткәч, судья-хакимнәр кереп, әүвәлге урыннарына барып утырдылар. Зал тынып калды. Шул тынлыкта прокурор, урыныннан торып, рәислек итүчегә:

— Минем номерлар хуҗасы господин Габдуллинга соравым бар,— диде.

Хаким-рәис мөсафирханә хуҗасы Габдуллинны чакыртты. Ул кергәч, прокурор болай дип сорау башлады:

— Господин Габдуллин! Сез бу эштә шаһит сыйфатында катнашкан Габденнәсыр Хәбибуллинны беләсезме?

— Беләм, бик яхшы беләмен,— диде Габдуллин.— Ул минем мөсафирханәдә инде күптәннән бирле тора.

— Яхшы. Алайса уйлап карагыз әле, бәлки исегезгә төшәр: мөсафирә Зөләйха үтерелгән кичтә Габденнәсыр Хәбибуллин өйдә идеме?

Гаҗәп! Нигә әле господин прокурор мөсафирханә хуҗасына шундый сәер сорау бирә? Хәтта судьялар да моңа ничектер гаҗәпләнеп куйдылар. Әмма, төптән караганда, прокурорның соравы шактый хикмәтле, мәгънәле сорау иде.

«Мөсафирә Зөләйха үтерелгән кичне Габденнәсыр әфәнде өйдә идеме әллә юкмы?» — дип, берникадәр вакыт үзалдына уйлап торды Габдуллин, аннары, ныклы бер фикергә килеп:

— Юк! Юк, господин прокурор! Ул кичне Габденнәсыр әфәнде өйдә юк иде,— дип җавап бирде.— Өйдә булмау гына түгел, ул гомумән Казанда юк иде. Мин яхшы беләм, ул өйдә юк иде... Кич сәгать алтыда ук ул мөсафирханәдән китеп барды.

Адвокат господин Андреев, урыныннан торып, мөсафирханә хуҗасы Габдуллинга карап:

— Ничек әле сезнең хәтерегезгә төште Габденнәсыр Хәбибуллинның ул кичне өйдә булмавы? — дип сорады.

— Габденнәсыр Хәбибуллинның ул кичне өйдә булмавын бер кәгазь-язу таныклык итә. Теләсәгез, күрсәтә алам, ул кәгазь минем янымда,— дип, мөсафирханә хуҗасы, кесәсеннән бер кәгазь чыгарып, хөкем рәисенә илтеп бирде.

Кәгазьдә русча түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Мәрхәмәтле Габдуллин әфәнде! Бүген кичен сәгать алтыда мин Кышкарга китеп барам, шул уңай белән миңа яхшы атлардан җигүле бер пар ат хәзерләтсәгез иде. Барып килү хакы күпме булыр, аны минем хисапка языгыз. Габденнәсыр».

Шуннан соң кәгазьгә язылу вакыты-елы һәм көне куелган иде. Язылу көне мөсафирә хатын үтерелгән көнгә туры килә иде.

— Шаһит Габденнәсыр Хәбибуллинны чакырыгыз! — дип әмер бирде хөкем рәисе.

Залдагы халык, сулыш алырга да җөрьәт итмичә, тынып калды.

Габденнәсыр әфәнде яңадан хакимнәр каршына кереп басты. Хөкем рәисе аңа Габдуллин биргән кәгазьне сузды. Габденнәсыр әфәнде кәгазьдә язылганны берничә кат укып чыкты да, берни дә әйтмичә, аны кире рәискә кайтарып бирде.

— Йә, ни әйтерсез бу хакта? — диде хөкем рәисе.— Монда язылганнар бая сез сөйләгәннәргә каршы килә. Бу язу сезнең кул белән язылгандыр бит? Әгәр шулай икән, димәк, сез

мөсафирә хатын үтерелгән төндә өйдә булмаган булып чыга. Дөресме шул?

— Монда нәрсәдер буталган булса кирәк,— дип, үзгәргән тавыш белән җавап бирде Габденнәсыр әфәнде.— Язу, әлбәттә, минем кул белән язылган, ләкин ул көнне мин Кышкарга бардыммы, юкмы — ачык кына әйтә алмыйм. Ахрысы бармадым.

Шулчак гаепләнүче Муса Салиховның:

— Мөсафирә хатын үтерелгән кичне мин Габденнәсыр әфәнде янында булмадым! Мин аның янына үтерешкә кадәр берничә көн алдан барган идем! Габденнәсыр әфәнде көннәр хисабында ялгыша,— дип кычкырып әйткән тавышы яңгырады.

Залдагы бөтен халык гаҗәпләнүдән аһ итте.

— Алайса, ул кичне, мөсафирә хатын үтерелгән кичне, сез кайда булдыгыз соң? — дип сорады хөкем рәисе.

— Мин сезнең бу соравыгызга җавап бирергә теләмим,— диде Муса әфәнде.

Адвокат господин Андреев чак кына чәчен йолыкмый, ә прокурор эченнән сөенеп утыра иде.

Шаһитләрдән сорау алу беткәч, гадәттәгечә, прокурор сүз алды. Ул мөсафирә хатынны үтерүдә Муса Салиховның ни рәвешле гаепле икәнен, аның җинаяте нинди дәлилләр белән расланганын шулкадәр ышандырырлык һәм тәэсирле итеп сөйләде ки, тыңлаучыда Муса әфәнде гаепсез табылыр, җәзадан котылыр дигән өметнең әсәре дә калмады.

Прокурордан соң сүз адвокат Андреевка бирелде. Ул да бик озак — бер сәгать чамасы сөйләде. (...)

Антлы утырышчылар киңәшмәсе ярты сәгать чамасы дәвам итте. Ниһаять, зең-зең итеп кыңгырау шылтырады. Бу — антлы утырышчыларның киңәшмәсе тәмамлануына ишарә иде.

Ишектә иң элек судьялар күренде. Алар артыннан антлы утырышчылар кереп, һәммәсе дә озын өстәл янындагы урыннарына барып утырдылар. Старшина дигәне кулына киңәшмә карары язылган кәгазьне тоткан иде.

Залдагы җәмәгать һәм Муса әфәнде, нәрсә укыр икән дип, старшинаның авызына төбәлеп катты. Старшина исә, киеренке

тынлыкны юри озаккарак сузарга теләгәндәй, кулындагы кәгазьне әйләндергәләп, бераз вакыт алдына каранып торды. Аннары борынына атландырган күзлеген төзәтте дә ашыкмыйча гына укырга кереште:

— Казанның почетлы гражданы Муса Салихов Зөләйха исемле мөсафирә хатынны үтерүдә гаеплеме? Әйе, гаепле!..

Старшина авызыннан «гаепле» дигән сүз чыгуга ук Муса әфәнде, бөтен аяк буыннары йомшарып, ихтыярсыз урынына чүкте.

Антлы утырышчыларның киңәшмәсе мөсафирә хатынны үтерүдә гаепле дип тапкан Муса Салиховка нинди җәза тиешлеге хакында хөкем карары чыгару өчен, судьялар, гадәттәгечә, икенче бүлмәгә кереп киттеләр. Унбиш-егерме минут үткәннән соң, алар янәдән залга чыкты. Хөкем рәисе кабул ителгән карарны укыды. Карарның нәтиҗәсе бу иде: «Муса Салиховны ун елга каторга хезмәтенә хөкем итәргә».

Шулай итеп, хөкем тәмам булды.

Халык һәм хөкем әһелләре тарала башлады. Муса әфәндене залдан үле кешедәй күтәреп алып чыктылар.

* * *

Вакыт кич. Төн уртасы якынлашып килә. «Царьград» чәйханәсендә Габденнәсыр әфәнде белән мөсафирханә хуҗасы Габдуллин чәй эчә-эчә сөйләшеп утыралар. Муса Салиховка хөкем тәмамланганнан соң, алар туп-туры монда килгәннәр иде.

Алар килгәндә чәйханәдә беркем дә юк иде. Ләкин дүрт-биш минутлар үткәч, чәйханәгә бер исерек рус килеп керде. Керде дә, Габденнәсыр әфәнделәрдән бер-ике өстәл аша гына урынга утырып, чәйханә хадименнән аракы китерүен таләп итте.

— Әүвәл акчасын бирегез, юкса түләми онытып китәрсез,— диде хадим.

Исерек рус:

— Сез, нәрсә, акчам юктыр дип уйлыйсызмы әллә? Менә күпме акчам бар! — дип, кесәсеннән бер уч көмеш акча чыгарды.— Юк, онытмамын, түләрмен, китерегез.

Ике-өч минут эчендә исерек рус өстәле өстенә соралган кадәр аракы килеп утырды. Бер-ике касә эчкәннән соң, ул, тәмам мәлҗерәп, утырган җирендә йоклап та китте.

Габденнәсыр белән Габдуллин әфәнделәр исә, йокыга киткән исерек руска игътибар да итмәстән, үзара сөйләшә-сөйләшә чәй эчүләрендә булдылар.

— Йә, энем, кичә миңа язып биргән язуыгыз эшне ничек үзгәртте, ә? — диде Габдуллин.— Әгәр ул язу булмаса, Муса Салиховны үтерүдә гаепли алмаслар, ул котылып калыр иде. Димәк, Муса әфәндене гаепле иткән төп дәлил сезнең шушы ялган язуыгыз булды. Сез бит ул кичне, үтерү булган кичне, өйдә идегез. Асылда, бу — безнең зур гөнаһыбыз. Сезнең ялган язуыгыз аркасында Муса әфәнде нахактан ун еллык каторга хезмәтенә җибәреләчәк.

Габденнәсыр әфәнде аның сүзләренә каршы:

— Бик яхшы, барсы да минем файдага,— дип җавап бирде.— Югыйсә янә бер-ике айдан соң Әхмәди байның кызы белән йөз мең акчасы Муса Салихов милкенә күчәчәк иде. Хәзер исә ул байлык бер-ике ай эчендә минем милкемә керәчәк.

Габденнәсырның бу сүзләреннән соң Габдуллин, нәрсәдер уйлагандай, бераз вакыт дәшми торды, аннары:

— Белеп булмый, Әхмәди бай үзенең кызын, бәлки, сезгә бирмәс,— дип куйды.

— Бирер! Бирер! — дип кабатлады Габденнәсыр.— Күрерсез, ничек кенә бирер әле. Хәзер комачау итәрлек бернинди киртә калмады. Әхмәди байның гүзәл кызы Хәдичә туташ белән йөз мең сум акчасы — һичшиксез минеке булыр!

Чәй өстәле янында шулай сөйләшә-сөйләшә утырып, Габденнәсыр әфәнде белән Габдуллин өйләренә сәгать берләрдә генә кайтып киттеләр. (...)

Инде «Царьград» чәйханәсенә аракы сорап кергән исерек руска килсәк, ул да гади бер кеше түгел, ә мәгълүмегез шымчы господин Шубин иде. Һәм ул исерек тә түгел иде. Йоклаган булып кыланса да, асылда йокламый да иде. Татарча аңлый-сөйләшә белү генә түгел, татарча укый да, яза да белгән господин Шубин үзенең зирәк акылы белән чәйханәдә Габдуллин һәм Габденнәсыр әфәнде арасында барган әңгәмәнең серле мәгънәсенә, сез укучылар кебек үк, бик тиз төшенде. (...)

IX

Икенче көнне, иртәнге сәгать унберләрдә, Нигъмәтулла әфәнденең өендә Әхмәди бай белән өй хуҗасы чәй табыны янында сөйләшеп утыралар иде. Алар хәзер генә Муса әфәнденең хәлен белеп кайтканнар. Муса әфәнде сырхауланып киткән икән, шуңа күрә Әхмәди бай белән Нигъмәтулла әфәнденең кәефләре аеруча төшенке; сүз саен: «Йа Аллаһы, әстәгъфируллаһ!» — дип кабатлыйлар; «Бер дә юкка һәлак булды! Ун ел каторга хезмәте бит, ничек түзмәк кирәк!» — дип офтаналар иде.

Шулай кайгырышып утырганда хезмәтче кереп:

— Господин Андреев килде. Рөхсәт бармы? — дип белдерде.

— Рөхсәт, рөхсәт, керсен! — диде өй хуҗасы.

Ярты минуттан ишектә сезгә мәгълүм адвокат-господин Андреевның озын гәүдәсе күренде.

— Сәламәтләрмесез?

— Әлхәмделилла, Аллага шөкер! — диде Нигъмәтулла әфәнде һәм утырыр өчен кунакка өстәл яныннан урын күрсәтте.

Андреев утырды. Бүлмәдә беразга гына тынлык урнашты. Сүзне беренче булып Әхмәди башлап җибәрде.

— Җинаять көнендә Муса әфәнде Габденнәсыргга бармаган булгач, кайда булган соң ул? — дип сорады ул господин Андреевтан.— Сезгә, адвокат кешегә, Муса әфәнде бу турыда сер итеп сөйләгәндер бит?

— Дөрес! Дөрес! Муса әфәнде бу хакта миңа барлык серләрен сөйләде. Әмма сер итеп әйтелгәнне башка кешегә фаш итүне мин үзем өчен зур гаеп саныйм. Сезгә фәкать шул кадәресен генә әйтә алам: Муса әфәнде үтерүче түгел! Гәрчә үтерүче буларак гаепләнсә дә.

— Йа Хода! Ни була инде бу? Кешене бер гаепсезгә каторга хезмәтенә озатсыннар, имеш! — дип куйды Нигъмәтулла әфәнде, еларга җитешеп.

Әхмәди бай да күз төпләрен сыпырып алды.

Бераз вакыт тын гына утырганнан соң, Нигъмәтулла әфәнде господин Андреевтан:

— Инде Муса әфәндегә ярдәм итәрдәй бүтән бер юл да юкмыни? — дип сорады.

— Нишләп булмасын, бар андый юл. Тик аның өчен күп акча кирәк,— диде Андреев.

Нигъмәтулла әфәнде белән Әхмәди бай, утырган җирләреннән дәррәү торып, өсте-өстенә сораулар яудырырга тотындылар:

— Нинди юл ул? Сөйлә, тизрәк сөйлә!

— Акча күпме кирәк булса да, табарбыз!

— Әйе, акчадан тоткарлык булмас!

— Тизрәк сөйлә, нинди юл ул?

Господин Андреев:

— Юлы менә мондый,— дип, фикерен аңлата башлады.— Әйткәнемчә, Муса әфәнде Зөләйханы үтерүче түгел. Димәк, безгә хәзер иң мөһиме: чын үтерүчене табу. Чын үтерүче табылгач, Муса әфәнде дә каторга хезмәтеннән котылып, иреккә

чыга дигән сүз. Ләкин бу эш өчен күп акча кирәк булыр. Акча бирергә разый булсагыз, мин Зөләйханы үтергән җинаятьчене эзләп табу эшен үз өстемә алам. Мин аны һичшиксез эзләп табачакмын!

Әхмәди бай белән Нигъмәтулла әфәнде Зөләйханы үтергән чын җинаятьчене эзләп табарга күпме акча кирәк булса, шулкадәр акчаны господин Андреевка бирергә вәгъдә кылдылар. (...)

Суд тикшерүчесе белән әңгәмәсе вакытында Андреев, әлбәттә инде, алдагы көнне булган хөкемнең нәтиҗәсе турында сүз кузгатты һәм:

— Муса Салиховны нахактан һәлак иттек, гөнаһысы сезгә төшәр! — диде.

Суд тикшерүчесе исә:

— Гөнаһысы ни өчен миңа төшсен икән? Муса Салиховның каторга хезмәтенә хөкем ителүенә мин сәбәпче түгел ич! — дип җавап кайтарды.

— Бәлки, тулысы белән сәбәпче дә түгелсездер. Ләкин тикшерү вакытында хата юл белән китеп, Муса Салиховны җинаятьче итеп күрсәтә торган нәрсәләрнең һәммәсен сез тупладыгыз бит. Инде, тырышлыгыгызның нәтиҗәсен күреп, бик тә шатлана торгансыздыр. Җинаяте булмаган кеше, үтерүдә гаепләнеп, каторга хезмәтенә китә.

— Гаҗәеп хәл! — диде суд тикшерүчесе.— Хөкем карары дөресме-юкмы, мин моңа сәбәпче түгел. Муса Салиховка бу эштә никадәр ярдәм итәргә теләсәм дә, мин булдыра алмыйм, моның өчен минем дәлилләрем, көч-куәтем юк.

— Алай түгел! Алай түгел! Ярдәм итәргә сезнең көч-куәтегез бар!

— Ничек инде алай көч-куәтем бар?!

— Менә ничек ярдәм итәргә көч-куәтегез бар,— дип кабатлады господин Андреев һәм суд тикшерүчесенә бая Әхмәди бай һәм Нигъмәтулла әфәнде белән булган әңгәмәне сөйләп бирде.— Безгә чын үтерүчене эзләп табарга кирәк. Сез шул эш өчен безгә бер яхшы шымчы бирегез. Без исә чын җинаятьчене эзләп

табарбыз. Чын җинаятьче табылгач, Муса Салиховны да азат итәрләр. Йә, сез ни дисез?

— Ни дим, яхшы фикер. Без кадәри хәл ярдәм итәргә тырышырбыз. Тик бу эштә шымчының бик зирәге кирәк булыр. Мин сезгә господин Шубинны тәкъдим итәм, аңа бу эш яхшы ук таныш та.

— Бик яхшы, бик яхшы. Алайса бүген үк господин Шубинны безгә җибәрегез,— дип, господин Андреев саубуллаша башлагач, суд тикшерүчесе, аны туктатып:

— Сабыр итегез, господин Шубин монда, минем өемдә. Күрергә теләсәгез, ул хәзер керер,— диде дә шундук бүлмәдән чыгып та китте.

Бераздан ул, господин Шубинны ияртеп, яңадан господин Андреев янына килеп керде. Суд тикшерүчесе, Шубинга карап:

— Менә господин адвокат әйтә, Зөләйханы үтерүче Муса Салихов түгел, ди. Чын җинаятьчене эзләп табарга теләк белдерә. Чын җинаятьче табылгач, әлбәттә, Муса Салихов азат булачак. Сез шул чын җинаятьчене эзләшергә ризамы? — диде.

— Баш өсте, бик ризамын. Эзләшербез. Йөзгә кара килмәс дип уйлыйм. Җинаятьчене эзләп табарбыз. Миңа инде үтерүченең кем икәне дә мәгълүм. Муса Салихов, бичара, үтерүдә гаепләнеп, хөкем ителсә дә, ул үтерүче түгел.

Господин Шубин авызыннан мондый сүзләрне ишеткәч, суд тикшерүче белән адвокат, гаҗәпләнеп, икесе берьюлы:

— Алайса кем соң Зөләйханы үтерүче? Кем, тизрәк сөйлә? — дип кычкырып җибәрделәр.

— Зөләйханы үтерүче — Габденнәсыр Хәбибуллин, башка кеше түгел,— дип җавап бирде Шубин.

Суд тикшерүчесе белән адвокат, ни дияргә дә белмичә, аптырашка калып, берникадәр вакыт дәшми тордылар, аннары господин Шубиннан:

— Зөләйханы үтерүче Габденнәсыр Хәбибуллин икәнен сез каян белдегез? — дип сорадылар.

Господин Шубин хөкем тәмамланган кичне «Царьград» чәйханәсендә булган вакыйганы сөйләп бирде. (...)

X

Муса әфәнденең авырып китүен язган идек. Авыру көннән-көн көчәя барганлыктан, Муса әфәндене төрмә камерасыннан төрмә шифаханәсенә күчерделәр. Шулай ук, кайгы-хәсрәттән, Хәдичә туташта да күкрәк авыруы башланган иде. Олуг табиб-докторларның киңәше буенча, аның авыруына дәва — Самара губернасына барып кыргыз кымызы эчү иде. Әхмәди бай, әлеге табибларның киңәшен тотып, җәйне кымыз эчеп уздыру өчен, Самара шәһәреннән биш-алты гына чакрым җирдә аренда хакы түләү шарты белән дача яллаган һәм озакламый бөтен өй җәмәгате-гаиләсе белән шунда китәчәк иде.

Әхмәди бай Самарага киткәндә господин Андреев төрмәдәге Муса әфәнденең сырхавы һәм тикшерү эшләре барышы турында Әхмәди байга атна саен ике тапкыр хат аша хәбәр җибәреп торырга вәгъдә бирде.

Көннәр гадәтчә уза, тикшерүче затларның эшләрендә дә артык дикъкатькә лаек яңалыклар юк иде. Господин Шубин, әүвәлгечә, Зөләйханы үтерүче Габденнәсыр дип гөман кыла иде. Шул сәбәпле, Шубинның киңәше буенча, Габденнәсырның җинаятен төгәл ачыклау өчен, мәгълүмебез шымчы Иванов, аена ун сум көмеш хак белән, мөсафирларга хезмәт күрсәтүче лакей-хадим сыйфатында Габдуллин номерларына эшкә урнашты.

Господин Шубин кебек үк дәрәҗәдә булмаса да, господин Иванов та зирәк шымчылардан иде.

Габденнәсыр әфәнде исә көннәрен Хәдичә туташ турында уйлап уздырды. Ул хәтта, Хәдичә туташны үзенә кәләшлеккә сорап, Әхмәди байга хат язарга да теләгән иде, тик җөрьәте җитмәде. Яучы-башкода җибәрмәкче булды, ахырда аны да мәгъкуль күрмәде. Ниһаять, уйлана торгач, Самарага үзем барырга кирәк дигән ныклы фикергә килде. Анда үзе барса, аның Әхмәди байга еш-еш кунак булып йөрү мөмкинлеге туачак, шунда, бәлкем, эшләрнең җаена карап, ул Хәдичә туташ мәсьәләсен дә хәл итә алыр. (...)

Самавыр өстәлгә менеп утыргач, Габденнәсыр әфәнде, хезмәтчегә карап:

— Василий, мин иртәгә сездән китәмен,— диде.

— Кая алай китәсез, әфәндем?

— Самарага, кымыз эчәргә китәм.

— Кымыз эчәргә? — дип, гаҗәпләнеп кабатлады хезмәтче.— Сезгә кымыз эчү нигә кирәк? Сез авыру түгел ич!

Габденнәсыр әфәнде елмаеп куйды.

— Әйе, мин авыру түгел. Шулай булса да һәр елны кымыз эчәм. Башка елларны монда, Казанда гына, эчәдер идем. Инде менә быел Самара ягына барырга булдым.

Шымчы-хадим берәр минут дәшми уйланып торды, аннары:

— Бик хуп эш, хәерле сәфәрләр булсын. Тик минем сезгә бер үтенечем бар иде,— диде.

— Нинди үтенеч ул, әйтегез.

Хезмәтче, янә бераз дәшми торгач:

— Юк, үтенечемне сез кабул итмәссез,— дип куйды.

— Нишләп? Мөмкин булса, кабул итәрбез. Нинди үтенеч? Әйдә, сөйлә.

— Хәер, кабул итмәс булсагыз да, әйтим алайса,— дип, хезмәтче Габденнәсыр әфәндегә үзенең үтенечен аңлатырга керешге.— Хикмәт шунда: миндә бераз күкрәк хастасы бар. Мине дә Самарага алып бара алмассызмы диюем. Шунда бергә мин дә кымыз эчәр идем, бәлки, файдасы тияр иде. Алып барсагыз, мин сезгә бөтенләй түләүсез хезмәт итәр идем. Ашатып-эчертеп торсагыз, аннары, үзегез кайтканда, мине дә Казанга алып кайтсагыз,— шул җитә.

Габденнәсыр әфәнде, хезмәтченең сүзен тыңлап бетерер-бетермәс үк, аны-моны уйламыйча:

— Бик яхшы, бик яхшы! — дип шундук риза булды.— Алып барырмын. Миңа барыбер хезмәтче кирәк ич... (...)

Шулай сөйләшә-сөйләшә чәйне тәмам иткәч, хадим Иванов тизлек белән Шубинның өенә барып, аңа бөтен булган хәлне түкми-чәчми сөйләп бирде. Господин Шубин, ялган хезмәтче Ивановның кыйссасын тыңлап бетергәч:

— Тырышуыбыз, бәлки, бушка китмәс,— дип, хезмәтченең Самарага сәяхәтен хуплап каршы алды.

Иванов, үзенең хадимлек вазифаларын үтәү өчен, мөсафирханәгә кайтып киткәч, господин Шубин, үз нәүбәтендә, Ивановтан ишеткәннәрен шул көнне үк господин Андреевка ирештерде.

Икенче көнне, иртәнге сәгать тугызда, господин Шубин, бер тәҗир-сәүдәгәр кыяфәтенә кереп, Габдуллин номерларына килде. Ул, гомумән, тикшерү эшләрендә шымчылык итү өчен һәртөрле кыяфәткә керергә оста һәм бу юлы сәүдәгәр булып кыланырга карар иткән иде.

Господин Шубин, мөсафирханәгә килеп кергәч тә, номерлар хуҗасы Габдуллиннан:

— Буш бүлмәгез бармы? — дип сорады.

— Әлегә буш бүлмә юк, ләкин бер-ике сәгатьтән бер бүлмә бушаячак,— дип җавап бирде Габдуллин.

— Бик яхшы, зарар юк, мин сабыр итәрмен. Ләкин бүлмәне хәзердән үк карарга булмасмы? Миңа яхшырак номер кирәк, чөнки Казанда бер-ике ай чамасы торырга исәбем. Бәлки, әле артыграк та торырмын.

— Алайса бераз гына сабыр итегез,— диде мөсафирханә хуҗасы һәм, йортның икенче катына менеп, Габденнәсыр әфәнде торган номерга юнәлде.

Номер хуҗасы үзендә иде. Габдуллин аңа:

— Газизем Габденнәсыр әфәнде, бер мөсафир килде, номер таләп итә,— дип, йомышын аңлатырга кереште.— Башка номерлар буш түгел, һәркайсында мөсафирлар яши. Сез бүген китәсез, мөмкин булса, сезгә хафа булмаса, әлеге мөсафирга сезнең номерны күрсәтергә ярамасмы?

— Ярый, ярый, керсен, күрсәтегез,— диде Габденнәсыр.

Бер минут үтмәстән, Габдуллин, ялган сәүдәгәрне ияртеп, яңадан Габденнәсыр әфәнде номерына килеп керде. Хуҗа кеше үзе кәнәфигә җәелеп утырган иде. Кәнәфи янында аның яңа хезмәтчесе — шымчы Иванов, хуҗа өйрәткән тәртип белән, чемоданга юл кирәк-яракларын тутыра иде. Артык тырышудан аның маңгаена хәтта тир бәреп чыккан иде.

Ялган сәүдәгәр, номерга кергәч, Габденнәсырга карап:

— Хөрмәтле әфәнде, борчыганым өчен гафу итегез инде,— диде.

— Зарар юк, зарар юк! — дип җавап бирде Габденнәсыр әфәнде һәм билгесез сәүдәгәргә утырырга урындык күрсәтте.

— Рәхмәт! — диде ялган сәүдәгәр, күрсәтелгән урынга утырып.

Господин Иванов белән господин Шубин бер-берсен әлбәттә таныдылар. Ялган сәүдәгәребез, номер эчен җентекле карашы белән күздән кичергәч, Габдуллинга таба борылып:

— Әйе, номер үзе дә, өстәл, урындык, кәнәфи, көзге кебек җиһазлары — һәммәсе дә бик яхшы икән,— дип мактап куйды.

Габдуллин исә:

— Номердагы бар җиһаз да минеке түгел... Аларның кайберләренә мөсафир үзе, Габденнәсыр әфәнде хуҗа,— диде.

— Әгәр дә җиһазларның барысын да кирәк дисәгез, мин үземнекеләрен сезгә сатып калдыра алам,— дип сүзгә катышты Габденнәсыр әфәнде.

— Бик яхшы булыр иде,— диде ялган сәүдәгәр, шатлануын белдереп.

Һәм алар, вакытны сузмастан, шунда ук, һәр әйбернең хакын сораша-белешә, үзара исәп-хисап ясашырга керештеләр. Шул исәп-хисап барышында шымчы господин Шубинның утлы күзләре, бүлмә буенча йөреп, анда булган һәр нәрсәне, бигрәк тә өстәл өстендәге кәгазьләрне дикъкать белән җентекли иде. Шулчак аның күзләре өстәл өстендә яткан револьверны шәйләп алды. Ул урынынннан торды да өстәл янына килде һәм, сабы алтын-көмеш белән бизәлгән револьверны кулына алып:

— Нинди гүзәл, зиннәтле револьвер! Моны да сатып алам, хисап кәгазенә хакын языгыз,— диде.

— Юк, револьверны сатмыйм, үземә кирәк,— диде Габденнәсыр. Аның тавышында ачулы бер аһәң ишетелеп китте.

Господин Шубин, револьверны учында әйләндергәләп караган булып, бүлмәдәге кешеләргә сиздермичә генә кесәсеннән балавыз кисәге чыгарды да, әлеге револьвер көпшәсенең очын балавызга тидереп, тишекнең зурлыгын-биеклеген үлчәп алды.

Аннары, револьверны өстәл өстенә кире куеп һәм Габденнәсыр әфәндедән килешеп алган әйберләр өчен тиешле акчаны түләп, номердан чыкты. Ул туп-туры Андреев янына юнәлде. Аңа номерда булган хәлләрне сөйләде һәм ахырда:

— Габденнәсыр әфәнденең өстәле өстендә Зөләйханың үлеменә сәбәп булган револьверны күрдем,— диде.

— Аның нәкъ шул револьвер икәнлеген каян беләсез? Бәлки, Зөләйханың үлеме бөтенләй икенче револьвердан булгандыр? — дип шөбһәсен белдерде Андреев.

— Мин Зөләйханың нәкъ шул револьвердан үтерелүендә һич тә шикләнмим,— дип җавап бирде господин Шубин.— Чөнки Зөләйханың гомерен өзгән пуляның кечкенәлеге ул пуля чыккан револьвер көпшәсенең дә шундый кечкенә тишекле булуын таләп итә. Габденнәсыр өстәле өстендә яткан револьвер нәкъ шундый нечкә көпшәле иде. Менә аның көпшәсенең үлчәме! (...)

* * *

Господин Шубин, үз өенә кайткач, чемоданына тиз генә улбу әйберләрен төяп, урын-җирләрен алып, ат белән Габдуллин мөсафирханәсенә юл тотты. Аны мөсафирханә ишеге төбендә номер хадиме хезмәтләрен башкаручы шымчы Иванов каршы алды. Ул, үзенә бер тырышлык күрсәтеп, тирләп-пешеп, арбадан әйберләрне бушатты һәм икенче катка — Габденнәсыр әфәндедән бушаган бүлмәгә ташырга кереште. Ялган хезмәтче, соңгы әйберләрне җилкәсенә күтәреп, ялган сәүдәгәр белән баскычтан менеп барганда, тегесе аңардан:

— Габденнәсыр әфәнде әллә китеп тә өлгердеме? — дип сорады.

— Хәзер генә китте,— дип җавап бирде ялган хезмәтче.

— Мөсафирханә хуҗасы үзендәме соң?

— Ул да китеп барды... Габденнәсыр әфәндене озатырга...

Шулай сөйләшә-сөйләшә алар номерга керделәр. Иванов әйберләрне җилкәсеннән идәнгә төшерде дә:

— Сез килгәнгә кадәр номер эчен җыймый-тазартмый тордым,— диде.

— Бик яхшы иткәнсең... Ишекне ябып бикла,— диде Шубин.

Номер эче эшкә яраксыз нәрсәләр, анда-монда ерткалап-бөгәрләп ташланган кәгазьләр белән тулы иде. Господин Иванов ишекне бикләгәч, господин Шубин:

— Инде эшкә керешик! — дип боерды.

Алар, ашыкмыйча гына, бер-берсенә сүз дәшмәстән, идәндәге кәгазьләрне берәм-берәм карый-тикшерә башладылар. Ярты сәгать чамасы вакыт узгач, ниһаять, Иванов:

— Бу кәгазьләрдән безгә ярардай нәрсә күренмәстер, ахрысы,— дип уфтанып куйды.

— Бернәрсә дә тапмадыңмыни? — дип сорады господин Шубин.

— Юк шул, бернәрсә дә тапмадым.

— Ә мин менә эшкә яраклы бер кәгазь таптым шикелле,— дип, господин Шубин кулындагы кечек бер кәгазь кисәген селкеп күрсәтте.— Хатын-кыз кулы белән язылган нәрсә. Алай гына да түгел, язуы мәрхүмә Зөләйханың язуына бик охшый...

Господин Шубин кулындагы кәгазьне өстәл өстенә куйды. Иванов та, өстәл янына килеп, табылдык кәгазьне карарга керешә. Бу ярым ертык кәгазь кисәге булып, андагы язу да тулы җөмлә түгел, ә берничә сүздән генә гыйбарәт иде. Сүзләр русча язылып, аларның татарчасы болай иде: «Кырым, Бакчасарай, Салачыкта Сөләйман мирза хатыны...»

Язуны кат-кат бергәләп укып чыккач, господин Шубин, үзенчә аңлатма биреп:

— Бакчасарай — шәһәр исеме, Салачык — авыл исеме, ә Сөләйман мирза хатыны дигәне, күрәсең, мәрхүмә Зөләйханың әнисе булырга тиеш,— диде.— Безгә бу кәгазьдән күп нәрсә мәгълүм булуы ихтимал. (...)

...Бер атна үткәч, господин Шубин, Габденнәсыр әфәндедән түләп алып калган бүлмә җиһазларын мөсафирханә хуҗасы Габдуллинга арзан бәһага генә сатып һәм юл чыгымнары өчен кирәкле акчаны Нигъмәтулла әфәндедән алып, әлеге эш белән Бакчасарай шәһәренә чыгып китте. Шулай ук Габденнәсыр

әфәнденең яшь хадиме — шымчы господин Иванов та, үз өстенә алган хезмәтчелек вазифаларын үтәү өчен, вәгъдә буенча, Самара шәһәренә юл алды.

Хәерле сәфәрләр булсын үзләренә!

XI

Габденнәсыр әфәнде, Самарага барып җитү белән «Гранд-отель» мөсафирханәсендә бер бүлмә алып, кымыз эчүне башлап та җибәрде. Бераздан хадим Иванов та килеп җитте һәм, кымыз эчү белән бергә, Габденнәсырга хезмәт күрсәтү вазифасына кереште. Аның шымчылыгы хакында беркем дә бернәрсә дә белми иде.

Габденнәсыр әфәнде ара-тирә Әхмәди бай дачасына кунакка барып йөрде. Анда булганда ул Казан хәлләре, Муса әфәнде турында сүз кузгатмаска тырыша иде.

Шулай, Әхмәди бай дачасында булган мәҗлесләрнең берсендә, хуҗа кеше Габденнәсыр әфәндегә:

— Минем сезгә бер соравым бар,— дип мөрәҗәгать итте.— Тик, зинһар, турысын әйтегез. Соравым шул: мөсафирә Зөләйха үтерелгән төндә Муса әфәнде сезнең номерыгызда булмагач, кайда булган соң ул?

— Муса әфәнде ул кичне мәрхүмә Зөләйха номерында иде,— дип, өзеп-кистереп җавап бирде Габденнәсыр әфәнде.

Әхмәди бай, Габденнәсыр әфәндедән мондый җавапны ишеткәч, тирән гаҗәпләнү белән:

— Муса әфәнде чит-ят хатын бүлмәсенә төн вакытында ничек барып керсен икән? — дип сорады.

Шуннан соң Габденнәсыр әфәнде, үзеннән дә ялганнар кушып, Зөләйханың нинди кыз икәнлеген, аның Муса әфәнде белән кайда, ничек танышуларын, араларында нинди мөнәсәбәтләр булуын тәфсилләп сөйләп бирде.

— Алай булгач, кызны үтерүче кем соң? — дип, тагын сорады Әхмәди бай.

— Бу соравыгызга туры җавап бирергә минем кодрәтем юк,— диде Габденнәсыр әфәнде.

Габденнәсыр әфәнденең сөйләгәннәре Әхмәди байны шактый борчуга салды. Ул төрлечә юрап карады, хәтта Муса әфәнде чынлап торып гаепле микән дигән шөбһәле уйларга да батты.

* * *

Көннәр шулай гадәтчә үтә торды. Әхмәди байга Казаннан— адвокат господин Андреев белән Нигъмәтулла әфәндедән хатхәбәр әле һаман килгәне юк иде. Муса әфәнденең хәл-әхвәленнән аңа бернәрсә дә мәгълүм түгел иде... Тик бер килешендә Габденнәсыр әфәнде генә аңа:

— Муса әфәнде акылдан язган, имеш,— дип әйтеп куйды.

— Аны син каян ишеттең? — дип сорады Әхмәди бай.

— Казанлы бер мөселман сөйләде,— диде Габденнәсыр әфәнде. (...)

Май аеның аяз бер көнендә Әхмәди бай үзенең дачасында кунак булып килгән Габденнәсыр әфәнде белән икәүдән-икәү чәй эчеп утыра иде. Шул чәй табыны янындагы әңгәмә вакытында Габденнәсыр әфәнде, җаен туры китереп, үзенең төп максаты булган Хәдичә туташ хакында сүз кузгатты һәм Әхмәди байдан кызны үзенә кәләшлеккә бирүен сорады.

Әхмәди байга Габденнәсыр әфәнденең бу тәкъдиме артык көтелмәгән нәрсә булып тоелмады. Дөрес, аның кызы Муса әфәндегә ярәшелгән иде... Ләкин хәзер хәл үзгәрде: Муса әфәнде үтерүче булып чыкты, ул каторга хезмәтенә озатылачак. Габденнәсыр әфәндедән башка яхшы, күңелгә хуш килерлек бүтән кеше күренми. Шул рәвешчә фикер йөртеп, Әхмәди бай кызы Хәдичә туташны йөз мең сум көмеш акчасы белән Габденнәсыр әфәндегә кәләшлеккә бирергә күңеленнән разый булды һәм егетнең ният-теләгенә:

— Җәмәгатем белән киңәш-табыш итеп, безгә кабат килүегездә катгый карарымны әйтермен,— дип җавап бирде.

Габденнәсыр әфәнде, табигый, бик канәгать булып, инде йөз мең сум көмеш минем кесәдә булыр дип шатланып, мәҗлес тәмамлануга дачадан үзенең мөсафирханәдәге бүлмәсенә кайтып китте. Әхмәди бай исә, Габденнәсыр әфәнде киткәч,

хатыны белән киңәш-табыш итеп, Хәдичә туташны йөз мең сум көмеш акчасы белән Габденнәсыр әфәндегә кәләшлеккә бирергә риза икәнлеген күңеленә беркетеп куйды.

* * *

Хәдичә туташка килсәк, аның уенда иртә дә, кич тә фәкать Муса әфәнде иде. «Бу кадәр озак ни өчен хаты килми икән?» — дип уфтана иде ул.

Менә шундый уйлар белән яшәгәндә ул әнисе авызыннан үзенең Габденнәсыр әфәндегә кәләшлеккә бирәчәкләрен ишетте. Аны хәсрәт биләп алды. Хәсрәт көннән-көн арта, тирәнәя бара иде. Ул төрле уйларга батты. Ләкин нәрсә генә уйласа да, ни кылсын? Ата-ана теләгенә каршы барсынмыни?!

Габденнәсыр әфәнде, киресенчә, Хәдичә туташны үзенә бирергә риза булулары турында Әхмәди байның катгый карарын ишетеп, иксез-чиксез шатлык хисе кичерде. Ни өчен шатланмасын, ди! Ниһаять, морадына иреште — йөз мең сум көмеш акча белән гүзәл кыз ала! Тагы унбиш-егерме көннән Самара шәһәрендә аларның никах мәҗлесе булырга тиеш.

Тик менә, үч иткәндәй, кулында туй мәҗлесе ясарга җитәрлек акчасы гына юк. Нишләргә? Туй мәҗлесенә, мәһәргә, бүләкләр алырга шактый күп акча кирәк! Габденнәсыр әфәнде Казаннан — Габдуллиннан туй чыгымнары өчен акча сорап хат язды. Хатны шымчы хадим Ивановка биреп, Казанга Габдуллинга юллады. (...)

XII

Господин Шубинның Казаннан Бакчасарай шәһәренә китүен язган идек. Ул, Бакчасарайга килеп җитеп, андагы иң яхшы мөсафирханәләрдән «Госман къәһвәханәсе»[1]нә төшеп бер бүлмә алды. (...)

Янә ярым сәгатьтән соң господин Шубин инде Салачыкта — Сөләйман морза хатыны Гайшә ханымның өендә иде.

---

[1] *Къәһвәханә* — кофеханә (*къәһвә* — кофе); *биредә:* «чәйханә-кунакханә» мәгънәсендә кулланылган.

Гыйззәтле укучы!

Кырымдагы ислам җәмәгатенең рус телен начар белүе Кырымда булган кешеләргә сер түгел. Ләкин Гайшә ханым рус телендә иркен сөйләшә генә түгел, русча укырга-язарга да оста иде. Шуңа күрә ул таныш түгел кешене шундук:

— Сез кем буласыз, кайсы җирдән? Монда нинди йомыш белән килдегез? — кебек сораулар белән каршы алды.

— Мин Казаннан, бер сәүдәгәр буламын. Сезгә зур бер эш белән килдем,— дип җавап бирде Шубин һәм йомышын аңлата башлады.— Моннан берничә айлар элек Казан шәһәрендә бер хатынны үтерделәр... Менә шул эшне тикшерү вакытында, ни хикмәттер, сезнең исемегез теркәлгән бер язу-кәгазь табылды.

Гайшә ханым, билгесез бер Казан кешесеннән мондый сүз ишетеп, гаҗәпләнү катыш хәвефле тавыш белән:

— Үтерү кебек эшләрдә минем исемнең нинди катышы булыр икән?! Минем гомеремдә бер тапкыр да Казанга барганым юк. Үтерелүче хатын нинди кеше, исеме ничек? — дип, Шубинның сүзен бүлдерде.

— Үтерелгән хатынның исеме — Зөләйха, үзе гаҗәеп тә гүзәл-сылу хатын булган,— диде господин Шубин.

Шубинның бу соңгы җавабы Гайшә ханымга шулкадәр тәэсир итте ки, аның йөзе, үлек йөзедәй, бердән агарып китте. Ул тетрәнүле тавыш белән:

— Зөләйха!.. Зөләйха!.. Зөләйха!..— дип, берничә тапкыр кабатлады да: — Зөләйха — ул минем кызым! — дип, үкси-үкси еларга тотынды.

Господин Шубин, мәрхүмә Зөләйханың әнкәсен юатырдай чара таба алмыйча, тәмам югалып калды, ни кылырга, ни сөйләргә дә белмәде.

Гайшә ханым исә, үксүдән бераз туктап, күзеннән яшьләрен сөртте дә:

— Әйе, Зөләйха, мәрхүмә Зөләйха минем кызым ул, ләкин сез хата сөйлисез: Зөләйханы үтермәделәр... Зөләйха револьвердан үз-үзен атып үтерде,— дип, тагы елый башлады.

— Гайшә ханым! Мин хата сөйләмим. Мәрхүмә Зөләйханы үтерүче кеше инде тотылып, җинаяте өчен округ суды тарафыннан ун елга каторга хезмәтенә хөкем ителде,— диде господин Шубин.

— Округ суды ялгышкан,— дип, аның сүзен бүлде Гайшә ханым.— Ун еллык каторга хезмәтенә бөтенләй гаепсез кешене хөкем иткәннәр. Минем кызымның фаҗигале үлемендә беркем дә гаепле түгел. Минем кызымның үләр алдыннан миңа язып җибәргән хаты бар, анда ул үз-үземне атып үтерәм дип ап-ачык язган.

Шулай дип, Гайшә ханым тагы да катырак үкси башлады. Хәер, хатын-кызның күп елавы гадәти нәрсә.

Господин Шубин, Гайшә ханым авызыннан башына һич тә килеп карамаган мондый хәбәрне ишеткәч, тырышлыгым бушка китмәде дип, эченнән сөенеп куйды. Бер минутлап тынып торганнан соң ул, Гайшә ханымга карап:

— Кызыгыз үләр алдыннан сезгә язып җибәргән ул хатны күрергә мөмкин булмасмы? — дип сорады.

Гайшә ханым, урыныннан торып, язу өстәле янына барды да, өстәл тартмасыннан бер конверт чыгарып, аны господин Шубинның кулына китереп тоттырды. Шубин, хатны ачып, хатта язылганны тирән бер тетрәнү-гаҗәпләнү белән берничә кат күзеннән кичерде.

Гыйззәтле укучы! Мәрхүмә Зөләйханың мөселманча-татарча укый-яза белмәвен беренче бабта әйткән идек. Аның соңгы хаты да русча язылган иде. Хатның тәрҗемәсе болай:

«Әнкәем, йөрәк бәгърем! Мин сез җәнабе галиләрегез алдында җинаятьлемен. Мәхәббәтле әткәемнең дөнья куюыннан болай да җәрәхәтле күңелегезгә минем сезне ташлап, качып китүем аеруча зур зәһәр булгандыр. Инде менә бер ай үтте сезне ташлап качып китүемә. Әмма кай җиргә, ни сәбәптән качып китүем турында мин сезгә хат аша хәбәр итмәдем... Минем сез газизләргә моңарчы хат язмавым минем тарафтан олуг гаептер. Инде, шәфкатьле әнкәем, хәл-әхвәлемне бәян итеп сезләргә хат язарга мәҗбүрмен. Сөекле әнкәем, үткән

елны, мәрхүм әткәемнең күзләре авырган вакытта, Петербургка барып, «Татар ресторан»ында мөсафир булып торган чагыбызда, безнең номер белән күрше номерда бер казанлы яшь егет мине үзенә хәләл җефетлеккә сораган иде. Мәрхүм әткәем һәм сез, сөекле әнкәем, Муса әфәндене яхшы белмәвегез аркасында, мине Муса әфәндегә хатынлыкка бирергә риза булмадыгыз. Инде, миһербанлы әнкәем, Муса әфәндене хәтерегезгә төшердегезме? Бераз уйлап баксагыз, хәтерегезгә төшәр. Мин, сезнең гөнаһлы кызыгыз Зөләйха, Муса әфәндегә гашыйк булуым аркасында, сезнең рөхсәтләрегездән башка, Муса әфәндегә кияүгә чыгу нияте белән Казан шәһәренә килдем. Сезнең рөхсәтләрегездән башка качып китүем сәбәпле, минем Казанга сәфәрем дә хәерле булмады. Мәгъшукым Муса әфәнде, казанлы бер бай кешенең кызын йөз мең сум көмеш акчасы белән үзенә хәләл җефетлеккә алырга йөргәнлектән, миңа өйләнүдән баш тартты. Ярым сәгать элек кенә Муса әфәнде минем номерымда булып китте. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә Муса әфәнденең һәм кәләше Хәдичә туташның гомерләрен озын кылып, мәхәббәтләрен көннән-көн артык әйләсен!

Мин инде ни кылыйм?! Бакчасарайга кайтып сезнең күзегезгә күренергә намусым кушмый. Мәгъшукым Муса әфәндедән аерылу газабын кичерергә дә сабыр-көчем калмады. Ни кылыйм?! Хәерле булырдай бернәрсә кылырга да куәтем юк! Инде мин үз-үземне револьвердан атып үтерәмен! Һич тә уйфикер кылынмаган гаҗәеп эш — шундый яшь килеш, кыз вакытымда үз-үземә кул саламын. Йәнә бер сәгатьтән соң мин, кызыгыз Зөләйха, дөньядан үтеп, мәет-үле булырмын. Дөньяның рәхәтләре миннән калыр. Сез дә, әнкәем, бу юлларны укыганда, җинаятьле кызыгызны шәфкать белән искә төшереп, әлбәттә егларсыз! Хәзер мин номерның кечек бүлмәсендәмен. Кулымда револьвер, ул шушы сәгатьтә мине дөньядан алып китәчәк. Шәфкатьле әнкәем! Әгәр сез хәзер бу номерда, минем янымда булсагыз иде, мин, бәлкем, үз-үземә кул салмыйча, әүвәлгечә, дөньяда торып калыр идем. Ниләр кылыйм соң?! Син дә, сөекле әнкәем, минем янымда юк! Гөнаһларым өчен минем

хөкемем тәмам: үз-үземә кул саламын. Сез бу хатны укыганда мин кабер эчендә булырмын. Газиз әнкәем! Сезләргә бер үтенечем бар, үтенечемне кире какмагыз! Үтенечем шул: җинаятьләремне гафу итеп, бәддога кылмаенча, хәер-догалар белән искә алыгыз. Минем игелекле эшләрем юк, мин сезнең догаларыгызга мохтаҗмын! Миңа булган хокукларыгыздан ваз кичеп, миннән разый булып яшәдегез, сезләргә Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сәламәтлек биреп, ахыр көннәрегезне матур ямьле әйләсен!

Сөекле әнкәем! Әлбәттә, бу минем хатым сезнең күңелегезгә тирән җәрәхәт ясар, сезне бетмәс кайгыга салыр...

Бәхил булыгыз! Бу хат минем тарафтан соңгы җинаятемдер, моннан соң мин сезне, әнкәем, язмаларым белән дә, телем белән дә — һичбер төрле юл белән дә рәнҗетмәм. Үз-үземне үтерәмен дәйү номерымда да язу калдырамын. Бәхил булыгыз! Җинаятьле кызыгыз Зөләйха».

Господин Шубин хатны конверты эченә салып өстәл өстенә куйды. Гайшә ханым, конвертны алып, әүвәлге урынына — өстәл тартмасына яшерә башлагач, Шубин:

— Бу хатны миңа бирмәссезме икән? — дип сорады.

— Бу хатны мин кабергәчә үз янымда саклаячакмын! — диде Гайшә ханым.

Шулай да, күп гозерләр кылып, хатны бер ай эчендә Казаннан почта белән кире кайтарырга вәгъдә иткәч, Гайшә ханым кызының соңгы истәлеген Шубинга биреп җибәрергә риза булды.

— Минем кызым аркасында гаепсез кеше каторга хезмәтләренә озатылмасын, котыла күрсен,— диде ул хатны биргәндә.— Ләкин эшләрегез тәмам булгач, озакка сузмыйча, хатны үземә кайтарыгыз.

Господин Шубин саубуллашып чыгып китәр алдыннан Гайшә ханымга үзенең Казандагы адресын да язып калдырды.

Къәһвәханәгә кайтып кергәч, господин Шубин, Казанга суд тикшерүчесе исеменә телеграм язып, телеграмны къәһвәханә хезмәтчесе Энгель аша телеграф станциясенә күндерде. Телеграмда болай диелгән иде:

«Зөләйханың үлемендә Муса Салихов та, башка бүтән кеше дә гаепле түгел. Зөләйха үз-үзен атып үтергән. Шубин».

XIII

Әлеге телеграмны юллаганнан соң үткән ун көн эчендә господин Шубин Казанга кайтып җитте.

Муса Салиховның төрмәдә авырып китүе турында язган идек. Шымчы Шубин Бакчасарайдан әйләнеп кайткан арада ул инде тәмам сәламәтләнеп беткән иде.

Господин суд тикшерүчесе, адвокат господин Андреев һәм шымчы господин Шубин мәрхүмә Зөләйханың үләр алдыннан әнисенә язган хатын тотып прокурор каршына бардылар һәм, хатның Зөләйха кулы белән язылганлыгын исбатлап, Муса Салиховның төрмәдән чыгарылуын таләп иттеләр. Өч көннән ул инде төрмәдән иреккә чыккан иде. (...)

* * *

Муса әфәнденең төрмәдән котылып чыгуы Казанның бөтен мөселман халкына билгеле булган кебек, күпчелек рус җәмәгатьчелегенә дә мәгълүм булды. Мөсафирханә хуҗасы Габдуллин, Муса әфәнденең төрмәдән ни рәвешле котылуын сорашып белеп, Самарадагы Габденнәсыр әфәндегә, Муса әфәнде төрмәдән чыкты, дип, кыска гына телеграм сукты.

Муса әфәнде төрмәдән котылып чыкканнан соң ике-өч көн үткәч, өч кеше — Муса әфәнде үзе, Нигъмәтулла әфәнде һәм дә адвокат господин Андреев Самарага Әхмәди байга кунак булып килделәр. Әхмәди бай үзе дә, гаиләсе дә кунакларны бик шатланып каршы алдылар. Бигрәк тә Хәдичә туташ каләм белән язып бетереп булмаслык дәрәҗәдә сөенде.

Хәдичә туташ гөман кылганча, Муса әфәнде шактый бетерешкән, ябыккан иде.

Әхмәди бай господин Андреевтан:

— Ни өчен Муса әфәнденең хәле, сәламәтлеге турында бер дә хат язмадыгыз? — дип сорагач, Андреев аңа:

— Юк! Без сезгә өч хат язып салдык, тик алар сезгә барып җитмәгәннәр, өчесе дә Габденнәсыр әфәнде кулына эләгеп, аңарда торып калганнар,— дип җавап бирде һәм, кесәсеннән өч хат чыгарып: — Менә бу хатлар сезгә атап язылган иде,— дип, аларны Әхмәди байның кулына тоттырды.

Әхмәди байның сөйләвенә караганда, дачасы Самарадан читтәрәк булуы сәбәпле, Әхмәди бай исеменә килгән хатларны шәһәр почтасыннан алу вазифасы Габденнәсыр әфәндегә тапшырылган булган. Ул, күрәсең, Казаннан Әхмәди байга килгән хатларны ачып укып, иясенә бирмичә, аларны үзендә калдыруны файдалырак тапкан. (...)

XIV

...Муса әфәнде төрмәдә вакытта Габденнәсыр әфәнде Хәдичә туташны йөз мең сум көмеш акчасы белән кәләшлеккә алам дип сөенеп-шатланып йөргән булса, хәзер аны өметсез бер хәсрәт биләп алды. Хәер, шундый хәлдә кеше ничек хәсрәтләнмәсен? Йөз мең сум көмеш акча белән гүзәл кыз кулдан китә!

Габденнәсыр әфәнденең хәсрәте көннән-көн көчәя-арта барды. Ниһаять, хәсрәте чиктән ашып, аны дәвалап бетерерлек дару-чара тапмыйча, тәмам гаҗиз калып, ул шундый бер эш кылды ки, аның бу эше җинаятьләре өчен тиешле бер җәза төсен алды — кыскасы, Габденнәсыр әфәнде үз-үзен үтерү нияте белән зәһәр-агу эчте һәм ярты сәгать эчендә дөньялыктан китеп тә барды.

Габденнәсыр әфәнденең вафатыннан соң бүлмәсендә, мөсафирханә номерында, түбәндәге бер язу-кәгазь табылды.

«Әхмәди Хәмидовның кызы Хәдичәне йөз мең сум акчасы белән кәләшлеккә алу насыйп булмаганлыктан, мин үз-үземә кул саламын. Минем үлемемдә һичкем дә гаепле булмасын. Муса Салихов Зөләйханы үтерүдә хаксызга гаепләнгән кебек, минем үлемемдә дә кемне дә булса гаепләмәсеннәр өчен, мин үләр алдыннан ишекне эчтән бикләп куямын. Алдан ишекне бикләмичә үз-үземне үтерсәм, полиция килгәнгә кадәр кем дә булса бүлмәгә кереп, берәр төрле явыз уй белән, бу хатымны,

урлап чыгуы ихтималы бар. Мылтык тавышын ишеткәч, мин аның бикләнми калган ишегеннән бүлмәсенә кердем дә, Зөләйханың үлемендә Муса Салиховны гаепләсеннәр дип, Зөләйханың үзе-үзен атып үтергән револьверы белән «үз-үземне үтерәмен» дип язып калдырган хатын бүлмәсеннән урлап чыктым. Бу эштә мин зур җинаятьләргә бардым. Шулай булса да максатыма ирешә алмадым — Әхмәди байның кызына һәм йөз мең сум акчасына ия булмадым.

Һәр кешегә үлеме алдыннан тәүбә итү тиеш булганлыктан, мин дә үлемем каршында үз-үземне үтерү нияте белән кулыма бер касә агу-зәһәр алып тәүбә итәмен! (...)

Җинаятьле Габденнәсыр».

* * *

Язылган вакыйгалардан соң бер ай үткәч, Хәдичә туташ тәмам сәламәтләнеп җиткәч, Казанда Әхмәди байның өендә никах мәҗлесе уздырылды; кичерелгән кайгы-хәсрәтләрдән соң туй шатлыгы күрелде.

Туй мәҗлесендә, Муса әфәнде белән Әхмәди байның тугантумача һәм якыннарыннан башка, адвокат господин Андреев һәм шымчы господин Шубин, шымчы Иванов, шулай ук суд тикшерүчесе дә булдылар.

Инде яшьләребез Муса әфәнде белән Хәдичә туташка килсәк, алар, тәмам теләкләренә ирешеп, бәхетле булып, кәефсафада яши башладылар.

Безгә мәгълүм башка кешеләр дә һәркайсы әүвәлгечә үз эшләрендә калдылар.

Бетте.

ЗУР ГӨНАҺЛАР

(Гөнаһе кәбаир)

Роман

(1890)

I

Хикәябезгә Габделгафурның катнашы булганлыктан, аның кем һәм ниндирәк кеше икәнлеген язып үтик. Габделгафур Мансуров мулла-имам баласыдыр. Атасының исемен фаш итмичә, романыбызда аны Нәкәс[1] мулла дип кенә йөртербез. Нәкәс мулла угылы Габделгафурның төп ватаны Нижгород губернасы Сергач өязе авылларыннан бер авылдыр. Нәкәснең чын исемен язмаган кебек, әлеге авылның исемен дә, тулысынча язмыйча, фәкать «К» хәрефе белән генә атап йөртербез.

«К» авылы кешеләренең тормыш өчен асыл хезмәте игенчелек хисапланса да, күпчелеге башка шәһәрләргә — мәсәлән, Нижний, Казан, Мәскәү, Петербург һәм Ростов-Дон кебек җирләргә китеп, сәүдә һәм башка төрле хезмәтләр белән шөгыльләнә иде.

Югарыда әйтелгән авылда өч мәчет һәм дүрт имам бар иде. Башкаларында эшебез юк, Нәкәс мулла исә байтак заманнардан бирле «К» авылында имам булып, хәйләи шәргый[2] һәм хәрам кәсепләр, ришвәт һәм риба[3] юлы белән мал казанып, хәзерге вакытта авылның башка имамнары белән чагыштырганда шактый бай тормышта яшәгән, ике хатынга ир һәм биш балага ата булган бер кеше иде. Без бәян итәчәк унҗиде яшьлек Габделгафур аның өлкән баласыдыр, кискен бер угландыр.

* * *

Җомга көн. Җомга намазы вакыты җитеп килә. Нәкәс мулла мәхәлләсе кешеләре берәм-берәм мәчеткә җыелалар.

---

[1] *Нәкәс (накәс)* — кешелексез; тупас, саран.

[2] *Хәйләи шәргый* — шәригать, дин исеме астында төрлечә алдашу, хәйләләү.

[3] *Риба* — арттырып түләү (процент) шарты белән бурычка акча бирү.

Араларында гаять фәкыйрь кыяфәтле кешеләр дә күптер. Шуларның берсе — Габдеррәзак бабай. Ул, тәһарәтләнеп, аягына кияргә булмаганлыктан, яланаяктан гына мәчеткә барырга чыккан. Әмма юл бик пычрак-баткак, шуңа күрә ул, мәчет ишеге төбенә килеп җиткәч, комган хезмәтен үтәгән бер савыт белән су китереп, иң элек аягындагы пычрак-туфракны тазартып юды, шуннан соң гына мәчеткә керде.

Болай Хода юлында йөргән намуслы фәкыйрьләр булган шикелле, әлеге авылда мордар һәм намазсыз фәкыйрьләр дә аз түгел. Намазга, җомгага, тәравихка[1] барырга чакырсаң, алар сиңа:

— Алла кием һәм байлык бирсен, шуннан соң мәчетегезгә, намазыгызга да барырбыз,— дип җавап бирәләр җүнсезләр.

Азан әйтелде, кешеләр намазга тәмам әзер, тик Нәкәс мулла гына юк. Биш-ун минуттан, ниһаять, ул да килде. Килде дә, намазга керешеп, вәгазь-нәсыйхәт әйтү кайда, хотбә[2] урынына: «Әлхәмделиллаһ, әлхәмделиллаһ, әлхәмделиллаһе раббел-галәмин»[3],— дип, намазны тиз генә тәмамлап та куйды.

Намаздан чыккач, мәчет янында мулла белән ике кеше кул биреп күрештеләр. Болар «К» авылы кешеләреннән булып, әле генә Ростов-Доннан кайтканнар иде. Мулла бу акчалы кешеләрне шундук үз өенә чәйгә чакырды. (...)

II

Якшәмбе көн җитте. Бүген — Габделгафурның Казанга китәчәк көне. Ир-ат иртәнге намазны укып әле генә мәчеттән кайткан. Габделгафурны мәдрәсәгә озатырга дип, өйгә туган-кардәш һәм якын-белешләр җыелган. Озатырга килүчеләрнең берсе гаять кечелекле, тыйнак табигатьле, мөлаем һәм тәмле телле икенче мәхәллә имамы карт хәзрәттер. Карт хәзрәтнең Габделхак исемле угылы өч-дүрт елдан бирле Казанда

---

[1] *Тәравих* — уразада кич белән укыла торган намаз.

[2] *Хотбә* — вәгазь, нотык.

[3] Мәгънәсе: мактау-дан булсын Аллага... бар галәмнең хуҗасы, иясенә.

мәдрәсәдә булып, атасының сүзенә караганда, уңышлы рәвештә гыйлем эстәвен дәвам иттерә иде. Хәзер исә карт хәзрәт угылы Габделхакка чәй-шикәр һәм биш сум көмеш акча җибәрергә дип килгән. Габделгафурга кечкенә төен һәм биш сум акчаны биргәндә, ул:

— Менә, энем-карендәшем Габделгафур, бу әманәтләрне угылыма тапшыр һәм сәламнәребезне әйт,— диде.

Габделгафур, сузылган әманәтләрне кулына алып:

— Бик яхшы, тапшырырмын,— диде.

Берникадәр вакыт үткәч, карт хәзрәт, Габделгафурга карап, сүзен дәвам итте:

— Ярый, энем, сау-сәламәт бул, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә сәфәрегезне мөбарәк кылсын... Угылыма һәркайсыбыздан сәлам әйт, икегез яхшы дус булып яшәгез. Вакытыгызны әрәм итеп, гомерегезне бушка уздырмагыз, җилгә очырмагыз! Үзегездән кече оланнарга ихсан-ярдәм... Хәер, Казан мәдрәсәләре бөек вә олуг мәдрәсәләрдер. Анда сездән кечек кемсә, валлаһе әгъләм[1], табылмас та. Үзегездән олуг вә бөек оланларга һәрвакытта вә һәр урында әдәп һәм инсаф белән тәгъзыйм-хөрмәт күрсәтегез. Иншалла[2], үзегез дә олуг булырсыз. Казан мәдрәсәләре алар — зур мәдрәсәләр, анда һәр гыйлем булган кебек, шәкертләренең дә төрлесе буладыр... Начар-яман шәкертләр белән дуслык кылмагыз, мәҗлестәш булмагыз, шулвакыт аларның яманлыкларыннан сезгә, затыгызга зарар тимәс. Әмма шәкертләрнең шул мордарлары белән мәхәббәт вә дуслык итсәгез, гыйлем алу бер тарафта калып, яманлык вә бәдна- мыгыз[3] шундук мәйданга чыгар. «Адың чыкканчы, җаның чыксын!» — дип, картларыбызның әйткән сүзләре бик тә тугры. Бер вә ничә мең чакрымнарга сәяхәт вә сәфәр бер хәтъвә-адым белән башланган кебек, яманлык та бер кечкенә гөнаһ вә кечкенә яманлыктан башланып, аз-азлап арта барып, соңыннан

---

[1] *Валлаһе әгъләм* — Алла белә; Алла күбрәк белә («кем белә» мәгънәсенә якын гыйбарә).

[2] *Иншалла* — Алла теләсә; Алла кушса (гыйбарә).

[3] *Бәднам* — яманат.

«зур гөнаһлар»га әвереләдер. Менә гыйбрәт күзе белән кара әле син безнең авылның хәзердәге хәленә вә илле ел элек булган хәленә. Без ул вакытта сезнең кеби япь-яшь егет идек, ул вакытта, хәзердәге кебек, авылыбызда мәйханә-кабаклар юк иде. Түгел аракы эчәргә, чәйне дә ул вакытта бик аз кешеләр генә белә иде. Хәзер исә унбиш-егерме яшьлек угланнан башлап алтмыш-җитмеш яшенә якынлашкан картларыбызга кадәр, Аллаһ сакласын, аракы өчен җанын фида кылыр, туганын үтерер, атасын кыйнар... Хатыннарыбызның да аракы вә башка исерткеч эчемлекләрне сөйгәннәре юк түгел. Әмма бу «зур гөнаһлар» — яманлык вә бозыклыкларыбыз безнең өскә бердән килеп төшмәделәр. Ана карынынннан болай исерек вә сәрхуш булып тугмадык. Бер кечкенә нәрсәдән аз-азлап башланып, әйткәнем кеби, яманлыкларыбыз күбәеп вә куәтләнеп, бәрәкәт күтәрелде. Аллаһ сакласын, уттан вә хатыннан курыккан кеби, шул исерткечләрдән сакланыгыз вә куркыгыз! (...)

Карт хәзрәтнең Габделгафурга укыган бу нәсыйхәтләре тәмамланып килгәндә, җигүле ат та тәмам әзер иде инде.

Габделгафур, һәркем белән куллар биреп саубуллашып, эченнән: «Яңа тормыш һәм сәфәремә изге ярдәмеңне бир, Ходаем!» — дия-дия, мөәзин белән бергә арбага чыгып утырды да Казанга юл алды.

III

...Маһруйның атасы Гали Ваһабов даими Казан шәһәрендә яшәп, алыш-биреш сәүдәсе белән шактый күп мал-акча казанган алтмыш биш яшьләрендәге яхшы күңелле, тәкъва һәм юмарт бер кеше иде. Ул, гыйбадәт белән мәшгуль диндар адәм булып, галим-голяманы һәм инсафлы шәкерт халкын олылап хөрмәт итә, аларга һәрвакыт матди ярдәмен күрсәтә — кыскасы, Казан шәһәренең дәүләтле һәм могтәбәр картларыннан санала иде.

Гали Ваһабовның хатыны Мәрьям абыстай да, яхшы ата баласы булып, алтмыш яшьләренә җитеп килгән суфый һәм намазчыл бер хатын иде.

Гали бабай белән Мәрьям абыстайның югарыда телгә алынган Маһруйдан башка бүтән балалары юк иде.

Без, Маһруйның бишектәге һәм сабый бала чагындагы хәлләренә күз салмыйча, аның унсигез яшеннән соңгы тормышына тукталырбыз.

Исеме җисеменә муафикъ дигәндәй, Маһруй[1] шулкадәр зифа, чибәр кыз иде ки, аның матурлыгын каләм белән язып тасвирларга да мөмкин түгел. Шулай да, героинябызны мактау өчен, чын исеме Маһруй булмаса да, без аны шул исем белән атадык.

Хәмзә Агиев уртача дәүләтле, алтмыш яшенә җиткән яхшы карттыр. Хәмзә бабайның илле яшенә якынлашкан хатыны һәм Җиһангир исемле егерме биш яшьлек улы бар иде.

Җиһангир Агиев, хикәябезнең героинясы Маһруй кызның акылы һәм тәрбиясенә хәйран, гүзәллегенә гашыйк булып, ахырда аңа өйләнү уена килде. Аталар һәм кыз тарафыннан ризалык алынып, Җиһангирның теләк-морадына ирешкән һәм бәхетле булган көне нәкъ менә бүгенге кичәдер. Бүген яшьләрнең никах мәҗлесе булды.

IV

Җиһангир белән Маһруйның никах мәҗлесеннән соң бу көнгә кадәр өч ай вакыт узды.

Бүген сентябрьнең унбере, кич сәгать җиде. Хәмзә Агиев өендә кечкенә генә бер мәҗлес җыелган. Катнашучылар — «К» авылыннан мөәзин Госман, Нәкәс мулланың улы Габделгафур, өй хуҗалары Хәмзә бай белән Җиһангир әфәнде һәм казанлы Шәфигулла абзый.

Габделгафур белән мөәзин Госман хәзрәтләре әле бүген генә Казанга килеп төшкәннәр иде. Юл әйберләрен мөсафирханәдә калдырып, алар күрешер өчен шундук Хәмзә бай өенә юнәлделәр. (...)

---

[1]*Маһруй* — фарсыча «ай йөзле» дигәнне аңлата (*маһ* — ай, *руй* — йөз, чырай).

Хәмзә бай исә, түбәнчелекле, юмарт һәм кунакчыл кеше буларак, мөсафирләрне камил ихтирам белән, олылап каршылады.

Инде менә ашъяулык җәюле табын әйләнәсендә үзара сөйләшә-сөйләшә чәй эчеп утыралар.

Хәмзә бай, мөәзин әфәндегә таба карап, сорашуын дәвам итте:

— Бик яхшы иткәнсез, хәзрәт, егетне мәдрәсәгә алып килеп, бик яхшы иткәнсез. Мулла баласы дип әйтәсез, әткәсенең исеме ничек соң?

— Әйе, әткәсе безнең мәхәлләнең имамы, Нәкәс хәзрәт,— диде мөәзин.

— Кайсы мәдрәсәгә кертмәкче, кайсы мәдрәсәдә укытмакчы буласыз?

— Сез, Хәмзә абзый, ничек мәслихәт кыласыз? Кайсы мәдрәсәгә керсә яхшы булыр икән?

— Әткәсе нәрсә әйтте, кайсы мәдрәсәгә мәслихәт кылды? — дип, сорауга сорау белән җаваплады Хәмзә бай.

— Хәер, әткәсе катгый өзеп бер сүз дә әйтмәде... Безнең авылның карт хәзрәт угылы Габделхак монда укый, сезгә дә килеп йөри бугай, ул фәлән мәдрәсәдә,— дип, мөәзин карт хәзрәтнең улы Габделхакның кайсы мәдрәсәдә укыганын һәм ул мәдрәсә мөдәррисенең исемен атап әйтте.— Без дә менә бу егетне — Габделгафурны шул мәдрәсәгә куймакчы булабыз.

Хәмзә бай берникадәр вакыт үзалдына уйланып торды.

— Хәер, безнең Казанда һәр мәдрәсә яхшы,— диде ул. Анары сүзен дәвам итеп: — Һәркайсысында, мәдрәсәләрдә, күп төрле гыйлем укытыла. Ләкин мин үз тарафымнан бу шәкерткә дамелла Габделкәрим хәзрәт мәдрәсәсенә керергә мәслихәт кылыр идем. Аны Күл буе мәдрәсәсе дип йөртәләр. Ул мәдрәсә, без наданнарча әйткәндә, кадимнән биру[1] олуг мәдрәсә булып киләдер... Ничә вә ничә дана[2] вә галим мөдәррисләр шул мәдрәсәдән гыйлем алып чыкканнар.

---

[1]*Кадимнән биру* — борынгы заманнардан бирле.

[2]*Дана* — укымышлы, белгеч.

Бу мизгелгә кадәр әңгәмәгә колак салып, тын гына тыңлап утырган Шәрифулла абзый да, телгә килеп, мөәзиннән Габделгафур хакында сорашты. «Нindirәк кеше, баймы?» — дип, атасы турындагы соравына «юк» дигән җавапны ишеткәч, Казан байларына тел озайтып, гайбәтләренә төште:

— Гаять кешелексез байлар... Араларында яхшы гына бай, маллы кешеләр күп булса да, фәкыйрь шәкертләргә яки башка хосуста мохтаҗ булганнарга ярдәм вә изгелек кылганнары һич тә юк. Чиксез саран, комсыз, ач күзле, көнче үзләре, мәңгелек суы эчкән кемсәләр кеби кыланып, көн-төн дөнья малын арттыру кайгысында йөриләр, халык файдасы, дин куәте, дөнья рәхәте өчен гамь чигеп, зарарыбызның муҗибе-сәбәбе булган нәрсәләрне төзәтүгә ярдәм вә тырышлык кылганнары күренми. Араларында шундый комсызлары бар ки, түгел шәкерткә яки башка мохтаҗ кемсәгә ярдәм кылу, үзләре үк шул фәкыйрьләрнең кулыннан икмәкләрен тартып алырга тырышалар. Хәер, шәкертләр үзләре дә Мәкәрҗә вакытында...

Шәфигулла абзый байларга шулай тел озайтып утырганда, дивар сәгате унике тапкыр «күк-кү» дип кычкырды. Кунаклар, хәер-догалар кылып, Хәмзә байның өеннән чыгып киттеләр.

Хәмзә бай, мөсафирләрне озатып, ярты сәгать үткәч йокларга ятты. Җиһангир белән Маһруйның бүлмәләрендә исә төнге сәгать икегә кадәр ут сүнмәде.

* * *

Бу кичәдән соң өч көн узды.

Нәкәс мулла угылы Габделгафур, дамелла Габделгалләм мәдрәсәсенә кермичә, «К» авылындагы карт хәзрәт угылы Габделхак укый торган мәдрәсәгә урнашты.

V

Яздыгыбыз вакыйгалардан бу көнгә кадәр ике ел кичте.

Җиһангир Агиевның атасы Хәмзә бай һәм анасы Хәлимә абыстай, хаҗ кылу нияте белән сәфәр чыгып китеп, берсе —

Мәккәи Мөкәррәмәдә һәм берсе Мәдинәи Мөнәүвәрәдә[1] дөнья куеп, шул шәһәрләрдәге Җәннәте Мөгаллә һәм Җәннәте Бакыйга исемле зиратларга дәфен кылындылар.

Маһруйның атасы Гали Ваһабов та, безнең шикелле мәңгелек суын эчкәннәрдән булмыйча, бер авыруга очрап, ике атна чамасы хаста булып ятты да фани дөньядан мәңгелеккә китеп барды.

Хәзерге вакытта исәннәр — Маһруйның әнкәсе Мәрьям абыстай, Маһруй үзе, Маһруйның кызы Фәридә һәм Җиһангир — дүртесе бер өйдә яшәп яталар. Хәмзә байның үлеменнән соңгы еллар гаять авыр булып, сәүдә һәм кәсептә күп зарар күрү һәм күп мал югалту аркасында, Җиһангирның дәүләт һәм байлыгына зур кимчелек килде. Хәзер исә Җиһангир, Казанда булмыйча, коммерция — сату-алу хезмәтләре белән Себер тарафына алты-җиде айлык сәфәргә чыгып киткән иде.

VI

Ибраһим белән Ягъкуб, ике бертуган, мәрхүм Габделмән байның балалары Галиевләрдер. Ибраһимы — утыз биш яшендә, өйләнгән, ике бала атасы, олуг юрист, мәкерле һәм фетнәчел кеше. Ягъкубы исә егерме җиде яшьлек өйләнмәгән егет булып, азгын һәм тәүфикъсыз бер адәмдер.

Ике туган һәм школа учительләреннән Әхмерский исемле берәү Галиевләр өендә бергәләп чәй эчеп утыралар иде.

Ибраһим Галиев, кунак учитель Әхмерскийдан тормыш хәлләре һәм яңалыклар турында белешмәкче булып:

— Ни хәлләр, нинди хәбәрләр бар? Сәламәтлекме? — дип сорады.

— Аллага шөкер әле, сау һәм сәламәтбез... Прогресс һәм просвещениедән башка хәбәрләр юк.

Галиевләр Әхмерскийның «прогресс», «просвещение» сүзләрен бик өнәп бетермәделәр.

---

[1] *Мәккәи Мөкәррәмә, Мәдинәи Мөнәүвәрә* — Кадерле-газиз Мәккә, Нурлы-якты Мәдинә — бөтендөнья мөселманнарының хәзерге Согуд Гарәбстанындагы изге шәһәрләре.

— Без немецча, французча әйтелгән сүзләрнең күбесен аңламыйбыз, безгә тугры татарча сөйлә,— диде Ибраһим әфәнде, елмая төшеп.

Ягъкуб әфәнде исә, чәй касәләренең берсен — кунак алдына, ә икенчесен Ибраһим уңына куеп:

— Җә, ашка да, чәйгә дә кәрәм боерыңыз! — дип ашаргаэчәргә кыстый башлады.

Учитель Әхмерский бераз тын гына утырганның соңында:

— Хәбәр, хәзердәге хәбәрләр сезгә мәгълүм,— дип, имаммуллаларның русча укый-яза белүенә мәҗбүр итүче яңа тәртип турында сөйләп, патша хәзрәтләренең шул турыдагы фәрманын укырга кереште. (...)

Учитель Әхмерский падишаһ фәрманын укып тәмам итәр вакытта, ишек ачылып, бүлмәгә Галиевләрнең приказчигы килеп керде. «Әссәламегаләйкем»,— дип исәнләшкәннән соң ул, Ибраһим әфәндегә мөрәҗәгать итеп, сәүдә хәлләреннән хисап бирергә кереште:

— Алафузовка мең сигез йөз данә ат тиресе, дүрт йөз сиксән данә сыер тиресе бирдек,— диде ул һәм, ат тиресе фәләнчә хактан, сыер тиресе фәләнчә хактан дип, тиреләрнең нинди бәһагә сатылганлыгын әйтте.

Ибраһим Галиев, «тире» сүзен ишеткәч, бөтен игътибарын приказчигына юнәлтеп, падишаһ фәрманын бөтенләй онытты.

— Әйдә, кантурга керик, хәзер хисап-счетлар бирермен,— диде ул приказчикка һәм, табын яныннан торып, «кантуры» урнашкан күрше бүлмәгә таба атлады.

Ибраһим Галиев китүгә, аның алты-җиде яшьлек улы Мостафа, бүлмәгә кереп һәм Әхмерский белән Ягъкуб утырган табын янына килеп, Ягъкуб әфәндегә бер конверт-хат сузды.

Ул арада, тире алу-сату хисапларын тәмамлап, Ибраһим әфәнде дә контор бүлмәсеннән чыкты һәм табын янындагы әүвәлге урынына килеп утырганда, улы Мостафаны күреп:

— Нихәл, мелла Мостафа? Мәдрәсәдән кайттыңмы? Сабакны яхшы белдеңме? — дип, улына сораулар яудыра башлады. Аннары, Әхмерскийга таба борылып: — Угылым сабакны бик

яхшы укый, бик мелла[1] булды,— диде дә янәдән улына эндәште: — Җә, кил әле, менә абзаңа укып кара.

Әхмерский да, Мостафага карап, елмаеп:

— Җә, кил, нәрсә укыйсың? Китапларың кайда? Кил! — диде.

Мостафа, «Һәфтияк»[2] белән «Аллаһ дигел бәдәвам»[3] китапларын алып кереп, Әхмерский каршына килеп басты һәм, әгузе бисмилласын да әйтмичә, «Һәфтияк»тән сабагын укырга кереште.

— Бигрәк җегет икән угылың! — диде Әхмерский, Мостафаны этисенә мактап.

Мостафа бу мактау сүзләре сөйләнгән арада бер юллык сабагын укып тәмам итте.

Шуннан соң этисе аңа:

— Җә, китабыңны да укып кара,— диде.

Мостафа, «Бәдәвам» китабын кулына алып, әсәрнең баш өлешеннән — утыз тугызынчы юлыннан башлап укырга кереште:

Имансызны дуст тотма,
Аңа син яхшылык итмә,
Андыйн һәм яхшылык көтмә,
Аллаһ дигел бәдәвам.

Шул рәвешчә сабакны укып һәм үзләштереп, мактау сүзләре дә ишеткәч, Мостафа, сабак китапларын махсус урынга җыеп куеп, табын янына утырып чәй эчәргә башлады.

---

[1] Бу урында «мелла» сүзе «белемле кеше», «гыйлем иясе» мәгънәсендә.

[2] *«Һәфтияк»* — Коръәннең кыскарак сүрәләрен, аятьләрен эченә алган җыентык. Исеме фарсыча «җидедән бере» дигән мәгънәне аңлата. Элекке мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек буларак та кулланылган.

[3] *«Аллаһ дигел бәдәвам»* — «Бәдәвам китабы» — татарлар арасында киң таралган дини-әхлакый эчтәлекле, көйле, тезмә әсәр. Дүрт юллы һәр строфасы «Аллаһ дигел бәдәвам» («Берөзлексез Аллаһ дип кабатла») сүзләре белән тәмамлана.

Ягъкуб әфәнде исә, Мостафа китергән хатны укыгач, тиз генә җыенып өйдән чыгып китте.

VII

Ягъкуб Галиев, хатны укып, мәҗлесне калдырып, өйдән ашыгып чыгып киткәннән соң, ун-унбиш минут эчендә Воскресенский дигән урамга барып җитте.

Воскресенский урамы Казанның иң зур, иң яхшы урамнарыннан булып, казанлылар анда кышын да, җәен дә саф һава суларга һәм тамаша кылырга чыга иде.

Воскресенский урамыннан бер-ике әйләнгәч, Ягъкуб әфәнде Пассажга[1] керде. Пассажда бер яшь хатын янына туры барып, аның белән саулык-сәламәтлек сорашырлык кадәр генә сүз алышты да, Пассажның Черек күл[2] бакчасы тарафына караган ишегеннән чыгып, беренче туры килгән ямщикны туктатты һәм, Пассажда очрашкан теге хатын белән шул ямшикның атына утырып, Балык базарындагы[3] мәгълүм кунакханәләрнең берсенә илтергә кушты.

Ягъкуб белән бергә кунакханәгә китеп барган бу ханым Җиһангир Агиевның хатыны героинябыз Маһруй иде. (...)

«Яшь гомерне бушка уздырырга ярамый» дигән сылтау белән, бер карчык, бу ике яшь арасында тылмачлык һәм арадашлык итеп, аларның яшь гомерләрен әнә шулай «рәхәттә» һәм «кирәкле эштә» уздырттыра башлады. («Яшь гомерне бушка уздырырга ярамый» диюче мондый карчыклар һәм шул кагыйдәне тотучы хатыннар Казанда аз түгелдер.)

---

[1] *Пассаж* — Казанның элеккеге Воскресенский (хәзерге Кремль) урамында 1880—1883 елларда төзелгән зур йорт. Анда кибетләр, кунакханә, концерт залы (соңрак кинотеатр) һ. б. урнашкан булган.

[2] *Черек күл* — Казанның Кремль урамына параллель (Кремль калкулыгының көнчыгыш итәгендә) урнашкан уйсулыктагы бакча-парк. Казан ханлыгы чорында бу урында чишмәләр агып, бер-берсенә ермаклар аша тоташкан күлләр тезмәсе булган.

[3] *Балык базары* — Казанның үзәгендә (Тукай мәйданында) урнашкан бу базарда элек ит, балык, яшелчә ише төрле ашамлыклар белән сату иткәннәр, кунакханәләр булган.

Бүген октябрьнең егерме җидесе. Җиһангирның Казаннан китүенә нәкъ сигез ай, ә Маһруй белән Ягъкубның беренче күрешүләренә җиде ай тулган көн. Маһруй бу җиде айның беренче аенда ук йөккә узды. Маһруйның үзеннән һәм сәбәпчесе Ягъкубтан кала, бу нашәргый хәмел[1] хакында беркем дә белми иде.

Ягъкуб әфәнде, кунакханә номерына кереп, ишек ябылуга ук Маһруйны битәрләргә тотынды:

— Мин сиңа ничә тапкыр әйттем, миңа хат язма дип... Мин юк вакытта хатыңны китереп бирерләр дә, икенче кеше кулына төшеп, Алла сакласын, бу хәлләребездән хәбәрдар булырлар... Җә, әйдә сөйлә, шулкадәр ашыгыч нинди йомыш бар? Нигә хат белән чакырттың?

Маһруй, Ягъкуб әфәндегә елмаеп карап, янына сыеныбрак утырды да, кулын аның җилкәсенә куеп:

— Бик шатлыклы хәбәр бар, шул сәбәптән хат язып чакырдым... Җук нәрсәләргә ачуланып маташма,— диде.

— Җә, сөйлә тизрәк, нинди хәбәр ул?.. Озак утырырга вакытым юк.

Маһруй, бер минут чамасы дәшми торганнан соң, кесәсеннән бер конверт чыгарды да Ягъкуб әфәндегә сузды:

— Менә бу хатны укы... Нинди шатлыклы хәбәр икәнен белерсең.

Ягъкуб, хатны кулына алып:

— Нинди хат соң бу? — дип сорады.

— Бүген генә почтадан алдым, ирем-хуҗам җибәргән,— диде Маһруй.

Ягъкуб әфәнде хатны акрын гына кычкырып укый башлады. (...)

Ягъкуб хатны укып тәмам иткәч, Маһруй, янәдән әүвәлге кебек елмаеп:

— Менә шатлыклы хәбәр ич! — дип куйды.— Ике ай эчендә кайтырмын дип язса да, өч айсыз да кайта алмый ул... Мине

[1] *Нашәргый хәмел* — никахсыз (уйнаштан) балага узу.

хәсрәттә калдырмас өчен, күңелемне юатыр өчен генә шулай ике айдан кайтырмын дип яза. Чынында, өч айсыз да кайта алмаячак. Ул миңа Себер җагына киткән чакта да өч-дүрт айдан кайтып җитәрмен дип әйткән иде. Менә инде Казаннан киткәненә сигез ай булды, әле һаман кайтканы юк. Җә, бик яхшы, ике-өч ай кайтмаса, бала табар вакытым җитеп, бала тапканнан соң кайтып килсә, бер нәрсәдән дә хәбәре булмый калыр.

Шулвакыт кунакханә хадиме соралган нәрсәләрне поднос белән күтәреп кереп, өстәл өстенә куйды. Хадим чыгып киткәч, Ягъкуб Галиев:

— Әйе, дөрес, шатлыклы хәбәр икән,— диде һәм сүзен болай дип дәвам итте: — Әлбәттә, Җиһангирның безнең бу хәлләребездән хәбәрсез калуы синең өчен дә, минем өчен дә файдалы, бигрәк тә синең өчен... Йөкле булмасаң, бүген кайтса да бернәрсә дә белә алмас иде. Алла сакласын, белә калса, хәлең бик мөшкел булыр. Йөгең кемнән икәнлеге беленсә, миңа да яхшы булмас. Ничек кенә булса да, кешегә белгертмичә, йөгеңнән котылу юлын тап, һичкем шикләнерлек булмасын. Минем дә бу кичә синең белән аулакта ахыргы күрешүем булсын... Хатлар язып мәшәкатьләнмә, чөнки ике-өч көннән мин үзем дә йомышларым белән Мәскәүгә китәмен. Бер йә ике айсыз Казанга кайта алмам. Мин кайтканчы, бәлкем, ирең дә кайтып төшәр. Әгәр дә бу эшләребезне беркем дә белми калса, соңыннан, җае туры килгән чакларда очраша торырбыз. Инде дә, йөгеңнән котылганчыга кадәр, күрешергә вакыт булмас, бу кичәбез ахыргы кичәдер.

Маһруй Ягъкубтан мондый салкын сүзләр ишетергә уйламаган иде. Гаять дәрәҗәдә гаҗәпләнгән һәм көенечле бер хәлдә, ул җиде-сигез ай буе «бушка узмаган» гомеренең нәтиҗәсе һәм җимеше юк нәрсә түгел икәнлеген төшенә башлады.

VIII

Бала туар көннәр якынлашкач, Маһруй үзенең әнкәсенә: «Мин бер-ике атнага авылга кунакка барып кайтам»,— дип, өй чыгымнары өчен биш-ун сум акча бирде дә әнкәсен һәм кызын

калдырып китеп барды. Кунак булып төшәрдәй туган-тумачалары берничә авылда булуына карамастан, Маһруй, авылга китмичә, Пеләтәндә (Казанның бер төбәге) бер карчыкның өенә урнашып, бала туар көнне көтә башлады. (Яшерен рәвештә бала табучы хатыннарга урын биргән һәм соңыннан балаларын тәрбия кылырга алынган мондый карчыклар Казанда юк түгелдер.)

Ниһаять, бала табу көне җитеп, әлеге карчыкның ярдәме белән, Маһруй бер ир бала дөньяга китерде.

Бала тапканнан соң берникадәр вакыт үткәч, әлеге карчык Маһруйга болай диде:

— Җә инде, кызым, әлхәмделиллаһ, сәламәтләнеп киләсең... Балаңны-угылыңны ни кылырга, кая куярга уйлыйсың? Әгәр дә теләсәң, мин балаңны воспитательни йортка тапшыра алам яки башка җиргә дә ташларга мөмкин. Хәер, воспитательнига минем беркемнең дә баласын илткәнем юк... Алла сакласын, анда кем баласы булсын — чукындыралар.

Маһруй, бераз дәшми торганнан соң, карчыкка:

— Башка җиргә дә ташларга мөмкин дип әйтәсең. Кая башка җиргә ташларбыз икән? — диде.— Йа Алла, әстәгъфирулла! Нишләрбез икән? Зәүҗем[1] кайтмадымы икән? Син, абыстай, зинһар, кемгә дә сиздерми генә бүген белеп килсәнә, ирем кайтмадымы икән? Ух!..

— Яхшы, бәбкәм, яхшы, кызым, белеп кайтырмын... Менә узган елда да бер кыз минем өемдә бала тапкан иде. Аның баласын мунчага алып бардым да, мунчага кергәч, җуынгаччабынгач, бала бик еглый башлаган иде, мунча эчендәге бер карчыкка: «Абыстай, зинһар, шул баланы кулыңда тотып торсана, мин әнкәсен чакырып китерим әле»,— дип, баланы карчыкта калдырып, тиз-тиз киемнәремне кидем дә мунчадан чыгып киттем. Әле дә, бүгенгә кадәр, баланың әнкәсен чакырып китерәм... Синең балаң белән дә шулай эшләрбез. Бу — бик саваплы эш. Мин күп кешеләргә — хатыннарга шулай ярдәм итәмен.

[1] *Зәүҗем* — ирем.

— Мин, абыстай, үзем дә шулай: кемнең дә булса ишеге төбенә баланы ташлап китәрмен дип уйлый идем. Ләкин хәзердә кеше ишеге төбенә ташлап китүдән дә бик куркам. Яхшы, әгәр дә баланы кабул итеп, үз балалары шикелле итеп тәрбия кылсалар. Әмма, кабул итмичә, әлеге, син әйткән воспитательни йортка юлласалар, Алла сакласын, харап булыр. Гөнаһы да бик зур ич... Менә, абыстай, мин баланы болай итәргә теләр идем,— дип, Маһруй сүзендә дәвам итте: — Әгәр дә син кабул итсәң, мин баланы синең өеңдә калдырыр идем... Син яхшы гына тәрбия кылыр идең. Мин үзем дә форсат булган вакытларда килеп карар идем; ни дисәң дә үз күз алдымда булыр иде. Алла сәламәтлек биреп, ике йә өч яшенә кадәр синең өеңдә торса, аннан соң, Хода ризалыгы өчен бер ятим баланы алган кебек, бу баламны мин үз өемә дә ала белер идем. Менә, әгәр дә син разый булсаң, шулай кылсак яхшы булыр иде. Ни әйтәсең, абыстай, разый буласыңмы?

— Шулай син әйткәнчә кыла алсак, кызым, бик, бик яхшы булыр иде, кызым,— диде карчык һәм сүзен болай дип дәвам итте: — Мин бик разый буламын. Балаң минем өемдә калсын, үзем тәрбия кылырмын... Балаңны кайчан алу ягын үзең карарсың, сәламәт булса, теләгән вакытта алырсың. Ләкин бу эш бик авыр хезмәттер. Миңа хезмәт хакы күпме, никадәр бирерсең икән соң?.. Менә өемә килеп бала таптың, бирәү дә белмәде, шулай ук бу көннән соң да, иншалла, бирәү дә белмәс. Балаң да үз кулыңдагы кебек тәрбияләнер, һәрвакыт килә-китә, күрә торырсың. Синең хуҗаң малдар[1] кеше, сездән күп сорарга да мөмкин, ләкин мин бу эшләрне савап өчен эшлим. Сиңа да бер ярдәмем булсын, бәбкәм.

— Мин, абыстай, иншалла, сине разый кылырмын, ләкин хәзердә кулымда бер дә акчам юк, актык егерме биш сумны да сиңа бирдем. Хәзергә һичбер кайдан акча алыр җирем юк. Хуҗам кайтканчы сабыр ит, никадәр кирәк булса да яшерми әйт; ирем кайткач, иншалла тапшырырмын,— дип, Маһруй

---

[1] *Малдар* — бай, маллы, дәүләтле (кеше).

сүзен тәмам иткәч, баланы тәрбиягә алырга ризалыгын биргән карчыгыбыз әйтә куйды:

— Син, бәбкәм, әлбәттә, минем хакымны үтәрсең, хыянәт кылмассың, ләкин иреңнең акчасын мондый җирләргә сарыф итү сиңа бер дә лаек түгел... Гөнаһы булыр, бәбкәм. Бу баланың үз атасы да бардыр ич, баланы тәрбия кылырга акчаны син, әнәтерә, баланың үз атасыннан сорап ал, аннары миңа бирерсең. Бу — бик мәшәкатьле хезмәт... Әгәр дә миңа ике йөз сум көмеш акча бирсәгез, икегез дә, өчегез дә бөтен-бөтенәйгә котылырсыз.

Маһруй, бераз уйланып торгач, карчыкка:

— Белмим шул... Баланың атасын, инде бер-ике ай булыр, күргәнем дә юк. Акча бирерме икән?! — диде.

— Акча бирми чарасы булмас. Атасы кем, бай кешеме?

— Баланың атасы — болай яхшы гына дәүләтле кеше, ләкин арабызга бераз салкынлык төшкән иде. Күптән күргәнем дә юк, белмим, хәзердә Казандамы икән. Аны нинди юл белән күрсәм яхшырак булыр икән?

— Җә, кызым, миннән бер дә яшереп торма, кем бу баланың атасы? Әйдә сөйлә. Казанда барлыгын-юклыгын да үзем белермен, икегезне күрештерергә дә тырышырмын.

— Белә дә торгансың, абыстай, Ягъкуб Галиевне, менә шул җегет инде баланың атасы була.

— Җә, Ягъкуб Галиевне бик яхшы беләмен. Узган җылда бер кыз минем өемдә бала тапкан иде дип әйттем ич. Ул кыз да шул йөзе кара Ягъкубтан йөккә узган иде. Ул Ягъкуб Галиев — бик мордар кеше. Теге кызны да бик җәберләгән иде. Ягъкуб хәзер дә Казанда, төнәгенәк Печән базарында[1] күрдем,— дип,

---

[1] *Печән базары* — Казанның Иске татар бистәсендә (Болакның көньягында), хәзерге Париж Коммунасы һәм Галиәсгар Камал урамнары арасындагы мәйданны биләп торган базар. Эреле-ваклы кибетләр, сәүдә фирмалары тезелеп киткән бу урын шәһәрдә татарлар сәүдә итә торган төп урын булган. Шушы тирәдә соңрак татар газета-журнал редакцияләре, матбагалар, «Болгар», «Амур», «Сарай» кебек кунакханәләр калкып чыга. Печән базары 1930 елларга кадәр яшәп килде.

карчык тагын сүзендә дәвам итте:— Менә нәрсә эшләрбез. Син Ягъкубка, сине күрергә йомышым бар, дип, хат яз. Мин ул хатны үз кулым берлән илтеп бирермен. Күрешергә нинди урын билгеләсә, бүген кич шунда очрашырсыз... Акча бирми чарасы булмас,— дип, карчык, утырган җиреннән торып, Маһруйга каләм-кәгазь китереп бирде. (...)

IX

Әби-анай, акушерка карчык, Маһруйның хатын Ягъкуб Галиевкә тапшырды. Ягъкуб, шатлыктан бигрәк ризасызлык күрсәтебрәк, Маһруй белән күрешергә вакыт һәм урын билгеләде.

Билгеләнгән кич һәм сәгать якынлашты. Караңгылык төшеп, гашыйкларга юл ачылу белән, Маһруй очрашу урыны билгеләнгән җиргә ашыкты.

* * *

Ягъкуб Галиевнең мәетен арбага салып Ибраһим Галиевнең өенә алып киткән вакытта романыбызның героинясы, кулга алынып, полициягә озатылган иде.

X

Үтерү җинаятеннән соң Маһруйны полициягә китереп, «секретный» бүлмәгә ябып куйдылар. Бүтән гади «секретный»лар кебек үк, кечкенә генә бер бүлмә иде бу. Тимер рәшәткәле кечкенә тәрәзәсеннән яктылык аз кергән кебек, анда сулар өчен саф һава да юк иде. Маһруйның, ике газиз баласыннан, әнкәсе һәм иреннән, дәүләте һәм рәхәт тормышыннан, туган-кардәшләре һәм дусларыннан аерылып, үтерүче сыйфатында кабер шикелле тар, караңгы бүлмәгә ябылуы әйтеп бетергесез авыр вакыйгага булып, Аллаһе Тәгалә аңа сабырлык һәм түземлек бирсен диюдән гайре сүзебез юктыр.

Ярты төн үтеп, полиция янәшәсендәге чиркәүдә тиз-тиз чаң кага башлауга күзеннән йокысы качкан Маһруй шәһәрнең кай төшендәдер янгын чыкканын абайлады. Бераздан полиция

ихатасында да янгын атларын тиз-тиз җигеп, кешеләрнең ашыгып янгын сүндерергә китүләре ишетелде.

Маһруйны шундук шомлы фикерләр биләп алды. «Әстәгъфирулла, янгын чыккан бугай! Кайда яна икән? Бәлкем, безнең йортыбыз яна торгандыр? Бәлкем, әнкәем, балам шул янгын эчендә яна торганнардыр?» — дип, ул, чынлап та баласы яна торган кеше кебек, тәмам куркуга төште; янгынның ялкыннары һәм шул ялкыннар эчендә калган әнкәсе һәм баласының «Әнкәй!», «Кызым!», «Тизрәк, ярдәм ит!» дип ачыргаланып кычкырган тавышлары колагына ишетелә һәм ут капкан гәүдәләре күзенә күренә шикелле булды. (...)

XII

Ягъкубның абыйсы Ибраһим Галиевнең мәкерле һәм фетнәчел кеше икәнлеген язган идем. Энесе Ягъкубның үтерелүен ишеткәч, ул бу җинаятьне кем һәм ни өчен эшләвен, Ягъкубтан туган баланың бер карчык тәрбиясендә булуын һәм ул карчыкның торган җирен сорашып белеште дә икенче көнне үк, кояш баер алдыннан, шул карчыкны эзләп китте.

Ибраһим Галиев, үзе эзләгән йорт янына килеп җитеп, капкадан чыгып килүче бер хатынга очрады да аңа: «Абыстай, фәлән карчык кайсы өйдә тора?»— дип, акушерка карчыкның исемен әйтте.

— Ул карчык нигә кирәк, Ибраһим абзый? — диде хатын һәм бераздан: — Мин буламын ул карчык. Әйдә, рәхим ит, Ибраһим абзый,— дип, олуг юристны өенә алып керде. (...)

— Мин, абыстай, сиңа зур йомыш белән килдем,— диде Ибраһим әфәнде, карчыкның өенә кергәч.— Монда өйдә бүтән кеше юкмы?

Карчык, Ибраһимның сүзләреннән шөбһәгә калып, куркакурка гына ишекне япты да:

— Җук, җук, Ибраһим абзый, беркемсә җук, әйдә сөйләгез. Тыңлыйм, ни җомышыгыз бар? — дип, Ибраһим әфәнде янәшәсенә урындыкка утырды.

Ибраһим әфәнде, бераз тын гына утыргач, карчыкка карап сүзгә кереште:

— Менә, абыстай, йомышым үзегезгә дә мәгълүм... Озаклап сөйләшергә вакытым юк. Шул энем Ягъкубның баласы хакында килдем...

— Баланы ни кылмакчы буласыз? — диде карчык, Ибраһим әфәндене сүзеннән бүлеп.

— Әйе, Ягъкубның Маһруйдан туган баласы хакында килдем,— дип кабатлады Ибраһим әфәнде.— Аны ир бала дип әйткәннәр иде. Ул баланы Маһруй синең өеңдә тудырган икән. Кичә Ягъкуб белән Маһруй күрешеп сөйләшкәннәр. Баланы тәрбияләр өчен Маһруй Ягъкубтан ике йөз сум көмеш акча сораган. Шул хакта килдем. Бала Ягъкубныкы булгач, әлбәттә, тәрбиясе дә Ягъкуб өстендәдер. Ләкин, абыстай, син бу хәлне беркемгә дә сөйләмә, кешегә ишетелсә, үзең беләсең, яхшы түгел.

— Бик яхшы, Ибраһим абзый, баланы мин үзем тәрбиягә алам... Минем өемдә туды — кемсә белмәде, моннан соң да беркем белмәс. Үз баламны тәрбия кылган кебек тәрбия кылырмын. Бик саваплы эш ич, Ибраһим абзый... Тик минем хакымны бирерсез,— диде карчык һәм, кулына шәм алып: — Әйдәгез, баланы да күрсәтим,— дип, Ибраһим әфәндене икенче бүлмәгә — бала янына алып кереп китте.

Өч-дүрт минуттан алар, бала яткан бүлмәдән чыгып, яңадан әүвәлге урыннарына килеп утырдылар.

— Менә, абыстай, баланы тәрбия өчен ике йөз сум көмеш акчаны ал,— дип, Ибраһим кесәсеннән мөбарәк акчаларын чыгарды.— Ләкин, абыстай, баланың тәрбиясе өчен шушы акчаны миннән алганлыгыңа бер язу бир. Чөнки Маһруй хәзер үз өенә кайтты, синең өйгә бүтән килеп йөрмәячәк... Ул, акчаны абыстайга бирсәгез, кулыннан язу алыгыз, дип әйтте. Безнең сүзебезгә генә ышанмас, баланың тәрбиясе өчен акчаны алдым дип язу язсаң, ул язуны укыгач, эшнең уңай хәл ителүен белеп, Маһруй үзе дә сөенер... Язу яза белә торгансыңдыр бит? — дип, сүзен тәмамлады Ибраһим әфәнде.

— Җә, Ибраһим абзый, ни сөйлисең, язу яза белмәскә буламыни? Яшь вакытымда балаларга сабак укыттым. Шәкертләремә гарәп, фарсы китаплары да укыта идем. Маһруйны да укырга-язарга мин өйрәттем. Маһруй — минем шәкертем ич! Балалар укыту бик саваплы эш ич! — дип, акушерка карчык, утырган җиреннән торып, каләм-кәгазь алып килде дә: — Нәрсә языйм? — дип, Ибраһим әфәнденең боерык сыман әйткән сүзләрен язарга кереште.

Язу язылып беткәч, Ибраһим Галиев аны арыслан гайрәте белән сузылып алып кесәсенә яшерде. Шул арада карчык та, бая Ибраһим бай өстәл өстенә кесәсеннән чыгарып куйган акчаларга күзләрен майландырып карап һәм: «Ибраһим абзый, бик саваплы эш ич!» — дип кабатлый-кабатлый, акчаларны ашыгып үз кесәсенә күчерде.

Акча һәм язу шул рәвешчә кесәләргә кереп урнашкач, олуг юрист Ибраһим Галиев болай дип сүз башлады:

— Минем бу эштә беркадәр шөбһәм бар иде. Ләкин Маһруйның сүзләре хак икән... Кардәшем Ягъкубны, бер мәслихәттә булып, икәү бергә үтергәнсез икән!

Карчык, Ибраһимның сүзләрен аңлап бетермичә, гаҗәпләнеп:

— Ни сөйлисең, Ибраһим абзый, нинди үтерү?! — дип сорады.

— Нинди үтерүме?.. Бер дә белмәгән сыман кыланасың... Кичә Маһруй Ягъкубны үтергән. Хәзер Маһруй ябылуда, хөкем тикшерүе астында,— диде Ибраһим.

Шуннан соң ул, тәфсилле һәм тагы да шомлырак итеп, Маһруйның ничек Ягъкубны үтерүен һәм бу җинаятьне тәфтиш[1] вакытында аның тикшерүчегә сөйләгән сүзләрен, «Ягъкубның баласы кайда?» дигән сорауга фәлән җирдә, фәлән карчыкта дип җавап бирүен, Ягъкуб Галиевкә хат язарга киңәш итеп, карчыкның шул хатны Ягъкубка илтеп бирүен һәм, бала тәрбиясенә акча бирмәсә, шулай ит, болай ит дип, Маһруйны котыртуын — һәммәсен сөйләп бирде.

[1] *Тәфтиш* — тикшерү, ачыклау.

Ибраһим Галиевнең сүзләреннән акушерка карчыкның күзләре, чынаяктай зураеп, дүрт булды.

— Савап эш дип кылган эшләреңнең нәрсә икәнен Себергә катр киткәч белерсең,— дип куркытуын дәвам иттерде олуг юрист.

Шул вакытны ишек шакыган тавыш ишетелде. Карчык утырган урыныннан торды да, өйалдына ашыгып чыгып:

— Кем бар, нәрсә кирәк? — дип, ишекне ачты. Ишектән бераз сәрхуш кыяфәтле мөселман бутышнигы — городовой керде. Керде дә:

— Исәнме, сәламәтме, абыстай? Көчкә эзләп таптым,— диде.

— Нихәл, угылым, ни йомыш бар?

— Ни булсын, абыстай,— диде бутышник, исерекләрчә елмаеп.— Ни хәл булсын, беләсең ич, без яхшы йомыш, яхшы хәбәр белән килмибез... Следовательдән җәлебнамә-повестка китердем... Менә карт көнеңдә үзеңне... Менә бу кәгазьне укып, нинди хәл икәнен белерсең,— дип, һаман елмайган килеш, карчыкның кулына язулы бер кәгазь тоттырды.— Абыстай, бер ун капик акча бирсәң, ямщиккә утырып кайтыр идем...

Карчык бер кулы белән кәгазьне алып, икенче кулы белән кесәсеннән раст килгән акчаны чыгарып, солдатның учына төртте. (...)

— Җә, Ибраһим абзый, зинһар... зинһар, карт көнемдә юк нәрсәләр белән хәүфләндермә. Ни кылыйм, слидуателгә ничек җавап бирергә мәслихәт кыласың?.. Әгәр дә мөмкин булса, зинһар, карт көнемдә бу нахак бәладән коткар. Әстәгъфирулла! Ходаем, үзең кичер! — дип, карчык яңадан еларга башлады.

— Дөньяда мөмкин булмаган нәрсә юк. Сива-л-ваҗиби вәлмөмтәнигый — һәр нәрсә мөмкин. Елама, менә минем әйтәчәк сүзләремне тыңлап, минем мәслихәтемчә эшләсәң котылырсың,— дип, олуг юрист сүзен болай дәвам итте:—Синең бу фетнәдән котылу юлың шул: следователь каршына баргач, ул синнән: «Маһруй синең өеңдә бала тудырдымы? Баланың кемнән булуын беләсеңме? Ягъкубка хат язарга котырттыңмы?» — дип сораса, син, бу вакыйгадан һич хәбәрең булмаган кеше

кебек: «Маһруйның йөккә узуын һәм кемнән йөккә узуын һич тә белмимен, минем өемдә аның бала тудырганы юк. Ягъкуб Галиевкә хат язарга Маһруйны котырту түгел, Ягъкуб белән Маһруйның араларында булган хәлләрне бөтенләй белмим»,— дип җавап бирсәң һәм Маһруйның әйткән сүзләрен дә, кичергән хәлләрен дә — барсын да инкяр итсәң, Маһруйның бар сөйләгәннәре низам-закон каршында расланмыйча һәм кабул ителмичә, синең котылып калачагың шөбһәсез. Ләкин һәммәсен мин мәслихәт иткәнчә сөйлә; Маһруй ни әйтсә дә, юк, юк, дип, ялганга чыгар.

— Бик яхшы, Алла разый булсын,— диде карчык, олуг юристның сүзе белән килешкәндәй итеп. Аннары: — Әгәр дә Маһруй үз сүзләренең хаклыгын шушы, миндә булган бала белән исбатласа? Яки шушы баланы минем өемнән эзләп тапсалар нишләрмен, ни әйтермен? — диде.

— Менә, менә, минем сүзләрем-мәслихәтем беткәне юк әле,— диде Ибраһим Галиев һәм мәслихәтнең төп максатын ачып салды: — Син ул баланы ничек булса да бу кичтә тәмам кыл!.. (...)

* * *

Һәм, чыннан да, фетнәчел Ибраһим әйткәнчә, әлеге мордар карчыкка баланы «тәмам» итү өчен авыр мәшәкать кирәк булмады. Галиев чыгып киткәннән соң ике сәгать чамасы вакыт үтеп, кич тәмам караңгылангач, карчык сабый баланы алып өеннән чыкты да туры Кабан күленә таба юнәлде. Ике данә кирпечне һәм баланы бер капчыкка салып, Кабан күлендә беренче туры килгән бәкегә капчыкны әкрен генә төшереп җибәрде — шул рәвешчә баланы «бөтен-бөтенәйгә тәмам» кылды.

Маһруйдан туган баланың Ягъкуб Галиев баласы икәнлеге исбат ителеп, шәригать алдында Ягъкубның мал-мөлкәтенә варис була күрмәсен һәм Галиевләрнең яманаты чыкмасын дип, Ибраһим Галиев, карчык-акушерканы алдалап һәм аны җинаятькә гайрәтләндереп, әнә шулай сабый баланың гомерен өздерде.

XIII

Акушерка карчык, хөкем йортыннан җибәрелгән җәлебнамә-повестканы алып, чакырылган көн, билгеләнгән сәгатькә суд тикшерүчесе каршына килгән шикелле, Мәһруй да бу вакытта «секретный»дан тикшерүче мәхкәмәсенә китерелгән иде.

Карчыкка гадәттәге сорауларны биреп, нинди мәсьәлә буенча хөкем йортына чакырылганлыгын әйткәннән соң, тикшерүче:

— Мәһруй синең өеңдә бала тудырдымы? Бала хәзер синең өйдәме? Баланың Ягъкубтан булганын төгәл беләсеңме? Мәһруйны Ягъкуб Галиевкә хат язарга күндереп, хатны Ягъкуб Галиевкә син илтеп бирдеңме?.. Кыскасы, бу эш хакында нәрсә беләсең, берсен дә яшермичә сөйләп бир! — диде.

Тикшерүченең бу сорауларына җавап бирергә дип, карчык авызын ачкан гына иде, Мәһруй күз яшенә чыланган йөз, ялварулы тавыш белән карчыкка эндәшеп:

— Алла хакына... ярдәм кыл... Кара, нинди хәлгә төштем? Ярдәм кыл, коткар мине. Синнән башка беркем дә минем хәлемнән хәбәрдар түгел, бер Алла белә дә, икенчесе — син,— диде дә, аяк өсте басып торырга хәле калмыйча, урындыкка чүкте һәм үксеп еларга кереште.

Мордар карчык, бу вакыйгадан бер дә хәбәре юк сыман, гаҗәпләнгән булып:

— Йа Алла, әстәгъфирулла! — дип чәчрәп чыкты.— Мин бу эшләрне һич тә белмимен... Минем өемдә беркем дә бала тудырганы җук. Ягъкуб Галиевне дә, бу хатынны да, араларында булган хәлләрне дә — берсен дә белмим. Ягъкубның үтерелүен яңа ишетәм, бу хатынны да беренче күрүем, ул нинди хатын — һич хәбәрем җук.

Карчыкның бу җавапларын ишеткәч, Мәһруй:

— Йа Рабби! Минем балам шушы карчыкта! — диде һәм үз сүзләренең хаклыгын Ягъкубтан булган баласы белән исбатларга теләп:— Карчык өендә тентү ясалсын! — дигән үтенечен әйтте.

— Теләсәгез биш кат тентү ясагыз, минем өемнән бернәрсә дә таба алмассыз. Мин андый карчык түгел, мин һәрвакыт тугрылык җулында, һичбер вакыт җалган сүз сөйләмим. Әгәр минем өемдә бала тудырган булсаң, мин аны бер дә яшермичә хөкем каршында әйтер идем. Әйе, яшерен рәвештә бала тудырырга теләүче хатыннарга ярдәм итәмен, ләкин синең нинди хатын икәнеңне дә белмим.

Карчыкның бу сүзләреннән соң Маһруй ни кылсын, баласы барлыгын ничек исбат итсен? Һәм, баланың Ягъкубтан булуы исбат ителсә дә, аның, Маһруйның, җинаяте гафу кылынырмы?

Шул сораулардан башы әйләнгән Маһруй, шашкан кеше кебек:

— И Алла! Кайда мин? Балам, балаларым, анам, кайда сез?! Сез кемнәрсез?! Минем белән ни кыласыз?! Ни өчен баламны бирмисез?! Ни өчен дөресен сөйләмисез?! Йа Рабби! Юкса әллә өнем түгел, төшемме бу?! Йа Аллаһ! Йа Аллаһ!..— дип сөйләнергә һәм кычкырынырга тотынды. (...)

(XIV бүлекнең эчтәлеге болай: Җиһангир Агиев Себердән кайтышлый Түбән Новогород шәһәрендә туктала. Чәйханәдә тамак ялгап утырганда, Казанда бер чибәр хатын Галиевне үтергән, ире сәүдә һәм акча дәрте белән, яшь хатынын калдырып, Себер тарафына киткән булган, дип сөйләшүләрне ишетә. Сөйләшеп утыручылар Җиһангирның үз фамилиясен — «Агиев»ны да телгә алалар.— *Төз. Ш. С.*)

XV

Бу хәбәрнең хакыйкатен белә алмыйча, Җиһангир, юлга чыгып, кирәк кадәр вакыт үткәннән соң Казанга кайтып җитте. Ишеткән хәбәрләрнең һәркайсы хата булыр дигән өмет белән, үз-үзен юатырга тырышып, ул ашыга-ашыга өйгә керде дә үзен каршы алган каенанасы белән:

— Саумы, әнкәй? — дип, кулын үбеп күрешкәннән соң: — Кызым, хатыным Маһруй кайда? Өйдәме? Сәламәтләрме? — дип сорады.

— Белмим... Анда,— диде әни кеше, башы белән өй эченә таба ишарәләп.

Алар шулай, башка сүз сөйләшмичә, бергәләп өйнең бүтән бүлмәләренә керделәр. Җиһангир әфәнде иң беренче булып хатыны Маһруй бүлмәсенең ишеген ачты — буш! Хатыны юк!.. Икенче бүлмәгә кергәч, кызы Фәридәне күрде. Кечкенә бала, үз әткәсен танып, шатланып, каршысына йөгереп килде:

— Әткәй! Әткәй! — дип, куллары белән муеныннан кочаклап, йөзен һәм башын үбәргә тотынды.

— Анаң кайда? — дип сорады Җиһангир.

Бала, әнисен искә төшерүгә, балаларча түгел, ә олыларча тыелгысыз бер үксү белән елый башлады.

— Ни булды, кызым? Нигә елыйсың?

— Әнкәбез юк!..

— Кайда соң әнкәгез?

— Белмибез...— диде кечкенә бала. Ул, тирән кайгы кичергән хәлдә, һаман үксеп елавында дәвам итә иде.

Кызы авызыннан бу җавапны ишеткәч, Җиһангирның куллары салынып, күз алды караңгыланып китте. «Йа Рабби!.. Юлда ишеткән хәбәр хакмы икән әллә?» — дип уйлады ул һәм каенанасыннан:

— Әнкәй, ни булды?.. Маһруй кайда? — дип сорады.

Маһруйның әнкәсе, бу сорауга җавап бирмичә, сабый балалардан да катырак тавыш белән кычкырып елый башлады. Фәридә исә, әбкәсенең елаганын күреп, әүвәлгедән дә артыграк яшьләр түгеп, әткәсенең кочагына сарылды. Җиһангир әфәнде үзе дә, бу «рәсемгә» — күренешкә түземлеге калмыйча, күзләреннән ихтыярсыз аккан яшьләрен тыя алмады. Өйдәге өч кешенең өчесе дә яшь урынына кан коялар иде. (...)

XVI

...Тикшерүче яныннан кайткан көнне Маһруй ашамады-эчмәде. Кич булгач та, күзенә йокы кермичә, ярты төнгә кадәр йокламады. Маһруйның йокысыз үткәргән шул кичне аның ире Җиһангир да, Казаннан өч-дүрт сәгатьлек еракльпкта

булып, йокысыз һәм тынычсыз бер хәлдә, ямщик атлары белән өенә кайтып килә иде.

Инде Маһруйга нишләргә? Хөкем алдында хурлыкка калудан һәм түбәнлеккә төшүдән, аннары Себергә каторга хезмәтенә китүдән аны нәрсә генә коткара ала соң? «Юк, Аллам сакласын, бу рәхәт, мул тормыштан Себер китеп, каторга хезмәтенә тарыганчы, күпергә барып, күпер өстеннән суга ташлану биш мәртәбә хәерлерәк. Юк, юк, кабер хәерлерәк. Бу кадәр авырлык һәм кимсенүләргә сабыр итәр, чыдар хәл калмады. Әҗәл... ләхет биш мәртәбә хәерлерәк. Ул әҗәлне нинди юл белән табыйм? Ничек итеп үз-үземне тәмам кылыйм?» — кебек фикерләр эчендә берникадәр вакыт гасабиланып утырганнан соң, Маһруй, өстенә кигән ике итәкле күлмәген салып, шул күлмәкнең бер итәген ертып алып һәм телгәләп, бау-аркан үрергә тотынды. Ярты сәгать эчендә ике аршын озынлыгындагы бау үрелеп, бауның бер очына элмәк ясады һәм, шул элмәкне муенына киеп асылынып үлү максаты белән, бауның икенче очын беркетер өчен дөм-караңгыга чумган «секретный» бүлмәнең дивары-стенасыннан, кулы белән капшап, берәр кадак-мазар юк микән дип эзләргә тотынды. Ләкин бернәрсә дә таба алмады. Ахырда: «Алла боерса, таң露 аткач нәрсә булса да табармын»,— дип, муеныннан элмәкне чыгарып, бауны баш астына салды да төрле уйлар эчендә бик озак ятканнан соң гына — төнге өч сәгать ярымда йокыга китте.

Биш сәгать үлгән кеше кебек йоклагач, иртәнге сәгать сигезләрдә, өстенә кайнар су коелган кеше сыман, Маһруй яткан җиреннән янә сикереп торды. «Берәрсе күрмәсен»,— дип, ашыгып-кабаланып, янә бүлмә диварыннан берәр кадак-чөй юкмы дип эзли башлады. Утлы күзләрен шулай дивар буенча йөрткәндә, аның игътибарын кечкенә тәрәзә-тәнлеккә куелган тимер рәшәткә җәлеп итте. Бу рәшәткә булганда кадакның кирәге юк иде инде. Һәм Маһруй, кулына бауны алып, бүлмәдәге кечкенә өстәлне тәрәзә буена китереп куйды да, өстәл өстенә менеп, бауның элмәксез очын рәшәткәгә бәйләде, ә элмәкле башын муенына киде. Шуннан соң өстәлне аягы белән тибеп

аударды да, бауда асылынып калып, гаять авыр мәшәкатьләр белән әҗәл газабы кичерә башлады.

Нәкъ шул вакытта ишек ачылып китеп, «секретный» бүлмәгә Җиһангир әфәнде белән бер солдат килеп керде. Җиһангир, хатыны Маһруйны асылынган кыяфәттә күреп, үз-үзен белешмәс бер халәттә өстәл өстенә сикереп менде дә, кесәсеннән пәке чыгарып, тиз генә элмәкле бауны кисте — шуның белән Маһруйны коткарып калды.

XVII

Җиһангир әфәнде Маһруй ябылган бүлмәгә тикшерүченең рөхсәте белән килгән иде. Тикшерүче, Җиһангирга Маһруй белән күрешергә рөхсәт бирүе өстенә, тагын Маһруйның җинаятьче-үтерүче булуын, шаһитларның күрсәтүләрен, Маһруйның әйткән сүзләрен һәм акушерка карчык белән күзгә-күз куеп сорау алу-тәфтиш ясалуын — кыскасы, Маһруй эшен тәфсилле рәвештә сөйләп биргәнгә, Җиһангир, үзенең хатынын үлем элмәгеннән коткарып калганнан соң, аңардан бернәрсәне дә сорашып-белешеп тормады: табиб килеп, кирәкле дәваларны биргәч, «секретный»дан китеп барды.

Инде аңа нишләргә? Маһруйны хөкемнән коткару өчен, көченнән килгән кадәр гайрәт-тырышлык күрсәтеп, берәр төрле ярдәм чарасына керешергәме? Әллә, иренә хыянәте өчен, «эзләгәнен үзе тапты» дип, мөмкин булган ярдәмне дә күрсәтмәскәме?

«Юк,— диде ул,— Маһруйның миңа хыянәт итеп эшләгән җинаяте һәм гаебе никадәр зур булса да, минем тарафтан аңа мөмкин ярдәмне күрсәтмәү кешелексезлек, хайванлык булыр иде. Минем никахлы хатыным буларак, аның миннән ярдәм һәм булышлык көтәргә хакы бар».

Ул, шундый уйлар уйлап, полициянең «секретный» бүлмәсеннән чыккач, туп-туры акушерка карчыкның өенә юнәлде. (...)

Әмма, бернигә ирешмичә, карчык бүлмәсеннән чыгып, капкага таба барганда ул әлеге йортны карап торучы хезмәтчегә очрады. (...)

— Кара әле, иптәш,— дип эндәште Җиһангир хезмәтчегә,— син күптәнме бу йортта торасың?

— Күптән, хуҗам бу йортны сатып алганнан бирле шушында торам. Өчме-дүртме ел булды инде,— диде хезмәтче, анары: — Ни өчен аны сорыйсың? Берәр йомышың бармы? — дип өстәде.

— Йомышым шул: мондагы карчыкның кайчаннан бирле бу йорта торуын беләсем килгән иде,— диде Җиһангир һәм акушерканың исемен әйтте.

— Ул карчыкмы?.. Кыскасы, ул карчык әле минем хатыным исән чакта ук монда күченгән иде... Мәрхүмә хатыным бик әйбәт кеше иде... Аллаһы Тәгалә... Кыскасы, хатыным үлгәнгә, мәрхүмәгә ике ел булды. Менә шулай ике ел инде хатынсыз торамын. Мәрхүмә белән унтугыз ел гомер сөрдем. Тиз үлеп китте, мәрхүмә. Менә без яшь вакытыбызда... — дип сөйләнә башлады хезмәтче.

— Алайса, ул карчык ике елдан бирле сезнең йортта тора икән,— дип, хезмәтчене сүзеннән бүлде Җиһангир һәм аңардан әлеге карчыкның кәсебе һәм шөгыле турында сорады.

— Кәсебе... Юк, кәсеп кылганы бер дә сизелми. Күп вакыт яшь-яшь хатыннар белән кайнаша. Ни өчен аны сорыйсыз? — диде тагын хезмәтче.— Әле күптән түгел генә бер хатын килеп, карчык бүлмәсендә бер-ике атна кунак булган иде... Хәер, бик яшеренеп торды, һич тә бүлмәсеннән чыкмый иде. Ахырда шул хатын бер бала тапты... Карчык менә шундый эшләр белән кәсеп итә... Хәер, безгә фатир өчен акча бирсә, без башка нәрсә сорамыйбыз.

— Бала тапкан хатын хәзер кайда соң? Әле дә бу карчыкта торамы? — дип сорады Җиһангир.

— Юк, юк, хәзер күренгәне юк, дүрт-биш көн булды. Киткәндер, ахрысы. Мин һәр көн шулай, тәрәзә аша булса да, һәркайсын карый-күзәтә торам. Хезмәтебез шул ич.

— Хәзер баласы кайда? Карчыктамы?

— Әлбәттә, карчыкта булыр, башка кайда булсын,— диде хезмәтче.— Нигә син миннән шундый нәрсәләр сорыйсың?

Шуннан соң Җиһангир әфәнде, хезмәтчегә җавап рәвешендә, хатыны Маһруйның шушы соңгы вакытларда карчык өендә бала тапканын һәм бала тапканнан соң булган хәлләрне сөйләп, Маһруйның төс-кыяфәтен дә тасвирлап бирде һәм хезмәтчедән:

— Мин тасвир иткән хатын белән син карчык өендә күргән хатын арасында охшашлык юкмы? — дип сорады.

— Әйе, сез тасвир иткәнгә туры килә, ләкин мин ул хатынны бик сирәк, бары кичләрен тәрәзә аша гына күрә идем. Бик яшерен торды, шулай да, күрсәм, мин хәзер дә ул хатынны таныр идем.

Җиһангир, хезмәтче авызыннан мондый файдалы сүзләр ишеткәч, күзләренә яшьләр килеп, үзенең кайгы-хәсрәтен сөйләп бирде.

— Әгәр дә шушы миңа сөйләгән сүзләрне тикшерүче алдында сөйләсәң, иншалла, Маһруйга файдалы булыр иде, шунда сине дә риза кылыр идем.

— Сез баланы Ягъкуб Галиевтән дип әйтәсез... Ләкин... Хәер, мин ул кадәресен белмимен. Ләкин дүрт-биш көн моннан элек Ибраһим Галиев тә йәстү намазы[1] вакытында бу карчыкка килгән иде. Ни йомыш белән килгәндер — белә алмадым. Ләкин мин бу эшнең асылына төшәрмен. Үз хезмәтләрем бар иде, үткән көнне төнлә мин монда юк идем — ни йомыш беләндер политсә ияртеп слидуател дә килгән булган, тик нигә килгәннәрен генә белә алмадым.

Хезмәтченең бу сүзләреннән Җиһангирның өстеннән авыр таш төшкәндәй булды, ничектер хәле җиңеләеп китте.

— Мин, тикшерүчегә барып, синнән бу эш хакында сорау алуларын үтенермен, повестка җибәрттерермен. Зинһар, бар белгәнеңне аларга сөйләп бир, иншалла, моннан соң да ризалатырмын үзеңне,— дип, Җиһангир кесәсеннән бер данә «ак» кәгазь акча чыгарды да хезмәтчегә сузды.

Хезмәтче, гаять шатланып һәм гаҗәпләнеп:

---

[1] *Йәстү намазы* — кояш баегач укыла торган (бишенче) намаз.

— Иншалла, кадәри хәл тырышырбыз. Алла разый кылсын,— дип, акчаны кулына алып, кесәсенә тыгып куйды.

Җиһангир әфәнде, хезмәтченең исем-фамилиясен язып алып, үз юлы белән китеп барды.

XVIII

— Кара, ниндәй аз хезмәт өчен никадәр күп акча — егерме биш сум бирде. «Хода бирсә колына, китереп бирерләр кулына» дигән мәкаль бик хак икән. Менә инде бай абзыйның сәламәтлеге өчен тиз генә барып берәрне кәгеп килсәң дә ярый, бераз буыннар да куәтләнер,— дип, хезмәтче туп-туры якындагы мәйханәгә юнәлде.

Ярым сәгатьләр вакыт үткәч, бер-бер артлы ике бөтен савытны каплаган хезмәтче тәмам «бай» булып кайтты. Йортка кайткач, туп-туры карчык фатирына керде.

— Исәнме, саумы, абыстай?

Карчык, хезмәтченең болай вакытсыз һәм исерек килеш керүенә гаҗәпләнеп:

— Әлхәмделиллаһ, саулык хәзергә. Нихәл, нигә кердең? Ни йомыш? — диде.

— Нигә кердең? — дип, карчыкның сүзен кабатлады хезмәтче.— Мин хуҗа ич бу йортта... Бай мине бу йортка хуҗа итеп куйган ич... Менә... менә карарга кердем, өйне яхшы тотасыңмы икән,— дип, якында булган бер урындыкка утырды.

Карчык исә, хезмәтченең мондый кыланышларына ризасызлык күрсәтеп, өстенә киемнәрен кия-кия:

— Әйдә чык... Эшләрем бар, базарга, Печән базарына барамын,— диде һәм хезмәтчене куа башлады.

— Яхшы, яхшы, чыгармын. Хәзер чыгарсаң да... менә слидуател каршына баргач күрербез... Вакыт булыр, чакырырсың да, кермәбез! — диде хезмәтче, урыныннан кузгалып.— Ярар, слидуател хозурында сөйләшербез. Мин, исерек булсам да, сезнең эшләрегезнең һәркайсын беләм.

— Җә, сабыр ит, ник юк сүзләр сөйлисең? Нәрсә беләсең, ниндәй эшләрне беләсең? — дип, хәвефкә калып сорады карчык.

— Менә слидуател каршына баргач сөйләшеп карарбыз, нәрсә белгәнемне белерсең... Ягъкуб Галиевнең баласын кая куйдыгыз?.. Исерек... исерек булсам да, һәркайсын беләм... Бүген генә монда — бу өйдә торасың. Иртәгә сиңа да, Ибраһим Галиевкә дә — икегезгә дә «акчасыз фатир» бирерләр. Менә миңа Җиһангир бай хәзер генә күпме акча бирде! — дип, кесәсеннән берәрлек, өчәрлек һәм бишәрлек бер уч кәгазь акчалар чыгарып күрсәтеп, хезмәтче ишеккә таба атлады.

— Җә, сабыр ит, кая чыгасың?.. Утыр, Әхмәди абзый,— дип, карчык, хезмәтчене туктатып, эшнең төбен белергә теләсә дә, хезмәтче, карчыкның сүзләрен гүя ишетмәгәндәй, аның тарафына кулын бер селтәде дә, өйдән чыгып, «буыннарны куәтләндерү» өчен янә әүвәлге мәйханәгә юнәлде.

Хезмәтче авызыннан шундый куркынычлы сүзләр ишетеп коты очкан акушерка исә, олуг юрист, мәкерле һәм фетнәчел Ибраһим Галиев янына ашыгып барып, аңа бөтен булган хәлне сөйләп бирде. (...)

XIX

...Өч ел вакыт эчендә Габделгафур әфәнде бер мәртәбә дә «К» авылына кайтмады, Казанда гел укуда булып, зирәклеге аркасында өч елда биш-алты еллык гыйлем тәхсыйль итеп[1], бу артык зур-бөек булмаган мәдрәсәнең үзенә күрә бер оста мөназыйры[2] һәм укуда, беренче дәрәҗәдә үк булмаса да, икенче дәрәҗәдәге шәкерте булып танылды. Ләкин Габделгафур әфәнде, яздыгыбыз «К» авылы карт хәзрәтнең нәсыйхәтләренә колак салмыйча, мәдрәсәдәге эшлексез шәкертләр белән мәхәббәт һәм дуслык тотып, кечкенә гөнаһлардан башлап, карт хәзрәт әйткән «зур гөнаһлар»га да җиңел генә барып житте — азазлап исерткеч нәрсәләр һәм аракы эчкәли башлады... (...)

Шәкертләр һәм мәдрәсәләр хакында бу сүзләрне язудан максатыбыз — бүтәннәрнең кимчелекләрен фаш итеп, үзебезне

---

[1] *Гыйлем тәхсыйль итеп* — гыйлем-белем үзләштереп.

[2] *Мөназыйр* — шәригать кануннары һәм мәсьәләләре буенча диспут (мөназәрә, бәхәс) остасы, бәхәсләшүче.

ерак күрүче һәм күп белүче итеп күрсәтү түгел; максатыбыз— мәдрәсәләрнең рәисләре, үзләрендә мәдрәсәләргә тиеш тәртип һәм кануннар урнаштырып һәм укытыла торган гыйлемнәрне хисапка алып, әлеге шикелле шәкертләрне баштан ук яхшы карап, яхшы тәрбия кылырга гайрәт итсеннәр иде, ә һәлакәтле юлга баскан угланнарны мәдрәсәләрдә тотмасыннар иде дип әйтү генә. (...)

Бу куылган шәкерт, ягъни безнең Габделгафур, мәдрәсәгә килгән вакытта шулай эчәргә ярата идеме дигән сорауга, әлбәттә: «Юк, юк! Мәдрәсәгә килгән вакытта бер дә андый нәрсәләрне белми иде, аракы эчәргә мәдрәсәдә өйрәнде»,— җавабын бирербез.

Алла сакласын, балаңны мәдрәсәгә җибәргәч, анда шушындый «җегетлекләр»гә өйрәнеп яки мәдрәсәдән сөрелеп кайтса, сиңа яхшы, хуш булырмы? Әлбәттә яхшы булмас. Яхшы булмаса, мәдрәсә башлыклары мәдрәсә шәкертләренең көнкүреш хәлләренә игътибар итсеннәр, дикъкатьләрен көчәйтсеннәр. Гыйбрәт һәм дәлил итеп Габделгафурның хәленә күз салсак, сүзебезнең хаклыгы мәгълүм булыр һәм исбат ителер. (...)

* * *

Габделгафурның мәдрәсәдән куылуыннан алып бу көнгә кадәр бер ай вакыт кичте.

Мәдрәсәдән чыккач, Габделгафур, «К» авылына кайтмыйча, Печән базарындагы бер харчәүнәдә (номер-мөсафирханәне казанлылар харчәүнә диләр) бер бүлмә килешеп, Казанда торып калды. Кулында булган дүрт-биш сум көмеш акчасын тотып бетергәч, теге-бу нәрсәләрне, ата-бабасы язган кулъязма китапларны сатып көн күрә башлады. Акча да, сатылырдай нәрсәләр дә беткәч, Габделгафур әфәнде, әлеге бүлмәсен ташлап, икенче бер харчәүнәдә мөсафир булып яшәгән дусты Мәмәт әфәнде янына торырга күчте.

Мәмәт әфәнде әүвәлдә Русия дәүләтенә табигъ[1] булып, соңыннан Иран-Персия мәмләкәтенә качкан, ике-өч ел чамасы

---

[1] *Табигъ* — буйсынучы, гражданы исәпләнүче.

Мәшһәд һәм Тәһран шәһәрләрендә яшәгән, аннары, Төркия мәмләкәтенә чыгып, госманлы тәбәгасенә[1] күчкән адәм иде.

Госманлы дәүләтенә табигъ булган бу Мәмәт әфәнде кебек шөбһәле затлар Русиядә аз түгелдер. Кайберләренең нәсел-нәсәбәләре, ата-бабалары мәгълүм булмаганга, мондый адәмнәр белән аралашмаган яки диннәре-мәзһәбләре ачык билгеле булмавы аркасында аларга хатын-кыз бирергә теләмәгән кешеләр ялгышмыйлар. Чөнки мондый шөбһәле Мәмәт һәм Әхмәт кебек әфәнделәр арасында русияле чуваш һәм чирмеш адәмнәрне дә, яки Русиядән мөртәд булып китеп,— Ходаем, шулардан саклый күр,— Төркиядә ислам паспортлары алгач, монда мөселман булып кайткан кемсәләрне дә күп күргәнебез бар. Әлбәттә, Русиядән китеп, Төркиядә Әхмәт һәм Мәмәт исемнәрен алган ул кешеләрнең һәммәсен чирмеш һәм мөртәд димибез. Әмма романыбызда хикәя ителгән Мәмәт әфәнде бик шөбһәле адәм булып, аның мөселман баласы, мөселман булуына шәһадәт[2] бирмибез. Паспортына карасаң: яше — утыз дүрт, мәзһәбе-дине — ислам, исеме — Мәмәт Мәхмүд угылыдыр.

Мәмәтләр авыр-мәшәкатьле хезмәтләргә өйрәнмәгән һәм караңгы кәсеп белән булса да җиңел тормышта яшәргә омтылган адәмнәр булып, алар керергә ярамый торган урыннарда да табылалар.

Габделгафур мәдрәсәдә вакытта ук Мәмәт белән мәйханәләрдә һәм фәхешханәләрдә күрешеп танышкан һәм дуслашкан иде. Акчасы һәм ашарга-эчәргә азыклары беткәч, Габделгафур кай җиргә барсын да кемнән ярдәм күрсен — ул туп-туры Мәмәт әфәнденең номерына китте һәм, аның тарафыннан кабул ителеп, менә бер атна инде алар бергә бер номерда торалар иде. Соңгы вакытта Мәмәтнең дә кәсепләре начар булганлыктан, алар, бер көн — ач, бер көн тук хәлдә, хезмәтсез һәм авырлык белән көн кичерәләр иде.

Шулай беркөнне, кайдан акча алырга икән, ничек бай булырга икән дип, ачлык хәсрәте эчендә үзара сөйләшеп

---

[1] *Тәбәгасенә* — буйсынуына, гражданлыгына.

[2] *Шәһадәт* — таныклык.

утырганда, номер ишеге ачылып, бүлмәгә мәгълүмегез Ибраһим Галиев килеп керде.

— Әссәламегаләйкем!

— Вәгаләйкемәссәлам! — дип, Мәмәт белән Габделгафур, керүчене олылап, утырган җирләреннән тордылар.

Акушерка карчыкның хезмәтче Әхмәдидән ишеткән хәбәрне олуг юрист, мәкерле Ибраһим Галиевкә сөйләгәнен һәм Ибраһим Галиевнең, бу хәбәрне ишетеп, «ярар» дип, карчык өеннән чыгып киткәнен унсигезенче бабның ахырында язган идем.

Олуг юрист, өйдән чыккач, киңәш һәм ярдәм эзләп, туптуры Мәмәт янына ашыкты. Мәмәт әфәнденең Ибраһим әфәндегә мондый эшләрдә, зур акча бәрабәренә булса да, берничә тапкыр ярдәм иткәне бар иде инде.

Саулык-сәламәтлек сорашкач, Ибраһим әфәнде Мәмәт әфәндегә:

— Синдә бик мөһим, үзеңә генә әйтә торган йомышым бар, әйдә,— дип, Мәмәтнең бүлмәдән, Габделгафур яныннан чыгуын таләп итте.

Мәмәт әфәнде исә, Габделгафур әфәндегә карап:

— Зинһар, бер-ике минутка безне... икебезне калдыр,— диде.

Габделгафур бүлмәдән чыгып киткәч, Ибраһим Галиев, кесәсеннән бер кәгазь — акушерка карчык йортындагы хезмәтченең адресы язылган кәгазь кисәген алып:

— Менә шушы язуда әйтелгән кешене... — дип, Мәмәт кулына тоттырды.

Шуннан соң алар, үзара пышылдап кына биш-ун сүз алышып, Габделгафурны чакырдылар.

Габделгафур бүлмәгә кергәч, Ибраһим әфәнде биш данә йөзлек акча чыгарып, Мәмәт белән Габделгафурның алдына өстәлгә куйды. Мәмәт әфәнде, мөбарәк акчаларны кулына алып карап һәм Габделгафурга күрсәтеп, Галиев әфәндегә:

— Яхшы... Без риза... «Тәмам» кылырбыз,— диде.— Ләкин син безне мондый хезмәткә яллавың турында бер кечкенә

кәгазьдә булса да бер язу язып бир. Ахырда безнең генә аркабызга авырлык килмәсен.

— Җә, юк нәрсәләр... Кәгазь нигә кирәк, кем белер?..— диде Ибраһим әфәнде.— Ул бу кичне исерек... дөм исерек... Кычкырырлык та, каршы торырлык та куәте юк, барырсыз да җиңел генә «тәмам» итәрсез...

— Син үткән юлы теге эштә дә бернәрсә дә булмас дип ышандырган идең,— диде Мәмәт, узган бер эшне искә алып.— Ләкин ахырда, вәгъдәңне үтәмәдең дә, мин алты ай төрмәдә яттым. Әгәр язу бирсәң — мөмкин, булмаса — икенче кеше тап. (...)

* * *

Төн караңгылана төшкәч, Мәмәт белән Габделгафур, акушерка карчыкның йортына килеп һәм карчыктан хезмәтченең яткан җирен сорап, үлек кебек сәрхуш хезмәтчене, йөзенә ярым сәгать чамасы мендәр-ястык каплап торып, җиңел генә «тәмам» кылдылар.

XX

Маһруйны ире Җиһангир әфәнде үлемнән коткарып калса да, элмәк һәм хисапсыз авыр хәсрәт сәбәбеннән ул тәмам хәлсезләнгән иде. Хезмәтченең үлеме белән тикшерүченең дә тәфтише төгәлләнгәч, Маһруйны полициядән төрмә-хәбесханәгә күчереп, авыруы сәбәпле, хәбесханәнең хәстәханәсендә ятак бер караватка салдылар. (...)

Шушы хәлендә Маһруй хәстәханәдә ике атналап ятты. Аның авыруы көннән-көн көчәеп, көч-куәте тәмам бетте. Ул көчкә генә сулыш ала, үлеп барган кеше кебек, ихтыярсыз күзләре ябыла иде. Кулын күтәрергә һәм хәрәкәтләндерергә көче-тәкате калмыйча, аның кул-аяклары салкына башлады.

Шул рәвешчә күпмедер вакытлар аңгы-миңге ятканның соңында Маһруй бер көнне каты йокыга китте. Шундый йокыга ки, аның сулыш алуы да, кул тамырының кан тибеше дә ишетелми башлады.

Табиб килде, Маһруйның кан тибешен тикшерде, күзен ачып карады:

— Үлгәнме? — дип сорады аңардан фельдшер.

— Әлбәттә үлгән. Күрәсең ич,— диде табиб һәм китәр алдыннан Маһруйны мәетләр өчен билгеләнгән бүлмәгә күчерергә боерык бирде.

— Ни сөйлисез, мин үлмәдем... Мин сәламәт, һәр сүзегезне ишетәм,— дип, Маһруй, кычкырырга теләсә дә, сүз әйтү түгел, иренен дә кыймылдата алмады.

«Йокы бу, үлем түгел... Ләкин үзем йокыдан уяна алмыйм. Йокым тәмам булыр, уяныргмын»,— дип уйлап, Маһруй хәрәкәтсез ятуында дәвам итте.

Ул арада хәбесханә конторы, рәсми кәгазь язып, имам әфәндегә Маһруйның вафатын хәбәр итте һәм мәетнең ислам шәригате таләбенчә дәфен кылынуын[1] үтенде.

XXI

Икенче көнне икенде намазы вакытында «тере мәет» һәм имам әфәнде каберстанда әзер булсалар да, 1888—1889 нчы елларның кышы гаять салкын һәм карсыз килү сәбәпле, җир бик туңган булып, кабер тәмамланмыйча, нибары бер аршын тирәнлегендә генә казылган иде.

— Ничек булса да күмәргә кирәк. Әйдә казыгыз,— дип әмер бирде имам хәзрәтләре.

Кабер казучылар имамга кардәш тиешле кешеләр иде.

— Җук, хәзрәт, җук, берничек тә бүген казып бетерә алмабыз. Карагыз, җир теш кадәр генә булып куба, бик туңган. Бүген күмә алмабыз, хәзрәт,— диделәр алар.

— Ничек булса да дәфен кылырга кирәк. Бераз казыгыз да, ярар... ләхет алырсыз...

— Җук, хәзрәт, артык казырга тәкать тә, куәт тә калмады, кич тә җитте. Салкынга һич чыдарлык түгел, көне буе шул салкында торабыз.

— Бүген дәфен кылмасак, мәетне нишләтербез икән? — диде хәзрәт.

---

[1] *Дәфен кылыну* — җиргә тапшырылу, күмү.

— Мәетне монда калдырырбыз. Иртә намаздан соң килеп, каберне казып бетерербез дә күмәрбез.

Шулай дип, кабер казучылар, биш-ун минут эчендә әйбер-коралларын җыеп, атны чанадан тугардылар да, Маһруйны өстенә ябылган иске киемнәре белән чанада калдырып, ахшам намазы вакытында каберстаннан кайтып киттеләр.

* * *

...Маһруйны каберстанда калдырып киткәннән соң ярты сәгать чамасы вакыт үткәч, ул айный-уяна башлады. Биш-ун минут эчендә тәмам уянып бетеп: «Йа Рабби, кабер эчендәменме?!» — дип, бераз хәрәкәтләнеп, кулы белән кәфенен ачты да: «Аллага шөкер! Күмелмәгәнмен икән!» — диде. Бераздан ул торып утырмакчы булды, ләкин хәле-куәте юклыктан гәүдәсен күтәрә алмады.

Бу сәгатькә кадәр көн гаять суык булса да, Маһруй уянган вакытта, хикмәти Хода, һава үзгәреп, тәмам җылынып киткән иде.

Шул рәвешчә тагын ун-унбиш минутлар вакыт үтте. Ниһаять, Маһруй, бөтен көч-куәтен җыеп, яткан җиреннән торды, өстенә ябылган иске киемен зур мәшәкать белән киеп һәм кәфен кисәкләрен аягына чорнап, каберстаннан чыкты да өенә таба юнәлде.

XXII

(Себер якларында ук чирләгән Җиһангир, авыр кайгыларга түзә алмыйча, хәстәханәдә авырып ята. Дәваланып чыккач, төрмәгә барып, Маһруй турында сораша. Әмма: «Маһруй вафат булды»,— дигән җавапны ала. Җиһангир, өенә кайтып, каенанасы һәм кызы Фәридә белән елашалар.— *Ш. С.*)

Болар шулай елашып утырганда, Маһруй, авыр мәшәкатьләр чигә-чигә каберстаннан өйгә кайтып җитеп, җир астыннан чыккан җен кебек, ап-ак кәфенгә төренгән килеш, бикләнми калган ишектән әнкәсе һәм ире утырган бүлмәгә килеп керде.

* * *

Икенче көнне каберне казып бетерергә һәм мәетне күмәргә килгән кешеләр, Маһруйның мәетен кабер янындагы чанадан тапмыйча, этләр-кочыклар алгандыр дип, каберстан буйлап эзләргә тотындылар, һәм, таба алмагач, хәлне имам әфәндегә җиткерделәр. Имам әфәнде йөгерә-чаба шундук каберстанга килеп, курку катыш бер гаҗәпләнү белән: «Йа Аллаһ, әстәгъфирулла, харап булдык. Карарга кирәк, шундадыр кайда да булса»,— дип, үзе үк мәетне эзләргә китте. Ләкин, сезгә мәгълүм ки, бернәрсә дә таба алмады. Шуннан соң имам:

— Мәетне җеннәр алгандыр,— дип, буш каберне күмәргә боерды.

— Алла сакласын... Белә күрмәсеннәр, юкса һәркайсыбызга Себер булыр,— дип сөйләнде имам хәзрәтләре һәм, кулына көрәк алып, каберне күмешә башлады.

Кабернең буш — мәетсез күмелүе башка беркемгә мәгълүм булмаган кебек, Маһруйның исән һәм сәламәт калуыннан да һичкемнең хәбәре булмады.

XXIII

Габделгафур белән Мәмәт, акушерка карчык йортындагы хезмәтчене «тәмам» иткәннән һәм тотылмыйча иректә калганнан соң, җиңел килгән акчаны җиңел генә туздырырга керештеләр. Ләкин берәр ай үткәч, аларның акчалары бетә — «тәмам» була башлады.

Менә бүген алар, Мәмәт белән Габделгафур, бер касә «кәшшафелкъолуб»[1] алып, чәйханәнең «сәттарелгойуб»[2] бүлмәсендә утыралар. Габделгафур гаять тә кайгылы кыяфәттә, елар дәрәҗәгә җитеп, күзеннән тамчы-тамчы яшь тама.

— Әйдә боер,— диде Мәмәт, Габделгафурның кулына касәне тоттырып.— Юк нәрсәләр белән башың ватма... Хәзер син

[1] *Кәшшафелкъолуб* — күңелләрне ачучы (бу урында «аракы» мәгънәсендә).

[2] *Сәттарелгойуб* — гаепләрне яшерүче (бу урында «яшерен аерым бүлмә» мәгънәсендә).

әүвәлге Габделгафур түгел. Юк-бар нәрсәләр уйлап, әнкәй-әткәй дип елыйсыңмы? Әнкәң сиңа хәзер ярдәм итә алмый.— Бераз тынып торганнан соң: — Әткәең нәрсә язган? Бир әле хатыңны, карыйм,— дип, Габделгафурның әткәсеннән килгән хатны сорады.

Габделгафур кесәсеннән конвертлы хатны чыгарып Мәмәт әфәндегә бирде. (...)

Мәмәт хатны укып бетереп, Габделгафурга кире бирде дә, бераз уйланып торгач:

— Юк, сиңа өйгә кайтырга туры килмәс... Авыл-иген хезмәтенә сәләтең юк. Булса да, мәдрәсәдән куылып өйгә кайту — бик хурлыклы эш,— диде. Аннары сүзен болай дип дәвам итте: — Менә мин әйткән эшне «тәмам» кылыйк... Күп акча алырбыз, бик бай урын... Соңыннан — туп-туры Истанбулга һиҗрәт[1]. Алладан ярлыкау сорап, тәүбә кылырбыз да, яхшы кешеләр кебек, чалма һәм хилгат[2] киеп, алыш-бирешсез генә яши башларбыз.

Габделгафур, Мәмәтнең сүзләренә җавап бирмичә, әткәсеннән килгән хатка төбәлеп, кылган эшләре һәм үз хәле турында уйланып утыруында булды.

Мәмәт сүзен дәвам итте:

— Бер-ике ел Истанбулда торып, соңра өйгә кайтсаң да ярый. Яшьлектә булган гөнаһларны халык һәм Аллаһы Тәгалә үзе кичерер... Тугры юл — истикамәттә булып кайтырсың. Әткәең урынына имам да булырсың. Ләкин бу килеш өйгә кайтсаң, хәлең бөтенләй башкача булыр. (...)

* * *

Шул кичнең төнендә Мәмәт белән Габделгафур, сөйләшенгән «эшне» тәмамлау өчен, Печән базары мәчете янындагы чиркәү эченә үтеп керделәр дә анда булган акча, алтын-көмеш әйберләрне алганда кыска гына вакытка ут-шәм кабыздылар.

---

[1] *Һиҗрәт* — күчеп китү.

[2] *Хилгат (хилгъәт)* — югары дәрәҗәле кешеләр тарафыннан бүләк ителгән («кидерелгән») кыйммәтле өс киеме (халат).

Чиркәү сакчысы, бина эчендә ут яктысы күреп һәм эшнең яхшы булмавын аңлап, городовой белән тагын дүрт-биш кешене ярдәмгә чакырып китерде. Мәмәт белән Габделгафур акча һәм алтын-көмешне урлап чыгып килгәндә, посып-көтеп торган сакчылар, алар өстенә һөҗүм итеп, каракларның икесен дә әйберләре белән тотып алдылар.

XXIV

Мәмәт белән Габделгафурны урланган әйберләре һәм урлау кораллары белән бергә чиркәүдән туры полициягә юлладылар. Полициядә, кыска гына сорау алудан соң, каракларның янында һәм кесәләрендә булган нәрсәләрне барлый башладылар. Габделгафурның кесәсеннән Габделгафур исеменә бирелгән иске паспорт һәм әткәсеннән килгән хат белән дүрт сум сиксән тиен акча табылды.

Мәмәтнең кесәсеннән исә, Мәмәт исеменә бирелгән Госмания паспорты һәм кырык биш сум акчадан тыш, акушерка карчык йортындагы хезмәтчене үтерү шарты рәвешендә Ибраһим Галиевтән алынган язу-кәгазь чыкты. (...)

* * *

Мәмәт, Габделгафур һәм Ибраһимның җинаятен тикшерү тәмам булгач, хәбесханәдә аларның өчесен бергә бер бүлмәгә яптылар. Ябылуларына инде менә өч атна үткән иде. Бүген өчесе бергә бүлмәдә сөйләшеп утыралар. Ибраһим, Мәмәт белән Габделгафурга эндәшеп:

— Эшләребез начар... Тизме окружныйда каралыр икән? — диде.

— Әлбәттә начар... Безне унбишәр елга каторжный хезмәткә һичшиксез хөкем итәчәкләр,— диде Мәмәт һәм сүзен болай дип дәвам итте: — Төрлечә уйлап карадым, әмма каторжный хезмәттән котылырга һич тә бүтән юл таба алмадым. Безнең өчен иң җиңеле, хәерлесе — моннан, хәбесханәдән, качу... Юкса хәлебез мөшкел.

— Качарга?! Качу әлбәттә яхшы булыр иде, ләкин ничек качарга?! — дип сорады Ибраһим.

— Иншалла качып була... Ничек качарга икәнен үзем өйрәтермен, ләкин моның өчен кырык-илле сум акча кирәк. Синдә акча бармы? — диде Мәмәт.

— Акчадан тоткарлык булмас, тик качарга юл гына тап.

(Ибраһимнан 25 сум акча алгач, Мәмәт, төрмәдә эшләүче буяучылар төшке ашка киткәндә, аларның җитәкчесе Гомәрдән аракы алып килүен үтенә һәм шәһәрдәге бер иптәшенә язу язып җибәрә.— *Ш. С.)*

XXV

Ике сәгать чамасы вакыт үткәннән соң, Гомәр абзый һәм башка буяучылар хәбесханәгә кире әйләнеп кайттылар. Гомәр абзый Мәмәт әфәндегә әйтелгән өч савыт аракыны да, кәгазьдә язма рәвештә соралганны да алып килгән иде.

Гомәр абзый башта Мәмәткә аракыларны бирде, аннары кечкенә генә кәгазь кисәгенә төрелгән нәрсәне тапшырганда:

— Монысының кешесен көчкә таптым, бик ерак тора икән... Моннан чыккач, ашарга да бармыйча, туры аны эзләп киттем,— дип куйды.

— Бик яхшы, бик яхшы... Дуслык шулай була ич... Иншалла, мин дә сине онытмам,— дип, Мәмәт аракыны һәм әлеге кечкенә кәгазьдәге нәрсәне алды да, ашыгып, Ибраһим белән Габделгафур янына китеп барды.

Буячы Гомәр абзый исә, бернинди шик-шөбһә тотмыйча, кәгазьгә төрелгән нәрсәнең ни икәнен белмәде дә, кызыксынмады да.

Мәмәт, ябылу бүлмәсенә кайткач, аракы савытларының берсен ачып һәм бер-ике рюмка аракысын эчеп, кулындагы кәгазьдә булган порошокны аракы савытына салды да, яхшы гына селкеп-болгап: «Догада булыгыз!» — дип, шул аракылы савытны алып буяучылар бүлмәсенә юнәлде. Анда кергәч:

— Менә, иптәшләр, аз булса да гаеп итмәссез... Шушы тереклек суын эчеп җибәрегез әле! — диде.

Буяучылар: «Бу зур гөнаһ ич... Без аракы эчмибез»,— дип тормадылар, аракылы савытны дүртесе дә шатлык белән кабул

итеп, Мәмәт бүлмәдән чыгып киткәч тә тамчысын да калдырмый эчеп бетерделәр.

Аракы савытына салынган порошок йоклаткыч дару-дурман иде. Аның тәэсире шулкадәр көчле булды ки, биш-ун минут эчендә буяучыларның дүртесе дә, һуштан язып егылган кешеләрдәй, бер-бер артлы аяк өстеннән идәнгә авып, үлем йокысы белән йоклый башладылар.

Алар шулай йокыга талгач, бүлмәгә Мәмәт, Габделгафур һәм Ибраһим кереп, үз киемнәре урынына буяучыларның эш киемнәрен өсләренә киделәр дә, кулларына тегеләрнең коралларын тотып, буяучылар сыйфатында, «Йа кичерүче Алла! Үзеңә тапшырдык!» — дия-дия, хәбесханә бинасыннан чыга башладылар. (...)

Капканы саклаучы солдат алардан:

— Кемнәр сез? — дип сорады.

— Кемнәр сез?! Күрәсез ич: буяучыларбыз... Капканы ач! — диде Мәмәт.

— Ярар, ярар, сабыр итегез,— диде капка сакчысы һәм: «Әйдә, рәхим итегез, боерыгыз!» дигәнне аңлаткандай, каерып капканы ачты.

Ялган буяучылар, күңелләреннән Аллага шөкерләр әйтеп, капкадан чыгып җиткәндә генә, арттан тагын:

— Сез буяучылармы? — дип сораган тавыш ишетелде. Качаклар борылып карадылар. Мәмәт, эндәшүченең хәбесханә караучысы икәнен танып:

— Әйе, без буяучылар,— дип җавап бирде.

— Бик яхшы... Эшләрне бетердегезме? Дүрт кеше идегез, берегез кайда?

— Юк, эш бөтенләй үк бетеп җитмәде әле. Без алданрак киттек, мунчага барабыз. Беребез калды, калган эшләрне тәмам итәргә,— диде Мәмәт.

— Менә минем эш бүлмәсендәге тәрәзәләрне буярга кирәк иде... Әйдә кереп карагыз әле.

— Зинһар, безне туктатмагыз, иртәгә карарбыз.

— Юк, юк, бүген карап чыгыгыз. Иртәгә кирәкле буяуларны алып килеп буяп та алырсыз,— диде хәбесханә караучысы, үз сүзендә нык торып.

«Йа Аллаһ, мәдәд[1]!» — дип, буяучылар хәбесханә караучысы белән бергә аның эш бүлмәсенә керделәр. Анда нәрсәләрдер язып хәбесханәнең сәркәтибе утыра иде. Ул, ялган буяучыларны күреп, шөбһәле тавыш белән хәбесханә караучысыннан:

— Болар нинди буяучылар? — дип сорады.

— Болар хәстәханәнең өстәмә бүлмәсендә эшләүче буяучылар,— диде хәбесханә караучысы.

— Юк, юк! Болар ул буяучылар түгел...— диде сәркәтип.— Ул буяучыларны мин иртә килгән вакытларында күргән идем. Болар ул кешеләр түгел.

Бу сүзләр качаклар өчен шактый куркынычлы булса да, Мәмәт, курку-каушау әсәре күрсәтмичә:

— Юк, без иртә якта килгән буяучылар түгел... — дип аңлата башлады.— Алар өйгә ашарга кайткач, хуҗабыз аларны профессор Закталовның өен буярга җибәрде... Алар яхшы, оста буяучылар... Хуҗа безне алар урынына хәбесханәгә юллады,— дигән вакытта хәбесханә сакчыларыннан берәү, бүлмәгә йөгереп кереп:

— Тизегез!.. Тизрәк, әйдәгез!.. Әйдәгез!.. Арестантлар качтылар!.. — дип сөрән салды.

— Кемнәр?! Кайчан качтылар?! — диде хәбесханә караучысы, тәмам каушап калып.

— Әйдәгез... үзегез карарсыз...

Сакчының шул җавабыннан соң, хәбесханә караучысы белән сәркәтип, буяучыларны бөтенләй онытып, куркынычлы хәбәрне китергән сакчы артыннан, кемнәр һәм нинди юл белән качканлыгын белер өчен, ашыгып төрмә бинасына таба элдерттеләр.

Мәмәт, Габделгафур һәм Ибраһим исә, сабырлык белән, ашыкмыйча гына атлап, хәбесханә караучысының бүлмәсен-

---

[1] *Мәдәд* — ярдәм, булышлык.

нән туп-туры капкага таба юнәлделәр һәм, Исраил балалары судан коры чыккан кебек, хәбесханәдән «коры» чыгып котылдылар.

XVI

Үлемгә тиң мәрт йокысы аркасында хәбесханәдән котылып калса да, Маһруй электәге авырулары яңарудан һәм каберстанда яткан чагында, аннары аннан өйгә кайтканда салкын тидерүдән, кул-аяклары өшүдән шактый заманнар хәстә булып ятты. Җиһангир белән Маһруй, тәмам терелеп, сәламәтләнеп җиткәч тә, Казанда тору мөмкинлеген тапмыйча, шәһәрдән китеп гаиб булдылар[1]. Кай җиргә, нинди шәһәргә һәм ничек киттеләр — бу эшләр шулкадәр яшерен эшләнде ки, моны «Зур гөнаһлар» исемле романны язучы автор үзе дә белә алмады.

* * *

Олуг юрист, мәкерле һәм фетнәчел Ибраһим Галиевнең һәм Габделгафур белән Мәмәтнең качканнан соң кичергән хәлләрен киләчәктә язачак «Мөртәд» исемле романымда сөйләрмен*.

---

* «Мөртәд» романы, әдип тарафыннан язылып тәмам булса да, басылмый кала. Әсәрнең кульязмасы табылганы юк.

[1] *Гаиб булдылар* — юкка чыктылар, күздән югалдылар.

Гали Чокрый

(1826—1889)

[ШӘМСЕДДИН ЗӘКИ ТУРЫНДА]

Тәрҗемә

Үзе тома сукыр күзгә,—
Зирәклеге чыккан йөзгә,
Галим һәм оста сүзгә.
Күзе юктан язалмады,
Әһел ирләр[1] табалмады,
Сорарга да базалмады...

[ШИҺАБЕДДИН МӘРҖАНИ ТУРЫНДА]*

Чынанча сахибе шөһрәт, Шиһабеддин — гали фикрәт,
Укыптыр чук фөнүн, хикмәт, һадилар кем безем саздыр.
Казандыр мәскүне ватан, кабиләсе аның — Мәрҗан**,
Нәселләре билә әгъян, һадилар кем безем саздыр.
Рәфигъдыр хале зи тәмкин, атасыдыр Баһаведдин
Янә тугмасы Садреддин, һадилар кем безем саздыр.
Языптыр күп рисаилне, ачып төрлүк мәсаилне,
Хафиздыр күп дәлаилне, һадилар кем безем саздыр.

Тәрҗемәсе:

Чын-чыннан шөһрәт иясе, Шиһабеддин — бөек фикер иясе,
Күп фән, фәлсәфә укыган, безне туры юлга салган.

---

* «Шәмгыз-зыя» («Яктылык балкытучы шәмнәр», 1883) китабыннан.

** Ш. Мәрҗани 1818 елда Татарстанның хәзерге Әтнә районындагы Ябынчы авылында туа. Ата-бабалары Мәрҗан дигән авылдан була. Әнисе ягыннан бабалары — Татарстанның Чүпрәле районы Татар Бизнәсе, Иске Чокал авылларыннан чыккан укымышлылар.

[1] *Әһел ирләр* — шагыйрьнең әйтеп торганын язып баручылар, күчерүчеләр.

Торган җире — Казан, нәселләренең чыгышы — Мәрҗан,
Бик атаклы нәселләре, туры юлга салган безне.
Атасыдыр Баһаведдин һәм туганы Садреддин —
Шулай ук безне туры юлга әйдәгән әһелләрдин.
Төрле мәсьәләләр ачып, күп китап һәм хезмәт язган,
Күп дәлилләрне китереп, безне туры юлга салган.

БОРЫНГЫ БОЛГАР ТУРЫНДА*

Менә шәһри Казаннан күп мөкатдәм[1] шәһри Болгар хуп[2],
Дарелислам иде мәхбүп[3], мәгәр тәкый харап саздыр[4].
Ләтыйф җайда булып мәгъмүр[5], ләтыйф хәлләр табыптыр ул,
Ки мәсҗедләр итеп мәхсул[6], мәгәр тәкый харап саздыр.
Мөселман ханнары торган, мөселман(г)ә хисар[7] булган,
Татар, башкорт, мишәр тулган, гали җайда бина саздыр[8].
Дәхи анда китап, Коръән, уку-язу бары булган,
Тәмам дин асаре[9] тулган, дарелислам эшен саздыр.
Ләимнәрдән ләим[10] тәкый, кем ул Аксак Тимер багый[11],
Мөселман һәдменә[12] сәгый булып[13], шәһри харап саздыр...

---

* «Мәдхе Казан» («Казанны мактау», 1889) китабыннан.

[1] *Мөкатдәм* — элек.

[2] *Хуп* — гүзәл, матур.

[3] *Дарелислам иде мәхбүп* — сөекле ислам йорты иде.

[4] *Харап саздыр* — харап ителгәндер (саздыр — шигырь юллары азагында шагыйрь кулланырга яраткан ярдәмлек сүз, «шулай булган» мәгънәсендә).

[5] *Ләтыйф җайда булып мәгъмүр* — матур урында төзелгән булып.

[6] *Итеп мәхсул* — хасил итеп, төзеп.

[7] *Хисар* — крепость.

[8] *Гали җайда бина саздыр* — югары, биек урында салынган шәһәрдер.

[9] *Асаре* — әсәрләре, китаплары.

[10] *Ләимнәрдән ләим* — кабахәтләрнең кабахәте.

[11] *Аксак Тимер багый* — урта гасырларда яулап алулары белән танылган, кансызлыгы белән дан тоткан хөкемдар (1336—1405). 1391—1395 елларда Идел буе шәһәрләрен, шул исәптән Болгарны җимереп, талап, яндырып китә.

[12] *Һәдменә* — егылуына, бетерелүенә.

[13] *Сәгый булып* — тырышып.

Ләимнәрнең йөзе кара, ничек тупка кулы бара
Атарга шәһри Болгарга?! — Ничә әбрар мәкам саздыр[1]...
Рижалене[2] кырып салмыш, хатыннарын әсир алмыш,
Тәмам Болгар янып калмыш, иман әһле фәган саздыр[3]...

КАЗАН ҺӘМ АНЫҢ ХАЛКЫ ТУРЫНДА

Мона шәһри Казанны, яр, карасаң кәррә гәр унар[4],
Назар саен[5] назы тәкрар, һаман фазле гаян саздыр[6].
Чыгар андин кием-салым, читек-башмак булып мәнзум[7],
Зифалык васфида мәгълүм[8], җиһан халкы мәдех саздыр[9].
Дәхи анда хатын-кызлар чигү-чәнчү нәкыш дәяр[10],
Җиһан халкы санынча бар сияп-сәрпүш гаян саздыр[11].
Иң әүвәл, йортлары бик саф, икенче, ирләре бик саф,
Өченче, җырлары бик саф, әмерләре назар саздыр[12].
Ләбибләр[13] күплеге берлә, әдипләр күплеге берлә,
Табиблар күплеге берлә тәмам илгә гаян саздыр...
Азанчылар, хатыйпчылар, карый-хафиз, вәгазьчеләр[14],
Суфый-закир[15], намазчылар тәмам урман кеби саздыр.

---

[1] *Ничә әбрар мәкам саздыр* — никадәр изгеләр торган, яшәгәндер.

[2] *Рижалене* — ирләрен.

[3] *Фәган саздыр* — зар елаганнар.

[4] *Карасаң кәррә гәр унар* — әгәр унар мәртәбә карасаң.

[5] *Назар саен* — караган саен.

[6] *Фазле гаян саздыр* — күркәмлеге, камиллеге ачык күренеп тора.

[7] *Булып мәнзум* — тукылып, эшләнеп.

[8] *Зифалык васфида мәгълүм* — үзләренең матурлыклары белән билгеле.

[9] *Җиһан халкы мәдех саздыр* — дөнья халкы алдында мактаулыдыр.

[10] *Нәкыш дәяр* — бизәү эшендә бик осталар.

[11] *Сияп-сәрпүш гаян саздыр* — анда эшләнгән киемнәрнең һәм кәләпүшләрнең саны.

[12] *Әмерләре назар саздыр* — эшләре карап туйгысыз яхшыдыр.

[13] *Ләбибләр* — акыл, белем иясе.

[14] *Карый-хафиз, вәгазьчеләр* — Коръәнне яттан укучы, вәгазь сөйләүчеләр.

[15] *Закир* — догалар укучы, Алланы мактап зикер әйтүче.

ФАСЛЫ КЫШ*

Суытды кыш көнен, карлар ягырды,
Акызды су итеп яз айларында.
Тәмам дөнья йөзе ак кар булубән,
Тотар боз су йөзен һәр җайларында.
Сулу алырга такать тотмаз инсан;
Суыклык хәддин ашар җайларында.
Һәммә таг-таш илә сахра вә әшҗар[1]
Алыр кар табгыне[2] һәр җайларында.
Ничә таглар кеби кар калканыны
Акызыр су итеп яз айларында.

ФАСЛЫ ЯЗ

Тәрҗемә

Апрель туды, яз булды,
Төннәр көндездәй булды,
Көннән-көн матурланды,
Һәммә тереклек уянды.

Бизәнде җир нияз белән[3],
Тулды төрле наз белән,
Куанды килгән яз белән,
Яшеллектән ямьләнде.

Әгәр йортта йөресәң дә
Яки тауда йөресәң дә,
Яланнарда йөресәң дә,—
Ходайны мактау авазы!

Бу вакыт һәртөрле җанвар
Җир бетереп йөри, сайрый.
Боларда да дәлилләр бар:
Гыйшык җырын җырлый алар.

Күгәрчен, карлыгач уйный,
Язны мактап гомре уза,
Сабан тургай ничә төрле
Моңы белән җырын суза.

Бүре, төлке, елан, куян,
Балыклар һәм күпме хайван,
Мактау әйтеп, аваз бирә,
Бар да йөри шул дәрт белән.

---

*«Фосулы әрбәга» («Елның дүрт фасылы») әсәреннән.

[1] *Әшҗар* — агачлар.

[2] *Алыр кар табгыне* — кар белән капланыр, басылыр.

[3] *Нияз белән* — теләгән кадәрле, кирәгенчә.

Бакалар су буйларында
Бата-чума сикерешә,
Бакылдый, бугазын ерта,
Хуш тавышларын бирешә.

Кайсы — яфрак белән гөлләр
Арасында укый шигърен,
Кайсы күккә күтәрелә,
Җырлый-җырлый гыйшык
җырын.

Кайсы — җирдә, кайсы — суда,
Кайсы — көндез, кайсы —
төндә,
Кайсы берөзлексез йөри,
Кайсы утырып көен көйли...

Кичләрендә тыңлар булсаң,
Фикер йөртеп уйлар булсаң,
Гаҗәпмени, дәрткә тулсаң,—
Бары безгә хөрмәт җырлый.

Килеп былбыл, бакча күрә,
Соклангыч, дип, куна гөлгә,
Мең төрле җыр җырлый аңа,
Гөл тыңлый, серен белә.

Килим мин дә үз эшемә,
Хуш, димен дус-кошыма,
Булсам иде кош кебек яз да,
кыш та:
Мактау җырлый ул һөнәргә,
эшкә!

Яков Емельянов

(1848—1893)

ЯРЛЫ ТОРМЫШ*

Менә бүген бишенче числа,
Ярый инде, хуш;
Кесәләрне караштырдым —
Һәрберсе дә буш.

Байга бардым алмага,
Артыкларны салмага[1];
Артыкларны алмады,
Кесәмә дә салмады.

Җыласыем, яшь чыкса,
Нужа хакына тансыкка,
Мин кайтуга самавыр куй, дип,
Әйтмәгән булсам карчыкка.

Мин кайтуга самавыр
Бик шатырдап кайнаган,
Чәйне кешедән аласыек,
Шикәр һич тә калмаган...

Кояш баеп, ай калыккач,
Ашарга җибәреп алдырдык,
Ашаганда яктыртсын дип,
Телеп чыра яндырдык...

Ятарга урын җәйгәчтен,
Икебез дә көендек,
Йоклаганда катмыек, дип,
Шәрә тунга төрендек...

КАЙГЫ

(өзек)

Китсен моннан зур кайгы,
Минем алда тормасын;
Йөдәгән җанны, җил-давыл күк,
Уңга-суңга бормасын!

---

* Кыскартып алынды. Бу әсәр рус шагыйре И. С. Никитинның (1824—1861) «Талаш» («Ссора») шигыре тәэсирендә язылган.

[1] Берәр әйберне биреп торып, бурычка акча алу турында сүз бара.

Бормасын аны һичбер якка,
Ул таш-тау күк ныгып утырсын;
Кайгылы чакта җыйган уйдан
Савытын басып тутырсын.

Тутырсын савытын нык уй белән,
Ул соңыннан аңар куаныр;
Алҗыган чакта тилпенмәсә,
Талир күк[1], бәла уалыр.

Уалсын бәла, ярылсын,
Каушатып җанны җиңмәсен;
Таудан чыгып, диңгез белән
Сыналган җанга килмәсен!

Килмәсен җанга шаулап-улап,
Ул үлән күк аннан сыгылмас;
Аның куәте кагылганда,
Каушап, калтырап егылмас!

Егылмас инде сыналган җан,
Син һәрчакта аңа күрендең;
Куәтең, иркең аңлаткачтын,
Үзең дә каушап сүрелдең.

Сүрелдең инде, бөкре кайгы,
Ялкының һич тә кыздырмый,
Эчкә кереп кайнатсаң да,
Куәтең мине сыздырмый!..

Юансын җан шуны уйлап,
Югыйсә монда калтырар,
Дөнья утына түзгән җан
Буласы көндә ялтырар!

---

[1] *Талир күк* — тәлинкә кебек.

* * *

Көн дә ызгыш, ялан әр
Җебектерде инде җанымны!
Каты кылмыш, тиешсез тормыш
Киптерә минем санымны[1]!
Чү! Җитәр,
Каты кайнап
Пар тулганда,
Артык чыгып китәр!..

ӘЛӘК*

Тор гадел,
Йөр шиксез,
Бул изге,
Кыл яхшы,
Уйла туры,
Сөйләш чын,—
Буяр әләк!

Кайгыр, көен,
Интек, инәл,
Ела, тилмер,
Уйла, шәйлә,
Уеңны җәймә,
Телеңне бәйлә,—
Ябышыр әләк!

Каладан илгә[2],
Җирдән суга,
Суыктан утка,
Төшлектән төнгә,
Таудан атауга
Күч, кач,—
Табар әләк!

Чыкма, йөрмә,
Барма, кермә,
Бераүне белмә,
Шиклән, биклән,
Яклан, саклан,
Башыңнан капла
Сизәр әләк!

Шушы яман,
Тинтәк башлы,
Иң акылсыз
Чак каргадан
Котылмасак,—
Итәр харап!

---

* Шагыйрь бу әсәрен И. С. Никитинның «Гайбәт» («Сплетня») шигыре тәэсирендә язган булса кирәк.

[1] *Санымны* — гәүдәмне, тәнемне.

[2] *Илгә* — авылга.

САРАН БАЙ

Өеңә керсә саран бай,
Аңар ишегең ачма;
Ул килгәндә ялангач
булсаң,
Аннан оялып качма.

Качма аның йөзеннән,
Оялма аның үзеннән;
Саранлыгының чиге җиткәч,
Җаны алыныр күзеннән.

Күзенең туймас ялкыны
Яндырыр аның саннарын;
Ярлыдан кызганган
сараннарның
Шайтан эчәр каннарын.

Каны белән кабере тулыр,—
Күмүчеләр җирәнер;
Үзеннән калган мал белән
Дөньядагылар кинәнер.

Килегез, бәндәләр, кинәнегез
Сараннан калган мал белән,
Җанын шайтан кинәндерер
Үзеннән аккан кан белән!

ОЛЫСЫМАНЛЫК

Олысыманлыкны ватар өчен
Җыегыз җирдән кораллар;
Аның куәтен киметер өчен
Тагыгыз бакыр богаулар.

Бакыр богау аны басып,
Җиргә чаклы төшерсен;
Шул яманга узган-барган
Тамагын кырып төкерсен!

Төкерсен аңар барысы да,
Ул хурлыкны тулы аңласын,
Аның куәте җир өстендә
Тамырын җәеп калмасын.

Калмасын монда яман шәүлә,
Ул, төтен күк, җирдән җуелсын,
Көферлек чыгы, шайтан шыгы
Хурлыгын күреп тыелсын!

Мифтахеддин Акмулла
(1831—1895)

ДАМЕЛЛА ШИҺАБЕДДИН ХӘЗРӘТНЕҢ МӘРСИЯСЕ

*(поэмадан өзекләр)**

Казанда бер фазыйл[1] чыкды алмас булып,
Көнчеләре күбәйде гам-хас булып[2],
Фикер җәүһәрләрен кулга әлгән,
Хакыйкать диңгезендә гаувас[3] булып.
Мәйданда ул чыгарды артык гайрәт,
Мизмарда сабикълардан чыкды гасрәт[4],
Хәмде лиллаһ, бу ил-җирдә бездән чыкды
Мәрҗани Шиһабеддин ахунд хәзрәт!
Караңгыда фонарьны кабызган ул,
Кайнар сөткә сары майны тамызган ул;
Сәламәтлек чишмәсеннән юллар ачып,
Хаклык елгаларын агызган ул.

---

* Кайбер сүзләр хәзерге телгә күчереп алынды.

[1] *Фазыйл* — өстен, олы (зур галимнәргә карата кулланыла торган эпитет).

[2] *Гам-хас булып* — түбән һәм югары (укымышлы) катлау кешеләрендә.

[3] *Гаувас* — суга чумучы, водолаз.

[4] *Мизмарда сабикълардан чыкды гасрәт* — бәйге мәйданында элгәргеләрдән ялгышлар чыкты.

Сүз кузгар ул ир асыл — кирәк йирдән,
Ходаем сизгер-кыю йөрәк биргән;
Инженерлар сизмәгән йирдән казып
Чыгарды татлы суны тирән йирдән.
Болагы — саф, чәйгә һәркем су алгандай,
Хаклыкка сусаганнар куангандай;
Энҗесеннән күпме бала сөткә туеп,
Башкалар була калды су алгандай.
Хакыйкатен күргән адәм куангандай,
Галимнәргә юл күрсәтеп ту[1] алгандай;
Көрәш мәйданына бу чыккан соң
Батырлар була калды җугалгандай.
Аңнаусыз һичкем аңа тотынмасын,
Анау-монау кеше имәс чобалгандай...
Дошманына җан аямай каршы торып,
Аның өчен көрәшчебез алгы сафдан.
Тирән уйда мөшкил[2] чишеп калдырган ул,
Биш йөз елгы батырларны талдырган ул,
Гасырында үзенә охшаш тиңне тапмай,
Карышучы йөрәген яндырган ул...
Үтә алмыйлар эзеннән басып аның,
Китә алмыйлар юлыннан ашып аның;
Хак нурын сүндерә алмай дошманнары,
Күрә алмыйлар галәмгә фашын аның!
Аһ, дәрига[3]! Баралмадым каршына аның,
Сүзенә артыкча мин гашыйк аның...

*

Мин үзем бер дәрдемәнд[4] диванәмен,
Кайда бер хаклык күрсәм куанамын.

---

[1] *Ту* — байрак.
[2] *Мөшкил* — кыен мәсьәләләрне.
[3] *Аһ, дәрига!* — аһ, үкенеч!
[4] *Дәрдемәнд* — кайгылы, моңлы.

Бу затда гаҗәп хаклык күргәннән соң,
Чарасыз шул сәбәбдән хуб аламын...
Бәхетемез ачылмаган без бер фәкыйрь,
Абыруем артык юк, эшем такыр.
Яшьтә җыйган бер буаз мәҗмәгым[1] бар,
Аның да кайбер җире какыр-макыр.
Ул заман китап кайда бу замандай,
Йөримен тирән йирдән су алалмай;
Бер иптәш калын китап тотып торса,
Кызыгып, мин фәкыйрьнең күзе аландай.
Үгәй ана кулында ятим калдым,
Андан да бик эрәтем китеп калдым.
Өстемдә керле күлмәк, ертык чалбар,
Кайда мелла бар дисә,— йитеп бардым.
Фәкыйрьлектән артык фән күрә алмадык,
Шәһәр чыгып, ерак юлга йөрә алмадык;
Мәргәннәрне таныйрлык хәлемез бар,
Шул сәбәбдән сабыр кылып тора алмадык.
Аз гына дәресем бар кыш вакытда,
Китап карау — гадәтемез буш вакытда;
Бездән дә фәйзъ бабы[2] бикләнгән юк —
Аңлыймыз кәеф килгән хуш вакытда...

*

Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән,
Анчә күз алартмаңыз хиддәт[3] берлән...
Һәр фәндә шигырь менән китаб тулы,
Карасак, ияләре нинди олы!..
Шигырь дөрест — нәсыйхәтне хамил булса[4],
Иясе кадәри халь гамил булса[5];

---

[1] *Буаз мәҗмәгым* — калын (дөньяга чыкмаган, басылмаган) җыентыгым.

[2] *Фәйзъ бабы* — белем һәм бәрәкәт ишеге.

[3] *Хиддәт* — ачулану.

[4] *Хамил булса* — йөкләгән, күтәргән булса, үзендә йөртсә.

[5] *Гамил булса* — эшләүче, гамәл кылучы, фикер йөртүче булса.

Ишеткән адәмнәрне елаткандай,
Вәгазь менән гыйбрәтне шамил булса[1].
Киткәннәр нинди ирләр гәүһәр сачып,
Аларның эшләренең юлы ачык.
Гаҗәеб кыйммәт әсәр калдырганнар,
Хикмәт хәзинәсеннән юллар ачып.

*

Бәрадәр, сезгә үтенәм сәлам язып,
Күзең сал: Мәрҗани — ул Тимер казык[2]!
Булмаса, кыйбла тапмай адашырсың,
Караңгыда җүн белмәй юлдан язып!
Имгәнеп, коры, бушка азапланма,
Бакыр чыкмас урыннан алтын казып!..
Керләсәң — һәр нәрсәне карайтырсың,
Көнчесез андый фазыйл ничек торсын?
Истамбул, Мисыр, Шамда[3] тиңдәше юк,—
Кышкар, Казан, Дагыстан болай торсын!

*

Курса хәзрәт[4] алардан борын булган,
Мактауга ул бер лаек урын булган,
Ул, мәрхүм, Мәрҗанидәй мәфтүн булып[5],
Күп галим ул газизгә кырын булган...

*

Адәм камил булмады кайнап пешмәй,
Мәхәббәт касәсеннән шәраб эчмәй.

---

[1]*Шамил булса* — эченә алган, үзенә җыйган булса.

[2]*Тимер казык* — Тимер казык йолдыз, һәрвакытта Төньяк котып ягына күрсәтүе белән географик дүрт тарафны билгеләүдә файдаланыла торган табигый ориентир йолдыз (Поляр йолдыз).

[3]*Шам* — Сирия яки Сүрия.

[4]*Курса хәзрәт* — кеше акылына ирек таләп итеп чыккан фикер иясе Габденнасыйр Курсави (1776—1812), Ш. Мәрҗанинең рухи остазы.

[5]*Мәфтүн булып* — мавыгып, үз-үзен онытып, тәмам бирелеп.

Дошманнар тозагыны салып карый —
Тургайның тозагына лачын төшмәй.
Һавада ул — бер шоңкар, әйләнә очкан,
Без йөрәмез кара коштай эзләп тычкан...
Без сатдык меллалыкның коры атын[1],
Бездән артык яулыклы дөрест хатын;
Күңлемезне бер сындырып еламаймыз,
Уйланып гарасатның вәкафатын[2].
Ашкан бер галим чыкса — яманлаймыз,
Мәҗлесне гайбәт илән тәмамлаймыз;
Эшемез — йә мыскыллау, яисә хурлау,
Үземезне һәр гаебдән амандаймыз[3].
Яхшыны сүккән илән аты китмәс,
Яман сүзнең күңелдән даты[4] китмәс;
Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс!
Кыйшык ук, аткан менән, туры китмәс,
Күңелдән яман сүзнең куры[5] китмәс,
Котырган эт һава карап өргән менән,
Асманда[6] торган айның нуры китмәс!

* * *

Иң әүвәл кирәк нәрсә — иман дигән,
Ахирәт эшләренә инан дигән;
«Хода кичәр» дигән менән эш бетмәйде,
Иман шартын өйрәнмәсә — Ибан дигән[7].
Икенче кыйммәт нәрсә — күңел дигән,
Күңле бозык адәмнән түңел[8] дигән;

---

[1]Иске фикерле, фанатик муллалар күздә тотыла.
[2] *Гарасатның вәкафатын* — кыямәтнең киләчәген.
[3] *Амандаймыз* — исән кебек тоябыз, азат шикелле сизәбез.
[4] *Даты* — кере, табы.
[5] *Куры* — дуены, чүп-чары, пычрагы.
[6] *Асман* — күк.
[7] *Ибан* — Иван, ягъни рус кешесе була, мөселман түгел.
[8] *Түңел* — дүн, түн, йөз чөер.

Бозыкка җир өстеннән асты артык,
Булмаса күңел таза — күмел диган!
Өченче кыйммәт нәрсә — гакыл дигән,
Гакылсызда тәүфыйк ягы такыр дигән;
Аз эшкә ачуланып, динен бозар,
Иманын көферлеккә сатыр дигән.
Дүртенче кыйммәт нәрсә — шөкер[1] дигән,
Нигъмәткә шөкерсезлек — көфер дигән;
Җаткан җирдән «Ходай кичәр» дигән — хурлык,
Сәбәб эзләп, төз җул менән җөгер дигән!
Бишенче кыйммәт нәрсә — әдәб дигән,
Әдәб дигән — мәхәббәткә сәбәб дигән;
Көферлек әдәбледә тормагандай,
Әдәбсездә иман тору гаҗәб дигән.
Алтынчы кыйммәт нәрсә — сабыр дигән,
Сабыр кеше морадын табыр дигән;
Һәр эшдә сабырсызның төбе — хурлык,
Сабырсызлык башка бәла салыр дигән!..

* * *

Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен,
Эчтә тулып җатмасын сасык эрен.
Аһ, дәрига! Эч тазарсын, эч тазарсын,—
Булмаса, файда бирмәс коры белем!

* * *

Бирелдем мин яшьлегемдә угрылыкка[2],
Бу очратды мине бик зур ким-хурлыкка.

---

[1] *Шөкер* — Алланың биргән ризык-нигъмәтләренә, яхшылыгына шатлык, канәгатьләнү белдерү.

[2] Ятим үскән Мифтахеддинның мәдрәсәдәге тормышы ачлы-туклы үткән, күрәсең, кайбер вакытларда сорамый алырга да мәҗбүр булган. Шагыйрь шуларны искә ала.

Нәтиҗәдә Акмулла дип исем алдым[1],
Бу исем бүләк булмыш тугрылыкка.

* * *

Халь килсә, төрле фәнне күргән яхшы,
Камилләр катарына[2] кергән яхшы;
Урысча укып кына түгел белмәк —
Халь килсә, французча белгән яхшы!

---

[1] Шагыйрь халык арасында үзенең туры сүзлелеге, гаделлеге белән таныла, «Ак күңелле мулла», «Ак күңелле остаз» — Акмулла дип атап йөртелә башлый.

[2] *Камилләр катарына* — укымышлы, әхлаклы, камил-күркәм кешеләр сафына.

Габдрахман Ильяси

(1856—1895)

БИЧАРА КЫЗ

Драма

Ике фасыл[1], дүрт пәрдәдә

ӘШХАС[2]:

Биктимер — бер кара бай кеше.
Фәрихә — байның хатыны.
Маһитап — аларның бик матур кызлары.
Фатыйма — аларның асраулары.
Сәхибә — имче хатын.
Яучы.
Җантимер — бик бай кешенең углы, ямьсез, аңгыра.
Җанбай — яхшы гына галим бер егет.
Җанъяр — Җанбайның дусты.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче фасыл

Маһитап *(ялгыз)*. Аһ, һавалар, аһ, мәхлуклар... йа кадир Алла! Аһ, бәнем әхвәлем... *(Бу вакытта Фатыйма керер.)* Сандугачлар сайрый, агачлар яфракка бөреләнә, нәфис хуш җилләр исәдер.

---

[1] *Фасыл* — бүлек.
[2] *Әшхас* — катнашучылар.

(Бераздан соң янә.) Аһ, галәм көннән-көн үзгәрәдер. Ләкин бәнем хәлем ничек үзгәрер: кояш чыгуы кебиме яки кояш батуы кебиме?

Бу сүзләрне тәмам кылганда Ф а т ы й м а килеп:

Ф а т ы й м а. Кояш ба-а-атуымы, белмим.

М а һ и т а п. Һай, оятсыз, нигә юрыйсың?

Ф а т ы й м а. Туташым, бәгърем, юрамаска, шулай булырга охшагач *(дип, Фатыйма чыгар).*

М а һ и т а п *(бераз уйда).* Аһ, бу Фатыйма, йөдәдем бу Фатыймадан... Бер сүзнең ахырын сөйләп бетерми, пыр итеп чыгып китә, кешене хафага салып. Тукта, чакырыйм, сорыйм әле. Фатыйма! Фатыйма! Һай, чукрак, Фатыйма!!!

Ф а т ы й м а керер.

М а һ и т а п. Ух, калмады кычкыра-кычкыра тамагым. Фатыйма, җаным... Әйт, җаным, бая гына ник «шулай булырга охшагач» дидең. Әллә бер-бер хәбәр ишеттеңме?

Ф а т ы й м а *(хафаланыбрак).* Ни... ишетми ни, йә... Сезне бит Тимербайның углы Җантимергә бирәләр, имеш, дип, халык өстенә таралган.

М а һ и т а п. Булмас! Аһ! *(Башын тотар. Бу вакыт Фатыйма чыгып китәр.)* Аһ, аһ! Расмы икән бу эш? *(Егыла. Бераздан торып.)* Бакчы син, мине шул кабахәткә бирергә. Әгәр бу эшләр була калса, мин ни эшләрмен? *(Дип егыла.)* Ааа... аһ, күрәлем[1], нәйләр[2], нәйләрсә, гүзәл әйләр. *(Бу арада анасы Фәрихә керер, Маһитап бераз караңгырак.)*

Ф ә р и х ә *(кызына карап).* Кызым, ни булды сиңа, авырыйсыңмы әллә?

М а һ и т а п. Юк... юк... әни, авырмыйм...

Ф ә р и х ә. Юк, кызым, авырый торгансыңдыр... тукта, Сәхибә абыстайны алдырыйм *(дип чыгып китәр).*

М а һ и т а п *(торып).* Ха-ха-ха... Әни мине авырый дип белде. Мин авырмыйм. Миңа ир зәхмәте тигән, кайсыдыр Сәхибә

---

[1] *Күрәлем* — күрермен.
[2] *Нәйләр* — ни эшләр, ни итәр.

абыстайның файдасы тими аңа... Аh, Раббем, мин нәрсә күреп көләмен?.. Юк, Маhитап, көлмә, көлмә, ела, ела!.. *(Еглар.)* Уф, мине... Җантимергә бирсәләр? Мин ни эшләрмен? Юк, юк, бармам... бармам... Минем ризалыгымнан башка бирмәсләр. *(Көзге каршысына барып, көзгегә карап.)* Аh, гүзәл кыз, гүзәл кыз... Чынлап укмы син шул кабахәт Җантимер куенында булырсыңмы? Аh, минем бу сөалемә[1] җавап бирүче бер дә юк... Аh, җавап, җавап! Ярабби, синнән башка мәдәт[2] сорый торган зат юк... Ярабби, барча галәмнең халигы[3] син, син... син, синнән башка юк, Раббем!.. Рәхмәтеңнән ташлама, ярабби!

Бу арада имче хатын С ә х и б ә керер.

С ә х и б ә. Аh, Алла, әстәгъфируллаhелгазим... Әстәгъфируллаhелгазим... Һай, бик каты авырый икән! Җен зәхмәтедер, ахры... Бик кычкыра икән *(дип, кызның янына барыр)*. Бәбкәм, кай төшең авыртты?

М а h и т а п. Кит, шайтан, бер җирем дә авыртмый!

С ә х и б ә. Чү, чү, чү... *(Дип, кызның башын тота.)* Әйшә-Патыйма кулы[4], минем кулым түгел.

Маhитап башыннан Сәхибә кулын ала.

М а h и т а п. Үз кулың ич *(дип алып ташлар)*. Әби, мин саташмадым да, авырмыйм да... Әби, зинhар, миңа рәнҗемә, сезне орыштым.

С ә х и б ә. Юк, кызым, юк... Рәнҗемим, бәбкәм.

М а h и т а п. Әбием, җаным, кил, утыр... Мин синнән бер сүз сорыйм: син карчык кеше, дөрес әйтерсең.

С ә х и б ә. Сора, кызым, әстәгъфирулла, ялган сөйләргә.

М а h и т а п. Әби, син кияүгә бардыңмы?

С ә х и б ә. Бардым, бәбкәм...

---

[1] *Сөаль* — сорау.

[2] *Мәдәт* — ярдәм.

[3] *Халигы* — яратучы, бар итүче (дини).

[4] *Әйшә-Патыйма кулы* — гади кул түгел, «изгеләр кулы», «ярдәме тия торган кул» мәгънәсендә. Имче карчыклар шул сүзләрне әйтә торган булганнар.

Маhитап. Үзең яратканга бардыңмы? Көчләп бирделәрме?

Сәхибә. Үзем сөйгәнгә бардым.

Маhитап. Ничек?

Сәхибә. Менә, кызым, мин сиңа сөйлим. *(Үзе як-ягына караныр, үзе борынын сөртер.)* Менә бервакытны мине әниләр кияүгә бирәселәре булды. Карыйм... Карыйм... болар мине икенче кешегә бирәләр. Күрдем, эш болай ярамый. Бервакыт этиләр, әниләр уракка чыгарга хәзерләнәләр иде. Мин башымны авыруга салып калдым. Әни әйтте: «Алайса, кызым, менә мин чыкканда Хәбибе абыстайга әйтә китәрмен, синең яныңа иптәшкә керер»,— дип чыгып киттеләр. *(Янә авызын сөртеп алыр.)* Шуннан Хәбибә абыстай килде. «Әби, исән килдеңме?» — дидем. «Аллага шөкер»,— диде. Безнең авылда Хәбибә абыстайдан яхшы хатын юк иде. Алла рәхмәтен итсен бичарага. Шуннан соң, сүздән-сүз киткәч, мин үземнең хәлемне әйттем. Хәбибә абыстайның шундыйга азрак осталыгы бар, диләр иде. Хәбибә абыстай әйтә: «Кызым, миннән бер яхшылык булсын, мин сиңа бер эш ясыйм»,— дип, бернәрсә өшкереп бирде. Аннан соң бер дога бирде: «Боларны, иртә белән этәч кычкырганчы, бусагага кыстыр»,— диде. Мин шуны шулай эшләдем. Хәбибә абыстайга бер оч киндер дә бирдем. Шуннан соң син күр дә мин күр... Этиләр, торган җирдән кайтышып, үзем теләгәнгә биреп куйдылар. Мәрхүмә рәхмәтле Хәбибә абыстай шул эшне миңа да өйрәтте. Менә мин шуны үзебезнең авылда бер кызга ясап биргән идем, кул белән койган кебек булды.

Маhитап *(тез чүгеп)*. Әби җаным, ана бул, миңа да яса!..

Сәхибә. Ярый, бәбкәм, хәзер, тәhарәтем дә бар *(дип, почмакка барып утыра)*.

Маhитап. Аh, Алла, ниләр кылам... ниләр кылам... никадәр гөнаh кылам... Дога, дога! Доганы бусагага куярмын... әй Раббем...

Сәхибә хәзерләп бирер. Маhитап кием шкафыннан бер асыл күлмәк алып бирер, Сәхибә китәр.

Сәхибә. Хуш, кызым, минем кулым түгел, Әйшә-Патыйма кулы. Хәерле сәгатьтә булсын! *(Чыгар, Маһитап бер кулындагы әйбергә карап, бер имче хатынның юлына карап калыр.)*

Пәрдә төшәр.

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Биктимер байның залы. Яхшы бер йорт күренер. Биктимер бай язу өстәле янында, аның янында хатыны утырадыр.

Фәрихә. Йә, сиңа әйтәм, яучы килсә ни әйтим?

Биктимер. Ни әйтәсең килмәгән яучыга...

Фәрихә. Фатыйма, Сәхибә әбине чакыра барганда, Җантимерләрнең капкасы төбендә асраулары белән сөйләшкән. «Бүген сезгә яучы җибәрәләр»,— дигән. Шуңар күрә әйтәм. Син базарга чыкканда килсә, мин ни әйтергә дә белмәм дип әйтүем.

Биктимер. Ни әйтерсең, тәвәккәлләп бирербез.

Фәрихә. Соң, сиңа әйтәм, Маһитап яратырмы икән? Уртарак, диләр.

Биктимер. Тагы кемгә бирмәкче буласың?

Фәрихә. Соң, миңа Маһитап шулай дип әйтсә, дип әйтәм.

Биктимер. Мин риза булгач, әйтмәс!

Бу арада Фатыйма керә.

Фатыйма. Бикә абыстай, яучы килде.

Биктимер. Яхшы, хатын, мин чыгып торам *(дип, чыгып китәр)*.

Фәрихә. Бар, әйт, керсен.

Яучы керә. Фатыйма артыннан керер.

Яучы. Уф, ух, уф, ух... баскычыгыз бик биек икән, уф, тыным бетте. Уф, уф, исән-сау торасызмы? Ух... йә, бер дога кылыйк. *(Дога кылалар.)*

Фәрихә. Әлхәмделиллаһ, бик исән торабыз, үзең исән-сау йөрисеңме?

Яучы. Шөкер, бик исән йөрим... Кара әле, кем... Фәрихә, ни хәлегез бар, ни ниятегез? Уф, кара әле, кем, Фәрихә, бу чакта

егетләр сайланган. Юньле кеше бер дә юк. Ух-ух-ух... Йөдәдем инде бу ютәл белән. Дару да итеп карадым. Ух-ух-ух, бер дә файдасы булмады. Егетнең ашавы-эчүе юк. Тәвәккәлләп бирү кирәк иде.

Фәрихә. Без, ахры, Аллага тапшырырбыз, истихарә[1] дә кылдырып карадык, ахыры хәерле булсын!

Яучы. Бик яхшы, бик яхшы... Насыйп булса, бу эшне озаклатмыйк. Сәфәр ае кергәнче булса иде.

Фәрихә. Иншалла, шулай итәрбез.

Яучы. Соң, шулай да кайчан дип әйтим?

Фәрихә. Алла боерса, үзем хәбәр итәрмен әле, бу арада кызлар җыймакчы булабыз. Шуннан соң бер килеп китәрсең.

Яучы. Йә, кем, бер дога кылыйк. *(Дога кылалар.)*

Яучы чыгар. Фатыйма озата чыгар. Фәрихә, Биктимер керер.

Фәрихә. Сиңа әйтәм, орышсаң орышырсың, мин вәгъдә бирдем инде.

Биктимер. Ник орышыйм, бик яхшы, бик яхшы.

Фәрихә. Тукта әле, сиңа әйтәм, бер йомышым бар әле. Кара әле, рөхсәт итсәң, кызлар җыяр идек, дип әйтәм.

Биктимер. Минем эшем юк, җыйсагыз җыярсыз! *(Дип чыгып китә.)*

Пәрдә төшәр.

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Җанбай йорты. Җанбай бүлмәдә өстәл янында газета карап утыра. Вакыт кич. Бу арада ишектән бәрәү керә башлар.

Җанбай. Кем бар?

Җанъяр. Җанъяр Болгатаев!

Җанбай. Һа, мәрхәба, дустым, рәхим итсеннәр!

Җанъяр. Әссәламегаләйкем, дустым, исәнме?

---

[1] *Истихарә* — төшлек салу. Бер эшнең соңы уңышлы булып-булмавын төштә күреп белү өчен дип, тәһарәтләнеп, намаз укып, йокыга яту яки шул йоланы башкаруны икенче бер кешегә тапшыру.

Ж а н б а й. Әлхәмделиллаһ, бик сәламәт, сезнең догагызда.

Ж а н ъ я р. Бер хәбәр ишеттем дә чыдый алмадым... Сезгә килеп әйтим дидем.

Ж а н б а й. Их, их... нәкъ Болгатаев син.

Ж а н ъ я р. Ха-ха-ха.

Ж а н б а й. Йә, сөйлә, ни ялганың бар?

Ж а н ъ я р. Менә бүген Биктимернең кызына кияү керә.

Ж а н б а й. Һе, син шул эч пошыра торган сүз сөйләрсең.

Ж а н ъ я р. Син тагы кеше өчен кайгырасың.

Ж а н б а й. Гаҗәп кеше син, мин дә кайгырмыйм, кызларның ата-аналары да кайгырмасын, алар өчен кем кайгырыр? Безнең халыкка бай булсын, бай булса, бар да ярый.

Ж а н ъ я р. Вакыйган[1], бик дөрес әйтәсең. Ярый, хуш, минем барасы җирем бар. Хуш. *(Чыга.)*

Ж а н б а й *(аягүрә торыр. Арлы-бирле йөрер. Үз-үзенә).* Ах Алла, дөнья бу, дөньяда ниләр булмый. Безгә яхшы әле. Бакчы, бүген Маһитапка зиндан[2], зиндан! Бак, нинди хафа, бичара, юк аны кызганучы. Ник башка кеше кызгансын аны, үзенең ата-анасы кызганмаганны... Аһ, бәгърем, берәү дә кызганучы юк. Юк, юк, мин кызганам, мин кызганам, мин кызганам... Юк, тукта... *(Бераз уйлап.)* Ни булса да булыр, бер эш кылырмын. *(Чыгып китәр.)*

Пәрдә төшәр.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Биктимер байның залы. Утлар яндырылган, кияү урыннары хәзерләнгән. Бер асыл чаршау янында, чаршауга кереп, Маһитап утыра. Ишекне әкрен генә ачып, Ж а н б а й килеп керә.

Ж а н б а й. Аһ, җаным, соңга калмаган икәнмен.

Бу арада, кияү килде бугай, дип, я у ч ы килеп чыгар, икенче ишектән яучы килеп, Җанбайны күрер.

Я у ч ы. Чү, җаным, бу ни хәл? *(Дип, бик җәһәтләп чыгып китәр, җиңнәрен селкеп. Җанбай әкрен генә килеп кызның чаршавын ачар.)*

---

[1] *Вакыйган* — чынлап та.

[2] *Зиндан* — төрмә.

Җанбай. Аһ, бәгърем, мин сине бу зинданнан коткарырга килдем. Зиндан бу сиңа! Зиндандыр, бак, кара миңа!..

Маһитап *(Җанбайның муенына асылынып)*. Аһ, җаным, рас әйттең. Аһ, ни кылыйм?

Бу арада Биктимер, Фәрихә, яучы, Фатыйма кереп, кызның кочаклашып торганын күреп, хәйран булалар...

Җанбай *(Биктимергә карап)*. Һай, зөбани[1]! Һай, җәллад[2]! Ни кылдың үзеңнең газиз балаңа!

Бу арада Фәрихә килер.

Фәрихә. Чү, җаным, бу ни эш?

Җанбай. Һи, зәнки[3], бәдбәхет[4], кит!!! *(Янә Биктимергә карап.)* Һи, һи, һи, җәллад!!! Син, син җәллад!!!

Бу арада кияү Җантимер килеп керер, кергәндә сөртенер, үзе ямьсез һәм исерек.

Җантимер. Ааа... Кая кияү-ү-үне каршы алмыйсыззз... *(Җанбай белән Маһитапның кочаклашып утыруларын күрер дә.)* Әй, син, минем хатынны ник алдың?

Җанбай. Кит! Бәдбәхет!.. Әнә синең хатының... *(Дип, асрау Фатыйманы күрсәтер. Җантимер Фатыйма янына бара башлар, алпан-тилпән.)*

Яучы. Юк, юк, бәбкәм, әнә шул синең хатының *(дип, Маһитапны күрсәтер, Җантимер янә килә башлар)*.

Җанбай *(кияүгә)*. Кит!!! *(Бу вакыт Маһитап Җанбай куенына тагын да кереп.)*

Маһитап. Аһ, җаным, зинһар бирмә!

Биктимер. Аһ, оятсыз, хур иттең!

Җанбай. Һәй, һәй, җәллад, минме хур иттем? Син үзең җәллад! *(Маһитапка карап.)* Әй, бәгърем, хафа булма, һәрвакыт мин синең белән, дөньяда вә ахирәттә...

Биктимер. Кара, йөзе кара, ни әйтә.

---

[1] *Зөбани* — газаплаучы, дини мифологиядә тәмугта яндырып торучы газап фәрештәсе.

[2] *Җәллад* — баш кисүче, палач, бик кансыз, мәрхәмәтсез кеше.

[3] *Зәнки* — кара эчле, тупас, усал кеше.

[4] *Бәдбәхет* — әшәке, начар, явыз.

Җанбай *(Маһитапка карап.)* Котылырсың бу зинданнан, һай, җаным *(дип, маңгаеннан үбеп алыр).*

Биктимер. Кара, кара, ни эшли... *(Бу арада кияү, Фатыйма янына барып, аның белән уйный. Фатыйма төртеп-төртеп җибәрә. Биктимер моны күрә, кул селкеп, читкә карар. Кияү, әйләнеп-тулганып, янә Маһитап янына килер, килгәндә гаять исереклектән егылыр.)*

Җантимер. А-а, мине болай ясадыгызмы, мин, мин-н дә сезне бик кызык итим *(дип, «Та-та-ллак!» — дип кычкырыр. Бу вакыт Маһитап сискәнер).*

Маһитап. *(Җанбайны тагын да кочаклабрак).* Җаным, котылдым, аппагым! Мин синеке...

Җанбай. Бәгърем! *(Үбәр.)* Бәгърем. *(Үбәр.)* Минеке булдың! *(Үбәр.)*

Биктимер авызына бармагын куеп исе китеп торыр, башкалар да шулай булыр.

Пәрдә төшәр.

Тәмам.



Фатих Халиди

(1850—1923)

РӘДДЕ БИЧАРА КЫЗ[1]

Драма

Гакыллы приказчик мәслихәтсез югалтадыр үзенең гомерен.

Әсәр басмасына рөхсәт бирелде Петербургта 8 май 1888 елда.

КАТНАШУЧЫЛАР:

Мирза — бик фәкыйрь, ишек кагучы, түгәрәк сакаллы, карарак йөзле, яше 51 дә.

Сәлимә — Мирза хатыны. Түгәрәк йөз, ак битле, тулы гына. Яше 43 тә.

Хәлимә — Мирзаның кызы. Урта буйлы, сызылган кара кашлы, ак битле, энҗе тешле, озын кара чәчле, матурлыкта Зөләйхәи сани[2]. Яше 16 да.

Мәхүп — күрше хатыны. Чагыр күзле, тешләренә кара яккан. Даимән эше өйдән өйгә сүз йөртүдә, үзе бик көнче хатын. Яше 48 дә.

Биби әби — мәшһүр яучы да, әби дә була. Яхшы карчык. Яше 76 да.

Фәрханә — Әхмәт бай кызы. Бик һавалы, үзе шадра, курнос. Яше 21 дә.

Закир — Әхтәм бай приказчигы. Бик купшы, кызыл сакаллы, зәңгәр күзле. Яше 33 тә.

Әхтәм бай — фабрикант, ак сакаллы, кызыл йөзле, бик бай. Яше 64 тә.

---

[1] *Рәдде бичара кыз* — «Бичара кыз»ны кире кагу, кабул итмәү.

[2] *Зөләйхәи сани* — икенче Зөләйха.

Ә л и ф ә б и к ә — Әхтәм бай хатыны. Бик симез, гадәти буйлы, ачык чырайлы. Яше 59 да.

Ә п т е м — Әхтәм бай углы. Бик матур, тәүфыйклы, бик гакыллы. Яше 24 тә.

Ә х т ә м б а й л а р н ы ң а с р а у к ы з ы — яше 13 тә.

Х ә й р и — Әхтәм бай кучеры. Зур сакаллы, озын мыеклы. Яше 55 тә.

ФАСЫЛ ӘҮВӘЛ[1]

Беренче действие[2]

Пәрдә ачылыр.

Күренеше бер иске йорт. Түшәме бик тәбәнәк. Йортның эчендә бер иске кисмәк янә бер калайлап бетергән табак. Янә стенада бер шүрлек, ул шүрлектә ничә төрле иске кораллар. Янә йортның уң тарафында бер иске караватт. Ул караватта утыра бер хатын, исеме — Сәлимә. Ул хатынның бер генә кызы бар, исеме — Хәлимә. Йорт хуҗасының исеме — Мирза. Сәлимә хатын идән себерә, Хәлимә иске күлмәк кигән. Шул күлмәгенең ертыгын ямап караватта утырган Хәлимәнең инәсе сынар да.

(Х ә л и м ә ә й т ә, м о ң а е п):

Әни, актык инәм иде, Ходаем, ул да сынды, инде нихәл кылаем, әти дә тиз кайтмас инде... *(Дип, Хәлимә тәрәзәдән атасын карар да, ул арада, сискәнеп торып, мич артына керер дә):*

Әни, күрше Мәхүп абыстай берлә Биби әби кереп килә, минем күлмәгем ертыкны күрмәсеннәр. Әгәр, Хәлимә кайда, дип сорасалар, мич башында ята, башы авырып, дип әйт.

(А н а с ы):

Яхшы, кызым *(ди). (Ул арада Мәхүп абыстай берлә Биби әби ишектән керерләр дә, караватка утырып, фатихадан соң, Биби әби акрын гына әйтә):*

Нихәл, кызым Сәлимә, исәнме? Мирза исәнме, нихәлегез бар? Кая кызым Хәлимә, күренми дә.

(С ә л и м ә ә й т ә):

Әлхәмделиллаһ, Биби әби, бик сәламәтләрмез, эткәсе дә бик сәламәт, кызым Хәлимә дә бик сәламәт. Әле тик бераз башы

---

[1] *Фасыл әүвәл* — «беренче бүлек, беренче пәрдә» мәгънәсендә.

[2] *Действие* — күренеш, пәрдә.

авыртып, кичә кич йоклый алмаган иде, бераз йоклыйм дип, мич башына менеп яткан иде, йокыга да киткән.

(Б и б и ә б и ә й т ә):

Йә инде, Сәлимә, яшь вакытта хәзер авырыйсың да, хәзер тереләсең. Алай булса да, Сәлимә, яшь бала. Аллаһ бәхет берлән сәламәтлек бирсен.

(М ә х ү п а б ы с т а й ә й т ә):

Амин.

(С ә л и м ә ә й т ә):

Кара әле, Мәхүп, син Әхтәм байларга туйга баргансың? Әле бүләк бактыгызмы, нинди бүләкләр җибәргән, мәһәр нәрсәләре ничек? Инде байларның байларчадыр. Беркөн Мирза абзагыз ишетеп кайткан иде, егерме табын ирләр булган дип, хәйран калган идек.

(М ә х ү п ә й т ә):

И Сәлимә, син сорама, мин әйтмим! Инде ул мәһәргә килгән камзуллык, чатма тунлык, хәтфә, чук-чук энҗе димсең, ул кыйммәтле мрантиклар димсең! Кияү анасыннан егерме пар кырыклык алтын — чәч тәңкәсе өчен, ул башка бүләкнең хисабы юк, штук-штук асыл, ничә камзуллык ыштуф, ул, Сәлимә, төргәк-төргәк йон димсең. Төргәк-төргәк ситсы, ул пакет-пакет акчаның хисабы да юк. Көзгесе идәннән түшәмгә кадәр, тоташ калайлы сондык, бик зур, гаҗәеп-гараеп[1], эчендә фруктылар, һәртөрле ислемайлар инде, Сәлимә, әйтеп бетерерлек түгел. Тукта әле, Сәлимә, ул да торсын, шунда бүләк бакканда бай хатыннары сүзләшәләр, «аслиһи, нәслиһи»[2] дип: Әхмәт бай кызын Ислам мулла углына бирмәгән дип. Ул арада Мәхмүт бай хатыны Хәбибҗамал бикә гайрәт берлән әйтте: «Ник бирсен Әхмәт бай Фәрханәне Ислам мулла углына! Ахрысы, матур дип барырга, Фәрханә юләр түгел, матурлыгына кызыгып, бер ярлыга барырга. Ул теге «Бичара кыз» китабында әйткән: «Маһитапка туй булгач, кияү кергән кичне Маһитап, Җан-

---

[1] *Гараеп (гараиб)* — күрелмәгән, ишетелмәгән ят нәрсәләр, искиткеч әйберләр.

[2] *Аслиһи, нәслиһи* — асылы, төп чыгышы, нәселе.

тимер ямьсез дип, Җантимердән аерылып, Җанбайга, муллалыгы[1] бар, үзе дә матур, ярлы булса булсын, Җанбайга барам»,— дип язган. Мин, кунаклар, бу Маһитапның, ямьсез дип, бай егеттән аерылып, матур дип, бер ярлы егеткә барганына бер дә ышанмыйм. Ахрысы, бу була торган эш түгел. «Хатыннар сөяр байны, ирләр сөяр сауны»,— дигәннәр; «бай иргә бару бик кыйммәт, әгәр нәфсе теләгән кеше бай иргә баргач, кирәк булса, матур егетне табып була»,— дип, Мәхмүт бай хатыны елмаеп көлде.

(Б и б и ә б и әйтә а к р ы н г ы н а):

Тукта, Мәхүп, мин сезгә бер сүз сөйлим, мин яшь вакытта тумачи әни сөйли торган иде: Маһитап-Җантимерләр кыйссасыны, алар ул заманда булган икән, ул Маһитап үзе кечкенәдән усал булды, кыз чагында ук үзләрендә торган хезмәтчеләр берлән йөреп, Маһитапның аты-суы чыккач, бер юньле кеше алучы булмаган иде. Алай да Җантимер, үзе бик ямьсез булса да, бик гайрәтле егет иде, үзе бик байның углы иде. Маһитапның матурлыгына кызыгып, аты-суы чыкса да разый булып, ат иясенә килгәч аксамасын, мин аны тота белермен дип, Маһитапны алган иде. Җантимер кияү булып, ул кичне үк Маһитап янында Җанбайны күргәч, гайрәтлегеннән шул сәгать талак кылган. Ул теге «Бичара кыз» китабында язган Җантимер исерек иде, исереклектән белешми, Маһитапны кызык итим дип, талак кылган дигән. Юкса үзеңез уйлап караңыз, аек булса, ирләр, хатыннары янында кочаклап бер тәвәккәл ят ир күрсәләр, аермый нишләр? Гакыллысы булса үтерер дә, аеру түгел. Җантимернең Маһитапны аеруы гайне[2] гакыллылыгыннан. Ахрысы, әүвәл кичне үк бер ят егетне кочаклап утырганын күргәч уйлагандыр, дуңгызны кондыз итә алмам дип. Хәер, хәер, Мәхүп, ул торсын, тукта әле, Сәлимә, мин сиңа сөенеч берлә килдем. Хәлимә ишетмәсен, мине Әхтәм бай приказчигы Закир әнкәсе җибәрде сезгә, яучы итеп. Закир ишеткән икән кызның матурлыгыны. Закир әнкәсе әйтте, бу көн чакыртып,

---

[1] *Муллалыгы* — белеме.

[2] *Гайне* — нәкъ менә, тулысынча, нәкъ үзе.

бар, Биби әби, Мирзаларга яучы бул, Хәлимәне бирсеннәр, диде. Мин әйткән идем Закир әнкәсе Патыйга, Мирзалар фәкыйрьләр шул, дип. Закир әнкәсе әйтте, юк, Биби әби, Закир дәүләт сорамый, жалованиесе дә елга өч мең тәңкә. Инде үзенең дәүләте дә Әхтәм бай дәүләтеннән ким түгел. Бары матур кыз аласы килә.

(Мәхүп абыстай әйтә, бик көнләшеп, эче берлә сулап):

Җә инде, Сәлимә, бу чакта приказчиклар байлардан бай була. Әйдә, бик яхшы, Әхтәм бай бүләкләреннән ким булмас әле *(дип, Мәхүп аһ итеп эченнән уйлар: «Әйдә, тик Биби әби яучы булып йөрсен, мин мең хәйлә берлә туйларын бозармын»,— дип сулап җибәрер).*

(Сәлимә, кулы берлә яңагына таянып):

И Биби әби, белмисең, ахрысы, туй итәргә байтак эш кирәк, инде сездән яшерен-батырын түгел. Мирзагыз да шул ризыклык кына таба. Кыз бирә башлагач, үзенә күрә алды-арты дигән күк, ичмаса, бер каты да булмагач. Дус бар, дошман бар, бер матурлык берлә эш бетми.

(Биби әби әйтә):

Җә инде, Сәлимә, әле Закир Хәлимәне бер күрсен, Мирза берлә дә мәслихәт итеңез, юкса Закир әнкәсе яман сүз әйтмәде. Закир Хәлимәне күрсен, ахрысы алыр өчен харам түгел, яратса, туена да, барысына да акчасын үзем бирәм, диде.

(Мәхүп әйтә):

Җә инде, Сәлимә, аның өчен кайгырма, мең тәңкә бирер әле, Хәлимәне күрсен, харам эш түгел. Безнең әби әйтә торган иде, бабагыз мине бер чынаяк чәй эчеп алды, дип, ул гаеп түгел, пәйгамбәрләрдән калган эш.

(Сәлимә әйтә):

Яхшы, Аллага тапшырдык, атасы берлә киңәш итик, шул расходны да үзләре биргәч, чәче бәйләнгән булса белмәссең дә.

(Биби әби):

Яхшы, кызым Сәлимә, Аллага тапшырдык, яхшы сәгатьтә булсын, әүвәл-ахырысы хәерле булсын, Мирза берлә яхшылап

сүзләшеп карагыз, әгәр мәслихәт булса, көндез кереп чыгармын, өйләдән соң Закирны алып килермен, Аллага тапшырып. Закир керер, тәрәзәдән карар, Хәлимә тәрәзә яныннан узып китәр. Хуш, Сәлимә *(дип чыгар)*.

(Мәхүп абыстай, куанган булып):

Хуш, Сәлимә, бик һәйбәт инде, кызың Хәлимә менә дигән байга бара, минем кызым Гафифәгә дә шунда үземез күк бер фәкыйрь булса да ярар, тыныч урын булсын! *(Дип чыгар, Сәлимә хәйран булып калыр. Ул арада мич башыннан Хәлимә төшеп караватка утырыр да):*

Әни, Мәхүп абыстай бик күп сүзләр сөйләде, Мәхмүт бай хатыны ни дип әйтте?

(Хәлимә әнкәсе Сәлимә әйтә):

И кызым, Мәхүп — булган хатын, аның бай кардәшләре бар, һәрвакытта байлар мәҗлесенә дәшәләр. Аның ишеткәнен, күргәнен сөйләп бетерер хәл юк *(дип торганда, ишектән Мирза керер дә кычкырып):*

Ах! Кызым, мә, ал янчыкны, мә, тагын сиңа биш-алты клиндер алдым *(дип Хәлимәгә бирер, Хәлимә клиндернең берсен шарт итеп теше берлә сындырып алыр да):*

Алла, бик каты икән! Тешем сынар, имеш! *(Дип янчыкны чишеп, бакыр акчаны санар да):* Әти, кырык биш тиен монда *(диер дә Хәлимә янә әйтә):* Әти, кемнәрдә эшләдең бу көн эш?

(Мирза әйтә):

Әхмәт бай ике ишегенең күннәрен яматты. Кызым, алай да һай каты кеше Әхмәт бай, ике ишек төзәткәнгә барысы кырык биш тиен бирде; ярты гөрәнкә вак кадак та үзем алдым әле, барсына — кырык биш тиен.

(Хәлимә авызларын елмайтып сорый):

Әти, Әхмәт байның кызын күрмәдеңме, ничек, чибәрме?

(Мирза әйтә):

Күрдем, кызым Хәлимә, Фәрханә исемле икән, атасы дәшеп алды, исемене дә шунда белдем, бик чибәр кыз икән. Хәер, кызым, мин бай балаларының шунсын яратам, бик әдәпле булалар. Әдәплелекләре берлә кешегә күркәм күренәләр. Ул

безнең күрше Мәхүп кызы Әпипә күк әдәпсез түгел инде, Ходай күрсәтмәсен, кичә мин кайткан чакта, капка төбендә лач-лач сагыз чәйнәп, узган-барганга эт күк өреп, дәшми калмыйдыр *(дигәндә Сәлимә әйтә):*

Тукта, атасы, аларны сөйләшер вакыт булыр, әле бу көн итче Ваһап әнкәсе Биби әби килде, яучы булып Хәлимәгә *(дигәч, Хәлимә авызын тотып ишектән чыгып китә. Сәлимә, Мирза караватка утырып, Сәлимә Биби әбинең сүзләрен барын да Мирзага әйтә).*

(Мирза):

Хәерле булсын, әнкәсе, ахрысы, шул акча да бирсә, Закирга бирермез дә шул, үземез сәламәтлегемездә тапшырасыбыз килә, тәвәккәлләп. Әнкәсе, Биби әбигә әйтерсең, Мирза, Аллага тапшырып, риза булды диярсең *(дип. Мирза, янә коралларын алып, эшкә чыгып китәр. Мирза чыгуына Биби килеп керер дә караватка утырып әйтер):*

Нихәл, кызым Сәлимә, ничек киңәш, Мирза ни әйтте?

(Сәлимә әйтә):

И Биби әби, Мирзагыз ни әйтсен, ахрысы, ул да фәкыйрьлек берлә йөдәгән, үзенең исәнлегендә тапшырасы килә; кыз бала дигән нәрсәне саклавы бик кыен, атасы да шул, тәвәккәлләрбез шул, диде. Мәһәренә дә акчалай биргәч, диде. Аның акчасы безгә буласы түгел, үзенең туена тотасы, тик дус-иш алдында туйны да кеше туе төсле итәсе килә, диде.

(Биби әби әйтә):

И кызым, Мирза акыллы кеше шул. Замана бик авыр, дәүләтле кешеләр дә ах итеп туй уздыралар, бик яхшы, мин Закирны алып килим, хуш, Сәлимә *(дип чыгып китәр. Хәлимә өйгә кереп юынып сөлгегә сөртенер дә шәл ябынып келәткә чыгар. Ул арада Биби әби берлә Закир ишектән килеп керер дә башын матчага орып):*

Алла башым! *(Дип, Биби әби берлә караватка утырып дога кылырлар. Сәлимә арты берлә торыр.)*

(Биби әби әйтә):

Мөхәммәт Закир, мәхәббәтле күзең берлә кара тәрәзәдән,

Аллага тапшырдым, һәр икегезне бер-берегезгә мәхәббәтле күрсәтсен *(диер), (Закир тәрәзәдән карар. Хәлимә вак-вак атлап, йөзен күрсәтеп, тәрәзә яныннан үтәр. Закир, Хәлимәне күргәч, гашыйк булып, Биби әбигә карап әйтә):*

Биби әби, кыз миңа ошады, колак сөенечлеккә йөз тәңкә бирәм. Янә хәзер үзең күлмәклек асыл китерерсең *(дип, бумажникны ачып, йөз тәңкә акча бирер дә Закир Биби әби берлә хушлашып чыгар. Алар чыккач, Мирза да кайтып, Сәлимә, кыз, Мирза акчаны санап сөенеп утырганда, Биби әби бер эскәтергә төргән нәрсә алып ишектән керер).*

(Мирза):

Әйдә, Биби әби, хуш килдеңез.

(Биби әби утырып дога кылыр да, эскәтер чишеп, штуклы асылны бирер. Һәм поднос берлә фруктыны да бирер. Мирза, Биби әби, Сәлимә дога кылып, хәерле булсын диешеп, фруктыны капкаларлар да, ул арада Хәлимә мич артында, куанып, асылны карар).

(Биби әби китмәк булганда, Биби әбинең яулыгын Сәлимә сорап алып, фруктыны төйнәп бирер).

(Сәлимә әйтә):

Мә, әби, Ваһапның кечкенәләре бар, аларга күчтәнәч булыр.

(Биби әби әйтә):

Җә инде, Сәлимә, җитәр, оят булыр. *(Мирза куеныннан янчык чишеп, бер биш-ун тиен садака бирер.)*

(Биби әби, Аллаһеммә дип, бит сыйпар. Мирза да бер аягыны тезләнеп, бер аягыны басып, кулларын чаш-чош китереп, дога кылыр.)

(Биби әби):

Хуш, углым Мирза, Сәлимә кызым, сау бул, туйны кай көн икәнен үзем хәбәр бирермен. Бу көн Әхтәм бай хатыны Әлифәбикәдән Закир рөхсәт сорарга кушты әле, анда барам *(дип чыгар. Ул чыккач, Хәлимә дә мич артыннан чыгып фруктыны капкалар).*

Пәрдә төшәр.

Икенче действие

Икенче пәрдә. Әхтәм байның түбәнге этажы пулатта, контор ишекне кергәч, ишекнең ике ягында ике конторка, янә түрдә бер конторка, ул конторкада Закир утырыр, берничә телеграмма укып. Күрше хатыны Мәхүп абыстай, Сәлимәләрнең вәгъдә куйганнарыны белеп, бик көнләшеп, бик хафаланып, кара җилән бөркәнеп, Әхтәм байның конторына китәр.

Пәрдә ачылыр.

Әхтәм бай конторы, конторга Мәхүп килеп керер.

(Мәхүп әйтә):

Мөхәммәт Закир монда микән?

(Закир борылып карар да):

Нихәл, абыстай, ни йомыш? Закир без буламыз.

(Мәхүп әйтә):

Мөхәммәт Закир, инде сез булсагыз, гаеп итмәсәгез, мине сиңа Әхмәт бай хатыны Асылбикә абыстай җибәрде, сәлам әйтте. Янә әйтте, әйт Закирга, дөрес җавапны бирсен, диде. Мин бу арада күрдем Закирны ишек кагучы Мирзаларга килеп киткәнен, әллә югыйсә Мирза кызы Хәлимәне алырга йөри микән, бар, Мәхүп, Закирга әйт, диде, мин Закирны кызганам, кечкенә вакытта бездә самавыр куеп торган иде, мин аны үз балам күк күрдем, диде. Ул Хәлимәнең төсенә карап кызыкмасын, аның бик начар эшләре бар, диде. Балалар авыруы димсең, ташка үлчим, тфү, төче зәхмәтеме димсең, диде (*шулай дигәч,* Закир әйтә):

Юк, абыстай, мин ишек кактырмакчы идем, шуның өчен барган идем, хәер, Мирзаның кызын күрдем, бик чибәр икән.

(Мәхүп әйтә):

И Мөхәммәт Закир, чибәр-ни түгел әле, теге «Бичара кыз» китабында язган имче Сәхип әби Мәһитапка өшкереп язып бер дога биргән, бусагага кыстырырга дип, шуның күк кызның әнкәсен буш кеше димиләр, юкса кыз чибәр-ни түгел, бер-бер хәл иткәннәрдер, шуңар синең күзеңә чибәр күренгәндер, чибәр кызлар бар ул. Менә кыз, менә кыз, менә кыз, менә кыз шәһәр-

дә бер дип әйтсәң буласы, безнең Асылбикә абыстай кызы Фәрханә, ул матурлыкка димсең, корпус димсең, ул укымышы, менә кыз, менә кыз. *(Закир Фәрханәне мактаганын ишеткәч, сакалларын сыпырып, мыегыны авызына кабып карап уйлап торды. Мәхүп, бу хәлне күреп, сөенеп, боларның эшләрене бозам дип көлемсерәп әйтте):*

Әле, Закир, без сине уйлый торган идек, безгә Фәрханәгә кияү булыр дип, чөнки Ислам мулла углына бирмәй калулары да уйлары сездә дип. Фәрханә үзе дә синең узган-барганыңны карап кына тора. Әхмәт бай үзе дә сине мактап сөйли, Әхтәм байның бар фабрик эшләрен караган да Закир гына дип.

(Закир сорады):

Соң, абыстай, сезне кем дип белик?

(Мәхүп әйтә):

Минем исемем — Мәхүп, мин Фәрханә янында торам, Әхмәт байның түрендә генә, Асылбикә абыстайның киңәшчесе мин.

(Закир әйтә):

Алай булса, Мәхүп абыстай, инде син үзең рәтләп, Асылбикә абыстайга әйт, мин Мирза кызын вәгъдәләшкән идем, йөз сум акча биргән идем, мин инде, Асылбикә абыстай мәслихәт күрмәгәч, вәгъдәмнән кайтам.

(Мәхүп әйтә):

Алар кайтарырлармы соң йөз сум акчаңны?

(Закир әйтә):

Тфү, төкерек миңа йөз сум акча, әгәр ашасалар да. Инде син Асылбикә абыстайга әйт, рәхмәт безне исеңдә тотып, безнең өчен тырышканга, юкса минем беркемем дә юк. Әни безнең — бер сала карчыгы, бернәрсә дә белми, дус-ише юк, абыстай үзе һәрвакытта догада була күрсен *(дип, бумажникны ачып)*:

Мә, Мәхүп абыстай, бераз мәгәрич, яхшы хәбәрләр китергәнеңә ун сум, янә, Мәхүп абыстай, инде үзең Фәрханәне булдырырга тырыш, бу ун сум берлә калмассың.

(Мәхүп әйтә):

Закир, оят булмаса инде, бик күп ун сум да, юкса ул Фәрханә сезнеке инде, аны бер дә уйламагыз, хуш, Закир!

(З а к и р д а):

Хуш, Мәхүп абыстай, һәрничек булса да Асылбикә абыстайдан догаларын үтен *(диер, Мәхүп чыгар. Закир үз-үзенә әйтә):*

Менә син, Алла коткарды лабаса, мин юләр булганмын, юкса бер җимерек өйдә ни күреп үскән ул кыз, аннан ни хәер күрмәк кирәк, ни сүзеннән рәхәт күрмәк кирәк, ни үзеннән, бер-бер затсыз кыз, ахрысы, борынгылардан калган сүз бар да дөрес: «Асылынсаң асылын агачның асылына»,— дигәннәр. Менә син кызык, харап була яздым бит, матур дип бер ярлыны алчы. Корсын матурлыгы, ямьсез булсын, бай булсын. Фәрханә кемнән ким: бары борыны җимерек тә, бераз шадрасы бар, ул да булса әллә ничек мәхәббәтле, кечкенә чагында ук мине сөя торган иде *(дип куанып торганда, ишектән Б и б и ә б и килеп керә).*

(Б и б и ә б и ә й т ә):

Әй Алла, шул байларның баскычы бик биек, тыным бетте, әй ютәл, бу картлык. Нихәл, Закир, мин югартын Әлифәбикә яныннан төштем. Әлифәбикә бик яратты, Әхтәм абзагызга үзем әйтермен, туен да үземездә итәрмез, диде. Хәлимәне кечкенә чагында матурлыгыны күреп, хәйран калган идем, бик яхшы, диде.

(З а к и р ә й т ә):

Хәер, Биби әби, инде мин ул эштән кайттым, бар, Мирзаларга әйт, асыл берлә йөз сумны кайтарып бирсеннәр, миңа сихерче кызы кирәкми.

(Ә б и ә й т ә):

Ул ни дигән сүз, Закир? Мирза хатыны — бик тәкъва хатын!

(З а к и р ә й т ә):

Хәер, Биби әби, минем сүзем бер булыр, кайттым дигәч кайттым, кирәкми, юк, миңа зыяндашлы, янә череп сасып беткән төче зәхмәтле кыз. Кирәкми. Хатынсыз торсам торам, андый черегән кыз алмам!

(Б и б и ә б и, х ә й р а н б у л ы п):

Ах Алла, бу нинди эш булды бу, патшаларга ярарлык кыз, сезгә килеп нинди шайтан яманлаган!

(З а к и р ә й т ә):

Хәер, әби, юк инде, кайттым, тәгаен ничек икәнен белдем, гаеп итмә, Биби әби, сине өшәндердем.

(Б и б и ә б и ә й т ә):

Юк, Закир, мин өшәнмим, ай-һай хата итәсең, пешкән эш иде, ахыры хәерле булсын *(дип чыгар. Закир шалт-шолт чут салырга тотыныр, пәрдә иңәр).*

Өченче действие

Өченче пәрдә. Мирза өе чыгар. Пәрдә ачылыр. Мирза, Сәлимә, Хәлимә сөенешеп утырганда, ишектән Б и б и ә б и керер.

(М и р з а ә й т ә):

Хуш киләсең, Биби әби! *(Сәлимә башындагын алыр, Биби әби караватка утырып дога кылыр да):*

Исәнмесез барыгыз да, хәерле булсын ахырысы. Мирза, мин сезгә күңелсез эш берлә килдем, изге эшкә шайтан керә, дигәннәр, бар да рас, белмим кем барып яманлаган Закирга Хәлимәне, зыяндашлы, янә череп, сасып беткән, төче зәхмәте берлә һәм әнкәсе дә сихерче икән дип. Закир ышанган, мине җибәрде, бар Мирзаларга, кайтарсыннар минем асыл берлә йөз сум акчаны, диде. Мин, Мирза, Аллаһ шаһит, шулкадәр Закирны үгетләдем, һич үгетем кабул итмәй, әгәр кайтарып бирсәләр бирерләр, бирмәсәләр ашасыннар, диде.

(М и р з а, г а й р ә т б е р л ә а я к т и б е п):

Сәлимә, бир акчасыны, Хәлимә, бир асылыны! Минем башта ук әллә ничек күңелем бик разый булмаган иде. Син шул, Сәлимә, туена да, барына да үзе бирә дип әйттең. Юкса аның баеннан урлап җыйган акчасына кызыкмыйм *(Сәлимә акчасыны бирде, хафа берлә Хәлимә асылны).*

(Б и б и ә б и):

Хуш, Мирза, хуш, кызым Сәлимә, Аллаһ Тәгалә бәхетен яры кылсын, иншалла, хәергәдер әле *(дип чыгып китәр).*

(С ә л и м ә к а р а в а т к а я т ы п к ы ч к ы р ы п е г л ы й):

И Ходаем, үзеңә мәгълүм, сихернең нәрсә икәнен белмәдем, сихерче дип гаеп табып, кызыма килгән вәгъдәне кайтардылар, бу ни гөнаһым шомлыгы, Ходаем?

(Х ә л и м ә е г л ы й):

И Ходаем, бу ни гөнаһым, Илаһым, үзеңә мәгълүм, атамнан гайре ир йөзе күргәнем юк иде, һичбер авыру күргәнем юк, бакчы, минем өчен анамны да сихерче дигәннәр, Ходаем, өебезгә кергән хатыннар, кызлар җаныма килсә, әйтә торганнар иде, Хәлимә, нинди ислемай сөрттең, синнән гел май исләре килә, дип. Инде бу көн ишеттем: череп, сасып беткән дип.

(М и р з а й ө р и - й ө р и З а к и р н ы т и р г и):

Бәдбәхет, авылда бәрәңгегә туймый үскән нәрсә, ниләр әйткән булып йөри, имеш *(дип, болар: Мирза, Сәлимә, Хәлимә хафа булып өйалдына куйган самавырларыны онытканнар, самавырдан ут үрләп, боларның өй стенасына кабар, бер заман пожарный чабышып килеп, боларның өйләрен ватып, утны сүндерерләр. Болар көчкә тәрәзәдән чыгып калырлар, ул арада базар халкы утны тамаша кылырга килерләр. Шунда Әхтәм байның углы Ә п т е м килер. Закир берлә Әптем Хәлимәне күреп гашыйк булып, Закирдан сорады):*

Бу кем йорты? *(Дип.)*

(З а к и р ә й т ә):

Бер ярлы, ишек кагучы Мирза йорты *(диде).*

(Ә п т е м ә й т ә):

Закир, бу матур кыз кем кызы?

(З а к и р ә й т ә):

Шул Мирза кызы *(диер дә, болар кайтырлар, пәрдә төшәр).*

Д у р т е н ч е д е й с т в и е

Дүртенче пәрдә. Әхтәм байның гостиные чыгар. Озын өстәл, өстәлдә өч тәлинкә, өч кашык, өч чәнечке, өч пычак, аш хәзерләгәннәр.

Пәрдә күтәрелер.

Ә х т ә м бай чыгып утырыр, Ә л и ф ә б и к ә чыгып утырыр, Ә п т е м чыгып утырыр.

(Ә л и ф ә ә й т ә):

Әптем, пожар кайда булды?

(Ә п т е м ә й т ә):

Ишек кагучы фәкыйрь Мирза йорты янды.

(Ә л и ф ә ә й т ә):

Безнең яңа кода икән.

(Ә х т ә м ә й т ә):

Ул ничек кода тагын?

(Ә л и ф ә ә й т ә):

Бүген Биби әби рөхсәт сорый менгән иде, Закир аның кызы Хәлимәне вәгъдәләшкән. Биби әби — яучылары. Әле мин, атасы, үзем сезгә әйтмәкче идем, әйдә алсын, бик чибәр кыз, мөфтигә бирсәң, оят килмәс, шундый кызы *(дип, Әптем бу сүзләрне ишетеп, колакларыны шәңкәйтеп калды, болар ашар. Ул арада Әхтәм бай әйтә):*

Әйдә, әнкәсе, бик яхшы, Закир үзе яраткач, миңа ярар. Югыйсә мин ул Мирзаны бик беләм, бик яхшы кеше ул, бары фәкыйрь, бичара *(дип ашап бетерерләр дә, Ә л и ф ә, Ә п т е м чыгар. Колокол кагар, а с р а у к ы з чыгар):*

Нихәл, Әхтәм абзый, ни йомыш?

(Ә х т ә м):

Бар, конторга төш, Закир менсен. *(К ы з чыгар, З а к и р менәр):*

Әссәламегаләйкем, ни йомыш, Әхтәм абзый?

(Ә х т ә м):

Закир, Мәскәүгә Карамановка телеграмма бир, бу көн пахта[1] акчасыны, йөз илле меңне, банкага перевод ясасын[2].

(З а к и р):

Яхшы, Әхтәм абзый, хәзер бирермез.

(Ә х т ә м ә й т ә):

Яхшы, Закир, бәрәкаллаһ, өйләнмәкче булган икәнсең. Әлифә абыстаң әйтте; бик яхшы, әйдә фәкыйрь булса, итагатьле булыр, кызны бик матур диләр. Мирза үзе — бик яхшы кеше, бары фәкыйрь.

(З а к и р ә й т ә):

Юк, Әхтәм абзый, алмакчы булган идем, инде кайттым.

(Ә х т ә м ә й т ә):

Һай юләр, ник кайттың, бик матур диләр кызны.

---

[1] *Пахта* — мамык.

[2] *Банкага перевод ясасын* — банкка күчерсен.

(З а к и р   ә й т ә):

Матурын матур, ләкин зыяндашлы һәм төче зәхмәтле диләр.

(Ә х т ә м   ә й т ә):

Һай Закир, алданма.

(З а к и р   ә й т ә):

Юк, Әхтәм абзый, мин бик расыны белдем, дөрес.

(Ә х т ә м   ә й т ә):

Хәерле булсын. *(З а к и р чыгар, Ә л и ф ә керер.)*

Нихәл, карт, Закир туйны кайчан итәсе килә?

(Ә х т ә м   ә й т ә):

Юк, әнкәсе, Закир кайткан, кызны зыяндашлы, төче зәхмәтле, сасып беткән дип. Мин әйткән идем, һай Закир, кеше вәсвәсәседер, дип. Закир әйтә, юк, бик тәгаенен белдем, диде. *(Әлифә хәйран булып калды. Әптем дә кереп, бу хәбәрләрне ишетеп, «Әлхәмделиллаһи» дип сөенеп торыр. Әхтәм бай намазга китәр.)*

(Ә п т е м   ә н к ә с е   я н ы н а   к и л е п   ә й т ә):

Әни, синдә бәнем бер гарызым[1] бар, зинһар, шул гарызымны кабул итсәнә. Әгәр син кабул итсәң, бәнем эшем була, әгәр син кабул итмәсәң, мин харап булам.

(Ә н к ә с е   Ә л и ф ә   к ө л е п   ә й т т е):

Ни гарызың бар, мәкъбүл[2] улым.

(Ә п т е м   ә й т ә):

Әни, шул Мирза кызын пожарда күреп гашыйк булдым. Зинһар, шул Хәлимәне миңа алып бир. Мин Закир күк түгел, ярар сасы булса да, ислемай күбрәк сөртәрмез *(диде)*.

(Ә л и ф ә,   к ө л е п):

Ярар, углым, сүз юк, ул кызга үзем дә гашыйк идем, ләкин әүвәл бер күрим, ничек икән авыруы, менә кызлар җыясым бар, шунда дәшим, күрим шунда.

(Ә п т е м   ә й т ә):

И әни, теге драм «Бичара кыз» китабында Маһитапка яучы йөргән чакта әнкәсе кызлар җыены ясамакчы булган, ясамый

[1] *Гарыз* — үтенеч, тәкъдим.

[2] *Мәкъбүл* — кабул ителгән, хупланган, яраклы табылган.

калдырган. Шуның күк, әни, син дә кызлар җыены җыям дип, җыймый калмасаң ярар иде.

(Әлифә әйтә):

И углым Әптем, шул юк драмнарны сүзләп утырма, бу көн өндәү чыгарам, минем, ахрысы, бер чакырып, кечкенә кодачаларны да өйгә кертәсем килә.

(Әптем әйтә):

Яхшы, әни, рәхмәт.

(Әптем чыгар. Бераздан кунаклар килер. Җәмгысы егермеләп кыз, араларында Әхмәт бай кызы Фәрханә дә булыр. Актыктан Биби әби Хәлимәне алып килер. Хәлимә ишектән кергәч, бар кызлар, Хәлимәне күреп, аяк үзәренә[1] торырлар, хәйран булып аның нурлы йөзенә. Хәлимә Әлифәбикә берлә күрешер дә): Исәнмесез? *(Әлифәбикә елмаер.)*

(Әлифәбикә әйтә):

Исәнме, кызым Хәлимә, анаң исәнме, бу арада сезгә зур каза булган икән, хәерле каза булсын. Әхтәм абзагыз бик кызганды, Мирза яхшы кеше дип. Ихтимал, йорт та салып бирер күк. Хәлимә, әллә бу арада авырдыңмы?

(Хәлимә әйтә):

Әлхәмделиллаһ, бер дә авырганым юк, бик сәламәт. *(Әлифә карар Фәрханәне дә, Хәлимәне дә, Хәлимәгә караган саен карасы килер. Бәгъдә[2] кунаклар торалар. Әхтәм бай кайтып керер.)*

(Әхтәм бай әйтә):

Нихәл, әнкәсе, сыйладыңмы кунакларны?

(Әлифә):

Бик яхшы сыйладым.

(Әхтәм әйтә):

Йә, әнкәсе, Әптемгә кыз күзләдеңме?

(Әлифә әйтә):

Һи карт, күзләмиләрме соң! Күрдем Фәрханәне дә, ятратмадым. Бер яхшы кыз юк бай кызлары арасында. Менә бер

[1] *Аяк үзәренә* — аягүрә.

[2] *Бәгъдә* — аннан соң, аннары.

кыз бар, әлеге Мирза кызы Хәлимә, матур, гакыллы, әдәпле, асыл сөякле. Әткәсе, син фәкыйрь димәсәң, Әптемгә мин шуны алыр идем. Әптем үзе дә шуны аласы килә. Юкса матурлыкта бу заманның Зөләйхасы дип әйтергә мөмкин.

(Әхтәм әйтә):

Соң, карчык, Закир аны сасы диде.

(Әлифә әйтә):

Юк, карт, Закирны ни дә булса берәү көнләшеп котырткан. Бернәрсәсе дә юк, тулган ай кук.

(Әхтәм әйтә):

Бик яхшы, бикә, син яратсаң, Әптем яратса, мин бик яратам, чөнки Мирзаны мин бик яратам. Әгәр хатын аласыгыз килсә, мин хәзер алдыраем Мирзаны. Барсын Хәйри кучер, дәшеп алып килсен.

(Әлифә):

Яхшы *(дип чыгып, Хәйри кучерны Мирзага җибәрер. Тиз заман. Мирза килеп керер ишектән, култыгында киндергә төргән кораллары бар).*

(Мирза):

Әссәламегаләйкем, Әхтәм бай, сәламәтләрме, ни йомыш?

(Әхтәм):

Вәгаләйкемәссәлам. Әйдә, Мирза, түрдән утыр, кода булырсың.

(Мирза әйтә):

Юк, бай, инде ул уйдан без дә кайттык. Закирыңыз хуш исле кыз алсын инде.

(Әхтәм бай әйтә):

Юк, Мирза агай, Закир өчен мин әйтмимен, җәмәгатем Әлифә синең кызың Хәлимәне бик яраткан, углым Әптем дә ярата, шуңар күрә әйтәм. Мин үз углым Әптемгә кызың Хәлимәне аласым киләдер. Әгәр, Мирза агай, син риза булып бирсәң.

(Мирза әйтә):

Хәер, Әхтәм агай, хезмәткәрең Закир вәгъдәләр куеп бер мыскыл иткән иде, инде сез дә шулай итмәкче буламсыз?

(Ә х т ә м б а й ә й т ә):

Юк, Мирза агай, мин алай итеп йөрергә яшь кеше түгел, бу сакалым берлә, Аллаһ сакласын, менә, Мирза агай, әле сезнең торыр җирегез дә юктыр, әнә минем түрдәге зур өйгә бүген төялеп килегез, иртә туй итәрмез, Аллаһ теләсә. Туй расходы, янә үзегезнең үлгәнчә тәрбиягез бәнеке булыр. Үзең эшкә дә йөрмәссең, намазга йөреп, безнең өчен дога кылып утырырсың.

(М и р з а ә й т ә):

Алай булса, Әхтәм бай, бик яхшы булыр иде. Аллаһ риза булсын, без фәкыйрьләрне тиң күреп, үзегезнең кабул иткәнегезгә.

(Ә х т ә м б а й ә й т ә):

Бар, Мирза, ишегалдыннан дворник берлә бер ат алып кит тә, хәзер төянеп килегез *(диер, Мирза, яхшы дип чыгып, бер җиккән ат, малай алып китеп, нәрсәләре һәм үзләре түрдәге агач өйгә төянеп килерләр.)*

Бишенче действие

Бишенче пәрдә. Әхтәм байның гостиниенда кунакларга аш хәзерләнгән. Янә аскы катта Әхтәм байның конторы күренер. Анда Закир.

Пәрдә ачылыр.

Югары катта гостиныйда Әхтәм бай кунакларны каршылый алыр, әйдәгез, кунаклар, бик яхшы килдегез, дип; шунда бәнарас[1] чапан кигән, аякта зәңгәр читек, башта ак бүрек М и р з а килеп керер, барча кунаклар, әйдә, кода, хуш килдегез, дип, түргә утыртырлар. *(Әмма түбән конторда Закир үз-үзенә йөреп сүзләшә):*

Йөзе кара Әптем, мине нишләтте, бәдбәхет, әллә ниндәй бер хатын җибәреп, Фәрханәдән дигән булып. Мин ахмак, бер хатын сүзенә ышанып, бер кешегә мәслихәт итмәенчә, беткән эшне бозып, бу йөзе кара Әптем хәйлә берлә миннән вәгъдәне кайтартып, Хәлимәне үзенә алды. Ах, ах, юк, юк, Әптемдә гаеп юктыр. Хәлимәне, мин вәгъдәсене кайтаргач, пожарда күрде.

---

[1] *Бәнарас (банарас)* — ярым ефәк юка ак тукыма.

Ахрысы, миннән шунда Әптем сорады, бу матур кыз кем кызы, дип. Юк, юк, бик хәйләкәр Әптем. Шул урамда уйнап үскән Мирза йортын белмиме соң ул. Тукта, ул Хәлимә миңа насыйп булмады, Әптемгә дә насыйп булмасын *(дип, конторка ачып револьвер алыр да аны корыр да, янә әйтә):* Әүвәл Әптемне атып үтерим, аннары үземне атып үтерим, ахрысы, үлүдән артык эш юк. Бөтен галәм халкы ишетте, Фәрханәгә ышанып, Хәлимәне кулыннан ычкындырды дип. Фәрханәнең уенда да юк икән. Ахрысы, Фәрханә Ислам мулла углына бармаганны миңа киләме. Фәрханә дә миннән көләр, үземне үзем атып үтерүдән артыгы юк. Хәер, әүвәл Әптемне үтерим. Ул рәхәттә калмасын *(дип, револьверын кесәсенә тыгар, ул кесәгә уңайсыз булыр. Әле кесәдә беленер, халык сизәр... дип, казаки астыннан кендек турысына биленә кыстырам дип маташканда, револьверның ялгыш чакмасы эләгеп тартылып атылып китәр дә Закирның күкрәгенә кереп, Закир егылыр, җан бирер. Кунаклар револьверның шартлаган авазын ишетеп, барысы да куркып, аяк үзәренә торырлар да, шулвакыт тәмам булып пәрдә төшәр).*

Ризаэддин Фәхреддин

(1858—1936)

ӘСМА, ЯКИ ГАМӘЛ ВӘ ҖӘЗА* (1903)

Габбас мелла

«Б...» авылы мәшһүр бер авыл улдыгы кеби, кәндесендә (үзендә) исеме ерак җирләргә китмеш күренекле бер имам бар иде. Кырык яшьләрендә булган бу имамның гаиләсе (җәмәгате) Гаишә исемле хатыны илә Әсма исемендә бер данә кыздан гыйбарәт иде. Габбас мелланың (имамның исемедер) башка балалары да улмыш исә дә, барысы да вафат улып, ялгыз ошбу кыз дөньяда яшәмәктә иде. Ошбу сәбәптән Әсма бу гаилә эчендә иң сәвекле бер җан иде.

Габбас мелла яшьлегендә гаять тә зирәк вә шат вә һәрнәрсәгә, вә һәрнәрсә кулыннан килер ки мөстәгыйт (сәләтле) бер бала иде исә дә, уйланылган, фараз ителгән кадәр камиллек кәсеп идә алмадыгы хәлдә мәдрәсәдән чыгып имам улды...

Мәгълүмдер ки, дөньяда бай балалары мал кадерен вә мөдәррис балалары гыйлем кадерен тиешле мәртәбә белмәсләр. Ләкин боның өчен мондый балалар гаепле улмай, бәлки бу

---

* Әсәр кыскартып алынды. Аңлашылмаган сүзләрнең кайберләренә автор үзе җәяләр эчендә аңлатма бирә барган. Язучының шул алымын саклаган хәлдә, тексттагы күп кенә сүзләр һәм гыйбарәләр төзүче тарафыннан хәзерге телгә күчерелде.

нәрсәләрнең хөрмәтене белерлек рәвештә тәрбия идә алмаклары вә шушындый тәрбияләргә игътибар итмәдекләре өчен аталар гаепле улсалар кирәк.

Габбас мелла, әгәр дә үзе кеби җиңел фикерле, дөньяга илтифатсыз бер хатынга тугыры килмеш улса, гомерене ахмаклар гадәте эчендә бозыклык дөньяларында кичермәк вә бөтен фамилиясенең олы, хөрмәтле исеменә дегет буяп, дөнья белән хушлашачак иде.

Ләкин җәнабе Илаһиның мәрхәмәте уларак, боңа гакыллы, тәкъва[1], диндар, булдыклы, мәрхәмәтле бер хатын җиңел туры килде.

Ошбу хатынның гайрәт вә тырышлыгы аркасында Габбас мелла да үзенә ябышмыш улан начар гадәтләрене берәм-берәм өстеннән төшермәгә вә табигый сәләт һәм зирәклеген хәрәкәтләндермәгә башлады...

Гаишә абыстайның тәрбиясе вә төн-көн улган тырышлыгы сәбәбеннән Габбас мелла һәрбер яңа вә иске китапларны, рус, төрки, гарәби газета вә журналларны укымага һәм дә бөек бер ихлас вә хирыс илә укымага башлады.

Әдәби, фәнни китаплар да Габбас мелланың холкыны төзәтмәк өчен күп ярдәм итте. Укыла, өйрәнелә торган китаплар адәм угылы өчен иң куәтле тәрбиячеләр идеке шөбһәсездер. (...)

Габбас мелла, белер өчен гайрәтле улдыгы кеби, белдекләре илә гамәл кылыр иде. Вәгазьләрне йомшак сөйләр, мисалларны ачык күрсәтер, ислам кагыйдәләрене гавам халкына саф вә ап-ачык аңлатыр иде...

Габбас мелланың янә бер олуг эше улды. Ул исә мәхәллә мәктәбе төзеп, бөтен авылда улган ислам балаларыны мәктәпкә җыеп дәрес бирер вә бу эшкә яраклы мөгаллимнәр билгеләп, балаларны алардан да укытып, белем бирдерер иде... (Бу урында Габбас мелланың мәктәптә яңа ысул — «осуле җәдидә» белән укыту кертүе турында язылa.— *Ш. С.*)

---

[1] *Тәкъва* — дин кушканны гына эшләү, диндар булу.

Габбас мелла бай кемсә дәгел иде. Ләкин тормыш-көнкүрешен сорыкорт тәртибенә куймай, бәлки, бал корты ысулына кормыш, ягъни үзе хәле җиттеге кадәр иген иктерер вә ханәсе янында улан җимеш багчасында Гаишә абыстай илә җәй көнендә эшләрләр иде.

Хатыны илә берлектә рәхәт-рәхәт сөйләшеп, мәзәк сүзләр әйтешеп, тәрбия әйләмеш багчаларының уңышы уларак чия, карлыган, җиләк кеби җимешләрен саттырып яхшы гына акча кәсеп идәрләр иде...

Гаишә абыстай, үз тирә-якларында шөһрәтле бер мөдәррис кызы улдыгы хәлдә, ни өчендер мәхдүм вә мәхдүмәләр[1] табигатенә тәмам башка бер табигатьтә вә анлар гадәтеннән башка бер гадәттә иде. Мәсәлән, гыйлемлек хөрмәтене белер, укыр һәм язар, иркәлек нәдер — белмәс, тәкәбберлекне күңеленә китермәс, кешедән асла көлмәс иде...

Гаишә абыстай, әгәр дә дәүләтле кемсә кызы улса иде, Габбас меллага дәгел, бәлки аның хәлфәләренә яр улачак иде. Ләкин дәүләтсез улдыгыннан бу егеткә яр улды вә бер байгура баласына әсир дөшмәдекеннән шатланып, Габбас мелланың холкыны тәрбия идәргә керeште һәм теләгенә дә ирeште.

Ирләрнең һиммәте[2] урыннарыннан тауларны күчерер, диерләр. Ләкин хатыннарның һиммәте боннан дәхи бәләндтер (артык, бөек).

Чөнки анларның һиммәтләре арсланнардан гайрәтле ирләрне үз фәрманнары астында тотарлар. Эстәсәләр, һич тәрбия кабул итмәгән ирләрне тәрбияле бер ир итмәгә муафыйк улырлар. Ирләр һәрвакытта хатыннар теләгәнчә улырлар.

Әсма

Әсма сигезенче яшенә җиттекеннән сабак укытмак заманы тәмам килмеш, вә бу фикер Гаишә абыстай илә Габбас мелланың күңелләрендә олуг бер урын алмыш иде.

---

[1] *Мәхдүм вә мәхдүмәләр* — мулла уллары һәм кызлары.

[2] *Һиммәт* — теләккә омтылу, эш белән кайгыртучанлык күрсәтү, тырышлык.

Бу көнгә кадәр Әсмага бер хәреф улсын дәрес бирелмәдеке Гаишә абыстай тарафыннан: «әлеп, би, ти, си әләх» дия күңеленә бикләттерелмәдеке Әсманы хәтергә алынмадыгыннан улмай, бәлки билгакес (киресенчә), боны фәүкылгадә (гадәттән тыш) бер олуг эш хисап иделдегеннән иде.

Вакыты тәмам килмәсдән элек, булыр-булмас рәвешчә сабак укытмак, хосусән әлифбаның исемнәрене ятлаттырмак баланың башыны бозмага вә дәресләрене тәртипсез укымага сәбәп идеке мәгълүмдер.

Мәгълүм заманы җитешмәсдән элек йөк тарттырылмыш ат имгәнеп, эштән чыктыгы кеби, вакыты җитмәсдән элек сабак укыттырылмыш бала да имгәнеп калмактадыр.

Начар мөгаллимнәр вә дәрес ысулыннан хәбәрсез хәлфәләр кулында алтын улачак балаларның тупрак улып калдыкларыны яхшы белдеге сәбәбеннән, Габбас мелла кызы Әсмага сабак укытмак өчен боннан ике-өч еллардан бирле хәзерләнмәктә иде...

Әсманың сабак укымакта улан шатлыгы, зирәклеге илә туры килешеп торганлыктан, көннән-көн алга бармакта иде. Боны күреп, Габбас мелла илә Гаишә абыстай сөйләп аңлатуы мөмкин дәгел дәрәҗәдә куанырлар вә җәнабе Илаһига нә кеби шөкерләр идәргә белмәй гаҗиз калырлар иде. Чыннан да, мондый шатлык иң дөрес вә тиңе улмаган бер шатлыктыр.

Әсманы тәрбия итмәктә ата вә анасы бу мәртәбә сәгый (тырышлык) иттекләре кеби, бәхет вә сәгадәте хакында һәм һәрдаим Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә мөнәҗәтләр кыйлырлар вә ялынырлар иде. Вә дөнья һәм ахирәттә улан өмитләре дә Әсмада иде. (...)

Хикмәт хаҗи

«Б...» авылында бөек мал вә күп милек-мөлкәт иясе Хикмәт исемле бер сәүдәгәр бар иде. Ошбу илле яшьләрендә улган Хикмәт хаҗи авылларда дәгел, шәһәрләрдә тиңе аз улган байларның бере улдыгы хәлдә чиксез надан, риялы, тәкәббер бер зат иде.

Һич тәкъва улмадыгы хәлдә тәкъва күренер, беренче дәрәҗәдә залим улдыгы хәлдә хаҗилар кеби үзен изге, тыйнак белер иде. Очраган вакытта ерактан торып сәлам бирмәгәннәргә яки тиешенчә хөрмәт күрсәтмәгәннәргә бер вакытыны туры китереп җәзасыны бирер иде.

Хикмәт хаҗиның байлыгы ата вә бабадан мирас булып калмыш дәгел, бәлки Казан сәүдәгәре истилахынча (әйткәнчә), сәүдәгә мәһарәттән (осталыктан) килмеш иде.

Яхшы нәрсәләр арасына начар нәрсәләр салып бер бәһадән җибәрмәк, акчага гаҗиз булып карз (бурыч) сорамыш кемсәгә акча янына сигез тиенлек ситсаларны егерме тиен бәһагә куеп бирмәк, базарларга читтән алучы вә сатучы күп килдекендә очсыз вә кыйммәт алып, чит сәүдәгәрләрне биздермәк, соңра тәмам үзе теләгәнчә ялгыз иркенләп сатмак сәүдәгә маһирлек имеш!..

Ләкин Хикмәт хаҗиның осталыгы бу дәрәҗәдә генә дәгел, тагын да артыграк иде. Үзе хезмәт итмәктә улган байның ике яшь угылыны сәфаһәткә (бозыклыкка) үгрәтмеш вә анлар акчага гаҗиз улдыклары бер сәгатьтә һәр икесенә йөзәр тәңкә акча табып биреп, егермешәр мең тәңкәлек вексель алмыш иде. Әлеге бай вафат улдыгында, ул байның хатыныны никах идеп, аның теге угылларыны исә бөтен милектән куып чыкармыш иде. (...)

Хикмәт хаҗи агачтан да надан кызларыннан дүртене Казан тарафыннан олуг шөһрәт илә укып килмеш дүрт муллага биреп, бу муллалар да Хикмәт хаҗиның һәр эшенә фәтва[1] вирерләр, хәтта кикерер исә дә, янында «ярхәмекә...» укып торырлар иде...

Хикмәт хаҗи бишенче кызыны яңа указ алмакта улган Габбас мелла сорамакында һич шөбһә итмәюр иде. Меллаларның нәфес коллары идекене бер дәгел, хәтта дүрт кемсә илә тәҗрибә идәрәк белдегеннән вә бонлары да ишәк җыеннары дия эченнән хисап иттегеннән, Габбас меллага үзе һәм тәмам

---

[1] *Фәтва* — нинди дә булса бер эшне эшләү дин-шәригать ягыннан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү, хөкем чыгару.

теләге илә бирәчәк иде. Ләкин Габбас мелланы кулдан җибәрүне теләмәгән хәлдә беркадәр назланмак вә ялындырмак фикерендә иде.

Әгәр дә бу кызыны Габбас меллага бирер исә, Хикмәт хаҗиның сафсаталарын хуплап утыручы дүрт ишәк урынына биш ишәк улачак иде.

Ләкин чук улсын ки, ишәк улмак Габбас мелланың язмышында юк, имеш. Хикмәт хаҗи кызы аңа булмады. Гәрчә ике дәфга (тапкыр) сорамыш иде исә дә, Хикмәт хаҗиның бу дәфга улан политикасы җиренә килмәде.

Хикмәт хаҗи кызыны нә бирмәс вә нә өзмәс, бәлки үлчәвенең телене бер тарафка авыш иттермәй тордыгында, иң сәүмәктә улан карт хезмәтчесе Сәлим бабайның, хатынсыз мал кирәк улса — Хикмәт хаҗи кызыны, вә малсыз хатын кирәк улса — Сөләйман хәзрәт кызыны алырсың, дия киңәш бирүенә карап, Габбас мелла Сөләйман хәзрәт кызыны (Гаишә абыстайдыр) сорады, алып та кайтты.

Бу хәл Хикмәт хаҗига бик ачы килмәде, чөнки, озак тормас, икенче хатынга алыр, дия фикер әйләмәктә иде. Чөнки хаҗиның вафат улмыш вә аермыш ничә гадәд (данә) хатыннарыннан башка, бүген дә өч гадәд хатыны улып, дүртенчегә яучы йөртмәктә улдыгыннан, кызларыны бирмәктә дә, хатын өстенә улмасын иде, димәс иде. Боның фикеренә күрә, хатынның күп вә аз улмасында бер аерма улмай, гаилә вә әдәп җәһәтенчә, хатын күп улмасында да кимчелек күрмәс иде.

Ләкин Габбас мелланың уй-фикере боңа каршы, ягъни хатынының иң тугры аркадаш вә тереклек мәшәкатьләрендә иптәш вә сердәш дия белдегеннән, зарурлык улмадыгында, хаҗи кызыны сорамак ихтималы юк иде. Боны гүзәл аңладыгы соңында, Хикмәт хаҗи олуг бер дошман улды вә ничек улса да аягыннан чалып аудармага вә яки тирән базга төшереп батырмага бер чара эзләр иде.

Ундүрт-унбиш еллар үтеп киттеге хәлдә, бу дошманлык йомшамады, бәлки артты вә киләчәктә хәбәр биреләчәк олуг мажараларга сәбәп улды.

Гәрчә икенче мәртәбә хаҗ сәфәренә киттегендә, холкыны бәлки төзәтеп кайтыр, дия Габбас мелла өмит идеп торды исә дә, Хикмәт хаҗи исә, киресенчә, әүвәлгедән артык тәкәбберлелек, көнчелек, ходбинлек (үзен яратучылык) ияртеп килде. (...)

Сәлим бабай

Сәлим бабай Габбас мелланың атасы заманасыннан бирү торыр, җәй көннәрендә умарта саклар, кыш көннәрендә вак-төяк йомышларга йөрер алтмыш яшәрлек бер карт иде.

Бер аралык, бонлардан чыкып, Хикмәт хаҗида вә аннан соң Сөләйман хәзрәттә дә беркадәр хезмәт итте исә дә, «өйрәнгән яу сугышырга яхшы» дия, янә Габбас мелла атасына кайтып китте.

Ата вә анасы вафат улып, йорт-җирләрне карау Габбас меллага калдыгы соңында, Сәлим бабай да әүвәлге мәнсабында (хезмәтендә) калмыш иде. Габбас мелла «безнең атай белмәгән» диер балалардан улмалыгыннан, атасы заманында улган хәл вә мөгамәләләре, атасының дусларыны җөмләсене әүвәлге хәлендә тотар иде.

Сәлим бабай, һәр нәкадәр умарта каравылчысы исә дә, башка умарта вә кыяр каравылчылары төреннән юк җиргә картаймыш дәгел, бәлки кичмеш заман хәбәрләрене, ата-баба мәкальләрене, милли мәсәлләрне, әһле исламга мөнәсәбәтле улган хикәяләрне укылачак бер китап иде.

Иске тарихларымызны сөйләдегендә, иске гасырларны вә иске гасырның халыкларыны тәмам күз уңына китерер иде. Үгезләр җигеп, арбаларның көпчәкләрене (тәкермәч) сары май илә майлап, сырт өсләреннән йөрүләрене сөйләдеге вакытында, тыңлаучылар, үзләренең тимер юл, пароход, телеграм, телефон заманасында идекләрене онытып, иске дөнья кешеләре улырлар иде.

Сәлим бабай ялгыз Габбас меллага дәгел, һәртөрле халыкка ярый торган иде. Боның хикәяләреннән имамнар, шәкертләр, байлар, гавамнар[1], хатыннар, хәтта кызлар ләззәт алырлар иде.

---

[1] *Гавам* — гади халык, масса.

Сәлим бабай ялгыз Габбас мелла бабасы улмай, бөтен халык бабасы иде. Сөйләдеге вакытта башка хикәячеләр кеби ялындырмас, тәкәбберләнмәс, иркәләнмәс иде. Һәм дә никадәр ләззәтле идеп сөйләр, асла йөткермәс, төчкермәс, тамак кырмас, урынсыз җирдә сүзне тәкрар әйтмәс, кулыны һавада йөртмәс иде.

Үзе милли тарихларымызны вә табышмакларымызны белмәктә тиңсез бер кемсәмез улдыгы кеби, курай уйнарга, җырларга улган маһирлеге гакылларны хәйран идәр иде.

Җәй көнендә авыл каршысында улан тау башыннан моңаеп җырлап җибәргән тавышларына бөтен авыл халкы уйкыларыннан уйганырлар, тышка чыгып, камил рәхәтлек илә тыңлап утырырлар иде.

Кымыз эчәр өчен килмеш, төрки тел укымакта улан бер рус студенты Сәлим бабайның саф вә калын тавышы илә:

Әй, кая ул көн ки бездә шәп торулар бар иде,
Әмма дошманнарда гамьнәр, эч пошулар бар иде.
Бер заман чыгар идек без кырга дус-ишләр белән,
Анда уеннар, көлүләр, сикерүләр бар иде.
Һәй, гомерләр үтте китте, кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һай-һулар, гөфтегүләр[1] бар иде.
Бервакыт бонча рәхимсез дәгел иде кызлары,
Анда туташларда ымнар, күз кысулар бар иде.
Ничә еллар үтте, әмма күрмәдек кызлар йөзен,
Янымызда әүвәле кандай сылулар бар иде.
Шигыренә күргәч Закирның* диде өлкәннәр дә һай!
Яшь чагында бездә һәм андай йөрүләр бар иде,—

укыдыгы вә тәкрар иттегене тыңлап торып, Мәскәүгә кайттыгында нотага алдырып, «Сәлим» исеме вирмеш иде.

Сәлим бабайның май, июнь айларында, халыклар урыннарына кереп яттыклары соңында уйнамыш курай тавышы,

---

* Бу әсәр — XX йөз башы татар поэзиясенең күренекле вәкиле Дәрдемәнд (Закир Рәмиев, 1859—1921) шигыре.

[1] *Гөфтегү* — кара-каршы сөйләшү, әңгәмә.

станциядә улган электрик, бөтен шәһәрдә улган фәргъләрене (бүлекләрене) эшләттеге кебек, карт, яшь, ир, хатын, егет, кыз — җөмләсенең күңелләренә селкетер иде.

Буыннарыннан, арка вә бил сөякләреннән сызланып ятмакта улган картлар урыннарыннан сикереп тордыкларыны белмәй калырлар вә: «Һай, үзәкләрем өзелә!..» — диерләр иде.

Киленнәрене сүгеп, кырып, бимаза идеп йөрмәктә улган каенаналар боның курай вә яки җырладыгы тавышларыны ишеттекләрендә май кеби йомшарып кидәрләр, киленнәренең кимчелекләрен гафу итәрләр, гафу гына дәгел, орыштыклары өчен үкенеп гозер идәрләр иде.

Сәлим бабай курай уйнаган яки җырлаган кичәдә яшь киленнәр бик рәхәт оерлар, күңелле төшләр күрерләр иде. (...)

Сәлим бабай ялкау дәгел, гаять иҗтиһатлы вә шат адәмнәрнең бере иде. Исерткеч эчмәк дәгел, искерткеч эчкән кемсә илә хәтта мәҗлестәш улмаз иде. Исерткеч эчмәк — агу эчмәк кадәр зәһәрле вә һәртөрле хәстәлекләрнең баш сәбәбе идегене бер доктордан ишетеп тәмам канәгать әйләмеш иде. Без исә Сәлим бабайның тәрҗемәсене яздыгымыз өчен юк гаепләрне юк димәгә вазифамыздыр. Ләкин бар гаепләрне яшермәгә көчебез әлбәттә юктыр. Мәсәлән, Сәлим бабайның тәмәке тарттыгыны яшереп калдырмыермыз. Дөрес, тәмәке тартадыр.

Сәлим бабай бу яман гадәтне Габбас мелладан үгрәнмеш дәгел, бәлки Габбас меллага үзе үгрәтмеш иде. Бабайның бик җиңел үгрәтмеш улган бу начар гадәтене Гаишә абыстай бик агарлык белән ташлатмыш иде.

Сәлим бабайның Хива сәфәрене, кыргызларның гореф-гадәтләрене, туй тамашаларыны риваять иттеге вакытында тыңлаучыларның авызларыннан сулар агар иде.

«Т...» кабиләсендә бер кыргыз кызына мәхәббәте төшеп, хатын итеп алмага сорадыгыны вә гакыд һәм идәрәк (сүз бирешеп) Хивадан кайттыгында, рәсмән (рәсми рәвештә) никах вә туй иделмәгә вәгъдә тәмам улдыгыны, ләкин кайттыгында кызның җиназасы хәзерләнмеш улдыгыны әсәрле бер сурәттә сөйләр, соңыннан, сәвеклемнең ядкаре, дия кыргызлар

вәзене[1] белән, калын тавыш илә кычкырып көйләп җибәрер, соңрасында җиргә ятып еглар иде.

Бу мәҗлестә улган кемсә иң усал кемсә улса улсын, кичкән эшләренә үкенер, күңеле йомшар, табигате кар кеби эрер, әбәди (мәңгелек) улган бер галәмгә барачак көн барлыгыны хәтеренә китереп, җәнабе Илаһига мөнәҗәт идәрәк чыкар иде.

Кызганычтыр ки, Сәлим бабай вафат улдыгында, эчендә нәкадәр мәгълүматы улды исә, җөмләсе үзе илә вафат уларак тупрак астына күмелде. Язып алып калмак тугырысында бер зат тарафыннан улсын гайрәт сарыф иделмәде.

Безләрдә бер гадәт бардыр ки, милли җырларны, ата-баба мәсәлләрене язмак, хикәя вә романлар тәхрир әйләмәк (язмак) галимнәр өчен кимчелек вә гыйлем мәнсабенә (хезмәтенә) лаек дәгел бернәрсә хисап иделмәктәдер!.. Ләкин мондый нәрсәләрне галимнәр язмас исә наданнармы язачак?! Анлар язылмадыгында милли әдәбиятымыз нә рәвешчә тәэсис иделенәчәк (төзеләчәк)?!

Тәрәкъкый тормозлары

Габбас мелла мәктәп ачып балалар укыттыгында, Хикмәт хаҗиның көнчелеге шул мәртәбәдә иде ки, әгәр дә мөмкин улса, мәктәбене ваттырып, урынында улан тупракны суга салдырыр иде (боның баш сәбәбе кыз мәсьәләсе идеке мәгълүмдер).

Гәрчә Габбас меллага иптәш бер имам алып, йөрәгенә кадәр салкын су сипте исә дә, Габбас мелланың моңа исе китмәгәнлегене, бәлки, киресенчә, мәхәллә эшләрене аңа тапшырып, үзе тагын да артыграк ихлас белән шушы эшендә улдыгыны күреп, хәсрәте әүвәлгедән артмыш иде.

Бу җиргә ерак дәгел бер мулла яңа указ алдыгы илә — бонларны яндырмак дөрес дәгел, аның өчен нә кеби хайван мае вә нә кеби кемсә зәбех иттеге (хайван чалдыгы) безгә мәгълүм дәгел, китапларда да күренми дип, керосин янмакта улган лампаларны мәсҗеттән чыкартмыш иде.

---

[1] *Вәзен* — шигырь үлчәме, ритм.

Бере, ахшам намазыны укыр өчен шәм эзләтеп, намаз вакытыны уздырмыш иде. (...) (Бу урында әдип иске фикерле төрле муллаларны ирония белән сурәтли.— *Төз. Ш. С.*)

Ошбу төркемнән уларак Хикмәт байның яңа мулласы да бер яңа сүз тапты. Боның сүзе һәр нәкадәр гаҗәп дәгел исә дә, гаҗәпсез дә дәгел иде. Боерыгыз, нә диер:

— Грифель илә кара тактага язмак шәригатькә каршы, соңра аны бозып алмак та хәрәм!..[1]

Ишеттегезме яңа хәзрәт сүзен?!

Кем усал?

«Б...» авылыннан ерак дәгел, кечкенә бер авылда укымаенча мулла улган бер гами (надан) мөрит бар иде. Боның эше ишаннар, мәнакыйбләрне (мактаулы эшләрне) сөйләмәк вә кәраматләрне риваять итмәк, вә аңа тәбган (ияреп) үзенең күрмеш вә күрмәмеш төшләренә хикәят әйләмәк иде.

Һәр нәкадәр фарыз намазларыны калдырмас исә дә, кеше күзе күргәндә гаять тә ихлас илә укыр, әгәр бер кемсәнең күзе төшдегене белер исә, «әле бән үзем руза да» димәктән тартынмас иде.

Боның исеме Муса иде исә дә, ләкин үзе... бозык холыклы иде. Бигрәк мәкерле, ялганчы, бозык күңелле, эттән артык тамгалы (ач күзле), яла ягучы вә һич сакланмай гайбәт сөйләүче иде.

Үз авылларында улан җамигъ мәсҗетне янәдән тәгъмир идәр (яңадан төзәр) өчен дия, һичкемнең мөшәвәрәтеннән (киңәшеннән) башка бер иганәт[2] дәфтәре ясап, акча җыярга дия «Ф...» шәһәренә китте. Дәфтәрнең уң тарафында, гомумән, байлар исеменә язылмыш бер мәктүп вә акчалата ярдәм белән изгелек әйләмәк тугырысында кыскача бер нәсыйхәт улыныр иде.

[1] Кадимче, иске фикерле муллалар балаларны укытуда кара тактага язу һ. б. шундый яңа алымнарга каршы торганнар.

[2] *Иганәт, иганә* — ярдәм, булышлык; берәр яхшы эш өчен халыктан җыелган акча.

«Ф...» шәһәрендә улган игътибарлы затлар дәфтәрдә Габбас мелла мөрәҗәгатен күреп, хатның тәэсире улмасыннан һәм дә бу затның гүзәл исемене күп тапкыр ишетмеш улдыкларыннан, арзулары (теләк) илә иганәт идәрәк дәфтәргә яздылар вә нәкадәр идеге ачык мәгълүм улмаз исә дә, бер мең рублядән аз улмаячагы чамаланыр.

Халык арасында танылган кемсәләр белән күрешүләрне тәмам иттегеннән соң, дәхи бер ханәгә керде, ләкин акча алыр өчен дәгел, бәлки бирер өчен...

Иртәсендә уйкысыннан тордыгында күз уңына дәфтәре килмеш иде. Мусаның бу кичәдә улган мәсарифы (чыгымы) күп дәгел, бары егерме биш рубля имеш!.. Хәерле каза улсын, тирләп тапкан акча дәгел, кесәдә калганы җитәрлек. Дәфтәрдә улган номерлардан берсене, икесене төзәтелсә, боны һичкем беләчәк дәгел, хәтта тәмамыны бирелмәс, бәлки һичкемгә әйтелмәс исә, кинә һичнәрсә улачак дәгел!..

Кесәләргә кул тәкрар кереп чыкты исә дә, һәр тыгылуында буш чыкты!.. Ах!.. Акча юк!.. Алмышлар!.. Акча җирендә җилләр исеп торыр!.. Муса акчасыны аннан карады, боннан эзләде, сорады, ялынды, аглады, юк, табылмады.

Беркадәр маҗаралар соңында дәфтәре илә берлектә полициягә китте, китте дәгел, алып киттеләр. Полиция тарафыннан бер чиновник җибәрелеп, Габбас мелладан җавап соралды. Габбас мелла исә Мусаның исеменә ишетмеш исә дә, шәхесенә танымадыгыны, хәтта вә дәфтәр бирмәк дәгел, бәлки бу кеби эштән асла хәбәрдар дәгел идегене сөйләде. Бу турыда эш тә тикшерүчегә бирелде, Муса да кулга алынды.

Бу кара хәбәр, акчасыз телеграммалар васитасы (чара) илә әтрафка таралды. Табигый, Хикмәт хаҗи илә ишан хәзрәт тә ишеттеләр. Хикмәт хаҗи дүртенче хатынлыкка ишан хәзрәт кызыны алып, кунаклап тордыгы вакытта беркадәр кәефене бозды.

Бу тугырыда һәркем бертөрле сүз сөйләмәктә вә фикер бәян итмәктә улса да, бүрәнәгә борчак атмак кебек, бер файда күрелмәс иде. Чыннан да, бонларның сүзе файда китермәк өчен

улмай, бәлки эшсез адәмнәрнең сакал вә борын илә уйнаулары яки тырнак кимерүләре төреннән бер эш иде.

Әмма Хикмәт хаҗи бу тугырыда Габбас мелланы эләктермәк вә ишан хәзрәт тә Мусаны коткармак өчен ихлас илә чара эзләрләр иде.

Хикмәт хаҗи үзенең «Ф...» шәһәрендә улган хосусый дәгъва вәкиленә (адвокатына) кеше җибәреп, эшне белешеп, үз хозурына килергә боерды. Хикмәт хаҗи бу яһүди адвокатына шул дәрәҗә инабәт идәр (ишаныр) иде ки, аның сүзене күктән килмеш вәхи[1] мәнзиләндә (урынында) тотар, аның сарыф идән акчасыны хисап итмәс иде.

Биш көн соң яһүди бай ханәсенә авылга килеп җитте һәм дә эшне белешдеге, әгәр дә хатны Габбас мелла яздыгы дәлил илә исбат иделсә, Габбас мелла да Муса янына китәчәгенә сөйләде.

Бу эш Хикмәт хаҗи өчен ярыйдыр иде. Шуның өчен каршыфәлән килмәде, бәлки аның яздыгыны исбат әйләмәк чарасына фикер идәр иде...

Күңелсез хәбәр

Муса тугырысында, дөресе дә Габбас мелланы Муса урынына вә һич улмадыгында Муса янына җибәрмәк өчен, Хикмәт хаҗи тырышып йөрдеге бер көндә, дус вә белешләре, мәхәллә әһелләре илә саубуллашып, Габбас мелла хаҗ сәфәренә чыгып китте. (...)

Габбас мелланың сәфәреннән ике вә Янбәгъ шәһәреннән язмыш улан соң хатыннан бер ай үттеге соңында, Гаишә абыстай кулына чит мәмләкәт (Төркия дәүләте) маркасы илә бер мәктүб бирелде.

Һай! Яхшы хәбәр булса ярар иде!.. Бу хатны ачдыкында куллары тетрәде, йөрәге селкенде, җөмлә тәне бер кызды, бер өшеде. Безләр исә бу кеби хәлләрне «эч сизмәк» дип әйтәбез. Ләкин нә күрсен, хат Габбас мелла хаты улмай, бәлки башка бер

---

[1] *Вәхи* — берәр фикерне Алла тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу, күктән боерык, хәбәр җиткерү.

белеш кемсә хаты улып, Янбәгъ илә Мәдинә арасында Габбас мелланың вафат улан хәбәре бирелмеш иде!..

Вай! Бу кара хәбәргә вай!.. Гаишә абыстай да, «Инна...» укып, һушсыз уларак җиргә ятты. Сабый улган Әсма да үлмәк нә идегене тиешенчә тәсаувыр итмәюр (күз алдына китерерлек түгел) вә анда барган кемсәнең дә тәкрар кайтмадыгын белмәюр иде...

Гаишә абыстай да һушы килдегендә, кызы Әсманы кочаклап, озак вакытлар еглады вә:

— И бәнем газиз яклаучым! Вай, бәнем мөхтәрәм ирем! Фиракның (аерылу) уты яндырадыр да, шуңа мәҗбүр уларак аглаюрым! Хәлбуки терек уларак җәнабе Илаһиның хисапсыз ярдәмнәренә ирешә алган булуың өмидемдер...

— И Раббым! Иртәгә көн кызым илә бәне, мөхтәрәм ирем илә берлектә, рәхмәтләрең күләгәсендә кавыштыр!..— дия аглар вә үз-үзен сабыр итәргә өндәр иде.

Гаишә абыстай һәр нәкадәр буйлә олуг казага тугыры килде исә дә, көннән-көн үз-үзен юатып вә мәтанәттән (чыдамлылык, түземлелектән) аерылмаеп, зилләтләргә (түбәнлекләргә) төшмәде. Бәлки әүвәлге гамәлләрене вә кәсепләрене иҗра итмәктә вә кызы Әсманы һәр нәкадәр Габбас мелла дәрәҗәсендә улмас исә дә, һәмишә гүзәл тәрбия итмәктә улды (афәрин бу гайрәтле хатынга!..)

Гаишә абыстай исә һәр нәкадәр сабырлы, вәкарьле иде исә дә, буйла хәбәрдән бер ел үттеге хәлдә хәсрәте һич җиңеләймәс иде. Ләкин кызы Әсманы хәтерләп, янә җәнабы Илаһидан гомер сорар иде... Бичара бәндә!.. Бер минут эчендә бер-беренә зыйдди (каршылыклы) улан догаларны әйтмәктәдер!.. Үзе өчен ни нәрсә мәслихәт, ни нәрсә мәслихәт дәгел — һич белмәер.

Бичара Әсма

Габбас мелла хәбәреннән бер ел соңында Гаишә абыстай вафат улды, вә аның вафатыннан бер атна соңында күршедән зоһур итмеш (килеп чыкмыш) янгында Габбас мелланың җөмлә әшья (әйберләре) вә йортлары янып, бернәрсәләре

калмады. Хәсрәт вә шатлык күп вакытта бер-беренә тоташ килмәктәдер.

Дөнья шулай инде — шатлыгында да дәвамы юк, хәсрәтендә дә!.. (...)

Унынчы яшенә чыкмыш улган Әсма ата вә анадан һәм дә иң газиз вә иң мәрхәмәтле ата вә анадан ятим калды. Боның башына килгән кайгыларның агырлыгыны һәркем үз фикере илә белер. (...)

Якын карендәшләреннән мәхрүм улган Әсманы авылның игътибарлы кемсәләреннән саналмакта улган Йосыф бабай тәрбия итмәк улып ханәсенә алды. Габбас мелланы сәүдегеннән Алла ризасы өчен тәрбия идеп асрамак улды. (...)

Йосыф бабай вә картчыгы

Йосыф бабай һәр нәкадәр белдеге кадәр диндар, үз малыны кешегә бирмәс, кеше малына күз төшермәс, җыеп әйткәндә, заманасының бер ярарлык кемсәсе иде исә дә, ханәсендә Габбас мелла мәктәбендә укыган бер угылыннан башка укымак-язмак белер зат юк иде...

Картчыгы исә яшь вакытында абыстайга ир балалар илә берлектә сабакка йөреп, абыстайның чыра күтәреп тә: «Укыгыз! Үтерермен!..» дигән сүзенә каршы шаян малайларның, арттан торып көлә-көлә: «Һич үтермәс, бу хөкемсез җир дәгел, курыкмагыз!..» дигән сүзләреннән гыйбрәт алып, һичнәрсә укымамыш иде. (...)

Йосыф бабай гаиләсе бу авылда яхшы исем тоттыгыннан, боның ханәсендә яшәдегендә Әсма да һәр нәкадәр милләт анасы ула алмаса да, шаять, милләт бәласе дә улмас. Боңа да чук шөкер. (...)

Саф мәхәббәт

«Б...» авылы, кымызы ләззәтле, һавасы яхшы, чишмәсе гүзәл, суы тәмле (тәгамлы), сахралары иркен улмак, әрәмәсендә һәртөрле кошлар сайрамак илә мәгъруф (билгеле) улдыгыннан, кымыз эчәргә вә ял идәргә килүчеләрнең иң күп килмәктә улдыклары авылдыр.

Бу авылга Петербург, Мәскәү, Казан, Вятка, Харьков, Томск, Иркут, хәтта Финляндияләрдән адәмнәр килер вә бер җире тәмам авыру улган затлар улыныр иде.

Хәтта узган елны Венгрия (Мәҗарстан) мәмләкәтеннән яшь бер мөгаллим бар иде. Ләкин һәр нәкадәр бу зат кымыз эчүчеләр җөмләсеннән күрелер исә дә, боннан мең еллар элек ата вә бабалары бу тарафтан күчеп киткәнлектән, анлардан калган әсәрләрне тикшермәктә вә венгр теле илә башкорт теле арасында улган мөнәсәбәтләрне белмәк өчен башкорт телен үгрәнмәктә иде. (...)

Әсма килеп кердеге көндә Йосыф бабай ханәсендә унбишләп кемсә кымызчы улынып, бонларның арасында унбиш-уналты яшьләрендә улса кирәк, гүзәл кыяфәтле, инсафлы, гаять мөлаем бер шәкерт тә бар иде.

Бу шәкертнең ошбу кыш көннәрендә сәламәтлегенә хәлел (кимчелек) килдегеннән, табиблар мәслихәте илә Казан шәһәреннән килмеш, бонда килдегендә юкарыда телгә алынган будапештлы венгр илә белеш улмыш иде. Ләкин ул мосафир, боннан калкып Верх-урал[1] вә Уса өязләрене сәяхәт итмәгә китдеге көннән бирү көннәрене гаять күңелсезлектә кичерер иде...

Бу шәкертнең килдегенә тәмам бер ай улдыгыннан, холкы, фигыле сыналмыш вә гаять гөнаһсыз бер бала идегенә канәгать иделмеш иде. Хәтта Йосыф бабай ханәсе дәгел, җөмлә игътибарлы затлар боны сәвәрләр вә балаларыны боның кеби шәкерт итмәгә омтылырлар иде.

Шәкерт илә Әсма бер-беренә очрашырлар вә тартынусыз сөйләшерләр иде. Әсманың кара хәбәрләрене вә хәсрәтле сәгатьләре идегене шәкерт белер вә бик тә кызганыр, әгәр дә эленнән (кулыннан) килер исә, үз җаныны фида идәрәк Әсманың ата вә анасыны кире дөньяга кайтарыр иде. (...)

Бу кызга шәкерт үзе янында улган хикәят китапларыны сөйләр вә укытыр иде. Бу хәл бер ай дәвам итте. Ләкин бер-беренә тәмам мунис улмышлар (ияләшкәннәр) вә бер-бере илә

---

[1] Хәзерге Чиләбе өлкәсендәге Верхнеуральск шәһәре.

рәхәт вә хозур тапмакталар иде. Бонлар арасында һичкемгә шөбһә салмаячак улган саф бер мәхәббәт бар иде. (...)

Бер-беренә очрадыклары вакытта йөзләре нурланыр, йөрәкләре селкенеп, тезләре тетрәр, җөмлә шатлык вә хәсрәтләре онытылып, ялгыз каршыларында бер-берене күрерләр. Әмма нәкадәр дә саф вә чын мәхәббәттер!.. (...)

Август башы килде, шәкертнең иптәшләре Казанга бармак өчен килмешләр вә боны да үзләре белән алып китмәктәләр иде. Мәдрәсә кагыйдәләренә күрә ошбу сәгатьтә калкып китмәк лазем иде.

Бонлар күзләрене яшьләндереп исәнләштеләр, тәкрар күрешмәк вә бер-беренә сердәш улмак вәгъдәсе илә саубуллаштылар. Ләкин бу кеби хушлашулар анчак саф мәхәббәт әһелләрендә генә ула белер.

Шәкерт анасыннан ядкяр уларак калмыш һәм дә иң мозтар (чарасыз) көннәрендә дә кулыннан чыкармамыш улган бер алтын тәңкәсене бүләк итәрәк бирде. Әсма исә боны гадәттән тыш бер шатлык белән кабул әйләде. Боңа мокабил (каршы) уларак, анасыннан калып та, зурлыгына күрә изүенә беркетелмеш улган көмеш балдак (хилкасыны) бирде...

Шайтан ялчысы

Йосыф бабай ханәсенә көннәрнең берендә мосафир бер хатын килде. Кырык яшьләрендә улган бу хатын, үзенең хәбәренә күрә, аслы «Ф...» шәһәреннән вә исеме дә Хәмидә улып, ерак бер җирдән кайтып килмәктә, имеш.

Бу хатын Әсманың анасы улган Гаишә абыстайның белешләреннән вә якын дусларыннан идегене вә Әсманы да «Ф...» шәһәренә бер-ике айга кунакка алып китмәк өчен бонда туктaлдыгыны бәян әйләде, вә Йосыф бабайдан рөхсәт сорап, соңра үзе китереп тапшырмак улып сүз бирде. (...)

Унбиш көн соңында Хәмидәдән килмеш улган мәктүптә Әсманың тир (тиф) илә хәстәләндеге хәбәр бирелде. Боны ишетеп Йосыф бабай бик рәхәтсез улды исә дә, нә әйтсен, бу көнгә кадәр үз гомерендә шәһәргә бармадыгыннан, тимер юл вә паро-

ходларны күрмәдегеннән, йортта эш күп улдыгыннан, үзе Әсма янына китмәгә мөмкин дәгел иде. Барып та нә кыйлсын!..

Өч көн соңра килгән мәктүптә хәстәлеге агыр вә бер атна соңында килгәнендә — бик агыр, ниһаять, өч көн соңра килгәнендә вафат улдыгы бәян иделендә. (...)

Теләнче кыз

Вокзалда поездның төн тарафында улган койрыгында гайне (нәкъ) почта арбасы тугырысында (бәрабәрендә) бер теләнче кыз улыныр иде. Ошбу мөслимә теләнче озын буйлы, ләкин арык вә ак чырайлы (чәһрәле), кара күзле вә гүзәл кашлы, яше бәлки уннарда улыныр иде. Башына багламыш нәрсәсе йон шәл улып, ләкин сәламәт җирләренә нисбәтле (караганда) ертык урыны күбрәк вә бу ертыклардан сачлары чыкып, тузылып, җил илә селкенеп торыр иде. Йон шәл идеге ялгыз бәгъзе кисәкләреннән аңлашылыныр иде. Өстендә кырык ямаулы, җитмеш ертыклы бер бишмәт улып, бу бишмәттән һич манигъсыз (тоткарсыз) җил бер тарафыннан икенче тарафына үтеп йөрер иде. Сул тарафында гәүдә буенча асылмыш бер капчык улып, ләкин капчыкта һичбер ертык вә тишек күрелмәс, бөтен иде.

Ай, бу капчык, вай, бу капчык!.. Сөйләдегемез кызга асылмага һич килешмәс иде. Ләкин нә чара ки, баш язисы (язмыш төшүе) буйлә имеш тә, асылмыш, боңа нә чара?!

Дидегемез теләнче кызның аягында ташландык резинка калош улып, балтырлары (балдырлары) ачык улдыгыннан, өшеп кып-кызыл улмыш иде. Ике күзеннән яшьләре тамчылап торыр вә үзе дә бизгәк чирле кемсә мисалында дер-дер калтырар, тешләре дә берберенә шак-шак сугылыныр иде.

И гаҗәеп хикмәт! Җөмлә инсаннар, бер ата вә бер ана баласы улдыклары хәлдә (безнең ышануыбызга күрә), кыйсмәтләре пәк мөхтәлиф (алган өлешләре тигезсез), табигатьләре дә төрлечә, бәхетләре дә карарсыз мөтафавиттер (бик аерылып торадыр).

Бере нә кимәгә белмәдеге хәлдә, икенчесе кияр өчен һичнәрсә булмамактадыр. Бере бик төрле гыйззәт вә назларга

мөстәгъръкъ (күмелгән), ул бере этләр кадәр улсын рәхәт күрмәмәктәдер. Бере салкын бураннарда, кар-ягмурларда, суыкларда туңып, ягмурларга чыланып, ризык эзләп йөрдегендә, ул беренең дөньяда буйлә кемсәләр улыначагы да хәтеренә килмәс.

Хәтере табылмак өчен бер яр вә хәрәм дәгел хатынга асылташлар бүләк иделдәге хәлдә, адәмлек хакы өчен улсын, икенче беренә ун копеек улсын бирелмәс.

Башка теләнчеләр һәркемнең артыннан, гүя алачаклары бар кеби сорап йөрдекләрендә, бу кыз туктамыш урынында гүя җансыз нәрсә вә йә күләгә мисалында, һич тибрәнмәй вә кузгалмай торыр иде. Әгәр дә дикъкать иделенеп күрелсә иде, әлеге кызның теләнчелеккә үгрәнмәдеге вә яки теләнче улырга эстәмәдеге аңлашылыныр иде.

Зәйнүш абыстай яки теләнчеләр

«Ф...» шәһәрендә, ...урамында үз ханәсендә Зәйнүш абыстай исемендә бер хатын тормыш итмәктәдер. Бу хатынның исеме бөтен Башкортостан губернасында билгеледер. Тупрак[1] сатар өчен килмеш башкорт вәкилләре боның ханәсенә нөзүл идеп (төшеп, туктап), айлар илә вакыт калырлар вә тупракларына сәхиб (ия) таба алмый йөрдекләрендә, Зәйнүш абыстай ярдәме илә эшләренә җиренә куярлар.

Зәйнүш абыстайның һәртөрле халыктан дус вә белешләре күп улыр, дөньяның рәвешене гүзәл аңлар вә заманага ярашлы хәрәкәт итмәк юлларны да белер. Җир сатучы башкортларга алучы таптыгы кеби, җир алучы нимсәләргә, латышларга, хохолларга да сатучы табар. Шәһәргә килеп, хатыннары яннарына озак вакыт кайта алмай тормакта улган кемсәләргә дә хаҗәт улган шәйләрне табып китерер, мохтаҗ итмәс иде.

Зәйнүш абыстай башка хатыннар кеби гакылсыз улмай, күп шәйләр белер иде. Бу белүе сәбәбеннән күп мал тапмыш, хәтта ошбу ханәсене бер копеек акча сарыф итмәй, бер бай баласыннан бер хезмәт бәрабәренә алмыш вә соңра закон буенча

[1] *Тупрак* — «җир, җир биләмәсе» мәгънәсендә.

беркетеп, бал капкан кебек ләззәтле идеп йотмыш иде. Һәр нәкадәр үзе кечкенә гәүдәле исә дә, карыны иркен вә мәгъдәсе (ашказаны) сәламәт улдыгыннан, күп шәйләрне ашар, вә җөмләсене һич мәшәкатьсез сеңдерер иде.

Бер аралык хәйлә кәгазе язмак тугырысында хөкем астында калды исә дә, диңгезгә батып, коп-коры чыкмыш кемсә мисалында, һиммәте сәясендә һичбер керсез котылмыш иде...

Ләкин соңрак заманнарда Зәйнүш абыстайның яшь вакытлары үтеп, һиммәте азайды, куәте тәнәззел идеп (төшеп, түбәнләнеп), шөһрәте дә кимеде. Дәгъвалы вә гаугалы терекләкләргә булдыра алу, кулдан килү куәте калмадыгыннан, дуслар, белешләр таралды, җилдән килмеш маллар да давылга китте. Нәкадәр орлык сачмыш исә, җөмләсене үзе урды, вә кешегә хәзерләмеш чокырларга үзе төшеп, олуг бәдбәхетлеккә калды...

Ләкин эт, тәненнән җаны чыкканча һәмишә эт улып, этлегене итәр. Ошбуның өчен бу хатын да дөнья көтмәгә башка бер юл тапты. Шуйлә ки: атасыз вә анасыз калмыш яки карау-чысыз улмыш ятим кызларны җыеп теләнчелек иттерер вә анлар җыеп китермеш акчалар илә көн уздырыр иде. Шул сәбәптән теләнче кызларының саны һәрвакыт тукыз-уннан ким улмаз иде...

Үтмеш бүлекләрдә сөйләмеш улдыгымыз теләнче кыз да Зәйнүш абыстайның теләнче кызларыннан бере улачак иде. «Улачак» дидек, чөнки бу хатын кулына төштегеннән соң бу сәфәре әүвәлге сәфәре иде. Чибәрлек вә гүзәллеге җирендә, сөйләшүе ләззәтле, үзе дә гаять тә җазибәле (сөйкемле) улдыгыннан, тиз көннән боннан элек китмеш теләнче кызлар урынына бу да китәчәк иде!..

И хөрмәтле ислам байлары!.. Вай, бай угыллары!.. Күрсәтегезче, сезләрнең акчагыз кемнәрне һәлак итмәс!.. (...)

Яшь кыз вә хатыннар

«К...» шәһәрендә улган хәстәханәләрнең берендә уннан артык мөслимә хәстәләр улынып, бонлар янына дәхи аякы сынмыш яшь бер кыз китерелде. Бу кыз, аягыны бәйләгәннәре

вакытта һәр нәкадәр бер дәрәҗә кычкырмага вә шикаять итмәгә мәҗбүр улды исә дә, соңра рәхәтләнеп уйкыга китте.

Өч атна кадәр салынмыш урынында яттыгыннан соң, култык таягына таянып хәстәханә эчендә йөрмәгә рөхсәт улынды. Бонда улган мөслимә хатыннар элек хәлдә бу кыз янына үзләре килеп утырдыклары кеби, боннан соң мәзбурә (әйтеп үтелгән кыз) дә анлар янына барыр улды.

Сәламәтләнмеш хатыннар чыгып, анлар җиренә яңалар килеп-китеп торырлар, яшь кыз исә озын вакыт бонда калдыгыннан һәрберенә таныш улыр иде. (...)

Бу яшь кыз китап вә хатлар укымак илә генә дәгел, хатыннарның үтенүләрен тыңлап, йортларына, якыннарына хатлар да язар иде. Хәтта мөселман хатыннары өчен, гомумән, бер язучы улмыш иде. (...)

Яшь кызның аягы тәмам сәламәтләнеп, чыкар көннәре якын калдыгында хәстәханәгә дәхи бер хатын китерелде. Ләкин бу хатынны күреп бөтен хәстәханә халкы: «Аллаһы Тәгалә сакласын...» — дия җәнабе Илаһига ялвармага башладылар...

...Бу хатын уникенче бабта сөйләмеш улган Хәмидә имеш!.. Безнең Муса белешемез дә мәгълүм эше сәбәбеннән җәзага дучар улмыш, имеш!..

Ана илә кыз

Волга буенда улган пароход конторапарының береннән утыз чакрым ераклыкта улган ислам авылында ялгыз бер кечкенә һәм дә пәк кечкенә бер үдә[1] хатын кызы илә торыр иде. Бу кечкенә вә яртысы җир астында улган бинага һәр айда кырык тиен хак бирерләр иде. Ошбу акчаны һәм дә үзләренең карыннарыны туйдырмак өчен хезмәт итмәгә мәҗбүр улырлар иде. Кыш көннәрендә хак илә җеп вә йон эрләрләр, киндер сугарлар, көз көнендә балчык басып өйләр сыларлар, җәйлектә көнләп кыр эшене эшләрләр. Бу сәбәптән ач-ялангач улмаслар иде. Хатынның исемене белмәермез. Ләкин кызның исеме Зәйнәп вә атасы да Госман исемендә идеге мәгълүм иде.

---

[1] *Үдә* — өйдә *(диал.)*.

Ошбу авылдан китеп сәүдә итеп тормакта улган бер сәүдәгәр, Мәкәрьядән[1] кайттыгында, якыннары илә күрешмәк өчен туктамыш иде.

Үз ханәләрендә хезмәт итмәк өчен юкарыда сөйләдегемез тол хатынны үзе илә бергә бармасы хакында тәкъдим итте. Хатын кызы илә берлектә улмак шарты илә бу тәкъдимне кабул итте. Вә җөмләсе берлектә сәфәр әйләделәр.

Бонлар ничә көннәр соңында «Г...» шәһәренә җиттеләр. Мәгәр дә Салих байның тәрбияханәсе ачылмагы шәһәр эчендә шаигъ улмыш (таралган) иде. Бу сәүдәгәр исә, бер тамак расходы аз улсын нияте илә, кызны әлеге тәрбияханәгә бирмәк тугырысында хатынга киңәш бирде.

Хатын да байның бирмеш гакылына вә үгрәтмеш дәресенә күрә Салих байга барып, ялгыз бер ятим кызы илә урамда калдыгыны сөйләде. Һәм нәкадәр буйлә алдап хәйләләр кормас исә дә, кызы тәрбияханәгә алыныр иде. Ләкин сәүдәгәрнең үгрәтдеге илә гамәл итмәгә мәҗбүр улмыш иде...

Ләкин бәракәт бирсен ки, Салих бай күп төпченмәде дә, Зәйнәп кабул иделенәчәк улды...

Тәрбияханә

«Г...» шәһәрендә мөселман ятимнәренә махсус улган тәрбияханәдән хәбәрегез бармы?.. Улмаз исә, боерыгыз, бонын хакында сезләргә бер-ике сүз сөйләялем: бөтен Азиягә исеме мәгълүм улган Салих бай «Г...» шәһәрендә ир вә кыз балалар өчен ике бүлектән гыйбарәт бер ислам ятимханәсе төзегән иде.

Тәрбияханәнең ирләргә махсус бүлегенә дәгел, бәлки хатыннарга махсус улган бүлегенә боерыгыз, сезләр илә бәрабәр кереп күрәлем. Курыкмагыз, кермәгегез хакыйкать дәгел, бәлки фараз вә хыялыйдыр.

Олуг бер залда уникешәр гадәттән гыйбарәт улдыгы хәлдә, алты саф уларак тезелмеш кыз балалар күрелер. Аякларында ап-ак оек, өсләрендә яшел материядән күлмәк, ак киндердән ал

---

[1] Түбән Новгородта һәр җәй саен була торган зур ярминкә — Мәкәрҗә ярминкәсе.

япма, башларында кызыл хәтфә (катыйфә) өстенә чикмеш калфак, аның өстендә зәңгәр төстә кечкенә шәл салынмыштыр.

Сафларның бер башында дин мөгаллимәләре ике мөслимә, икенче башында һөнәр мөгаллимәләре улган өч рус хатыны вә бонлардан бер тарафта гарәп теле, фарсы теле мөгаллимәсе вә ятимханәнең мөдирәсе, дәхи өч мөслиме булынып, анлар артында конторада дәфтәр тотучы язып баручылар вә иң соң урында тәрбияханә хадимнәре тезелеп, җөмләсе бер кыяфәт үзәрендә тезеленеп тормакталардыр.

Беренче сафның тәмам урта бер җирендә башында чуар чалма, өстендә сөт кеби ак җилән улдыгы хәлдә бер карт хәзрәт кызларга каршы тордыгы хәлдә күреләдер. Ак сакалы, мөлаем сүзе, нурлы йөзе, саф күңеле бу урында телгә алынмага яраклыдыр. (...)

Югарыда әйтелгән кызлардан күпләре тегеш, чигеш, нәкыш һөнәрләре үгрәндекләре кеби, өсләрендә улган киемнәре үз куллары илә тегелмеш вә эшләнмеш, имеш. Кул һөнәрләреннән күп шәйләр камил кызыксыну илә олуг магазин (мәхазин)нар тарафыннан алынмакта, имеш.

Мөгаллимә ханым

Кичкән бүлектә ишарәт иттегемез мөслимә мөгаллимәләрдән бере хикәямезгә мөнәсәбәтле улдыгыннан, бу җирдә аның тугырысында дәхи беркадәр сүз сөйләмәк икътиза (кирәк) идәр. Бу мөгаллимә егерме яшьләрендә бер кыз улып, ошбу тәрбияханәнең иң элек чыкмыш сачкәсе вә яки беренче уларак пешмәк җимеше иде. Ятимханәдә алты ел тәрбияләнеп вә гыйлем-мәгърифәт алып, имтихан бирдеге соңында, ошбу тәрбияханәгә мөгаллимә... улынмыш иде.

Бу кеби милләт аналары арабыздан зоһур иттеге (килеп чыгуы) җөмләмез өчен бер ифтихар (горурлык) улдыгы кеби, исемнәре дә милләтемез өчен бөек бер бәхеттер. Ләкин «мөгаллимә ханым» тәгъбире илә хикәят итмәк җиңел улдыгыннан, безләр хәзерге боның мөбарәк исемнәрене зикер итмәермез. «Хәзерге» дидек, чөнки киләчәктә дөрес вә асыл исеме зикер

иделенер вә күп хәлләре мәгълүм улыр. Ихтимал ки, бу кыз бу әсәрнең иң беренче баһадиры ула белер. Безләр мөгаллимә ханым дия хикәямездә дәвам итәчәкмез.

Мөгаллимә ханым яшь вакытында ата илә анадан мәхрүм калмыш улган бер ятим кыз иде. Салих бай тәрбияханәсе ачылдыгында иң элек кабул ителгән кызлар илә берлектә тәрбияханәгә кабул улынмыш иде. Тәрбияханәдә улган дөрес тәрбия сәясендә вә хосусан ахыр сыйныфларында карт хәзрәт килдегендә аның гүзәл нәсыйхәтләре вә мәбзул (мул, күп) улган һиммәтләре (тырышлыклары) сәбәбеннән, әхлагыны гаять гүзәлләштермеш иде. Тәрбияханәдә улган җөмлә ятимнәр ханымны үзләренең аналары мәртәбәсендә сәвәрләр иде. Чыннан да, һәр нәкадәр тугдырмыш аналары дәгел исә дә, аналарыннан артык шәфкатьле вә аналарыннан күп мәртәбә мәрхәмәтле улып, җөмләсене яклар һәм ярдәм итәр иде.

Мөгаллимә ханымның, туганым, карендәшем, балам, бәгырем, дия ачык йөз вә ләззәтле сүзләр илә бирмеш нәсыйхәтләре ятим балаларга Наполеон гаскәреннән артыграк эш күрер вә көлемсерәп сөйләмеш юатулары балаларга елдырым[1] кеби тәэсир бирер иде. (...)

Инсанның яшьлегендә алмыш тәрбиясе каберенә кадәр берлектә улыр, аерылмас. Бу исә гакыллы кемсәләрнең тәҗрибәләре илә исбат ителмеш бер шәйдер...

Тәрбия голәмасы фикеренә күрә, гаилә кечкенә бер дәүләт кебидер. (...)

Әдәбият илә шөгыльләнү күңелене сафламак вә нәфсене тәрбия итмәк бабында иң әсәрле углан дәвадыр. Шуңа күрә хатын улган кемсә әдәп китапларыны укудан һич вакытта мөстәгъни (хаҗәтсез) улмас. Гарәби, фарси, төрки телләрене белгән затлар өчен һәртөрле әдәп китаплары бардыр. Шуңа күрә гаилә башлыгы вә милләт анасы улган хатын буш вакытларында, бонлар илә гомер кичерер вә әдәби мәҗлесләр корып,

---

[1] *Елдырым* — төнлә яки кичен офык читендә ялт-йолт итә торган яктылык чаткысы (еракта яшен яшьнәү чагылышы); аҗаган; яшен (*диал.*).

кул астында улганнарга гүзәл әхлак вә гыйбрәт дәресләре сөйләр. Буйлә итмәкнең файдасы гаилә вә өммәт өчен чиксездер.

Мөгаллимә ханымда бу камиллекләр җөмләсе бардыр...

Хикмәт хаҗиның соңгы көне

Бикбулат хәзрәт ир уртасы улып, сакаллары агара башладыгы бер вакытта, кара кашлы, ак йөзле, симез бәдәнле бер кызның калпаганы кырын салып, каршысында тордыгыны җаны эстәмәгә башлады. Әүвәлге абыстай күп хәстәлекләр күреп өшәнгән вә балалар тәрбия итеп мәшгуль улдыгыннан әүвәлге төсләрене ташлаган, уен-көлкеләрдә дә артык рәгъбәте (теләге) калмаган иде...

Ләкин алыначак хатын бөек бер бай кызы улмадыгында, каршыга килеп, киенеп, бизәнеп тормагы мөмкин улмадыгыны гүзәл аңладыгыннан, Бикбулат хәзрәт тә олуг һәм дә иң олуг бер сәүдәгәр кызы эзләр иде...

Дөньяда бар нәрсә тырышлык камил улмак шарты илә әлбәттә табылыныр. Бикбулат хәзрәткә дә җаны арзу әйләмеш рәвештә бер кыз табылды. Бу да Хикмәт хаҗиның Габбас меллага бирмәк фикерендә улган бишенче кызы иде. Вәгъдәләшдектән соң, никах көннәренә кадәр янә улган ике ай вакытта Бикбулат хәзрәтнең күрмәктә улган төшләрене, күңелендә улган хыялларыны һич сорамагыз... Бонлар исә сөйләп, язып аңлатырлык хәлләрдән дәгелдер. Энҗе калпакларыны киеп, муеннарына асылташларны асып каршысына килеп торачак бер кыз килмәгенә, күңел бозачак шәйләр улмасын өчен, Бикбулат хәзрәт карт хатыныны олуг вә кечек җиде баласы илә: «Үз көнегезне үзегез күрегез. Бәннән сезгә хәер-фатыйха!» — дия, авылның икенче бер очына бер ү(өй) салып, аерып чыкармыш иде.

Бикбулат хәзрәт: «Һай, көннәр бик озын үтә!» — дия, көн кичерә алмай йөрдегендә, ике олуг хадисә (вакыйга) булды. Бере — йөз мең рублялек сәнәд (вексель) җаваплылыгынча, Хикмәт хаҗиның хәзинәсендә улган барлык әйберләренә торг (мөзаядә) игълан ителде. Икенчесе — Мәкәрья базарына китмеш улган угылы Казан шәһәрендә банкыдан илле мең рубля

акча алып чыкмыш улдыгыннан, дүрт-биш сәгать соң бер фәхешханәдә кател улынып (үтерелеп), акчасы угырланды. (...) Хикмәт хаҗи урамда торып ач калды...

Хикмәт хаҗи, бу көннәр соңында фәкать берәр ай микъдары яшәп, бер башкортның иң зәбун (начар) бер ханәсендә вафат итте...

Мөгаллимәне таләпләр[1]

1901 сәнәсе җәй көннәре иде, мөгаллимә ханымны бердән ике таләп зоһур итте (сораучы килеп чыкты). Бере —...Таһир бай угылы Ибраһим, икенчесе... мөгаллим әфәнде иде. Таһир бай тиңсез бер бай улдыгы хәлдә, Ибраһим Таһир байның ялгыз бер баласы иде. Әмма мөгаллим исә... иң фәкыйрь бер зат иде. Таһир бай вә угылы Ибраһим һәркемгә мәгълүм улдыкларыннан, хакларында сүз сөйләмәк габәстер (файдасыздыр). Әмма мөгаллим әфәнде авылда мәктәбе ибтидаи (башлангыч мәктәп) күрдегеннән соң, атасыннан мирас уларак калмыш өлешене акчага тәбдил идәрәк (алыштырып), ике йөз рубляне кесәсенә салып Казанга китмеш вә харикылгадә (гадәттән тыш) бер тырышлык белән ун сәнә укып, ошбу сәнәдә кайтмагы илә «Г...» шәһәренә килмеш иде. Казан шәһәрендә ислам гыйлемнәрендә мәһарәт (сәләтлелек) кәсеп иттегеннән башка Дарелмөгаллимин (Учительская школа) программасы нигезендә имтихан биреп, шәһадәтнамә[2] алмыш вә хаҗәт әда идәр (үтәр) микъдарда французча, немецча да үгрәнмеш иде. Боннан башка бухгалтерия, матбагачылык гыйлемнәрене дә белер иде.

Бу ике таләптән һичбере икенчесенең сорадыгыны белмәерләр, бу хәл фәкать мөгаллимә вә Салих бай илә аның хатыны улган өч зат арасында мөштәрәк (уртак) бер сер иде. Салих бай вә хатыны исә мөгаллим әфәндегә бирмәгә камил дәрәҗә арзу итдекләре хәлдә, мөгаллимәнең үз күңелене белмәк эстәрләр иде. Әгәр дә бу мөгаллимәдән башка бере улса иде, һич шөбһәсез, Таһир бай угылы вә иң дөресе дә Таһир бай угылының

---

[1] *Таләпләр* — теләүчеләр, сораучылар.

[2] *Шәһадәтнамә* — таныклык язуы, диплом, аттестат.

байлыгын ихтыяр итәр иде. Ләкин мөгаллимә, хисапсыз мондый бер байлыкны бер тарафка куеп, бернәрсәсе улмаган мөгаллим әфәндене ихтыяр итте...

Мөгаллимә илә мөгаллим гыйлем, мәгърифәт, гүзәл холык, тәкъвалык тугырысында бер-беренә шулкадәр бәрабәр килмешләр иде ки, буйлә рәвештә бер-беренә бәрабәр килгән ир илә хатыннарга дөньяда надир тәсадеф (сирәк очрашу) иделенер... Гали әфәнде (мөгаллимнең исемедер) боннан ун-унбер сәнәләр мөкатдәм «Шәриф» авылында бер гами (надан) угылы улдыгы хәлдә, бу көндә, Гали әфәнде дип, шөһрәтле әдип вә мөхәррирләрдән улып, гаять мәгълүматлы вә гүзәл холыклы бер кызга ир улмак шәрәфенә иреште...

Иске кешедән яңа хәбәр

Мөгаллимә ханым Салих бай илә хатыны каршында үз балалары кеби могтәбәр вә сәвекле улдыгыннан, туйга хаҗәтле нәрсәләр анлар тарафыннан хәзерләнмәктә вә буйлә бер ятим баланы һәм иң яшерен серләренә сердәш улган вә һәрбер язуларыны укымакта вә язмакта улган иң якын балаларыны гакыллы вә гүзәл холыклы, вә үзенә тиңдәш улган кемсәгә тапшырачак улдыклары өчен гаять сөенерләр иде. Туй вә никах көне бонлар тарафыннан рабигыләүвәл аеның уникенче көне уларак билгеләнмеш иде. (Әмма Таһир бай улы Ибраһим, кызга үзе өйләнә алмау ачуыннан, мөгаллимә мөселман кызы түгел, дип, хөкем идарәсенә гариза бирә. Кызның тәрбияханәгә кергәнче яшәгән авылына кеше җибәреп, метрика дәфтәрләреннән эзләсәләр дә табалмыйлар. Мөгаллимә Салих байга үзенең ул авылда вакытлыча гына торганлыгы, андагы «анасы»ның да үзенең әнисе түгеллеге турында сөйли.— *Төз. Ш. С.*)

Салих бай:

— Алай исә, атаң вә анаң кемнәр? Исемнәрене белерсеңме?

Мөгаллимә:

— Атам Бикмәт авылында Габбас исемендә бер имам вә анам да Гаишә исемендә улып, бән дә ул вакытта Әсма исемендә идем. Ләкин озын маҗаралар соңында, әлеге хатын кызы

улдыгым көннән башлап Зәйнәп исемене алдым. Тәрбияханәгә бу исем илә кабул ителдегем соңында, кем идегемне ачык белдерергә сәбәп улмадыгыннан, гарияты улган (алып торган) Зәйнәп улып йөрдем...

Салих бай, тәмам бер хәйрәттә (аптырауда) калып, нә димәгә белмәеп торыр иде.

Мөгаллимә:

— Әфәндем, бонлар бәнем тарихымның соң кәгазьләредер. Мөсагадә итәр исәгез (мөмкинлек бирсәгез), башыннан сөйләялем дә, төп чыгышым, кем иканлегем ачык мәгълүмегез улсын, бу көндә атам да сез, анам да сезсез!..

Салих бай:

— Хикәятеңне белдем. Ләкин бу гаҗәп вакыйга сәбәбеннән беркадәр һушым китте дә сөйләшә алмый тордым. Азрак утыр! Бонда дәхи бер башка эш килеп чыкты (бу вакытта дүрт-биш минут кадәр читкә чыгып йөреп килде).

Мөгаллимә:

— Әман[1], ярабби, хәерле улса иде!

Салих бай:

— Атаңны күрер исәң, таный алырсыңмы?

Мөгаллимә:

— Күрмәк насыйп улса, әлбәттә таныр идем, һәр нәкадәр аерылдыгым вакытта яшь идем исә дә, йөзе вә кара сакалы төштә күрдегем кеби һәмишә хыялымдадыр. Ләкин вафат улган кемсәне күрмәк һич мөмкин улырмы?

Салих бай:

— Атаң вафат дәгел, бәлки сәламәттер. Ошбу шәһәрдә, үзегез тормакта улган тәрбияханәдә улган карт Юныс хәзрәттер. Хәзер чакырттым, атаң илә күрешәчәксең. Инде бер туй җиренә ике туемыз улачактыр. Бу кеби бөек мәрхәмәт вә нигъмәтләргә дөнья йөзендә бездән башка һичкем ирешмәгән вә улмаз. Безнең сәбәбемез илә аталы-кызлы улачак вә һич өмет ителмәгән лятыйфләргә мәзһәр улачаксыз (киң бәхетләргә ирешәчәксез).

---

[1] *Әман* — иминлек; коткарыгыз, мәрхәмәтле булыгыз!

Мөгаллимә:

— Юныс хәзрәт бәнем атам улачакмы?

Салих бай:

— Сән Зәйнәп исеме илә йөрдегең кеби, атаң да Габбас улдыгы хәлдә, бәгъзе сәбәпләргә күрә, Юныс исемене алмыштыр. Бу сәгатьтә бонда килеп җитешер.

Мөгаллимә:

— Йа Алла! Бу нә хәл! Ярабби! Хәлемә мәрхәмәт әйлә! Гакылыма куәт бир! Дәхи нә хәлләр күрәчәкмен! Дөньяның күп зәхмәтләрене күрдегем соңында, иншалла, боннан соң рәхәт күрәчәкмен! Йа Алла, мәрхәмәт!..

Тәрбияханәдә улган карт хәзрәт килеп кердегендә икенче бер бүлмәдә хәлдән хәбәр бирдеге соңында, һәр икесене күрештерде. Бонларның бу вакытта улган шатлыкларыны, кочаклашып аглаштыкларыны вә башка хәл вә рәвешләрене сөйләп аңлатырга көчебез җитми. Бу кеби олуг бер шатлыкка бары тик ялгыз Гаишә абыстай катнаша алмады, имде боның өчен ахирәттә тиңсез шатлыклар күрсен.

Озын мәҗлес вә сөйләшеп утырулар соңында, тәрбияханәсенә кайтырга дип, Салих бай ханәсеннән чыктыгында, Әсма ханымга бер фәкыйрә хатын тугыры килеп, кулыны сузды. Аяклары улмадыгы сәбәптән бәләкәй арбага утырып, ике яктан ике таяк ярдәме илә йөрмәктә улган бу хатынны күреп бик тә кызганды. «Һай, без сәламәтлек нигъмәтене белеп шөкер итә алмыйбыз. Бонә Аллаһы Тәгаләнең нә хәлгә төшмеш бәндәләре бар»,— дия, кесәсеннән ике-өч данә көмеш тәңкә алып, садакасыны биреп китте.

Бәхетле Әсма

12 нче бабта Йосыф бабай ханәсеннән Әсманы Хәмидә исемендә бер хатын алып киттегене сөйләмеш идек. Бу хатын, кәндесе сөйләдеге рәвешчә, Гаишә абыстайның белеш вә дусларыннан дәгел, бәлки дөнья вә ахирәт дошманы иде. Күрендеге кеби яхшы хатын да дәгел, бәлки шайтан ялчысы улып, адәм башына хәсрәт, милләт өстенә бәла китереп йөрүче иде. Ятим бичара кызларны вә садәдил (беркатлы) яшь хатыннарны аулап,

фәхешханәләргә китереп сатар иде. Гөнаһсыз балаларны вә саф, намуслы хатыннарны буйлә рәвештә хараплык коесына ташламак, дөнья вә ахирәт бәдбәхет улмакларына сәбәп улмак, боның каршында урманнан куян тотып та базарга чыгарып сатмак дәрәҗәсендә җиңел бер эш иде. Дөньяда нәләр улмас, нәләр!..

Риваятьләргә күрә, арамызда бу кеби хәрәм кәсеп итүче дәхи бер чук Хәмидәләр улынып, харап улучы Әсмалар, Хәсәнәләр сансыз, имеш! (...)

Әсма, әгәр дә... буйлә бер тәрбияханәгә төшмәй, баттыгы шәрирләр (җинаятьчеләр) арасында калмыш улса иде, шөбһәсез, бер Хәмидә вә Зәйнүш улыр иде. Әгәр дә Зәйнүш илә Хәмидәгә Әсма тәрбиясе насыйп булса иде, бәлки Әсма дәрәҗәсендә гүзәл холыклы, мәрхәмәтле, тәкъва, диндар бер милләт аналары ула белерләр иде.

Хәмидә «Ф...» шәһәренә киләрәк, Әсманы белдегемез Зәйнүшкә тапшырды. Ләкин бу вакытта Әсма тиф хәстәлегенә дучар улып, өч ай микъдары агыр ятты. Бәгъзе вакытлар хәятыннан өмит һәм киселде исә дә, ахырында шифа кәсеп итте вә хәстәханәдән Зәйнүш үз ханәсенә алып килде, вә бу вакытта Зәйнүш өйрәтүенә күрә Хәмидә тарафыннан Йосыф бабайга мәктүпләр вә ахырында бәгъзе әйберләре вә шәһәрдә улган имам исеме илә бер ышаныч язуы җибәрелде. Ләкин бу язу имам язуы улмай, фәкать аның исеменнән язылмыш иде.

Соңра беркөн Зәйнүш Әсманың башка хезмәтләр өчен яшьрәк улдыгыны фикерләп, бераз вакытлар теләнчелек иттермәк улып, хәзерләмеш киемнәрне кидермәк улды. Бичараның затлы, бөек табигате мондый зилләтләргә (хурлык, түбәнлекләргә) риза улмадыгында, Зәйнүш тә ишегене бикләп, сүс чыбыркыны урыныннан алып, мескинәне ярмага башлады. Бу чыбыркы боннан элек тә күп балаларның яшьләрене агызмыш, аһларыны да күкләргә чыкартмыш иде.

Ата вә анасыннан каты күз җәзасыны күрмәгән гөнаһсыз бала элек мәртәбә уларак адәм сурәтендә улган эттән камчы җәзасыны тартты. Бичара нә итсен! Тугыз-ун яшендә улган вә авылда тереклек иткән, нә закон вә нә тел белгән кыз бала

шәһәрдә хәлене кемгә сөйләсен вә кемнән ярдәм сорамага белсен. Авыл халкы һәрнәрсәне сорап вә һәрнәрсәне күреп йөргендә, шәһәр халкы боның киресеедер. Араларында ялгыз бер стена улган күршеләр берлектә ун сәнә торырлар, берсенең хәлене икенчесе асла белмәс.

Бер атна соңында Зәйнүш тарафыннан «Киенегез!..» командасы биреелдегендә, җөмлә балалар киемнәрене киенмешләр вә камчы ачысы онытылмадыгы, хәтта гомер барынча онытылачак улмадыгы сәбәпле, Әсма да киенеп, теләнче кызлар илә берлектә нәкадәр ерак улган вокзалга китте. Вокзалда нә хәлдә тордыгы исә 13 бабта укылмыштыр.

Зәйнүш үзе дә, һәрвакытта улган гадәте үзәрендә, рус хатыны сурәтендә киендеге хәлдә, вокзалда улыныр вә гаскәренә дә һичкемгә белдермәй нәзарәт (контроль) итәр иде. Бер аралык Зәйнүш ишарәт илә Әсманы вагонга алып керде вә шул сәгатьтә кузгалып та киттеләр. Мәгәр дә бу вагонда Дарвин мәймүннәре илә Эрбет базарыннан кәсеп итеп кайтучы бер хатын бар, имеш. «Эт үз иптәшене табар» дидекләренчә, Зәйнүш тә бу хатынны белеп, Әсманы сатмыш вә үзе икенче мәнзилдә (тукталышта) төшеп калмыш иде. Хәлбуки Әсма, сатылынып йөрмәктә улган сандугач кеби, үз хәленнән асла хәбәрдар улмаер иде. Ләкин теләнче киемнәре салынып, гадәти киемнәр киендерелмеш иде.

Бичара бервакытта Казан шәһәренә килде, бер һәлакәт чокырыннан котылганы хәлдә икенче бер һәлакәт коесының агызына җитеп туктамыш вә төшеп китмәгә дә ялгыз ярым аршын калмыш иде. Байлар акчасы кемнәрне һәлак итмәер? Байларның эч пошулары нә кеби газиз балаларны вә шаян мәрхәмәт затларны дөнья вә ахирәттә зур вә зар итмәер?..

Бичара Әсма бер байның нәфесне хозурландырмак вә эч пошуыны бастырмак өчен хәзерләнмәктә, хәзерләнмәктә дәгел, хәзер кылынмакта иде...

Усаллар арасында Әсма зарарсыз хезмәтләр илә мәшгуль уларак беркадәр көннәр гомер уздырдыгында, югары каттан түбән катка төшеп килмәктә икән, баскычтан ялгыш егылып төште дә аягы сынды...

Боның үзәренә Әсма да хәстәханәгә җибәрелмеш иде. (...)

Ләкин бу кызның ятим вә һичкеме юк идегене белдеге илә, шул көннәрдә хәстәханәдән чыкачак бер картчык үзе илә бергә авылга алып китеп, кызы итеп тәрбия итәчәк улды. Бер ай микъдары бергә торып, хәле мәгълүм улдыгыннан, хосусан догасыны укыдыгыннан соң, бу хатыннан чиксез шәфкатъ вә мәрхәмәт күрә килдегеннән бәрабәрендә китмәктән курыкмас иде.

Тулы җәрәхәт илә Хәмидә хәстәханәгә килеп кердеге көндә Әсма да картчык илә чыкып авылга җәяүләп киттеләр. Әгәр дә бер кич кунмыш улса иде, үзен угырлап китмеш улган Хәмидәне танымыш улачак иде.

Гаҗәеп тәсадефдер ки (көтмәгәндә очрашу), Әсма Хәмидә илә Зәйнүшне күзе илә күрдеге хәлдә һич танымамыш вә хәлләренә мәрхәмәт итеп, яшьләрене агызып кызганмыш иде. Хәмидәне хәстәханәдә күреп, Зәйнүшне дә боннан ничә сәнәләр соң «Г...» шәһәрендә күрмеш иде. Хәтерлисездер, Әсма ханым атасы Габбас мелла илә очрашкач, тәрбияханәгә кайтмага чыктыгында аякларыннан мәхрүм калган бер хатын теләнчегә тугыры килеп, садака биреп китмеш иде. Бу фәкыйрә хатын үзен камчы илә ярган Зәйнүш иде...

Ир һәм хатын

Никах вә туйлар узгач, кыз илә егет бер-бере илә күрештекләре кичәнең иртәсендә ире (кечкенә кулында улган балдагыны салып ханым әфәндегә бирдегендә):

— Һәр нәкадәр кыйммәтле дәгел исә дә, гаять тә кадерле улган бу балдакны сәңа бүләк иттем, кабул боер!..

Хатыны:

— Рәхмәт, нә бирелер исә, сәннән бирелмеш нәрсә бәнем өчен һәм кадерле, һәм кыйммәтледер. Кадерле нәрсә һичкем каршында да кыйммәтсез улмаз.

Ир:

— Морадым чыннан да кыйммәтсез димәк иде. Юкса, дидегең кеби, бәнем өчен сабавәт (балалык) вакытымда вә шәкертлек көннәремнең сачәк кеби чагында иң кызганмакта улды-

гым бер ятим кызның үзем кеби ата вә анадан мәхрүм улган бер гаҗизнең ядкяре улдыгы җәһәте илә һәм кыйммәтле һәм кадерледер.

Хатын:

— Ләкин бу балдак балаларның дәгел, зурларныңдыр.

Ир:

— Аңа да анасыннан калмыш вә анасының ядкяре иде. Кымыз эчеп тордыгым авыл имамының (атасының исемене белмәерем) кызы иде. Аһ, бичара, нәкадәр шаян мәрхәмәт иде. Фәкать бу дөнья хәсрәтләреннән котылды. Чөнки Казанга бардыгыннан өч ай соң вафат улдыгыны ишеттем. Үзе һәмишә хәтеремнән китмәер.

Хатын:

— Эм... эм... (балдагының астында улган тамгаларга бакып вә сачы очына тагылмыш бер алтын тәңкәне иренең кулына бирәрәк): — Ул балага шундый бер алтын тәңкә бирдегең хәтереңдә юкмы?

Ир:

— Бирдем, бу көн кеби белерем. Ләкин боның кеби дәгел, хәтерем ялгышмаса, бу тәңкә бәнем бирмеш тәңкәмнең үзе кеби күрелер. Бонда нә сер бар?.. Боны сәңа кем бирде?..

Хатын:

— Икенче мәртәбә күрештегемез көндә кире үземә бирмәк шарты илә ошбу балдакны алган зат бирде. Ялгышмас исәм, иптәшләрең илә Казан шәһәренә укырга киттегең вакытта исәнләштегемез сәгатьтә син бирдең!..

Укучылар үзләре белер ки, ошбу мөгаллим 11 бабта язылган яшь шәкертнең үзе, имеш. Бу хәлләре мәгълүм улдыгында, бонларда хасил улган әсәрне (тирән кичерүле хәлне) бәян әйләмәк һич мөмкин дәгелдер. Дөньяның бонча мәшәкатьләрене күрдекләре соңында Әсма илә Габбас җәнабы Илаһиның бу кеби лөтыйфларына (мәрхәмәтләренә) мәзһәр (лаеклы) улдылар. Адәмнәр, кирәк яхшы, кирәк яман улсын, гамәлләренә күрә җәза күрерләр...

Фатих Кәрими

(1870—1937)

ҖИҺАНГИР МӘХДҮМНЕҢ АВЫЛ МӘКТӘБЕНДӘ УКУЫ*

(Торналы авылының мәктәбендә)

(1898)

Әлеп, би, ти, си! Әлеп, би, ти, си![1] Торналы авылының мәктәбендә бик күп бала тавышы арасында шул «әлеп, би, ти, си! Әлеп, би, ти, си!» дип көйләп әйткән тавыш бик аерымачык ишетеләдер. Моны әйтә торган бала шушы мәктәптә укыта торган Әхмәтша хәзрәтнең үз угылыдыр. Исеме Җиһангир. Яше унда. Хәзрәт бу ел үз угылына да сабак башлатты. Әүвәлән үз мәктәбендә бераз укытып, аннан соң бер зур мәдрәсәгә җибәрмәк ниятендәдер. Хәзрәтнең гыйлемгә ихласы бик куәтле. Угылыны бик яхшы укытмакчы була. Һәм, әлхәмделиллаһ, мәхдүм дә бик зирәк булырга охшыйдыр. Үзегез дә ишетәсез бит, ничек бертуктаусыз сабагыны кабатлап тора. Бала, селкенеп-селкенеп: «Әлеп, би, ти, си!» — дип кычкырган саен, хәзрәтнең сөеннече артып бара. Менә бүген әлеп, би укыйдыр, исән-сау

---

* Хикәя бераз кыскартып алынды. Кайбер гарәп-фарсы сүзләренең мәгънәсен автор үзе җәяләр эчендә күрсәтеп барган. Кайбер шундый сүзләр төзүче тарафыннан хәзерге телгә күчерелде.

[1] *Әлеп (әлиф), би (ба), ти (та), си (са)* — гарәп әлифбасының беренче хәрефләре. Бозып әйтелгән.

булса, бераздан иман иҗеге башлар. Язга таба, бәлки, «Һәфтияк» иҗегенә дә төшәр. Бер иҗек танымага башлагач, сүрәгә төшеп, «Кисекбаш»[1], «Бәдәвам», «Ярым алма»[2], «Йосыф китабы»[3]... кеби авыл мәктәпләрендә укыла торган дәрес китапларыны тәмам итсә, аннан соң эше сарыфка[4] төшәргә генә кала. Аһ, шул сарыф! Сарыф исенә төшкәндә хәзрәтнең авызыннан сулар киләдер. Шул күз карасы кеби газиз Җиһангирының сарыф вә нәхү[5] башлаганлыгыны күрсә, үлсә дә хәзрәтнең нияте үкенергә түгел. (...)

Хәзрәт үзе кырык яшьләрендәдер. Зур бер хәзрәтнең мәдрәсәсендә күп гыйлем укыган. (...) Ләкин һәр фәннән артыграк ихласы гарәпчә сарыф илә нәхүдәдер. Чөнки бонлар өммәһате голүмдер (гыйлемнәрнең анасыдыр). Мәдрәсәдән чыгып, Торналы авылында әткәсе урынына мулла булган. Мәдрәсәдән чыккан вакытларында егерме тукыз яшьләрендә иде. Бер күрше авыл мулласының кызы илә өйләнмеш. Иң олы баласы югарыда әйтелгән Җиһангир мәхдүмдер. Әхмәтша хәзрәтнең нияте мәдрәсә тотып дәрес әйтүдә иде. Вә аеруча, үзенең фикеренә күрә, һәр мөэмин вә мөселман өчен тиеш булган гыйльме сарыф илә гыйльме нәхүне бик яхшы укытмакчы иде. Шуның өчен дә, мулла булып җитәр-җитмәс, авылындагы мәктәпкә балалар җыеп укытмага башлады.

Бу мәктәп берничә мулла заманыннан бирле калып, бер дә төзәтелмәгәнлеге сәбәпле бик иске исә дә җимерелмәгән, бер почмагы эчке яктан бик яхшы итеп балчык берлән сыланган вә тышкы яктан тишек җиренә бер зур таш тыгып, өстеннән туфрак илә күмеп куелган иде. Матчасы, дәхи бик черек булса да, ике җирдән багана берлә терәтеп куелган иде. Бинаән галәйһи

---

[1] *«Кисекбаш»* — XIV—XV гасырларда иҗат ителгән татар әдәбияты ядкяре.

[2] *«Ярым алма»* — дини-мифологик хикәяләр китабы.

[3] *«Йосыф китабы»* — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре (XIII йөз).

[4] *Сарыф* — морфология.

[5] *Нәхү* — синтаксис.

(шуңа күрә) атна кич малайлар мендәрле уйнаганда вә яки мужик[1] кергән чакта аны мендәр илә кыйнап чыгарганда шул баганаларга бик каты килеп бәрелмәс исәләр, түбә тактасының ишелеп төшмәк ихтималы юк иде.

Мәктәпнең дүрт тәрәзәсе булса да, күбесенең пыяласы ватылган иде. Ватылып төшкән пыяла күзе җиренә: «Әүвәл алдым бер дистә куян тиресе унар тиеннән, бәһасе булды сигез сум көмеш», — дип, матур язу кәгазьләре яисә карындык куялар иде. Мәктәп авылның урта җирендәрәк бер юл өстендә вә күпер башында булганлыгы сәбәпле, шәкертләр өчен су якын булса да, мәктәпнең югары ягына, күпер астына мужиклар бик күп тирес түккәнлекләреннән, язга каршы көннәр җылытмага башлагач, тиресләр эреп, бик бозык вә сасы исләр чыгадыр иде. Һәм дә, ни хикмәттер, язга таба, зәхмәт кагылып, шәкертләр хәстәләнергә башлыйлар иде. (...)

Мәктәп кечек булса да, кунып ятучы җитмеш бала бар. Быел гына түгел, һәр елда шулай җитмеш, сиксән, хәтта кайбер елларны йөзгә якын шәкерт буладыр. Ләкин хәзрәтнең эчене пошыра торган нәрсә шулдыр ки: мәктәп алга бармыйдыр. Шәкертләрне сарыф вә нәхүгә төшереп, тирә-яктан укучылар җыеп, төрле фәннәрдән дәрес мәдрәсә хәленә кермидер. Хәзрәт үзенең гыйлемендә бер дә кимчелек күрми. (...) Ләкин мәктәп алга китми. Әллә Әхмәтша хәзрәтнең үзенең укытуында бер кимчелек вә сабак үгрәтүендә бер тәртипсезлек бар микән?

Алай дисәң, хәзрәт үзе укытуында да бер дә кимчелек күрмидер. Гәрчә авылга кунак килеп яки туй төшеп, аш-су булган вакытларда сабак бирергә мәктәпкә берәр атна керә алмыйча торса да, буш вакытында вә бахосус (бигрәк тә) көннәр озайгач, кайбер вакытларда көненә өчәр мәртәбә керәдер. Әмма шунысы бар ки, хәзрәт дәртләнеп кенә мәктәпкә керә башлагач, бәдбәхет мужик балалары мәктәптән чыкмага да башлыйлар. Чөнки яз җитә. Малайларга тырмага йөрергә кирәк буладыр. Һәм дә шунысы гаҗәптер ки: бу мәктәп бу авылда берничә мулла

[1] *Мужик* — гади авыл кешесе, игенче, крестьян.

заманыннан бирле булып килгән. Авылның ничә йөз кешесе бу мәктәптә укып чыккан. Ләкин укырга-язарга белә торган кешеләр бик аз. «Әүвәл алдым бер дистә куян тиресе, хакы булды өч сум көмеш»,— дип язарга белүчеләр байтак табылса да, солдатка киткән угылларга, кияүгә киткән кызларга үз куллары берлә, теләгән сурәттә хат язып җибәрерлек аталар, агалар, энеләр вә сату-алуга киткән аталарга хат язып җибәрерлек вә анлардан килгән хатларны теләгәнчә аңлап укырлык угыллары бик сирәк табыла. Солдатка киткән угыллар рус арасында вә яисә үзе кеби укырга-язарга белми торган татар солдатлары илә бергә тугыры килсәләр, берничә айлар хат җибәрә алмаенча торалар. (...)

Әгәр мәктәпнең ни өчен алга китмәгәнене хәзрәт низамлы (тәртипле) вә монтазам (рәтле) мәктәпләрдә укыган бер кешедән сораган булса, ул кеше шунда ук: «Хәзрәт, гәрчә син мәдрәсәдә егерме биш ел гомер кичермеш исәң дә, ялгыз тәһарәт алырга вә кычкырып-кычкырып моназара кылышырга (сүз көрәштерергә) өйрәндең, бала укытырга өйрәнмәдең. Балалар тәрбиясе гыйлеме вә мәктәп идарәсе кеби балалар укытырга вә мәктәп карарга өйрәтә торган махсус фәннәр бардыр. Аларны белмәгән кешенең укыткан баласында вә тоткан мәктәбендә алга китү ихтималы юктыр. (...)

Мәктәптә тәрбия итеп балалар укыта белүнең бик күп шартлары бар. Шуның өчендер ки, руслар, төрекләр вә башка Аурупа халыклары кеби мәдәниятле милләтләр бала укытырга мөгаллимнәр вә мөгаллимәләр җитештермәк өчен укытучылар хәзерли торган махсус мәктәпләр ясаганнар. Син мәсҗеттә имам торырга, җеназа күмәргә, никах укырга вә ашка йөреп бөлеш ашар өчен билгеләнгән бер адәмсең. Бинаән галәйһи (шуның өчен) син үз вазифаларыңнан бушый алмый торгансың. Мәктәптә укытыр өчен ничек булса да тырышып, балалар укыту гыйлеменә ия булган бер мөгаллим билгеләргә кирәк иде.

Мәктәпкә мөгаллим билгеләгәч, безнең доходымыз кимер дип курка торгансыз. Ләкин бу бер буш фикердер. Әгәр халыкның файдасына намус вә инсафыгыз берлә тырышыр исәгез,

əhали (кешеләр) сезгә тагын да артыграк мәхәббәт итәр. Доходыгыз тагын артыр. Җәмагать арасында кадер вә игътибарыгыз артыграк булыр»,— дип әйтер иде. Ләкин безнең Әхмәтша андый кешеләр илә күп күрешмидер. Һәм күрешүне тиеш тә күрми. (...)

Гаен, гаен, фи, кап[1]! Гаен, гаен, фи, кап! Гаен, гаен, фи, кап! Күрдегезме? Кичә әлифба башлаган Җиһангир мәхдүм бүген, ягъни бер көн эчендә кайда килеп җитте. Гаен, гаен, фи, капны ничек көйләп укыйдыр. Хәзрәтнең баласы, ахрысы, кеше булырга охшыйдыр. Кичә иртә берлә эткәсенең биргән сабагыны кич берлә дә, өйләренә кайтып, әнкәсенә тыңлаткач, аннан да бер сабак алды. Әнкәсе илә бертуган күрше авылдагы мөәзин абзасы килгән иде. Аңарга тыңлатып, аннан да бер сабак алды. Менә шул сәбәпле бер көн эчендә җим, хи, дал, зәлләрне[2] үтеп, гаен, гаен, фи, капка да килеп җитте.

Җиһангир мәхдүм бик яхшы алга баруында иде. Ләкин бер казага дучар булып, берничә көннәр мәктәпкә килә алмады.

Казага дучар булмасы бу рәвештә булды. Беркөн иртә берлән мәхдүм ашыгып-ашыгып мәктәпкә киләдер иде. Хәлбуки мәктәп ишегенең тышкы ягына бик калын боз туңган иде, мәхдүм ишектән керәчәк булганда, таеп егылып, өйалдында кайнап торган самавырга бәрелде, самавыр мәхдүмнең өстенә ауды, мәхдүмнең кайбер җирләре пеште. Шуның өчен дә берничә көннәр хәстә ятты. Шул кагыла торган зәхмәт әсәре булмасын дип, абыстай дөнья күргән, гомер сөргән бер карчыктан җиде төн уртасында җиде мунчадан җиде таш алдырып, җиде сахраның уртасына аттырды вә, име-томы шул булсын, диде. Хәзрәт үзе дә тәһарәт алганнан соң комганда калган суны җен догалары илә өшкереп мәхдүменә һәр көн эчерә торды. Арасы күп үтмәде. Бер камышлы күлдә ишетелгән бака тавышы кебек, Әхмәтша хәзрәтнең мәктәбендә дә чиксез вә хисапсыз булган башка тавышлар арасында «вау, һи, лам, әлиф, йа!»,

---

[1] *Гаен, гаен, фи, кап (каф)* — гарәп алфавитындагы хәрефләр.
[2] *Җим, хи, дал, зәл* — гарәп алфавитындагы хәрефләр.

«вау, һи, лам, әлиф, йа!»[1] тавышы аерымачак ишетелмәгә башлады. (...)

Җиһангир мәхдүмнең язуга да дәрте булган булырга кирәк, чөнки өйдә ялгызы гына калдыгы вакыт, атасының каләм вә кара савытыны алып, тугыры килгән кәгазь өстенә төрле-төрле сызыклар вә сыгыр сурәте кебек нәрсәләр ясап маташадыр иде. Атасыннан берничә мәртәбә үзенә кәгазь илә каләм сораса да, хәзрәтнең фикеренчә, иҗек вә төрки танып бетермәгән баланы язу вә сызу, вә хисап кеби нәрсәләр берлә маташтырмак һич тә яраклы вә акылга сыя торган булмадыгыннан, мәхдүмнең риҗасыны (үтенечен) кабул итмәде. (...)

Яз җитте, мәдрәсә таралды. Шул үткән бер кыш эчендә кайсы бала тырышкан? Кайсы бала алга киткән? Кайсы артка калган? Укыган нәрсәләре кирәкле вә файдалы нәрсәләрме? Балаларның гомерләре берлә бичара вә фөкара (ярлы) мужикларның балаларыны укытыр өчен тоткан мәсарифлары (чыгымнары) заигъ (әрәм) вә буш китмәгәнме? Мәдрәсәнең хәлләрен вә балаларның уку тәртибен үзгәртергә, яңартырга хаҗәт юкмы?.. Боларны синең берлә мин түгел, мәктәптә укыта торган Әхмәтша хәзрәтең үзе дә белмидер. (...) Мәктәп тотудан, шәкерт җыюдан максуты — аларга бернәрсәләр белдермәк дәгелдер, бәлки укытмактыр. Һәм дә нә укытмак? Тугрысыны сөйләсәк, укытмак та дәгел, дәрес әйтмәк һәм дә сарыф вә нәхүдән, ягъни үзенең ана телене белмәгән балаларга гарәпчәдән дәрес әйтмәктер. Мужиклар балаларыны бик күп булса, тырышып, тырмашып, ике-өч ел мәктәптә тоталар, бер-ике елы һичбер нәрсә аңламыйча иҗек берлә үтәдер. Калган бер-ике елында «Кисекбаш», «Бәдәвам», «Кызыл алма»[2], «Фәзаилеш-шөһүр»[3] кеби һич файдасыз китаплар укытылып, гомерләре заигъ ите-

[1] *Вау, һи, лам, әлиф, йа* — гарәп алфавитындагы хәрефләр.

[2] *«Кызыл алма»* — борынгы әдәбият ядкяре.

[3] *«Фәзаилеш-шөһүр» (Изге айлар)* — Җамаледдин Бикташи дигән мулла язган дини эчтәлекле әсәр. Беренче тапкыр 1854 елда Казанда басылган.

ләдер. Асыл һәрбер мөселман өчен тиеш булган иман, инану вә дини хөкемнәрдән вә дөньяга чыгулары илә һәр көн вә һәр сәгатьтә кирәк булган язу, хисап, тарих вә җәгъърафиядән һичбер хәбәрләре булмый кала. Мөселманлыкны мыек кисеп, баш кырдырып кәләпүш киюдән вә яхшы чапан киеп мәсҗеткә йөрүдән генә гыйбарәт дип ышанып, фикере бозылып, сүз аңламый торган бер мөтәгассыйб (фанатик) була. Бөтен эше, көче кеше гайбәтене сату белән чикләнгән булып, мәдәният вә прогресска дүрт башлы дошман була. Үзе һичбер нәрсә белми вә башкасына инанмый, перепись[1] вакытында татар дип язачак булсалар, юк, юк, мин татар түгел, мин мөселман, дип, сугыш чыгара. Менә безнең ибтидаи (башлангыч) мәктәпләребезнең яшьләре шулардыр.

«Шул өч-дүрт ел эчендә синең угылың ни укыды? Ни белде? Дөнья өчен файдалы берәр нәрсә өйрәтмешләрме?» — дип, мужикларның үзләреннән соралса, ни җавап бирерләр икән? Бирәчәкләре җавап мәгълүм түгел. Чөнки алардан болай сораучы юк. Хәзрәт үзе әлбәттә сорамый. (...) Соралса да: «Тәкъдирдә язылганы булгандыр»,— дип, кыска гына җавап бирерләр иде. Ләкин көтүдә бер кәҗә бәрәннәре сазга батып ашамаенча калса, тәкъдирдә язылганы булгандыр, дип тормыйлар. Ни өчен хайваннарны карамыйсың, ни өчен яхшы җирләрдән ашатып симертмисең, дип, көтүчене тотып тәпәлиләр. Күз нурларыннан газиз булган балалары бөтен гомерләре буена надан, ахмак буларак һәм үзе өчен, һәм дә башкалары өчен мөгезле бер бәла булып калса: тәкъдирдә язылганы булган, имеш! (...)

Яз үтте, көз килде. Ялгыш әйттем, көз түгел, кыш килде. Чөнки Әхмәтша хәзрәт мәктәпкә балалар җыеп укытырга башлаганда декабрь ае җиткән иде... Февраль аена кадәр һәр көн диярлек мәктәпкә яңа бер шәкерт киләдер иде. Ничек мәктәпкә сыялар иде, дип гаҗәпләнмәгез. Чөнки бер яктан шулай җыелсалар да, икенче яктан чыгарга да башладылар.

---

[1] *Перепись* — халык санын алу.

Казый[1] һәр көн җәмәгать акчасы сорый, шәм вә утын китерергә әйтәдер. Шәм алырга дигән акчага баланың атасы базардан аракы эчеп кайта. Кайткач, хатыныны кыйнарга ябыша. Мәктәптә казый әфәнде баласының аркасына чыбык ора. Атна кич иртә берлән хәзрәткә садака бирергә баланың атасы акча китерә алмый. Суфый абзый* күмәчкә Исмәгыйль вә кара икмәккә Ибраһим атлы исемнәр куйган, ике дә, бер дә балага: «Кая, бу көннәрдә бер дә Исмәгыйль күренми башлады! Ялгыз Ибраһим берлә генә күңелсез була бит»,— дип әйтәдер.

Менә шәкертнең чабата башмагы югалган. Атна кич өйләреннән самавыр алып килеп чәй эчмәкче булганнар иде. Үзләре кергәч, өйалдында самавырның кранын борып куйганнар, суы агып беткән, чаж-чож эреп утыра. Ярабби! Ни эшләргә кирәк? Һәр көн яткан вакытта Суфый абзый кулына чыбык тоткан, «Әлиф ятыгыз! Әлиф ятыгыз!» — дип кычкырып тора, әз генә көлгән вә кычкырган тавыш чыкса да: «Биктимер, көлүче син бугай, кил әле монда»,— дип янына чакырып, сыртына чыбык суга. Һәм моңар сугарга да тиеш. Чөнки атасының байлыгы була торып Суфый абзыйга һәрвакыт Ибраһим җибәрә. Сирәк-мирәк кенә булса да ни өчен Исмәгыйль җибәрмәскә кирәк? Иртә торыр вакытта, казый әфәнде: «Торыгыз!» — дип, бер мәртәбә кычкыра. Икенчесендә чаж-чож чыбык тавышы ишетелмәгә башлый...

Һәм дә Сәйфулла вә Гайнулла агайлар, Әхмәтша хәзрәтне күргән саен: «Балабызның ите сиңа, тиресе безгә, каты тота күрегез, хәзрәт»,— диләр. Әхмәтша хәзрәт тә: «Шулай тиеш шул, остаз суккан җир җәһәннәмдә янмас»,— дип җавап бирә. Хәзрәт колакны бора, Суфый абзый илә казый, хаклы булсын, хаксыз булсын, һәр көн сыртка чыбык сугалар, иптәшләр көлә, мыскыл итә, чабата-башмакны урлыйлар. Кара шешәсене вата-

---

* *Суфый абзый* — элек заманда, берәр ишанга мөрид булып, суфый исеме астында мәктәп-мәдрәсә почмагына оялап, гомерен шунда үткәрүче, халык һәм шәкертләр хисабына яшәп ятучы кеше.

[1] *Казый* — мәктәп-мәдрәсәдә тәртип саклаучы.

лар, сабакны белеп булмый, чөнки аңлаткан кеше юк, ничек итеп укырга вә өйрәнергә юл күрсәтмиләр. Фәкать, укы, тырыш, мулла булырсың, диләр. Тормыйм бу мәктәптә, чыгамын! Менә тамчылар тама башлады. Яз җитә. Тырма бавы, сука дилбегәсе ишәргә кирәк.

— Әти! Мин иртәге өчен дә сабак алып кайттым, иртәгә бармамын, йорт эшләрен карармын. Менә сыер бозаулаган, әнигә бозау муенчагы кирәк икән, аны да ишеп бирермен.

— Ярар, угылым, бер көннән әллә ни булмас.

...Менә мәктәпкә килмәенчә йөрсәң, шулай булыр! Сал чикмәнеңне, ят сузылып, чаж-чож! Һәр чыбыктан атна кич иртә белән бирмәенчә калган ике тиенлек акча тавышы чыгадыр.

— Үлсәм үләрмен, бу мәктәпкә моннан соң килмәмен! (...)

Безнең Җиһангир мәхдүм бик зирәк бит. Быел иҗекне тәмам илә танып сүрәгә төште. Сүрәне бераз укыгач та, «Кисекбаш» китабын башлады, һич өйрәткән кеше булмаса да, шунда балалардан күрә-күрә хәрефләр куярга өйрәнгән... Шулай маташа торгач, мәхдүм язга таба кеше исемнәре дә язарга башлады. Бервакыт мәхдүмнең күрше авылдагы мөәзин абзасы килгән иде. (...) Мөәзин мәхдүмнән каләм сорап алды. Менә мин сиңа бер юл күчергеч язып бирим, мин икенче килгәнгә кадәр шуны бик яхшы итеп өйрәнеп куй, дип, кәгазьне тез өстенә куйды. Каләмне яхшы гына учлап тотып, агызыны йомып, башыны сул якка бераз иеп вә хәреф куйган саен иреннәрене кыймылдатып шул рәвештә язып бирде: «Әүвәл алдым бер дистә төлке тиресе сигезәр сумнан, хакы булды егерме биш сум көмеш».

Мәхдүм бик сөенде. Хәзрәт берлә абыстайның да шатлыгыны әйтеп бетерерлек түгел. (...)

Апрель башында мәктәп таралып җитте. Мәдрәсә буш калды. Хәзрәт быел дәхи кыйраәт (кычкырып уку) иттермәкче булып торадыр иде. Ләкин Суфый абзый: «Кыш көне һәр атна кичтә мин аларга кыйраәт укыттым, алар хәзер дә яхшы беләләр»,— дигәч, шуның берлән канәгатьләнде. Суфый абзый Торналы авылыннан җитмеш чакрым җирдә бер ишан

хәзрәткә барып, аның тәкиясендә (мөридләрнең ишан кулы астына зикер[1] әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары) тормага башлады. (...)

Мәдрәсәнең капкасы алдында озын агачлар сөяп, аларның өстенә салам каплап куелган иде. Гәрчә яз башы булса да, кайбер көннәр суык булганлыктан, күрше мужиклар бу агачларны берәр-берәр алып өйләренә якмага башладылар. Ишелеп төшкән саламнары өстенә сыгырлар килеп ятадыр иде. Апрель ахырларында кояш кыздырып карларны эреткәч, мәдрәсә тирәсе ачылды. Мәдрәсәнең тышкы яктан өелеп куелган тупрак нигезе өстенә озын сакаллы вә гаять һавалы, тәкәббер карт кәҗәләр вә яшь-яшь дәртле кәҗә тәкәләре җыелып кояшта кызынып ятарга башладылар. Боларның күп йөрүләреннән мәдрәсәнең тишек почмагына тыгып куйган таш өстендәге тупраклар ишелеп, тишек ачылды. Кәҗәләр юк вакытта бу тишектән үрдәкләр эчкә кереп, мәдрәсәнең әчелегендә (идәнендә) кыш буенча җыелып торган пычраклар берлә түбә тактадан кар сулары агып җыелган сазлыкларда гаять кәеф вә сафа илә йөриләр иде.

Яз булып җир кипкәч, мужикларның беренче эше сабан туе ясамактыр. Моны ясар өчен әүвәлән мулладан рөхсәт алалар. Аннан соң яшь киленнәрдән сөлге вә яулык вә йорт саен кереп йомырка вә акча җыеп, авылның бер читендә бер җыен ясыйлар. Көрәш иттерәләр, ат чаптыралар. Вә кешеләрне йөгерешкә җибәреп, узганнарга вә өстен чыкканнарга бүләкләр бирәләр. Бичара мужикларның елында бер мәртәбә килгән милли бер бәйрәмнәредер. Моны бетермәк түгел, ничек булса да ярдәм итеп, алга җибәрергә, вә елдан-ел зуррак вә яхшырак ясарга тырышырга кирәк иде. Хәлбуки, егетләр илә кызлар күрешәләр, дип, Әхмәтша хәзрәтнең сабан туе ясарга бер дә рөхсәт бирәсе килмидер.

Әгәр яшь-җилкенчәк туп-туры үзләре барып сорасалар, рөхсәт бирмәү бик мәгълүм булганга күрә, яшьләр моңарга бер

[1] *Зикер* — Алла исемен бергәләп кабатлау.

чара тапканнар. Авылда Биктимер атлы карт бер мужик бар. Бала-чагасы аз. Бу мужик мулланы да ярата. Ләкин мужикларны бигрәк сөядер. Һәрберсене үз баласы кебек күреп мәхәббәт итә. Вә аларга файда китерергә тырыша. Мужиклар да моны гомуми ата кебек белеп хөрмәт итәләр. Ашын ашаган, яшен яшәгән бу карт тәҗрибәле вә тугыры фикерле бер адәмдер. Моның фикеренә күрә, яшьләрне бик кысарга ярамый, кысудан файда юк. Яшь вакытларында аларга азрак ихтыяр бирергә кирәк. Уйнасыннар, көлсеннәр. Бу дөньяда гомер ике килмидер. Усаллык итәсе килгән кеше никадәр кыссаң да итә аладыр. Яшьләрнең үз кулларына ихтыяр биреп тә, аларны холык вә тәрбиягә өйрәтергә кирәк. Яхшы илә яманны үзләре белеп туктый торган булсыннар. Биктимер агайның хәзрәткә дә сүзе үтәдер. Чөнки сагъ вакытында бу адәмнән һәр ел байтак кына гошер, зәкят вә фитыр[1] килеп торадыр. Менә үзе көннән көнгә картая бара. Үлгәннән соң моның фидиясе[2] дә аз булмас. Моны ачуландырырга ярамый. Чөнки тирә-якның муллалары вә аеруча ишан хәзрәт бу адәмне һәрвакыт кармак салып, ауламактан кире тормыйлар. Ләкин, Аллага шөкер, Биктимер агай мондый аулауга төшми. Чөнки Аллаһы Тәгаләне танып, пәйгамбәрләрне белеп, кулдан килгән кадәре гыйбадәт иткәч, тырышып, хәләленнән мал тапкач, кешегә зарарым тимәгәч, кулдан килгән кадәре башкаларга ярдәм дә булгач, мин үзем ишанмын, атна кичләре мәсҗеткә җыелып ишан каршысында йоклый-йоклый борын сызгыртып утырудан күп файда килмәс, дип әйтәдер.

Сабан туен ясарга вакыт җиткәч, яшьләр җыелып Биктимер агайга киләләр вә хәзрәттән рөхсәт алып бирергә үтенәләр иде. Быел да шулай иттеләр. Биктимер агай:

---

[1] *Гошер, зәкят, фитыр* — гадәттә муллага китерелә торган садакалар. Гошер — уңышның уннан бер күләмендә дини налог. Зәкят — еллык керемнең 40 тан бере күләмендә түләнгән еллык налог. Фитыр — ураза вакытында авыз ачу садакасы.

[2] *Фидия* — үлгән кешенең гөнаһысын йолып алу (коткару) өчен бирелгән мал, йолым.

— Иртәгә мәсҗеттән чыгуга мин хәзрәтне чәйгә алып килермен. Иртә илә коймак пешерегез вә маен да күбрәк салыгыз,— дип, кичтән хатынына әйтеп ятты. Иртә берлә Биктимер агай хәзрәтне алып килде. Тарелка-тарелка коймаклар бушады. Хәзрәтнең чапан кукрәгендәге таплар тагын күбәйде вә сабан туена да рөхсәт бирелде. (...)

Сабан туйлары үтте. Эш башланды. Хәзрәт сука өмәсе итте. Карабодай вә солы чәчтерде. Өмә итте — печән чаптырды. Өмә итте — арыш урдырды, көлтә китертте. Көз килде. Тагын сука өмәсе итте — арыш чәчтерде. Өмә итте — утын китертте. Бер яктан, балалар туа, яшьләр өйләнә, ир берлә хатын гауга итәләр, аерылалар, вә картлар үләләр. Бу эшләрнең барысы да хәзрәт аркылы үтәләр. Аз булса да кесәгә — хәрәкәт, малга бәрәкәт килә торадыр.

Сентябрь вә октябрьләр кичте. Ноябрьнең яртысы җитте. Менә хәзрәткә тагын мәдрәсә кайгысы кермәгә башлады.

Хәзрәт — бик кайгыртучан, тырышлыклы, бик тәкъва кеше, ничек булса да шул мәдрәсә кайгысыны бер дә хәтердән чыгармыйдыр. Һәм дә мужиклар да, кыр эшләре бетте, балалар буш торалар, хәзрәт укытырга башласа ярар иде, дип әйтә башладылар. Хәзрәтнең үзенең дә дәрес әйтергә дәрте зур. Ноябрь ахырында бер җомга көн җомгадан соң хәзрәт халыкка әйтте:

— Менә, җәмәгать, кыш җитте. Балаларны укытырга вакыт килде. Балаларны укытмак вә аның остазыны тәрбия итмәк ата вә анага фарыздыр. Үзегез дә беләсез, без тырышлыкта кимчелек итмибез. Сез дә шул мәдрәсәне карарга тырышыгыз. Менә утын, шәм кирәк. Насыйп булса, мин мәдрәсәгә дүшәмбе көн керергә башлыймын. Сез бу көннән үк балаларыгызны җибәрергә башлагыз. Үзебезнең мәдрәсәбез була торып, укымак өчен балаларны чит авылларга җибәргән кешеләргә рөхсәтем вә ризалыгым юк. Остазның каһәр догасы һич вакытта төшмичә калмас.

(...) Шимбә көн мәктәпкә берәм-берәм балалар килмәгә башлады. Эчне себереп чыгардылар. Ватылган тәрәзә күзләре җиренә карындыклар кордылар. Мәдрәсәнең почмагындагы

үрдәкләр кереп-чыгып йөри торган тишекне тагын шул иске таш илә тыгып, тирә-ягын чүп белән тутырдылар. Шәкертләрдән беренең анасы балчык алып килеп моны эчке вә тышкы якларыннан һәм түбән тактаның да тишек җирләрен сылады. Балалар өйләренә кайтып, берәр агач утын күтәреп алып килделәр. Мәдрәсәнең пичен яктылар. Мендәр вә чикмәннәрен сәндерәгә вә чабаталарын пич башына атып, кәтмәрләрене[1] вә комганнарын идәнгә тезеп куйдылар. (...) Пич бераз янгач, берсеннән чәй-шикәр вә берсеннән күмәч белән уртак булып кәтмәр белә чәй эчмәкче булганнар иде. Ләкин языклар булсын! Бу дөньяның кемгә рәхәт күрсәткәне бар! Арасы күп үтмәде, мәдрәсәнең эче төтен белә тулды, чөнки пич, бер дә каралмаган сәбәпле, ярылып беткән икән, һәм былтыр да берничә мәртәбә ут чыга язып куйган иде, быел тагын күп бозылган вә ярылган. Бер бала тагын өйдән анасын чакырып балчык белән морҗаны сылатты. Шәкертләр көннән көнгә артты вә дүшәмбе, ягъни хәзрәтнең дәрескә керәсе көне килеп җитте. (...)

(Әмма Әхмәтша хәзрәт атна буена мәдрәсәгә керә алмый: авыл агайлары аны йә кунак янына чәйгә, йә балага ат кушарга, йә никах мәҗлесенә чакыргалап торалар, яисә хәзрәтнең үзенә берәр кунак килеп чыга. Шәкертләр исә вакытларын шаярышып, төрле уеннар белән уздыралар.— *Төз. Ш. С.*)

Хәзрәт мәдрәсәгә кереп, бер җиргә өеп куйган мендәрләр өстенә утырып, дәрес бирергә кереште. Балалар хәзрәтнең тирәсенә җыелып, һәрбере үзенең сабагыны кычкырып укырга вә хәзрәт тә һәрберенә аерым-аерым дәрес бирергә башлады. Әлбәттә, иң әүвәл сабак алучы Җиһангир мәхдүм булды. Шул былтыр башлаган «Фәзаилеш-шөһүр» китабыны чыгарып дәрес алды. Гәрчә тотлыгып-тотлыгып укыса да, яхшы танырга башлаган иде. (...) Укыганны аңлыймы, юкмы, төрки телдә булган башка китапларны да укый беләме, күчермәенчә язу яза

---

[1] *Кәтмәр* — чуеннан ясалган бер комгандыр ки, моның илә һәм чәй эчәрләр һәм дә абдәст (тәһарәт) алырлар. (*Ф. Кәрими искәрмәсе.*)

беләме, имлясы[1] тугырымы, аз булса да хисаптан кайбер нәрсәләр өйрәнергә тиеш түгелме? Боларның һичберсе хәзрәтнең зиһененә кермидер. (...)

Хәзрәт вакыты булганда мәдрәсәгә икешәр-өчәр мәртәбә керәдер. Вакыты булмаганда вә туй-төшемнәр күбрәк булганда атнасы белә кермичә дә каладыр иде. Суфый абзый тагын мәдрәсәгә кайтты вә Ибраһим белә Исмәгыйльнең арасындагы аерманы яңа шәкертләргә бик яхшы аңлатадыр иде. (...)

Җиһангир мәхдүм әүвәлгесе кебек тырышуда иде. «Фәзаилеш-шөһүр»не чыкты... Мөәзин абзасы килгәндә «Бакырган»ны[2] бик көйләп укып дәртләндерәдер иде. Хәтта бер мәртәбәсендә мөәзиннең бик кәефе килеп, мәхдүмгә янчыгыннан ун тиенлек бер көмеш тәңкә алып бирде. Мулла җенесе өчен бирү дигән нәрсәнең никадәр авыр булдыгы бик мәгълүмдер. Аеруча, бер мөәзин өчен бу кадәр бөек бер кайгыртучанлык, теләктәшлек күрсәтү харикылгадә (гадәттән тыш) бер нәрсәдер. (...)

Кояш чыгып көннәр җылынмага вә тамчылар таммага башлагач та, мәдрәсә тагы бушалды, вә озын сакаллы карт кәҗәләр белән дәртле яшь кәҗә тәкәләре генә, мәдрәсәнең нигезе өстендә ятып, бертөрле фәлсәфи фикерләргә вә шагыйранә хыялларга талмага башладылар. Әхмәтша хәзрәт тә, абыстай вә абыстайның кардәше мөәзин белә киңәш итеп, бу елдан соң Җиһангир мәхдүмне шәһәргә мәдрәсәгә җибәрмәкче булды. (...)

---

[1] *Имля* — орфография, дөрес язу кагыйдәсе.

[2] *«Бакырган»* — XII йөздә Урта Азиядә яшәгән, төрки дөньяда киң танылган мәшһүр шагыйрь Сөләйман Бакырганый (1186 елда вафат булган) китабы. Бу китап кулъязма һәм XIX гасырда басма рәвештә татарлар арасында киң таралган, мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланылган.

Закир Һади

(1863—1933)

ҖИҺАНША ХӘЗРӘТ* (1908)

Уфа губернасында Б. өязендә төньягыннан төшлек ягына ага торган бер су буенда, суның кояш батыш тарафында, Ш. исемендә зур гына бер авыл бардыр. Урамнары рәтле төзелгән, суның буенча төньягыннан төшлек ягына сузылган. Бер якта урман улдыгыннан, күренеше гүзәлдер. Урамнарының беренчесе суның кырында (ягасында), башкалары да аның янында, берничә урамнар рәттән тезелмештер. Су янында урамнан башлап беренче, икенче, өченче, дүртенче дип санарга мөмкиндер. Болар исә авылның иң биек[1] урамнарыдыр. Бу урамнардан башка берничә кечек урамнар вә тыкрыклар дәхи бардыр.

Авылның уртасыннан үткән, биек урамнарны кискән, кояш чыгышына киткән бер юл ошбу биек авылны ике бүлемгә аермыштыр. Ул юл ерак җирләргә китәр, башкорт авылларыннан үтәр, Бәләбәй каласына җитәр. Бер аермасы Уфа шәһәренә дә илтер.

Авылның йорт-җирләре төрлечәдер. Бере башкасының тәмам киреседер: бер йорт зур булса, аның янында башкасы кечектер; бер өй биек булса, башкасы тәбәнәктер. Бәгъзеләре дә

---

* Повесть бераз кыскартып алынды.

[1] *Биек* — бу урында «зур, олы» мәгънәсендә алынган.

тәмам җир астындадыр. Өйләрнең күбесе агачтан, бәгъзеләре таштан, бәгъзесе чи кирпечтән салынмыш, бәгъзеләре чыбыктан үреп, тышкы ягыннан балчык белән сыланмыштыр. Түбәләре бәгъзесе такта, бәгъзесе тимер, бәгъзесе кабык исә дә, күбрәге салам белән ябылмыштыр. Арада бәгъзе зур йортлар, биек өйләр күренсә дә, аларның күбесе искергән, бәгъзеләре тәмам җимерелгән, иясез йортлардыр.

Бу йортларга, чынлап кына уйлап караганда, берничә ел элек бу халык бай булып, хәзердә фәкыйрь улдыкларыны белдерәдер. Халыкның җир-сулары яхшы, басулары, кырлары игенгә яраклы, печәнлек вә урманнары да күптер. Халкы өч төрледер: Казан татары, башкорт, яңа башкорт, ягъни читтән килеп башкорт булып язылган адәмнәр, яхуд[1] типтәрләр булса да, күбесе башкортлар.

Бу халыкның элек заманнарда җирләре күп булган исә дә, хәзердә бик үлчәүле генә калмыштыр. Башкортларның иске гадәтләренчә, авыл башлары юк бәһагә сатып, кем чакырып бер кәррә[2] сыйласа, аңа җир биреп, типтәрләрне вә Казан татарларыны үзләренә җирдәш итеп, бер кадак чәйгә 10 йә 15 дисәтинә җир бүләк итеп, җирләрен үзләренә дә аз калдырмышлардыр. Шулай булса да башкортларның җирләре башкаларның җиреннән күптер.

Җирләрнең бер бүлемен бәгъзе байлары картларга аракы эчертеп алдыгы кеби, бер кисәген фатыйха белән ишан хәзрәтләре дә элмештер. (...)

Муллалары күп, мөдәррисләре, ишан хәзрәтләре, зур мәдрәсәләре булса да, халкы бик надандыр: бер-ике яза белүче, өч-дүрт исемене язып куючы, болардан башкалары: каз эзе, куян эзе төшерүчеләр, бармак берлә хисап итүчеләр, таяк киртләүчеләрдер.

Бу авыл халкының надан булуына сәбәп нидер?! Өстән генә караганда, халыкта һәм гаеп күренмидер. Мулла сайлаула-

---

[1] *Яхуд* — яки.

[2] *Кәррә* — тапкыр.

рында да кимчелекләре беленмидер. Күрәсез бит, муллалары: кайсы хатыйп-мөгаллим, кайсы хатыйп-мөдәррис һәм ишан...

Шулай була торып та халык бик надандыр!..

Муллаларыннан безгә кирәклесе Җиһанша ишандыр. Шул сәбәптән, хәзердә бу авылны үз көенчә калдырып, Җиһанша ишанның туган авылына китеп, Җиһанша ишанның бала вакытыннан башлап, мөдәррис, ишан булганга кадәр башыннан үткән хәлләрен сөйләрмез дә янә ошбу авылга кайтып килермез.

Инеш атлы авылда иген игеп, хайван асрап тереклек итүче урта гына тормышлы Дәүләтша исемле бер адәмнең Мәрданша, Җиһанша исемендә ике улы булып, кече улы Җиһанша бигрәк тә үткен бер бала иде.

Дәүләтша агай, үзе надан булса да, муллаларны сөяр, муллалык вә мөәзинлекне иң биек мәртәбәдән хисап итәр, кече улы Җиһаншаны да: «Минем Җиһаншам мулла булыр, мөәзин булыр, фәлән булыр»,— кеби сүзләрне әйтеп сөядер иде.

Бу вакытта Җиһаншага унике яшь тулып, Фатыйма абыстайга сабакка йөреп, иҗек танып, сүрәгә төшеп, «Бәдәвам», «Кисекбаш» китапларын да җырлый башлаган иде. Атасының «мулла булыр» дигән сүзенә Җиһаншаның рәхәте килеп атасының йөзенә елмаеп карый иде. Чөнки Җиһанша, үзенең үткенлеге сәбәпле, мужик хезмәтендә булган мәшәкать белән муллалык хезмәтендә булган рәхәтне уйлап һәм үлчәп тә карый иде.

Бәгъзе вакытта Дәүләтша агай авылның имамы Гыйбадулла хәзрәтне ашка чакыра, хатыны Хәмидәгә яхшы ашлар хәзерләргә боера, аш хәзер булгач, Җиһанша Гыйбадулла хәзрәтне арбага ястык өстенә генә утыртып ат берлә алып килә. Дәүләтша агай каршы ала. Хәзрәт өйгә керә, халык барчасы аягүрә тора, Гыйбад хәзрәт, түргә менеп, мендәр өстенә утыра, садака ала, тамак туйдыра да арбага утырып китеп бара; Җиһанша бу эшләрне баштан ахыргача карап тора иде.

Менә безнең Җиһаншаның атасы сөйгән вакытларда, гүя Җиһанша мулла була, яшел чапан, ак чалма кия, ишектән керә,

халык аягүрә тора, түргә утыра, акча ала, аш ашый, шикәр салып чәй эчә, утырып кайтып китә... Шул нәрсәләр хәтеренә килә дә атасына карап көлеп җибәрә.

Җиһанша, адәм баласы булганлык сәбәпле, адәм булуны телидер, үзенең белүенчә, адәмнәрнең дә иң беренчесе булуны телидер, фәкать Җиһаншага адәм булуның юлын күрсәтергә тиешледер.

Бала туган вакытта чын кеше булыр, кеше булуны теләр, ата-анасында инсаният[1] булмаса, баланың да инсанияте югалыр. Һәр нәкадәр инсан булмак юлында иҗтиһад итсә дә[2], юл күрсәтүчеләр булмаса, юлында адашыр да, нә инсан вә нә хайван улыр; соңыннан үзенчә бер юл белән китәр, шул юлны туры юл дип игътикад итәр[3], башкаларны да шул юлга өндәр, ашар, эчәр. Вакыт кичәр, гомер үтәр.

Безнең Җиһанша да үзен сөяр, каршысында булган нәрсәләрнең иң яхшысын үзенә сайлар. Һәрвакытта үзенең башкалардан өстен булуын уйлар иде. Әгәр дә Җиһанша, гүзәл киемнәр киенгән, җилкәсендә укалар куелган, янында кылыч салындырган, ничә мең адәмне үзенә баш идергән командирларны, гаскәр башларын күрсә иде, шунда ук гаскәр башы булуны теләр, юлын сорашыр, юлга салучы булса, җаныны аямыйча тырышыр иде. Шул рәвештә Җиһанша муллалык фикере берлә сабакка бара. Фатыйма абыстай: «Балам, тырышып кына укы, мулла булырсың!» — дип, үгет-нәсыйхәт кыла; Җиһаншаның бу сүзгә рәхәте килеп көлә, баягы хыяллар вә фикерләр: хәзрәтнең яшел чапаны, ак чалмасы, ашка баруы, акча алуы хәтеренә килә иде. Фатыйма абыстайның морады[4]: укы, галим булырсың, димәк иде; әгәр дә Җиһаншаның фикерендә булган нәрсәләрне белсә, мулласына иптәш мулла булудан куркып, ул сүзне авызыннан ычкындырмаган булыр иде.

---

[1] *Инсаният* — кешелек.
[2] *Иҗтиһад итсә* — тырышса да.
[3] *Игътикад итәр* — ышаныр.
[4] *Морады* — уе, теләге.

Кыш үтте, кар бетте, җир ачылды, сабан туйлары да узды, Гыйбад хәзрәт тә сабан өмәсе итте. Өмәгә Дәүләтша агай да барды. Янында Җиһанша да бар иде. Гыйбад хәзрәт үзе дә барып, сакалын сыпырып-сыпырып, борын үтә генә сөйләп, халыкка хезмәт боерды. Җиһанша да хәзрәтнең хезмәте җиңел генә беткәнне күреп торды. Сабан бетте. Җәйнең яхшы вакытлары килде. Дәүләтша агай да, Гыйбад хәзрәтне чакырып, фатыйха алмакчы булды. Тавыклар арасыннан сайлап иң яхшысын суеп, Хәмидәгә бирде. Хәмидә дә тавыкны әрчеп йомырка белән тутырып пешерде. Тавык шулпасы хәзерләде; бер айдан бирле ашамыйча җыйган майны хәзерләп, май белән ашарга майлы-йомыркалы күмәч тә пешереп, самавырны кайнатып, каплап куйды. Бервакыт ак чалмалы, яшел чапанлы Гыйбад хәзрәт капкадан керде. Дәүләтша агай каршы алды. Хәзрәт, ишектән кереп, түргә узды. Ястык өстенә менеп, йомырка өстенә утырган кош кеби утырды. Дәүләтша агай садака сонды[1], хәзрәт алып дога кылды. Хәмидәнең дә 25 тиен нәзере бар икән, Дәүләтша аркылы хәзрәткә бирдерде. Соң Дәүләтша агай тавык шулпасын хәзрәтнең каршысына куйды. Шулпадан соң тавык ите дә килде. Хәзрәт тә Дәүләтша агайның һәр эшендә пөхтәлекне, Хәмидәнең дә тавыклар ашатырга, ашка-суга осталыгын сөйләп, яхшы вә йомшак җирләрен сайлап, мактап-мактап ашады. Аштан соң чәй, чәй янында күмәч белән май, аштан соң булса да, чәй арасында күмәч белән май да терәлеп тормады. Мәҗлес тәмам булды, фатыйха кылды. Чыгып, өенә кайтып китте. Дәүләтша агай хәзрәтне озатып калды. Җиһанша да хәзрәтнең кереп утырганнан башлап чыгып киткәнгә кадәр булган хәлләрене берәмберәм күздән кичерде: хәзрәтнең ак чалмасы, яшел чапаны, озын борыны, түгәрәк сакалы, каршысындагы тавык итләре, май-күмәчләре, чәй-чынаяклары Җиһаншаның хәтерендә урнашып калды. Атасының тереклегендә булган мәшәкатьләр белән хәзрәтнең рәхәтен үлчәп карады, бу вакытта Җиһанша

---

[1] *Сонды* — сузды, бирде.

үзе дә, тырма тырмаларга, себерке себерергә йөреп, дөнья газабын күрә башлаган иде, шул сәбәптән ничек итеп мулла булырга, бу газаптан ничек котылырга дип уйлый башлады.

Уйнаган вакытларында да үзе мулла булып, башка балаларны мужик итеп уйный иде. Өйдә аулак калган вакытларында үзен муллага охшатып, иягенә корым сөртеп түгәрәк сакал ясап, атасының озын җиләнен киеп, башына сөлге чорнап, көзгегә карап, үзенең муллага охшаганын күреп бик куана иде.

Остазы Фатыйма абыстайдан да муллаларның дөньяда вә ахирәттә рәхәт күрәчәкләрен, ахирәттә мужикларга ярдәм итәчәкләрен, садака биргән адәмнәрне үзләре белән оҗмахка алып керәчәкләрен ишетеп белгән иде.

Шулай булса да Җиһанша, яшьлеге сәбәпле, мулла булуның юлын, күпме укырга, кайда укырга, муллалыкны кайдан алырга — боларны белми иде. Фәкать Фатыйма абыстайның: «Укыңыз! Мулла булыңыз!» — дигән сүзене ишетеп, шул абыстайдан укыган балаларның күп укыганнары мулла булып чыга торгандыр, дип уйлап йөри иде. Шулай булса да аңар бик ышанып җитми, Җиһанша алдында укыган балалардан берничәсе чыкты, берсе дә мулла булмады. Алай булса да Җиһанша мулла булудан өметен кисми иде.

Янә җәй үтте, көз җитте. Балалар Фатыйма абыстайга сабакка йөри башлады. Җиһанша да, мулла булу дәрте белән, укырга кереште. Иҗтиһады сәбәпле, төрки таныды[1]. Берничә сүрәләр[2] дә ядына алды. Мулла булырга гына эш калды. Төрки таныгач, үзенең белгән китапларын укый башлады; голәманы мактаган җирләрне күрә. Фатыйма абыстай голәманы муллалар ди, шул сәбәптән Җиһанша китапта голәманы мактаган җирләрне укып рәхәте килә; муллалыктан бөек дәрәҗә юк дип белә иде. Бервакытта Дәүләтша агай илә Җиһанша шул сүзләрне сөйләштеләр:

Дәүләтша: «Мәхдүм атасы урынына мулла булган».

Җиһанша: «Ул мәхдүм ничә ел укыды?»

---

[1] *Төрки таныды* — «ана телендә язу таныды» мәгънәсендә.

[2] *Сүрәләр* — Коръәннән өзекләр.

— Өч ел укыды.

— Мин инде дүрт ел укыймын, мин дә мулла булырга ярармын.

— Мәхдүм, атасыннан берничә ел укыганнан соң, мәдрәсәгә барып өч ел укыды.

— Мин дә мәдрәсәгә барып өч ел укырмын да мулла булырмын.

— Юк, угылым. Өч ел уку белән мулла балалары гына атасы урынына, яисә бай баласы акча белән генә мулла була; безнең кебек мужик баласына хәлфә булганчы укырга кирәк була.

— Ничә елдан хәлфә булырга мөмкин?

— Унбиш ел, аз булганда ун ел укырга кирәк, хәлфә булгач та берничә ел торырга кирәк, шуннан соң урын чыкса...

— Бик озак.

— Муллалык җиңел генә килми шул, укыр өчен озак вакыт, тырышлык, байлык кирәк. Безнең Гыйбад хәзрәт: «Укыр өчен Нухның гомере, карунның байлыгы кирәк. Уку энә белән кое казу кебидер»,— дип әйтә.

— Алай бай балалары гына укый торгандыр?

— Мәдрәсәдә бай шәкертләргә хезмәт итеп укучы ярлы шәкертләр дә була.

— Мин дә Тирыш (Торыш?) авылына мәдрәсәгә барыр идем, күп кенә укып, мулла булыр идем. Анда безнең кардәшләребез дә бар.

— Юк, угылым, ул мәдрәсәдән мулла булып чыккан кеше юк. Ярми хәлфә, анда ун ел ятып, ахырда мөәзин генә булып чыкты.

— Хәзердә кайсы мәдрәсәдән муллалар күп чыга?

— Чорнаш авылының Габдрахман хәзрәт мәдрәсәсеннән муллалар күп чыга, Габдрахман хәзрәтне бик гыйлем кеше диләр. Беркөн безнең Гыйбад хәзрәт: «Чорнаш Габдрахман хәзрәт кебек гыйлем кеше дөньяда булмас»,— дип мактап сөйләде.

— Чорнаш бездән еракмы?

— Алтмыш биш чакрым, дип йөриләр.

— Мине дә Чорнашка укырга илтер идегез.

— Без бай кешеләр түгел шул. Укуга мал кирәк дип хәзер генә әйтеп үткәрдем.

— Мин, әти, шәкертләргә хезмәт итеп тә тук булыр идем. Тырышып кына укыр идем.

— Укыр идең. Синең сабакка япьтәшлегең бар, бәлки мулла да булыр идең. Гыйбад хәзрәт: «Фәкыйрьлек белән укыган шәкертләр бигрәк тә мулла булалар»,— дип әйтә. Анаң риза булырмы? Абыстай рөхсәт бирерме? Остаздан[1] дога алмаенча китәргә ярамас. Остаз хакы ата-ана хакыннан артыграк, диләр.

Бу сүзләрдән соң Дәүләтша агай Җиһаншаның укырга дәрте барлыгын белде. Хәмидәгә дә киңәш итте. Ул да риза булды. Абыстайга да барып рөхсәт сорады. Фатыйма абыстай күтәрелеп бәрелде. «Быелга калсын, асла (һич) ризалыгым юк»,— диде. Дәүләтша агай Гыйбад хәзрәтне чәйгә чакырып карады. Хәзрәт: «Асла ризалыгым юк, абыстасыннан үзенә кирәк кадәр укыр. Аңа мулла булмаска»,— дип җавап бирде.

Шуннан соң Җиһанша: «Атам җибәрмәсә, качып булса да китәрмен»,— дип, анасына сөйләнеп йөри башлагач, анасы бу эшкә бик кайгылы булды. Чөнки Җиһаншаның үзсүзле бер бала улдыгыны бик яхшы белә иде. Шул сәбәптән качып китәр дә ни дә булса булыр дип курыкты. «Инде усал җиргә бармый, яхшы җиргә бара, урынсыз дога төшми, диләр, аларга карап баламны югалтыр хәлем юк, атасы, илтеп кайт! Ходага тапшыраек»,— диярәк, Хәмидә Дәүләтша агайга сөйләде. Шуннан соң Дәүләтша агай Җиһаншаны Чорнашка илтеп, Габдрахман хәзрәткә бирде. Бу эшне Гыйбад хәзрәт тә ишетте, шул кич Дәүләтша агайның Җиһаншаны иптәш мулла итәргә приговор җыеп йөргәнене төшендә күреп куркып уянды да як-ягына карап төкерде, төшне Фатыйма абыстайга сөйләде, Фатыйма абыстай да: «Бәгъзе төшнең киресе керә, кирегә булсын»,— дип юрады.

---

[1] *Остаз* — өйрәтүче, тәрбияче, юл күрсәтүче; монда «сабак укытучы» мәгънәсендә.

Шул көннән башлап Гыйбад хәзрәт Дәүләтшага дошман булды. «Ул мөнафыйк[1] бәңа дошман»,— дип, артыннан сөйләр иде.

Җиһанша атасыннан аерылып мәдрәсәдә калгач, Габдрахман хәзрәт Җиһаншаны Таһирҗан хәлфәгә бирде. Җиһанша да, сабакка күңел биреп, иҗтиһад белән укырга кереште.

Җиһанша мәдрәсәдәге хәлфәнең хәлләрене, көмеш сәгать чылбырыны муеннарына элеп, түбәтәйне кыңгыр гына киеп, мыекларыны борып, каршыларына шәкертләрен җыеп, сабак өйрәткәннәрене, озын җилән, ак чалма киеп, читек-кәвештән акрын гына шыгыр-шыгыр шыгырдап кына мәчеткә яки мәҗлескә килгәннәрене, хәлфәләр үткәндә шәкертләр аягүрә торып хөрмәт иткәннәрене, хөрмәткә кимчелек күрсәткән шәкертләргә җәза бирдекләрене, чит мәдрәсәләргә моназарага[2] йөрдекләрене күреп, бик кызыга иде.

Җиһанша барча хәлфәләрдән артык үз хәлфәсен сөя: хәлфәсенең холык вә табигате, Җиһаншаның фикеренчә, бик гакылга тугыры килә, шул сәбәптән Җиһанша да холыкта вә табигатьтә, кыланышта вә күренештә хәлфәсе кебек булырга иҗтиһад итә иде.

Җиһанша бу эшендә хаксыз дәгел, бу бер Җиһаншаның гына да фикере дәгел, башка шәкертләр дә: «Дөньяда беренче галим — Габдрахман хәзрәт, хәзрәттән кала — Таһирҗан хәлфә»,— дип сөйлиләр иде.

Таһирҗан хәлфә үзе бер куштан мулланың өченче хатынынан туган, башка туганнарыннан үткенрәк булган, үги туганнар белән узышып, көнләшеп, хурлашып, талашып үскән, соңыннан мәдрәсәгә килгән, үгилек тәрбиясе илә шәкертләрне дә җиңгән иде. Таһирҗан хәлфә һәр эштә башкалардан өстен булуны сөяр, каршы килүчеләргә теләгән кадәрле зарар итәр, башкаларның өсләренә басып китәр, үзенең теләгән максатына җитәр иде.

---

[1] *Мөнафыйк* — икейөзле кеше.

[2] *Моназара* — бәхәсләшү.

Таһирҗан хәлфә яшь вакытларында сәфаһәт галәмендә[1] булды, күп эшләр башыннан узды исә дә, бу соңгы елларда суфыйлык күрсәтеп, тәсбих тотып, хәзрәткә мөрит булып, ул эшләрне күмде... Габдрахман хәзрәткә якыннардан булып, бөтен мәдрәсәне кулга алды. Әгәр дә шәкертләрдән бере өскә китә башласа, Таһирҗан хәлфәнең көнчелек тамырлары хәрәкәткә килер, селкенер, ачуыннан йөрәге ташыр, гакылыннан шашар. Ул шәкерттән ничек булса да үч алырга, бер гаеп табарга, мәдрәсәдән тәмам куарга тырышыр иде.

Бер хатыны атасы өендә, бере каенатасы өендә булса да, һаман да хатын-кызга яшь чагындагы кеби... иде.

Габдрахман хәзрәтнең үсеп килә торган бер гүзәл кызы улдыгыннан, Таһирҗан хәлфәнең дә нияте шул кызны ничек булса да үзенә каратып, алдап, өченче хатынлыкка алып, Габдрахман хәзрәтнең урынына мөдәррис булып калмакчы иде. Бу вакытка кадәр ни уйлады, шул булды; шул сәбәптән бу эшкә дә керешкәндә булмый калыр дип хәтеренә килми, якыйнән[2] булыр дия уйлый иде.

Мәдрәсә янында кибет ачып, шәкертләргә өч бәя берлә сатып, авыл халкына да бурычка чәй таратып, бераз акча да җыйган иде.

Таһирҗан хәлфә Габдрахман хәзрәтнең иң якын хәлфәләреннән булган, якынлыкның чигенә терәлгән, яңадан артык якын булырга юл да калмаган иде.

Безнең Җиһанша да шул мәдрәсәдә сигез-тугыз ел гомерене үткәрде. Холык вә табигате дә, фикер вә исеме дә үзгәрде: моназир[3] Җиһанша, Җиһанша казый, Җиһанша хәлфә исемнәре белән мәшһүр булды. (...)

Авылына кайтканда Дәүләтша агай илә Хәмидә куансалар да, Фатыйма абыстай илә Гыйбад хәзрәтнең бәгырьләрене көйдерә, тавык итләрене агу итеп йийдерә[4], мәҗлесләрдә Гыйбад

---

[1] *Сәфаһәт галәмендә* — бозыклык дөньясында.

[2] *Якыйнән* — һичшиксез.

[3] *Моназир* — бәхәскә оста.

[4] *Йийдерә* — ашата.

хәзрәт берлә кычкырышырга керешә, өстенә өстәл сугып кычкыра иде. Шушы сәбәптән Гыйбад хәзрәт бик кайгыра, бу нәрсә иптәш мулла булса, башыма бер бәла булыр, дип төшенә-төшенә бераз йөткерә дә башлаган иде, чөнки авыл кешеләре дә: «Җиһанша хәлфәне үзебезнең авылдан җибәрмәскә кирәк, бер муллага урын бар, Ходa ризыкларын ирештерер»,— дип сөйләнә башлаганнар иде. Дәүләтша агайның да, Җиһаншаны үз авылына мулла итеп, мулла атасы булып, чалма-чапан киеп, угылы берлә ашка йөрергә дәрте бар иде. Бәгъзе вакытта төшендә, Җиһанша мулла була, угылы берлә ашка бара, мәҗлестә, син мулла атасы, түргә утыр дип, Дәүләтша агайга да Җиһанша янында утырырга боералар; Җиһаншага садака биргәндә, Дәүләтша агайга да садака соналар да, Дәүләтша агай кулларыны сузып уянып китә, Хәмидәгә сөйләп, икәү куанышалар иде.

Әмма хәзрәт исә төшендә Җиһаншаның мулла булганыны күрә. Гыйбад хәзрәт мәҗлестә вакытта Җиһанша килеп керә. Түргә менеп, хәзрәт янына утыра. Хәзер бер сүз чыгарып өстәл сугып кычкыра, хәзрәт куркып, калтыранып уяна да як-ягына төкерә иде.

Гыйбад хәзрәт илә Дәүләтша агайның Җиһанша хакында уйлаган фикерләре хата иде. Чөнки бу вакытта Җиһаншаның фикере башка иде; мулла булса да, үз авылына мулла булмаска, кайда булса да бер яккарак китеп мулла булырга, бер бай кызын алырга, бояр кеби торырга. Дәүләтша угылы дигән исемне калдырырга, яисә Бохарага барырга, мөдәррис булып кайтырга уйлый иде.

Таһирҗан хәлфә дә Җиһаншаны өскә җибәрмәскә тырышып карады исә дә булдыра алмады. (...)

Җиһаншаның бу вакытта күбрәк уйлаган нәрсәсе баю белән өйләнү мәсьәләсе иде; боларда ике юлның берсен ихтыяр итәчәк иде.

Берсе — бай мәхәлләгә мулла булып, бер байның кызын алып, мәдрәсә салып, дәрес әйтү; вә берсе дә Бохарага барып кайтып, мөдәррис булып ишанлык кылып, байларны кулга алып, барча муллалар вә мөдәррисләргә өстен булып, теләгән

кадәр хатын алып, гомерене рәхәт кичермәк иде. Җиһанша әүвәлдә авылга мулла булып, бәлеш ашап йөрергә канәгать кыла иде. Канәгать кылуына сәбәп рәхәтнең башка төрлесене белмәгәнлектән, үзенең дә булдыруына ышанмаганлыктан иде. Хәзер Габдрахман хәзрәтнең ике остабикә белән кадер-хөрмәттә генә торуын, абыстай белән янәшә утырып, тройкада кунакка йөрүен күреп, фикере үзгәрде. Үзенең дә бу вакытка кадәр ни уйлаганы була килде, шул сәбәптән горуры артты; имде авылга мулла булуны, Дәүләтша угылы булуны да теләми иде. (...) Бохарага китәргә дип кисеп уйлады.

Бу фикерне Габдрахман хәзрәткә сөйләде, Габдрахман хәзрәт: «Укыган кешегә монда һәм Бохарадан ким түгел. Бохарага барып та буш килгән адәмнәр күптер; мән сәбәтә нәбәтә, ягъни бер җирдә генә торган нәрсә үсәдер димешләр»,— дип җавап бирде. (...)

Җиһанша хәзрәтнең рөхсәт бирмәслеген белде. Шуннан соң Җиһанша өенә кайтып китте. Ата-анасыннан рөхсәт алып, берничә көннән соң Бохарага сәфәр кылды.

Җиһаншаның бу эшенә Гыйбад хәзрәт бик куанды исә дә, Дәүләтша агайга бу эш авыр күренде, чөнки мулла атасы булып, ашка йөрергә вакыт җитте дип торганда гына, Җиһанша Бохарага китте.

Дәүләтша агайның да авызыннан аш төште. Габдрахман хәзрәт тә: «Минем рөхсәтемнән башка китеп, бәһрә[1] тапмас»,— дип сөйли иде. Җиһанша берничә еллар Бохарада калды. Бу араларда атасы Дәүләтша вафат булып, Җиһанша да Дәүләтша угылы булудан котылды.

Шүрәле авылында кыш урталарында, гыйнвар аенда, кич сәгать тугызда аяз, ай яктысы фонарь кеби авылның барча урамнарыны бик ачык күрсәтә; агачлар исә һәркаюсы һаваның суыклыгыннан хәбәр бирә, каюсы чарт, каюсы чырт дип кычкырып җибәрә, юлчыларның чаналары, гаять тә суыклыктан,

[1] *Бәһрә* — «бәхет, өлеш» мәгънәсендә.

шыгыр-шыгыр дип илерә, урамнан үтүчеләр дә суыктан куркып йөгерә иделәр. Иске мәхәлләдә Фәтхи агай өендә бер җыен бар, мәхәлләнең картлары вә яшьләре җыелганнар, өйнең түрендә бер... адәм утыра, өстенә сырган чапан киеп, билене соры чалма берлә буган иде. Ишектән кергәч уң якта, түрдән беренче тәрәзә турысында, өстәлгә каләм, кара савыты, бер зур табак кәгазь куелган; өстәл янында бер язучы да утырган иде. Язучы: «...әфәнденең имам булуына разый булган адәмнәр ошбу кәгазьгә тамгаларыгызны салыгыз. Язу белгәннәрегез кулларыгызны куегыз!» — дип әйтеп тора.

Шуннан соң халык, берәм-берәм килеп, каләм алып, өстәлдәге кәгазьгә каюсы куян эзе, каюсы сәнәк, каюсы чүкеч сурәте ясап киттеләр; фәкать өч адәм исем, фамилияләрене яздылар.

Бу адәмнәр, үзләре надан булсалар да, гыйлем сөярләр, голәмага мәхәббәт идәрләр, үзләренең наданлыкларына үкенәләр, балаларының да үзләре кеби надан булуын теләмиләр иде. Шул сәбәптән киләчәкне төшенеп, бер галим адәм табып, вәгазь-нәсыйхәтләре илә эш кылып, наданлыктан котылуны уйлап, барчасы бергә җыелып, киңәшләр иттеләр дә Дәүләтша угылы Җиһаншаны муллалыкка китерделәр, шул җыенда приговорны тәмам кылдылар.

Бу вакытта Җиһаншаның, Бохарадан яңа кайтып, мәҗлесләрдә сүз чыгарып, халык теленә кергән вакыты иде. Җиһанша, әүвәлдә сөйләгәнебезчә, Габдрахман хәзрәт мәдрәсәсендә укып, Таһирҗан хәлфәдән өлге алып, әхлак киеме печеп, соң Бохарага барып, ул киемне Бохара риясы[1] белән тышлап, төрле буяулар белән буяп кайтканга, авыл халкы Җиһаншаны күркәм холыклы, галим вә белекле бер зат дип беләләр, аннан күп нәрсәләр өмет итәләр иде. Шул рәвештә Җиһанша имам булды. Указны[2] кулга алды. Бохарилык белән атаклы булып, дәүләтле бер адәмнең кызына никахланып, Шүрәле авылына торырга килде. (...)

---

[1] *Риясы* — ясалмалылыгы.

[2] *Указны* — мулла булу турында бирелә торган документны.

Бара-тора башка авыл муллаларыны да үзенә ияртеп, бәгъзеләрене үзенә ярдәмче итеп, ишанлык арбасына утырып, наданлык сахрасында гизеп, адәмнәр җитмәгән җирләргә барып, хуҗа булмакчы иде. Ул бу авылда башка мәдрәсә булдырмассызлык, үзеннән башкаларны мөдәррис итеп танытмассызлык фикерендә иде. (...)

Җиһанша хәзрәт дәрес әйтә башлап, Бохара исеме илә бераз шәкерт җыелса да, берничә елга кадәр бик артмады.

«Берәү үлми, берәү көн күрми» дигән кеби, берничә елдан соң авыл мөдәррисләреннән берничәсе вафат булып, Җиһанша хәзрәтнең мәдрәсәсенә күп шәкертләр вә хәлфәләр килә башлады. Мәдрәсәләр тулды. Җиһанша хәзрәткә дә хезмәт җиңел булды.

Мәдрәсәне байлар салдыра, төрле яктан шәкертләр килә, Җиһанша хәзрәт шәкертләргә бәгъзесенә шәкерт, бәгъзеләренә хәлфә дип исем бирә; шәкертләр укый, хәлфәләр укыта, Җиһанша хәзрәт үзе авылларга кунакка китә иде. (...)

Бу хәлдә күп еллар вә айлар үтте. Җиһанша хәзрәтнең эшләре елдан-ел алга китте: инде үзене халыкка ишан дип күрсәтә башлады. Ишанлыгы мөдәррислеккә, мөдәррислеге ишанлыкка ярдәм итте. Мәдрәсәсеннән күп муллалар чыкты, күп адәмнәрне үзенә мөрит итте; күп мәхәлләләр вә авыллар аның кулына күчте.

Мөритләрнең маллары һәм балалары да Җиһанша хәзрәтнең иркендә иде. Малларыны теләгәнчә сарыф кылыр; теләгән кызны теләгән егетенә бирер; мөритләр дә үзләрене, малларыны вә балаларыны — барчасыны Җиһанша хәзрәтнеке дип белерләр иде.

Җиһанша хәзрәт, әүвәл үзене мөдәррис итеп күрсәтергә тырышып, осталыгы аркасында үзенең теләгәненә иреште. Дәрес әйтә башлаган вакытларда гына башка авыллардагы мөдәррисләр вафат улып, шәкертләре Җиһанша хәзрәт мәдрәсәсенә килеп, еллар үтеп, хәлфә булып, исем җәйделәр, ахырда һәркаюсы мулла булып чыктылар. Үз урыннарына хәлфәләр калдырдылар. Бу хәлләр Җиһанша хәзрәтнең исеме таралуга, шәкертлә-

ре артуга сәбәп булды. Башкалар да, моны күреп, ул хәлфәләр Җиһанша хәзрәттән укып галим булганнар дип белделәр; хәлфәләр күп дип, шәкертләр килде, шәкертләр күп дип, хәлфәләр килделәр. Күп муллалар балалары вә бай балалары да килде; бәгъзесе укыды, бәгъзесе укытты. Халык та моны күрде. Күп адәмнәр Җиһанша хәзрәткә иярде. Җиһанша үз авылындагы муллаларга вә башка авыл муллаларына да өстен булды.

Шуның өстенә ишанлык флагыны да күтәрде. Күп адәмнәрне каршысына китерде. Күккә очырды, җир астына да төшерде. Диңгез кичерде, сыйраттан уздырды, җәннәткә гиздерде, хуриларны[1] күргәзде. Үзенә иярмәгән адәмнәрне, шайтан юлдашы яхуд мөнафыйклар дип, мөшрикләр[2] янына тездерде... Җәһәннәмгә кергезде... Буныңлә бәрабәр үзенә шәригать юлыннан тар бер юл төзеде, ул юлдан йөрмәгән адәмнәрне, бәгъзе галимнәрне дә: «Алар юлдан адашканнар»,— дип сөйли иде. Үзенә ияргән адәмнәргә шул юлны шәригать юлы дип күрсәтер иде. Ахыры елларда үз юлына үзе дә сыймый, үз юлыннан үзе чыгып йөри башлады. Файданы китерер өчен хәер-дога, зарарны китерер өчен бәддога коралы кулланыр иде. (...)

Хәер-дога өчен Җиһанша хәзрәткә садака бирәләр. Хезмәт итәләр, бәддогадан куркып, нәзерләр әйтәләр, малларыны корбан итәләр. Әгәр Җиһанша хәзрәтнең якын адәмнәреннән берсе фәкыйрьлеккә төшсә йә хәстә булса, бәлаләрнең иң катысы пәйгамбәрләргә, алардан соң изгеләргә була... Бу адәм вәлиләрдән[3] дия иде. Әмма дошманнарыннан бере бай булып рәхәттә гомерене кичерсә, Аллалы Тәгалә сөймәгән адәменә барча теләгән нәрсәләрене дөньяда бирер, дип кенә җелдерә[4] иде.

Өшкерү-төкерү белән дә күп авыруларга шифа бирә, күп хәстәләрне тергезә... иде: өшкергән авырулары йә үлә, йә терелә. Терелсә: «Минем өшкерүемнән терелде»,— ди; үлсә: «Үлемгә дару юк»,— дип җавап бирә иде. (...)

---

[1] *Хуриларны* — хур кызларын.

[2] *Мөшрикләр* — мәҗүси; ислам динендә булмаучылар.

[3] *Вәлиләрдән* — изгеләрдән.

[4] *Җелдерә* — алдалап сөйли белә.

Халыкны дөнья кумаска, дөньядан качарга боера: «Дөньяны кусаң качар, качсаң куар»,— дия иде.

Җиһанша хәзрәт бу сүзне әйтүдә хаксыз дәгел... Җиһанша хәзрәт, дөньядан качып йөри-йөри, бу соңгы елларда дөнья аны әсир әйләмеш, кулына алмыш иде! Җиһанша хәзрәт дөньядан кача белмәдеме?! Югыйсә дөнья аны осталык берлә кудымы?! Җиһанша хәзрәт, качкан саен, дөньяның уртасына керә барды. Ефәккә чорналган ефәк эчендәге ефәк корты кеби, Җиһанша хәзрәт тә, дөньяга чорналып, дөнья уртасында калды...

Бер адәмнең өч аты булса, берене садакага бирергә, өч сыердан да берене вә башкача артык малларыны һаман садака кылырга боерыр иде. Мөритләр исә андый зур садакаларны үзе кеби бер адәмгә бирмәс, муллага бирүне дә мәгъкуль күрмәс; ишан хәзрәттән башкага бирүне теләмәс иделәр. Шул сәбәптән мөритләр, маллары арта башласа, болай дөнья куарга ярамас, бераз ахирәтне дә искә төшерергә, җәннәттән бераз урын алып калу, сарайлар салыр өчен беразыны ишан хәзрәткә бирергә дип, атын җигеп, арба янына бер ат йә бер сыер тагып, арбасына бер-ике куй салып, иген сатып, берничә сумнар акча да алып, Җиһанша хәзрәткә илтәләр. Садакаларын биреп, җәннәт ачкычларыны алып китәләр иде. Бәгъзеләре Җиһанша хәзрәтне өйләренә кунакка алдыралар да, садакаларыны биреп, җәннәт ачкычын алып, теләгән урыннарына җәннәткә сарайлар да салдыралар иде.

Җиһанша хәзрәт моның илә генә калмый, мәхәллә халкының куштаннарыны кулга алып, бәгъзеләренә дога кылып, берничә йөз дисәтинә җирләрене дә осталык берлә алды, үзенә шактый бер дәүләт хасил кылды.

Инде яшь вакытта уйлаганнары күбесе тугыры килде: ике остабикә алды. Бере мулла кызы, бере бай кызы; алар да үзе уйлаганча туры килде: бере симез бәдәнле, йомшак тәнле, кара кашлы, кара күзле; вә бере дә нәфис тәнле, нечкә билле, ак йөзле, күксел күзле иде. Янә дә бер урта буйлы, соргылт күзле, кызыл йөзле вә алма битле кызга күзе төшеп, бик дәртләнеп алырга йөрде исә дә, бу юлы никтер теләгәне булмады.

Җиһанша хәзрәт шул заманның бөек бер адәме булгач, гавам халкы вә бәгъзе аңар ияргән муллалар да аңа киңәшкә киләләр. Һәр эшләрендә аңа киңәш итәләр. Аннан гакыл алып китәләр дә аның белән эш итәләр иде. Халыкның алга китүен уйлаган бер заманда, ул аларны берничә адымнар артка кайтарып җибәрә иде.

Җиһанша хәзрәтнең игътикадында[1]: мөселман падишалыклары арасында Бохарадан куәтле падишалык юк. «Бохараны фәрештәләр саклый, Бохара белән Өргәнечне һичбер падишалар ала алмаслар. Бохараны ком алыр, Өргәнечне су алыр»,— дип әйтә иде.

Гомерендә өч кәррә хаҗга барды исә дә, шундаен биек җәмгыятьтә булса да, һичбер файдалы нәрсәләр китермәде. Күзе ачылмады, фикере төзәлмәде.

Җиһанша хәзрәт тереклек эшләрендә дә халыкка гакыл бирсә дә, аның кәсеп тугырысында булган фикере игенчелектә Шәрәфи агайның сукасыннан, сатуда чүпрәкче Фәтхи агай илә кибетче Шәхми агайның сәүдәсеннән, һөнәрдә, осталыкта тимерче Якуп агайның һөнәреннән үтми иде.

Бәгъзе халык кояш вә ай тотылуның сәбәпләрен вә аның булачагын электән хәбәр бирүчеләр тугырысында сорасалар: «Боңа тугыры килсә дә ышанмагыз, бу гаиптән[2] хәбәр бирү була, ул хәбәр бирүчеләр — кяферләр»,— дип җавап бирә иде.

Хаҗ сәфәрендә вакытта мөритләре: «Электрик фонарьлары яктысында намаз укырга ярыймы?» — дип сорагач: «Маеның пакьлеге вә нәҗеслеге беленмәгәнлек сәбәпле, шөбһәледер, ихтиятән[3] укымаска тиеш»,— дип җавап бирмеш иде.

Шул ук сәфәрендә, бер рус шәһәрендә мөритләр берлә базарга чыгып, мөселман суйган ит эзләп, руслардан алмаенча, яһүдиләрнең дә яһүди икәнлекләре билгеле түгел дип, ышанмаенча, байтак йөргәннән соң, бер төрекчә белә торган, башына фәс кигән итче әрмәнгә туры килеп, төрекчә сөйләгәнен ишетеп,

---

[1] *Игътикад* — ышану.
[2] *Гаиптән* — киләчәктән; булмаганнан.
[3] *Ихтиятән* — саклык өчен.

«Менә мөселман ите, Ходa каян туры китерде»,— дип, әрмәннән алмышлар иде.

Газета укучылар гыйлем вә мәгарифкә дәлаләт кылалар[1], укырга кушалар дип, «Шулай шул, менә балаларыгызны укытыгыз! Мулла булырлар, мөәзин булырлар»,— дип, һәркемне муллалыкка укырга куша иде.

Чөнки, аның фикеренчә, гыйлем вә мәгърифәт арттыру — халыкны муллалыкка укытып, мулла вә мөәзин итү берлә һәм динне куәтләү — мәхәллә күбәйтү, һәр мәчеткә ике мулла, бер мөәзин куюдан гыйбарәт иде. Мәхәлләсендә яза белүче ике адәм булдыгы кеби, исемен язып, кул куя белүче дә өчтән артык юк иде.

Үзенең йорт-җирләрене бик нечкәләп караса да, мәдрәсә эшләрене бик өстән йөретә иде. Аның шәкерт җыюы, мәдрәсә каравы җигәр өчен ат, савар өчен сыер, йон өчен куй асраудан аермасы юк иде.

Мәдрәсәсендә кырык-илле яшьле хәлфәләр булса да, шәкертләр дә күп булса да, нә дөнья хәленнән вә нә башкасыннан хәбәре булмаган бичаралар иде. Аларча: «Җиһанша карт кеби дөньяда галим юк. Бу мәдрәсә кеби җир йөзендә мәдрәсә юк». (...)

Җиһанша хәзрәтнең ике абыстайдан күп мәхдүмнәре, үткен вә кабилиятле балалары булса да, анларга тәрбия биреп, яхшы тәрбияле мәдрәсәләрдә укытып адәм итә алмады.

Мәдрәсәсене дә тәртипкә салып, вәкыфлар тәгаен иттереп[2], даими сурәттә нигезне тазартып калдырырга кулыннан килмәде. Күп вакытлардан бирле дәвам итеп килгән вәкыфлы Бохара мәдрәсәләрендә укып кайтса да, аннан гыйбрәт алып, үз мәдрәсәсене дә шул мәдрәсәләр кеби итәргә һич тә хәтеренә килмәде. Башка эшләр хакында бик күп төшләр күрсә дә, мәдрәсә хакында бер кәррә дә төшенә иңмәде. Халык файдасына сарыф ителәчәк акчаларга, җәннәт сарайларыны сатып, үзенә

---

[1] *Дәлаләт кылу* — өндәү.

[2] *Вәкыфлар тәгаен иттереп* — мәдрәсәгә доход биреп торучы милек билгеләтеп.

сарайлар салдырды. Праклар сатып[1], атлар алды; шул сәбәптән аңа ияргән кешеләр барчасы гыйлемнән мәхрүм калды. Шулай итеп, Җиһанша хәзрәт берничә еллар халыкның малыны вә ашыны яхут башыны рәхәт-рәхәт ашады исә дә, бәгъзе вакытларда бугазына аркылы китерүчеләр дә булды. Ахыры гомерләрендә бәгъзе фикерле адәмнәр тарафыннан газета вә рисаләләр чыгып, бераз хафа кыла[2] башладылар.

Җиһанша хәзрәтнең мөдәррис булып, кызып дәрес әйтергә, шәкерт күбәйтергә, атаклылыгыны җәяргә тырышкан вакытларында гына, Шакир мәхдүм Кышкардан[3] кайтып, таш мәчеткә имам хатыйп, мөдәррис булып, боның күңеленә курку салды. Чөнки Шакир мәхдүм Кышкар мәдрәсәсендә укыла торган «фәннәрне» һәркайсын күргән. «Ханимелла»ны, «Казый мирза»ны[4] вә башка хашияләрне[5] дә күреп үткән. Казанга, Түнтәргә моназарага, бәхәсләшергә йөргән, мөҗадәлә[6] берлә күп адәмнәрне җиңгән иде. Шул сәбәптән оятсызлыкка өйрәнгән, һичберәүдән курыкмыйча сөйләргә гадәтләнгән, үзенең фикеренчә, күкрәгенә җәүһәрләр тутырып килгән иде. Шакир мәхдүм, мулла булгач та, үзен белдерергә, халыкка үзене галим итеп күрсәтергә, ничек тә булса бер кәррә Җиһанша хәзрәтне сүзгә керештерергә, селкетергә уйлап йөри торгач, Җиһанша хәзрәтнең дәресенә керде. Дәрес бирә башлагач, бераздан соң Шакир мәхдүм аның бер сүзеннән элеп алды да селкеп салды. Җиһанша хәзрәт, җавапка кереште исә дә, ахырда үзенең тирәләп калачагын сизде; Шакир һаман да бар куәте берлә кычкырып, башын селкеп-селкеп, бармагыны Җиһанша хәзрәтнең күзенә төртеп-төртеп сөйли иде.

---

[1]*Праклар сатып* — үлгәч «теге дөнья»да сезгә канатлы атлар бирeләчәк дип алдалап.

[2]*Хафа кыла* — тынычсызландыра, борчый.

[3]*Кышкар* — иске мәдрәсәләре белән дан тоткан авыл. Хәзерге Татарстан республикасының Әтнә районында.

[4]*«Ханимелла», «Казый мирза»* — борынгы мәдрәсәләрдә дәрес китаплары.

[5]*Хашияләрне* — аңлатмаларны.

[6]*Мөҗадәлә* — сүз көрәштерү.

Шуннан соң Җиһанша хәзрәт бераздан соң сәгатен ачып карады да: «Чакырган җир бар, китәргә вакыт икән»,— дип, дәресне тәмам итеп, чыгып китте. Шакир мәхдүм, Җиһанша хәзрәтнең хәлен белеп, китеп барды. Шәкертләрнең дә зирәкләре эшне сизеп калды. Җиһанша хәзрәт бу хәлдән кылган фаразларына, корган планнарына Шакир мәхдүмнең каршы киләчәгенә төшенде.

Шакир мәхдүм дә, атасыннан калган бер кечек мәдрәсәсендә мәхәллә балаларын җыеп, үзенең кардәш-ыругларыннан берничә мулла балаларыны да китереп, дәрес әйтә башлады. (...)

Җиһанша хәзрәт һәм бу вакытларда тик ятмады; юлны башка як белән каплады. Әлеге ишанлык крепосте белән Шакир мәхдүмнең һөҗүменнән үзен саклады. Янә күп адәмнәрне үзенә мөрит итте. Эшләре янә алга китте.

Шакир мәхдүмнең мөдәррислеге озакка бармады. (...)

Тәмам тыныч кына бервакытта, ахыргы елларда Хәсән исемле бер мулла Җиһанша хәзрәтнең юлына каршы килде. Хәсән мулла үзе дә ачык фикерле бер мулла иде. Шул сәбәптән Җиһанша хәзрәтнең эшләрене, килешмәгән җирләрене халыкка берәм-берәм күрсәтте. Күп адәмнәрне үз фикеренә ияртте. Хәсән мулла яшь вакытта Җиһанша хәзрәт мәдрәсәсендә укып, ул мәдрәсәдәге кимчелекләрне төшенгәч, шәһәр мәдрәсәсенә китеп, анда да теләгәне рәвештә канәгатьләнмичә, чит мәмләкәтләрдә дә гизеп, ахырда авылына кайтып имам булган иде. Хәсән мулланың авылы Җиһанша хәзрәтнең авылыннан утыз биш чакрымда исә дә, ул тарафта Җиһанша хәзрәтнең мөритләре күп булганлык сәбәпле, аның барып йөри торган авылларыннан иде. Бу авылның атаклы байларыннан улан Искәндәр хаҗи да Җиһанша хәзрәтнең мөритләреннән һәм бик дус булып йөрешә торган адәмнәреннән иде.

Искәндәр хаҗи, Җиһанша хәзрәткә мөрит булса да, үз авылының мулласы — Хәсән мулланың атасы улан Хафиз мулланы да бик сөя, бер-берләре илә йөрешәләр. Хәсән мулланы да үз баласы кеби күрә иде.

Хәсән мулла бала вакытта Искәндәр хаҗиларга килә. Искәндәр хаҗи: «Минем мулла киявем килгән»,— дип көлә. Хәсән мулла, оялып, каршыларыннан чыгып китә иде.

Чөнки Искәндәр хаҗиның Фәхрелбанат исемле бик гүзәл бер кызы бар иде. Хәсән мулла, атасы алдында «кияү» дигән сүздән оялса да, аулак калган вакытларда Фәхрелбанат белән бакчада күзгә-күз карашып, сөйләшеп йөриләр иде. Чөнки иске заман гадәтенчә, Фәхрелбанатның сигез яшендә гакде никахы[1] улган иде.

Хәлбуки бу хәлләрдән хәбәрсез Җиһанша хәзрәт, Искәндәр хаҗиның кызына кызыгып, өченчелеккә алырга үзенчә беркетеп куйган иде. Фәхрелбанат исә, сигез яшендә Хәсән муллага никахы баглану сәбәпле, Җиһанша ишанның тозагыннан котылган иде.

Мартның ахырына карлар эри башлап, чокырларда сулар күренә; кар астындагы чүпләр, саламнар да — барчасы көннән-көн өскә күтәрелә, урамнарда җыелган сулар янында «кыйгак-кыйгак!» дип кычкырган каз тавышлары да ишетелә...

Бу дәртле көннәрнең берсендә иде ки, Искәндәр хаҗи һәм абзарга чыгып, кулына көрәк алып, җыелып торган суларны агызып йөри иде.

Бу вакытта Искәндәр хаҗиның колагына шалтыр-шолтыр тавыш ишетелде, капканы ачып карады; килеп туктаган тройканы, чанада утырган Җиһанша хәзрәтне күрде. Хаҗи, капканы ачып, хәзрәтне, каршы алып күрешкәч, өйгә алып керде. Искәндәр хаҗи хәзрәтнең хәбәрсез, чакырусыз килүенә гаҗәпсенде... Исәнлек-саулык сорашып чәй эчә башлаганда, Искәндәр хаҗи: «Хәзрәт! Сезне ничек болай җил ташлады? Кайда булса бардыңызмы?» — диде.

Җиһанша: «Юк... тугыры сезгә килдем».

Искәндәр хаҗиның соравына сәбәп шул: Искәндәр хаҗига Җиһанша ишанның килә торган вакытлары мәгълүм иде. Бер

---

[1] *Гакде никах* — никах акты, алдан ярәшеп кую.

мәртәбә — тәкәләр симергәч, бер мәртәбә — каз-үрдәк өлгергәч, бер мәртәбә сугымнар суйгач килеп, кунак булып китә торган гадәте бар иде.

Шундаен уйламаган бервакытта Җиһанша ишанның килүе Искәндәр хаҗины шөбһәгә төшерде.

Җиһанша ишан, һаман йомырка салырга йөргән тавык кеби йөренеп, сөйләгән вакытта әйтер бер сүзе бар кеби беленә иде.

Җиһанша ишанның мөритләре дә ишетеп ишан берлә күрешергә килделәр. Икенче көн өйләренә ишанны кертергә вәгъдә алып киттеләр.

Кич булгач, янә дә чәй эчәргә утырдылар, кунак бүлмәсендә ишан белән хаҗидан башка бер адәм юк иде. Чәй арасында шул сүзләр сөйләнде:

Ишан:

— ...агай мәчеттә күренмәде.

Хаҗи:

— Яшь кәләшне ташлап китә алмый торгандыр.

— Ул яшькә өйләндеме?

— Ул хәзер яшәрде...

— Яшь хатын яшәртә бит...

— Яшь абыстайны алгач, сез дә яшәргән идегез.

— Мин ул чакта яшәргән идем дә, хәзердә картая башладым, шул сәбәптән яңадан яшәрергә исәпләп торам...

— Хәзрәт! Алай булса яшәртик... Шәригатьтә дүрткә кадәр дөрес дисез бит.

— Шәригать икедән башлап дүрткә кадәр өйләнергә куша...

— Алай булса яшәртәбез.

— Хаҗи әфәнде, тугрысыны дисәм, минем яшәрмәкем синең кулыңдадыр. Әүвәл төшемне сөйлим дә соң үзегез дә аңларсыз.

Беркөн рамазан шәрифнең әүвәлге җомгасын укыдым да җомгадан соң зиратларга барып, ясин шәриф укып кайттым. Икенде вакыты керде, мәчеткә бардым. Икенде, ахшам укыгач, өйгә кайттым да, ифтар итеп[1], хөрмә ашадым. Соң бер мең

[1] *Ифтар итеп* — ураза ачып, авыз ачып.

тәһлил әйттем дә, тәһарәт алып, тәравихка бардым. Җәмәгать берлә ястү вә тәравих намазларыны әда кылгач[1], өйгә кайтып, бер хөрмә ашап, фәкать бер чынаяк су эчеп, укый килгән Коръәнем бар иде, шуны укыдым. Арыгач, баш очыма сырган чапанымны куеп кына йокларга яттым. (...)

Шул вакытта төшемдә бик һәйбәт чылтырап ага торган бер елганың буенда ямь-яшел чирәм өстендә булдым; дөнья йөзе яп-якты, кояш күтәрелеп зөха намазының[2] вакыты елгадан тәһарәтләндем. Суы көмеш кеби саф һәм дә татлы иде. Шул вакытта шәехем хәзрәтләре каршымда булды. Янында ак сакаллы, нурлы йөзле бер карт һәм бар иде. Һәр икесе берлә күрештем. Картның куллары йоп-йомшак, мамык кеби, бармагында сөяге юк иде. Шәехемнән ул картның кем улдыгыны сорадым, ул: «Хозыр галәйһиссәлам»,— диде. Ул карт та бәнем кем улдыгымны сорады. Шәехем: «Татарларның шәехләре өстендә баш шәех дәмелла Җиһанша бине Дәүләтшадыр... Татар галәмендә сезнең гаеп ирәннәр арасындагы котып мәртәбәсендә[3] улан адәмдер. Димәк ки, татарларның котыбидыр. Вә һәм үземнең хәлифәләремнең арасында иң сөеклесе вә бөеге улдыгыннан, үземнең ләкабемә[4], фамилиямә тоташтырдым, һәм дә... авылның Искәндәр хаҗи дәмады (кияве) булачактыр»,— диде. Карт: «Бәрәкалла»,— дип кычкырып җибәрде. Шул тавышка уяндым; һаман шул тавыш колагымда ишетелә. Янымда хуш исләр килә, бөтен җаным вә тәнем рәхәтләнә иде, бу төшемә бик гаҗәпсенеп, сөбханалла, дидем дә бик озак уйлап яттым. Сезне бик дус күргәнлегем сәбәпле кәримәгез[5] Фәхрелбәнатны да балам кеби сөя идем! Шул сәбәптән аның хакында бик кайгыртам. Яхшы, тәүфыйклы гына бер юлдаш бирсен дип, Хак Тәгаләдән сорый идем. Чөнки заманнар бозылды, яхшылар да азайды. (...) Шул сәбәптән бән сезгә килдем,

---

[1] *Әда кылгач* — үтәгәч.

[2] *Зөха намазы* — кояш чыккач укыла торган намаз.

[3] *Котып мәртәбәсендә* — «иң югары дәрәҗәдә» дигән сүз.

[4] *Ләкабемә* — исемемә.

[5] *Кәримәгез* — хөрмәтле кызыгыз.

Фәхрелбәнат ничә яшьтә? Бу изге эшкә кайчан керешергә, шуны сездән белмәкче, үземнең дә фикеремне сезгә белдермәкче, киңәш итмәкче булдым.

Хаҗи:

— Хәзрәт, минем кызым хәзердә бик яшь бит.

Ишан:

— Шәригатемездә яшь булса да никах дөрестер; үз арамызда никах кылырмыз да, вакытына кадәр үзегездә торып торыр. Кунакка килгән вакытларда гына күрешеп, сөхбәт кылырбыз[1].

Вакыты җиткәч, зөфаф[2] улыр, өемезгә барыр. Теләгән вакытында сезгә килер, шул рәвештә гомерене рәхәттә үткәрер. Бу эшкә, әлбәттә, үзе дә разый булыр... Бондай шәехләр арасында булган серләрне һәркемгә сөйләргә дә дөрес дәгелдер. Әмма сез минем иң якын, иң сөйкемле мөритләремнән булганлыктан, сезгә сөйләдем. Хәзрәте Әбүбәкер хәзрәте рәсүлгә ничек иде, сән дә бәңа шуның кеби иң якын дусларымнансың. Кызыңыз Фәхрелбәнат та хәзрәте Гайшә кебидер! Фәкать арамызда бернәрсә генә калды. Фәхрелбәнат бәнем никахымда була... Боннан башка тарафларыны үзеңез дә белерсез. Яхшы гына уйлап караңыз!

Хаҗи:

— Хәзрәт! Мин сезгә тугрысыны дисәм: минем кызым сигез яшендә икән вакытта сөекле бер егеткә шәригатьчә никах ителмеш, багланмыштыр. Хәзердә аның никахы үз ихтыярындадыр. Шул сәбәптән сезгә һич тә әйтер сүзем юктыр. Чөнки бәнем ихтыярымнан чыкмыштыр.

Ишан:

— Алай булса да Фәхрелбәнат ихтыярлыдыр, балига[3] булганнан соң теләгән адәменә бара белер. Сез минем хәбәремне дә анасы аркылы әйттереп караңыз! Мин үзем дә, аны вәгазьнәсыйхәт кылып, бер мәктүп язармын.

Хаҗи:

---

[1] *Сөхбәт кылу* — күрешеп, сөйләшеп утыру.

[2] *Зөфаф* — кыз янына кияү булып керү.

[3] *Балига* — үсеп җиткән кыз.

— Әйттереп карармын, хәзергә сабыр итеп торыгыз!

Ишан:

— Шәригать изге эштә ашыгырга куша...

Искәндәр хаҗи Җиһанша хәзрәткә вәгъдә бирмәде. Шулай булса да хәзрәт Фәхрелбәнаттан өметне кисмәде; хаҗида бер көн торып, өенә кайтып китте.

Бичара Искәндәр хаҗи шул дәрәҗәгә килгән иде: әгәр дә Фәхрелбәнат Хәсәнгә никах иделмеш булмаса, ишанга бирүендә шик юк иде...

Башка мөритләре булса, «бөек дәрәҗәләргә ирешәм» дип, хатынын сораса, аерып ишанга бирәчәкләр иде!..

Хәсән мулла, атасы урынына имам булгач, авыл халкына күп файдалы эшләр кылды: каенатасы Искәндәр хаҗидан мәктәп салдырып, мәчет вә мәктәп файдасына вәкыфлар куйдырып, мөгаллимнәр алдырып, яшь балаларга татарча уку-язу үгрәтеп, русча укыту хакында да ярдәм итте. Чөнки балалар кыш айларында җиде ай мөселманча укып, бер ай хәл җыеп, соң өч ай русча укып, янә бер ай рәхәт улдыктан соң, мөселманчаны укырга керешәләр иде. Уку-укыту хакында булган мәсарифнең[1] күбрәге Искәндәр хаҗиның кесәсеннән алынып, калганы мәхәллә халкының баерак адәмнәреннән җыелып алына иде.

Шул сәбәптән ошбу авыл халкы берничә елдан соң башка авылларга караганда яхшы гына алга киттеләр, яхшы гына көн иттеләр.

Иген иктеләр, сәүдә иттеләр.

Хәсән мулла һәр җомгада халыкны гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнагать[2] илә кызыктырыр; бу тугырыда Коръәннән һәм пәйгамбәремезнең тәрҗемәи хәленнән сөйләп, халыкка аңлатыр иде.

Бу авылда һәр атнада бер мәртәбә — базар, елда бер мәртәбә ярминкә була иде. Искәндәр хаҗи, Хәсән мулланың мәслихәт

---

[1] *Мәсариф* — чыгымнар.

[2] *Сәнагать* — һөнәрчелек; товар җитештерү; промышленность.

күрүе сәбәпле, базар янында бер чәйханә салдырган иде. Моның аты чәйханә булса да, асылда көтепханә иде. Бу көтепханәдә төрле китаплар булыныр; берничә русча газеталар вә бәгъзе мөселманча газеталар да килер иде. Ярминкә вакытларында күп адәмнәр керер. Төрле җирдән килгән адәмнәр булыныр. Китап-газеталар укырлар, бер-бере белән күрешеп, сөйләшеп утырырлар. Гүзәл бер гыйлем мәҗлесе кылырлар иде.

Базар көннәрендә ул чәйханәгә Хәсән мулла үзе дә керер. Чәйханәдәге адәмнәрнең барчасы илә күрешер. Газеталардан кирәк җирләрне халыкка укыр, аңламаган җирләрне аңлатыр. Халыкка сөйләр. Халык та чәйләрене куеп тыңлар иделәр.

Хәсән мулла надан муллаларны, риялы суфыйларны, ялганчы ишаннарны сөйми. Анлар хакында ачы вә үткен сөйли иде. Шул сәбәптән муллаларның күбесе Хәсән мулланы алдында мәхдүм хәзрәт дисәләр дә, артында «ахыр заман мулласы, трактирщик» дип әйтәләр иде.

Көннәрнең берендә, ярминкә вакытында, чәйханәнең залында Хәсән мулла вә башкалары: берсе — бер ишан угылы, икенчесе — Җиһанша ишанның шәкертләреннән, берсе — кырык яшьлек карт хәлфә вә берсе дә яшь фикерлеләрдән улан яшь хәлфә, болардан башкалары кайсы мөрит, кайсы мулла, кайсы сәүдәгәр, төрле җирдән килгән адәмнәр бар иде. Хәсән мулла кулына бер мөселман газетасы алып укый башлады. Газетада, идарәгә мәктүпләр кыйсмендә[1], берничә хәбәрләр язылмыш иде. Хәсән мулла шул хәбәрләрне укый башлады. (...) (Саратов, Түбән Новгород һ. б. губерналардан килгән бу хатларда кайбер ишаннарның кылган гамәлләре, сорыкорт булып яшәүләре язылa.— *Төз. Ш. С.*)

...Шуннан ишан угылы сүзгә кереште: «Менә мин үзем дә ишан баласы, атам берлә йөреп, мөритләре килгән вакытта атамның анларны ничек алдаганыны күзем берлә күрә киләм.

Бер кәррә атам мөритләре илә бер авылга бардылар. Авылдан барчасы бергә кайтырга юлга чыкканда, ярты юлга җиткәч,

---

[1] *Кыйсмендә* — бүлегендә.

атам мөритләренә: «Бер нәрсәм онытылып калган»,— дип, кире шул авылга кайтыр; мөритләре белми торган бер тугры юлдан китеп, өемезгә кайтыр да караватына ятар. Бервакыт мөритләр дә безгә кайттылар. Әткәмезнең аерылып кире киткәнен әйттеләр. Атларыны тугарып, өйгә керделәр. Ишаннарыны күреп, ни дияргә дә белмәделәр.

Бер кәррә атам берлә бер мөритенә кунакка бардык; капкадан кердек, абзарда кем дә юк; бер чебешле тавык чебешләрене ияртеп йөри иде. Шул арада атам бер чебешнең муенын борып коега бәрде; атамның бу эшенә мин дә бик гаҗәпләндем. Соң безне күрделәр, каршы чыктылар. Өйгә кердек, чәй хәзерләделәр, хуҗа үзе чәй ясап чынаякларны каршымызга куйды. Атам бераз чәй эчмәенчә торды да: «Бу чәйнең суын кайдан алдыгыз?» — дип сорады. Хуҗа: «Коедан алганнар»,— дип җавап бирде. Атам: «Бу су нәҗестер, башка су белән яңадан куегыз»,— диде. Шуннан соң башка су берлә куеп китерделәр; коеның суын түгеп карагач, коедан үлгән чебеш чыгып, халык барчасы хәйран калдылар.

Минем атам бәгъзе вакытта исерткеч эчә, кеше малыны да алудан курыкмый иде. Әгәр дә аңа каршы сөйләүчеләр булса: «Минем дәрәҗәм бөектер, һәр нәкадәр гөнаһ эшләсәм дә, минем дәрәҗәмә күрә юк хөкемендәдер!.. Диңгезгә күпме нәҗес төшсә дә нәҗесләнмәгән кеби, мин һәр нәкадәр гөнаһлар кыйлсам да, дәрәҗәмә күрә тузан кадәр дә улмаз...» — дия иде»,— дип сүзене бетерде. (...)

Сәүдәгәрләрнең берсе: «Беркөн безгә бер шәехнең мөрите кунарга килде. Кием тегүчеләребез дә бар иде.

Анлар янында кунарга боердык. Кич булгач, тегүчеләр кием тегә, мөрит йоклар өчен сәндерәгә менгән иде, сәндерәдә тегүчеләргә таба карап, йөзтүбән ятып, тәсбихын шылтыратып арып йокыга киткәч, төшендә каршысында бер диңгез күрә... Диңгезнең янында үзенең шәехе карап тора, имеш. Шәехтән: «Бу нинди диңгез?» — дип сорый. Шәех: «Мәгърифәт диңгезе»,— дип җавап бирә. Мөрит: «Чумаеммы?» — дип, каты тавыш белән илерә, мөритнең тавышын тегүчеләр ишетеп:

«Чум! Чум!» — дип көләләр, мөритнең колагына «чум!» дигән сүзләре керә; мөрит шәехтән әмер булды дип гөман идә. Шуннан соң мөрит: «Йә шәехем, сәндән мәдәд[1]»,— дип, сәндерәдән сикереп йөзе белән идәнгә егылып төшә. Тегүчеләр моны күрәләр дә идәннән күтәреп алалар, яңадан сәндерәгә мендереп яткыралар. Төшен үзеннән сорап, сәбәбен беләләр».

Шул рәвештә наданлыклар вә бозыклыклар хакында күп сүзләр сөйләнде.

Ахырда Хәсән мулла сүзгә керешге: «Һәркем белә торган сүз — «су баштан болгана!» (...) Авылларда халык арасында бозыклыклар күрәбез дә соңыннан карыйбыз шул авыллардагы имамнарга, боларда һәм бозыклык күрәбез дә уйлыйбыз. Боларга кайдан килгән? Соң китәбез аларның укып, тәрбия алып чыккан җирләренә: мәдрәсәләренә вә мөдәррисләренә!.. Аларда һәм тәртипсезлек вә тәрбиясезлекне күрәбез дә янә баягы «су баштан болгана» дигән сүзне кайтарып әйтәбез. Менә зур мәдрәсәләребезне мөдәррисләребез тәртипкә салсалар иде, шәкертләрне яхшы тәрбия итеп, фикерләр бирер өчен, мәдрәсәләрне һәр фәннән укытыр өчен яхшы тәртип күргән мөгаллимнәр алсалар иде.

Әлхасыйл, һәр нә улса улсын, яхшы имамнар вә мөгаллимнәр хәзерләсәләр иде, алар да авылларга чыгып һәркайсы үз мәсләгендә[2] иҗтиһад итеп, фикерләрен төзәтеп, балаларны яхшы тәрбия итеп, халыкны тугры юлга салсалар иде, ул вакытта, бәлки, бераз гына эшләребез төзәлер иде.

Менә иң әүвәл зур хәзрәтләр һәм ишаннарыбызда җитешмәгәнлекләр күренеп тора; мәсәлән, Җиһанша хәзрәт үзенең мәдрәсәсене тәртипкә салмый, хәтта мәдрәсәсендә күпме шәкерт бар идекеннән дә хәбәре юк; күп вакыт дәрескә керми, хәлфәләр дә укытамы, юкмы, аны күрми, шулай булгач, ул мәдрәсәдән кем чыксын? Аның шәкертләреннән ни чыксын?.. Эшләребездән бар көткәнебез корсак кайгысы улып, тугрылык

[1] *Мәдәд* — ярдәм, көч.

[2] *Мәсләк* — дөньяга караш, караштан чыгып алган юл, ысул.

өчен эшләгән эшебез һич юктыр. Мулла булабыз — бәлеш йиәргә[1], мөдәррис булабыз — исем җәяргә, ишан булабыз — мал җыярга... Муллаларыбызның каюсына гына карасак та, чыккач та бер кәррә мәдрәсә салып дәрес әйтергә керешә. Ләкин үзендә дәрес әйтерлек куәт бармы, юкмы, аны һич тә уйламый.

Җиһанша хәзрәт мәдрәсәсеннән күп шәкертләр чыгып мулла булдылар, бер мәчетле авыллар — ике мәчет, ике мәчетле авыллар дүрт мәчет салдылар. Һәр мәчеткә ике мулла, бер мөәзин куйдылар, үзләре дә Җиһанша хәзрәткә мөрит булдылар. Бер мәхәлләне бишкә аерсак, бер мулла урынына биш мулла куйсак та, безнең бу надан муллаларыбыздан эш чыкмас. Бонлар илә диннең куәте артмас. Безнең бу эшләребез, ягъни үзебез надан була торып, фәкать нәфесебез өчен халык өстендә баш булмакымыз яхуд арамыздан үзебез кеби бер надан кешене өстемездә баш кыйлмакымыз диянәт[2] дәгел, бәлки дингә хыянәттер.

Бер фәкыйрь мәхәлләне икегә аерып, бер мәчет салачак акчага бер мәктәп салсалар иде, икенче мулла алачак җиргә бер мөгаллим алсалар иде, яхуд ике мулланың берсе мәхәллә эшләрене карап, икенчесе мәктәптә мәхәллә балаларыны укытсалар иде, шул вакытта бераз гына хәлләребез төзәлер иде. Ишан хәзрәтләремез дә халыкка: садакаларыгызны гыйлем юлына бирегез! Авылыгызга мәктәп салдырыгыз! Укучыларга, укытучыларга ярдәм кылыгыз! Балаларыгызны укырга бирегез! Һөнәр-сәнаигъ мәктәбендә тәрбия итегез! Моннан артык саваплы эш юктыр, җәннәт акчасыны гыйлем юлына сарыф иткән адәмнәргәдер, дип, вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләсәләр иде, ишаннары өчен малларыны, җаннарыны аямаган мөритләрнең кабул итүләрендә шик юк иде.

Бездә исә гыйлем вә мәгърифәткә ихласлы мөритләр балаларыны укыту хакында ишаннарына киңәш итәләр; ишаннар исә һәркемне мулла итәләр. Шул рәвештә барчамыз мулла

---

[1] *Йиәргә* — ашарга.

[2] *Диянәт* — динлелек.

булдык. Ни кылдык! Халык телендә мәшһүр сүз: «Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?!» Шуның кеби, барыбыз да мулла булдык та, атымызга печән салмадык. Атларымыз арып, җәяүле калдык; теләгән җиребезгә җитә алмадык. (...)

Бала анадан туар инсан улып, әгәр дә инсан тәрбиясе бирелмәс исә, калыр хайван улып. Бала саф бер инсандыр. Үгрәтсәң, һәрнәрсәне белер; шулай булса да кабилият вә сәләхият[1] төрлечәдер; барча адәм мулла вә мөәзин түгелдер: бәгъзеләре мулла вә мөәзин исә дә, арада игенче, сатучы, язучы вә башкача һәртөрле һөнәргә сәләхиятле балалар бик күптер. Һәр балада үзенә аерым бернәрсәгә осталык буладыр. Бере иген игүче булса, башка бере сәүдә итүчедер, бере кием тегүче булса, башка бере дә итек тегүчедер. Бере көйләргә оста булса, башка бере дә сөйләргә остадыр. Бере язучы булса, башкасы даручыдыр. Бере атка менүче булса, бере суда йөзүчедер. Бере сурәт алучы булса, башка бере дә өйләр салучыдыр. (...) Кыскасы, һәр баланың үзенә аерым бер фәнгә, бер һөнәргә дәрте булыр. Әгәр дә баланың дәртенә тугыры килгән, үзе теләгән фән бирелмәс исә, баланың дәрте югалыр да ул фәннән дә, бу фәннән дә хәбәрсез улыр, адашып, юлсыз калыр...

Баланың нинди фәнгә, нинди һөнәргә дәрте барлыгыны белеп, шул фән яхуд һөнәр мәктәбенә бирелеп, гүзәл тәрбия дә иделсә, ул баланың шул фәндә беренче адәм булуында шөбһә юктыр».

Хәсән мулла сүзене шунда туктатты.

Карт хәлфә: «Җиһанша хәзрәт хакында сөйләгән сүзләрегез тугры дәгелдер, чөнки ул коры ишан гына дәгел, ишан һәм мөдәрристер. Ничә еллар дәрес әйткән, милләткә хезмәт иткән, мәдрәсә юк җирдә мәдрәсә ачкан, башкалар аның кеби эш күрсәтсеннәр, күреп карыйк», — диде.

Хәсән мулла: «Җиһанша хәзрәт вафат булдисә, шәкертләр таралыр, мәдрәсәләре буш калыр, мәхдүмнәре дә дәрес әйтерлек түгелләр. Җиһанша хәзрәт мәдрәсәләрне тәрбия өчен вакыфлар

---

[1] *Кабилият вә сәләхият* — булдыклылык һәм сәләтлелек.

тәгаен итеп калдырса иде, ул вакытта аны мактарга да ярар иде. Безнең мондый мәдрәсәләремез элек заманнардан бирле була килгән нәрсәләрдер. Бер әсаслы, ышанычлы шәйләр дәгелдер. Тычкан уты кеби, караңгыда якты, яктыда караңгыдыр. Җиһанша хәзрәтнең мәдрәсәсендәге тәртип вә ысул да иске заманнардагы чыра яндырып дәрес укыган вакытлардагы ысул вә тәртиптер. Ул заманнарда заһири[1] яктылыклар чыра берлә булдыгы кеби, мәгънәви яктылыклары да шуңа муафыйк ысул берлә иде. Хәзердә чыра заманнары үтмеш, шәм вә лампа заманнары да кичмеш, электрик заманнары килмеш. Мәгънәви яктылыклары да шул нисбәттә алга китмештер. Шуның өчен хәзердә безгә укыту хакында булган ысул вә тәртипләремезне ошбу электрик заманына тугыры китермәк тиештер. Җиһанша хәзрәтнең, халык каршындагы дәрәҗәсенә караганда, хезмәте һич юктыр. Мәхәлләсе Җиһанша хәзрәт килгән вакытта ничек надан иде, хәзер дә шулай ук».

Карт хәлфә: «Сез Бохара, Истанбул мәдрәсәләренә карыйсыз. Анларның тәртибе тәмам башка, анларның мәдрәсәләрендә һәркаюсына вакыфлары электән кала килгән була; мөдәррисләрнең жалованьелары килеп тора; әмма Җиһанша хәзрәтнең мәхәлләсе фәкыйрь, байлар аз, вакыф кылырдай адәмнәр юк, байлар да вакыф ни нәрсә — белмиләр. Җиһанша хәзрәткә жалованье юк, жалованьесыз-нисез шулай дәрес әйткәч, гаеп итеп булмый. Хәзрәт үзе халыктан ни файда күрде?»

Хәсән мулла: «Җиһанша хәзрәт, Бохарадан кайтып бу халыкка мулла булгач, бөек дәүләт иясе булды. Дәүләт исә кайдан килде? Хәзрәт игенме икте, югыйсә сәүдәме итте? Әлбәттә, барчасы милләт акчасыдыр; әйтергә мөмкин ки: милләт Җиһанша хәзрәтне өйләндерде. Өйләр, сарайлар салып бирде, йөзләп дисәтинә җир бирде. Яхшы киемнәр кидерде. Кош итләре йидерде, тройкада гиздерде. Кыскасы, милләт Җиһанша хәзрәтнең һәр сораганыны бирде; мәдрәсәнең вакыфы булачак акчалар вә җирләр — барчасы Җиһанша кулына керде. Чөнки

---

[1] *Заһири* — тышкы.

дөньясыннан вә ахирәтеннән хәбәрсез улан надан мөритләр Җиһанша хәзрәтне мөршиде камил, ягъни тугры юлга салучы бер милләт атасы дип белделәр...

Үзләрене вә малларыны Җиһанша хәзрәткә тапшырдылар; аннан тугры юлны сорадылар, ул ни кушса, аны кылдылар! Малларыны Җиһанша хәзрәт кушкан җиргә бирделәр. Балаларына да Җиһанша хәзрәт ни эшләргә боерса, шөйлә эшләделәр. Җиһанша хәзрәтнең юлыны пәйгамбәр юлы дип гөман иттеләр; эш Җиһанша хәзрәттә! Теләсә аларны үз нәфесе өчен корбан әйләсен, теләсә аларга тугры юлны күрсәтеп, алардан милләткә хезмәт иттерсен...»

Карт хәлфә: «Хәзердә сөйләүчеләр булса да, эшкә килгәндә эшләүчеләр күренми»,— диде.

Хәсән мулла: «Әүвәл сөйләргә, халыкның фикерләрене төзәтергә кирәк, фикерләре үзгәргәч, эшкә килгәндә эшләүчеләр дә булыр. Фикер үзгәрмәенчә, эш эшләнмидер. Шуның өчен дә халыкка фикер бирмәк бөек хезмәттән хисап ителер; иң бөек адәмнәр дә халыкка фикер биргән адәмнәрдер...» — диде. (...)

Хәсән мулла сүзен дәвам итеп аннан-моннан бераз башка сүзләр сөйләп утырганнан соң, алар белән күрешеп, чыгып китте.

Хәсән мулланың авылыннан өч чакрым ераклыкта, төшлек тарафында, төшлек тарафыннан төн тарафына ага торган су буенда Искәндәр хаҗиның су тегермәнедер. Суның кояш батыш тарафында, тегермән тугырысында, судан ерак түгел нарат агачлары арасында Искәндәр хаҗиның дачасы, дачада нарат агачыннан бик гүзәл итеп, төшлек тарафыннан төн тарафына озайтып салынган, түбәләре тимер белән ябылган яшел түбәле өйләре күренер. Суның кояш чыгышы тарафындагы яшеллекләр Искәндәр хаҗиның печәнлек вә болыннарыдыр. Өйләренең кояш чыгышы тарафында вә төшлек тарафында чыгып һәр тарафны күреп утырырга, чәй эчәргә, көйле уеннар уйнап, кошлар сайраганын тыңлап, күңел ачарга бик гүзәл балконнары да бардыр. Өйләренең төшлек тарафындагы очында, төшлек ягында өч тәрәзә, кояш батышында өч тәрәзәле кунак бүл-

мәсе, кунак бүлмәсе берлә янәшә төн тарафында бер тәрәзәле Фәхрелбәнатның бүлмәседер.

Югарыда сөйләгән идек. Җиһанша хәзрәт Фәхрелбәнаттан өметне кисмәде. Фәхрелбәнатка вәгазь-нәсыйхәт кылып, бер мәктүп тә язды.

Хәзрәтнең мәктүбе бик озын, укырга дәртсез булганлык сәбәпле, үзене язмаенча, фәкать мәктүптән аңланган нәрсәләрне генә язабыз.

Җиһанша хәзрәт мәктүбендә хәмед-салават соңында барча гыйбадәтне, руза вә намазларыны, тәсбих вә тәһлилләрене, тәһарәт, намаз соңында яткач күргән төшләрене, төшендә үзенең, икенче кат күктә булып, Хозыр галәйһиссәлам Фәхрелбәнат берлә икесенә никах укыдыгыны, үзенең дә пәйгамбәр урынында бер адәм улдыгыны, Фәхрелбәнатның да шундаен бөек адәмнәргә зәүҗә[1] булырга тиешле бер кыз улдыгыны... язмыш. Әлхасыйл, мөритләре берлә аулак калганда анларны үзенә каратыр өчен алдаганда сөйли торган сүзләре берсе дә калмаган иде. Фәхрелбәнатка Җиһаншаның мәктүбе тапшырылмастан элек, Хәсән мулла илә Фәхрелбәнатның зөфафлары булган иде.

Фәхрелбәнатның Җиһанша хәзрәткә язган мәктүбе:

«Шәйхе Җиһанша хәзрәтләренә! Мәктүбегезне укыдым. Үзегезнең пәйгамбәр мәкаменда[2] бер адәм улдыгыңызны бәян әйләмешсез. Вә безне дә бик югары күтәрмешсез! Бездә андый хасиятләр юктыр, гадәтчә генә бер кешебез. Бездә сезнең кеби икенче кат күкләрне сәер иткән[3] адәмнәр илә сөйләшерлек гыйлем дә юктыр.

Ничек булмасын, бән үземә Хәсән әфәндене ихтыяр әйләдекемнең сәбәбене сезгә язам: бәнем әткәм илә Хафиз хәзрәт икесе дус иделәр. Хафиз хәзрәтнең угылы Хәсән мәхдүм илә без дә яшь вакытыбызда бергә уйнап йөри идек, һәрвакытта бер-беребез илә без дә күрешеп, хәлебезне белешеп, карендәшләр кеби яши идек, бән аны агам кеби, ул да бәне үзенең сеңеле кеби якын күрә иде; ул бәннән алты яшь бөек улдыгыннан, бән дә аңа караганда кечек бер бала идем. Хәсән мәхдүм ундүрт яшькә җитте, мәдрәсәгә укырга китте. Бераздан Хәсән мәх-

---

[1] *Зәүҗә* — ир хатыны.

[2] *Пәйгамбәр мәкаменда* — пәйгамбәр урынында.

[3] *Сәер иткән* — «гизгән, йөргән» мәгънәсендә.

дүмне кайтарып, Хәсән әфәнде илә арабызда гакде никах идеп, аталарыбыз безне бер-беребезгә бағладылар; фәкать, яшьлегебез сәбәпле, зөфафыбызны үз ихтыярыбызга салдылар; чөнки бән ул вакытта сигез яшемдә генә идем. Соң бу эшне һәр икебезгә белдерделәр. Хәсән әфәндегә дә безгә килергә, бәнем илә бергә йөрергә рөхсәт бирелде. Шуннан соң без йөрешә башладык. Ул мәктәптән кунакка кайта, күрешергә килә, бергә чәй эчә идек, сер сүзләребезне сөйләп утыра идек. Шул рәвештә электән үк бер-беребез илә гүзәл таныштык.

Бервакытта Хәсән әфәндем шәһәр мәдрәсәсенә китеп, берничә еллар торып кайтты; күп вакытлар аерылып торсак та, мәктүпләр язышып, хәлләребезне белешеп тора идек. Менә бу ел әткәм илә әнкәм, Хафиз хәзрәтләргә киңәшеп, Хәсән әфәндене кунакка чакырдылар; анам һәм дә атамның кыз карендәше һәр икәвебез юлдаш вә сердәш булып гомер итәчәгебезне сөйләделәр. Фәкать бәнем өчен хәзердә Хәсән әфәндене үземә ихтыяр итеп, тәҗдиде никах[1] *кылдырмак тиеш улдыгыны да сөйләделәр дә тәбрик итеп хәер-дога иттеләр.*

Шул хәлдә әткәм һәм әнкәм бәне Хәсән әфәнде илә күрештереп, хәзер дачага озатачакларыны сөйләделәр. Шуннан соң Хәсән әфәндем берлә икәү арбага чыгып утырдык. Әткәм илә әнкәм: «Аллага тапшырдык»,— дип озатып калдылар. Озак та үтмәде, дачабызга җиттек, дачадагы өйләребезнең кунак бүлмәсе янында бер бүлмә безнең өчен хәзерләнеп куелган иде. Кунак бүлмәсенә кердек, балхунга[2] *чәй хәзерләгәннәр иде, Хәсән әфәндем берлә балхунда чәй эчәргә утырдык. Кояш чыгыш тарафына бераз күзебезне салдык: тегермән буасы көзге кеби ялтырап күренә, тирәсендәге яшел таллары да акрын искән җил берлә иренеп кенә селкенәләр иде. Су өстендәге казлар, үрдәкләр, хәтфәдән ясалган йомгаклар кеби балалары илә, суны һич тә селкетмәенчә, акрын гына рәхәт-рәхәт йөзәләр иде. Суның аргы ягындагы яшел чирәмнәр вә печәнлекләр дә күңелгә шатлык бирәләр иде. Судагы бакалар, корыдагы бөдәнәләр вә тартарлар — барчасы безнең куанычыбызны күреп, куанып кычкырышалар; сандугачлар да, көйгә осталыклары сәбәпле, аларны узарга тырышалар. Чәй эчтек, чәйдән соң төшлек тарафындагы балхунга чыгып, кояш батыш тарафына карап утырдык, кояш бата торган җирдә сыек кына болыт бар иде. Зур алтын шарга охшаган кояш, болыт астына кергәч, гаять тә олуг, ал, кызыл алма кеби бигрәк тә гүзәл булып күренә иде.*

Хәсән әфәнде, кояшның җирдән нихәтле ерак улдыгыны, җирдән ничә дәрәҗәдә зурлыгыны, кояш безнең күзебездән югалгач, Америкада кояш чыгып, көн булачагыны, бездә кояш чыккач, Америкада кояш

---

[1] *Тәҗдиде никах* — никах яңарту.

[2] *Балхунга* — «балконга» дигән сүз бозып әйтелгән.

батып, төн булачагыны бәңа сөйли иде. Бән дә, бу кеби сүзләрне тыңларга сөйгәнлегемнән, һәм дә бу сүзләр гүзәл бер егетнең кара ефәк кеби мыеклары астыннан, кызыл гөл чәчәге кеби иреннәре арасыннан чыкканга, чын күңелем берлә тыңлый идем. Кояш, безнең берлә исәнләшеп, Америкага китте... Без дә йокы булмәсенә кердек.

Сезнең күргән төшләреңезгә безнең кеби кыска гакыллы адәмнәрнең гакылы җитешә алмыйдыр. Без уйлаганча, төшеңез чын төшкә охшамыйдыр. Тәһәҗҗет намазыннан соң исә дә, ул көн күп ашта булганлыгыңыз сәбәпле, ашыңыз сеңеп бетмәгән, күңелләрегез дә сафланып җитмәгән булырга кирәк! Чөнки сезнең лә безнең арамызда никах булганы юктыр һәм булачак дәгелдер.

Булган никах исә Хәсән әфәнде илә бәнем арамда улмыштыр. Җәнабе Хак Тәгалә барчамызның күңелләремезне саф, фикерләремезне тугры, фигыльләремезне дә төз итеп, кичә вә көндезләрдә вәсвәсә[1] бируче шайтаннарның шәрреннән[2], ялган төшләрдән мөхафәза[3] әйләсен! Амин! — диярәк сүземне бетердем.

Фәхрелбәнат»

Фәхрелбәнаттан бу мәктүпне алгач, Җиһанша хәзрәтнең өмете бетте. Шуннан соң берничә еллар үтте. Фәкать ике абыстай берлә генә гомер итте. Фәхрелбәнат та хәтереннән чыкты. Мәхдүмнәре вә мәхдүмәләре дә күп иде. Анлар да бере артыннан бере җитте; Җиһанша хәзрәт өченче остабикә алуны тәмам онытты. Күңеленә башкача кайгылар төште: мәдрәсәләрнең тәртипсезлеге, шәкертләренең, мәхдүмнәренең тәртипсезлеге хәзрәтнең башына күп бәлаләр китерде... Ничә меңләп адәмне юлга салмак дәгъвасында булган Җиһанша хәзрәтнең өй эчендәгеләрне дә юлга салырга кулыннан килми торган бер булдыксыз адәм икәнлеген заман күстәрде. Хәзрәтнең үзе ясаган тар юлы бу заманга ярамас улды; соңыннан бу юлга хәзрәт үзе дә сыймас улды. Җиһанша хәзрәт, үз юлына сыймый башлагач, акрын-акрын юлыны киңәйтә иде. Киңәйтә-киңәйтә бәгъзе эшләре шәригать юлыннан да чыгып китә иде.

Мәхдүмнәр дә, бере артыннан бере үсеп, егет булдылар. Мәхдүмнәрне аздыралар дип, берничә шәкертне мәдрәсәдән куып та

---

[1] *Вәсвәсә* — аздыру, начар юлга өстерәү, котырту.

[2] *Шәр* — явызлык.

[3] *Мөхафәза* — саклау.

карады. Алай да дөнья төзәлмәде. Мәхдүмнәре һаман да азган өстенә азды. Хәзрәтнең башына күп бәлаләр килде. Мал вә дәүләткә дә урыннар күбәйде: бер мәхдүме исереп кайтканда урамда егылып, аны мужиклар тотып китергәннәр; икенче мәхдүм исергән дә бер мужикны кыйнап, ул мужик мәхдүмнең өстеннән прошение биргән; вә бере дә бер шәкертне сугып башыны тишкән. Шәкертләр исә җыелып мәхдүмнең өстеннән хәзрәткә шикаятькә[1] килгәннәр; бер тарафтан асрау кыз йөкле булган... Икенче тарафтан мәхдүмәгә бер шәкерт мәктүп язган, аны асрау кыз да белгән! Хәзрәтнең дә башыннан тәмам гакылы киткән иде! (...)

Бер тарафтан Хәсән мулла, Җиһанша хәзрәтнең мәдрәсәләренең тәртипсез, шәкертләренең тәрбиясезлегеннән бәхәс итеп, халыкка сөйләмәктә, бәгъзе шәкертләре дә газета вә рисаләләр[2] укып, үзләренең кимчелекләренә төшенеп, качып китмәктә, анлардан: «Безне гыйлемнән мәхрүм иттең, юлдан адаштырдың!» — дип язылган мәктүпләр килмәктә иде. Үзенең мәхдүмнәре дә: «Безне инсан итмәдең! Кирәк кадәр тәрбия бирмәдең! Безне югалттың! Алла сәне югалтсын!..» — дия, дәгъвалашмакта иделәр.

Тора-бара Җиһанша хәзрәт ахыр гомерләрендә бер мәхдүмне үз урынына мөдәррис итте вә берсенә ишанлык бирде. Үзенең дә башыннан үткән эшләренә төшенде, аз гына булса да җәзасыны да күрде! Ахирәттә хәлем ничек булыр икән диярәк кайгырта-кайгырта, дөньядан да китте. Мәхдүмнәре кайсы ишан, кайсы мулла булды; башкалары да кайсы анда, кайсы монда таралды. Надан булса да атасы урынына мөдәррис булган угылы, шәкертләрне атасыннан калган хәер-дога берлә юатып, бәддога берлә куркытып, берничә еллар тотты; соң ул да, хәер дога вә бәддога кошлары да картайды; шәкерт таралды; мәдрәсәләрнең иске биналары калды... Чәукәләр, күгәрченнәр оя ясады; түбәләреннән ягмур үтеп, почмаклары җимерелеп, түбә-

---

[1] *Шикаятькә* — жалоба беләи.

[2] *Рисалә* — мәкалә; кечкенә китап, брошюра.

ләре тишелеп бетүе мәхәлләнең ямене китәреп, күргән кешеләрнең күңелләренә кайгы китереп торалар иде.

Караңгы төннәрдә бәгъзе җирләре бердән җимерелеп, үтүчеләр дә аны ишетеп, кайсыбер куркак адәмнәр куркынып хәстә булалар, бәгъзе адәмнәр дә төн заманнарында, куркынып карагач, төрле нәрсәләр күрәләр, «җеннәр иялəшкән» дип гөман итәләр иде. Балалар исә, мәдрәсә хакында сөйләгән сүзләрне ишетеп, мәдрәсәне җен оясы дип гөман итәләр... Аналары: «Сезне мәдрәсәгә җибәрәбез!» — дисәләр, шул сәгать балаларның хыялларына Җиһанша хәзрәтнең мәдрәсәләре күренеп, бердән куркынып китәләр иде. Шул сәбәптән бу авыл халкы балаларыны көч-хәл берлә, акыртып-бакыртып, мәктәпкә илтәләр иде.

ЭЧТӘЛЕК

Төзүчеләрдән 3

Борынгы һәм урта гасыр әдәбияты

Борынгы төрки рун язмалары үрнәкләре 5
Мәхмүд Кашгарый. Диване лөгатет-төрк 9
Йосыф Баласагунлы. Котадгу белек 12
Әхмәд Ясәви 22
Сөләйман Бакырганый 24
«Коръән»нән тәфсирләр 28
Кол Гали. Кыйссаи Йосыф 31
Котб. Хөсрәү вә Ширин 78
Бәркә Фәкыйһ 83
Харәзми. Мәхәббәтнамә 86
Хисам Кятиб. Җөмҗөмә солтан 88
Кисекбаш 90
Әхмәд Үргәнчи 95
Мәүла Казый Мөхсин 98
Мәхмүд Болгари. Нәһҗел-фәрадис 100
Сәйф Сараи. Гөлестан бит-төрки 104
Сөһәйл вә Гөлдерсен 125
Идегәй 134
Сайяди. Бабахан дастаны 138
Хәсән Кайгы 140
Мөхәммәд Әмин 141
Колшәриф 143
Шәрифи. «Зафәрнамәи вилаяти Казан» әсәреннән 145
Өмми Кәмал 147
Мөхәммәдьяр. Төхфәи мәрдан 151
Нуры содур 156
Мәүла Колый. Хикмәтләр 163
Береккәнләр сыйфаты 174
Габди 176
Мәҗмугыл-хикаят 178
Габдессәлам 181
Габдерәхим Утыз Имәни 182

XIX йөз әдәбияты

Рус-француз сугышы бәете 195
Әбелмәних Каргалый 197
Үзе турында 197
Туган ил 198
Сәяхәтләрдән кайтканда 198
Әсирлеккә төшкән дусты — казый турында уйлану 198

Мөнаҗәт 199
«Бөтен дөнья бәнем булса...» 200
Сәхрада 200
Һибәтулла Салихов 201
Әбелмәнихнең «Тәндә җаным...» шигыренә 201
«Мәҗмәгыл-адаб» китабыннан 202
Шәмседдин Зәки 206
«Һай, нә оерсән?!» 206
«Бу сүз(н)е кәгазь(г)ә язмак кирәкдер» 206
«Эстәсәм, галәмдә...» 207
Габделҗәббар Кандалый 208
Мулла белән абыстай 208
Онытмам сез наданнарны! 209
Сахибҗәмал 210
Бу хәсрәтләр бетәр микән? 216
«Иген икмәк...» 216
«Якутлар табыладыр...» 216
Каюм Насыйри. Хикәятләреннән үрнәкләр 218
Муса Акъегетзадә. Хисаметдин менла 226
Заһир Бигиев. Мәңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә 268
Зур гөнаһлар 322
Гали Чокрый. Шәмседдин Зәки турында 366
Шиһабеддин Мәрҗани турында 366
Борынгы Болгар турында 367
Казан һәм аның халкы турында 368
Фаслы кыш 369
Фаслы яз 369
Яков Емельянов. Ярлы тормыш 371
Кайгы 371
«Көн дә ызгыш...» 373
Әләк 373
Саран бай 374
Олысыманлык 374
Мифтахеддин Акмулла. Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе 375
«Иң әүвәл кирәк нәрсә...» 379
«Бирелдем мин яшьлегемдә...» 380
«Халь килсә, төрле фәнне...» 381
Габдрахман Ильяси. Бичара кыз 382
Фатих Халиди. Рәдде бичара кыз 391
Ризаэддин Фәхреддин. Әсма, яки Гамәл вә җәза 410
Фатих Кәрими. Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы ... 443
Закир Һади. Җиһанша хәзрәт 457

Учебное издание

Составители:
Миннегулов Хатип Юсупович
Садретдинов Шайхелислам Аляветдинович

ХРЕСТОМАТИЯ ПО ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ

Для 9 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Төзүчеләре:
Миңнегулов Хатыйп Йосыпович
Садретдинов Шәйхелислам Әләветдинович

ӘДӘБИЯТТАН ХРЕСТОМАТИЯ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
9 нчы сыйныфы өчен

Өченче басма

Редакторлары *Т. Р. Шакирова, Г. Г. Мөхәммәтҗанова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Р. А. Сәйфуллина*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректоры *Т. Н. Сәгъдуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.03.2005.
Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 31,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап
табагы 23,40 + форз. 0,39. Тиражы 16 000 д. Заказ К 5/43.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

420111. Казань, ул. Баумана, 19.
ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».

Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш иялəр һәрвакыт белемлегә.

Утыз Имәни.
XVIII—XIX йөз